ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2004



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ



*Хәзерге Ирек мәйданы урынындагы Казан шәһәр театры.*
*XX гасыр башы.*



*XX гасыр башы Болак күренеше.*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2004*

**5**

**(979)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Шәүкәт ГАДЕЛША. "Синдә, Себер, туган ягым... Шигырьләр. .......... 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. Роман. .......... 8
Җәүдәт СӨЛӘЙМАН. Нәфес күге. Шигырьләр. .......... 80
Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Акыллы атын мактар. Романнан өзек. .......... 84
Рөстәм МИНГАЛИМ. Янударым,көюләрем... Шигырьләр. .......... 121
Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Табигать хозурында. Шигырьләр. .......... 124
Владимир ЛАВРИШКО. Күңел дулкыннары... .......... 127

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Мирза МӘХМҮТОВ. Мәгълүмати көрәштә мәдәнилек. .......... 131

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Рафаэль МОСТАФИН. Чорлар чатындагы үзгәрешләр .......... 131

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 70 ЯШЬ**

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН. Күренекле галим,әдип, җәмәгать эшлеклесе. .......... 151
Миркасыйм ГОСМАНОВ. Алтын Урда: Башлангыч һәм мирас. .......... 151

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .......... 169

**СӘНГАТЬ**

Сәхнә бәхете. *(Мәнирә Булатовага 90 яшь.)* .......... 172

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Фәнзаман БАТТАЛ. Шигырьләр .......... 179

**НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ**

ЙОЛДЫЗ. Шигырьләр. .......... 181

Укучы сүзе. .......... 183
Берлекнең яңа әгъзалары. .......... 185
"Казан утлары" архивыннан. .......... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .......... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Ф. САДРИЕВА "Счастье несчастных" (продолжение); отрывки из романа К. МИННИБАЕВА "Мудрый похвалит коня"; эссе В. ЛАВРИШКО; стихи Ш. ГАДЕЛШЫ, Дж. СУЛЕЙМАНА, Р. МИНГАЛИМА, В. ФАТЫХОВА.
"Публицистика": статья М. МАХМУТОВА "Культура в информационной войне".
"Дискуссия": "Герой нашего времени": статья Р. МУСТАФИНА "На стыке времен".
"Наука": к 70-летию М. Усманова статья Дж. МИННУЛИНА "Ученый, литератор, общественный деятель"; М. УСМАНОВ. "Золотая Орда: начало и наследие"; А. ТИМЕРГАЛИН."Словарь нации".
"Искусство": "Счастье сцены" (к 90-летию М. Булатовой).
"Юмор-сатира": стихи Ф. БАТТАЛА.
"Мир малышей": стихи ЮЛДУЗ.
"Слово читателя."
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Утро Казани"—фотоэтюд Н. ИСМАГИЛОВА; поэт М. МИРЗА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

Prose and poetry: F. SADRIEV novel "Happiness of the unfortunates" (continuation of trilogy); fragments from K. MINNIBAEV novel "The wise will praise a horse;
Essay by V. LAVRISHK; verses by S. GADELSHY', Dj. SULEIMAN, R. MINGALIM, V. FATYHOV.
Publicism: article by M. MAHMUTOV "Culture in information war".
Discussion: Hero of our time: article by R. MUSTAFIN "On a joint of times".
Science: to M. Usmanov's 70-anniversary article by Dj. MINULLIN "Scientist, writer, public figure"; M. USMANOV. "Golden Horde: beginning and heritage"; A. TIMERGALIN. "Dictionary of the nation".
Art: "Happiness of a stage" (to M.Bulatova's 90-anniversary).
Humour—satire: F. BATTALA verses.
World of kids: verses by YULDUZ.
Word of the reader.
From a photoarchive of magazine.
Diary of a public—cultural life.
On our covers: (Morning of Kazan) photo of N. ISMAGILOV;
Poet M. MIRZA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 19.04.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8014. Заказ Э—288
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.



**Шәүкәт Гаделша**

## СИНДӘ, СЕБЕР, ТУГАН ЯГЫМ

### Соңладым

**Өстә атлар кешни. Ишетелә күк**
**Безнең ханлык исән заманнан.**
**Нинди атлар? Күпме алар? Күпме?**
**Ниндидер егетләр атланган...**

**Текә ярны тырнап үрмәлимен,**
**Тамырларга тешне батырам.**
**Хәлсез кемдер берәү мыжлап-гыжлап**
**Ишеп килә кебек артымнан.**

**Мыгырдана: "Яр бит—текә, биек.**
**Акыл күзең агып чыкканмы!**
**Җитмәдеме безгә кырылулар.**
**Ходай "пылтаерга" кушмады.**
**Җаннар санап, барлап мавыгырга**
**Кемнән рөхсәт килде татарга?"**

**Этеп, тибеп карыйм—менә һаман,**
**Пычагым бар-барын... Кадарга?**
**...Менеп баскач туры яр өстенә,**
**Чымырдатып күзне йомамын.**
**Күрәм бер-ике ат һәм аларның**
**Ялкау гына чебен куганын...**
**Әрвах белән озак тарткалашып**
**Соңлаганмын. Ай-яй, соңладым!**
**Күрми калдым Себер татарының**
**Ничәмә төмәнлек угланын.**

---

Шәүкәт ГАДЕЛША (1949) *—шагыйрь, "Ярык мөгез", "Аучы жыры" һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Тагын берничә иртә...
Күрмәбез сабыр талны:
Кортлар дөньясы эчтән,
Төптән кимерә аны.

Агач сер бирми әле—
Гөрләп, талпынган була.
Кочаклыйм дип, каенга
Сузылып, кагылган була.

Котылгысызлыклардан
Безме ул—каушап калган?
—Кунма, аударырсың!—дип,
Песнәкне куам талдан.

***

Үлән коры—тузанлана
Кырмыска йөгергәндә...
Елан теле җиленнән дә,
И Хода, төтенләнә.

Сөбханалла! Күз—шундый сак!
Аңны ярырдай булган.
Зур үрмәкүч миңа, бәйләп,
Кай ара ятьмә корган.

Ак күбәләк канатлары
Ятьмәдә леп-леп итә.
Битарафлык чак тирбәлеп
Кайдандыр әмер көтә.

Мылтыгымны сыйпап-сөртеп,
Нигәдер кулга алдым.
Аh, үрмәкүч көпшәгә дә
Корган бит ефәк авын.

...Үтәмәм бернинди әмер—
Көн шулай калсын әле.
Сагаю артындагы аң
Үзен аңласын әле.

## Чалгы

Бер селтәдем: койдым үлән чыгын.
Бер селтәдем: кыйдым чәчәк чугын.

Оныткамын—булмый... кылтырый тал.
—Чалгы килә! Уйный! Сикереп кал!

Черкиләрне куырып йөзем яна,
Тәнне кайнарлатып тирем тама.

Күреп каушавымны, күрше көлә.
Үртәләмен, ярсыйм—ачу килә.

—Чалгың, күрше, кире—үзең кебек.
Сына калса, миңа кубыз чүкик:

Бер төндә ук бетеп кирелеге,
Кылтырап, кырык кылга керер иде.

Нәкъ минемчә, сузып, моңланыр ул.
Көйләп борынгы көй, сызланыр ул...

Шунда чалгы кычкырды кук: "Җитте!"
Җиңел генә алга чабып китте.

## Үлемне уйлаганда

Нинди садә яктылык!
Күз чытырдый урамда!
Ниемә соң бу балкыш,
Җирдә үлем булганда.

Әмма нидер күңелне
Чеметә—өнди атларга.
Ерак Баба көтә күк
Тире түшәп ак карга.

Мондый уйлар кергәчтен
Атламыйча бит булмый.
Тере килеш туналган
Җәнлек сыман җил улый.

Чүктерерләр бабалар
Мине нинди тирегә?
Аккамы? Карагамы?
Ничек башны иергә?

Тагын кар ява... Аңа—
Явасы да явасы.
Калкулыклар һич бетмәс—
Калка тора яңасы.

***

Аз күренә урманнарда
Каеклык юан агач—
Ни терәтер күгебезне,
Куаклар гына калгач?

Яр буена чал дулкыннар
Бәрелә килеп-китеп.
Учагыңны өскә менеп
Ялап алырлар кебек.

Учак якмасак та ярый—
Ясыйк без яңа каек.
Каекка бер ир утыртыйк:
Ул булсын батыр, аек.

Әкияттән тылсымлы ут
Авылга табып кайтсын.
Йокымсыраган ир-егетнең
Тән-күкрәгенә бассын.

И якташым, селкен, ашык—
Елмаеп кына калма!
Соңгы юан агачларга
Ятлар көйдерә тамга.

...Ни көтә, ни эзли судан
Моңсу күзләрең синең?
Әллә батыр яткан кисмәк
Ярга кагылыр, димсең?

***

Аңкып куйса яңа тоткан балык исе,
Чыкта юешләнгән дары исе,
Аллабыздан бик үтенеп сораганын
Оныта да куя минем ише.

Шунда әз-мәз аңкып куйса карлыган да,
Бер яшь кыз да күзен кысса... тагын,
Рәхәтлеккә чыдый алмый, җаным чыртлап,
Үләм инде, синдә, туган ягым!

**Фоат Садриев**

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

9

Миңзаһит инде менә кайчаннан бирле бер утрау эчендә бөтерелә. Тирә-юнен томан каплаган кебек, зәңгәрсу элпә еленгән. Ул элпә вакыт-вакыт ачылып китә, элеп куйган кер кебек, селкенеп тора, ләкин беркая да күчми. Миңзаһит, шушы аңлаешсыз элпәнең ачык урыннарыннан атлап, эш урынына ашыга. Аның эш урыны утрау уртасындагы биек тауның очында, әмма ул анда һич тә менеп җитә алмый. Утрау үзе дә каядыр йөзеп бара кебек. Аның тирә-юнендә нәрсәдер дулкынланып тора, җыерчыкланып кайный, күктә болыт урынында нәрсәләрдер йөзә. Аларны җентекләп карагач, Миңзаһит байракларга охшата. Нишләп болай, бу нинди урын, биредә ул нишләп йөри?—Һич тә аңлый алмый. Күрәсең, аның җитәкчелегендә нидер төзелә, кешеләр йөгерешә, диварлар салалар, балчык, измә, кирпеч ташыйлар. Миңзаһитның үлеп эчәсе килә, ул һаман әлеге тау башына күтәрелмәкче була, ләкин аның юлын бүләләр, нидер сорыйлар, ул ашыгып тагын атлый, аны тагын туктаталар. Шул чак каршысына сакаллары күкрәгенә төшеп торган, зур гәүдәле бер адәм чыга, русча аңа үзе артыннан барырга куша, Миңзаһит карыша, теге кеше аны кулыннан тотып сөйри һәм тауның киртләнеп торган бер урынындагы тишегенә алып кереп китә. Куыш эченнән шактый баргач, теге адәм, кулына көрәк алып, аяк астындагы җирне казый башлый, аннан гарәп язулы нindидер гипс һәм җиз плитәләр алып Миңзаһитка тоттыра. Миңзаһит ул плитәләрнең җиңеллегенә, җылылыгына хәйран кала. Казый торгач, теге кеше бер-бер артлы зур пергаментлар сөйрәп чыгара. Аларда язылган гарәпчә сүрәләр, аятьләр моңлы тавыш чыгара башлыйлар. Миңзаһит аларга колагын якынайта, чыннан да һәр хәрефеннән, һәр сүзеннән йөрәкләргә үтеп керерлек моң ишетелә. Миңзаһит куркынып куышның үзләре кергән ягына күз сала. Аның авызыннан күк гөмбәзе, кешеләрнең үтеп-сүтеп йөрүе шәйләнә. Аларны күргәч, Миңзаһитның күнеле бераз тынычлана. Теге урыс аны плитә-пергаментларны тоткан килеш тагын эчкәрәк сөйри,

*Дәвамы. Башы 4 санда.*

атлаган саен куыш карангылана бара. Теге монлы тавыш та ерагая. Инде кап-карангы булды дигәндә, алда бер шәүлә күренә, анардан сизелер-сизелмәс яктылык бөркелә. Минзаһит үзенең ялгыз калганлыгын, ә теге шәүләнең хатын-кыз икәнлеген күрә. Озын чәчле бу хатын аның кулындагы пергаментларны, плитәләрне алырга тотына, ул нәрсәләр берәм-берәм югарыга очып китәләр. Шул чакта Минзаһит бу хатынның ярым шәрә икәнлеген күрә, аның гәүдәсе шундый матур, сылу.

—Арыдыңмы?—ди хатын ягымлы тавыш белән.

Минзаһит аның тавышының таныш булуына хәйран кала, ләкин кемнеке икәнен белә алмый, йөзен дә ачык күрә алмый.

—Су эчәсем килде,—ди Минзаһит.

Хатын кычкырып көлеп җибәрә һәм Минзаһит аны аермачык күреп ала: бу бит Сөембикә! Ул каядыр йөгерә, Минзаһит аның артыннан ташлана, кычкырмакчы була—тавышы чыкмый. Ул арада Сөембикә, иртәнге томан кебек эреп, аның күз алдында юк була. Шул чак куышның барлык җире көзгегә әверелгән, имеш. Минзаһит мангаенда ниндидер тирән җыерчык барлыгын күреп хәйран кала. Көзгегә ныграк иелеп, җыерчыкны бетермәкче булып, ул кулы белән ышкый, әмма җыерчык тирәнәя генә бара. Ул аска карый, көзгедә үзенең йонлы сыйракларын күрә һәм куркып уянып китә.

Бу төш көне буе Минзаһитның күз алдына килеп, гел күнелен бимазалап торды. Кичке якта ул Сөембикәне чакыртты. Сөембикә кергәндә, инде эш сәгате тәгәлләнгән иде. Минзаһит кабул итү бүлмәсендә утыручы инструкторга беркемне дә кертмәскә кушты.

—Якынрак кил,—диде ул читкә утырган Сөембикәгә.

—Ярар шушыннан да.

—Юк, ярамый. Каршыма утыр әле.

Сөембикә аның сүзенә буйсынды. Аның каршында элекке Арсланов түгел иде. Бизгәк белән авыргандай, бармаклары калтырый, күз төпләре күгелҗемләнеп тора, күз алмалары туктаусыз йөгерешәләр, алар эчтән көйрәгән төсле... Минзаһит эш буенча аңа берничә сорау бирде, институтта укуының ничек баруы белән кызыксынды, битараф һәм болай гына алып барылган бу сөйләшү вакытында Сөембикәне ул бик җентекләп күзәтте. Ул элеккедән дә яшәргән, чибәрләнгән, бит очлары алланып тора, гүя бернинди кайгы-хәсрәте юк иде. Менә алар бер тынга сүзсез калдылар.

—Йомышыгызны әйтсәгез, мин китәр идем,—диде Сөембикә, сәгатенә карап.

—Ашыгасыңмы?—Сөембикә аның бу соравына җавап бирмәде. Минзаһит, аклангандай, төшенке генә тавыш белән сөйләп китте:—Бүген бик киеренке көн булды. Иртәгә обкомнан сигез кешелек банда киләчәк. Сөт кими... Сплошной пресс... кысылганнан-кысыла... Кычкырыш-талаш, кемнәрдер куркыта, гаепли... Син башкаларны куркытасың, рәнҗетәсең. Йә, нинди шатлык бар минем? Бүген төнлә уянып, шул турыда уйландым. Карангы туннель эчендәге кебек, бер яктылык бар икән... Ул—син...

Сөембикә аның сүзләреннән каушап китте.

—Минзаһит Усманович... Мин бит өзеп әйттем кебек: безнең мөнәсәбәтләр бетте.

Минзаһитның йөзеннән ачу галәмәтенә охшаш күләгә йөгереп үтте.

—Шул кадәр мәрхәмәтсез булма, Сөембикә!—диде ул ялварулы тавыш белән.—Син минем белән сөйләшеп булса да утыра аласыңдыр бит?

—Беренче секретарь чакыргач, нишләмәк кирәк...

—Беренче секретарь белән түгел! Минзаһит дигән кеше белән сөйләшеп утыра аласыңмы?

Сөембикә башын аска иде, бер сүз дә дәшмәде.

—Аңлыйм, урыны бу түгел. Тик... очрашырга теләмисең ич хәзер. Син һаман да минем сүзләремнең никадәр житди икәнлеген аңламыйсың...—Минзаһит туктап калды, ул тын да алмый иде ахрысы, тавышы тагын да хәлсезләнеберәк чыкты.—Мин аны үзем дә яңа аңлый башладым... Аралар

ерагайган саен, син мине ныграк тилмертәсең...

Сөембикә, башын күтәреп, аңа гаҗәпләнүле караш ташлады.

—Мин сезне берничек тә тилмертә алмыйм...

—Ничек кенә! Син тирәнгә үк тамыр җибәргәнсең... Мин—котыла алмыйм... Хәзер төшләремдә газаплый башладың.—Минзаһит, урыныннан торып, Сөембикәнең каршысына ук килеп иелде, хәтта аның сулышы Сөембикәнең битенә бәрелде.—Син вампир түгелме? Җанны нидер суыра... Көннән-көн кимим, үземне югалта барам, ә эчемдә кайнар бушлык һаман арта бара.

Минзаһит, бүлмәне әйләнеп чыгып, кабат үз урынына барып утырды.

—Ник җавап бирмисең?—Аның тавышы кискен һәм ачулы янгырады.

—Турысын әйтер идем, ачуланырсыз...

—Әйт, яшермә.

—Вампир сез үзегез түгел микән?—диде Сөембикә, аңа шикләнү, курку белән карап.

—Мин?!

—Әйе.

—Нишләп?

—Сез безнең гаиләне җимердегез, пыран-заран китердегез, икебезнең дә канны эчтегез...

Минзаһит галстугын рәтләп куйды, өстәлендәге әйберләрен күчерде, йөзенең кызыша башлавын тойды. Сүзләре ишетелер-ишетелмәс булып кына, бер-берсенә буйсынырга теләмәгәндәй, көттереп кенә чыктылар:

—Әйе, мин аны Мәскәүдән кайтармый кала ала идем... Син җинелдең, дип мине котыртып тордылар. Тамчы тама-тама ташны тишә... Әллә инде аларга кушылып үземне үзем дә вәсвәсәләдем. Ышан, мин моны теләмәгән идем...

—Юк, сез баштук аның юлына аяк чалдыгыз!—Сөембикә үзенең ничек сикереп торуын сизми дә калды. Аның күзләре очкынланып яна, борын яфраклары еш-еш тирбәлә иде.—Бер нәрсәне әйтимме... Минем сезнең белән яшерен очрашуларым аңа бәйләнмәвегезне теләүдән генә иде. Язарына юл ачылсын, дидем...

Минзаһитның күзләре коточкыч зурайдылар. Сөембикәнең әйткәннәре аның бәгыренә кадалды. Бу хурлыкны ир кеше буларак күтәрү мөмкин түгел иде.

—Бары тик шуның өчен генәме?!—диде ул ямьсез тавыш белән.

—Әйе,—диде Сөембикә һәм, аны үртәгәндәй, кабат өстәп куйды:—Шуның өчен генә!

Минзаһитның маңгай тамыры бүртеп чыкты:

—Чыгып кит!—дип җикерде ул, үз-үзен белештермичә.

Сөембикә кабаланып ишеккә атлады.

Минзаһитның күкрәге кысылып куйды, өстәл тартмасын ачып, валидол алырга уйлаганда, дежур инструктор килеп керде. Беренченең чыраеның яшенле янгыр болытыдай каралганлыгын күреп, ул ник кергәнен оныткандай, сүзен әйтә алмыйча, бер урында таптанып, ык-мык итте.

—Нәрсә бар?!

—Ни... Мәскәүдән ике иптәш, төзелеш оешмасыннан...

—Керсеннәр!—диде Минзаһит, ник алай дип әйткәнен үзе дә белмәстән. Бу вакытта аның беркемне дә кабул иткәне юк иде югыйсә. Ләкин нидер булды, югарыдан килгән билгесез көчкә буйсынгандай, авызыннан әлеге сүз ычкынды.

Ул арада ишектә Мәскәү кунаклары үзләре дә күренделәр. Аның бик озын гәүдәлесе төптән кырып алынган ап-ак башы, кәгазьдәй ак озынча йөзе белән күңелгә әллә нинди шом салды. Аның салынкы кабаклары астыннан караучы эчкә баткан күзләре еланныкы төсле салкын иде. Икенчесе уртача юантык гәүдәле, кара-кучкыл йөзле, кара чәчле, Урта Азия халыкларын хәтерләтүче, күзләре уйнап тора торган ир-егет иде.

Кунакларның берсе аның каршындагы өстәлнең уң ягына, икенчесе

сул ягына утырды.

—Тынлыйм сезне,—диде Минзаһит.

Озынының гипстай саргылт хәрәкәтсез иреннәре әз генә кыймылдап куйдылар һәм аларның арасыннан тәндә бала йоннарын кабартырлык калын тавыш ишетелде:

—Без сезнең улыгыз Рашаттан... Ул җибәрде...

Арслановка бүлмә стеналары чайкалып киткәндәй булды. Бүген күргән төшендәге кебек, бу ике кеше белән бергә ул каядыр йөзеп киткәндәй булды.

—Рашат?!—диде ул пышылдап.

Ләкин керүчеләр бер сүз дә дәшмәделәр.

—Рашат исәнмени?!

Озын башның маскадай хәрәкәтсез йөзендә нидер селкенгәндәй булды: әллә ул елмаймакчы итте—Минзаһит аера алмады.

—Сезгә ничек кирәк соң?

Әйтерсең лә Минзаһитның өстенә тонналы таш бастырдылар. Ул ни сулыш ала алмады, башыннан яшен тизлеге белән мең төрле уй узды.

—Нишләп үзе кайтмады?! Ул кайда?!—Минзаһит тамак ярып кычкырырга теләде, әмма тавышы чыкмады.

—Ул әлегә кайта торган җирдә түгел.

Озын баш көрәктәй уң кулын йодрыклап өстәлгә таянды, ә сул кулы белән йодрыгын каплагандай итте.

—Ул оттырды.

—Нәрсә оттырды?

—Язмышын. Аңлыйсызмы?

—Шуннан?—диде Минзаһит тәмам хәлсезләнеп.

—Аны коткару өчен дүрт мең сум акча кирәк,—диде әлеге кеше, эчкә баткан күзләренең керфеген дә селкетмичә.

Минзаһит кинәт аның авыз кырыннан колак яфрагына кадәр сузылган тирән яра эзенә игътибар итте һәм төшендә үзенең маңгаендагы сырны сыпырып каравы келт итеп исенә төште.

—Рашат берәр язу-мазар җибәргәндер бит?

—Юк,—диде озын баш.

—Мин сезгә ничек ышанырга тиеш?

—Анысы инде сезнең эш.

—Ярый, мин ышандым да ди. Әгәр минем ул кадәр акчам булмаса?

—Ул чакта малаегызны югалтасыз.

Керүчеләр икесе дә урыннарыннан тордылар һәм ишеккә таба юнәлделәр.

—Туктагыз әле!—диде Минзаһит.—Утырыгыз зинһар.

Тегеләр сүзсез генә килеп урыннарына утырдылар.

—Кайда соң ул хәзер?

—Ул исән-сау,—диде теге кеше, яралы яңагын кулы белән ышкып.—Әгәр ике көн эчендә тиешле сумма түләнмәсә, сез инде аны бу дөньядан китте, дип уйлагыз.

—Ә сез кемнәр?

—Без аны коткарырга телибез. Рашат өчен бирелергә тиешле егерме меңнең уналтысы бар. Калган өлешен бирәсезме, юкмы?

—Иртәгә килегез... Иртәнге сигездән соң.

Тегеләр, бер-берсенә карашып, шактый вакыт сүзсез торгач, озыны:

—Ярый, без көтәбез. Тик шаярырга уйламагыз.—Ул күкрәк кесәсеннән пистолет чыгарды.—Кан күп булачак. Әгәр безне алсалар, җәзаның иң әшәкесен көтегез.

Алар, аяк очларына гына баскандай, тавыш-тынсыз чыгып киттеләр.

Арсланов шактый вакыт коелып төшеп утырды. Әлеге сөйләшүнең өндә булуына хәтта ышануы да кыен иде. Милициягә әйтсәң, аларны райкомга кергәндә үк эләктерәчәкләр. Ләкин бит моның азагы хәтәр. Сораган сумманы һичшиксез бирергә кирәк иде. Өенә каттый карарга килеп кайтса да, төне буе керфек тә какмады. Моңа кадәр ул партиядән дә көчле нәрсә юк, дип уйлый иде. Ныклабрак карасаң, бар икән.

Икенче көнне иртәнге җидедә үк ул банк управляющиена шылтыратты, бүлмәсенә чакырды. Ул кергәч, саклык кенәгәсен биреп, дүрт мең сум акча алып килергә кушты.

Сәгать тугызынчы ун минутта анын боерыгы үтәлеп, тиешле ордерны тутырып кул куйгач, дүрт мең сумны ул өстәл тартмасына атты. Берничә минуттан Мәскәү кунаклары да пәйда булды. Акчаны озынына биргәч, ул:

—Коткаруыгызга ышанасызмы?—диде, аларның күзләренә ялварулы караш ташлап.

—Ышанмасак, килер идекмени?

—Коткаргач, шылтыратсын. Миннән сәлам тапшырыгыз.

—Һичшиксез.

Алар кичәге кебек тавышсыз гына чыгып киттеләр. Райкомның югары катыннан ашыга-ашыга төшеп, таксига кереп утырдылар.

—Әйткән идемме мин сиңа?—диде озыны базык гәүдәлесенең иңбашына төртеп. Аннары шоферга кычкырды:—Бөгелмәгә! Туп-туры аэропортка!

10

Ирек повестен кыйммәтле бандероль итеп Әхмәткә салды. Инде берочтан театрга да шылтыратып алырга ниятләде. Пьесаның төзәтеп җибәрелгән вариантын укыганнармы-юкмы, фикерләре ничегрәк—белешәсе килә иде. Телеграф ягындагы кызлар аны ун-унбиш минутта театр белән тоташтырдылар.

—Мин сезне котлыйм, Ирек Сабитов!—диде режиссер көр тавыш белән.—Бик әйбәт эшләп чыккансың. Менә рольләр бүлеп утырам. Озакламый репетицияләр башлыйбыз.

Куанычтан Ирекнең тыны кысылды. Ул мондый җавапка әзер дә түгел иде, шуңа күрә авыз эченнән:

—Рәхмәт, рәхмәт инде сезгә,—дип мыгырданды.

—Премьерага барып җитик әле...

Бу хәбәрне Ирек бүген, бары бүген генә аракы белән билгеләп үтәргә булды. Ничәмә көннәр язып утыру аны тәмам алҗыткан иде...

Ул, кайтышлый саклык кассасына кереп, бераз акча алды. Кибетләргә кагылды. Айгөлгә бик матур кызыл башлык, шоколад, торт алды. Ул кайтып җиткәндә, ишек төбендә Миргаяз утыра иде. Повестьны җибәрүен, театрдан шатлыклы хәбәр ишетүен әйткәч, ул Ирекне котлап кулын кысты, хәтта кочаклап та алды.

—Бу шатлыкны юмый булмас бит инде,—диде ул, күзләрен майландырып һәм кесәсендәге яртының борынына чиертеп.

—Әйдә, әйдә, керәбез, минем үземнең дә бар монда,—диде Ирек елмаеп.

Өстәл янына утыргач кына, сызлангандай әйтеп куйды:

—Их, Миргаяз, мин бит бу әйберне капканчы кызым янына барырмын дигән идем.

Миргаяз көлемсерәп куйды:

—Бездән аның исе килмәгән чак бармыни инде. Әйләнерсең әле.

Кызы янына барасы Ирекнең күнелен гел бимазалап торса да, салып утыра торгач, бернинди дөнья кайгысы калмады. Миргаяз бүген нишләптер бик хисләнгән иде, аның күзе әледән-әле яшьләнә, ул, Ирекка күрсәтмәскә тырышып, башын читкә борып, җиң очы белән күзләрен сөрткәләп ала. Ахырда Ирек түзмичә аңардан:

—Син бүген үзгәргәнсең, әллә бер-бер хәл булдымы?—дип сорады.

Бер тын җавап бирми торганнан соң, Миргаяз очлы бугаз төенен хәтәр йөртеп, ике мәртәбә күз яшен йотып куйды һәм үтә дә сагышлы тавыш белән:

—Мин бүген Үзбәкстаннан хат алдым,—диде.

—Күнелсез хәбәр бармы?

—Күнелсез хәбәр юк-югын. Әнкәй язган,—бу юлы аның күз яшьләре битеннән тәгәрәп төштеләр, ул борынын тарта-тарта, кулъяулыгы белән

битләрен сөртте.—Туганнар анда, әнкәй анда, ә мин монда. Йөрәгемә урын таба алмыйм мин!..—Ул кинәт кычкырып җибәрде:—Нишләп без барыбыз да монда түгел?!

Бу хакта Ирек күптән уйлана, әмма Миргаяздан сорарга кыймый иде. Инде бу сорауны ул үзе биргәч, авырткан мәсьәләне кузгатмый кала алмады:

—Нишләп анда күчтегез соң сез?

—Бөтен фаҗига шунда. Әгәр сөйләсәм, син ышанмыйсың... Әйдә, берне тотып куйыйк та сөйлим.

Эчеп куйганнан соң, Миргаяз акрын гына сүз башлады:

—Минем әти мәктәп директоры булган. Шушында Болынкырда эшләгән. Заманында хәтта райком секретаре да итәргә маташканнар. Кемнең кем булуына карамастан, әти рәхимсез тәнкыйтьләгән, Ленин-Сталин әсәрләрен яттан белүе белән, аннан китергән өзекләре белән халыкны таң калдырган. Гөнаһ шомлыгына каршы, дөньяга мин туганмын. Әни дә коммунист, ул да укытучы, ә минә әби белән бабай яшерен генә намаз укып, ураза тотып яшәгәннәр. Бер елны, колактан колакка күчеп, авылга сөннәтче карт килүе турында хәбәр тарала. Әби белән бабай күптәнге планнарын тормышка ашыралар. Әти белән әнинең мәктәптән кайтуына, мин үкереп утырам. Өйдә кара тавыш куба. Ярар, тавыш чыга да бетә, ә кемдер моны райкомга тишә. Әтинең дошманнары эттән дә күп иде, ди әни. Кем белә, түрәләрнең кайберләре аның үз урыннарына үрләвеннән дә шөлләгәннәрдер. Бер сүз белән әйткәндә, әтине партиядән чыгаралар, әни белән бергә эштән куалар. Минем әби бик усал карчык иде. Райкомның беренче секретаре дус хатынының малае була, әбинең аңа үз күкрәк сөтен имезгән чаклары күп була. Шуңа күрә ул секретарьның бүлмәсенә ажгырып килеп керә дә:

—Салихҗан, сал әле ыштаныңны!—дип кычкырып җибәрә.

Райком секретаре берни аңламыйча:

—Син ни сөйлисең, Мөсәббихә әби?!—дип мыгырдана.

—Сал булгач, сал ыштаныңны!

—Туктале, Мөсәббихә әби, ник салыйм мин аны?

—Менә хәзер карыйбыз: сөннәтләмә син, юкмы?

—Соң син беләсең ич,—ди секретарь, кып-кызыл булып.

—Шулай булгач, ни өчен минем оныгым сөннәтле булмаска тиеш? Китер партбилетыңны! Синең дә партиядә торырга хакың юк!

Каушап калган секретарь нишләргә дә белмәгән, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты, дип сөйли торган иде әби.

—Син сөннәтле, сиңа партиядә урын юк!—ди икән әби, моңа һаман очып куныр.—Әгәр болай буласыңны белсәм, күкрәк сөтемне имезмичә, сабый чагында ук ачка үтергән булыр идем!—ди.

Әти белән әнигә Болынкырда урын бетә. Алар Үзбәкстан ягына чыгып китәләр. Әби белән бабайның кабере монда. Йә, кем гаепле безнең менә шулай булуыбызга? Океан кадәр илдәге кешеләрнең ыштан төбенә кадәр керергә партиягә кем хокук биргән?! Кемдә власть—шунда көч. Партиянең власте булмаска тиеш. Көч ул кулланмаганда гына әйбәт, ә куллана башлагач, берминди кешелек, намус, игелек калмый. Мин моны төрмәдә аңладым. Мин бик көчле идем, төрлечә мыскылларга, тезләндерергә маташтылар, ә мин баш бирмәдем. Тегеләр күп иде, ахырда алар мине төреп алып шундый итеп кыйнадылар—сынмаган бер генә сөягем дә калмады...

Миргаяз киткәч, Ирек ятып торырга булды һәм башын мендәренә терәгәнче үк йоклап та китте.

—Әти! Әти, дим.

Каян килә бу тавыш? Ирек авырлык белән генә күз кабакларын күтәрде һәм янында басып торган кызын күрде. Ул тормакчы булды, кургаштай авыр гәүдәсен күтәрә алмады. Терсәкләренә таянып, кызына караган хәлдә:

—Килдеңмени, Айгөлем?—диде.

—Әйе, килдем...—Айгөл шулай диде дә, еламас өчен иреннәрен тешләде. Ирекнең күңелендә аңа булган җылы хисләр кузгалды, шул ук вакытта

үзенең мондый хәлдә ятуыннан, өстәлдәге шешәләрдән, өйнең тәртипсезлегеннән кызы алдында оят иде. Шактый тырыша торгач, ул торып утырды, кулларын сузып, кызын иңбашыннан тотып, үзенә таба тартты. Айгөл йомшак ябык куллары белән әтисен кочты. Аның ак матур колак яфракларына, муенына, чигәләренә, бераз тузгыбрак торучы сары чәчләренә нишләптер кызганып карады Ирек. Кызының көрән төстәге пальто якасының бер җире сизелер-сизелмәс сүсәрә башлаган иде. Ул кулларын кызының аркасына куйды, бармаклары белән аның тәненен ябыклыгын тойды. Ирекнең күзенә яшь килде. Әйтерсең лә Айгөл бу дөнья тарафыннан рәнҗетелеп, шунын аркасында калак сөякләре чыгып тора һәм ул сөякләргә, әтисе якламаганлыктан, теләсә кем кагыладыр, аны кыерсыта аладыр кебек иде... Айгөл тураеп басты да житез генә өстәлне җыештыра башлады: буш шешәләрне мич алдына алып куйды, ашамлык калдыкларын кечкенә кулы белән сыпырып, чүп чиләгенә салды, рюмкаларны өстәл читенәрәк этте, шунда торган чүпрәкне юешләп, өстәлне сөртте, канат белән идәнне себерде.

—Әти, чиләк бирсәң, идәнне юар идем,—диде ул, кабат аның янына килеп.

—Кирәкми, кызым, үзем юармын...

—Юыйм инде...

Ирек урыныннан торып дипломатын алды, аны урындыкка куеп ачты һәм Айгөлгә кызыл башлыкны кигерде.

—Бүген үзем барырмын, дигән идем дә...

Ул аны житәкләп көзге каршына алып килде. Айгөл елмаеп җибәрде. Бу башлыкны кигәч, ул зур роза чәчәге кебек алсу нур чәчеп тора иде.

—Рәхмәт, әти,—диде ул, башлыгын ике кулы белән тотып тирәнрәк батыра-батыра.

Ирек аның кулына шоколад тоттырды. Өстәлгә түгәрәк тортны алып куйды.

—Торт белән чәй эчәсеңме, кызым?

—Юк, эчеп кенә килдем,—диде Айгөл.

—Ярый алайса, әниеңә алып кайтырсың...

Айгөл, шытырдата-шытырдата кәгазеннән сүтеп, шоколад сындырып капты, икенче урыныннан бер шакмак сындырып, Ирекка сузды. Алар икәүләшеп шоколад чәйнәргә керештеләр. Шоколадын йотып та бетермәстән, Айгөл күзләре белән кече якта нидер эзләргә кереште, аннары йөгереп барып, аралыктан эченә мунчала салынган чиләкне алып чыкты.

—Әти, юыйм инде?—диде ул ялынып.

Ирек бер сүз дә әйтмәде, казанның кунасын ачып, чиләккә җылы су салды һәм аны өйнең түренә илтеп куйды. Кызы пальтосын караватка ыргытты да, гел әнисенә охшатып, җиңнәрен сызганды, итәген алгы яклап бөрмәсенә кыстырды һәм идән юарга кереште. Өй алдына чыгып, Ирек икенче мунчала алып керде, жеп өзәрлек хәле булмаса да, тешен кысып, кызы янына килде, идәнгә тезләнеп, күптән буялган, инде купшаклый ук башлаган саргылт сайгакларны мунчала белән ышкый башлады. Ул идәнне әллә мунчала белән ышкыды, әллә йөрәге белән ышкыды, әллә мунчала сыкты, әллә мунчала урынына йөрәген кысып сыкты. Ирек бераз айный төште, әмма кызының ана ярдәм итәргә теләве, шушы нечкә генә беләкләре белән идән юуы аны бүтән төрле исертте...

Эш беткәч, Айгөл шоколадын кесәсенә тыкты да җәһәт кенә пальтосын киеп тышка чыгып китте. Ул чыкканда, Айгөл капкага житеп бара иде инде.

—Кызым, кая ашыгасың?—диде Ирек аны туктатып.—Тортың кала бит.

Айгөл башын аска игән хәлдә, кулларын кая куярга белмичә, әле пальтосының итәген бөтерә, әле сәдәфен бер ычкындыра, бер эләктерә иде.

—Кызым, ни булды?

Айгөл дәшмичә шактый вакыт торды. Ул күзләрен еш-еш йома, елап җибәрмәс өчен иреннәрен кыскан иде. Менә ул акрын гына башын күтәрде, Ирекка рәнжүле караш ташлап, зәгыйфь кенә тавыш белән:

—Әти, син ник бездән аерылдың?—диде.

—Кем әйтә?

—Үзем беләм... Әти...—ул мөлдерәп яшь белән тулган күзләрен туп-туры аңа төбәде.—Син безне яратмыйсыңмыни?

Ирек аны кочаклап алды:

—Яратам, кызым, яратам,—диде һәм аның битләреннән үпте, ирене белән кызының күз яшьләренең тозын тойды.

—Юк, яратмыйсың, әти,—Айгөл шулай диде дә аның кулларыннан ычкынды һәм капкадан чыгып йөгерде.

Хәлсез аякларын авырлык белән сөйрәп, Ирек өйгә керде дә караватына ауды. Күпме йоклагандыр, өй алдында аяк тавышлары ишетеп, күзен ачты, әмма берни дә күрә алмады: караңгы төшкән иде инде. Ул үрелеп утны яндыруга, ишек ачылып китте һәм аннан Сөембикә килеп керде.

—Хәерле кич,—диде ул, әле өстәлдәге рюмкаларга, әле кече яктагы шешәләргә күз ташлап.—Син Айгөлне нишләттең?

—Берни дә эшләтмәдем,—диде Ирек, Сөембикәнең ачулы йөзенә туп-туры карарга тырышып.

—Бала елый да елый, берни сөйләшми, син аңа нидер әйткәнсең.

Ирек кулына ипи кисәге алды:

—Ипи белән ант итәм: аны елатырлык бер нәрсә дә булмады.

Сөембикә ишек янындагы урындыкка утырды.

—Ирек,—диде ул тетрәндергеч тавыш белән.—Мин аңладым аның ник елаганын.

—Ник?—диде Ирек, аңа исерек карашын төбәп.

—Сине шушындый хәлдә күргәнгә елый ул. Ул бит, әтием янына киләм, дип килгән, исерек күрергә түгел. Юри генә үзеңнең кыяфәтеңә күз сал. Өеңдә тын алмалы түгел. Бетәсең бит.

—Бәлки мин бетәргә тели торганмындыр. Мин кемгә кирәк?

—Син безгә кирәк,—диде Сөембикә, аның кулына кулын салып.

Ләкин Ирек кискен хәрәкәт белән кулын тартып алды.

—Үле тормыш алып барган кешегә кагылма!

Сөембикә мөлдерәп яшь тулган күзләре белән карады:

—Әллә мине тере дип беләсеңме син?..—диде һәм ишеккә табан кузгалды.—Хуш!

—Сөембикә... Гафу ит мине.—Ирек күзләрен йомып башын артка ташлады.—Бер генә әйбер үтенәм: бу тортны гына алып кит. Мин аны бүген кич сезгә алып барасы идем...

—Ярый,—диде Сөембикә.—Бәлкем Айгөл тынычланыр...

Ул тортны алды да чыгып китте. Тыкрыкны узып, урамның каршы ягына атлаганда, чак кына машина астына килеп кермәде. Аның башындагы уйлар тәмам чуалган, зиһене таралган иде. Ул Ирекне ачуланырга да, кызганырга да белмәде. Менә хәзер яныннан чыккан кеше Ирек түгел кебек тоелды аңа. Шуның өчен җан аттымы Сөембикә? Күз алдында Ирекнең кызарынып бөртенгән йөзе, ямьсез булып салынып торган күз кабаклары, өйдәге сасы ис, исерек тавышы—элекке хыялый дөньясыннан чынбарлыкка кайтарды кебек. Ирек райкомга килгәч, ничек сокланып йөргән иде ул аңа. Әгәр дә шушы егет белән булсам, мин җир йөзендә иң бәхетле кеше булыр идем, дип үз-үзенә ничә мәртәбә кабатлады икән? Аның Зәнфирә белән йөргәнен белгәч тә, Сөембикә әлеге бәхетле уйларыннан һич тә чигенергә теләмәде. Киресенчә, ул тырышыбрак, нечкәрәк юллар белән Ирекнең күңел кылларына кагылырга, кирәксә дә-кирәкмәсә дә аның күзенә чалынып итәр торырга, аралашырга тырышты. Өйләнешкәннән соң Сөембикә үзен аның каршында мең мәртәбә гөнаһлы итеп тойды һәм бу шулай да иде. Шул гөнаһларын юк итәр өчен ул чәче белән җир генә себермәде, Ирекә аллага табынгандай табынды, аны районның гына түгел, бөтен Татарстанның мәшһүр кешесе итеп күрәсе килде. Ирек аның өчен фәрештә, пәйгамбәр, кул җитмәс илаһи зат иде. Болынкырда аның белән тиң куярлык бер генә кеше дә тапмады ул. Ирек аның өчен кояш кебек иде. Ә менә ул хәзер гайрәте чигеп, тамак төбенә нидер тыгылган хәлдә

каранғы урамнардан кызу-кызу атлаганда, үзенең бөтен тырышлыкларының юкка булганлыгын аңлады. Димәк, Ирек пәйгамбәр дә, фәрештә дә булмаган. Болынкыр халкы аңа бүген дә табына, һәр язмасын кулдан-кулга йөртеп укыйлар. Тик болар Сөембикәгә тәэсир итми инде. Ул үзенең хыялы белән ашлама сибә-сибә үстергән үсемлектәй, Ирекне әллә нинди аллы-гөлле буяуларга буяп, илаһи биеклекләргә күтәргән, үзе тудырган шул ялган сынга үзе үк табынган, үз-үзен югалтып, аңа хезмәт иткән. Дөрес, аның ялгыш юлга баскан, күтәрә алмаслык гөнаһка баткан чаклары булмады түгел, ләкин бит аны моңа мәҗбүр иттеләр. Менә хәзер, шушы минутта Сөембикә ачынып, кылыч йөзенә баскандай, нечкә, үткен нәрсә каршында җавап табарга азаплана. Мәҗбүр ителергә тиеш идеме соң ул? Димәк,моның нindидер җирлеге булган. Хыялы белән Ирекне күкләргә чөйсә дә, җаны белән, күңеленең кайсыдыр бер тирән почмагы белән ул үзенең ялган юлда икәнлеген сизенгән. Икенче төрле әйткәндә, Сөембикә бер нәрсәне аңлады: Ирекне ул беркайчан да яратмаган! Уртак гомер елгасы ага биргән, бала үскән, нindидер эшләр эшләнгән, дуслар, туганнар җыелган. Бөтенесенең тамырлары аерып ала алмаслык булып береккән, чуалган, бер тыгыз йомгакка чорналган. Ләкин бит моның нигезендә Сөембикәнең ялгыш адымы, Ирекне яратам дип, үз-үзен алдавы яткан. Бу фикергә ул менә хәзер генә килмәде, икеләнүләре Ирек өйдән чыгып киткәч тә башланган иде. Дөрес, Сөембикә аны юксынды һәм юксына, әмма ул өзелеп яратудан туган сусау түгелдер, ялган тойгыдыр. Сөембикә кызына күрсәтмичә төннәрен кайнар яшь түкте, ләкин бу яшьләр сөю аркасында бәгырьне көйдереп чыккан яшьләр булмаган. Әгәр ул аны хыялындагы кебек чыннан да яраткан булса, йөрәге күтәрә алмас, яисә ул үз-үзенә бер-бер нәрсә кылыр иде. Менә хәзер ул шуны аңлаган хәлдә каранғы урамнан атлый, ә уйлары яктырганнан-яктыра бара, ачык бер эзгә салына. "Юк, Ирек, яратмаганмын мин сине! Әмма мин барыбер гаепле, яратмаган килеш яратучыны уйнап, мин синең дә, үземнең дә бәхетемне җимергәнмен", дип уйлады Сөембикә эчке тетрәнү белән. Киләчәктә үзләренең тормыш юлларының беркайчан да кушылмаячагы менә хәзер барып җитте Сөембикәгә. Моңа кадәр әле ул күңелендә нindидер шик йөртте, нindидер өмет бар сыман иде. Шушыны тоеп, ул үз-үзенә һаман бер сорауны бирә килде: әгәр кушылсак, әгәр кабат торып китсәк? Нишләп соң бу сорауларга уңай җавап мине куандырмый, дип тагын аптырый иде ул. Бүген барысы да ачыкланды кебек.

Ул кайтып кергәндә, Айгөл тынычланган, дәресләрен әзерләп утыра иде. Сөембикә аны торт белән чәй эчәргә чакырды, әмма Айгөл, эчәсем килми, дип йокларга ятты. Сөембикә барып утны сүндерде дә өстәл янында хәрәкәтсез утыра бирде. Әле бит аның Арсланов яныннан чыкканына да ничә генә сәгать вакыт узды. Ниләр генә кылсаң да, бүген йокы булмаячак иде. Сөембикә киенеп тышка чыкты, болдыр култыксасына сөялгән килеш йолдызлы күккә карады. Иксез-чиксез җиһан куенында миллиардларча йолдызлар җем-җем итә, гүя сиңа күз кысалар. Никадәр сер, никадәр чиксезлек, никадәр бернинди уй белән дә колачлый алмастай аңлаешсызлык. Күңелдә дә чиксезлек, буталчыклык...

"Мәхәббәтне кешеләр уйлап чыгарган... Алла кебек хыялда гына яши ул." Тукта, бу сүзләрне кем әйткән иде соң әле? Мөнир абыйсымы, әллә Зөфәр Шәриповичмы? Икесе дә нык тырыштылар алар. Сөембикәне яшәргә өйрәтергә омтылдылар, күп нәрсәгә күзен ачтылар... Әгәр Мөнир Кәбиров булмаса, Сөембикәнең язмышы бәлкем башкачарак та язылган булыр иде. Анардагы кешене буйсындыру сәләтенә каршы тору мөмкин түгел. Шомырттай кара күзләрендә әллә нинди көч бар, көтмәгәндә яшендәй ялтырап китсәләр, бөтенләй югалып каласың һәм аның кебек үк уйлый башлыйсың.

Кәшифулла мәсхәрәләгән төнне Сөембикә якын кардәшләре Мөнир Кәбировка чапты. Авыл Советы председателе булып эшләүче Мөнир абыйсы аның аркасыннан сөйде дә:

—Әйдә, уйлап карыйк әле, сеңлем,—дип йомшак кына сүз башлады.— Син хәзер житеп беткән кыз, быел урта мәктәп бетерәсең. Шушы хәл халыкка ишетелсә, бөтенесе дә бармак төртеп сине мыскыл итәчәк.

—Мыскылласыннар! Мин аны барыбер төрмәдә черетәм!—дип ярсыды Сөембикә.

Мөнир Кәбиров, мең төрле дәлил китереп, аны һаман үзе теләгән якка бора барды:

—Мондый хәлләр күпләр белән була. Оныт син аны. Ир-ат та ялгыша, хатын-кыз да. Мәңге шулай бара тормыш. Тик моның әмәле бер генә: оныту.

—Мин оныта алмыйм, оныта алмыйм!—дип ярсый-ярсый елады Сөембикә.

—Булдыра алмасаң—онытма. Тик кычкырма!—диде ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.—Синең бит моны халыкка чәчүдән дәрәҗәң күтәрелми, егетләр күз алдында да үзеңне пычратасың гына... Әүвәл тормышта үз урыныңны тап.

Сөембикәнең бердәнбер хыялы башын авылдан кая да булса алып чыгып китү иде. "Зинһар ярдәм ит, Мөнир абыкаем, мәңге онытмам, гомерем буе рәхмәт укырмын, бу караңгылыктан гына коткар!" дип ялына иде аңа Сөембикә. Шәвәлиев беренче мәртәбә төнлә кунакханәгә килгәч, Мөнир шыпырт кына: "Бу синең язмышыңны хәл итә ала торган зур кеше. Авыз ачып калма",—диде. Ул барысын да аңлады...

Ирек яши торган якта зәңгәрсу ут булып йолдыз атылды, ул күз ачып йомган арада әллә Ык өстенә, әллә аның аргы ягына төште. Кем икән ул? Ирек белән икесенең берсеме, әллә башка берәүме? Шушы минутларда аңа карап, кемнәр ниләр генә юрамыйдыр...

...Зөфәр Шәрипович кебек зур дәрәҗәле кеше өстеннән үзенең хакимлек итә алуы Сөембикәне исертә иде. Ул җайлап телефоннан шылтырата, көйли, чөйли, очрашу эзли. Сөембикә тора-бара аны ялындыра башлады, рәхәтләнеп назланды, вакыт тапмаганга салынып, юри үртәде, очрашкач алдына тезләндерде, кирәксә табанын ялатты. Акрынлап райкомның икенче секретаре аның кулында курчак ук булмаса да, шуңа охшаш хәлгә төште. Әнисенең тәртипсез тормыш алып баруыннан, акчасызлыктан, бертөрлелектән гарык булган, бөтен дөньясына нәфрәт белән караган Сөембикә өчен икенче тормыш башланды. Шәвәлиев белән урнашкан яшерен мөнәсәбәт аны башкалардан өстен итеп тойдырды. Әхнәфкә иргә чыгып, райкомол машинасында парлашып эре генә авылга кайтып йөргән Фәһимәдән дә ул үзен шул рәвешле югары күтәрде. Аның өчен бу олы сер, үзен башкалардан югары күтәрүче яшерен һәм ләззәтле уен иде. Тормышта башкалар белән ачыктан-ачык, бертигез басып торырлык урыны булмагач, ул яшерен юл сайларга, үзен күңеле белән булса да биеккәрәк күтәрергә мәҗбүр иде. Ниһаять, Шәвәлиев кушуы буенча аны район үзәгенә эшкә алдылар, аннары җайлап кына ул аны райком китапханәсенә күчерде, культура училищесында укытты, аннары культура институтына керергә булышты...

Өйләнешеп яши башлагач, Сөембикә очрашулардан баш тартты. "Мин ир хатыны, хыянәткә беркайчан да бармаячакмын", диде. Аңа Шәвәлиев ничекләр генә ялвармады, чак-чак кына еламады, нинди генә сүзләр белән үгетләмәде, әмма Сөембикә кыядай нык иде. Бервакыт өлкә комитетыннан комиссия килер алдыннан Арсланов кушуы буенча аларның икесенә урман эчендәге иң караңгы авыл Кичүгә чыгып китәргә туры килде. Июнь башында була торган җәйге чиллә иде бу. Ирекнең Казанга семинарга киткән чагы. Инде кояш баеганда, алар кайтырга чыктылар. Ярты юлны узуга Шәвәлиев, машинаны юлдан читкә борып, әрәмә эченә кереп китте, аның иң куе урынына туктап, мәхәббәт сүзләре түгә, Сөембикәне коча, үбә башлады. Алар төне буе машинада тарткалаштылар, ул ниләр генә кыланып караса да, әзерләгән ризыгын да, рюмкаларга салган аракысын да эчмәде, туктаусыз бер сүзне кабатлады:

—Әйдәгез, кайтыйк!

—Их син, юләр!—дип тиргәде Шәвәлиев аны шул чакта.—Мәхәббәт бит ул кешеләр уйлап чыгарган алла кебек хыялый бер нәрсә. Тормышта кыска очрашулар гына бар, никах, гаилә дигән нәрсәләр ир өчен дә, хатын өчен

дә газаплы богау. Моның өчен кешеләрне гаепләргә дә кирәкми. Тормышның агышы шундый!

Таң атканда ул Сөембикәне көч белән буйсындыра башлады. Ул ничектер машина ишеген ачып җиргә сикерде һәм торып йөгерде. Билдән үлән ярып, куе томан эчендә шәйләнгән куаклар эченә чумды. Салкын чык аның итәкләрен биленә кадәр манма су итте, зәңгәр чәчәкле ситсы күлмәге тәненә ябышты. Аяк астындагы куе үләнгә инде егылам-инде егылам, дип йөгергәндә, ул бака яфраклары баскан тар гына юлга килеп чыкты. Сөембикә, юлның кая барганын да белмәстән, йөгерә-атлый, үзенең уйлавынча, һаман читкәрәк каерды. Озак та үтмәде, артта машина тавышы ишетелде. Сөембикә тагын адымнарын кызулатты. Машина якынайганнан-якынайды, ул куркудан тагын юлдан борылып, үлән эченә кереп китте. Нindiдер каты сабакка аягы уралып барып капланды. Машинаның туктаганы, ишеге ачылганы ишетелде. Сөембикә тезләнеп башын күтәрүгә, йөрәге ярыла язды: юлда ак “Жигули” тора, ә аның янына өрлектәй ике адәм йөгереп килеп җиткән иде.

—Менә балыкның шәбе капты безгә!—диде берсе русча.—Кил әле, матурым, бик туңгансың да, хәзер җылытабыз сине.

Ул иелеп Сөембикәнең биленнән эләктерде һәм аны акрын гына өскә күтәрә башлады. Сарымсак, суган исләре белән буталган аракы исе аны чак кына укшытып җибәрмәде. Ул терсәге белән урысның күкрәгенә төртте, теге авыртудан кулларын ычкындырды. Кире бөкләп, Сөембикә үзе килгән якка—таллар арасына ташланды.

—Давай поймаем, больно хорошая,—дип кычкырды аның артыннан урысларның кайсысыдыр.

Сөембикә балтырган, атлык, шома көпшә, түндербаш сабаклары арасыннан язын кереп калган уйсу урыннардагы суларны ера-ера йөгерде дә йөгерде. Тыны кысылды, хәле бетте, әмма туктамады. Тегеләрнең машина кабызып, кычкырышып йөргәннәрен ишетте, ләкин куаклар арасыннан алар аны күздән яздырдылар. Күпме вакыт үткәндер, Сөембикәнең каршысына томан эченнән Шәвәлиев килеп чыкты. Сөембикә акырып елап аның муенына үзе ташланды...

Шул ук көнне кич Ирек Казаннан кайтты. Ул шактый салган иде. Айгөл йоклагач, Сөембикәне ул, сагындым дип, кочаклый, үбә башлады. Сөембикә аңа ачуы килүдән бигрәк үзеннән-үзе җирәнеп, тавыш чыгарды, син хәзер шушы исереклек юлына кереп баттың, сиңа аракыдан башка берни дә кирәкми, син берни дә яза да алмаячаксың, дип аны битәрләде. Соңгы сүзләре Ирекне чыгырыннан чыгарды. Алар бик озак кычкырыштылар. Ахырда Сөембикә, китәм, дип, синең белән тормыйм, дип әйберләрен җыя башлады. Ирек, әнә бара юлың, диде, мин синең кебекләрне унны табам, диде. Сөембикә бөтенесенә төкерде. Иреккә ул нинди генә хыяллар белән чыкмады, имеш тә аларның тормышы ал да гөл булачак, аның бер-бер артлы пьесалары куелачак, китаплары чыгачак, алар һәр төрле мохтаҗлыктан котылачаклар. Әгәр теләсә, әнисен дә үзләре янына алып килерләр, алып килмәсәләр, йорт-кураны яңартырлар, машинага тиенерләр. Ләкин бу өметләрнең берсе дә акланмады, моңа иренең йомшак, чигенүчән булуы сәбәпче икәнлеген ул аңлап бетергән иде инде...

Өч көн талашкач, ул әйберләрен чемоданына тутырды да, Айгөлне алып, өйдән чыгып китте. Туп-туры үзенең ахирәте Фәһимәләргә юл тотты. Алар ах-ух килделәр, юләрләнмә, диделәр, аның кебек кешене каян табасың, диделәр, бер кискән икмәк кире ябышмый, бер чатнаган чүлмәкнең эзе кала, диделәр. Ирек белән нинди сөйләшүләр булгандыр, кич караңгы төшкәч, ул Сөембикәне алырга килде. Әхнәфләр каршында, мин исерек идем, мин гаепле, гафу ит, дип ялынды, ялварды һәм, Айгөлне кулына алып, алар бергәләп өйгә кайттылар. Сөембикә янадан, ничекләр генә элгәләшүләр-талашулар булса да, аерылып китү адымын ясамады, ләкин, менә хәзер билгеле булганча, Ирек белән торырга аны сөю дигән әйбер мәҗбүр итмәгән, аңа гомер итәргә кеше кирәк булган, ләкин моны Сөембикә чын ярату дип уйлаган. Беренче көннәреннән үк гаебен юу өчен ул баш күтәрми эшкә

чумды, Ирекнең оешмаганлыгын, йомшаклыгын аңлап, аның турында да кайгыртты, утыр, яз, дип, язу өстәле янына әйдәкләде, иренең ана чыккандагы өметләрен акламаячагын, әнисенә дә ярдәм булмаячагын тәмам аңлагач, хыял-өметләрен үзе булдыра алганча тормышка ашыра башлады. Гаилә арбасы үзенең бер көен алды, ул тәгәрәде дә тәгәрәде, ана икесе дә күнектеләр, күрәсен, икесе дә башка төрле үзгәреш тә теләмәделәр. Елга үзенең агышы белән чүп-чарларны алып киткәндәй чокыр урыннарга ком салып, калку урыннарын ашап тирәнәйткән кебек, гомер елгасы үз көенә акты да акты.

11

Казаннан Нәфисәнең әнисе килгәнгә инде дүртенче көн китте. Ул аны һәрвакыттагыча куанып каршы алды, барлык көчен биреп, яраткан ризыкларын пешерде, кунак итте. Әмма Хурлыжинан кәефсезләнгәннән-кәефсезләнә барды. Моның сәбәбен алар сизәләр: әнисе килдеме, Мэлс юньләп өйдә тормый. "Язгы чәчү чоры бит, әнкәй, йокы да, ял да юк аңа бу вакытта", дип акланмакчы булды Нәфисә. Әнисе дәшмәде, авыр сулап кына куйды. Әллә этисеннән күрмәкче, уллары Алмаз да менә өч көн инде юньләп өйдә күренми. Дәрестән соң йә консультация, йә түгәрәк дип, өйдән чыгып китә дә, караңгы төшкәч кайтып ашап, тагын клубка ычкына.

Бүген дә нәкъ шулай булды. Сәгать кичке тугызынчыларда кайтып, әштер-өштер капкалагач, ул тагын көзге каршысында киенә-төзәтенә башлады. Һәр көндәгечә, Нәфисә аны туктатмакчы булды. Турысын гына әйткәндә, иреннән ала алмаган үчне ул малаеннан алырга кереште.

—Кая барасың?—диде ул.

Алмаз әнисенә күтәрелеп кенә карады да, киенүен дәвам итте. Күрәсең, көн саен кабатлана торган бу сорауга ул җавап бирергә теләмәде.

—Мин җавап көтәм,—диде Нәфисә, аның янына ук килеп.

—Соң, әни, беләсең лә инде: китапханәдән, клубтан әйләнәм.

—Әйләнәсең!—диде Нәфисә мыскыллаулы тавыш белән.—Кичә дә төнге бердә кайттың. Шул гомер нишләп була?

—Ык буенда кичке уен уйнадык.

—Кичке уен уникенче яртыда ук бетте.

Алмаз гаҗәпләнүдән башын чайкап куйды.

—Син баш чайкама. Имтиханнарың борын төбендә, институтка керәсеңне дә онытма.

—Мин бит үзем генә түгел, әни. Бөтен классыбыз бергә.

—Бергә түгел. Синең кем белән чуалганыңны беләм мин. Әгәр шул Фәйзулла кызы белән арадңы өзмәсәң, моның азагы яхшы булып бетмәячәк.

Алмазның йөзе генә түгел, муенына кадәр кызарып чыкты. Калын кара кашлары сикерештеләр, ирене тартышып-тартышып куйды.

—Торасың да шуңа бәйләнәсең. Ни булган инде аңа?

—Мин мәктәптәге һәрберегезнең кем икәнен беләм. Укуының рәте юк, этисе алкаш, үзе артык кыю.

—Пар киләбез бит инде. Син дә бит этине очраган бер кешегә эчә дип сөйлисең.

—Синең әле безне хөкем итәргә борын астың кипмәгән.

Шулчак зал ягыннан Хурлыжинан чыгып сүзгә кушылды:

—Әгәр тыңлый алсаң, улым, мин сиңа бер сүз әйтер идем. Сезнең сөйләшкәнегез кичә дә колагыма керде. Син ул кыз белән дус булып кына йөрим, дисең. Менә шул дус дигән әйбер сагыз сыман бер-береңә ябыштырганны яшь чакта сизми дә каласың.

Алмазның күзләрендә ярсулы очкыннар кабынып китте, ләкин ул аларны баса алды. Әллә нигә бер мәртәбә кунакка килгән әбисеннән ана карата күңелендәге бик үк әйбәт булмаган уйларын яшерергә кирәк иде.

—Безнең арада чыннан да дуслыктан башка бер әйбер дә юк,—диде ул акрын гына.—Мин бит инде ул дуслыкны тора салып өзә алмыйм.

—Үзем ярдәм итимме соң?—диде Нәфисә.

Бу юлы Алмаз ачулы карашын яшерә алмады. Ул аның тавышына да бәреп чыкты.

—Мин бит синнән ярдәм сорамадым, әни.

—Менә, менә,—диде Нәфисә.—Күрәсенме, ничек сөйләшә. Атасына охшамаса, кыек китәр.

Бу сүзләргә Алмаз дөртләп кабынды:

—Ә мин кемгә охшарга тиеш?! Зәйнуллинга түгелдер лә?..

—Нәрсә?!—Нәфисәнең йөзе кара янып чыкты, сулышы кысылды.—Тагын бер мәртәбә кабатла әле, малай актыгы!

—Ишеттең лә инде, ник кабатларга?—диде Алмаз, аның күзләренә туп-туры карап.

—Бар, олак, Фәйзулланың исәре янына! Гел кайтмасаң да була.

—Кайтмам да!—диде Алмаз һәм ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып китте.

Нәфисә, кече якка кереп, күзләреннән яшьләрен сөртә башлады.

—Кызым, чык әле,—дип чакырды аны Хурлыжинан.—Бу бала нинди Зәйнуллин турында сөйләде?

—И, әни, минем турыда гайбәт сатарга бер сәбәп таптылар инде. Мәктәбебезгә моннан өч ел элек Зәйнуллин дигән бер укытучы килде. Чибәр генә, яшь кенә. Химия укыта. Менә шул кеше миңа үлеп гашыйк булды, артымнан күләгә сыман йөри. Аның безнең мәктәпкә килүе дә минем өчен булган икән. Август конференциясендә күреп калган. Яшәвенең мәгънәсе имеш тә миндә генә. Ул мине күтәреп йөртергә, табанымның туфрагы булырга әзер. Аның бу теләкләрен, өметләрен мин инде күптән кырт кистем, әгәр тагын шундый сүзләр сөйләсәгез, мин сезне Наратбаш мәктәбеннән генә түгел, районнан ук кудырам, дидем. Ул минем тирәмдә бөтерелүдән туктады, әмма укытучылар да, укучылар да аның ни дәрәҗәдә эчтән януын, миңа яшерен рәвештә нинди мәхәббәтле караш ташлавын, минем һәр адымымны сөеп озатып калуын күреп, аңлап торалар. Аның шулай кылануларына мин дә шундый ук җавап бирә, дип уйлыйлар. Әгәр шулай уйламасалар, Алмаз бу сүзне әйтер идемени? Зәйнуллин инде әллә ычкынып та бара: район газетасында туктаусыз мәхәббәт шигырьләре бастыра.

—Кияү бу хакта беләме соң?—дип сорады әнисе, аны тыңлап бетергәч.

—Аңа баштук үзем сөйләдем. Ә ул кычкырып көлде.

Шактый гына сүзсез уйланып утыргач, Хурлыжинан болай диде:

—Беркемнең дә өметен кисәргә ярамый, кызым. Кеше бит ул. Өмете белән яши бирсен.

—Бу ни дигән сүз була инде, әни?

—Ярамый дидем ич.

—Әгәр минем арттан кайсы мәхәббәт җыры җырлап, кайсы елап йөрүчеләрнең барысын да син әйткәнчә калдыра килсәң, ни булыр иде?

—Кызганыч, тормышның бик күп ләззәтен югалткансың, кызым. Бер әйберне аңла: кисәргә кирәкми!

—Син чын сөйлисенме, әни?!

—Күпчелек хатын-кызлар ялгыш уй белән яшиләр. Син шуларның берсе. Артыңнан йөрүчеләргә сөймәс сөякләр итеп түгел, тугандай якын кешеләрен итеп карарга, моның өчен горурланырга кирәк. Ул чакта кияү дә бераз көнләшер, сиңа игътибар беләнрәк карар, янында бөтерелер иде. Кем дисең әле? Зәйнуллинмы?

—Исемен дә ишетәсем килми! Шуның аркасында күпме гайбәт таралды.

—Гайбәт ул, кызым, тормыш бакчасына төшкән иртәнге томан гына.—Әнисе Нәфисәгә таба иелде һәм пышылдап кына сүзен төгәлләп куйды:—Алла сакласын, дөнья ул... Белмәссең, гел шул кеше кирәк булып куяр.

—Әни, син мине үпкәләтәсең...

—Бер нәрсәне исеңдә тот: син бу җир йөзендә берәү генә. Калган биш миллиард кеше сиңа дус та, дошман да булырга мөмкин. Анысы инде нинди ният белән яшәвеңә бәйле... Ә томан күтәрелгәч, көн бик матур булучан ул...

Алмаз төнге бердә дә, икедә дә, иртән яктыргач та кайтмады. Нәфисәнен күнелен шомлы болыт каплап алды. Ул, иртәнге көтүен кугач, Ык буйларыннан урады, клуб янын әйләнде. Мэлс төнге чәчүдә дежурда иде, ул да күренмәде. Нәфисә, дирекция каршына баргач, анын янына кермәкче булды, ләкин ул уеннан кайтты. Хурлыжинан да хафага төште:

—Берәр юләрлек эшләп ташламасын, абзар-кураларны карап кердеңме?—диде.

Нәфисә атылып-бәрелеп ишек алдына чыгып китте, мунчадан башлап бөтен җирне җентекләп күздән үткәрде, йөрәге тасыр-тосыр килде. Мәктәпкә баргач, ул, туктаусыз коридорга чыгып, Алмазларнын классына күз салды. Ләкин ул һаман күренмәде. Ахырда сабыры бетеп, Фәйзулла кызы Рәсимәне чакырды, анардан пышылдап кына коридорда Алмаз турында сорады. "Кичә ул клубка чыкмады, күренмәде", дигән сүзне ишеткәч, Нәфисәгә дөньянын асты өскә килгәндәй булды. Ул сәгать уннарга кадәр көч-хәл белән түзде, туктаусыз әнисенә шылтыратып торды, Алмаз һаман кайтмады. Ахырда укытасы дәресен ташлап, совхоз дирекциясенә йөгерде, ирен эзләп тапты һәм эшнең нәрсәдә икәнен анлатты. Мэлснын төне буе йокламаудан талчыккан, тузанга баткан йөзе ачулы кыяфәткә керде, ул Алмаз белән кичтән сөйләшкәннәрнең бөтенесен җентекләп сораштырды, аннары "ярар, үзем эзләп карармын", дип машинасына утырып китеп барды.

Мэлс Ык буйларын, болыннарны, әрәмәләрне урады, урман юлларынын керә-чыга ала торган урыннарын тикшерде, таныш-белешләренә барды, Болынкырда Ирекка кагылды, Баллы Төбәктә булып, әниләренең хәл-әхвәлен белеште, ә асылда: Алмаз анда түгелме икән, дип баруы иде. Сәгать өчләрдә Әхнәфләр турыннан үтешли, ул үз күзләренә үзе ышанмыйча, машинасын туктатты. Алмаз аларнын капка төбендәге утыргычта ялгызы гына утыра иде.

—Нишлисен монда?—дип кычкырды Мэлс, машинасынын ишеген дә япмыйча анын каршына килеп.

Алмаз акрын гына торып басты, анын йөзе көл кебек агарган иде.

—Хәнифнен мәктәптән кайтуын көтәм,—диде ул.

—Син кайда булдын?

—Хәнифләрдә кундым...

—Нишләп өйгә кайтмадын? Әниен белән безгә инфаркт ясыйсын килдеме?

—Әни кайтма, диде ич. Көн саен, туктаусыз тирги...

—Әни кеше нишләсә дә хаклы,—диде Мэлс анын беләгеннән тотып.— Ул тиргәргә дә тиеш, кыйнарга да мөмкин. Әйдә, утыр машинага.

Кайтып кереп ишектән күренүгә, Нәфисә кычкырып елап, аларнын каршына килде.

—И, балакаем, син ник шулай кыланасын?! Без бит әллә ниләр уйлап бетердек, эзләмәгән җиребез калмады.

—Үзен кайтмаска куштын бит,—диде Алмаз, үпкәләвен сиздереп һәм бүлмәсенә кереп китте.

—Ашарга берәр нәрсә әзерлә әле, басуга китәсем бар,—диде Мэлс һәм, әбисенен нидер әйтергә җыенуын күреп, ишек алдына чыгып китте.

Анын белән баштан ук Мэлснын боткасы пешмәде. Хурлыжинан карап торуга бик мөлаем йөзле, кин маңгайлы, мәһабәт гәүдәле хатын иде. Ул гаҗәп тә чиста йөри, бик затлы киенә, туктаусыз эшләпә алыштыра. Симез үрдәктәй алпан-тилпән йөри. Нәфисәне алып кайткан көнне туйны алып баручы Фәхразый барлык кунаклар тәмам кызышып беткән бер мәлдә Мэлска: "Син Нәфисәнен әнисенә ни дип эндәшәчәксен: әби дипме, әллә әни дипме?"— дип сорады. Мэлснын җавабын көтеп, мәҗлестәгеләр тып-тын калдылар.

—Тормышта ике әниле кешеләр була,—диде Мэлс.—Берсе баланы тапкан ана, икенчесе аны баккан ана. Безнен очрак андый түгел. Әнә минем әнкәем утыра, ул берәү генә. Шуңа күрә, әби, син ачуланма, мин сине бик яратып, "әби", диярмен.

Мәҗлес гөрләтеп кул чапты. Ул чактагы кайнар хисләр инде еракта калдылар, әллә кайчан сүнделәр. Әгәр яраса, хәзер аңа Мэлс әби дә димәс,

Хурлыҗинан карчык, кына дияр иде. Чөнки әбисе аларның тормышына уңай йогынты ясый торган кеше булып чыкмады. Ул үзе бик зур кеше, педагогия фәннәре кандидаты, иренә баш бирмәү аркасында, күптән аерылышканнар. Нәфисәне, сөйләвенә караганда, бик кадерләп үстергән, алиментны умырып алган. Башкалардан кызымны ким-хур итмим, дип тырышкан. Хәзер дә ул аны күз уңыннан ычкындырмый, гел шылтыратып, хат язып, килеп-китеп тора. Килсә дә, шылтыратса да, кызын һаман яшәргә өйрәтә, кияү кыерсытыр, дип уйлый, күрәсең. Хурлыҗинан кунакка килсә, Нәфисә танымаслык булып үзгәрә, бөтен тормыш Мэлс теләгәнчә түгел, алар теләгәнчә ага башлый, алар хуҗага әверелә, әбисе туктаусыз вәгазь укый, ә Мэлсның һич тә тыңлыйсы килми. Шуны белсә дә, Хурлыҗинан аның артыннан йөри, киявенең эш-гамәлләренә туктаусыз бәя куя, "алай түгел, болай кирәк", дип өйрәтә. Әле өйләнешер алдыннан булган бер вакыйга Мэлсның һаман да хәтерендә саклана. Инде балдаклар сатып алдылар, туй киемнәре, һәр ике якка бүләкләр әзерләнде. Шулай әвәрә килгәндә, бер кичне Нәфисә:

—Мин үз фамилиямдә калам,—дип ычкындырмасынмы.

—Нәрсә?!—диде Мэлс үз колакларына үзе ышанмыйча.

—Нигә? Фән кешеләре фамилиясе. Мин аны югалтырга теләмим,—диде Нәфисә.

—Йә Сабитова буласың, йә мин сине белмим,—диде Мэлс.

Ул чакта алар Нәфисә укыта торган авыл урамының зур өянкесе ышыгында торалар иде. Мэлс мотоциклына атланып кайтты да китте. Елап калган Нәфисә икенче көнне үк Баллы Төбәккә килде, "ялгышканмын", диде, "әни шулай кушкан иде", диде... Хурлыҗинанның бердәнбер өстенлеге мул яшәвендә булгандыр. Ул килгән саен кесәсенә калын бумажник тыгып килә, аның эчен кызы белән рәхәтләнеп туздыралар. Менә бусында да килгәненең икенче көнендә үк Нәфисәгә затлы итекләр, кара куртка сатып алганнар, Мэлс кич эштән кайтып бусагадан атлауга, икесе ике яктан ул әйберләрне күрсәтә башладылар. Нәфисә итекләрне аягына киде, курткасын да элэктерде, әбисе куртканың әле итәген, әле җиңен тотып, сыпыра-сыпыра Мэлска күрсәтте:

—Кияү, кара әле, чын кожа бит, чын кожа!

"Кожасын кожа, кем соң монда хуҗа?" дияр идең дә, акчага Мэлс хуҗа түгел. Ә Нәфисәнең бу киемнәргә күзе урыныннан купкан, битләре алланып чыккан, бөтен җиреннән нур бөркелә. Чыннан да ул хатынына килешә, Нәфисә чибәрләнгән, тик Мэлс мактаудан тыела, чөнки ачуы килә. Хурлыҗинан киткәч тә, әле бик озак аның йогынтысы астында Нәфисә өйдә хуҗа булып маташа, әле бусын, әле тегесен туктаусыз боера. Өйләнешеп яши башлагач та, ул гаилә дилбегәсен кулына алмакчы булды. Ләкин Мэлс аны бер генә мәртәбә кисәтте: "Әгәр баш буласың килсә, үзең яшә!"—диде. Зур нәрсәләрдә өстенлек ала алмагач, Нәфисә вак-төякләрдә гел аны бимазалап торды: "Суны чәчрәтеп юынма, ашаганда авызыңны шопырдатма, ашка борыч сипмә—нервыңны бетерә, ипине күп кулланма—симертә, аягыңны кагып, чистартып кер, идәнгә дөп-дөп басма, йомшак йөр, кычкырып сөйләшмә, режим белән йокларга ятыйк, режим белән торыйк..." Санап бетермәле түгел. Мэлс моны күтәрә алмый, холыксызлана, ул әйткәннәрнең киресен эшли, яисә бөтенләй үтәми. "Бу сиңа мәктәп түгел, укучы балаларыңны шулай үз командаңа буйсындырырсың",—ди. Бу сүзләрне хатыны күтәрә алмый, тавыш чыгара, елый, "син мине изәсең, кешелегемне калдырмадың, мин синең өчен беркем дә түгел, ихтыяҗларыңны үтәүче курчак кына",—ди. "Шулай булгач, начармыни,—ди ачуы чыккан Мэлс.—Курчакка берни уйларга, баш ватарга кирәкми. Ул гел матур килеш, мәңге исән-сау тора",—ди. Нәфисә тагын да ныграк ярсып китә, аннан котылу өчен Мэлс йә эшенә китә, яисә ятып гырлый-гырлый йоклаган булып кылана. Нәфисә тормышның чәлпәрәмә килүеннән зарлана, мескенләнә, үзен-үзе кызганудан рәхәтләнеп елый...

Мэлс кергәндә өстәл әзерләнгән иде, өчәүләп табынга утырдылар. Ул хатынының елаудан кызарып беткән күзләренә карап:

—Йә, ике педагог, кем хаклы?—диде.

—Син, кияү, капыл безгә ябырылма әле,—диде әбисе, кызын яклауга күчеп.—Әгәр ул синең барлык теләкләренә юл куюынны сизеп торса, әнисенә генә түгел, үзенә дә баш бирми башлар.

—Нишләп алай булыр икән?—диде Мэлс, Хурлыжинанга астыртын елмаеп.—Син бит әнә кызыңның барлык теләкләрен үтәп торасың. Бер дә бозылмый, көннән-көн әйбәтләнә бара.

—Житәр сиңа миннән көләргә,—диде Нәфисә, еларга әзерләнеп.

—Һич тә көләргә уйлаганым юк,—диде Мэлс, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.—Дөресе шулай түгелмени?

—Монда, кияү, Нәфисәне түгел, улыңның тәртибен тикшерергә кирәк.

—Их, әби-и-и!—дип суздЫ Мэлс, чын күңелдән уфтанып.—Сезнең дә су өстендә дулкын кебек чагыгыз булгандыр бит. Аның өйдә бикләнеп ята торган вакыты түгел ләбаса. Минем чамалавымча, аллага шөкер, үз акылы үзендә.

—Ә Фәйзулла кызы белән…—дип Нәфисә сүз башлауга, Мэлс шундук аның авызын каплады:

—Без барыбыз да кешеләр,—диде ул.—Кем белә, бәлкем Фәйзулла кызы безнең икебездән әйбәтрәктер.

—Әйбәт булса, бар, алып кайт, өйләндер малаеңны!

Кызының сүзен Хурлыжинан куәтләп куйды:

—Оясында ни булса, очканында шул инде ул, кияү.

Мэлсның йөзенә ачу бәреп чыкты.

—Әби, син кунакка килгәнсең икән, кунак кына бул әле,—Мэлсның әллә ничә еллар буе күңелен сызлаткан шеше тишелде дә китте.—Без ничек тә үз балабызны үзебез тәрбияләрбез. Кызганыч, башка балаларың булмаган. Шуңлыктан тупны гел безнең капкага гына тәгәрәтәсең.

Әбисе авызына капкан ризыгын чәйнәр-чәйнәмәс килеш көч-хәл белән йотып җибәрде. Аның башы калтырый башлады, моның иң ныкдулкынлану, иң нык борчылу билгесе икәнлеген алар беләләр иде.

—Мин сезне кайгыртып киләм…—Хурлыжинанның башы белән бергә калын иреннәре дерелдиләр, күз бәбәкләре дә атылып чыгардай булып киерелгәннәр иде. Ул тавышына буылып сөйли-сөйли урыныннан торды:—Бу минем соңгы килүем булыр. Рәхмәт, кияү. Мин сиңа нинди начарлыклар кылганмындыр, белмим. Мин рәнжеп кайтып китәм.

Хурлыжинан ава башлаган кебек артка хәрәкәт ясады, ләкин аумады, кулы белән кухня шкафының киртенә ябышты.

—Әни, әни!—дип барып тотты аны Нәфисә.—Ни карап торасың, булыш!

Мэлс әбисен икенче кулыннан барып тотмакчы булган иде, ул аны шактый зур көч белән этеп җибәрде. Шунда Хурлыжинанның рәнжетелгән кеше ролен уйнаганын аңлады.

—Кызым, плащымны китер, әйберләремне китер!—диде ул, аякларын аерып баскан хәлдә башын гына түгел, бөтен гәүдәсен, кулларын калтырата башлап.

—Әни, дару эчмисеңме? Мә, валокордин кап,—дип бөтерелде аның янында Нәфисә.

—Кирәкми!—диде Хурлыжинан кызганыч тавыш белән.—Әйберләремне әзерлә, мин китәм.

—Кич житкәч, кая барасың? Беркая да җибәрмим, син бит әле тагын бер атна торам, дигән идең.

—Ялгыш әйткәнмен, кызым. Кияү иркен сулыш алсын, мин сездә—артык кеше.

—Синең миңа рәнжерлек сәбәбең юк бит, әби.

—Син мине күрә алмыйсың. Мин килгәч, өйгә дә кайтмыйсың.

—Язгы чәчү вакытында өйдә ятсам, мин үзебезнең совхоз кешеләрен генә түгел, сезне дә ач калдырам. Күрә алмау дигән сүзең дә дөрес түгел. Ә үпкәм бар.

—Нинди үпкәң бар синең әнигә? Ул бит фәрештә,—диде Нәфисә,

энисенең инбашларыннан кочып.

—Фәрештә икәнен мин белмәгән идем әле. Ләкин котырта торган фәрештә булмасын иде ул.

Мэлсның башка сүз көрәштерәсе килмәде, эшенә китеп барды. Нәфисә әнисен тынычландыра алмыйча сәгатьтән артык маташты, аны төрлечә көйләде-чөйләде, ләкин Хурлыҗинан һаман үз сүзен бирмәде:

—Әйберләремне җый, китәм,—диде.

—Ни белән китәсең син, әни?

—Машиналар йөреп тора, ялгыз карчыкны юлда калдырмаслар.

—Төн заманында нишләмәкче буласың?—дип өзгәләнде ачуы кабара башлаган Нәфисә.

—Вокзалда кунам.

—Беркая да җибәрмим! Ят, тынычлан. Әгәр иртәгә китәм, дисәң, машина белән илтеп куярбыз.

Хурлыҗинан калды. Мэлс шоферы аны иртүк Чаллы автовокзалына алып китте. Шулай итеп әби белән кияү хушлашмыйча аерылыштылар...

12

Иртәгә авылга кайтып килергә кирәк иде. Әти-әниләренең хәлен белмәгәнгә егерме көннән артты бугай. Ирекнең соңгы вакытта акчасы кысылды. Айгөл дә авылда, алар янында иде. Иң элек ул керләнгән оекбашларын салып атты, әле чыгы кибеп бетәргә өлгермәгән бәпкә үләненә кайнар табаннары белән басты һәм, үләнне ерып, капкага таба атлады, артыннан кара-кучкыл булып эз калды. Ул аягын күтәрмичә, чаңгы белән йөргәндәге кебек, салкын чыклы үләнне ярып, аякларын шудыра-шудыра йөрде дә йөрде. Салкыннан табан аслары кымырҗыды, бармак араларын бала вакыттагы кебек үлән кытыклады. Өй түбәсендәге ояда, аңа эндәшкәндәй, пар сыерчык туктаусыз сайрады да сайрады. Өйгә керәсе килми иде. Койма буенда яткан юан имән агачына басып, ул Ык ягына күз ташлады. Нинди яшеллек! Сизелер-сизелмәс өрфия аша яр буендагы талларның шәүләләренә кадәр күренә. Ык өсте җем-җем итеп кояшка күз кыса, бал кортлары быжылдый, тагын әллә нинди бөҗәкләр оча. Урам якта яшәүчеләрнең кайсынындыр ихатасыннан тавыклар кыткылдаган, әтәчләр кычкырган тавышлар ишетелә. Ык ярында үлән чемченүче кәҗәләр, яшь бозаулар күренә. Ирекнең бакчасыннан ерак түгел бер сарык ике бәтиен ияртеп үлән чемченә. Аның бәрәннәре сикерә-сикерә әниләре тирәсендә йөриләр, сөзешәләр. Менә зәңгәр күктә сарык бәтиләре төсле ике ак болыт бер-берсен сөзделәр дә акрын гына бергә кушылып эределәр һәм кояшка таба шуыштылар. Талгын җилдә ялтырап торучы җете яшел агач яфраклары тын гына лепердәшә, барлык җиһан яшәү кичерә, җанлана, чәчәккә күмелә, җимеш бирергә әзерләнә. Табигать, ашкынып биегән чибәр кызлардай, болын уртасында чабучы яшь колындай, якты кояш астында каядыр томырыла, җәй кыяфәтендә тирә-юньгә җәелә, күз-колакларга, бөтен тәнгә иңә, хуш исләре, җилләре, дәртләндергеч тавышлары белән җанга һәм канга тула...

Ирек, юынып, кырынып, өс-башын алыштырып, кибеткә юл тотты. Башының авыртуына түзәрлек түгел иде. Ашыга-кабалана ике шешә сыра, ипи алып кайтты. Шешәнең берсен ачып, бик озаклап эчте, кичтән калган ике ярка салкын бәрәңгене тозга манчып, кара ипи белән теләмичә генә чәйнәп йотты. Аның ашарлык рәте юк иде. Шуннан соң күлмәкчән генә ишек алдына чыгып, ял итә-итә мунчага су ташыды, шабыр тиргә батты. Мунчаны ягып җибәргәндә, инде сәгать унбер тулып килә иде. Ул күңеленнән бер генә теләк теләде: аракы күтәреп килүче генә булмасын иде. Төштән соң мунча кереп хәл җыйгач, сумкасын тотып, тагын кибеткә чыгып китте. Әниләренә күчтәнәчкә конфет-прәннек, хәлвә, алма кебек нәрсәләр алды, аннары универмагның киемнәр бүлегендә бик озак йөреп, Айгөлгә ярардай зәңгәр йон кофта тапты. Аның бәхетенә ул көнне беркем дә кермәде.

Иртән иртүк, әйберләрен җыеп, Баллы Төбәккә юл тотты. Әтисе белән

әнисе аны гадәттәгечә куанып каршыладылар. Әнисе берөзлексез өстәлгә ашарга әйбер ташыды, шул арада Ирек каршына туктап, аның чал чәчләрен сыпырды, яшьле күзләре белән кызганып карады. "И, улым!"—диюдән башка берни дә әйтә алмады. Шушы бер сүзгә барысы да сыйган иде. Ул соңгы вакытта нык кына тартылган, хәрәкәтләре салмакланып калган. Әтисенең эштән туктаганына ике ел. Йөрәк бетереп, нервы туздырып йөрисе дә калмагандыр ана, дип уйлады Ирек эченнән генә. Айгөл рәхәтләнеп йоклый иде. Кызының аксыл йөзен, алсу мендәргә таралган йомшак чәчләрен, одеал өстеннән чыккан ябык кулларын ул күзләре белән туйганчы иркәләде. Аннары зәңгәр кофтаны алып кереп, кызының янәшәсенә салды. Артына борылып караса, әтисе белән әнисе кече яктан аны күзәтеп торалар икән.

—Бәгырьләрең өзеләдер инде, улым,—диде әнисе, елавын сиздермәскә тырышып борынын тарта-тарта.—Безнең дә исебездән гел чыкмый балакаем.

Аның сүзләрен ишетмәгәндәй, Ирек әтисенә:

—Миңа кичкә дежурга барасы, берәр эш эшләп китсәм, сезгә ярдәм булыр иде,—диде.

—И-и-и, улым!—әтисе көлгәндәй итеп куйды.—Ул эшләрне санап кына бетерерлекмени! Ихатада кыймылдап торучы булмагач, җыела икән ул. Мал өенең тәрәзә астындагы ике ниргәсе череп беткән. Беркөн төрткән идем, кулым тышка чыгып китте. Шуны рәтләп карасак инде.

Ирек эш киемнәрен киде дә, балта-пычкы алып, алар абзарга керделәр. Ике почмакка ике бүкән тыгып куйганнан соң, черек ниргәләрне бәреп чыгардылар, дөресрәге, Ирек үзе эшләде, әтисе өйрәтеп торды. Мал өенең озынлыгын үлчәп, бер ару гына имәнне кистеләр, аннары Ирек аның баш-башларын киртләде, өстенә бүрәнә утырырлык итеп, буеннан буена ырмау алып чыкты. Аны бау белән сөйрәп китереп, нигез ташы өстенә куйганда, аның киеменең коры җире калмаган иде инде. Көннең эсселеге, махмырдан соңгы хәлсезлек, күптәннән бернинди физик эш эшләмәү үзен нык сиздерде. Битендәге, муенындагы тирләрен сөртеп, ул койма кыләгәсенә килеп утырды, озын-озын итеп, шаулатып сулыш алды. Шул вакыт утарга зәңгәр кофта кигән Айгөл йөгереп керде һәм әтисенә ташланды. Ирек кызын күкрәгенә кысты, йөрәге туктап калгандай булды. Аны битләреннән, колакларыннан, муеныннан үпте.

—Әти, син моны миңа алып килдеңме?—диде Айгөл, кофтасына күрсәтеп.

—Сиңа, кызым.

Шулчак алар янына зур кызыл әтәч кукраеп килә башлады, өч-дүрт адымда туктап калды, башын кыйгайтты да аларны карарга кереште.

—Синең кофтаңа кызыгып карый, урлап китмәсен тагын,—диде Ирек һәм алар әтисе белән кеткелдәп көлделәр.

—Үз гомеремдә моның төсле усал әтәч күргәнем юк иде,—диде Хәйри.—Әле дә кеше булып яралмаган. Кеше булса, бөтен дөньяны канга батырыр иде.

Ул әтәчкә таба бер кизәк ыргытты, ләкин әтәч житез иде, үзенә туптуры килгән кизәктән ул башын иеп кенә калды, урыныннан кымшанмады.

—Кызым, чукый күрмәсен, менә моның белән куркыт,—дип Хәйри Айгөлгә бер чыбык тоттырды.

Көндезгә эш төгәлләнде. Ниргәнең ачык калган җиренә арыш саламын балта белән чапкалап тутырдылар.

—Мин аңа юеш сыер тизәге чабармын, цемент кебек тора ул,—диде Хәйри.

Аннары ишек алдына чыгып, тагаракта җылынган су белән икесе дә бил тиңентен юындылар. Ирек башта, тагын берәр эш эшләп булыр, дип уйлаган иде, әмма кереп ашагач, кыймшанырлык та хәле калмаганлыгын аңлады. Авыл хәлләрен сораштырып, Айгөл белән уйнап бераз вакыт уздыргач, ул китәргә җыенды. Әнисе аның сумкасына кечкенә миски белән сөт өсте, өч литрлы банка белән катык, карлыган вареньесы тыкты. Айгөл "китмә, китмә", дип бик ялынса да, эшкә барасым бар шул, кызым, дип, тагын кайтырмын

әле, дип аны юатты. Алар капка төбендә әнисе белән Ирекне озатып калдылар. Олы юл чатына чыгып баскач, әтисе Ирекнең йөзенә текәлеп карап торды.

—Улым,—диде ул әллә нинди сагышлы тавыш белән.—Бик таушалгансың...

—Их, әти,—диде Ирек өзгәләнеп.—Бөтенесе бергә җыйналды бит. Менә монда,—ул йодрыгы белән күкрәгенә сугып алды.—Мин акланырга теләмим. Сезнең йөзегезгә кызыллык китермәс өчен мин барысын да эшләрмен, әти...

—Ышанам, улым,—диде әтисе.

Ул арада юл идарәсенең чуерташ ташучы машинасы килеп туктады. Әтисенә кул биреп, Ирек кабинага күтәрелде.

Кайтып өенә керү белән, ул караватка ауды, тыелгысыз рәвештә эчәсе килә, шуна чакырып, ниндидер көч бәгырьне суыра иде. Әгәр бер генә йотса да, аның бөтен җаны рәхәтләнәчәк, рухы газаплы тартышудан, тыелудан котылачак иде. Юк, газаплансын, тартышсын, мин беркая да барачак түгел, диде ул үз-үзенә һәм мендәренә капланып ук ятты. Шулчак капка ачылып ябылганы ишетелде, кемнәрдер сөйләшә иде. Ирек шундук аларның Бәкер белән Миргаяз икәнлеген таныды. Ни гаҗәп, баягы уйлары, әтисе белән булган сөйләшү, аңа биргән вәгъдәсе, көчле җил алып киткән төтен кебек эреде дә юк булды. Йөрәге еш-еш тибеп, аларның керүен көтте. Менә алар ишек шакып эчкә үттеләр, Ирек торып утырды.

—Әллә көпә-көндез йоклап ятасың инде?—диде Миргаяз, кул биреп исәнләшкәч.

Аннары ул өстәлгә бик матур итеп эшләнгән, зур, шакмаклы шешә чыгарып утыртты.

—Энекәш миңа салган, күчтәнәч итеп, илле градус, инде без иртәнге якта да ике мәртәбә кагылып киткән идек. Башласак, сиңа авыз иттерми калырбыз, дип курыктык.

—Минем бит бүген эшкә барасым бар, егетләр.

—Авыз итеп кенә карарсың,—диде Бәкер.—Күчтәнәч бит. Алар шакмаклы шешәнең төбенә төшкәннәрен сизми дә калдылар. Кичкырын кояш сүрелгәндә, алар өчесе дә яшел чирәмгә чыгып утырдылар, Миргаяз гармунын дәртләнеп уйнады да уйнады, йөрәкләрне өзгеч моң Ык буеның яшел үзәннәренә, таллыкларына кереп, кош тавышларына кушылды һәм шунда эреп юкка чыкты. Ирек эшкә ярты сәгать соңарып барды. Инде караңгы төште, ул ишек алдына чыгып әрле-бирле йөрергә кереште. Гараж янында өч каен агачы уртасына ясалган кечкенә өстәл, утыргычлар бар иде. Анда шоферлар буш вакытларында тәмәке тарталар, гәп коралар, Ирек шунда барып утырды һәм бер генә минутка дип башын өстәлгә салды. Ул машина тавышына уянды, күзен фара яктысыннан кулы белән каплады. Әзрәк күз ияләнгәч, ул каршысында Гаскәров басып торганын күрде. Ул арада шоферы гараж капкасын бикләп куйды.

—Ирек Хәйриевич,—диде Гаскәров кисәтүле тавыш белән.—Сәгать төнге ике икәнен беләсезме? Мин ашыгыч Казанга киттем, урынбасарга әйтерсез.

Ирек хурлануыннан җир тишегенә кереп китәрлек булды.

Ике көннән соң, ул эштән азат итүне сорап гариза язды.

—Нишләп китәсез?—диде Гаскәров, аңа аптыраулы караш ташлап.

—Сезгә авырлык салырга теләмим. Барысы өчен дә рәхмәт, Сәет Мөбәрәкович.

Шул төндә аның район башкарма комитеты бинасында соңгы мәртәбә дежур торуы булды.

## 13

Июль башында Әхмәттән хат килеп төште. Ул Ирекне повесть буенча сөйләшергә Казанга чакырган иде. Димәк, басарлык булмаган. Нәрсәсе ошамаган—ул хакта Әхмәт ләм-мим бер сүз язмаган, күрәсең, алдан ук борчыйсы килмәгән. Ирек костюм-чалбарын үтүкләде, күлмәкләрен

юып киптерде, ярты көн буе плащын чистартты, туфлиләрен ялтыратты. Бакчада инде кыярлары өлгереп килә, помидорлар да күренә, кәбестәләр, суган-укроплар, чөгендерләр матур булып күтәрелеп килә. Ирек аларга батырып су сипте, ашлама кертте. Бәрәңгеләрен күмсәләп чыккан иде. Берничә көн генә вакыт үтәчәген уйлап, Бәкер белән Миргаязга ике көнгә бер мәртәбә яшелчәләргә су сибәргә кушты. Кайткач сыйлармын, диде, әгәр корытсагыз, муеныгызны борырмын, дип тә өстәде. Әхмәткә күчтәнәчкә бер чиләк жир җиләге сатып алды, аны полиэтилен капчыкларга тутырып, портфеленә салды.

Аэропортка барып, билет алып чыккач, ул самолет төшә торган урыннан әйләнде һәм үз-үзенә, җәй үтеп бара икән бит, дип куйды. Үләннәр инде яшеллекләрен югалтканнар, елмаеп-көлеп йөргән кешенең эчендә сиздермәс чир чыгып, йөзеннән нур китә башлаган кебек, алар да инде җәй белән хушлашырга әзерләнәләр иде, күрәсең. Аэропорт буендагы каеннарның әле кайчан гына майлаган кебек елтырап торган яфракларын әллә тузан каплаган, әллә инде аларга сүл җитми, әллә кояш күп кыздырудан хәлсезләнгәннәр—барысы да төс җуйганнар. Ирек иелеп бер сарут сабагын өзеп алды, бәләкәй чактагы кебек, аның буынын теше белән чәйнәде, суырып карады. Сарут сабагы инде катып өлгергән, ачкылт тәме юньләп сизелми дә.

Менә офыкта болытлар астыннан төшүче самолет күренде. Үрдәк төсле чех самолеты әкрен генә килеп, аэропортка кунды һәм, бик каты мотор тавышы чыгара-чыгара, пассажирлар янына диярлек үк килеп туктады. Берничә минуттан алар һавага күтәрелделәр. Бу элекке АН-2 түгел иде, очуы бик тә рәхәт булды. Сәгать нәкъ унберенче яртыда Ирек Әхмәт утырган бүлмәнең ишеген шакыды. Аның, керегез, дигән тавышын ишетүгә, эчкә узды, шау-гөр килеп кочаклашып күрештеләр. Ирекнең беркайчан да нәшриятта булганы юк иде, күңелендә аны нindидер илаһи сарай итеп, редакторлар заманча җиһазланган зур бүлмәләрдә утыралардыр, дип күз алдына китерә иде. Әхмәтне нindидер бер караңгы чоланны хәтерләтүче тар гына бүлмәдә күрү аны сәерсендереп җибәрде. Ишек катында ук бер олы китап шкафы, уртада бер-берсенә терәп куелган ике өстәл, ул өстәлләр турында стенага ук терәлеп торучы ике урындык һәм шуларның берсендә утыручы Әхмәт. Тәрәзә төбе тулы кәгазьләр, папкаларга төрелгән кульязмалар, уртада сулы графин, кырлы стакан, трубкасы зәңгәр изолента белән уралган телефон, карандашлар салынган пластмасса стакан, кергән кешегә утыру өчен күне шактый кыршылган диван.

—Йә, ничек килеп җиттең?—диде Әхмәт, өстәл тартмасыннан Ирекнең повесте салынган папканы чыгарып куеп.

—Сизми дә калдым, гел янәшәдә генә икәнбез, атна саен йөрешеп тормалы.

—Синең янга бер кайтып килсән, ярар иде ул,—диде Әхмәт елмаеп.

—Әйдә, китәбез.

—Һәй, малай, казанга салган тавыкның сикереп чыга алганын күргәнең бармы синең? Без дә шулай инде. Пешкәнче кайныйбыз да кайныйбыз. Син чишенеп утыр әле, тирләгәнсең.

Ирек плащын салып элүгә, ул повестьны актаргалый башлады. Ирек кульязмасының битләре кызыл карандаш белән чуарланганлыгын, сорау, өндәү билгеләре куелганын күреп алды.

—Әгәр мин нәшрият директоры булсам, синең бу повестьны бастыру өчен барлык көчемне салыр идем,—дип башлап китте Әхмәт.—Сюжетны кызык кына коргансың, язганнарың беркемне дә кабатламый. Син күтәргән проблемалар гаҗәп тә актуаль. Ләкин күп кенә урыннары бәхәс тудыра. Иң беренчесе—синең муллыкка каршы көрәш ачуың.

—Мин муллыкка каршы көрәш ачмыйм. Мин нәфесне чикләү ягында.

—Аңлыйм, аңлыйм,—диде Әхмәт.—Ул чикне билгеләп буламы соң? Әгәр дә без бүген чыгарыла торган товарларның, техниканың, җиһазларның, салына торган корылмаларның төрләрен киметергә чакырабыз икән, без кемгә кул күтәрәбез, кем бакчасына таш ыргытабыз? Беренчедән, бу партия куйган программага каршы килә.

—Мин алай димәс идем,—дип тагын бүлдерде аны Ирек.—Ихтыяжларны чикләү, акылга муафыйкларын гына үстерү кирәклеген партия үзе дә алга сөрә бит.

—Анысы шулай. Ләкин аскетларча түгел. Син халыкның яхшы тормыш хәленә кизәнәсең.

—Алай ук түгел бит инде, Әхмәт... Фантастик әсәр бит бу, чит планетада бара.

Әхмәт кычкырып көлеп җибәрде.

—Йә инде, дустым, бөгештермә инде син! Андагы вакыйгаларның кайда барганын һәркем аңлый. Җыйнап кына әйткәндә, повестьның идеясе начар түгел. Ләкин аны башкачарак яссылыкта, бүтәнчәрәк үстерергә кирәк.

—Йомшартып юкка чыгарыргамы?

—Белмим, көчәйтә алсаң, көчәйт. Тик бәйләнерлек булмасын.

Алар Әхмәт белән ике сәгать буе бәхәсләштеләр, кызышып беттеләр.

—Син бит бүгенге җәмгыятьне төбе-тамыры белән актарасың, яраксызга әйләндереп, сүтеп ташлыйсың,—дип очып-очып кунды ул Ирекка.—Һич югы син барысына да кагылма, икмәк тутырылган капчыкның бер почмагын тычкан тишкән төсле, бәлкем берсен генә сайлап алыргадыр. Тоташ кире кагып булмый, бер повесть моны күтәрә алмый.

—Ә менә театрда минем пьесамны әзерлиләр,—диде Ирек, шулай ук сүрелә алмыйча.—Анда да шушыңа якын сюжет, нәкъ шушында күтәрелгән проблемалар. Куркып тормадылар. Быелгы сезонны шуның премьерасы белән ачабыз, ди режиссер.

—Мин театрны белмим, мин үз эшем өчен үзем җавап бирәм. Ышан: бу хәлеңдә повестеңны хет Берләшкән Милләтләр Оешмасына алып бар— чыгара алмыйсың. Ялгыш әйтәм икән, Америкада шатланып чыгарырлар иде. Алар өчен бу атом бомбасыннан да көчлерәк корал булыр иде.

—Димәк, безнең ил өчен ярамый?

—Бик ярар иде дә...—Әхмәт аның күзләренә карап торды.—Ярамый шул. Бәлкем киләчәктә син күтәргән проблемаларны яктырткан меңләгән әсәрләр чыгар, ваклап-ваклап, аз-азлап. Ә болай берьюлы булмый. Аннары телен дә бер карап чыгасың бар. Синең язганнарың элек бик җанлы була иде. Ә бу повестеңда, турысын әйткәнгә гафу ит, ниндидер шапшаклык сизелә. Әллә ашыккансың, әллә башка сәбәп. Мин аларны кызыл карандаш белән күрсәтеп бардым. Бер эшләп чыгарга кирәк.

Ул папканы бәйләп Ирекка бирде. Ирек урыныннан торды.

—Миңа кайтып китсәм дә ярый инде алайса?

—Йөзеңә үпкәләү билгеләре чыкты. Сиңа дөресен әйтмичә, алдап-йолдап, редакциядән редакциягә йөртергә мөмкиннәр. Андый хәлләр очрый монда.

—Рәхмәт,—диде Ирек, повестен портфельгә салып.

—Аңлыйм, сиңа бу сүзләрне ишетүе авыр, башлаганда мин дә шулай идем. Кыйный торгач, күнегәсең аны.

—Миңа бүген очаргадыр инде,—диде Ирек.

—Ашыкмый тор. Повестеңны баш редакторга да укыттым. Ул иртәгә иртән сине кабул итә ала. Бүген өйдә юк. Аның белән сөйләшүнең зарары тимәс.

—Ярый алайса,—диде Ирек, аның белән килешеп.

Әхмәт аны нәшрият ашханәсенә алып кереп сыйлады, бүлмәсенә чыккач:

—График буенча бүген типографиягә төшерәсе кульязмам бар. Синең белән йөри алмыйм,—диде.—Казанны караштырып кайт. Бездә кунарбыз.

—Комачауламаммы соң?—диде Ирек ихлас күңелдән.

—Квартира зур минем,—диде Әхмәт көлеп.—Син теге вакытта килгәндәге бер бүлмәле түгел, икеледә яшибез.

Әхмәтнең хатыны аларны бик ачык йөз белән каршы алды. Квартирага кергәч, Ирек берни аңламый торды. Идәндә ике бала йөгереп йөри, тагын ике-өч хатын-кыз күренә. Ул да булмады, бер ир чыгып, Ирек белән күреште.

—Бусы минем энекәш була, Дамир исемле. Хатыны белән бездә торалар.

Әнә теге тешсез кыз—аларның баласы. Ә менә бу ташбашы—минем иреннән аерылган кызымның малае.

Әхмәт ыштансыз малайны идәннән күтәреп алды да, битләреннән, бүксәсеннән чат-чот үбеп кире бастырды. Ул арада кызы чыгып, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән генә исәнлек бирде, малаен, әйдә киендерим әле, дип алып кереп китте. Залга узгач, юан гына, яшь кенә хатын белән исәнләште.

—Бусы минем энекәшнең хәләл җефете.

Ирек биргә кайтканына үкенеп куйды. Квартирада ятып йоклау түгел, басып торырлык та урын юк иде. Ирек җиләкле пакетларны, бакчадан гына өзеп салган биш-алты кыярны өстәлгә куюга, теге тешсез кыз йөгереп килеп, кыярга үрелде. Бармагы белән тиюе булды, зур гына кыяр тәгәрәп килеп, аның нәкъ борынына төште, ул акырып елый башлады, әйдә тавышгауга купты.

Алар бик тәмләп кыздырылган бәрәңге суктылар. Чәй эчкәннән соң, Әхмәт аны ваннага алып керде. Борылгысыз булып әйбер тутырылган ванна бүлмәсенең бер почмагында тартмага охшаган шакмаклы нәрсә тора, аның өстенә клеенка җәелгән, шунда нинди-дер язулы кәгазьләр, ручка ауный иде.

—Минем язу өстәле шушы була,—диде Әхмәт көр тавыш белән.—Шәпме? Теләсә нинди язучы көнләшерлек. Берни эшләп булмый, малай. Әгәр башыңда фикерең, йөрәгеңдә ялкын булса, монда да язып була. Менә кичә генә язган шигыремне укыйммы?

Ул әлеге тартма өстендәге кәгазьләр арасыннан иң өстәгесен алды да укырга кереште. Ирек ванна читенә утырган килеш шигырьне тыңларга тырышса да, фикерен туплый алмады, аның нәкъ маңгай турында төрле үлчәмдәге колготкилар, ыштаннар, күкрәкчәләр, тагын әллә нәрсәләр асылынып тора, уң якта клизма савыты эленгән, каршыдагы кыпшакланган кечкенә көзгенең читендә теш пасталары, щеткалар, иннек-кершәнгә охшаган әйберләр, хушбуй шешәләре тыгызлап берсе өстенә икенчесе өелгән иде.

*Нинди иркен, нинди иркенлек бу!*
*Күз күреме җитми офыкка.*
*Күңелемдә бары якты уйлар,*
*Хыялларым җитми очып та...*

—Йә, ничек?—дип сорады Әхмәт, шигырьне укып бетергәч.

—Образлы, яхшы әйтелгән,—диде Ирек, алдашуы өчен кызарып.—Күңел хөрлеге турында моннан да яхшырак әйтеп булмый торгандыр.

—Мин менә хәзер бер поэма язып ятам,—диде Әхмәт.—Ул хакта хатын белән икебез генә беләбез. Турыдан-туры әйтелмәсә дә, Татарстанның бик олы бер җитәкчесе турында булачак ул. Аны укыган кеше ул икәнлеген төп-төгәл беләчәк. Ул поэмага заказны миңа өлкә комитетыннан бирделәр. Берүк беркемгә дә ычкындыра күрмә.—Әхмәтнең йөзе әллә ничек җанланып, монарчы күренмәгәнчә яктырып китте.—Их, малай, шуны әйбәтләп кенә ерып чыксам, юньлерәк квартир да бирмәсләр микән? Мин бит сине күрсен дип махсус алып кайттым. Әле бездә абыйның авылдан укырга килгән студент малае да тора. Ул бүген юк, кайтып китте. Күңелем киң, урыным тар.

—Поэмаң ни турында була соң инде ул?—дип сорады Ирек, аңа аптыраулы караш ташлап.

—Әлбәттә, син күтәргән проблемалар юк инде анда. Абзыйны әүлия кебек җитәкче итеп күрсәтергә кирәк. Мин моңа рәхәттән түгел, михнәттән алындым. Нәшриятка урнашуым да юкка түгел. Директор белән баш редактор ике-өч елда ничек тә квартиралы итәбез, дип ышандыралар. Мин, көн саен иртән уянгач, Аллаһы Тәгаләдән аларның исәнлеген сорыйм.

—Син бит гомер буе Алланы сүгеп йөргән кеше,—диде Ирек көлемсерәп.

Әхмәт аның көлемсерәвенә елмаеп та җавап бирмәде, тагын да җитдиләнеп китте.

—Сүксәм сүккәнмендер инде. Алай-болай була калса, ярдәме тимәсме, дим инде. Бүгенге җитәкчеләр эштән китеп барса, бөтен хыялларымның

пыран-заран килүе бар. Алар урынына миңа квартира бирердәй кешеләр киләме, әллә юкмы...

Әхмәт тагын дүрт-биш шигырь укыды, Ирек шигырьләрне дулкынланып тынлады, дустының әдәби осталыгының үсүенә чын-чынлап куанды. Алар бик соң яттылар, шулай да Ирек әз генә дә йоклый алмады. Квартираның стеналары уттай кызган, ачык тәрәзәдән дә саф һава нишләптер керми иде. Тәрәзәләр вак кына тишекле капрон челтәр белән капланган булсалар да, бүлмәгә үтеп кергән черкиләр нечкә тавышлары белән колак төбенә үк килеп "ми-и-и-ин!" дип сузалар, йокымсырап киткәндә генә уяталар иде.

Икенче көнне Ирек баш редакторга керде. Йөзеннән ару-талчыгу билгеләре бәреп торган бу кеше Ирекне кабул иткәч, сүз башлаганчы ук сәгатенә карап куйды:

—Беләсезме,—диде ул.—Мин өлкә комитетына киңәшмәгә ашыгам, төп фикеремне генә әйтәм. Бәлкем сез күтәргән мәсьәләләрнең шактые белән мин дә килешәмдер. Тик без бер нәрсәне оныта алмыйбыз: партия политикасы һәм идеологиясе бар, ул нәрсәләргә каршы килеп булмый, цензура да якадан ала. Шушы күзлектән чыгып караганда, язучының гениаль әсәре дә дөнья күрә алмый. Әхмәт белән без озаклап сөйләштек, фикерләребез туры килә, шуна күрә аларны кабатлап тормыйм.—Ул сәгатенә карап куйды.—Повестьның төп канвасын саклаган хәлдә, икенче яртысын кабат эшләргә кирәк.

Аның янынннан Ирек күңеле төшеп, каршылыклы уйлар белән чыкты. Әхмәт аны тагын бер-ике көнгә калырга кыстады, Ирек ризалашмады. Аэропортка шылтыратып, бүгенге самолетка урыннар бар икәнен белгәч, Болынкырга очты.

Берничә көннән Ирек Минзәләгә шалтыратты. Режиссерның тавышы бик борчулы ишетелде:

—Сезнең әсәр буенча репитицияләрне туктаттылар бит әле...

Ирек үзенең ничә көннәр буе яшәгән бәхетле дөньясының чайкалып куюын сизде.

—Нәрсә булды?

—Кемдер райкомга да, өлкә комитетына да безнең тормышка кара яга торган спектакль әзерләнә, дип хәбәр иткән.

—Хәзер нишлибез инде?

—Берни дә эшләп булмый,—диде режиссер тавышын акрынайтып.—Мин мәдәният министрлыгына барам әле. Төзәткәләп чыгарырга рөхсәт итсәләр, эшләп карарбыз.

Ике-өч көн уйлана торгач, Ирек чигенергә булды. Әхмәтнең киңәшләрен тотып, повестьның кайбер кискен урыннарын алып атарга, мөмкин кадәр йомшартырга, шул корбаннар бәрабәренә булса да, аны дөньяга чыгарырга ниятләде.

## 14

Гел көтмәгәндә бөтен районны шаулаткан хәл булды. Ике-өч көн саен сөт мәсьәләсендә әле колхоз-совхоз председательләрен, әле белгечләрне, әле ферма мөдирләрен җыеп, Арсланов берәм-берәм дип әйтерлек бастырып кыздыра, партиядән куу белән яный, тиешле күрсәтмәләр бирә, тик сөт кенә кимүен дәвам итә. Аның үзен дә әле өлкә комитетыннан, әле авыл хуҗалыгы министрлыгыннан туктаусыз бызгаклап торалар, олыраклары телгә алмаслык сүзләр белән сүгәләр, өлкә комитеты бюросы белән яныйлар иде.

Ул көнне өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире бер инструктор белән килгән иде. Ферма мөдирләреннән алып, барлык җитәкчеләрне район мәдәният йортына җыйдылар. Башта сөт җитештерүнең торышы турында авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы чыгыш ясады, аргта сөйрәлүче хуҗалыкларның җитәкчеләрен трибунага чыгарып информация ясаттылар, "сөтне фәлән көнгә фәлән кадәр арттырачакмын", дигән вәгъдәләрен

алдылар. Соңгы көннәрдә "Авангард" бик нык артка тәгәрәгән иде. Арсланов аны әйтеп кенә, бик итәгатьле итеп кенә кисәтеп үтә торган иде. Ләкин өлкә комитеты бүлек мөдиренең алдына куйган кәгазьгә "Авангард" дип язганын, сорау һәм өндәү билгесе төшергәнен күргәч, Батталовны трибунага чакырмыйча булдыра алмады. Батталов, аксак аягы белән тык-тык басып, залны аркылы үтте, чал чәчләрен сыпыра-сыпыра, трибуна артына басты.

—Без инде сезне, Гайсә Батталович, һәрвакыт башкаларга үрнәк итеп куябыз. Тик соңгы вакытта сөт белән артка тәгәрәвегез генә аңлашылмый. Эш нәрсәдә?—диде Арсланов, кулындагы ручкасы белән өстәлгә шакылдатып.

Батталов залга бер күз төшереп алды да, президиумга башын борып сөйли башлады:

—Мин инде үзем сезнең янга килергә йөри идем, Миңзаһит Усманович. Без малларга салам да, печән дә ташый алмыйбыз.

—Техникагыз бар, ник ташымыйсыз?—дип бүлдерде аны Арсланов.

—Партком секретаре сатты безне!—дип кычкырып җибәрде Батталов.

Залдагы халык та, президиумдагылар да аптырашып киттеләр.

—Әйе, сатты, бер генә эскерткә дә бара алмыйбыз. Кәк техника басуга таба кузгала, партком хәбәр итә дә, самолетлар килеп, эре калибрлы пулеметтан тракторларга пуля сиптерә башлыйлар.

Залда кемнәрдер көлеп җибәрде, аптыраулы пышылдау, сөйләшү тавышлары ишетелде, Батталовның чырае ачулы иде.

—Гайсә Батталович,—диде Арсланов кып-кызыл булып.—Без монда уйнарга җыелмадык. Нинди самолет сөйлисез сез?

—Нинди самолет булсын, немец самолетлары! Урманлы тау артында көтеп кенә торалар да һөҗүмгә ташланалар. Маллар ач килеш акырып ята. Әнә җавап бирсен ул хәзер сезнең каршыгызда.

Зал шаулый башлады, кемнәрдер көлештеләр, президиумдагылар сүзсез генә бер-берсенә караштылар.

—Гайсә Батталович, сез авырыйсыз түгелме соң?—диде Арсланов, аптыраулы карашын аңа төбәп.

—Мин сау-сәламәт, менә сез авырый торгансыздыр!—диде Батталов, аңа таба йодрыгын селтәп.—Үзегезнең партком секретарен яклыйсыз. Мин аптырагач үземнең ау мылтыгыннан атып карадым, ядрә белән немец самолетын бәреп төшереп буламыни?

Залда берни аера алмаслык шау-шу купты. Инде күпләр эшнең нәрсәдә икәнен аңлаганнар иде.

—Сезгә кайтырга мөмкин, Гайсә Батталович,—диде Арсланов, аннары больницаның баш врачы Әмировка карап:—Иптәш Әмиров, Гайсә Батталовичны озатып куегыз,—диде.

—Киңәшмә бетмәгән килеш, мин беркая да китмим. Әмиров ни пычагыма миңа! Әллә ул немец самолетларын мәтәлдерә аламы?—Батталов шулай диде дә залга төшеп үз урынына барып утырды.

Арслановка тәнәфес игълан итүдән башка чара калмады. Коридорга чыккач, Арсланов аны култыклап үз бүлмәсенә алып керде, утырырга кушты, аннары чыгып, Әмиров белән милиция начальнигы Хасбулатовны алып керергә чакырды. Аларны күргәч, Батталов урыныннан сикереп торды һәм Арслановка мыскыллы караш ташлады.

—Сез нишләтергә уйлыйсыз мине?—диде ул калтыранган тавыш белән.

—Бүгенгә ял итегез, Гайсә Батталович.

—Ә ник мин ял итәргә тиеш?! Әле киңәщмә бетмәде, сез үзегезнең партком секретаре сүзе белән миннән котылмакчы буласыз.—Аннары ул ничектер тиз генә Арслановның каршысына килеп басты.—Ә-ә-ә! Сез бит бергә эш итәсез, сез минем колхозны таякка таяндыру өчен немецлар белән берләшкәнсез!

Арсланов ияге белән Хасбулатовка ишарәләде, тегесе шундук Батталовны килеп кулыннан эләктерде, икенче ягыннан Әмиров култыклады. Аны Арсланов бүлмәсеннән акырта-акырта алып чыгып киттеләр...

Гайсә Батталович Казан психбольницасында бик озак дәваланды. Зиһене ачылган вакытларда, ул андагы авыруларны күреп, аптыраштa калды. Китапларда, газеталарда язылганча, ул биредә бер генә Наполеонны да, Гитлерны да, Сталинны да очратмады. Аның урынына сизмәгәндә сиңа ерткыч кебек ташланучылар, шулар белән бергә башын аска иеп, үз язмышларын аңлап, хәсрәткә баткан бәндәләр күп иде. Ул үзе кайсыдыр институтта профессор булып эшләүче кеше белән дуслашты. Кайчакларда алар көннәр буе сөйләшеп йөриләр, тормышның гаделсезлегеннән зарланалар, үзләрен шушында китереп япкан кешеләрне тиргиләр. Гайсә Батталович үзен дәвалаучы врачка да, хәтта больницаның баш врачына да инде терелеп бетүен әйтеп, кайтарып җибәрүләрен сорады. Уфада яшәүче инженер малае да, берничә мәртәбә килеп, аны алып китәргә сөйләшеп карады. Башкаларны берничәшәр айга өйләренә кайтарып җибәрсәләр дә, ни сәбәпледер, аны кайтудан тыйдылар. Октябрь башларында, инде беренче кар күренгәч, ниһаять, аны малае Уфага алып китте. Андагы таныш врачлары аша иң югары түрәләр дәвалана торган больницада айга якын яткырды.

Ул кайтып төшкәндә, инде беренче кар яткан иде. Райкомда аны куанып каршыладылар, күтәреп кенә алмадылар. "Син югында колхоз күзгә күренеп артка тәгәрәде,—диделәр.—Зинһар эшне үз кулыңа ал, "Авангард"ны үз урынына бастыр",—диделәр. Батталов дәртләнеп эшкә кереште, фермаларны йөреп чыккач, салкын җил өреп торган тәрәзәләрне, тизәккә батып беткән туракларны һәм малларны күргәч, аның йөрәге чәнчешеп куйды. Ничек туракларны, малларны шушы хәлгә төшереп булуына баш җитми иде. Колхозның барлык белгечләрен җыеп, идарәнең киңәйтелгән утырышын уздырды, һәркемгә аерым эш участогы билгеләп, башкару срокларын куеп, һәрберсен кулыннан тотып диярлек эшкә кушты. Заманында тәүге мәртәбә хуҗалык җитәкчесе итеп сайлангач, ничек бер караңгыдан икенче караңгыга чапкан булса, шулай чапты. Аның болай йөрүләренә хатыны Разия бик борчыла, "синең яшь чагың түгел, авыруыңның кабат булу ихтималы бар", дип куркыта. Кичләрен тизрәк өйгә кайтырга чакырып телефоннан шылтырата. Ләкин Гайсә аның сүзләренә буйсынмый, больницадан котылуына куанып, эшли дә эшли. Бервакыт колхоз-совхоз җитәкчеләрен Чаллы зонасына семинарга җыйдылар. Озак еллар председатель булып эшләгән, республикада танылган җитәкче буларак, ул райком секретарьлары, партия өлкә комитеты, министрлар советы вәкилләре катнашкан банкетка чакырылды. Банкет искиткеч мул табын янында матур-матур мәгънәле сүзләр әйтеп, шаулап-гөрләп барды. Менә бервакыт Гайсә Батталовичка тост әйтергә сүз бирделәр. Шунда ул тагын ялгышты.

—Без, иптәшләр, соңгы вакытта сизгерлегебезне югалттык,—дип башлап китте ул.—Менә минем каршыда утыра торган бу ике кешенең, әнә теге өстәлдәге пеләш башлы озын сары адәмнең немец шпионнары икәнен беләсезме?

Банкетта утыручылар бердәм күтәрелеп көлә башладылар, аның сүзләрен барысы да шаярту дип аңладылар.

—Мин сезгә өчесен генә күрсәттем, ә күпме алар биредә!—диде Гайсә Батталович, уң кулының йодрыгын өстәлнең төрле ягына төртә-төртә юнәлтеп.—Мондый гамьсезлек белән без бөтен илне юкка чыгарачакбыз...

Хәзер инде аның сөйләгәннәрен беркем дә тыңламый, банкет залы тәртипсез тавышлардан чайкалып тора иде. Арсланов үзенең янәшәсендәге Казан вәкиленә нидер әйтте, берничә минуттан әзмәвердәй ике егет Батталовны култыклап алып чыгып киттеләр. Үзенең "Волга" машинасына кертеп утырткач, ул тынычлана калды. Арсланов аның шоферына нидер әйтте дә эчкә кереп китте.

—Әйдә, кузгалдык, бу халык белән берни дә кырып булмый,—диде Гайсә Батталович.

Алар әйбәт кенә кайтып җиттеләр. Шоферы өйгә кадәр кертеп куйгач, Батталов үзенең үтә нык арыганлыгын сизде. Разия аны чишендереп урынына яткырды.

Иртән сыерларны көтүгә кугач, Разия черем итеп алырга яткан иде. Бервакыт коточкыч гөрселдәү тавышына ул чәчрәп сикереп торды. Ул арада тагын гөрселдәү яңгырады. Борынына дары исе бәрелде, өйгә зәңгәрсу төтен таралды. Ул йөгереп зал ягына чыкты, ачык тәрәзәдән иренен ике көпшәле мылтыктан патрон чыгарып маташканын күрде.

—Гайса, нишлисең, акылыңа кил!—дип мылтыгына барып ябышты.

—Тс-тс-ссс!—диде Гайсә, хатынынын авызын тотып.—Әнә койма артында немец разведчиклары яшеренеп тора, хәзер юк итәм мин аларны.

Шулай дип Гайса буш патроннар урынына яңаларын тыгарга әзерләнде. Разия анын кулыннан ул ике патронны тартып алды да урамга ташланды. Гайса да мылтыгын тоткан килеш, кычкырып анын артыннан чыкты:

—Хатын, капкага барма, немецлар эләктерә!

Разия урамга атылып чыкты, күршеләренә йөгереп керде. Аталы-уллы Мәхмүтовларга хәлне аңлаткач, алар, киенеп тә тормыйча, Гайса янына йөгереп керделәр. Ул аларны башта якын китерми торды, мылтыгы белән селтәнде, "Фашистлар, канэчкечләр, мин сезгә барыбер бирелмим!" дип кычкырды. Аны эләктереп бәйләделәр дә ашыгыч ярдәм чакырдылар. Бусында Гайсаны бер айдан кайтардылар. Ана эшләү тыелган иде инде. Ул үзенен кылган гамәлләрен күпмедер дәрәҗәдә хәтерләп, авырганын аңлады. Арсланов янында Нәҗмиевне дә чакырып сөйләшеп утырганнан соң, ул эштән азат итүне сорап гариза язды. Колхозчыларнын гомуми җыелышы бик тантаналы шартларда үтте. Батталовка партия өлкә комитетынын һәм Министрлар советынын Мактау грамотасын, тагын әллә нәрсәләр, үзе йөргән "Волга" машинасын бүләк итеп бирделәр. Гайса өйдә, ихатада, бакчада кыймылдап, хатыны белән тыныч кына көннәр кичерә башлады. Кайчакларда акрын гына басулардан, фермалардан, мастерскойлардан урап кайтты, идарәгә кагылды. Ул бернигә дә борчылмады, нәкъ врачлар кушканча, берни белән кызыксынмады, күзе белән битараф карап кына йөрде. Ләкин ана үз гомере буе күпме көчен түккән, йокысыз төннәрен, сәламәтлеген биргән шушы басулар күргән саен һаман аңардан ерагая баралар кебек тоелды. Мең төрле газап белән, законны мең төрле юллар белән урап, акча һәм материал табып төзегән ферма, мастерской торaклары, мәктәп, культура йорты, кибетләр, коттеджлар, шулай ук анардан ятсыналар, аны хәтта танымыйлар кебек тоелды. Ләкин алар дәшми торган җансыз әйберләр, ә менә җанлы кешеләрнен баш кагып кына китүе, аны күргәч, чит урамга, йә булмаса кабалана-кабалана берәр тыкрыкка кереп китүләре, "Нихәл, Гайса Батталович!" дип хәлен белешмәве анын бәгырен парә-парә телгәләде. Әллә соң минем чирем башымда гына түгел, кешеләргә йога торган микроблар рәвешендә бөтен тәнемә таралган микән?—дип үз-үзеннән сорады ул еш кына. Алар өчен тырышкан Гайсага кешеләрнен болай битараф карарга хакы юк иде. Мондый хәлдән котылу өчен ул колхозның барлык белгечләрен, тармак җитәкчеләрен, үзе кирәк дип санаган гади кешеләрен, пенсионерларын җыеп, зур бер банкет үткәрергә уйлады. Бу хакта ин элек райкомга барып Арсланов белән киңәште:

—Сәламәтлегем әйбәт, чирем кабатланмый,—диде ул көр тавыш белән.—Тик минем күнелне сезгә сөйләгән менә шул нәрсә кимерә,—диде ул әңгәмәнен ахырында.—Халыкны җыеп, күзгә-күз карап, бер гөрләшеп утырасы иде. Мин бит алтмыш яшемне дә район җитәкчелеге белән генә билгеләп үттем. Халыкнын йә шуна хәтере калгандыр.

Арсланов банкетка рөхсәт бирде. Өстәлен колхоз әзерләр, уздырыгыз, диде.

Колхоз идарәсенен икенче каттагы утырышлар залына йөз илле кеше сыешлы итеп урын әзерләделәр. Гайса үзе күрсәтмәләр генә бирде, анын урынына председатель булып калган Гобәев һәр төрле җиләк-җимешенә, виноград-хөрмәләренә кадәр үзе кайтартты, табынны үзе әзерләтте, менюны төзеп, кайсы ризыкны кайчан чыгарасын кисәтте. Төрле-төрле эчемлекләр, алар янына затлы рюмкалар куелды. Ул көнне Гайса белән Разия мунча кереп, өсләренә ин затлы киемнәрен киделәр. Киленнәре белән бергә өч яктан өч малай кайтып төште.

Кичен билгеләнгән вакыттан шактый алда барысы да идарәгә җыелдылар.

Гобәев ике-өч баян алып килеп куйды. Күрсәтелгән вакытка беркем дә килмәде, ярты сәгать узгач, баш зоотехник күренде, нишләп үзен генә, дигәч, хатын чирли диде. Бригадир белән агрономның да хатыннары авырган булып чыкты. Баш бухгалтерларның, бажасы авырып, Бакалыга китеп барган, диделәр. "Бу нинди бөтен кеше чирли торган көн булды соң бу?" дип эченнән генә борчылды Гайса. Ул эченнән борчылса, малайлары әрле-бирле бәргәләнделәр. Билгеләгән вакыттан сәгать ярым узгач, утыз җиде кеше җыелды. Алар да колхозның төрле тармагында җитәкче булып эшләүчеләр яисә белгечләр иде.

—Әйдә, башла,—диде Гайса Гобәевкә.

Гобәев үзенчә мәҗлесне ачкан булып, Гайсаның хезмәтләрен берсен дә калдырмыйча санап чыкты. Аны иң матур сүзләр белән мактады, рюмкаларга шәраб, аракы салып, эчеп җибәрделәр. Аннары кем туры килә, шул басып сүз әйтте, сыек кына итеп кул чаптылар. Гайса аларның бер генә сүзен дә ишетмәде, ул бу дөньядан каядыр еракка китеп бара иде. Соңыннан малайлары, хатыннары да сөйләде. Аш пешерүче пешекчеләрне дә чыгарып утырттылар, кемнәрдер җырлаган булып маташты. Бервакыт ялан кадәр залда унбиш-егермеләп кенә кеше утырып калды.

—Димәк, кешеләрнең читләшүе хак, аларга хәзер мин кирәк түгел,—дип уйлады Гайса.—Кайчандыр ничәмә-ничә авылдан торган бу хуҗалыкта Гайса ихтыярыннан башка бер генә эш тә эшләнми иде. Ул бер зур оркестрның дирижеры кебек, таякчыгын тотып, селтәп кенә җибәрә һәм бөтен халык аның кушканыннан энә очы кадәр дә чигенмичә, эшкә тотына иде.

Оркестрда утыручылар гомер буе Гайсаның күзенә карап тордылар, керфегенең селкенүеннән, сулыш алуыннан аның ни әйтергә теләгәнен аңладылар, һәр хәрәкәтенә булат кылычка караган кебек карап, сүзсез буйсындылар. Колхозның бу оркестры менә шулай ничәмә-ничә еллар буе өзлексез уйнады, аның тавышын районда гына түгел, Казаннарда, Мәскәүләрдә дә ишеттеләр. Председатель кабинетындагы мәңгелеккә алынган Кызыл байраклар, Мактау грамоталары, дипломнар—Гайса илһамландырган кешеләрнең хезмәт җимешләре. Ул, акрын гына торып, зал буйлап китте. Уйлана-уйлана тәрәзә каршына барды, аны ачып куйды, тыштан җәйге төннең хуш исле һавасы залга агылды. Гайса тагын бүлмә буйлап урап килде, тәрәзә каршына басып:

—Миңа да сүз бирегез әле,—диде.

—Рәхим итегез, рәхим итегез,—диде Гобәев кабаланып.

Гайса янына аның инженер малае килеп басты.

—Улым, мин сүз әйтәм, утырып кына тыңла әле,—диде Гайса, ана кисәтүле караш ташлап.

Ул түргә таба берничә адым атлады да туктап калды.

—Менә, балалар, безгә бүген шушындыйрак мәҗлестә утырырга туры килде. Үз гомеремдә минем төрле табыннарда булганым бар, тик мондыен беренче мәртәбә күрәм.—Ул сулышы өзелеп туктап калды, калтыранган кулларын яшерер өчен биленә салды.—Минем хезмәтемә шушыдыр бәя. И, җилкендем, и каударланып чаптык, басукайлардан кайтып кермәдек. Нәрсәдер төзедек, кемнәрнедер тиргәдек, үзебезне тиргәделәр, рәхмәт сүзләрен дә күп ишеттек. Мин эшләгән чорларны начарлык белән искә алмагыз, килүегез өчен рәхмәт. Борчуым өчен кичерегез, болай буласын белсәм, сезне дә чакырып интектермәгән булыр идем. Мин сезгә бер нәрсә васыять итеп калдырырга телим: яшьлегегезне башкаларга бирмәгез! Яшьлегегез үзегездән аерган өчен сездән үч алачак. Яшь гомерне башкаларга бирү—ул изге шәҗәрә агачының йөрәгендәге канын агызып читләргә эчерү, беркайчан да донор булмагыз! Бу гөнаһ өчен ул мәңге дәвалый алмаслык чир җибәрәчәк, яисә башкача җәзалаячак. Белеп торыгыз: бөтенесе дә бик тиз узачак! Сезгә мәңге бетмәс, очы-кырые күренмәс кебек тоелган тормыш юлының нибары ике адым озынлыкта икәнен аңларсыз, әмма соң булыр.—Гайса үрелеп рюмкасын алды, аның бите тирләп чыккан, кызарган һәм ялтырап тора иде.—Әйдәгез, яшьлегебезне үзебезнеке итү, аны озаккарак сузу өчен эчик.—Аннары ул

борылып, тәрәзә янында басып торган малаена дәште:—Улым, кил бире.

Малае өстәл янына килеп житә алмады. Гайса тәрәзәгә атылды, ачып куелган рамнарга тотынып, тупсага тезләнде, чылтырап пыяла коелып төште.

—Әти!

Малае бер сикерүдә аны костюмыннан эләктереп алды һәм идәндәге пыяла ватыклары өстенә сөйрәп төшерде. Табында утыручылар барысы да дәррәү сикереп тордылар.

—Улым, жибәр мине, зинһар жибәр!—дип илерде Гайса.

Анын маңгаеннан кан ага, күлмәгенә, өр-яңа күк костюм-чалбарына тама иде. Үзен сырып алган кешеләргә, ике ягыннан тоткан улларына ул ялварып карады, хырылдап акырды:

—Балаларым, жибәрегез!—диде.—Әйтегез аларга: жибәрсеннәр мине! Мин бит берни дә сорамыйм. Мина үләргә генә ирек бирегез!

Ул сабый бала кебек кычкырып еларга тотынды, анын коточкыч йөзенә карагач, тәннәрдә бала йоннары кабарырлык иде. Кинәт ул кычкыруыннан да, елавыннан да туктады һәм пыялаланган күзләрен тирә-юньгә йөртергә кереште. Гайса үзенә терәлә язып немецларнын тезелеп торуын күрде, үрсәләнеп үзенен Калашников автоматын эзләде, әмма таба алмады, талпынып караса да, каты итеп тоткан куллар аны ычкындырмадылар. “Барысы да бетте, жинелдем, үтерделәр”,—дип уйлады ул эченнән һәм күзләрен йомды. Анын каршында искиткеч матур күл пәйда булды. Күлнен өсте тып-тын, янәшәсендә зур ябалдашлы мәһабәт имән үсеп утыра. Күл өстендә тезелешеп сап-сары бәпкәләр йөзә, әмма нишләптер аларнын әти-әниләре күренми. Ул сары йомгаклар кызганыч итеп пипелдәшәләр, төрлесе-төрле якка йөзеп, әниләрен эзлиләр...

Иртән анын янына район үзәгеннән ике врач килеп төште. Алар Батталов белән озаклап сөйләштеләр, күзләрен ачтырып карадылар, нишлибез, дигән мәгънәдә бер-берсенә карашып тордылар.

—Әйе, кичтән мин авырып алдым,—диде Гайса, кайсы төшләренен авырганын күрсәтергә теләгәндәй, ике кулы белән башын сыпыргалап.—Барысы да үтте. Зинһар Казанга гына жибәрмәгез.

—Дәваланып чыксагыз, комачауламас иде.

—Егетләр, сүземә ышаныгыз: мин хәзер сау-сәламәт. Әгәр кабат авырсам, сөйләшеп тә тормассыз.—Анын күзләреннән яшь бәреп чыкты.—Үтенеп сорыйм...

Шактый вакыт уйланып торгач, баш врач Әмиров Арслановка шылтыратты.

—Мин Гайса Батталович яныннан әле.

—Хәле ничек сон?

—Ул сау-сәламәт, зиһене безнекеннән әйбәтрәк эшли. Нишләтик?

—Катлауланулар булмаса ярый да.

—Булмас, дип уйлыйбыз.

—Ул чакта өендә калдырыгыз.

Врачлар чыгып киткәч, Гайса жинел сулыш алды һәм тирән йокыга чумды.

## Өченче кисәк

### 1

Өлкә комитетындагы кинәшмә шактый озак барды. Аны йомгаклаганда, беренче секретарь Минзаһитны сискәндергән сүзләр әйтеп куйды. “Кайбер райкомнарнын беренчеләре,—диде ул.—Үзләренә бирелгән властьтан файдаланып, контрольне оныталар. Сонгы вакытта халыктан жалобаларнын артуы шул хакта сөйли. Кайберәүләр машина белән уйныйлар, кайберләре үзләренә аппартамент төзергә кызыга,

кайсыберләре кадрлар белән жонглерлык итә",—диде ул, залны авыр карашы белән капшый-капшый. Озакка сузылган киңәшмә гаять арыткан булса, әлеге сүзләр киемгә сипкән кислота кебек акрын гына күңел тынычлыгын көйдерәләр иде. Урамга чыккач, ул салкын декабрь һавасын күкрәк тутырып, рәхәтләнеп сулады. Инде сәгать ике тулып килә, эре кар ява һәм көчәйгәннән-көчәя баручы җил кар бөртекләрен тәртипсез бөтерә, буран чыгасын кисәтә иде. Ярты сәгатьтән караңгы да төшә башлаячак.

Минзаһит машинасына чыгып утырды да шоферына:

—Гостиницага,—диде.

Киңәшмәдә утырганда ук, аның планы әзер иде: Лира өйдә булса, бүген аңарда тукталып, күңелен бушатып, аңарда кунып кайтырга. Ул өйдә булмаса, башкаларына шылтыратырга була. Тик аңа Лира кадерлерәк иде.

—Бүген кайтып тормабыз,—диде ул шоферына, "Татарстан" гостиницасы алдына килеп туктагач.—Машинаңны урнаштыр, иртәгә сигезләрдә кузгалырбыз. Минем бүлмәне беләсең,—диде.

Керү белән Миңзаһит телефоннан Лираның эш номерын җыйды. Ул урынында иде.

—Минем синдә кунак буласым килгән иде,—диде ул, хәл-әхвәл сорашкач.

—Рәхим ит,—диде Лира.—Бик тәмләп әзерләгән дерелдегем дә бар...

Алар иң элек Лираның эш урыныннан ерак булмаган ресторанда очрашырга булдылар. Миңзаһит алданрак барды, иң караңгы почмактан урын алып, ике кешегә ашарга заказ бирде, аракы китертте. Ресторанда әлегә кеше күп түгел, талгын гына музыка уйный. Буранлы урамнан кергәч, аракы эчә-эчә кәефләнеп утыру өчен бик тә уңайлы иде. Лира нәкъ сәгать дүрттә килде. Алар хәл-әхвәл сорашып, ашап-эчтеләр, музыка астында башкаларга ияреп танцевать та иттеләр.

—Кайтабызмы?—диде Лира, ниһаять.

—Биш кенә минут утырыйк әле, киңәшмәдән бик арып чыктым,—диде Миңзаһит.—Хәтта аракы да ала алмый.

Шул чак аның күзе ресторанның ишегенә төште һәм ул урын эзләп башын як-якка боргалаучы Шәвәлиевне күреп алды. "Шайтан алгыры,—дип уйлады.—Әллә соң арттан йөриме бу? Киңәшмәдә дә биш-алты урын аша гына утырды. Күрешкәч, беренче секретарь авырый, шуның урынына килдем, диде." Миңзаһит Лираның колагына иелде дә:

—Әнә теге кешене күрәсеңме?—диде ишарәләп.

—Әйе. Кем соң ул?

—Бу миндә элек икенче секретарь иде.—Ул арада Шәвәлиев, әллә Арслановны күреп, әллә күрмичә, туп-туры алар ягына килә башлады.—Син мине, мин сине белмибез,—дип пышылдады Миңзаһит Лирага.—Бергә чыгу ярамас, мин үзем барырмын өенә.

Ул арада Шәвәлиев алар янына килеп басты.

—Юкка гына, дөнья тар, дип әйтмиләр, Миңзаһит Усманович,—диде ул ихлас елмайган кыяфәт чыгарып. Аннары ике буш урынның берсенә күрсәтеп:—Утырырга мөмкинме?—диде.

—Мөмкин генә түгел, кирәк,—дип көлгәндәй итте Миңзаһит.

Ул арада официант та килеп җитте. Шәвәлиев ашарга заказ бирде, Минзаһитка борылып:

—Очрашу хөрмәтенә берәрне тотарбыз бит?—дип сораулы караш ташлады.

Миңзаһит "ярар", дигән мәгънәдә баш какты.

—Бу чибәр ханым сезнең кемегез дип белик?—диде Шәвәлиев.

—Өстәлдәш кенә. Без таныш түгел,—диде Миңзаһит.

Ләкин Шәвәлиев барысын да аңлаган иде, өстәлдә бушаган ак аракы графины тора, ике рюмкага ак аракы салынган, һәртөрле салатлар тезелгән; "Оста кулын бозмый", дип уйлады ул эченнән генә. Шәвәлиев икесенә аракы салганнан соң графинның авызын Лираның рюмкасы өстенә китерде:

—Сезгә мөмкинме?

—Юк, юк, рәхмәт,—диде Лира кызарып.

—Минем исемем Зөфәр, сезнеке ничек?—диде ул Лиранын соры күзләренә төбәлеп.

Лира исемен әйтте һәм шундук Минзаһитнын кисәтүле карашын сизде.

—Менә, Лира туташ, сезнең каршыгызда халык ихтирамына лаек кеше, зур шәхес Минзаһит Усманович утыра. Әгәр анын хөрмәтенә без бер рюмка тотмасак, алла үзе безнең чыраебызга төкерергә мөмкин,—дип ул Лиранын да рюмкасын тутырды.

Ресторан мәйданчыгында танцы башланды, Шәвәлиев итәгатьле генә баш иеп, Лираны биергә чакырды. Лира каушап китте, күз чите белән генә Минзаһитка карап алса да, ниндидер көч тәэсирендә аягүрә басты һәм Шәвәлиев белән биергә китте. Минзаһитнын котырып ачуы чыкты. "Бу һаман да гомер буе минем юлыма аркылы төшәчәк икән", дип ачынып уйлады ул. Лирага баш тартып, кайтып кына китәргә кирәк иде бит. Ул каш астыннан гына аларның бер-берсенә сыланып бетеп танцы иткәннәрен, Шәвәлиевнең туктаусыз Лираның колагына иелеп нидер сөйләвен, Лираның туктаусыз матур итеп көлүен ачу белән күзәтеп утырды. Лира юри матур итеп көлде. "Иреннәренне бөреп көлгән чагында өстәлдәге озынча йомры борыч савытын, ай, авызкаена тишекле башы белән тыгып куярга!"—диде Минзаһит пышылдап. Ачуына чыдый алмагач, аракы эчеп куйды. Алар килеп утыргач, юри читкә карап, Лираның аягына аягы белән кагылды: бу—кайтып кит, дигән сүз иде. Шәвәлиев Лира исәнлегенә аны мактап тост тәкъдим итте һәм алар өчесе дә тутырып эчеп куйдылар. Мондый очракларда була торган вак-төяк сүз китте, Шәвәлиев анекдот сөйләп алды, Минзаһит кабат Лираның аягына кагылырга теләп аягын сузды, ләкин кагыла алмады, шуннан соң ул юри салфеткасын төшереп җибәрде һәм аны алу сылтавы белән өстәл астына күз атты: Шәвәлиевнең аягы Лираның аягы өстендә иде. "Ах, эт бүксәсе,—дип уйлады Минзаһит ачуыннан буылып.—Мин бүген анын өчен дип калдым, күпме вакытымны югалттым. Ә бу кәнтәй, әле Шәвәлиевнең килеп утыруына ярты сәгать вакыт узмаган, инде чыршы сагызы кебек аңа сыланды". Лираның үзенеке генә түгеллеген Минзаһит абайлый иде, әмма күз алдында шулай кыланыр дип башына да китермәде. Тагын танцыга чакырып музыка яңгырады. Шәвәлиев торып басып, бик нәзакатьле итеп башын иде һәм кулын сузды. Инде анын кайтырга кузгалмаячагын анлаган Минзаһит та кинәт кенә торып басты һәм Лираны танцыга чакырып баш иде. Лира көлеп җибәрде һәм күзләрен уйнатып, чытлыкланып әле Шәвәлиевкә, әле Минзаһитка карады:

—Гафу итегез,—диде ул маймылланып.—Алдан кем чакырган, мин шунын белән чыгам.

Шәвәлиев аны култыклап ук алды. Лира, артын килешле уйната-уйната, анын белән янәшә атлады. Минзаһит бер ярты китертте, бокалына салып каплап куйды һәм аларнын икесен дә ашардай булып карап утырды.

Шәвәлиев белән Лира көлешә-көлешә өстәл янына килеп утырдылар, икесенең дә битләре алланган, күзләре очкынланган. Шәвәлиевнең симез җәлпәк борынын чәнечке белән кадап алып, чытырдатып чәйнисе килде Минзаһитнын. Шул ачуын басар өчен ул шатыр-шотыр китереп тавык боты чәйнәде, Минзаһит крыжовник ярата иде. Лираның ике яшел күзен чәнечке белән чокып алып чәенә саласы һәм тешләп суырасы килде... Тик, шайтан алгыры, боларнын берсен дә эшләп булмый иде шул... Лира Минзаһитнын ни дәрәҗәдә ачуы котырганын чамалады, кисәк кенә сикереп торып:

—Гафу итегез, минем вакытым бетте,—дип чыгып китте.

Әмма төлкедәй хәйләкәр Лира, танцы вакытында сөйләшкәнчә, Шәвәлиев алып чыгып бирсен өчен ридикюлен юри урындыгында калдырган иде. Шәвәлиев өлгергәнче, Минзаһит ридикюльне эләктерде дә:

—Бу хатынның башын тәмам бутагансың, әйберләренә кадәр оныта башлаган,—дип анын артыннан чыгып китте.

Лира пальтосын киеп кенә бетергән иде, Минзаһит ана ридикюлен сузды һәм култыгыннан эләктереп ишеккә таба тартты. Тышка чыгу белән ачуына

буылып:

—Бар, олак, проститутка несчастная!—диде һәм аның яңагына чабып җибәрде.—Яңадан күземә күренәсе булма!

Минзаһит ярсып кереп китте.

—Бирдегезме?—диде Шәвәлиев, мәкер белән елмаеп.

—Бирдем, бирдем. Рәхмәт әйтеп алды. Әйдә, тотыйк әле. Сезнең тагын бер баскычка үсүегез өчен.

Шәвәлиев, иреннәрен мимыл-мимыл китереп, яңагын чәйнәп куйгач, болай дип өстәде:

—Миңа үсәргә сез этәргеч бирәсез бит, өметләнәбез инде...

Үзенең икенче районга күчүендә Арсланов кулы уйнаганны ул аңлаган иде инде. Шуңа күрә Минзаһит аңа астан гына карап:

—Ул этәргеч өчен сез үпкәләмисездер ич?—диде.

—Юк кебек,—диде Шәвәлиев сагаеп.

Миңзаһит, барысын да тутырып әйтмәкче булып, Лира ачуын алырга теләсә дә, тыелды. Әгәр алар монда якага-яка килсәләр, ул кайткач Болынкырга шундый сортлы гайбәт орлыклары сибеп китәчәк иде ки, инде алар тоташ шытым биреп, бер генә Лира булып түгел, йөз Лира булып үсеп чыгачаклар. Юк, Шәвәлиев белән ызгышырга кирәкми иде. Үгез үлгән—уртага аерылган. Шуңа күрә ул чәчүгә әзерлек, терлекчелек белән кызыксынган булды, нинди кадрлар эшләвен сораштырды. Рестораннан алар бергә чыктылар. Шәвәлиев машинасы белән илтеп куярга теләсә дә, ул, һава сулыйм, дип баш тартты.

Миңзаһит акрын гына Казан урамыннан атлады. Бирелдәге җитәкчеләр рәхәт яшиләр, дип уйлады ул эченнән. Кара инде, бөтен җирне гирляндаларга күмгәннәр. Әле яңа елга ике атна вакыт бар, ничә мең киловатт ут яна торгандыр, боларга күпме чыгымнар тотыла торгандыр—алар өчен бу пүчтәк, алар моны бар дип тә белми. Ә син үзеңнең караңгы районында һәр тиенеңне санап иза чигәсең. Эре кар бөртекләре аның битләренә килеп бәрелде, затлы бүрегенә, тун якасына кундылар, алар шаярырга, Миңзаһитның күңелен күтәрергә телиләр иде. Әмма аның сынар төге дә селкенмәде, уйлары әллә кайда йөрде. Аның күңеле бүген рәнҗетелгән, тапталган, ярдәм сорап кычкыра. Әгәр Хәятны ятратса, ул Миңзаһитка тиң булса, шушылай итеп йөрер идеме соң ул беренче секретарь башы белән? Барып чыкмады аның тормышы. Ул менә үзе белән бүтән районнарның беренчеләрен чагыштырып карый, күпләренең өйләрендә булганы бар. Шул чакларда ничә мәртәбәләр Миңзаһит көнләшү тойгысы кичермәде. Аларның барысының да хатыннары үзләреннән күп мәртәбә акыллырак, итәгатьлерәк һәм барысы да диярлек дөньяның бер чибәре. Ә Миңзаһит кемгә капты? Ни чибәрлеге юк, ни сәламәтлеге юк, ни башкасы... Нигә соң Миңзаһит гомере буе анардан котыла алмыйча, читтән үзенә пар эзли? Әйе, аның сөяркәләре булды, хәзер дә күп, арада Лира кебекләре дә шактыйдыр. Ул сиңа бүген шундый турылыклы кебек, синнән башка миңа беркем дә кирәкми, ди, мәче кебек мырлый, башын күкрәгеңә салып иркәләнә, борын очыңа кадәр үбә, икенче көнне шушы ук эшләрне башка ир-ат белән эшләми дип кем әйтә ала? Аның өчен Сөембикә генә кадерле, ул Миңзаһитның күңелендә аерым урын тота. Менә хәзер аның белән, беркемнән курыкмыйча, шушы ак карлар уртасыннан күңелең шушы кар бөртекләре кебек очынып илһамланган хәлдә култыклашып атласаң иде!

Ул кунакханәгә кайту белән тиз-тиз чишенде дә йокларга ятты.

## 2

Зөфәр Шәрипович Болынкырга төнге икенче яртыда гына кайтып керде. Ул юлга чыкканына үкенеп бетә алмады. Буранның котыруының чик-чамасы юк, юлда читкә төшкән машиналар, батып ятканнары, бөке ясап, берсе артына берсе тезелгәннәре санап бетергесез иде. Аның кайтасын көтмәгән Нажия ирен аптырап каршы алды, ашарга әзерләргә

керешге, ләкин Зөфәр ашаудан баш тартты. Машина этә-этә дә манма булган, күтәрә алмаслык булып авырайган пальтосын, кышкы ботинкаларын, чалбарын кабаланып салып ыргытты. Ул арада йокы бүлмәсеннән Нажиянең әнисе чыкты. Ул кияве белән күрешеп, хәл-әхвәлләрен сорашты, эшең бик күптер инде, бик сирәк кайтасың, диде. Зөфәр үзенчә акланды, менә бит Казаннан кайтышлый, төн заманы булса да, күпме юл урап, Болынкырга кагылдым, тегендә дә гел сезне көтәм, тизрәк күчү ягын хәл итәргә кирәк, диде. Алар сөйләшкән арада Нажия залдагы диванны зурайтып урын җәйде. Зөфәр аның бу эшен яратмыйча, күз чите белән генә карап торды. Менә әбисе дә йокы бүлмәсенә кереп китте, Зөфәр залга чыкты. Ятарга чишенә башлады, тыныч төн, диде Нажия һәм залдан чыгып китәргә кузгалды.

—Туктале,—диде Зөфәр ярым пышылдап.—Ничек инде син мине ялгызымны калдырып, әби янына кереп китә аласың?

—Без бу хакта күптән сөйләштек бит инде.

—Син сөйләдең, мин тыңладым. Әле минем ризалашканым юк. Без бүген дә ир белән хатын.

—Ялган торуның кирәге юк...

Зөфәр, кызулап чыгып, кече яктагы утны сүндерде һәм залның ишеген каты итеп ябып куйды.

—Кем сиңа ялган торырга куша?—диде ул тавышын күтәреп.

—Тормыйбыз, тормаячакбыз...

Зөфәр Нажияне иңбашларыннан тотып диванга алып килде һәм көчләп утыртты, үзе дә урындыкны тартып каршысына утырды.

—Нажия! Менә ныгытып уйлап карыйк әле,—дип сүз башлады ул.—Шушы гомер бергә яшәдек, балалар үсеп җитте. Әгәр аеры-чөере килсәк, без нишли алабыз?

—Яшибез,—диде Нажия гади генә.—Яшәячәкбез.

—Ә син беләсеңме, гомеребезнең азагына кадәр син дә, мин дә бер әйбер белән җәфаланачакбыз.

—Нәрсә ул?—диде Нажия куркынып.

—Улмы? Ник аерылышканыбызны аңлату. Барлык туганнарга, дусларга, танышларга, ә иң кыены—балаларга...

—Нишлисең инде, синең белән миннән калмаган,—диде Нажия.

—Таякның иң авыр башы балаларга төшәчәк.

—Мин алар барысын да аңлар, дип уйлыйм.

—Аңлавын аңларлар. Әле бит укып кеше буласылары бар. Аларга уңайлы эш урыны, яшәү шартлары кирәк булачак. Боларны миннән башка син эшли алмаячаксың. Ә инде менә безнең аеры-чөере килү гел юктан минем абруйга китереп сугачак. Мине беренче секретарь итеп калдырулары да бар югарыдагы абзыйларның. Әгәр бөтен республикага сасысак, миңа юл ябылачак, балаларга да. Мин аңлатып әйтә алдыммы?

Нажия бик озак дәшми торды. Зөфәрнең сүзләрендә дөреслек зур иде. Шул ук вакытта балаларга тормышта әзер юллар ачу белән кызыктыруы аңа ошамады.

—Кешечә яшәсеннәр,—диде ул кыска гына итеп.—Тормышның ни икәнен белсеннәр.

—Аңлашылды-ы-ы,—дип сузды Зөфәр.—Гаделлек сакчысы буласың килә. Күперенке сүзләр үзеңә кагылмаганда ярый ул. Итәгеңә төшеп яна башлагач, аңларсың әле.—Зөфәр беркадәр бүлмә буйлап йөренде дә тагын хатынының каршына килеп утырды.—Димәк, син миннән гомер буе яшәгәндәге ачуыңны аласың?

Нажиянең күзләре түгәрәкләнеп китте, аның йөзенә аптырау галәмәте җәелде.

—Әле мин андый түбәнлеккә төгәрәмәдем.

—Тәгәрәгәнсең!—диде Зөфәр кызып.—Син моны астыртын рәвештә күптән көткәнсең. Бу бит мин өйләнә алмыйм, дигән сүз. Әйе, әйе, син аерыласың, мин өйләнә алмыйм.

—Өйлән, минем сүзем юк.

—Менә син минем урынга утырып кара, белерсең анда, аерылып буламы, өйләнергә ярыймы, башкасымы...

—Хатын-кыз белән типтерергә яраганны ник анысы гына ярамасын ди?

—Ул синең каланчаңнан шулай күренә. Меңнәрчә кеше тормышы өчен җавап биреп кара әле син.

Нажия бармаклары белән ике чигәсен ышкый башлады, аннары җәһәт кенә барып, авызына дару капты, су эчте.

—Минем кан басымым күтәрелде,—диде ул ишеккә сөялеп.—Сиңа ничек унайлы, шулай хәл ит.

—Күрәм, син чигенергә уйламыйсың... Соңыннан чәпчеп йөрерлек булмасын, мин сине кисәттем.—Зөфәр тагын урыныннан торып сервант кырына барды, аның киртәләреннән бармаклары белән сыпырды, тузаны бар микән, дигәндәй бармагын күзләренә китереп карады.—Әгәр килешсәк, мин сиңа компромисс тәкъдим итәм: кем сораса да, без бергә яшибез, хәтта әби дә белергә тиеш түгел. Мин кайткалап йөрермен, кулдан килгәнчә булышырмын. Кешеләр сораштырса, күчәсем килми, күнелем тартмый, диярсең. Ләкин бер нәрсә бар: сиңа квартираны бушатырга кушарга мөмкиннәр, ул чакта инде мәҗбүри минем янга күчәсең була. Килештекме?

—Килештек,—диде Нажия һәм әнисе янына кереп китте.

Зөфәр бит аны бу кайтуында, сындырырмын, акылына китерермен, дип уйлаган иде. Юк, кайту ялгыш булды. Аның Нажияне әйләндереп салырлык дәлилләре уйланылмаган иде. Сөембикә Ирекка кияүгә чыккач, ни дәрәҗәдә горур, тугры булып калырга тырышты. Ә бит аны барыбер сындырды Зөфәр. Чөнки аның фикере көчле, дәлилләре кире каккысыз иде. Тормышның башка яклары шатлык бирмәгәч, ир-ат белән хатын-кыз бары тик үзара очрашулардан гына шатлык таба, аларны йөрәкләре ярылудан, тормыш газаплары астында тапталып һәлак булудан шул гына саклап кала, диде Зөфәр. Хәзерге кебек мәхәббәт дигән ялган культ, гаилә культы бетәчәк, диде. Яшәүнең барлык яклары да күрелмәгәнчә ләззәт бирә башлагач, сөю дә гадәти бер шатлык хисенә әвереләчәк, диде. Ярату дигән нәрсә булган сурәттә дә хәзергечә богаулап тотылмаячак, ашап-эчү кебек гадәти шөгыльгә әвереләчәк, диде. Ир белән хатын яшәүнең һәр мизгелендә ничек тели шундый гамәл кыла ала, тулы ирекле һәм монын өчен аны беркем дә гаепләмәячәк, кешелек җәмгыяте шуңа атлый, диде. Иң элек сүз булган, дигән гыйбарәнең әллә чынга әверелүеме бу? Зөфәрнең үз авызы белән кат-кат сөйләгән, Сөембикәне буйсындыру өчен юри уйлап чыгарган фикерләре үз гаиләсендә тормышка ашты түгелме соң?

***

Минзаһит Усманович төне буе саташып, бастырылып чыкты. Иртән күчтәнәчләр алып Эльзаның квартирасына кагылды.

—Кичә дус кызының туган көненә киткән иде, бүген якшәмбе булгач, шуңа йоклагандыр инде,—диде хуҗа хатын.

—Болай лекцияләр калдырмыймы соң? Кичләрен тегендә-монда йөрмиме?—дип төпченде Минзаһит.

—Төнге уннан калганы юк, аллага шөкер, лекцияләренә дә төгәл йөри.

Минзаһит Усманович күчтәнәчләрне калдырып, торган өчен дүрт айлык акчасын биреп чыгып китте.

Алар бик озак кайттылар. Буран инде басылган булса да, әле юллар ачылып бетмәгән иде.

Кайтып кереп чишенүгә, Хәят аны ашарга чакырды, ул балык кыздырган иде. Иң яраткан ризыгы булса да, Минзаһитның аңа кагыласы килми утырды. Бальзам салып, аракы эчү дә аның аппетитын ачмады, ахырда ул тозлы балык сорады, юк икәнен белгәч, хатынына йокысызлыктан һәм

махмырдан кызарган күзләре белән төбәлеп:

—Алырга акчаң юкмыни?—диде.

—Беркөнгесен искергән дип ташлаттың бит. Шуңа алмаган идем.

Хәят тавыш-тынсыз гына киенеп чыгып китте һәм ун минуттан тозлы балык алып кайтып, кискәләп куйды. Миңзаһит теләр-теләмәс кенә, берни сөйләшмичә ашады. Аннары ул Хәяткә мунча ягарга кушты. Суыткычтагы сыра искергән дип, яңа сыра кайтартты. Бераз йоклап ял итте. Торганнан соң берничә шешә сыра алып, мунчага китте. Озаклап, тәмләп керде ул мунчаны. Әммә кайткач, нишләптер хатынына бәйләнәсе килеп:

—Себеркесен юньләп пешермәгәнсең, мунчаның исе бар, ачып суыткач кына рәтләнде,—дип үпкә белдерде.

Аннары өстенә кигән пижамасын болгап атты:

—Сабын исе килә, юньләп чайкамагансың,—диде.

Ул, үзен-үзе тыя алмыйча, кичкә кадәр шулай котырды. Хәят тавышсыз гына елый, күзләрен кульяулыгы белән сөртә-сөртә тәмам кызартып бетергән иде. Кичкә ул анардан пылау пешертте. Аны ашый башлагач:

—Дөгесе тере, ите аз, майга лычкылдаткансың,—дип савытын этеп җибәрде, пылау өстәлгә чәчелде.

Хәят бусында тыела алмады, елап үз бүлмәсенә кереп китте. Миңзаһит өй буйлап кызу-кызу йөрде-йөрде дә аның артыннан керде.

—Ник елыйсың син, алла колы?! Нәрсә җитми сиңа?—дип ташланды.—Ашарыңа юкмы, киярәңә юкмы? Бөтен нәрсә житү, кая барыйм дисәң, кулыңда машина.

Шулчак Хәят яшьле күзләрен аңа таба күтәрде. Калтыранган иреннәре сүз әйтә алмый тордылар, аннары аның теле чишелеп китте:

—Миңзаһит, син ник җикерәсең миңа? Менә бүген көне буе җанымны ашыйсың. Кеше бит малга да алай кыланмый.

Миңзаһит хатыныннан мондый сүзләрне көтмәгән иде.

—Ир белән хатын бер камырдан әвәләнгән инде ул,—дип акланмакчы булды ул.—Мин сине... Мин сине куркытып бетердем бугай инде, Хәят...

—Әгәр курыксаң ярар иде әле ул,—диде хатыны пышылдап кына.—Миңа хәзер барыбер. Нишләтсәң дә барыбер...

Аның бу сүзләре Миңзаһитны сискәндереп җибәрде.

—Ә мин, минем синең янында булуым... анысы да барыберме?..

—Барыбер түгел,—диде Хәят еш-еш сулаган хәлдә.—Турысын әйткәнгә рәнҗемә... Син булмаганда миңа рәхәтрәк...

—Рәхмәт турысын әйтүең өчен,—диде Миңзаһит һәм киенеп тышка чыкты.

Ишек алдын энә табарлык яктыртып, тулы ай балкый, чекрәешеп караучы йолдызлар жем-жем итә. Кисәк суытканлыктан, кар бөртекләре аяк астында шыгыр-шыгыр килә иде. Миңзаһит бүреген киеп чыкмаган иде, аны алырга өйгә кермәде, ишек алдында йөрде дә йөрде. Бу минутларда аңа дөнья бушап калган кебек тоелды. Менә шушы салкын, хиссез ай астында, аңа бернинди җылылык бирмәүче, аны бар дип тә белмәүче салкын йолдызлар астында, шыгырдап торучы салкын кар өстендә, иксез-чиксез җиһан уртасында гүя ул берүзе иде. Ул эшлисе эшләр дә, ул кыласы гамәлләр, буласы очрашулар, кайгы-шатлыклар—һәммәсе каядыр чигенгән, ераклашкан, юкка чыккан иде. Аңа барыбер иде...

## 3

Ирек өчен көн белән төн буталды. Бөтен җирне, әйләнә-тирәсен, күк йөзен кара балчык белән көлне болгаткан төсле, аракы сөреме каплады. Шул сөрем белән тарткалашып җәй үтте.

Шул сөрем белән көрәшеп көз үтте, шул сөремне таратырга тырышып кыш җитте, яңа еллар үтте. Ул кайчакларда үзен көзгедән карый, шешенгән йөзен калтыранган бармаклары белән баскалый. "Бүген генә котылсам, туктыйм, бүген генә бу газаптан котылыйм", ди. Эчтә нәрсәдер утыра: ул

берөзлексез җанынны, тәненне суыра... гел кан гына сорый, ә ул кан шешәдә... Аны бераз эчеп кую белән җанны суыру кими, тартылган урыннарны—ә алар бөтен гәүдәдә—бераз гына ычкындыра бара, ахырда тән дә, җан да котыла. Моңа ышанып та бетәсе килми, гүя син гомерлек зинданнан ычкынгансың, бу якты дөньяга сусап аяк баскансың... Туктаусыз сөйләшәсе, гөрләшәсе, кешеләргә яхшылык кыласы килә. Бөтен нәрсә матур, бөтенесе күркәм, бөҗәгеннән башлап һәр җан иясе сиңа елмаеп-көлеп карый кебек...

Ләкин бу озакка бармый. Туктаусыз суыручы ул нәрсәне туендырырга бервакыт эчәр нәрсә калмый һәм кабат әлеге бәргәләнү башлана... Берни күрмисең, игътибар беркая тупланмый, уй гел бер генә урында бөтерелә: ничек бу интегүдән котылырга? Бары тик эчеп... Тагын ант итәсең: әгәр шушыннан котылсам, янадан бер дә капмас идем, дисең.

Унар-егермешәр көн ул туктап та алгалый. Андый чакларда дөньясын онытып каләмгә тотына. Республика газеталарында хикәяләре, мәкаләләре чыга тора. Болынкыр кешеләре аның белән баш иеп исәнләшәләр, танышбелешләре, яңа басылган әйберләрен укыгач, котлап кулын кысалар, искиткеч тормышчан, дулкынландыргыч, диләр, зинһар күбрәк яз, диләр.

Өенә теге яки бу үтенеч белән килүчеләр дә хисапсыз. Бер татар картының кычкырып елап килеп керүе аның күнеленә мәңгелек яра салды. Ир кешенең шулай ярсып елаганын гомерендә күргәне юк иде. Көч-хәл белән тынычландыргач, бабай карчыгы кабере белән янәшә урысларның күмелгәнлеген сөйләде. Ул карчыгы рухына намазга тезләнсә, урыслар аның каршында аракы эчәләр икән. Буш шешәләрен карчыгы кабере өстенә ыргытып та киткәләгәннәр. Сүз дә юк, мөселманнарны бер читкә, урысларны икенче читкә күмү һәр ике милләт өчен дә зарур нәрсә. "Зинһар язып чык әле, балам, без әйтеп-әйтеп карадык, файдасы булмады",—дип ялынды карт, кайнар күз яшьләрен коеп. Әмма үз исеменнән язуга ризалашмады. Ул кечкенә мәкаләне шул көнне үк Ирек "Бабай ник елый?" дигән баш астында язды. Озакламый республика газетасында басылып та чыкты. Ул газетада элек тә аның "Авыл—милләтнең терәге" дигән күләмле язмасы дөнья күргән, бәхәсләр уяткан иде. Әмма әлеге кечкенә мәкалә зур янарыш алыр, дип Ирек башына да китермәде. Иң элек Болынкыр шау-гөр килде. Аннары газетада милли гореф-гадәтләрне хөрмәтләү хакында җитди сөйләшү кузгалды. Әмма Ирек өчен мөһиме ана Вафин әйткән сүзләр булды: "Хәзер син үзеңне Арслановка каршы куючы реаль көч итеп тулысынча расладың." "Нишләп хәзер генә?—диде Ирек.—Мин гомергә гаделлек сагында тордым." "Беләсеңме, нәрсә, туганым,—дип дәвам итте Вафин.—Элек Болынкырда татарлар белән русларның каберләре икесе ике читтә иде. Арсланов эшкә килгәч, "Что за политика?! Милләтләрне аеруны прекратить!" дип ул нәрсәне туктатты. Сиңа халык магнитка тартылгандай тартыла." Моны Ирек үзе дә сизә. Күңелләрдә уртак ут кайный. Халык аның әлеге яшерен утны дөрләтеп җибәрүен тели, шушы юлда кешеләр аңа бер яклап булышырга телиләр, икенче яклап анарга таянырга, аннан ярдәм алырга өметләнәләр. Бу өмет-теләкләрне аклый алмавы өчен Ирекнең йөрәге парә-парә телгәләнә, көчсезлеге өчен җаны талкына...

Аның акчасы беткәнгә дә инде күптән. Ничә мәртәбә абыйсы Мэлс килеп, аның өстәлендә ипи катысыннан башка әйбер юклыгын күреп, бәрәңгесен, итен, онын китерде, кат-кат үгет-нәсихәт укыды. Ирек һаман вәгъдә бирде, бүген генә, диде, туктыйм, диде. Сөембикә дә килгәләде. Әмма Ирек, аягында йөри алган чагы булса, аның сүзләрен тыңламады: йә куып чыгарды, йә үзе чыгып китте.

Бүген Сөембикә килеп кергәндә, алар Бәкер белән бер борыч аракысын бетереп киләләр иде. Миргаяз баштук исерек иде, бер рюмка эчте дә идәнгә ауды. Сөембикә ишекне ачып керде дә, тупса янына баскан хәлдә, сүзсез торды.

—Ни күрдең?—диде Ирек ана тупас итеп.

Сөембикә җавап бирмәде, ике атлауда Миргаяз янына барып җитте, аны әллә ничек кенә эләктерде дә инбашларына кадәр күтәрде, иелеп

сыртына салды һәм тышка алып чыгып китте. Сөембикә сукмактан чыгып Миргаязны көртнен ин тирән урынына ташлады. Эшнен нәрсәдә икәнен анлаган Бәкер, әле аракысы бетмәгән шешәне кесәсенә тыгып, ишек алдына йөгереп чыкты. Сөембикә аны якасыннан эләктереп алды:

—Әгәр тагын бер мәртәбә шушында күрсәм, урыныгыз төрмәдә булыр. Анладыньмы?

—Ан... анладым,—диде Бәкер.

Сөембикә аны, каяндыр йолкып алырга теләгәндәй, селкетте-селкетте дә көрткә аударды һәм өйгә кереп юк булды. Бәкер аягына басып, кагынырга өлгермәде, карга куллары белән таянып, ах-ух килеп, Миргаяз озын гәүдәсен турайтты.

—Ни булды?—диде ул Бәкергә текәлеп.—Нигә мине чыгарып бәрдегез?

Бәкер ык-мык килеп артка чигенде. Шул вакыт Сөембикә баскычтан Миргаязнын пальтосы белән эшләпәсен болгады.

—Мин түгел, әнә ул,—диде Бәкер, борылып кереп китеп барган Сөембикәгә күрсәтеп.

—Шыттырма, ул мине ничек күтәрсен?

—Менә мин дә шуна аптырыйм шул,—диде Бәкер.—Минем күзем шар булды. Ай-яй, малай, очырды гына! Бәләкәй генә хатын шуны эшли ала димени? Алла бабайнын барлыгына ышандынмы менә?

—Юк, хатын-кыз түгел бу,—диде Миргаяз, эшләпәсен, пальтосын кигәч.—Аждаһадыр бу, ычкыныйк.

Алар йөгерә-атлый капкадан чыгып киттеләр.

Сөембикә, өстәлдәге әйберләрне алып, кайсын кая урнаштыра башлады. Юеш чүпрәк белән идәнне сөртеп алгандай итте. Ирек бер сүз дәшмичә, кулы белән иягенә таянган килеш өстәл башында йокымсыраган хәлдә утыра бирде. Сөембикә анын каршына килде.

—Мин синен аягына баса алмаячагынны тәмам анлап бетердем,—диде ул, Ирекнен кулларын иягеннән алып.—Ач күзенне. Сина үләргә күп калмаган.

Ирекнен кызарган күзләре зураеп киттеләр һәм хәрәкәтләнеп куйдылар.

—Гомер минеке,—диде ул акрын гына, аннары күкрәк турыннан күлмәген учлап, тарткалап куйды.—Менә шушы күлмәк төсле: телим—киям, телим—юам, теләмим икән—ташлыйм. Гомер дә шулай.

—Кызын турында уйладынмы син?

—Уйладым, Сөембикә, бик озак уйладым.—Ирек озын итеп уфылдап куйды.—Мин ана тере килеш ярдәм итә алмыйм. Әгәр мин булмасам, ана пенсия түләячәкләр.

—Андый пенсия кирәк түгел безгә! Мин дә күп уйландым, Ирек. Минем сине коткарасым килә. Мин сина бүген бер сүз әйтергә килдем.

—Нинди сүз инде ул?

—Безгә кайтыйк.

—Анысы мәнге булмас! Башка сүзен бармы?

—Ирек, тынла мине.—Сөембикә анын чәчләрен сыпырмакчы булды, ләкин Ирек тупас рәвештә анын кулын бәреп җибәрде.—Сина айнырга кирәк, берничә көн ял ит, һич югы бераз хәлләнн. Мин бит сине үзем белән яшәргә мәҗбүр итмим.

Ирек бармак янап болай диде:

—Кыз алдында минем дәрәҗәне төшермәкче буласын.

—Анын төшәсе калганмыни инде? Айгөл почмакка поса да елый, синен янга барып кайткан саен шулай. Анын җанынын телгәләнүенә син сәбәпче.

—Син түгелме?

—Ярый, шулай булсын... кайтыйк кына.

—Гөнаһынны юасын килә...

—Ничек телисен, шулай анла. Сине монда йә кереп үтереп чыгалар, йә бөтенегез бергә янып үләсез.

—Бәлкем мин шуны телимдер. Бар, кит әле, күз алдымда торма...

—Китмим, төне буе саклап утырам.

Ирек иелде дә диван артыннан башланган аракы шешәсе алды, стаканга аракы сала башлауга, Сөембикә шешәне аның кулыннан тартып алды да идән юа торган сулы чиләккә агызып бетерде.

—Минә күрденме, барыбер эчермим.

Ирек акрын гына урыныннан күтәрелде, аның бөтен җире калтырый иде. Ул кулларын йодрыклап, Сөембикәгә якынлаша башлады.

—Минем өйгә кереп... кем хокук бирде?.. Минем тормышка катышырга?!—Аның карлыккан тавышы үзенекенә охшамаган иде.— Әйбәтләп әйткәнне аңламасаң...

Ирекнең башының калтыравын, муен тамырларының бүртүен күргәч, Сөембикәгә куркыныч булып китте. Ул йодрыкларын төйнәп, алга ыргылды. Күкрәгенә китереп төртүгә, Ирек чайкалып идәнгә барып төште. Сөембикә юынгыч янындагы каралып беткән сөлгене эләктерде дә аның күкрәгенә тезләнеп, кулларын бергә китереп бәйләмәкче булды. Ирек ухылдап унга-сулга чайкала башлады, Сөембикә тигезлеген саклый алмыйча авып китте һәм аның астында калды. Алар идәндә мышный-мышный тәгәрәшергә керештеләр...

Урындыклар ауды, чиләкнең суы түгелде, шылтыр-шылтыр шешәләр тәгәрәште, өстәл урыныннан күчте, ахырда Ирекнең хәле бетте, ул капланып хәрәкәтсез калды. Сөембикә торып утырды, тузгып күзенә төшкән чәчләрен куллары белән аралап артка сыпырды. Алар икесе дә бөтен өйгә ишетелерлек итеп авыр сулыйлар иде.

—Болайга киткәч, барыбер минемчә булачак!—диде Сөембикә һәм тиз генә Ирекнең аякларын чәкән турыннан сөлге белән кысып бәйләде, торып өс-башын какты һәм шул сөлгедән эләктереп, аны ишеккә таба сөйри башлады. Ирек чалкан әйләнде, аяклары Сөембикәнең кулыннан ычкынып, идәнгә дөпелдәп төште.

—Хәзер үк тукта! Юкса бик начар булачак,—диде Ирек.

Аның тавышы да, йөзе дә котыңны алырлык иде. Сөембикә беравык карап торды да:

—Ник дөмегеп китмисен!—диде һәм ишекне ябып та тормыйча чыгып китте...

***

Кич Нәфисә мичтән кайнар бәрәңге чыгарып маташканда, ишек шакыдылар.

—Керегез,—диде ул.

Ишектән Сөембикә белән Айгөл килеп керде, ак пар өстәлгә үк килеп җитте, Нәфисәнең шәрә тәпиләренә, балтырларына салкын һава бәрелде.

—Мактап кына йөрисең икән, узыгыз.

—Сезне дә хурласаң, тагы ни була,—диде Сөембикә.

Алар чишенеп өстәл янына уздылар.

—Шоферың китердеме?

—Хәзер рульдә үзем йөрим бит. Эштән соң шоферны борчыйсы килми.

Нәфисә баштан ук Сөембикәне өнәмәсә дә, килендәш булып яшәгәндә дә, хәзер дә ул тойгысын яшерергә тырышты. Ул иң элек Алмаз белән Айгөлгә бәрәңге тәкәсен майлап залга алып чыкты. Аннан соң үзләре өстәл янына утырдылар. Сөембикә тагын да чибәрләнебрәк киткән, күзләреннән очкын сирпелә. "Хәзерге хатыннар ирләре үлсә, яисә ирләреннән аерылсалар, күкрәп чәчәк аталар",—дип уйлап куйды Нәфисә. Ул Сөембикә белән очрашкан саен аларның ни өчен аерылышканын ачыкларга тели, әмма "килешә алмадык" дигән сүздән башка нәрсә ишетми. Шуңа күрә ул бу юлы да түзмәде, өстәл янындагы әңгәмәне әкренләп шуна күчерде.

—Хәлләрегез ничегрәк соң, кабат якынаймыйсызмы?

—Бер кискән ипи ялганмый.

—Әйттең сүз. Минә безнең күршеләр гомер буе киселеп торалар, ялганып торалар.

Сөембикә авыр сулап куйды:

—Кем ничек яши бит инде.

—Ә син молодец, аерылыштык дип, борын салындырмыйсың. Культура бүлеге мөдире итеп тә куйдылар, атказанган исеме дә бирделәр.

Сөембикәнең йөзенә үпкәләү билгеләре чыкты. Ул кулына алган бәрәнге тәкәсе сыныгын авызына китергән жиреннән кире савытына куйды һәм акрын гына:

—Син ни әйтергә телисен?—диде.

—Мин хакыйкатне генә әйтәм. Нишләп шулай соң? Укырга кереп аны да төгәлләден.

Сөембикә алдындагы бәрәнге тәкәсен этеп үк куйды, аның кәефе кырылган иде, күзләре дымланып китте.

—Кеше бәхетсезлеккә тарыса, тормышында ялгышса, аңа бөтен юллар бикләнергә тиеш микәнни соң?

—Алай димим... Менә мин дә күпме көч түктем мәктәптә. Мин өйрәткән укытучылар республикада танылды, укучыларым арасында кемнәр генә юк. Мэлс та акрын гына югарыга үрләде: агроном, баш агроном, директор.—Нәфисә күз яшьләрен йота-йота бераз тынып торды.—Минем сөйләгәнем генә юк... беләсеңме, ул кайчан кайтып керсә дә—төн уртасындамы, таң аткачмы—мин аны бер минут йокламыйча көтеп торам. Мин аның кечкенә теләген дә үтәмичә кала алмыйм. Ул минем өстән ничек тели, шулай идарә итә.—Нәфисә кул аркасы белән күз яшьләрен сөртеп алды.—Мин мәктәптә дә аның турында уйларга мәжбүр ителгән. Бары аңа гына унайлы булсын, аның гына эшенә зыян килмәсен, аның эшләре гөрләп барсын.—Ул бераз туктап тынып торгач, әрнеп дәвам итте:—Минем кайгыртуларыма, януларыма Мэлс ничек жавап бирә? Әйтсәм әйтим, мин бит үз гомеремә юньләп ир-ат назы тоеп та яшәмәдем. Йә, әйт, мин аңа лаек түгелме? Мин бит аның өс-башында кеше күзе төшәрлек бер генә кимчелек тә калдырмыйм. Тырнагы киселгәнме, битендә төкләре калмаганмы, кашыннан озын йоннары чыгып тормыймы, чәче тәртиптәме—бөтенесен күздән үткәрәм. Юк, сез берегез дә минем кебек яшәмисез.

Шулчак ишекне ачып, Айгөл кухняга керде.

—Әни, кайтыйк инде, минем дәресләремне карыйсым бар,—диде.

—Хәзер, кызым, әз генә сабыр ит.

Айгөл чыгып киткәч, Сөембикә кухня ишеген япты.

—Кайтып житмәде бугай инде Мэлс абый.

—И, Сөембикә, аның законы үзе белән. Тели—төнге уникедә кайта, тели—иртәнге биштә. Ул кирәк идемени?

—Шулайрак иде шул...

—Ни әйтим соң?

—Ирек эчеп үләчәк, Нәфисә. Нишләргә дә белмим...—Ул кульяулыгын чыгарып күз яшьләрен сөртте.

—Мэлс аның янында гел булып тора бит инде. Бергәләп тә бардык.

—Хәзер аның карарлыгы калмаган. Соңгы чигенә килеп терәлгән. Мэлс абый дәваларга алып бара алмас микән, дигән идем.

Ул сүзләрне ишетүгә, Нәфисәнең йөзе кинәт үзгәрде, күзләрендә зәһәр очкыннар кабынды.

—Алып бара алмас шул,—диде ул бик кискен итеп.

Сөембикә аңардагы бу үзгәрешне һич тә аңлый алмады.

—Ул да алып бармагач...

—Син Ирек аркасында күтәрелдең, шуның абруе белән. Син бүген күз өстендәге каш кебек, сиңа бөтен район карап тора, сине Казан да белә. Ә менә мин—нуль. Ай-һай, бурычлы син Иреккә!

Сөембикә үз колакларына үзе ышанмыйча торды. Нәфисә үзенең жанын әйләндерде дә салды. Ул бары тик бер генә сүз әйтә алды:

—Мин дә аны күтәрү өчен аз тырышмадым.

—Юк, Сөембикә, ничек әйтсәң дә, син аңа бурычыңны түләп бетерергә тиеш.

—Мин синнән бу сүзләрне көтмәгән идем, Нәфисә,—диде Сөембикә һәм кухнядан чыгып киенергә кереште.

Ул арада аның янына Айгөл дә йөгереп килде.

—Сыең өчен рәхмәт. Ачның хәлен тук белми, дип юкка гына әйтмиләр икән...

—Син мина үпкәләмә,—диде Нәфисә.—Үзең кабат уйланып кара. Ә Иректе... Мәлска әйтеп тә маташма. Кул астында машинаң, шоферың бар, илт тә урнаштыр. Мәлс болай да эш белән талкынып беткән...

4

Ирек күзләрен ачарга теләде, ләкин керфекләре бер-берсенә ябышканнар, күз кабакларының аларны тартып аерырга көче җитмәде. Теле утта кыздырган бләү төсле аңкавына ябышкан, ул да купмый. Бөтен тәне яна, эчтән ниндидер кайнар сөрем генә чыга. Ул, караватына таянып, ынгыраша-ынгыраша торып утырды, тырышып-тырмашып күзләрен ачты. Бизәкләнеп каткан тәрәзә пыялалары аша сизелер-сизелмәс кенә салкын кояш нурлары саркый иде. Ул кичтән су түгәргә чыкмакчы булды, әмма хәле җитмәде, караватына ауды. Димәк, шул килеш кузгалмаган, ишек бикләнмәгән, юынтык су тупса янында утыра. Каралып беткән йон оекбаш тишелгән, ике бармагы күренеп тора. Чиләкне түгәргә кирәк. Ирек авырлык белән кече якка барып, ярты чүмечләп су эчте. Ул тешләрне сындырырлык салкын иде, бераз аның эчендәге уты сүрелеп, тәненә хәл кергәндәй булды. Өстәл өстендәге буш шешәләргә карап та тормады, чөнки бер әйбер дә калмаганын белә. Галошларын элде дә, чиләкне эләктереп, көч-хәл белән тупса аркылы атлады, өй алды ишеген төртеп ачты, баскычтан аякларын шудыра-шудыра төште, ләкин шунда хәлсезләнеп, чиләкне карга куйды, егылып китмәс өчен баскыч култыксасына тотынды. Февральнең салкын иртәсе уянып килә, күктә тоныкланып калган ай күренә, аның китек ягы кабып суырган лимон телемедәй төссезләнгән. Ничек тә булса читкәрәк алып китеп, бу суны түгәргә иде, ул инде кичәдән бирле аннан котылырга теләде. Әгәр контроль эшен эшләп биргән бер адәм ярты тотып кермәгән булса, ул аны һичшиксез түгәчәк иде. "Өеңдәге бу сасы искә ничек түзәсен?"—дип кичә шул адәм әйтте. Ә ул иснең су чиләгеннән килгәнен Ирек үзе аермады да. Кайдадыр әле якынаеп, әле ерагаеп әтәчләр кычкырган тавышлар ишетелә. Яңа көн туа, аяк астында ак кар. Ирек өчен әле кичә генә яшел чирәмле июль ае иде. Яшел чирәмнән ак карга шулай тиз күчеп була микәнни? Ул вакыт агышын югалтты, әйтерсен лә аның үз вакыты. Җир йөзендә яшәүче барлык кешеләрнең вакытлары бер. Ирек кенә аларның вакытын санга сукмый, аның өчен ел юк, аның өчен айлар, атналар да юк, көннәр дә юк, сәгатьләрне ул күптән вакытка санамый. Аның күзләренә ишек алдындагы яшел чирәм, бәрәңге бакчасы, түтәлдәге суган-кишерләр, кыярлар чагылып кала да, бөтенесен кар күмә. Күргән вакытта карның эрегәнен күрә, Ык суы җәелеп, бозлар киткәнен күргәне бар, тагын җәй, тагын кыш. Ничәнче ел икән бу? Аның да әһәмияте юк. Менә хәзер суны түгәргә кирәк. Аннары тәннең бу калтыравыннан, бу үлем газабыннан котылырга кирәк. Ләкин ул бүген шушы суны түгәргә үз-үзенә сүз бирде. Әгәр дөнья чайкалудан туктаса, аяк-куллары калтырамаса, су түгә торган урынга ул ун минутта барып җитәчәк. Бер уйласаң, хәзер аның яшәвенең һич тә катлаулылыгы юк. Элек мең мәшәкате белән кайнап торган тормыш шул кадәр гадиләнде, нервыны һәм баш миен борчый торган мәшәкатьләр барысы да читтә калды. Ирек хәзер тормышка бер генә тишек аша карый: тар гына тишек, башка берни дә юк, башка берни дә борчымый, бөтен уйларын, бөтен планнарын, бөтен хыялларын, барлык омтылышларын түп-түгәрәк, бәләкәй генә тишеккә керә дә бетә...

Ул ныклап торып калтырарга кереште. Инде аның теше-тешкә бәрелеп, шыкы-шыкы килә, куллары тунса да, ул башыннан һәм аркасыннан тир агуын

сизә. Кояш Ык буендагы өянке ботаклары арасына кереп кысылган, бакыр төсле кызгылт нурларын монда кадәр сузып, һаман күтәрелмәкче була...

Каяндыр өй түбәсе өстеннән ике чәукә фырылдап чиләккә таба томырылдылар да кинәт күтәрелеп киттеләр. Аларның фырылдавыннан Ирек егылып китә язды. Ул еш-еш сулап, чәукәләр артыннан ачулы карап калды. Аннары култыксадан кулын ычкындырып, сукмактан төгәл өч адым атлады да хәле бетеп туктады. Бераз тын алгач, акрын гына кире борылды, чиләкне алырга да оныткан икән. Тик аны күтәреп баруы икеле иде. Ул бер адым атлауга, шыгырдап капка ачылып китте, аннан ак шәл бәйләгән, кара тун кигән берәү керде дә Ирекә якынлаша башлады. Ирек кул сырты белән кабаланып күзләрен ышкырга тотынды, кулын алуга, тынсыз-өнсез калды: аның каршында Зәнфирә басып тора иде! Ул Зәнфирәнең елмаючы иреннәренә, елтырап торучы кышкы кояш итекләренә карады, сулышы кысылды, хәтта гәүдәсе калтыраудан туктагандай булды. Ник елмая соң ул? Ә юк, елмаймый, бу әллә нинди генә елмаю.

—Исәнме, Ирек?..

Ирек җавап бирә алмады. Бу таныш тавыш, бу таныш йөз аны кадаклап куйгандай итте. Мөгаен мин төш күрәм, дип уйлады ул. Ләкин бит аның төшендә Зәнфирәне бер генә мәртәбә дә күргәне булмады. Күргән төшләрен кабат хәтеренә төшерергә дә курыкты ул. Андый куркыныч саташулар, бастырылуларны хәтергә төшерү генә дә бу дөнья белән хушлашу теләге уята иде.

—Исәнме, Ирек,—дип кабатлады Зәнфирә.

—Исәнме,—диде ул көч-хәл белән.

Зәнфирә аңа якын ук килде, йөзенә әллә нинди сагышлы кыяфәт чыгарып, көйли башлады:

*Соңардың, кирәкми, димә син,*
*Алар бит чыктылар җанымнан...*
*Сөюебез сагышы бөркелә*
*Яшьлекнең мизгеллек язынннан...*

—Зинһар, тукта!—диде Ирек мең газап белән. Кычкырып әйтерлек рәте калмагач, пышылдап өстәде:—Тукта, Зәнфирә...

Ул күзләрен йомды, шушындый хәлендә Зәнфирә алдында басып торуыннан качарга теләп, күзләрен йомды, җәрәхәткә тоз сипкәндәй, күз кабакларын ачыттырып кайнар яшь бәреп чыкты. Ул күзләрен ачканда, Зәнфирә, ике кулындагы ике зур сумкасын куеп, чиләккә тотынган иде.

—Кит, үзем,—диде Ирек, күз яшен йотып.

Зәнфирә аптырап чиләкне куйды, аның теләгенә каршы килмәде, сумкаларын алып өйгә кереп китте.

"Онытмаган! Теге вакытта очраганда, мин ул шигырьләрне күптән оныттым инде, дип алдаган булган. Гомер буе онытмаган! Ник керергә уйлады икән? Ишетеп, ни дәрәҗәдә түбән төшүемне күрергәме? Юктыр, ул белгән Зәнфирә кеше кайгысына куана торган, андый усал җанлы түгел иде."

Ирекә көч кергәндәй булып китте, ул чиләкне күтәрде дә, галошларын шудыра-шудыра, акрын гына абзарга таба хәрәкәтләнде. Бу атлау түгел, суалчан кебек шуышу, алга таба тырмашу иде. Бу бер чиләк су аның беләзегеннән башлап иңбашларына, муенына кадәр бөтен тамырларын, сеңерләрен авырттырып тартты. Чиләктәге су җил вакытында елгада йөгерешүче дулкыннарны хәтерләтеп чайкалды, күпмеседер аның галошларына да түгелде. Юлның яртысын узгач, Ирек чиләкне икенче кулына күчерде. Тагын тартышып алга атлады. Ниһаять, чиләкне урынына түкте һәм җиңел сулап куйды, таянып ял итте. Ул авыр сулыш алып, өйгә таба атлады. Моржадан төтен чыга. Димәк, Зәнфирә ягып җибәргән. Ул иелеп битен кар белән уарга тотынды, кулларына кадалган төкләре кырынырга кирәклеген искәрттеләр. Әгәр аның киләсен белгән булса, ул ничек тә кырынган булыр иде. Кырына алмаса, өен бикләп, кыяфәтен күрсәтмәс өчен мунчага булса да кереп качкан булыр иде. Ул битен кар

белән уды да уды. Һич югы күздәге эреннәр калмасын, битендәге шакшы тир исе бетсен, дип уды. Авызына кар кабып чәйнәде, кайсын йотты, кайсын түкерде. Битен сырмасының җиңе белән сөрткәндәй итте дә өйгә керде. Зәнфирә чишенеп аткан, аның өстендә кара костюм, аягында ак йон оекбашлар иде. Кара чәчләрен үреп, бер генә толым итеп, күкрәк турыннан асылындырган. Ә уртада таныш медальон—Ирек Казаннан алып кайткан медальон иде. Плитәдә, күңелле тавыш чыгарып, чәйнек чыжлый. Ризык калдыкларыннан, шешәләрдән арындырылган өстәлгә чәчәкле клеенка җәелгән һәм аның өстенә коштабак белән пешкән ит, әрчелгән суган, бер банка кыяр ачып куелган, ипи туралган иде. Аларны күргәч, Ирек укшып җибәрә язды. Ул авызын учлап читкә борылды. Зәнфирә йомшак кына аның иңбашына кагылды.

—Авырыйсыңмы?—диде ул аның колагына гына пышылдап.

—Бик нык.

—Әйдә, утыр,—Зәнфирә аралыктан бер ярты алып килде, аны рюмкага салмакчы булды, ләкин Ирек аны туктатты.

—Рюмка белән эчә алмыйм мин.

Зәнфирә аракыны эмаль кружка төбенә салды. Үзе, Ирекнең хәлен аңлап, кухня ягына юнәлде. Ирек калтырана-калтырана, әллә ничә мәртәбә чәчи язып, аракыны эчеп куйды һәм, өстәл читенә ябышкан килеш, авызына берни капмыйча, иреннәрен кысып утыра бирде. Эчемлекнең хәзер башкачарак эшен көтү иде бу. Тәненә ниндидер җылылык тарала башлагач кына, иткә үрелде. Ул арада Зәнфирә борылып килеп, кыяр турады. Ирек өч литрлы банканы күтәреп, суын кружкага салмакчы булды, ләкин көче җитмәде, шапылдатып кире урынына куйды. Аның уйлаганын Зәнфирә эшләде. Һәр йотымының ничек төшкәнен санап, ул бер кружка кыяр суын эчеп бетерде. Шуннан соң гына Зәнфирәгә тутырып карады. Елмая алмады, бик җитди итеп:

—Рәхмәт,—диде.—Сиңа нинди рәхмәтләр әйтсәм дә, аз.

—Терелә генә күр,—диде Зәнфирә.

Бераздан бөтен өйгә мәтрүшкә, песи үләне, бөтнек, әрем, тагын әллә нинди үлән исләре таралды. Зәнфирә аның алдына чәй китереп куйды, банка белән бал алып, капкачын ачты.

—Менә бу үлән чәен эч әле, бөтенләй икенче кеше булачаксың.

Ирек йомрыны алып тәлинкәсенә аудармакчы булды, ләкин Зәнфирә аны туктатты:

—Юк, юк, кайнар көе эч, авызыңны пешерә-пешерә эч,—диде һәм үзе калак белән бал алып Ирекка тоттырды.

Ирек пешәләнә-пешәләнә ыскырт әче бу чәйне эчеп бетергәндә, маңгаеннан тир бәреп чыкты, Зәнфирә сөлге белән аның тирен сөртеп алды.

—Хәзер бераз ятып тор, мин идәннәрне юып чыгам,—диде ул.

Ирекнең чыннан да күз кабаклары авырайган иде. Ул урынына барып ятты, Зәнфирә аның өстенә одеалын һәм пальтосын бөркәде.

—Кузгалма, ныгытып тирлә,—диде ул.

Ирек уянып башын күтәрүгә, борынын әллә нинди исләр кытыклады.

—Әйбәт йокладың,—диде Зәнфирә.—Торасыңмы?

Ирек аңа җавап бирмәде, акрын гына торып утырды. Аның хәле иртәнгегә караганда әйбәтләнгән иде. Зәнфирә сабын күбеге ясый торган савытны китерде, кырынгычын кулына тоттырмакчы булды. Ирек тилмереп аңа карады.

—Кырына алмыйм.

—Үзем кырыйммы соң?

—Юк. Әз генә салып бир, аннан кырынам.

Зәнфирә, кружка төбенә аракы салып, аңа сузды, тагын теге кайнар үлән чәен алып килде, икенче кружка белән кыяр суын алдына куйды. Кулының калтыравы бераз басылгач, Ирек, юынгыч янына барып, яңакларына күбек буяды, бик авырлык белән озаклап кырынды, әллә ничә урынын кисте, аяк-муен тирәләрендәге тиреләр тәне-ние белән уйдык-

уйдык умырылып чыктылар, алардан кан саркыды. Эшен бетергәндә, ул шактый урыннарына кәгазь ябыштырып, чуар кыяфәткә кергән иде. Зәнфирә өстәлгә суган-сарымсак, сельдерей, укроп исләре килеп торган кып-кызыл борщ китереп куйды.

—Әйдә, аша, хәзер сина кайнар шулпа кирәк.

Ничә көннәр кайнар ризык күрмәгән Ирек борщны кабуга ашыйсы килгәнен ачык тойды. Ул бер коштабак ашны бөкләп кенә куйды.

—Болай булгач, өмет бар,—диде Зәнфирә елмаеп.

Ул әле генә томалаган мичнең авызындагы капкачын ачып карады:

—Озакламый бәлеш тә өлгерә.

—Зәнфирә, синең кайтасың да бардыр бит инде.

—Анысы өчен борчылма,—диде Зәнфирә ягымлы итеп.—Хәзер бәлеш алып киләм.

—Мин болай да атналыкны ашадым инде.

Зәнфирә аның каршына ук килеп утырды.

—Кырынгач, яшәреп киттең син,—диде ул, Иреккне жентекләп карый-карый.—Яшермичә генә әйт әле, мин картайганмынмы, Ирек?

Ирек тә аңа шактый озак карап торды. Зәнфирәнең чигә чәчләренә бераз чал кунган, әмма йөзе җыерчыксыз, муены ап-ак, күзләрендә генә ниндидер тирән сагыш сизелә иде. Хәер, Ирекне шушындый хәлдә карап утырганда, ул күзләрдә ни булырга мөмкин? Юк, Зәнфирә картаймаган иде, аның әле иреннәре дә элеккечә, сусыл булып, кызарып, күпереп торалар.

—Мин синнән көнләшәм, Зәнфирә. Шушы синең соравына җавап була аламы?

—Рәхмәт. Тормыш мине дә ару талкыды. Яшь чактагы бер адым өчен кеше гомере буе түли. Нигә бу тормыш шуны кире атларлык итеп яратылмаган? Синең шул хакта уйлаганың бармы?

—Ул хакта бөтен кеше дә уйлана.

Зәнфирә өстәлгә бәлешне алып куйды, аны әйбәтләп болгатты. Бәлештән чыккан тәмле исләр, кайнар бу белән кереп, борыннарны кытыклады.

—Савытка бүлмим, кайнар көе ашыйбыз,—диде Зәнфирә һәм үзе беренче булып бәлешкә үрелде.

Ирек кулына калагын алды, бәлешне авызына китергәндә, кулы калтыраудан аның шактые клеенкага коелды.

—Эчендәге җен сине һаман калтырата әле,—диде Зәнфирә һәм кружкага бераз үлән суы салып аңа сузды.

Аны эчкәннән соң, Ирек әйбәт кенә ашап китте, икесенең дә күңелендә бер-берсенә бирәсе мең төрле сорау бөтерелде. Ләкин аларны биреп булмый иде. Ничә еллар аерып торган гомер дивары аша бер-берсеннән еракта, көл астындагы күмер кебек, сүнмичә дә, янмыйча да яшәгән хисләр әле кузгала алмыйлар иде. Ләкин аларга берни дә кирәкми, бер-берсе каршына утырып, менә шулай бер савыттан ашау, ара-тирә күзләренә карашып елмаеп кую бик тә рәхәт, әллә ниләрне алыштыра иде. Бәлеш ашап, чәй эчкәч, Зәнфирә:

—Әйдә, Ык буеннан урап кайтабыз,—диде.

Ирек каршы килмәде. Аңа инде ярыйсы гына хәл кергән, саф һавага чыгу бәлкем гәүдәсен калтыратучы бу чирне дә күпмедер юар кебек тоелды. Зәнфирә казанга су өстәде, морҗаның юшкәсен этеп бетерде, газның кранын борды да, алар киенеп, ишекне бикләп, тыкрыкка чыктылар. Көн искиткеч иде. Кояш инде өянке ботаклары арасыннан чыккан, күзләрне авырттырырлык итеп нурын коя, ялгышып та бер җил әсәре юк, салкын һава күкрәкләргә кереп тәнгә көч өсти, әллә нинди җиңеллек бирә.

—Ирек, кар бөртекләренең ничек җемелдәвен кара әле,—диде Зәнфирә чүгәләп.

Аңа ияреп, Ирек тә чүгәләгән иде, чалкан авып китте, алар икесе дә берьюлы шаркылдап көлеп җибәрделәр. Мондый гамьсез, балаларча беркатлылык белән, дөньясын онытып, күптән көлгәне юк иде инде

Ирекнен. Мондый көлү Баллы Төбәк урамнарында гына янгырый торган иде. Күрәсең, аны Зәнфирә иятреп алып килгән. Кар бөртекләренә карый алмыйча, Ирек күзләрен кысты. Салават күперендәге барлык төсләр кар энәчекләрендә жем-жем итеп уйнаклый. Алар, нәни көзгеләр кебек жәлтен-жәлтен итеп, кояш нурлары белән шаярышалар. Ни өчен алар тик тормыйлар, ни өчен жемелдиләр? Әллә инде йокыдагы жир, акрын гына сулыш алып, үз өстенә зөбәржәт, энже-мәржән бөртекләре итеп ябылган юрганын селкетәме? Ерактагы таулар, агачлар зәнгәрсу өрфия пәрдә аша томанланып күренәләр, офыкка киткән саен аларның сызыкларын томанлы пәрдә каплый һәм дөнья тоташ аклыкка әверелә, күк йөзенә таба гына зәнгәрләнә бара... Алар бу матурлыкка сокланып, хәйран калып карап тордылар.

Ык уртасында кара кеше гәүдәсе аермачык калкып тора, күрәсең, кемдер кармак салып утыра иде.

—Әйдә, барып килик әле,—диде Зәнфирә һәм Ирекне шунда таба сөйрәде.

Алар балыкчыга таба атлаганда, жем-жем итеп торган кар өстеннән икесенең кара-кучкыл күләгәсе шуышты. Балыкчы шактый өлкән яшьтәге кеше булып чыкты. Ул кечкенә көрәге белән шакмаклап карны ачкан, алдына ике тишек тишкән, икесенә ике кармак салган. Ул күптән утыра ахрысы, бүреге, калын мыегы ап-ак булып бәсәреп беткән.

—Ничек, чиртәме?—дип сорады Ирек исәнләшкәннән соң.

—Мактанырлык рәт юк, әнә бит,—диде абзый, уң якка ишарәләп.

Анда кызыл күзле ару гына ике чабак ята, икесенең дә гәүдәсенә кар ябышып каткан. Шул вакыт абзыйның жебен астан нидер тарта башлады, ул утыргычыннан торып тизләнде һәм "ә" дигәнче бер балыкны өскә чыгарды. Бусы кул яссуыннан артык булмаган алабуга иде. Аны кармагыннан ычкындырып, абзый чабаклар янына ыргытты. Алабуга карда үрле-кырлы сикерергә тотынды, башы белән койрыгын кара-каршы китереп бөгәрләнде, аннары икенче якка бөкләнде, шул рәвешле туктаусыз сикерде, бәргәләнде. Ул инде карга батып бетте, гәүдәсе күренми дә башлады. Ирекка балык бик кызганыч тоелды һәм ул бер сүз дә әйтмичә борылды да, үзләре килгән эзгә басып, кызу-кызу читкә атлады. Бераздан аны Зәнфирә дә куып житте. Алабуганың тартышып бөгәрләнүе, кар каплаган гәүдәсеннән күренеп торган кызыл канатлары, туктаусыз ачылып торучы авызы, канлы саңакларының селкенүе Ирекнең күз алдыннан китмәде. Әллә нишләп бик тә кызганды ул балыкны...

Өйгә кайткач, алдан үзе керде, аягын салды да, чишенеп тә тормастан, кружкага аракы салып эчеп жибәрде. Зәнфирә кергәндә, ул кул сырты белән иренен сөртеп маташа, йөзе аракының зәһәр ачысыннан жыерылган иде. Зәнфирә аңа бер сүз дә әйтмәде, бары тик:

—Хәлең ничек?—дип кенә сорады.

—Алга инде. Син сонарасың бит, Зәнфирә. Көн кичкә авышты.

—Безнең коданың малае Болынкырга килде. Ул мине көтәчәк.—Зәнфирә сүзеннән туктап бераз уйланып торды да Ирекнең кулын үзенең учларына алды. Аның куллары салкынча, Ирекнеке дымлы, кайнар һәм калтырый иде.—Хәлеңне яхшырту өчен сиңа система куярга кирәк...

Ирек кулын акрын гына тартып алды:

—Бүген минем өчен эшләгәннәреңә ничек рәхмәт әйтергә дә белмим. Тик ул әйбер белән газаплама инде син мине.

—Ирек, зинһар карышма. Башкача котыла алмаячаксың. Мин сине акрынлап чыгарам.—Зәнфирә аның күзләренә шундый ялвару белән карады, Ирек үзе дә сизмәстән:

—Ярый,—диде.

Аның бу сүзләрен ишетүгә, кош тоткандай, Зәнфирә сумкасын ачты һәм аннан система куя торган әйберләрен чыгарды. Ирек өч сәгать буе тамчы астында ятты. Кеше кермәсен өчен Зәнфирә капканы эчтән элде, ишеккә тышкы яктан йозак асып куйды, караңгы төшкәч тә ут яндырмады.

Ике мәртәбә капкага кемнәрдер килеп дөбердәтеп тә карадылар, күрәсең, йозакны күреп китеп бардылар.

Система беткәч, Зәнфирә Ирекккә үлән чәе алып килде, ул авызына алгысыз әче, тамак төпләрен өттерсә дә, көчли-көчли эчереп бетерде. Аннары кружкага өч йомырка сытып, үзе алып килгән сарымсагын, суганын турап, ике төрле борыч сибеп, кайнар суга утыртып, шул йомырканы бик ныклап туглады, тагын ана ниндидер дарумы, нәрсәдер тамызды һәм Ирекккә эчерде. Шуннан сон да Зәнфирә китәргә ашыкмагач, Ирек хафага төште.

—Бәй, син бик соңардың бит, сүзләве бар,—диде.

—Сүзләмәс,—дип куйды Зәнфирә, аннары уйчан гына итеп өстәп куйды:—Мин бүген кайтып йөрмәм инде...

Ирек, башын янтайтып, ялгыш ишеттемме әллә дигәндәй аңа күзен тутырып карады.

—Сине терелтмичә кайта алмыйм инде мин, Ирек,—диде ул.—Курыкма, мин сиңа тимәм.

Ирек ни әйтергә дә белмәде. Зәнфирә икенче караваткa үзенә урын җәйде. Утны сүндерсә дә, Ирек тәрәзәдән төшкән кар яктысында аның күлмәкләрен салмыйча гына ятуын күрде. Төн тыныч узмады. Ирек, әз генә йоклап китсә, саташып сикереп торды, Зәнфирә килеп аны тынычландырды, ниндидер укол кадады, шуннан соң гына Ирек рәхәтләнеп йоклап китте.

## 5

Иртән ул табада нәрсәдер чыжылдаган тавышка уянып китте. Зәнфирә аның янына килде.

—Тор, Ирек, юын. Мин сиңа бик тәмле итеп бәрәңге кыздырдым.

Зәнфирә аңа көчли-көчли теге тәмсез суны эчерде. Ирек тәнендә тагын канының җылынуын, гәүдәсенә яшәү көче инә башлавын тойды. Ашаганнан соң, Зәнфирә чоланнан йорт хуҗасының җиз самавырын алып керде.

—Әйдә, Ирек, гел авылча булсын әле: мунчада самавырны чистартып кайтыйк,—диде.

—Ул бит салкын.

—Мин аны ягып томаладым инде.

Алар бергәләп җылы мунчага киттеләр. Зәнфирә алдан әзерләп куйган ком белән самавырны чистартты, Ирек чүмеч белән аңа җылы су салып торды. Самавыр көләп җибәрде, аның җиз кырында үзенне күреп була иде.

Кайткач, Зәнфирә тагын сумкасыннан эремә салынган пыяла савытларны өстәлгә алып куйды, аларга Ирекнең яратмыйча карап торуын күреп:

—Тагын куярга кирәк, шунсыз организмыңнан агуны чыгарып бетереп булмаячак,—диде.

Ирекнең нишләптер карышасы килде. Бераз уйланып торганнан соң, ул урынына ятты, Зәнфирә система куйды.

—Сиңа кайтырга вакыт бит инде, өеңдә ничек күренерсең?

—Анысы минем эш,—диде Зәнфирә.—Мин отпускыда, үзем теләгәнчә ял итәргә тиешмендер ләбаса.

Ирек нәрсәдер сизенә башлады, әллә берәрсе сөйләшеп, Зәнфирәне махсус аның янына җибәрде микән? Моны абыйсы да, Әхнәф тә эшләргә мөмкин. Әгәр шулай булса? Бу мәхшәрдән котылу өчен җиде башлы диюне җибәрсәләр дә, ризалашырга кирәген ул зиһене белән яхшы аңлады, әмма күңеле бу нәрсәне өнәми, Зәнфирәнең китүен тели иде. Бу ямьсез теләген күпме генә куарга тырышса да, ул көчәя генә барды. Кичкә таба Ирек Зәнфирә белән бөтенләй сөйләшмәс булды. Күзгедән карагач, үзенең йөзендә ачы әйбер капкан төсле чытыклык күрде. Зәнфирә аңа:

—Эчәсең килә, шулаймы?—диде.

—Әйе, Зәнфирә, әз генә, бүген генә... Аннары туктар идем.

—Туктый алмаячаксың. Ул сине тагын да тирәнгәрәк сөйриячәк.

Зәнфирә апа укол ясап, үлән суы эчергәч Ирек тагын йоклап китте.
Иртән торып, ашап-эчү белән, Зәнфирә апа:
—Әйдә, әзрәк хәрәкәтләнеп керик әле,—диде.
Бергәләп ишек алдындагы бөтен карны көрәп бетерделәр. Капкадан чыга торган тар сукмак та машина керерлек итеп киңәйтелде. Ирекнең өзелеп карыны ачты, алар итле кәбестә шулпасын тәмләп ашадылар. Зәнфирә тагын система куярга җыенгач, Ирек:
—Юк, юк, мин инде үземне яхшы хис итәм,—диде.—Рәхмәт сиңа. Миңа редакциягә барып кайтырга кирәк.
—Анда ник барасың?—диде Зәнфирә.
—Язган мәкаләм бар иде...
—Ул чакта бергәләп барабыз.
Ирекнең йөзе ямьсезләнде.
—Син нәрсә?!—диде ул дөртләп кабынып.—Ни өчен мин синең белән урамнан барырга тиеш?
—Ояласыңмыни?
—Оялмыйм. Моны бит көне-сәгате белән әти белән әнигә, синекенә җиткерәчәкләр.
—Шуннан ни була?—диде Зәнфирә.
Ирек апа, әллә ычкына башлады микән бу хатын, дигәндәй хәйран калып карап торды.
—Була, бик күп нәрсә була,—диде ул.—Сиңа мин кайтканчы кузгала торсаң да ярар.
—Туйдың дамыни?
—Күңелем сизә... Әйбәт түгел синең монда минем өйдә куныш ятуың.
Ирек дипломатын тотып чыгып китте. Ул, урамнан атлаганда, үзен инде читлектән чыгарган кош сыман хис итте. Аның башында “Кая барырга?” дигән уй бөтерелде. Кесәңдә бер тиен акча булмаган килеш кая барасың? Оят булса да, райсоюз председателе Ивановка керде. Ул Ирекне ишек төбеннән үк кочаклап каршы алды. Ирек кызарып аска карады һәм, пычак белән тәнен кискәндәй, кыенсынып кына:
—Николай Кузьмич, ашыгыч кына илле сум акча кирәк иде, коткара алмас идегез микән?—диде.
—Ничек коткармаган ди, Ирек Хәйриевич!
Шундук кесәсеннән илле сум акчаны чыгарып та бирде.
—Минем аны сезгә бик тиз генә түли алмавым да мөмкин,—диде Ирек чыгарга кузгалып.
—Сез аны, мин онытты, дип уйлагыз инде.
—Юк, юк!—Ирек кесәсеннән акчаны чыгарды.—Алай булса, мин алмыйм.
—Ай, Ходаем, түләрсез инде алайса!
Николай Кузьмич, Ирекнең акчалы кулын үз куллары белән тотып, кесәсенә салдырды. Аннары Ирекнең колагына пышылдады:
—Ирек Хәйриевич, минем әрмәннәр алып килгән бик затлы күчтәнәч бар иде... чача... Әгәр вакытыгыз булса, минем арт бүлмәгә кереп бераз утырыйк.
Ирек елмаеп ризалыгын белдерде. Ул Николай Кузьмич яныннан чыкканда, инде күптән караңгы төшкән иде. Кәефле генә өенә кайтып барганда, кинәт кире борылды, сыраханәгә кереп, кипкән балык белән ашыкмый-кабаланмый гына берәрсе белән гәп сатып утырасы килде...

***

Изабелла Назаровна редакция машинасы белән “Авангард” колхозыннан кайтып килә иде. Олы юлдан борылып кергән урында машина уйнаклап китте һәм чак кына артка таба борылып туктамады.
—Чамалап,—дип кисәтте ул шоферын.

Редакторның зәһәр очкыннар сипкән күзләреннән болай да коты алынган шофер акрын тизлек белән Болынкыр эченә керә башлады. Инде багана башларындагы лампочкалар да янган, машинаның уты да шактый көчле яктырта, урам коймаларыннан алып бөтен нәрсә күренә иде. Изабелла Назаровнаның күзе коймага тотынган хәлдә басып торган бер кешегә төште. Аның пальто изүләре ычкындырылган, ак күлмәге, шуның өстеннән кыйгаеп чыккан галстугына кадәр ачык күренә. Ул аңа кемнедер хәтерләтте.

—Туктале,—диде ул шоферына, инде теге кеше турыннан узып киткәч. Мондый хәлдә аның үзләренен фотокорреспондентын берничә мәртәбә алып кайтканы бар иде, аңа да ошаган кебек, охшамаган да кебек.

—Бар әле, кара, безнең имгәк булмасын,—диде ул шоферына.

Шофер тиз арада килеп тә житте.

—Ул түгел, Ирек абый бу.

—Кайсы Ирек?

—Сабитов. Өенә кайтарып куймыйбызмы?

—Бездән башка да кайтарырлар,—диде Хасбулатова, эченнән шатлык кичереп, аннары шоферына кычкырып жибәрде:—Нәрсә аксак алаша адымы белән кайтасың? Тизрәк бул!

Ул каушап газга басып жибәрде, машина тагын уйнаклап алды, әмма редакторыннан кисәтү ишетмәгәч, шофер тизлекне арттырганнан-арттыра барды.

Кабинетына керү белән, Хасбулатова иренең эш бүлмәсенә шылтыратты:

—Хәзер үк берәүне алып кайтыгыз әле,—дип кычкырды ул трубкага.

—Кайда? Нәрсә? Каян?—диде ире, берни аңламыйча.

—Безгә бик кирәк кеше. Тизрәк алып кайтып яп.

—Кем соң ул?

—Сабитов!—дип кычкырды Изабелла Назаровна.—Әгәр шуны эшләсәң, беренчедән рәхмәт ишетерсең. Нәрсә, аңламый торасың, аңгыра!

—Кайда соң ул?

—Сыраханәдән ерак түгел, каршы яктарак, тиз бул, аны илтеп куючылар табылыр. Кара аны, үзең бар! Банкага башы белән керә торган ул ахмакларыңа ышаныч бәләкәй.

Изабелла Назаровна, трубкасын куйгач, бер тын урыныннан купмыйча, ләззәтләнеп утырды. Үзенең ак чәчләре өчен гел көтмәгәндә шушындый үч алу мөмкинлеге чыгар дип ул башына да китермәгән иде. Анда гына эләксен, бер эләксә, ничек эшкәртергә белерләр. Иренең бервакыт сөйләгәнен ачык хәтерли ул: анда ябылган кешедән үч алырга кирәк булса, янына бандитларны гына кертәләр икән, аннары тикшереп карасыннар—кем гаепле, кем гаепсез. Анданиләр булганын алла үзе генә белә...

Хасбулатов штаб начальнигына боерык бирде дә үз машинасы белән хатыны әйткән урынга элдерде. Мин барып житкәнгә кадәр алып кына китмәсеннәр, диде ул үз-үзенә, тешен кысып. Бәхетенә, Ирек шунда ике кулы белән коймага ябышкан көе тора иде. Хасбулатов, аны карый-карый үтеп китеп, машинасын биш-алты өй аша караңгырак урынга туктатты. Ул арада өсте ябулы милиция машинасы да килеп житте. Егетләр иң элек арткы ишекне ачтылар, аннары Сабитовны күтәреп алып, күз ачып йомган арада машинага ыргыттылар. Хасбулатов аларны узып китте һәм алдан кайтып туктады. Иректе ике милиционерның ике ягыннан култыклап алып кергәнен, аның карышырга маташканын ул тәрәзәдән астыртын гына елмаеп карап торды.

—Ну, карчык, милиция майоры Хасбулатов синең боерыгыңны үтәде!—диде ул кайтып кергәч, үкчәсен үкчәгә бәреп.

—Молодец!—диде Изабелла Назаровна.—Әйдә, ашарга утыр.

Хасбулатов юынып килеп утырды.

—Мондый тантаналы көн хөрмәтенә әзрәк тамак төбе чылатсак та ярар иде.

—У-у-у, мөшкә авыз, сиңа сәбәп кенә булсын.

Шулай да аның хатыны өстәлгә башланган ярты китереп куйды.

***

Сөембикә Айгөлгә дәрес әзерләшеп утырганда, телефон шылтырады. Ул трубканы алды да, кабаланып дәшкән тавыштан аптырап китте:
—Сөембикә апа, мин бик ашыгыч шылтыратам...
—Танымыйм, кем белән сөйләшәм соң әле мин?
—Бу сезнең элекке күршегез, милициядән мин. Ирек абыйны монда алып кайтып яптылар, аңладыгызмы?
—Кайчан? Ни булды?—дип сорады Сөембикә, кызы ишетмәсен өчен телефон трубкасын каршы як колагына күчереп.
—Исерек ул, нык эчкән...
Айгөл, китап-дәфтәрләрен җыештырып, телевизор кабызды. Сөембикә, йокы бүлмәсенә кереп, караватка таянды, башында мең төрле уй бөтерелде. Иректе коткарырдай бер кеше бар, ул—Арсланов. Теге вакыттагы баш әйләндергеч сүзләрен чынлап сөйләгәнме ул, әллә юри генәме? Сөембикәнең үтенечен салып таптаса, димәк, барысы да ялган була. Әмма... ничек шылтыратырга? Айгөл барында аны аңлатып та булмый бит әле.
—Кызым, бар инде, йокларга вакыт,—диде ул, сәгатькә күрсәтеп.
—Әз генә карыйм инде, әни,—дип ялынды Айгөл.
Ул телевизор карап утыруын дәвам итте. Ахырда Сөембикә телевизорны үзе сүндерде. Айгөл авыз-борынын бүлтәйтеп, тып-тын гына йокы бүлмәсенә кереп китте. Сөембикә ашыга-кабалана Арслановның өенә шылтыратты. Әгәр трубканы хатыны алса, бармагын сузып, телефонны өзәргә әзерләнде. Аның бәхетенә Арслановның:
—Әйе, тыңлыйм,—дигән тавышы ишетелде.
Сөембикәнең битләренә, бөтен гәүдәсенә ут капкандай булды. Бу вакытта беренче секретарьның өенә шылтырату гадәте юк һәм Сөембикә шуны бозганы өчен бик нык каушады.
—Хәерле кич, Миңзаһит Усманович,—диде ул тирән дулкынланып.—Сабитова әле бу. Зинһар шылтыратуым өчен кичерә күрегез. Ләкин минем башка чарам юк.
—Дәвам итегез,—диде Арсланов акрын гына.
—Минем элекке иремне бүген кич эчкән хәлендә милиция бүлегенә кертеп япканнар. Үтенеп сорыйм, зинһар чыгартыгыз.
—Әйе, ул саннар миндә,—диде Арсланова Хәятны бутау өчен.—Хәзер мин эш урыныма барам да, үзем шылтыратып әйтермен.
Сөембикә барысын да аңлады. Димәк, ул хатыны яныннан шылтырата алмый.

Арсланов, күктә чекрәешкән йолдызларга карап, кызу-кызу райкомга атлады. Бу көннәрдә аның күнеле таш кебек катып калган иде. Хисләре елга өстендәге калын боз кебек хәрәкәтсез, мәңге эремәс кебек иделәр. Сөембикәнең шылтыратуы аның күңел яраларын йомшак май белән сылап җибәргәндәй булды. Бүлмәсенә кергәч чишенеп тормастан, ул, өстәл янына барып, телефоннан номер җыйды. Милиция начальнигының хәрбиләрчә купшы тавышы яңгырады:
—Әйе.
—Иптәш майор, сез анда бүген кич Сабитовны алып кайткансыз, диләр.
—Әйе, алып кайттык, Миңзаһит Усманович,—диде Хасбулатов, аны шундук танып.—Үзем барып, үзем алып кайттым. Эчкечеләргә каршы аяусыз көрәшмәсәк...
Арсланов, йөзен чытып, аны тупас бүлдерде:
—Сез лекция укымагыз әле. Ул тәртип бозганмы?
—Аның урамда коймага ябышып, чайкалып торуы—үзе җәмәгать тәртибен бозу инде.
—Шулай укмыни?!—диде Арсланов, ачулы тавышына киная кушып.
—Шулай,—диде дә милиция начальнигы телен тешләгәндәй туктап калды. Ана беренче секретарь әйткән сүзнең мәгънәсе яңа барып җитте.
—Начальник! Слушай внимательно. Хәзер үк үзең бар, Сабитовны чыгар,

өенә илтеп куй, потом мне доложишь, эш бүлмәсенә шылтырат. Понял?
Хасбулатовның:
—Понял,—дигән тавышы ишетелде.
Арсланов шундук Сөембикәгә шылтыратты:
—Боерыгың үтәлде, иптәш Сабитова,—диде ул елмаеп.
—Рәхмәт, Минзаһит Усманович. Бу яхшылыгыгызны мәңге онытмам.
—Сөембикә, мин сине шундый сагындым,—диде Арсланов.—Әгәр хәзер, биш минут сөйләшәбез, районның теләсә кайсы ноктасына килеп җит, дисән, мин, гараждан машинаны алып чыгып, шунда барып җитәм.
—Минзаһит Усманович, зинһар, үтенәм... Бүгенгә калдырып торыйк әле.
—Димәк, киләчәккә ниндидер өмет бар. Мине шул өмет яшәтәчәк. Әгәр җыелышларда, кинәшмәләрдә минем ихлас елмайганымны, күнелемнең күтәренке чагын күрсән, белеп тор: аның сәбәпчесе менә шушы өмет булыр.
Ирекне чыгаруларын белсә дә, Сөембикәнең күнелен нидер тырнап тора иде. Ярар, чыгарып җибәргәннәрдер, ә өенә кадәр кайтып җитә алырмы соң ул? Йокы бүлмәсенең ишеген акрын гына ачып, Айгөл янына килде. Тигез сулыш алып, кызы тыныч кына йоклый иде. Барып кайтырга кирәк, дигән карарга килде Сөембикә. Ашыга-кабалана киенеп, ишегенә йозак салып, урамга чыгып йөгерде. Тышта битләрне чеметтерә торган салкын иде. Ул ярым йөгереп, ярым атлап, Болынкырның икенче башына килеп җиткәндә, бүрек астыннан чыгып торган чәчләренә, каш-керфекләренә ап-ак булып бәс сарган иде. Ирекнең өендә уты югын күрде, капканы төртеп карады—ул эчтән бикле булып чыкты. Бәлкем кереп тормаскадыр? Ләкин бу көе китә алмый иде ул. Сөембикә койма өстенә ыргылды, көч-хәл белән ишек алдына төште, коймага бәрелеп, күкрәгенең бик нык авыртуын тойды. Барып ишекне кагарга керешле. Шундук өй алдының уты кабынды һәм хатын-кыз тавышы ишетелде:
—Кем бар анда?
Сөембикә аның тавышын һич тә таный алмады, әллә Баллы Төбәктән әнисе килгәнме, дигән уй аның миен көйдереп үтте. Ләкин дәшүдән башка чара юк иде:
—Мин әле бу, Сөембикә.
Ишек киләсе шылтырап ачылды һәм ул эчкә атлады. Парлы һава аша сыек кына төшкән яктылыкта ул һаман да үзен кем керткәнен танымады. Өйгә узып, ут яндыргач кына, Сөембикә телсез-өнсез калды. Ирексездән аның авызыннан бер сүз ычкынды:
—Зәнфирә?!
—Әйе, мин. Әйдә, салыгыз өстегезне. Бик туңгансыз.
Сөембикә пальтосын ычкындырмакчы булды, әллә тунудан, әллә каушаудан—аны бармаклары тыңламады. Зәнфирә, пальтосын элеп куйгач, караватта одеал астында йоклаучы Ирекне күрде. Ирек кыймылдап куйды, одеалын тарта төшеп капланып ятты. Сөембикә, һаман да нишләргә белмичә, идән уртасында басып тора бирде.
—Әйдәгез, утырыгыз,—диде Зәнфирә, чакырылмаган кунакка урындык күрсәтеп. Ә үзе плитә кабызып, чәй куйды. Сөембикә иң элек аптырап, өстәл түрендә утырган җиз самавырга карады: каян чыккан ул, дигән уй йөгереп үтте аның башыннан.
—Ашыйсыгыз килмиме?—диде Зәнфирә, аның уйларын бүлеп.
—Ә... ни... юк. Миңа берни дә кирәкми...—Сөембикә әйтер сүз таба алмыйча газапланды.—Ирекне кем кайтарды?
—Милициялләр китерде,—диде Зәнфирә берни булмагандай.
—Анда ничек эләккән соң ул?
—Белмим... Сорарга өлгерә алмадым, үзе юньләп сөйләшмәде.
—Өегезне нык җылыткансыз,—диде Сөембикә, кулъяулыгы белән маңгаен сөртеп.
—Җылы сөяк сындырмый,—диләр бит.
—Болынкырда җылы оя табу һәркемгә тәтеми.

Сөембикәнең төрттерүен аңласа да, Зәнфирә дәшмәде. Өстәлгә ипи, май, бал белән варенье куйды. Куян каны кебек итеп ясап, ике кулына ике чәшке чәй тотып килә башлады. Сөембикәнең шул минутта аның каршысына барып, чәйләрен Зәнфирәнең чыраена сибәсе килде.

Алар башта тавыш-тынсыз, бер-берсенә күз читләре белән генә караш ташлап, ипигә дә үрелмичә, калакларына да кагылмыйча, чәйләрен тәлинкәләренә дә аудармыйча, йомрыдан гына пешәләнә-пешәләнә капкалап утырдылар. Сөембикә күңелендә чәйдән дә кайнаррак нәрсә кабаруын сизде. Ул аның ни икәнен дә аңламады. Бу көнләшү дә түгел, Зәнфирәгә ачу килү дә түгел, аны биредә артык итеп күрүгә охшаш бер тойгы иде.

—Мин сезне биредә дип белми идем,—диде ул, мөмкин кадәр тыелып, эчен өтүче әлеге теге кайнар тойгыны басарга тырышып.

—Мин дә шушы вакытта сезне бирегә килеп керер, дип уйламадым. Бикле капка аркылы.

—Ә бездә капка бикләү гадәте юк.

—Әле монда капка бикләп тә тамангa туры килә. Сорап-нитеп тормаганнар, алып киткәннәр бит әнә.

—Күрәм, сез тәмам хуҗа булып урнашкансыз.

Зәнфирә тагын сүзне кискенләштерүдән качты:

—Хуҗасыз йорт таркала, диләр ич.

Ирек ишек дөбердәтү белән уянган иде, аның Сөембикәнең килеп керүенә дә, Зәнфирәнең чәй куюына да, икесенең өстәл янында, аның мәете өстендә сөйләшкәндәй, сөйләшеп утыруына да җене чыкты. Ул кинәт одеалын селтәп идәнгә атты һәм сикереп торып утырды.

—Нәрсә бүлешәсез? А ну-ка, вон!—дип кычкырып җибәрде.

—Ирек, син нәрсә? Нишлисең?!—шул сүзләр белән Зәнфирә тынычландырмакчы булып аның янына килүгә, Ирек аны төртеп җибәрде. Зәнфирә шартлап идәнгә үк барып ауды. Куркынган Сөембикә дә сикереп торды.

—Оялыр идең!—диде Сөембикә.—Сине мин чыгарттым.

—Нәрсә белән түләп?—дип җикерде Ирек.

Аның бу сүзләреннән Сөембикәнең чигәсе чәнчеп куйды. Ул аңа ачу белән карады да пальтосын алды, нидер әйтмәкче булды, әмма өлгерә алмады, Ирек аны да этеп җибәрде.

—Киен!—дип җикерде ул Зәнфирәгә.—Берегезне дә күрәсем килми. Ялгызымны калдырыгыз!

Ул ике кулы белән өстәлне төйде, чынаяклар куркыныч булып, сикереп-сикереп куйдылар.

Зәнфирә дә аягына итеген киде, шәлен бәйләде, өстенә пальтосын салды һәм ишеккә ташланды.

Ирек аларның артыннан дөп-дөп басып чыкты да өй алды келәсен шартлатып бикләп куйды. Өй алдында да, өйдә дә ут сүнде.

Капкадан чыгып бераз атлагач, Сөембикә туктап калды. Зәнфирә һаман чыкмады, Сөембикә, кире борылып, ишек алдына керде. Зәнфирә ишек каршында басып тора иде.

—Нишләп торасың?—диде Сөембикә аңа ачу белән.

—Бу вакытта мин кая барыйм соң?

—Әйдә, атла минем арттан...

Зәнфирә теләр-теләмәс кенә аңа иярде. Бер сүз сөйләшмичә, кайтып житеп өйгә керделәр.

—Чишен.

Алар икесе дә бик нык туңганнар иде. Сөембикә тиз генә чәй кайнарлап алды, Зәнфирә керфекләрен бер генә мәртәбә дә күтәрмичә чәй эчте. Аннары:

—Мин кунакханәгә барып карыйм булмаса,—диде.

—Бу вакытта нинди кунакханә ди?!

Сөембикә аңа диванга урын җәйде, ләкин Зәнфирә утырган урыныннан

купмады. Акрын гына керфекләрен күтәреп, ул Сөембикәгә куркулы караш ташлады.

—Сез миңа ачуланасыздыр инде?

—Ә нигә?—Сөембикәнең иреннәреннән мыскыллы елмаю чагылып үтте.—Ялгыз калуын көтеп торгансың, килгәнсең...

—Мин сезгә баштук әйтергә тиеш булганмындыр,—диде Зәнфирә һәм калын булып үрелгән чәченең очын әле сүтте, әле кире үрде.—Мин аның янына бөтенләйгә дип килдем...

Сөембикә әллә нишләп китте, әйтерсең лә ул баскан идән сайгагын табан астыннан тартып алдылар.

—Менә ничек! Әгәр без... кабат кушылырга уйласак?

—Комачауламам,—дип куйды Зәнфирә, тагын керфекләрен аска төшереп.—Бер мәртәбә юлдан киттем бит... Тагын китәрмен...

—Зәнфирә, мин сиңа хатын-кыз буларак әйтәм: нинди җәһәннәмгә сикергәнеңне аңлыйсыңмы син?

—Аңласам, сикерә алмас идем шул... Аңламавым әйбәтрәктер дә...

Сөембикә аның бу сүзләренә нидер әйтергә теләде, әмма теле буйсынмады. Зәнфирәне беләгеннән тотып диван янына алып килде дә:

—Тыныч йокы,—диде һәм утны сүндерде.

Зәнфирәнең күзенә йокы кермәде. Ирек янына чыгып киткәндә Заһитның кисәтүен исенә төшерде.

—Ул айнымаячак. Барыбер кайтачаксың, Ирек сине куып чыгарачак,—диде ире.

—Ирек андый түгел.

—Күрербез әле. Ярсыган чагында ул сине бәреп үтерергә дә мөмкин.

—Юкны сөйләмә!..

Дөрескә килде түгелме соң аның сүзләре?! Әгәр Заһитның соңгы кисәтүе дә туры килсә? Күпме көч түгеп айныткан иде бит аны Зәнфирә...

Сөембикә дә бик озак йоклый алмыйча ятты, аның эчендә нидер котыра иде. Юк, ул көнләшмәде. Ә ни өчен көнләшми икән соң ул? Димәк, Ирекне яратмавы хак. Шулай да аның янында Зәнфирәнең булуын теләмәде. Ахырда йоклап китте. Әллә нинди албастылар, милиция киемендәге бандитлар белән саташты, бастырылып, куркып уянып китте. Тышта нидер дөбердәгән кебек булды, Сөембикә куркып сикереп торды һәм иң элек диванга күз салды: ул буш иде. Кече якта утны яндыргач, Сөембикә Зәнфирәнең киемнәренең дә юклыгын күрде. Сәгатькә күз төшерде: төнге ике тулып килә иде. Өстенә киенеп, ул ишек алдына чыкты. Зәнфирә бәдрәфкә киткәндер, дип уйлап, бераз көтте, аннары эндәшеп куйды, әмма җавап бирүче булмады. Аннары ишекләрне элеп, утны сүндереп, җылы урынына кереп ятты...

## 6

Зәнфирә кайтып житкәнче йөгерде. Ишекне тартып карады—ул бикле иде. Зәнфирә, Ирек алай-болай берәр нәрсә эшләмәсен, дип кояләнде, аның йоклый алмый ятуы да, Сөембикәгә әйтмичә чыгып йөгерүе дә шуның өчен иде. Ул тәрәзәгә капланды, аны сулышы белән эретте һәм караватта яткан Ирекнең ак оекбаш кигән аягын күрде. “Шакыргамы, юкмы?” дип бәргәләнде. Әгәр уятсаң, ул хәзер аракы сораячак, ә аракы юк иде. Зәнфирә аны уятмаска булды. Мунчаның өйалдына эленгән ялганчы йозагын ачып эчкә узды, андагы керосин лампасын яндырып, ләүкәдәге әйберләрне алып куйды да, утны сүндереп, шунда ятты. Өй кебек булмаса да, мунча жылы иде. Әллә борчылудан, әллә туктаусыз йөгереп кайтудан арыган иде, әллә күңеле тынычланып калгангамы—ул шундук тирән йокыга талды. Иртән яктырылгач кына күзләрен ачты. Чәчен-башын төзәтеп, тунына ябышкан себерке яфракларын төшерде дә ишек алдына чыкты. Бүгенгә көнне сындырып жибәргән, һавада соры болытлар йөзә, кояш күренми иде. Ул торганны сизгәндәй, өйалды ишеге ачылып китте, чәче-

башы тузган Ирек, өстенә дә кимәгән килеш, чалдый-болдый атлап, абзарга таба ашыкты. Зәнфирә өйгә узды, самавырны алып, су өстәде, торбасына күмер салды һәм ут кабызып чыра ташлады.

Ирек керде дә караватына ауды. Зәнфирә аның янына килде. Ул якынлашуга, Ирек күзләрен чытырдатып йомды.

—Хәлең авырмы?

—Үтенәм, кайтып кит.

—Сине аякка бастырмыйча китмим мин.

—Мин синең күзләреңә карарга оялам. Үтенәм, кайтып кит.

Ирек сүзен әйтеп бетерә алмады, укшырга тотынды. Зәнфирә шәлен бәйләп тунын эләктерде дә чыгып йөгерде. Ул ике шешә сыра алып кайтып килгәндә, үзләренең турында торган ак "Нива" машинасын күреп туктап калды. Кире борылып, урамга таба чапмакчы булды, ләкин аяклары тыңламады. Машинаның ишеге ачылды һәм кара пальто, норка бүрек кигән Заһит төшеп басты. "Әгәр аңа китәсе булсаң, мин сине шушы мылтык белән атып үтерәчәкмен..." Заһитның бу сүзләре аның колак төбендә кабат яңгырадылар. Йа Хода! Заһиттан барысын да көтеп була. Салкын кан белән уйлап бетереп, ул шушы эшне эшләргә мөмкин бит. Язгы күктә тирбәлгән тургайдай, Зәнфирәнең йөрәге еш-еш типте, ул яшәргә тели иде. Әмма гомерне урамга таба йөгереп кенә саклап калып булмаячагын Зәнфирә яхшы аңлады. Тагын аның сүзләре аңында яңгырады: "Әгәр аның янына китсәң, мин сине шушы мылтык белән атып үтерәчәкмен..."

Үзенә төзәлгән мылтык көпшәсенә каршы баргандай, Зәнфирә хәлсез адымнар белән аңа таба атлады. Бөтен гәүдәсе калтыранса да, ул, бер учка җыйгандай, үзенең ихтыярын туплап, йөзенә гамьсез һәм эре кыяфәт чыгарырга тырышты.

—Исәнмесез, Зәнфирә!—диде Заһит, ничә еллар буе иртән үбеп чыгып киткән, кичтән үбеп каршылаган гадәтеннән баш тартып. Бу инде үзе үк күп нәрсә турында сөйли иде.

Зәнфирә аның исәнлеген алмады.

—Ник килдең?—диде ул, юри читкә карап.

—Синең белән соңгы мәртәбә сөйләшергә килдем: син минем кисәткәнемне хәтерлисеңме?

Зәнфирә ялт итеп аңа карады, Заһитның йөзе җитди генә түгел, әллә ни төсле иде. Ул давыллап килүче кара-кучкыл болытны хәтерләтә иде.

—Син мәктәп директоры, син бөтен авылның тәрбиячесе, син моны эшли алмыйсың.

—Синең бу сүзләрең миңа тәэсир итми. Бу фикерне инде мин әллә кайчан чәйнәп, чүбеккә әйләндереп, төкереп ташладым. Мин бәләкәйдән үк, бер кап шырпы югалтсам да, бәргәләндем, зуррак әйбер булса, минем төн йокыларым кача. Ә сине югалтуны мин күтәрә алмаячакмын.—Заһит буылып сулыш алган хәлдә аның йөзенә иелде:—Син минеке генә булырга тиеш!

—Мине калдыр!—диде Зәнфирә, аңардан бер адым читкә чигенеп.—Барыбер синеке булмыйм. Булган кадәресе өчен Аллага рәхмәт укы.

—Юк инде, җаныкаем! Әгәр син миңа чыкмаган булсаң, мин синең теләсә нинди гамәлләреңә битараф булыр идем, хәзер, күпме гомер бергә яшәгәч, мин сине исән җибәрә алмыйм.

—Синең бит үзенне дә атачаклар,—диде Зәнфирә, соңгы дәлилен китереп.

Аның бу сүзләренә Заһит көлгәндәй итеп куйды:

—Минем өчен барыбер.

—Күпме яшәп, мин сине шушы кадәр мәрхәмәтсез, түбән җанлы дип уйламый идем. Ничек нык ялгышканмын!

—Мин гаепле түгел—син! Соңгы сүзеңне әйт: янадан килеп торыйммы, үзең кайтасынмы?

Зәнфирә аның күзләренә сынап, бик озак карап торды, иренең күз алмалары боздай хәрәкәтсез, салкын һәм мәрхәмәтсез иде.

—Мылтыгың белән кил...

Зәнфирә башын иеп ишек алдына кереп китте...

Ирек урынында ята, самавыр ап-ак пар атып кайнап утыра иде. Зәнфирә, бер шешәне ачып, зур кружкага тутыра язып сыра салды һәм Ирекне иңбашыннан тотып торгызды.

—Эчә аласыңмы?

Ирек калтырана-калтырана сыраны эчеп бетерде, изиген күкрәгенә терәп, башын салындырган килеш, теш арасыннан гына сыкранып, аерым-аерым сүзләр чыгарды:

—Сүк мине!.. Ник син мине сүкмисең?..

—Ни өчен?—диде Зәнфирә, аның каршына утырып.

—Барысы өчен дә...

—Синең үзеңне үзең сүккәнең дә җитәр...

—Каян беләсең?

—Йөзеңдәге, күзләреңдәге газаптан...

Ирек кинәт сикереп торды, чайкала-чайкала, тәрәзәдән ташланырга теләгәндәй, өйнең түренә таба китте, тәрәзә тупсасына ике кулы белән таянып карап торды да кабат Зәнфирә каршына килде һәм ачыргаланып:

—Нишләргә миңа?! Әйт, Зәнфирә, нишләргә?!—дип кычкырды.

Аны иңбашларыннан тотып, Зәнфирә караватына утыртты. Аннары калган сыраны салып бирде, Ирек аны өч йотуда эчеп бетерде.

—Турысын әйтсәм, ачуланмассыңмы?—Ирек "юк" дигән мәгънәдә башын чайкады.—Сиңа дәваланудан башка чара юктыр инде...

Ирекнең күзләре хәтәр елтырап китте, куллары йодрыкланды. Зәнфирә, коты очып, аның кичәге кебек ташлануын көтте. Ирек кулларын шулкадәр каты йодрыклады, аның бармак буыннары агарып күренде. Киеренкелектән йодрыклары калтыранды.

—Үлсәм дә бармыйм...

—Ул чакта үләсең,—диде Зәнфирә ниндидер битараф тавыш белән.—Икенең берсен сайла, Ирек, сузарга ярамый. Ризалашсаң, мин сине үзем алып барам...

Зәнфирәнең бу сүзләре Ирекне тагын әллә нишләтеп җибәрде, үз колакларына ышанмагандай, ул аңа күзләрен зур ачып карап катты.

—Әйе, үзем алып барам. Син бөтенләй башка кеше булып кайтачаксың. Элеккечә матур тормыш башланыр.

Ирек нәрсәгәдер төшенә башлады.

—Ә син?!.

—Минме?.. мин синең белән калам... мәңгегә...

Ирек, күзләрен дә йоммыйча, ул әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенер-төшенмәс хәлдә авызын ачып карап торды. Зәнфирәнең сүзләре аңа бәхетле, якты дөньяның пәрдә читен әз генә ачып күрсәткән кебек булды. Тик бу дөнья хыял җитмәслек ераклыкта, Ирек кебек кешенең анда эләгүе әкият кебек бер нәрсә генә иде. Ләкин бу дөньяның барлыгын тою үзе генә дә рәхәт иде. Ул дөньяда бик күпләр яшиләр, шул исәптән Зәнфирә дә шунда, кызы Айгөл дә шунда, әтисе белән әнисе, Мэлс абыйлары да шунда, Әхнәф тә шунда, тик Ирек кенә ул дөньядан еракта, кара сөрем эчендә газаплана, пычракта ауный. Аның каршында утыручы Зәнфирә менә хәзер аны шунда чакыра, аның әнә шул матур кулларына тотынасы да атлыйсы гына. Әмма кинәт кенә булмый, иң элек тотынырга кирәк, аннары тезләнергә, аннары басарга, шуннан соң гына атлап булачак. Ирекнең моңа көче җитми. Димәк, ул дөнья аның өчен түгел. Аны бакый дөнья көтә. Бу уйдан ул тагын сискәнеп китте. Бакый дөнья?! Бу—кара гүр, дигән сүз, салкын туфрак, илле бер көннән итнең сөяктән аерылуы, кортлар ашап бетергәннән калган скелет, күз уемнары, бер-берсенә тиеп торган аскы һәм өске тешләр, черемәгән чәч бөртекләре, кул-аяк сөякләре, кабыргалар, шуларның бөтенесен баскан кызыл балчык. Аны менә шул көтә...

Икенче көнне иртән Ирек ашаудан баш тартты, аның йөзеннән төсе качкан, куллары зәңгәрләнеп тора, тырнаклары күкшел төскә кергән, гәүдәсе

калтырый, хәрәкәтләре үзенә буйсынмый иде. Күпме генә тырышса да, Зәнфирә аңа берни дә каптыра алмады. Ахырда ул кибеткә чыгып китәргә мәҗбүр булды, бер чөл аракы, шифалы су алып кайтты. Үлән суына бераз гына аракы салып, шуны эчкәннән соң, Ireкка бераз төс керде. Көндезгә ул аңа ит шулпасы пешерде. Тагын бераз эчемлек биреп, берничә кашык борычлы шулпа каптыра алды. Һава сулатмакчы булып, киендерә генә башлаган иде, Айгөл килеп керде.

—Исәнмесез,—диде ул, елмаерга тырышып.

—Исәнме, кызым, әйдә, уз,—диде Ирек, аны иңбашларыннан сөеп.

—Әйдә, Айгөл, кил әле, бик тәмле шулпа ашатам,—дип Зәнфирә аның пальтосын, башлыгын салдырды.

Икесенә дә аш бүлде һәм алар бәрәр савыт шулпаны ашап куйдылар.

—Рәхмәт, Зәнфирә апа,—диде Айгөл, шап-шоп эченә суккалап.—Әби әйткәндәй, корсагым бет үтерерлек булды.

Ул чәй эчмим диде.

—Әйдә, бергәләп Ык буеннан урыйбызмы, Айгөл?

Айгөл әтисенә карады. Аның сораулы карашына Ирек:

—Әйдә, кызым, мин дә барам бит,—дип җавап бирде.

Алар өчәүләп тар сукмактан Ыкка таба атладылар. Әкрен генә кар бөртекләре төшә, кояш каядыр качкан, җил астыртын гына үзенең барлыгын искәртә. Ыкка якынлашканда, аргы якта бер төлке чабып килгәне күренде.

—Айгөл, кара әле, кара!—дип чүгәләде Зәнфирә һәм үзенең бармагын төлкегә таба юнәлтте.

—Күрәм, күрәм!—дип сикергәләде Айгөл.—Әнә бит алдан куян да чаба.

Ул арада куян куаклар арасына кереп юк булды, төлке туктап калды һәм утырды.

—Ник куа ул аны?—диде Айгөл, әтисенә карап.

—Төлке куянны тотса, ашый, кызым.

—Төлке нишләп туктады соң?

—Куян җитез, тоттырмый ул аңа,—диде Ирек, кызының башлыгыннан чыккан чәчләрен рәтләп.—Төлкенең хәле тиз бетә. Әнә бит аның койрыгы нинди зур, шул артка сөйри торгандыр аны.

Айгөл әтисенә карап көлеп җибәрде. Ул арада төлке дә әрәмә эченә йөгереп кереп китте. Айгөлнең йөзенә борчылу билгеләре чыкты:

—Ә тотып ашаса?—диде ул әтисенә, ярдәм сорагандай карап.

—Борчылма, кызым, хәзер куян әллә кайда инде.

Алар Ык уртасына кадәр бардылар да, балыкчы тишек ясаган урында эз бетте. Айгөл боз астыннан ничек балык тотулары турында җентекләп сораштырды, Ирек аңа кар өстендәге эзләрнең кайсы карганыкы, кайсы этнеке, кайсы куянныкы икәнен аңлатып бирде. Кайтып житкәч, кызы кереп тормады, “кайтам, дәресләремне карыйсым бар”, диде. Зәнфирә аңа, кайтышлый шоколад алырсың, дип акча тоттырды.

Өйгә кергәч, Зәнфирә Иреккнең кан басымын үлчәп карады, пульсын тыңлады. Кан басымы югары, пульсы минутына йөздән артык тибә иде. Ул аңа укол ясады да, үлән суы эчереп, ятып торырга кушты. Ирек шундук гырылдап йоклап китте.

Ул караңгы төшкәч кенә уянды. Тору белән аракы сорады. Зәнфирә иң элек кыяр турады, шулпаны кайнарлады, аны салып, алдына китереп куйды. Мул итеп борыч сипте, калган ярты рюмкадан артык аракыны салды, ләкин Ирек аңа үрелергә өлгермәде, ишек ачылып китте һәм Сөембикә килеп керде.

—Хәерле кич,—диде ул керү белән һәм карашын өстәлгә төбәде.

—Әйдә, узыгыз, Сөембикә,—диде Зәнфирә.

Сөембикә аңа җавап бирмәде, тупсадан узмыйча гына, кинаяле тавыш белән:

—Тереләсенме?—диде.

Ирек авыз чите белән мәсхәрәле елмайды да рюмкадагы аракыны эчеп куйды. Аннары чәнечке белән кыяр кисәге алып, шатыр-шотыр чәйнәргә кереште.

—Кайнар шулпа бар иде, узсагыз.

—Рәхмәт. Хушыгыз,—диде дә Сөембикә ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып китте.

Ирекнең сырмасын эләктереп, Зәнфирә аякларына галошлар гына элде дә яланбаш килеш анын артыннан чыкты, өй алды утын кабызды.

—Молоде-е-ец!—дип суздь Сөембикә, эчендә кайнаган ачуын сүндерә алмыйча.—Бергәләп эчеп ятасыз.

Ул кинәт ике кулы белән Зәнфирәнең чәчләреннән эләктереп алды, Зәнфирә авыртудан кычкырып җибәрде, аның кулларына ябышты, әмма ычкындыра алмады.

—Ник син аны эчерәсен, кәнтәй?!

—Мин аны кинәт туктата алмыйм,—диде Зәнфирә елый-елый.—Ул бит үләргә мөмкин!..

—Син дөресен әйт: карт ирдән туйдым, диген! Мин аны, күпме түбәнлекләргә төшеп, милиция кулыннан алып кайттым!

Чәченнән тоткан килеш, Сөембикә аны як-якка селти башлады, Зәнфирә карга ауды.

—Кем чакырып китерде сине?!—Сөембикә, аның чәчләрен ычкындырып, куллары белән күкрәгенә басты.—Син кемгә кирәк?!

Зәнфирәнең тыны кысылды, ул бары бер генә сүз әйтә алды:

—Ана...

Сөембикә гәүдәсен турайтты, кулларын кагып куйды, шул арада Зәнфирә дә торып басты. Сөембикә тагын аңа якынлаша башлады, тегесе куркып артка чигенде.

—Әгәр кайтып китмәсәң, милиция белән киләм, аңладыңмы?

—Хәзер үк алып килегез милициягезне...—диде Зәнфирә хәлсез тавыш белән.—Мин китмәячәкмен... Мин аның ялгызын калдырмыйм.

Шул вакыт ишектән яланбаш, яланөс көе, оекбашлардан гына Ирек килеп чыкты.

—А ну-ка, ычкын!—диде ул, кызу-кызу Сөембикәгә таба атлап.

Сөембикә капкага юнәлде һәм, артына борылып:

—Белеп тор, бу хатын сине эчертеп үтерәчәк!—диде.

—Сиңа ул хатын кебек булырга кирәк әле.

Капканы ачкач, Сөембикә туктап Зәнфирәгә янады:

—Кара аны, мин әйткән сүземне үтәми калмыйм!—дип кычкырды.

Тагын ике көн узды. Зәнфирә үзе дә, Ирекне дә беркая да чыгармады, шикләнеп әледән-әле ишегалдын урап керде, Сөембикә әйткән милиционерларның килеп үзен алып китүеннән курыкты. Бүген кичкә ул мунча якты, яхшылап себерке пешерде, шифалы үлән сулары әзерләде, Караңгы төшкәч, мунчаның лампасын кабызды, аннары кайтып, чиста кием-салым, сөлгеләр алып, Ирекне мунчага озатып кайтты. Ишек алды тулып, ул юган керләр эленеп тора, төн караңгы һәм тыныч иде. Саф һавада шактый вакыт уйланып торды. Ниләр генә кыланып караса да, Ирекнең күңеленә энә очы кадәр дә юл сала алмады Зәнфирә. Әнисе сөйли торган иде: албастыларны буйсындыру өчен кешеләр аларның тәненә энә кадыйлар, әгәр шул энәне кадый алсаң, албасты синең дошманыңнан дустыңа әверелә, имеш... Зәнфирә кискен карарга килеп өйгә керде. Оекбашларын, гамажларын салып ыргытты, җиңелчә бер кат күлмәктән калды, чиста сөлге алды, сумкасы төбендә яткан кечкенә шешәдән чәченә, битләренә, тәннәренә ислемай тигерде. Үзен көзгедән карады, утырып тагын уйланып торды. Аның хәзер ясаячак адымы коточкыч тәвәккәл һәм бик куркыныч иде. Инде ул аңа бер генә мәртәбә омтылып карамады. Ничә мәртәбә мунча ягып, Ирек киткән саен баш ватты, ул адымны ясыйм дип, мунча ишеге төбенә баргач, кире борылып кайтты. Ирекнең моны ничек кабул итәчәген һич белеп булмый. Әгәр ул аны дөрес аңламаса, аларның аралары мәңгегә өзелергә мөмкин иде. Ләкин болай билгесезлектә, берниндн гамәл кылмыйча, аның аякка басуына кемдер кодрәт бирүгә ышанып утыру аны упкынга этәрү белән бер иде. Соңгы эш итеп, ул әбисеннән өйрәнгән

доганы күзләрен йомган хәлдә әллә ничә мәртәбә кабатлады. Азактан бөтен өйне яңгыратырлык итеп кычкырып укыды һәм аңаниндидер көч ингән кебек булды. Ул үзенең бу юлы кире борылмаячагын, уе барып чыкканчы бирешмәячәген сизенде.

Зәнфирә өйнең дә, өйалдының да утларын сүндерде, ишекне йозак белән бикләп, ачкычын кофта кесәсенә салды. Сөлгесен култыгына кыстырды һәм кызу-кызу адымнар белән мунчага атлады. Ул мунча өй алдына килеп керүгә Ирекнең:

—Кем бар?—дигән тавышы ишетелде.

—Мин бу, Ирек.

—Нишләп йөрисең?—Ирекнең тавышы кырыс һәм ачулы иде.

—Аркаңны ышкырга килдем.

—Мин аны юдым инде, кирәкми.

Зәнфирә аның белән сөйләшкән арада салкын өй алдында чишенеп беткән иде инде. Ул ишекне ачты һәм, йөрәге дөп-дөп типкән хәлдә, оялуын җиңәргә тырышып, эчкә атлады. Мунча идәнендә арты белән утыручы Ирекнең гәүдәсе аксыл пар эчендә калды, башы Зәнфирәгә таба борылды һәм ул:

—Кермә!—дип кычкырды.

Ирекнең күз карашыннан җыерылган Зәнфирә, зур адым атлап, тәрәзә төбендә янып утырган куыклы лампаның куыгы өстенә өрде, ут шундук сүнде. Башта мунча эчендә берни дә күренмәде, аннары ул тыштан төшкән яктылыкта үзенең тәнен дә, Ирекнекен дә шактый ачык күрде. Зәнфирә аны арттан килеп инбашларыннан кочып алды. Ирек үзенең калак сөяге турында аның йомшак, салкынча күкрәгеН тойды.

—Кагылма, зинһар,—диде ул әллә нинди калтыравык тавыш белән.

Зәнфирә аның кайнар тәненең җиңелчә дерелдәвен, мускулларының киерелүен тойды. Әгәр ул дөртләп кабынса, ачуы чыкса, нишләсен белеп булмый иде. Аның уйларын сизенгәндәй, Ирек акрын гына:

—Минем уң ягымда ярты чиләк шаулаган су тора,—диде.

Ләкин хәзер чигенергә соң иде инде. Зәнфирә аның колагына пышылдады:

—Кой син аны миңа.

Ирек куырылып башын аска иде, аның еламсырагандай өзек-өзек тавышы ишетелде:

—Зәнфирә, оят миңа...

—Оялма, җаным...

—Мин берни дә теләмим...

—Кирәкми дә,—диде Зәнфирә, тагын аның колагына пышылдап.

—Минем өчен берни дә юк.—Ирек өзек-өзек сулыш алды.—Син дә...

—Булачак... Мин дә булачакмын... Миңа берни дә кирәкми, Ирек,—диде ул күтәренке тавыш белән.—Рөхсәт ит, зинһар... Мин сине юындырырга гына телим.

—Мин юындым бит инде.

—Ә мин тагын юындырырга телим. Безнең икебезне аерып торган барлык елларны юып төшерергә телим,—ул шулай диде дә кулына сабын алды, йомшак кына итеп Ирекнең инбашларын, калак сөякләрен, беләкләрен сабынларга керешге.—Рөхсәт итәсеңме?

Ирек дәшмәде. Аңа шул хәтле рәхәт иде. Зәнфирә, аны биленә кадәр сабынлап бетергәч, ләгән белән җылы су әзерләде һәм йомшак куллары белән ышкый-ышкый сабынын юдырды. Бу вакытта аның сүтелмәгән чәч толымы әле Ирекнең күкрәгенә, әле аркасына тиеп китте, әле кулларына кагылды. Аннан соң Зәнфирә аны култык астыннан тотып күтәрде. Ирек торып баскач, аяк бармакларын сабынларга керешге. Аяклардан тезләренә, биленә кадәр күтәрелде, тагын юып төшерде.

—Хәзер чалкан ят,—диде Зәнфирә.

Ирек сүзсез аның боерыгына буйсынды. Шулчак Зәнфирә аның чәчләрен сыпырырга керешге, башына, җилкәләренә бармаклары белән басты,

кулларын сыпырды һәм акрын гына инбашларыннан кочаклап, бер аягын аның өстенә куйды. Ирек аның кайнар иреннәрен үзенең иреннәрендә тойды...

Ничә еллар үткәч, караңгы мунчада, анадан тума хәлдә, язмыш аларны кабат очраштырды. Зәнфирәнең иреннәре татлы, искиткеч йомшак һәм пешерерлек дәрәҗәдә кайнар иде. Ул шул иреннәре белән Ирекнең инбашларын, күкрәген үбәргә кереште. Ә ике кулы белән аның билен, янбашларын сыпырды. Менә ул кайнар иреннәр аның биленә җиттеләр... Ирек ыңгырашып иреннәрен тешләде, барлык гәүдәсенә ниндидер кайнар дәрт, кодрәт таралуын тойды... Ул, үзе дә сизмәстән, корыч пружина кебек, әллә ничәгә бөтерелеп алды һәм ике куллап Зәнфирәне кочагына кысты. Бу шулкадәр кискен булды, Зәнфирә кычкырып ук җибәрде. Аннары күкрәгеннән бер аваз чыгарды да тынып калды... Шул кичне алар бер караватта йокладылар...

***

Алар дүрт көн буе оҗмахта яшәгәндәй яшәделәр, сабый балалар кебек, иртәдән кичкә кадәр шаярыштылар, көлештеләр, үртәштеләр. Зәнфирә берсеннән-берсе тәмлерәк әйберләр пешерде. Олы яктагы өстәлне Ирек үзенең повестена әзерләнгән материаллар белән тутырып атты. Аны Зәнфирә белән бергәләп кычкырып укып чыктылар. Зәнфирә хәйран калды, син—гений, диде, синең кебек беркем дә яза алмый, диде, әгәр шушы повестеңны гына чыгара алсаң да, кешеләр сиңа мең-мең рәхмәт укыячак, анда күтәрелгән бер генә проблема хәл ителсә дә, халыкның тормышында уңай үзгәреш ясалачак, диде.

Ирек повестьны төзәтергә җиң сызганып кереште, ләкин ниндидер күренмәгән көч аның каләмен кадаклагандай тотып тора, зиһенен томалый иде. Ул көч бик еракта, кайнар, нечкә корыч чыбык белән тарткандай, үзенең барлыгын сиздереп тора һәм акрын гына, канны суырган сөлектәй, көчне суыра иде.

Бүген Зәнфирә больницага барып кайтырга булды. Аның кичәдән бирле эче авырта, төсе китте, моның сукыр эчәк булуы ихтимал иде. Ул киткәч, Ирек язарга утырды. Повестьның элекке вариантын актарды, соңгы язмаларын күздән кичерде, ләкин берни дә барып чыкмады. Теге нечкә чыбык аны тартуын дәвам итте. Ахырда ул аңа буйсынганын үз-үзенә икърар итте һәм, шул минутта сулышының кинәеп, тәненә көч кереп китүен тойды. Ул ничек итеп киенгәнен сизмәде дә. Өйгә йозакны элде дә капкадан тыкрыкка атылды, кибеткә ничек барганын, ничек кайтканын да сизмәде. Керү белән аягын да салып тормыйча, кече якка үтте, кырлы стаканны тутыра язып аракы салды һәм комсызланып эчеп җибәрде. Әйбер кабасы урынга, шартлап урындыкка утырды. Бөтен җанын телгәләгән нәрсәләр барысы да тынды. Дөнья түп-түгәрәк булып калды...

Көндезге унберләрдә кайтып кергәч, Зәнфирәнең йөрәге туктагандай булды. Ирек өстәл янында чишенмәгән килеш утыра, аракы шешәсе инде бушап бетә язган, ә алдында ашарга сынар валчык әйбер дә юк иде.

—Тагын шул ук хәл?!—диде Зәнфирә күз яшьләре белән.

Ул аягындагы итекләрен салды, шәле белән тунын караватка атты. Хәрәкәтләре салмакланган Ирек кулын селтәп куйды, аннары әллә ничек ахмакларча елмайды, җитдиләнергә тырышты, әмма аның елмаюы шул килеш иреннәренә ябышып калды.

—Зәнфирә, кичер. Менә бер мәртәбә...

—Җаның бармы, Ирек?! Күпме тырыштык...

—Беләсеңме, соңгы мәртәбә. Яңадан бер тамчы да капмыйм...—Ирек имән бармагын шешәгә төртте:—Менә моның белән хушлашу мәҗлесе.

Шулчак Зәнфирә тәрәзәгә карады һәм борчулы тавыш белән:

—Хәйри абый килә!—диде.

Бу сүзне ишетүгә, Ирек сикереп торды, аның йөзе җитди төс алды.

—Яткыр мине, бөркә!—дип кычкырды ул Зәнфирәгә һәм, пальтосы белән бүреген салып, Зәнфирәнең туны өстенә ыргытты.

Алар берни дә эшләргә өлгерә алмадылар, өйалдыннан Хәйринең дөп-дөп атлаганы ишетелде һәм ул ишектән килеп керде.

—Исәнмесез,—диде ул акрын гына, һәр ижегенә басым ясап.

—Исәнмесез, Хәйри абый,—диде Зәнфирә, нишләргә дә белмичә, аның битенә бурлаттай ут капкан иде. Шулай да ул Хәйри кергәнче башына шәлен салырга өлгергән иде.

—Әйдә, уз, эти,—диде Ирек, аңа таба бер адым атлап.

—Гайбәттер дип килгән идем, хак икән. Яшәп ятабыз, дисез алайса?—Хәйри аларның икесенә дә усал караш ташлап алды.

—Хәйри абый... китерегез пальтогызны, элим. Чишенегез.—Зәнфирә аңа таба кулларын сузды.

Ләкин Хәйри кыймшанып та карамады.

—Йә, малай актыгы, син миңа ни дип сүз биргән идең?

Ирек аның каршысында башын игән хәлдә басып тора бирде. Хәйри бер сүзсез аны уңлы-суллы яңакларга кереште. Ирекнең борыныннан кан ага башлады, ул бармаклары белән канын сыпырып куйды да:

—Үтер мине, эти...—дип пышылдады.

—Мин сине үтерә алмыйм!—дип бармак янады Хәйри.—Ә менә син әниең белән мине үтерәсең әле. Бар, торма каршымда ачу китереп!—Ул Иректе төртеп җибәрде, Ирек караватка барып ауды.—Син хәзер безнең киленмени инде, Зәнфирә?

Зәнфирә упкынга очкандай булды.

—Юк, Хәйри абый,—диде ул, яшьле күзләрен аңа төбәп.—Мин элекке дуслык буенча гына... Берүзе бит ул.

—Ә ирең?—диде Хәйри кискен генә.—Ирең берүзе түгелме?

Зәнфирә бу сорауга берничек тә җавап бирә алмады, кычкырып елап җибәрмәскә аскы иренен тешләп, башын аска иде.

Хәйри карашын Ireккә күчерде:

—Сиңа мин бер генә сүз әйтәм:—Ул караватка иелде һәм Ирекне якасыннан җилтерәтеп торгызып утыртты.—Әгәр эчүеңне ташламасаң, сиңа авыл зиратында урын булмаячак. Әниең белән безнең әйтәсе сүзебез шул!

Хәйри кызулап чыгып китте. Зәнфирә, өстенә дә, аягына да кимичә, аның артыннан иярде.

—Хәйри абый, зинһар, дөрес аңлагыз. Мин аны бит айнытырга телим. Инде әллә ничә мәртәбә туктаткан идем. Дүрт көн авызына бер әйбер дә капмаган иде. Менә бүген больницага барасым булды. Шул арада эчкән. Кем белә, йә берәрсе алып кергәндер. Ул бит язарга утырган иде.

Хәйри капкадан чыкканчы, шулай сөйләнә-сөйләнә, аңа ияреп барды. Хәйри туктап кискен генә борылды да, пышылдап:

—Булдыра алсаң, зинһар терелт, кызым,—диде. Аның да күзләре яшь белән тулган иде.—Әрәм була бит малай...

## 7

Инде бер атна Нәфисәнең мәктәптән кайтып кергәне юк. Башта фронталь тикшерү килә, дип дөньяларын онытып әзерләнделәр. Ниһаять, ул башланды. Көн саен район үзәгеннән алты-җиде кеше килә, дәресләргә керәләр, документларны, барлык төр планнарны тикшерәләр, контроль эшләр, тестлар алалар, тәрбия чараларында катнашалар—кыскасы, бөтен эшне энәсеннән җебенә кадәр күздән үткәрәләр. Мәктәптә утырып, бүген дә ул карангы төшкәнен дә сизмәде. Инде өстәлен тәртипкә китереп кузгалам гына дигәндә, ишек шакыдылар.

—Керегез,—диде Нәфисә арыган тавыш белән.

Аннан һәрвакыттагыча пөхтә киенгән, костюм-галстуктан химия укытучысы Дамир Зәйнуллин күренде.

—Биш кенә минутка мөмкинме?—диде ул, гадәттәгечә Нәфисәне күргә каушап.

Нәфисәнең ана нәрсә беләндер алып бәрәсе килде. Зәйнуллиннын сагалап торуларыннан, шушылай биш минут дип сүз башлауларыннан ул инде гарык булган иде.

—Дамир Нәгыймович, сезгә ничә мәртәбә әйтергә мөмкин? Туктагыз кеше көлдереп йөрүегездән!

—Туктыйм,—диде Дамир һәм аның каршына килеп басты.—Минем сезгә әйтәсе сүзем бар.

—Тынларга да теләмим. Кабатлап күрсәтимме сүзләрегезне? "Төшләремдә сез генә...", "Минем беркайчан да болай булганым юк иде", "Янығызда эшләргә генә рөхсәт итегез", "Мина башка берни кирәкми"...

—Мин сезнен мәктәбегездән китәм.

—Нәрсә?! Уку елы тәмамланып килгәндәме? Әллә бу сезнең чираттагы саташуыгызмы?

—Мин бүген мәгариф бүлеге мөдире белән ныклап сөйләштем.

—Ә нәрсә булды?

—Сәбәбен беләсез... Ләкин мин ана алай димәдем.

—Соң шуннан?—диде Нәфисә, әле һаман да аның әйткәненә ышанып бетмичә.

—Мин сезне кисәтергә телим... Тормышыгызга зур фаҗига килү ихтималы бар.

Нәфисәнең күнеленә шом керде. Дамир—Алмазның класс җитәкчесе, аның белән ни дә булса булгандыр, дигән уй йөгереп үтте аның башыннан. Теге вакытта малаеның кайтмый калуы аның күнелендә тирән эз калдырган һәм, нинди генә күнелсезлек булса да, ул яра сыкрап куя иде.

—Сез нинди фаҗига турында сөйлисез?

—Сез мине бер җилбәзәк исәргә санап йөрдегез. Мин сезне яраттым һәм сынадым. Әгәр сез холкыгызны үзгәртмәсәгез, гаиләгез таркалырга мөмкин.

Нәфисәнең шомлануы ачу белән алышынды. Шушы пешәр-пешмәс укытучының аның язмышы өстеннән хөкем йөртүе һич тә ошамады.

—Кайсы якка үзгәртергә соң мина холыкны?

—Белмим,—диде Дамир, башын аска иеп. Ул югары класслар̧да укучы баланы хәтерләтә иде.—Сез артык көчле, тимер кебек. Ә андый хатын-кызлар ир-ат белән яши алмыйлар... Ирләр йә үзләре китә, йә андый хатынны куалар.

—Рәхмәт күрәзәлек итүегез өчен.

—Ә сез кинаяламагыз. Йомшак хатын-кызны гына назлап була. Ир-ат үзеннән көчле кешене назлый алмый.

Нәфисәгә ачуны ничектер басарга кирәк иде.

—Алайса нишләп соң сез... ел буе минем арттан сөйрәлдегез?

—Минем бөтен холкым хатын-кызныкы. Шуна сезне яратканмындыр да.—Ул ничектер сәер итеп көлемсерәде, бу вакытта аның йөзендәге үзгәрешне аңлый торган түгел иде. Әллә көлү, әллә елау аша ул сүзен болай дип тәгәлләде:—Сез мине назламадыгыз, Нәфисә апа.

Зәйнуллин чыгып китте. Нәфисә бу сөйләшүне эченнән елмаеп кына кабул иткән булса да, мәктәптән кайтканда юл буе башка нәрсә турында уйлый алмады. Химия укытучысының әйткән сүзләре, тактага язылган химик формулалар кебек, үзләренең эчке мәгънәләрен һаман тирәнрәк ача бардылар. Өйдә ашарга әзерләгәндә, инде ул бу сөйләшүнең асылына тәмам төшенеп бетте.

Бераздан Мэлс та кайтып керде. Алар ашарга утырырга өлгермәделәр, телефон шылтырады. Мэлс йөгереп барып трубканы алды.

—Исәнме, улым.

—Исәнме, әти. Ни хәлләрдә ятасыз? Авырмыйсызмы?—диде Мэлс бу араларда кайта алмау гаебен тизрәк юу өчен.

—Хәлне кайтып белерсең әле. Хәзергә түзәрлек. Энекәшең янына кергәнең бармы?

—Әти, яшерә алмыйм: бу араларда гына юк.

—Кермәвең начар,—диде әтисе.—Айный алмый малай. Дәваларга алып барырга кирәк аны, улым.

—Мин дә шулайрак уйлап тора идем инде.

—Озак уйлама. Кеше гомере келт кенә итә ул.

—Ярый, әти.

Мэлс инде трубкасын куярга әзерләнгән иде, Хәйринең нәрсәдер кыштырдатканы ишетелде.

—Сөт белән нишләп хурлыклы урынга төштең?—Аның тавышы тагын да ныграк кырысланды.—Синең өчен монда мин оялып ятам. Район гәзитен кулга аласы килми. Сводкага карамаска тырышып, күземне читкә борам, башка мәкаләләрне укырга маташам, ә үзем сизмәстән һаман “Биектау”ны эзлим. Ә ул һаман күтәрелә алмый.

—Фураж белән хәл авыр безнең, әти.

—Син миңа акланма, син миңа сөт бир. Аңладыңмы?—әтисе трубканы куйды.

—Тагын нәрсә куыра?—диде Нәфисә, ире өстәл янына килеп утыргач.

—Сөтең юк, дип тирги. Бер яктан райком, икенче яктан исполком, өченче яктан трест, хет тресни.

***

Мэлс икенче көнне нарядын бетергәч тә Болынкырга элдерде. Ул барып кергәндә, Ирек әле караватта ята, өстәлдә чәй кайнап утыра, мич ягылган, Зәнфирә идән юып йөри иде. Мэлсның аны беренче күрүе түгел, энекәше янында элек яратып йөргән кешесенең булуын ул баштук хуплаган иде. Мэлсның кычкырып сәлам бирүенә Ирек иң элгәре башын калкытты, аннары авырлык белән торып утырды.

—Хәлләр ничек?—диде абыйсы аңа кул биреп.

—Әйбәт...

Зәнфирә, чиләк-мунчаласын ташлап, кулларын юды, ашарга әзерләргә кереште.

—Энекәш, син чатлатып-уратып сөйләшергә яратмаганны беләсең. Мин тиешле документларны әзерлим, сиңа дәваланырга кирәк.

—Син нәрсә, абый?!—дип кычкырып җибәрде Ирек.—Үзеңне дә, мине дә хурлыкка калдырмакчы буласыңмыни?

—Ә син нишлисең? Хурлыкка калдырмыйсыңмы?! Берсүзсез барасың!

—Мэлс абый дөрес әйтә,—дип сүзгә кушылды Зәнфирә.

—Мин күреп торам: сез сүз берләшкәнсез.

—Сүз берләшмәдек, энекәш. Без синең нинди хәлдә икәненне күреп торабыз, борчылабыз. Сөякләренә кадәр калтырап тора бит. Үз алдында үлеп торалар. Без аның чир икәнен аңлыйбыз. Дәвалансаң, берьюлы котыласың.

—Димәк, башкача мөмкин түгел,—диде Ирек, күзләрен ачу белән елтыратып.

—Юк, булмый.

Ирек күз карашын әле абыйсына, әле Зәнфирәгә юнәлтте дә, тәрәзә аша ишек алдына күз ташлап, болай диде:

—Әйдә, абый, соңгы мәртәбә: үзем туктыйм. Зинһар ышан миңа. Башка кабатланмаячак.

Мэлс энесенә бик озак сынап карап утырды.

—Ярый,—диде ул.—Әгәр үзең ташлыйсың икән—бигрәк әйбәт. Барыбызны да хурлык тамгасыннан коткарасың.

Абыйсы чыгып китү белән, Ирек Зәнфирәгә:

—Менә бүгенге чирдән коткар да, туктыйм,—диде.

Зәнфирә, аның сүзләрен үтәүдән кискен баш тартты, үлән суыннан башка әйбер бирмәде. Икенче көнне иртүк Зәнфирә система кую өчен аптекага барырга җыенды.

—Кеше кермәсен өчен өстеннән бикләп кенә китәм,—диде ул, йозакны кулына алып.

—Син нәрсә, Зәнфирә. Мине бикләнгән өйдә ятарга кем дип белден?!

Шулай итеп Ирек йозакны урынына куйдырды. Зәнфирә китү белән, тиз-тиз кырынды да, дипломатын алып, кибеткә йөгерде. Сатучы хатын аңа күптән таныш һәм Ирекне хөрмәт итә иде. “Ашыгыч кунак килеп төште, ике ярты биреп торыгыз”,—дигәч, ул үзенең кара кенәгәсенә язып, Ирекка бер литр аракы биреп җибәрде. Ирек яртының берсен утынлыкка яшерде, икенчесен башлап, кружка тутырып эчеп җибәрде. “Соңгы мәртәбә”, дип уйлады ул эченнән. “Соңгы мәртәбә туйганчы эчәргә дә шып туктарга”.

Зәнфирә кайтканда, ул инде йоклап ята иде. Аның сорауларына Ирек җавап та биреп тормады. “Керделәр”,—дип кенә мыгырданды... Система кую турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Ул тагын ике көн буе айнымады. Өченче көнне Мэлс килде, аның нинди хәлдә икәнен күргәч, исәнлек-саулык сорашмады, туп-туры:

—Йә, ничек?—диде.

—Синенчә, абый...

Мэлс шул көнне үк, аның паспортын алып, больницада йөреп, документлар әзерләде. Икенче көнне Казанга алып та китте.

Анда больницада үткән өч атна гомер Ирек өчен өч ел кебек тоелды. Үз гомерендә юньләп больница күрмәгән кеше өчен ул җәһәннәм газабына тиң булды. Ләкин өч атна үткәндә, рухы белән Ирек инде икенче кеше иде. Ул үзен аракыдан тәмам гайрәте чиккән кеше итеп тойды.

Абыйсы биргән акчага билет алып, самолетта Болынкырга очып китү аңа үзенең караңгы үткәненнән аерылу иде. Ул Казанга киткәндә, күренә генә башлаган яз кояшы хәзер инде тулы көченә кыздыра, кар ала-кола булып, чокыр-чакырларда, урман-әрәмәләрдә генә калган. Басуларда эшләп йөрүче тракторлар күренә, болыннарда көтүләр йөри, бозлар китеп, сулар җәелгән. Дүрт стена эчендә аракы, дару, косык исе иснәп җаны талкынган Ирек, бу күренешләрне карагач, яшьтән үк таныш тургайлар җырын ишеткәндәй, тәмле туфрак исен тойгандай булды. Болынкыр урамнарыннан ул ашкынып үзенең тыкрыгына атлады. Кайтып җиткәч, капка төбенә баскан килеш, ярларыннан чыгып җәелгән Ык суына сокланып карап торды. Ул киткәндә, күзләрне авырттырып җемелдәгән ап-ак кар катламы урынында пыяладай тигез булып җәелгән су ята, аның бер чите хәтта бакчаның түр ягына кадәр үтеп кергән. Ул кузгалырга өлгермәде, арттан капка ачылган тавыш ишетелде һәм, Ирек борылуга, Зәнфирә аны кочаклап алды. Ул кыска җинле күлмәктән, аякларына кәлүшләр генә элгән. Кочаклашкан хәлдә алар беравык тып-тын тордылар, бер-берсенә сулыш алулары гына ишетелде. Ирек битләренә тигән чәчләрнең хуш исеннән башы әйләнеп китүен тойды...

Нәкъ аларның артында сискәндереп әтәч кычкырып җибәрде. Ирек үзләреннән өч кенә метр ераклыкта койма өстенә басып тамагын ерткан кызыл әтәчкә аптырап карады.

—Кемнеке бу?

—Үзебезнеке,—диде Зәнфирә көлеп.—Әле биш тавык та алып җибәрдем.

Ирек сызгырып куйды. Зәнфирә аны өстәл әзерләп көткән иде. Нәкъ табын уртасында коштабакта ит өелеп тора. Ул савытларга кайнар борщ салды.

—Бәй, тегесе юкмыни?—диде Ирек көлеп.

—Тфү, тфү, авызыңнан җил алсын!

—Алды инде, алды. Мәңгегә алды.

Зәнфирә ышанмагандай аның йөзенә сынап карады һәм пышылдап кына сорап куйды:

—Ирек, гел эчәсең килмиме инде?

—Гелләрем дә килми.

Алар табын янында бик озак юындылар. Зәнфирәнең өстәлне

жыештырганын Ирек сокланып карап утырды. Аннары аны үзе янына тартып утыртты, Зәнфирәнең инбашларына кулын салды. Күзен каядыр почмакка төбәп, шактый вакыт сүзсез утырды. Аннары күнелендә кайнаган иң кадерле сүзләрен уеп салды:

—Их, Зәнфирә, белсәң иде... мин дә сезнең арада бит. Мин хәзер башка кеше, барлык кешеләр белән бергә.

—Мин синең өчен бик шат, Ирек.

—Ә бит күпме сәламәтлегемне, вакытымны югалттым. Тормыштан ай-яй нык артка тәгәрәдем.—Аннары өзгәләнеп әйтеп куйды:—Ә узган гомерне берничек тә кире кайтарып булмый...

—Юк, Ирек, безнең яшиселәр алда әле!

Ирек аны кочагына алды, үзенең алдына аударды һәм елмаючы иреннәреннән шашып үбәргә кереште...

Икенче көнне ашап-эчү белән Ирек үзенең кульязмаларына тотынды. Зәнфирә тышта тавыкларны карады, ихатаны чистартты, агач бакчасындагы чүп-чарларны җыештырды. Өйлә җиткәндә, Ирек тә чыкты. Алар су ташып, мунча ягып җибәрделәр. Ыкта һаман су күтәрелә иде. Тыкрык башына җиткән суга аяк очларын тигерә язып, бик озак карап тордылар. Каршы якта су эчендә утыручы өянкеләр инде яшелләнеп килә, аларның шәүләләре көзгедәгедәй Ык өстендә чагыла. Еракта кемдер көймәдә йөри, күрәсең, ау сала. Ара-тирә генә соңга калган бозлар күренә, аларның күбесе, күлләрдән чыкканга, яшел төстә, шунда ук камышлары, күрәннәре тырпаеп тора. Табигать чистарына, артык-мортык чүп-чарларны агыза, яшәреп җәйгә әзерләнә. Колак төбендә кошлар сайравы ишетелә, бал кортлары, чебен-черки безелди. Әле казлар гына күренми, алар үзләренең бәпкәләрен чыгарырга оялырында утыралар, чыгарганнары өйдә, ишек алдында гына көн күрәләр ахрысы.

Ихатада бергәләп тагын шактый вакыт эшләделәр. Ирек купкан койма такталарын алыштырды, асылынган җинел капканы күтәртебрәк куйды, аннары кульязмалары янына ашыкты.

Зәнфирә су эчәргә дип өйгә кергән иде, чыгып киткәндә аны Ирек туктатты:

—Менә тыңлап кара әле, бүген генә яздым,—диде ул, кулына кәгазь алып.

Өч бит укыгач, туктап калды.

—Йә, ничек?

Җавап урынына Зәнфирә аның ике битеннән үбеп алды.

—Мондый юлларны син генә яза аласың, Ирек. Син бөек язучы булачаксың.

Аның бу сүзләренә Ирек иреннәренә мыскыллау чыгарып җавап бирде:

—Очты инде андый хыяллар. Бар иде саламнан тәртә каерып, чикерткә жиккән чаклар. Гомернең барысын да бушка үтте, дип булмый. Мәгънәле өлеше дә булгандыр. Тик мине ничек кирәк, шулай бөктеләр. Тагын безнең өскә аракы коеп тордылар. Кая барсаң да, автоматтан аткан кебек... Төрле яклап аталар... Син шуннан иелә-бөгелә исән атларга тиеш. Эләксән—исән калу юк. Сагалаучылар шул кадәр күп! Шуның өстенә җилкәдә мен төрле мәшәкать... Иртәдән кичкә кадәр бөтерелеп тә сине туктаусыз битәрләп, өркетеп торулар... үзеннән-үзе куллар рюмкага үрелде. Ул кадәр киеренкелеккә ничек чыдамак кирәк...

Аның бу фикерләрен тынлый-тынлый, Зәнфирә хәтәр нәрсәгә килеп төртелде: Ирек үзен гаепле санамый, тормышны, кемнәрнедер гаепли иде. Шуңа күрә ул аның күнелен китмәслек кенә итеп сүз кыстырды:

—Синең күршең Расих бер грамм да капмый бит. Туктаусыз атып торган ул аракы автоматларына нишләптер Гаскәров, Вафин кебекләр дә эләкми калган.

Аның бу сүзләрен ишеткәч, Ирек иреннәрен тешләп куйды. Кулындагы ручкасын сындыра язып, бармаклары белән бөкләргә маташкандай итте һәм сүзне икенчегә борды:

—Ярар, күңелсез нәрсә турында сөйләшмик әле. Миңа шифалы су булса да алып кайтмассыңмы икән? Ачы әйбер эчәсем килә. Шифалы суга әчегән катык салып эчәр идем.

Зәнфирә анын теләген үтәде. Әмма шифалы су белән әчегән катык анын кәефен күтәрмәде, киресенчә, йөзенә аларның ачылыгы чыккан кебек булды.

Көннәр акрын гына уза торды. Ирек белән алар Ык буйларын урадылар, капка төпләрен чистартып, коры чүпләрне өеп яндырдылар. Зәнфирә сарымсак төртте, кишер чәчте, Ирек агач ботакларын кисте: һәр иртәне ул үзенең кульъязмалары белән мәшәләнде. Ояда утырган каз үзенең йомыркаларын томшыгы белән әкрен генә шакы-шокы әйләндергәндәй, ул да кәгазьләрен кыштырдатты. Үтеп-сүтеп йөргәндә, Зәнфирә Ирекнең уфылдап куюына, ике кулын янагына куеп утыруларына борчылып күз салды. Сизеп тора: яза алмый иде Ирек. Бүген дә уфылдап сәгать тугызларга кадәр утырды да кулындагы ручкасын шапылдатып өстәлгә атты. Ручка өстәлдән чәчрәп китеп, тәрәзәгә чартлап барып тиде, аннары идәнгә төште дә ярыктан тәгәрәп кереп китте.

—Булмый,—диде ул өзгәләнеп.—Алдымда меӊ тонналы таш. Кузгатып кына җибәрергә иде. Кубарып, кузгатып булмый. Аннан тәгәрәтер идем.— Ул шулай диде дә тышка чыгып китте.

Зәнфирә анын өчен көяләнеп кече якта басып калды. Ул ни кылырга, нинди киңәш бирергә белмәде. Әгәр мөмкин булса, җанының яртысын кыеп бирер иде дә...

Ирек яңадан кергәч, ул аңа:

—Мин сиңа бер киңәш бирсәм, ачуланмассыңмы?—дип сорады.

—Нинди киңәш?—диде Ирек төксе генә.

Анын бөтен кыяфәтенә, синнән нинди генә нәрсә чыгар икән, дигән уй язылган иде.

—Икенче әйбергә тотынып кара,—диде Зәнфирә.—Әйтик, менә безнең тормышны яз.

Ирек аңа сораулы караш ташлады:

—Кемнекен, икебезнекенме?

—Юк, Заһит абый белән безнекен.

—Сезнең тормыш... ни инде ул? Туп-туры, шоп-шома яшәүне язып буламыни?

Зәнфирәнең күзләре дымланып китте, ул аларны яшерү өчен читкә борылды.

—Шулай шоп-шомадыр дип уйлыйсыңмы?—диде ул, кече якта нәрсә беләндер әвәрә килеп.

—Язган әйбердән укучы гыйбрәт алырга тиеш.

Зәнфирә, эшен ташлап, Ирекнең каршына килде һәм ярым пышылдаулы тавыш белән:

—Син анын мине атарга йөргәнен беләсеңме?

Ирек сискәнеп китте. Ул Зәнфирәнең һәр сүзен ачык ишеткән иде, ләкин ул сүзләр читлектән пырхылдап очып чыккан кошлар кебек анын аңына керә алмадылар.

—Син, арттырам, дисәң дә, чамалап сөйлә, Зәнфирә,—диде ул аны кисәтеп.

—Арттырырга уйлаганым да юк. Сиңа китәсемне белгәч, ул ике көпшәле мылтыгын алып, күз алдымда корды.—Зәнфирә тирән итеп сулап куйды, керфекләрен йомып, шактый вакыт сүзсез торды.—Аннары мине ишек алдына җитәкләп алып чыкты. Абзар янына бәйләнгән бозау кадәр ап-ак бурзаебыз бар иде, безне күргәч, этебез койрыгын болгый-болгый, куанып безгә тартылды, куанычын белдереп, тамак төбеннән баланыкына охшаган тавышлар чыгарды. Мин Заһитның нишләргә теләгәнен уйлап та бетерә алмадым, ул этка атып та җибәрде. Эт чинап та өлгерә алмады, күкрәк турыннан, авызыннан каны аккан хәлдә ак карга егылды. Мин елый да алмадым, авызым ачылып катты, бөтен гәүдәм калтырарга кереште,

кулларымны чытырдатып кысудан тырнакларым тәнемә баткан иде. Акбаебыз кар өстендә канга батып шактый озак тыпырчынды, тартышты, канлы авызы белән кар тешләде, аннары тынып калды. Аның матур, чем-кара түгәрәк күзе ачык килеш ялтырап тора иде. Заһит мине терсәгемнән тотып аңа таба иде, "Күзләрендә икебезнең шәүләбезне күрәсеңме?—диде ул.—Сиңа да шушы язган булачак, әгәр миннән китсәң...

—Ышанмыйм!—диде Ирек, Зәнфирәнең йөзеннән, күз карашыннан ялганлау билгеләре эзләп.—Заһит абыйны мин синнән яхшырак беләм. Ул беркайчан да мондый адымны ясый алмас.

—Аны белеп бетерү мөмкин түгел...

Зәнфирә сумкасының берсен актарырга кереште һәм бармак калынлыгы зәңгәр дәфтәр тартып чыгарды.

—Менә укып кара,—диде ул аны Ирекккә сузып.

Ирек дәфтәрне ачып алдыннан да, артыннан да актарып карады. Ул беренче гыйнварда башланган, утыз беренче декабрь белән төгәлләнгән иде. Аның һәр көне графаларга бүленгән. Дәфтәрне актарып карагач, Ирек аны кабат Зәнфирәгә сузды.

—Мин моның Заһит абый кулы белән язылганлыгын күрдем. Заем язуындагы кебек, матур, тигез булып тезелгән вак хәрефләр. Тик биредә ни язылганын мин аңламыйм.

—Моның нәрсәсен аңламаска ди? Биредә безнең яшәгән һәр көнебез язылып барылган. Һәр көнне нәрсәгә, ничә тиен, ничә сум акча тотылган, һәр көнне ничә тиен, ничә сум акча кергән, һәр айда ничә сум, ничә тиен акча алынган, ничә сумлык әйбер ашалган, әгәр бозылса, ватылса, ничә сумлык әйбер бозылган, ватылган һәм башкалар...

Ирек кулларын як-якка җәеп җибәрде, тыны беткән кешедәй, башын әле уңга, әле сулга борды, аның авызы бер ачылды, бер йомылды, кашлары, маңгаен җыерчыкландырып, югары күтәрелде.

—Зәнфирә-ә-ә! Ник соң болар барысы да?!

—Анысын инде аның үзеннән сорарга кирәк,—диде Зәнфирә.—Һәр елның дәфтәре исән-сау килеш чормага куеп барыла. Алар хәзер ике төргәк. Мин менә сиңа күрсәтер өчен дүртесен алдым.

Ирек башын тотып уйга калды.

—Бар, чыгып тор әле, Зәнфирә,—диде акрын гына.

Аның сүзенә буйсынып, Зәнфирә шактый гомер ишек алдында эшләп йөрде. Менә ишектә Ирек күренде, ул акрын гына атлап, Зәнфирә янына килде, аның ике битенә йомшак кына итеп куллары белән кагылды, йотылып күзләренә карады.

—Аның сине чыннан да үтерә алуына әллә ышанасыңмы?—диде Ирек тотлыга-тотлыга.

—Белмим... Аңардан теләсә нәрсә көтеп була. Ул әллә нинди кануннар белән яши.

—Бу бит коточкыч!—диде Ирек. Ул, кемнәндер җавап эзләгәндәй, капка янынннан ук әйләнеп килде.—Ул бит шундый ачык йөзле... өздереп гармунда уйный, күңеле начар кеше алай моңлы уйный алмый.

—Менә, менә!—дип җанланып китте Зәнфирә.—Кайчандыр мин дә аңа шушы хакта әйткән идем. Ул болай дип җавап бирде: "Бу тормышта яшәү өчен үзеңне яки яшереп бикләп куярга, яисә үтерергә кирәк,—диде.—Әмма бикләсәң дә, үтерсәң дә, җаның барыбер кычкыра, аның тавышы гармунда."

Ирек кул кушырып, бакча коймасына аркасы белән терәлгән килеш уйга баткан иде. Сөйләмә дә, әйтмә дә, аңларга да теләмим, дигәндәй, ул күз карашын кояшта җемелдәп ятучы Ык өстенә, язгы суларга юнәлткән килеш, акрын гына башын чайкады. Зәнфирә, аны култыклап алып килеп, баскычка утыртты һәм Заһит белән ничек яшәвен сөйләп бирде. Аны тыңлап бетергәннән соң, Ирек ачынып:

—Ник соң син аның белән тордың?!—диде.

—Башта укытучым итеп буйсындым, аңа карыша алмадым. Аның һәр сүзе дәлилле. Ул минем өчен "Заһит абый" булды. Балабызның теле

ачылганда гына, мин ана “Заһит” дип дәшә башладым. Анысына да ул мәҗбүр итте.

—Ник аерылмадың?

Бу сорауны ишетүгә, Зәнфирә күзләрен уйнатып алды, аның иреннәре калтырап китте:

—Син ник язмадың соң?!—диде әчке ачуын яшерә алмыйча.

Ирек аның бу соравыннан аптырап калды. Зәнфирәнең болай дөртләп кабынуы беренче мәртәбә иде, шуңа күрә, әллә каушаудан, төгәл генә җавап та бирә алмады.

—Нидер җитмәде...

—Миңа да шулай... нидер җитмәде, Ирек...

Аларның карашлары очрашты; алар бер-берсенең күзендәге тирәнлекне бик озак аңларга тырышып карадылар һәм күбесен аңладылар. Мондый саф, риясыз караш, икең бер булып, бер-береңнең күзенә төбәлү күп еллар буе көтеп алынган илаһи мизгел иде... Алар аны мөмкин кадәр озаккарак сузарга тырыштылар, күзләрендә язылганнарны, җылыга, яктыга сусаган чәчәкләр кояш нурларын үзләренә таба тарткандай, сүзсез генә сеңдерделәр...

8

Ниһаять, Зәнфирәгә урын табылды: больницаның терапия бүлегендә шәфкать туташы булып эшли башлады. Сменалы эш булса да, моңа икесе дә куанып бетә алмадылар. Димәк, каяндыр аз булса да акча киләчәк.

Ул көнне Зәнфирә көндезге сменада иде. Ирек язарга тырышып бик озак утырды. Пьесасын төзәтә алмагач, читкә ыргытты. Аннары повестен ачты. Инде күпме вакытлар күңеленнән Әхмәт белән килешеп, аны үзгәртмәкче булып, каләменә үрелде, әмма бер юл да яза алмады. Повесть төгәлләнгән, ана кагылып булмый иде. Ирекнең, кешегә биологик сыйфатлар ул туганчы ук ген белән салына, иҗат кешесе иҗатчы булып, карак карак булып туа, дип укыганы бар иде. Һәм ул кешеләрне бернинди тәрбия дә төзәтә алмый, каракны урлашудан, хулиганны сугышудан туктатып булмаган кебек, йомшак холыклы кешедән хулиган, хулиганнан йомшак холыклы кеше ясап булмый. Аның да язган бу ике әйберсе шулайрак булып туганнардыр, күрәсең. Каләмең кулыңда, кәгазең алда, ничек телисең, шулай төзәт, беркем дә сиңа комачауламый кебек, әмма шушы гади генә нәрсәне инде күпме гомерләр эшләп булмый.

Ул, ишек алдына чыгып, берни уйламыйча, шактый вакыт басып торды. Аның янына тавыклар җыелды, алар үзләренчә нидер сөйләшәләр, чыгып баш төрткән яшел чирәм төбеннән нәрсәләрдер чүпләнәләр, тырманалар, вакыт-вакыт нидер өметләнгәндәй Ирекка карап торалар. Араларында мәһабәт басып кызыл әтәч йөри, нәрсәдәндер “кырыйк” дип кисәтә, зәһәр итеп берничә мәртәбә кычкырып куя.

Ирек, яшелчә бакчасына чыгып, бер кишәрлек җир казыды. Зәнфирә кайтуга, берәр нәрсә пешерергә ниятләп, өйгә керде. Ашыкмый-кабаланмый гына бәрәңге әрчеде, аны юып, майда тәгәрәтеп, плитәнең духовкасына тезде, тоз, бөтнек, укроп сипте һәм пешерергә куйды. Аннары Ык буеннан урап кайтырга уйлап, ишегенә йозакны элеп кенә куйды да капкадан чыкты. Шул чак тыкрыктан Бәкер белән типографиядә эшләүче Сания апаның килгәне күренде. Ирек Бәкер белән кул биреп күреште.

—Тегене карап чыга алмадыгызмы?—диде Сания.

Ул моннан берничә көн элек институтта укучы кызының татар теле грамматикасыннан контроль эшен алып килгән иде. Ирек аны шул көнне үк төзәткәләп, кайбер урыннарын янадан эшләп куйган иде.

—Әйдәгез, керәбез, әзер ул, Сания апа.

—Мин өйгә узып тормам,—диде Сания, баскыч төбендә туктап.—Алып чыгып кына бирсәң...

Ирек аңа контроль эшне алып чыкты, Сания рәхмәтләр укый-укый, кәгазьгә төрелгән әйбер сузды.

—Юк, юк, син нәрсә, Сания апа. Берни дә кирәкми. Мин аның өчен эшләмәдем,—диде Ирек, кучтәнәчне читкә этеп. Куллары белән эткәндә, ул кәгазь эчендә шешә барлыгын тойган иде инде.

—Әгәр алмасаң, үпкәлим. Әнә Бәкер белән үзегез хәл итәрсез,—диде дә, рәхмәт укый-укый, капкадан чыгып ук китте.

Бәкер кулындагы Сания биргән кучтәнәчне селкетеп-селкетеп карады да:

—Сания апаның көмешкәсе әйбәт була инде аның,—дип кеткелдәп көлеп җибәрде.

Алар Бәкер белән өйгә уздылар. Ирек өстәлгә бер рюмка, тозлы кәбестә, ипи, пешкән йомырка куйды.

—Син эчмисең инде алайса?—диде Бәкер.

—Юк, ярамый...

Бәкер бер рюмканы салып эчеп куйды, кетердәтеп тозлы кәбестә ашарга тотынды. Ирек инде үзендә Сания апаны күрү белән нindидер үзгәреш булганын тойган иде: әллә шатлык, әллә бер җинеллек—нindидер бер нәрсә аның җанына, тәненә үтеп керә башлаган иде. Отыры аның бөтен күзәнәкләренә дөртләп ут капты... башы җинеләеп, рәхәт булып акрын гына әйләнә башлады. "Нәрсә булды соң миңа?"—дип уйлады Ирек, духовкадагы бәрәңгеләрнең пешүен тикшергәндә. Кабат өстәл янына килгәндә, аның йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып тибә, шатлыгы сыя алмыйча тыны кысыла, сулышы әле туктап кала, әле күкрәгеннән бәреп чыга иде. Шул чакта аның зиһене бер нәрсәне әләктереп алды: бу шатлык юкка түгел, аның бөтен барлыгын рәхәтләндерәчәк шушы ләззәт бик якында гына... бер генә хәрәкәт ясыйсы, моны эшләргә тулы мөмкинлек бар.

Аның бу халәтен Бәкер сизеп алды булса кирәк.

—Әллә берәр генә йотып карыйсыңмы? Зәһәр бу, алтмыш градус бардыр,—диде.—Миләштән ясалган, чын дару. Сания апа, кызыл миләш белән кара җимешне кушып, йөземнәр, хөрмәләр салып ясый.

Ирек инде, ул дәшмәсә дә, ике капма-каршы ярга тарттырылган корыч бауда чайкалып торган кеше кебек, "миңа да сал", дип әйтергә әзер иде. Ләкин әле ул үзенең шул бауга басып торырлык ихтыяр көче барлыгын тоюдан үзен нindидер батырлык кылучы дип саный, Бәкердән һәм башкалардан үзен өстен итеп куя иде. Менә шушы тойгы аны рюмкага үрелүдән шушы минутка кадәр коткарып торды, әмма Бәкернең әлеге әйткән сүзләре аның бу батырлыгын җимерергә бер сәбәп булды. Әйтерсең лә ул әлеге сүзләре белән бауны кисеп төшерде һәм аска очуына Ирек үзе түгел, Бәкер сәбәпче иде. Дертләп бөтен күзәнәкләрен көйдергән шатлык уты "мөмкин, мөмкин!", дип дөрләде. Ирек елмаеп җибәрде һәм кабаланып рюмка алып килде.

—Әйдә, булмаса, синең белән күптән очрашкан юк бит. Тик миңа ярамый, өч кенә тамчы сал.

Бәкер, күзләрен кысып бетереп елмая-елмая, аның рюмкасына яртылаш салды. Чәкештергәч, Ирек тагын берничә генә секундка уйланып калды, ул тыелырга теләде, ләкин бу теләк шул кадәр көчсез, инде әллә кайда еракта ук калган, аңа таяну мөмкин түгел, ул теләк юк ителгән; шатлык, йөрәкнең ашкынып тибүе аны инде күптән алып ташлаган иде. Ахырда ул тәмам бирешә, көмешкәне сөзеп кенә эчеп куйды, берни дә капмады, Бәкер гадәттәгечә ач иде, ул куйган йомыркаларны, ипиләрне, кәбестәне бөтенесен рәхәтләнеп ашады, кемнең көмешкәсе нинди булуы хакында туктаусыз гәп куертты:

—Ну, малай, үзенә генә әйтәм, беркемгә дә әйтмәссеңме?

—Юк инде,—диде Ирек.—Син нәрсә? Миннән кайчан сүз чыкканы бар?

—Хак әйтәсең. Әйдә, синең шул сыйфатың өчен эчик әле.

Алар тагын бер рюмканы дөңкеп куйдылар.

—Беркөн мин Хасбулатоваларга бәдрәф чокыры казырга бардым. Вәйт аларныкы көмешкә ул! Коньякларың бер як читтә торсын. Әллә нинди үләннәр салынган, илле градус бардыр. Эчкән саен дәрт керә.—Бәкер пышылдап кына хәйләкәр елмаеп сорап куйды:—Әллә, малай, милициягә ничек ясарга икәнен өйрәткән рецепты да килә микән?

Алар көлешеп алдылар.

—Миргаязның хәле ничек соң?

—Ул сөт заводында эшли. Безнең дуслык бетте әле аның белән.

—Нишләп?

—Теге атнада "төрмә кошы" дигән идем, кыйнады. Күз төбен күрмисеңмени? Хәзер бетеп килә инде.

—Язамы соң?

—Белмим.

Бәкер тагын дәртләнеп үзе яраткан темага күчте:

—Әй, малай, хәзер төнлә һәркемнең мунчасында көмешкә куалар. Ул ишек бикләп, тәрәзә томалап, уйнаштан туган аракы ясаучылар өй аралаш. Беркөн Сәйфетдиннәрнең борчактан ясаганын авыз иткән идем. Күзем шундук маңгайга менде. Бодайныкы да шәп. Хәзер чөгендер кайнатып ясыйлар: бер йоту белән тәнеңә тир бәреп чыга, ул дару белән бер икән. Ник дисәң, табигый нәрсә бит, шикәре дә эшкәртелмәгән килеш, бөтенесе үзендә.

Алар тагын берне күтәрделәр.

—Теге больница завхозы Зәкиев ацетон, тавык тизәкләре кушып ясый, диләр. Мин аныкын бер мәртәбә алып карадым. Үлгәндә чак калдым, бер атна чирләдем. Ну, бөтен кеше шуңа бара, төннең кайсы вакытында баруыңа карап, бәясе дә төрлечә. Веранда ишегенә шешә сыярлык тишек ясаган: акчаңны бирәсең, аннары гына шешәсен тыга. Булган икән рәхәт заманнар, кадерен белмәгәнбез. Зәкиев самогонын эчеп, бер кеше үлде инде. Шауламакчы булып караганнар иде—тавыш-тын бетте, акчасы күп кешегә кем тия алсын.

Көмешкә беткән иде инде. Ирек, Зәнфирәнең шкатулкасы эчендәге акчасын алып, Бәкергә бирде:

—Озак йөрмә, Зәнфирәнең эштән кайтыр вакыты житә.

—Биш минут,—диде Бәкер күзләрен очкынландырып.—Минә монда тыкрыктан чыгу белән бирәүдә бар.

Бәкер алып кайткан көмешкә борыннарны әчеттерерлек исле, телгә алгысыз ачы әллә нинди нәрсә булып чыкты. Алар берәр рюмка эчкәч, Бәкер:

—Хатының кайтыр вакыт житте, мин китәм,—диде, урыныннан торды.

Бәкер ындыр артлатып кына өенә элдерде. Ирек кереп өстәлләрне җыештырды, духовканы сүндерде, алган көмешкәне мунча өй алдына яшереп куйды. Ул аның әле кирәк булачагын белә иде.

Зәнфирә үзе кайтканда бакчада шактый жир казылганын күреп куанып куйды. Ләкин өйгә керү белән аның куанычы юкка чыкты: Ирекнең йөзе, муеннары ямьсез булып кызарган, бүртенгән, бөтен өйне тәмсез ис алган иде. Ул барысын да аңлады.

—Их, Ирек,—диде Зәнфирә өзгәләнеп.—Нишләдең син?!

Иягенә таянып утырган Ирекнең кулы кинәт жансыз әйбер кебек төшеп китте.

—Бетте, бетте, карчык,—диде ул.—Кабып кына карадым. Моның зыяны юк. Башка кабатламыйм. Гафу итә аласыңмы бер көнгә?

—Мин гафу итәрмен итүен, организмың нишләр бит?

—Син итсәң, ул итәр...

Ирек караңгы төшкәнче бакчада буталды, шул арада мунча өйалдына кереп чыккалады һәм кичкә көмешкәне эчеп тә бетерде. Изрәп-йомшап беткән гәүдәсенең торган саен авырая барганын тоеп, көч-хәл белән кереп ауды.

Ул күзләрен ачканда, бөтен дөнья дөм-караңгы, тәненең һәр күзәнәге

сулкылдый иде. Ул кычкырырга теләде, ләкин бернинди тавышы чыкмады, телен әйләндереп сүз әйтерлек хәле юк иде. Ул бары бер әйбер тойды: туктаусыз оча. Ул берни күрми, тик баш ягынын аска таба авуын, аяк ягынын туктаусыз өскә күтәрелүен генә тоя. Йөрәге типми, анын урынында ниндидер ут бөтен тәнен көйдереп тора. Аягы күтәрелде-күтәрелде дә иң ахырда каядыр очты...

...Ынгырашкан тавышка Зәнфирә күзләрен ачты, эчке күлмәктән килеш кенә йөгереп барып утны кабызды. Ирекнең йөзе зәңгәрсу-шәмәхә төскә кергән, сулыш алганы ишетелми, җан биргәндәге кебек, күкрәге куркыныч гырылдый. Кабаланып ул анын кулын күтәрде һәм пульсына бармагын куйды. Тамыр тибәр-типмәс кенә селкенеп куйды. "Йә, Хода, үлеп бара ич бу", дип өзгәләнде Зәнфирә. Ашыгыч ярдәм чакырырга өстенә тунын киде, ләкин өй алдына чыккач, кире борылып керде. Ул каядыр барып шылтыратканчы, ашыгыч ярдәм килгәнче, соң булачак. Өстен салып идәнгә ыргытты да шприцларын, даруларын актарырга керешге. Нашатырь спирты алып, Ирекнең борыны янына китерде, ләкин анын йөзендәге бер генә мускул да хәрәкәтләнмәде. Күрәсең, ул комада иде. Зәнфирә ут эчендә калды. Анын башына тәвәккәл уй килде: йөрәгенә укол кадарга! Шул гына коткарачак. Тик шул ук укол анын үлеменә дә сәбәпче булмасмы? Баш миен көйдергән шушы уй анын бөтен барлыгын ут булып яндырды. Ләкин икеләнергә вакыт юк иде инде. Ул иң озын энәне эзләп тапты, калтыранакалтырана шприц белән хлорлы кальций суыртты һәм, шприцны куеп, Ирекнең күлмәген салдырып атты, тагын бер мәртәбә сулышын, йөрәгенең тибүен колагын куеп тыңлады. Йөрәк бер минутта туктамаса, икенчесендә туктар шикелле иде. Анын үз гомерендә кеше йөрәгенә укол кадаганы булмады. Ул энәне йөрәкнең кайсы төшенә туры китерергә кирәген генә белә. Спирт алып, Зәнфирә йөрәк турын мамык белән чистартты, тирән итеп сулыш алды, бисмилласын әйтеп, шприцка үрелде. Шул чакта тагын икеләнеп калды, хәзер кирәчәк бу энә анын иң якын кешесенең гомерен өзәргә, аны да, Зәнфирәне дә һәлак итәргә дә мөмкин иде. Күзләрен йомып, тирән бер сулыш алганнан соң, энәне Ирекнең күкрәгенә батырды. Анын гәүдәсе ток үткәндәй дертләп куйды. Энә урынынннан кан чыкты, шприц эченә шулай ук кан бәрде. Зәнфирә бөтен тәненең тирләвен сизде, тешләрен кысып, калтыранган бармаклары белән шприцтагы даруны эчкә кертте һәм энәне тартып алды. Анын урынына бармаклары белән спиртлы мамык басты. Анын бөтен тәне калтырый, йөрәге шашып тибә иде. Ул сул кулынын аркасы белән маңгаендагы, битләрендәге тирләрен сөрткәндәй итте дә колагын Ирекнең күкрәгенә якынайтты, ләкин йөрәкнең тибешен сизмәде. "Туктаган!" дигән хәтәр уй аны яшен суккандай итте. Ул кабаланып сул кулы белән Ирекнең пульсын капшарга керешге һәм йөрәк тамырынын жинелчә генә тибүен сизде. "Исән! Ул исән!" Ирекнең сулышы да сизелә башлады, ләкин йөзендә барыбер хәрәкәт күренмәде, күз кабаклары, керфекләр мәетнеке кебек тораташ катканнар иде. Шушы вакытта гына анын кулларына игътибар итте: алар да шәмәхәләнеп, күгәреп шешенгәннәр икән ич. Зәнфирә тәрәзәне ачып җибәрде, бармагы белән тоткан мамыкны пластырь белән ябыштырып куйды.

Ул үзе әле генә укол кадаган урыннан күзләрен һич тә ала алмады, кулынын шушы эшкә баруына ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Бераз зиһенен җыйгач, Ирекнең битләренә салкын сулы сөлге тигерде, күкрәк тирәләрен сөртеп алды, кулларына, буыннарына массаж ясагандай итте, борынына тагын нашатырь спирты китерде. Бусында анын иреннәре калтыранып куйды, күз керфекләре аз гына ачылды. Ләкин анын пыялаланган күзләре нәрсә булганын аңларлык, Зәнфирәне күрерлек түгел иде. Пульсын тыңлагач, йөрәгенең шактый көчле, тигез ритм белән тибә башлавы сизелде. Зәнфирә тунын элеп, шәлен бөркәнде дә чыгып йөгерде. Ул үзләреннән ерак түгел берәүләрдә телефон барлыгын белә иде. Бәйдәге этләре дөнья кубарып өрүгә карамастан, Зәнфирә койма өстеннән очып кына ишек алларына төште. Ул арада веранда алдындагы ут янды һәм

трико-майкадан хужа күренде. Зәнфирә хәлне аңлаткач, ул берсүзсез аны өйләренә алып керде һәм алар ашыгыч ярдәмгә шылтыраттылар.

Ирекне ашыгыч ярдәм машинасына керткәч, Зәнфирә үзе дә аның янына утырды. Больницада дежур врачка хәлне аңлатып бирүгә, аның йөзе үзгәрде.

—Сез нәрсә әйткәнегезне аңлап сөйлисезме?—диде ул, тавышын күтәреп.—Бәлки сез ул уколны йөрәккә бирмәгәнсездер? Читкәрәк кадагансыздыр?

—Юк,—диде Зәнфирә ышаныч белән.—Даруны керткәндә энәне йөрәк тибеше әз генә селкеткәне сизелде...

Врач хәйран калып баш чайкады.

Ирекнең ике беләгенә дә система куйдылар—ашыгыч рәвештә организмнан агуны чыгарырга кирәк иде. Йөрәк мускулларының эшчәнлеген яхшырту өчен уколлар ясалды. Ирек инде күзләрен ачып сөйләшер хәлгә килде. Ләкин Зәнфирә аңа бер сүз дә әйттермәде, тыныч кына ят, барысы да үтәчәк, диде.

Ул Ирекне дүрт көннән алып кайтты. Бу вакыйгадан соң Ирек әллә нишләп калды, сөйләшмәде, күзен йомган хәлдә ятты да ятты. Әлбәттә, Зәнфирә аның уйланып ятканын сизде, йөзенең караңгылыгыннан үз-үзен өзгәләвен дә чамалады. Ул аякка басканчы дип, Зәнфирә бер атнага ял алды. Ирекне җитәкләп, һавага алып чыкты, акрын гына Ык буеннан уратып алып кайтты, әмма Зәнфирәнең үзенең хәле әйбәт түгел иде. Ул инде күптән уң яклап эченең авыртуын сизеп йөрде, әмма бер көнне түзә алмаслык булып сулкылдый башлады. Ял алган килеш больницада күренеп йөрисе килмәде. Аннары аны бер нәрсә куркытты: әгәр бу сукыр эчәк-мазар булса, операция ясасалар, Ирек ныклап торып аягына баса алмас, баскан суреттә, рюмкага үрелүе бар, дип һаман сабыр итте. Беренче көнге түзә алмаслык сызлану икенче, өченче көннәрне бераз җибәргәндәй тоелды. Зәнфирә, хәле ничек кенә авыр булмасын, Ирек белән бергә түтәл ясады, аның да кулына җиңел, бәләкәй тырма тоттырды. Үзе бер кулы белән эчен учлап, икенчесе белән суган төртте, кишер белән чөгендер чәчте. Әмма төнлә кисәк кенә температурасы күтәрелде һәм бөтен эче ут булып яна башлады. Ярты төнгә кадәр Зәнфирә түзеп ятты, узар дип өметләнде. Әмма шуннан соң, түземе төкәнеп, ыңгырашырга тотынды. Моңа кадәр, эчем авыртып тора, диюдән башка сүз ишетмәгән Ирек, утны яндырып, аның янына килде. Зәнфирәнең чырае кәфен төсле иде. Тәннәре кулны пешерерлек кайнар, сулыш алуы әле генә чабыштан кайткан атның сулавын хәтерләтә.

—Нишләп баштук әйтмәдең?—диде Ирек, коты очып һәм киенә башлады.—Ашыгыч ярдәм чакырам.

—Кирәкми,—дип ыңгырашты Зәнфирә.

Ирек аңа җавап бирмәде, чыгып йөгерде.

Зәнфирә әле һаман да ныклап борчылмый, бу берәр кизү генәдер, узар, ашыгыч ярдәм чакыртырлык сәбәп юк, дип үзен юата иде.

Ирек кайтып аз гына узуга, ашыгыч ярдәм машинасы килеп тә житте. Ирек аны озата барды. Шул төнне үк Зәнфирәгә, сукыр эчәгесе шартлап, каны агуланган булырга тиеш, дигән диагноз куелды. Хирурглар, баш терапевт, операциядә катнашачак шәфкать туташлары, лаборатория хезмәткәрләре чакырылды. Анализларны тикшерү башланганда ук, Зәнфирә аңын җуйган иде инде.

Әллә нинди музыка яңгырый... Ул чеңгел-чеңгел ерактан ишетелә башлый, башка тавышларны ярып, һаман көчәя бара, килеп житә, колакларны авырттырырлык булып яңгырый да, шау-шу тавышларын ияртеп, тагын еракка йотыла, инде юкка чыкты, дигәндә тагын көчәя башлый, тагын килеп житә, гүя синең колак төбеңә кадәр диңгез дулкыны шаулап килә дә кире чигенә...

Операция дүрт сәгатьтән артык барды, сукыр эчәк шартлаган булган, үлек канга киткән. Әгәр тагын бераз сонарсалар, инде аны врачлар коткара да алмаган булырлар иде...

Зәнфирә икенче көнне көндезге сәгать унбердә генә аңына килде. Ул

реанимация бүлмәсендә ята, янында хирургия бүлегенең шәфкать туташы саклап утыра, беләгенә система куелган иде. Күзләрен ачу белән, ул система шешәсеннән пылт-пылт итеп чыккан һава шарчыкларын күрде, эченең ут булып януын тойды. Таныш хирургия сестрасын күргәч, операция ясаганнарын аңлады...

9

Өч көннән соң Зәнфирәне алты урынлы палатага күчерделәр. Бирегә чыккач, хәле бераз җиңеләйгәндәй булды. Хатыннар туктаусыз сайрашалар, үзара тормыш хәлләре турында сөйләшәләр. Бөтенесенең дә диярлек ирләре эчә, шуның аркасында күргәннәрен берсеннән-берсе уздыра-уздыра сөйлиләр, вакыт-вакыт көлешеп алалар, вакыт-вакыт елашалар, гомерләренең шулай узып баруына уфтаналар. Арада бер җырчы хатын бар, ул урман эчендәге унбиш өйле Кичү дигән авылдан. Биш бала тапкан, җиденче классны бетергәннән бирле фермада сыер сава, ире механизатор, көне-төне эчә, холыксыз, хатын-кызлар янында булып кайтканнан соң, балалары белән өйдән куып чыгара икән. Коңгырт чәчле, коңгырт күзле, ябык кына шушы хатындагы яшәү көченә Зәнфирә сокланып туймады. Гәүдәсе дә зур түгел югыйсә, фермада да эшли, йорт эшләрен дә үзе башкара, балаларын да тәрбияли, печәнен чаба, утынын әзерли һәм берниндн төшенкелеккә дә бирелми.

—Син мондый тормышның ни рәхәтен табасың соң?—дип сорыйлар хатыннар аңардан.

Ә Равия бу сорауга көлеп кенә җавап бирә:

—Әй, малайлар, дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк. Өч малай, ике кыз үстереп карагыз әле сез! Кайсыгызның бер бала, кайсыгызның икәү, аны бар дип торасыңмы, юк дип торасыңмы? Ә минекеләр, өчесе берьюлы елап җибәрсәләр, өеңдә берниндн дә оркестр кирәкми, дүртенчесенә кайчакта үзем кушылам, аннан туктыйбыз. Бөтенесенең дә күз яшьләрен сөртәм дә җырлап җибәрәм. Бер кайгыларым да калмый. Их, сез җырның нәрсә икәнен анласагыз икән!

Ул шулай ди дә, әле "Карурман"ны, әле "Тәфтиләү"не, әле башкасын саф, моңлы тавыш белән сузып җибәрә. Ул озын җырларны җырлаганда, хатыннар барысы да елыйлар, Зәнфирә дә елый. Бүген дә шулай Равиянең җырлавын тыңлап утырганда, Зәнфирәгә кемдер килгәнен хәбәр иттеләр. Чәчләрен рәтләп, чүәкләрен киеп, акрын гына коридорның аргы башына барды, аның каршысында сумка тотып Заһит басып тора иде. Зәнфирәнең йөрәге әллә нишләп китте. Равияне тыңлаганда, болай да тулышып утырган күңеле, түгеләм-түгеләм, дип дулкынланырга керешгте.

—Минем килгәнгә ачуланмыйсыңмы?—диде Заһит исәнләшкәннән соң.

—Рәхмәт,—диде Зәнфирә чын күңеленнән.

Ирек дүрт көн рәттән килде дә туктады. Зәнфирә, ул һаман аякка баса алмагандыр, салдым белән буталадыр, дип хафаланды. Әгәр шулай булмаса, килми калыр идемени? Ә менә Заһит авылдан ук килеп җиткән.

—Хәлең ничек? Тереләсеңме?

—Рәтләнәм инде,—диде Зәнфирә, елмаерга тырышып, ләкин күкрәгендәге кайнарлык аңа елмаерга ирек бирмәде.

Заһит бераз калтыранган куллары белән аның чәчен сыпырып куйды.

—Терел... берүк терел, яме, җаным.

Зәнфирә "ярар" дип җавап бирә алмады, аның күңеле тулган иде. Моны күреп, Заһит сумкасына иелде һәм аннан бер пакет эре антоновка алмалары алды, берсен Зәнфирәгә сузды.

—Икәү көз көне бияләй киеп җыйган идек бит... Әйбәт сакланганнар...

Зәнфирә аның кулындагы алманы алып, халат кесәсенә салды да пакетка үрелде.

—Юк, юк, әле сиңа ярамый,—диде Заһит.—Үзем алып барып куярмын.

Аның бу сүзләре Зәнфирәнең котын алды. Хатыннар, әгәр дә аны

күрсәләр, сораштыра башлаячаклар, "бу кемең?" диячәкләр. Дөресен әйтсә, анын бөтен дөньясын актарачаклар һәм, әлбәттә, туп-туры әйтмәсәләр дә, Зәнфирәне барысы да гаепләячәкләр. Анын хәле жир йөзендәге беркемнекенә дә охшамаган, беркемгә дә аңлата торган да түгел. Йөрәгендәге утны ул бары үзе генә белә, үзе генә анын көне-төне дөрләвен тоя һәм шуна риза иде. Ул утнын бер ялкыны анын теленнән гадәти сүзләр булып чыкты:

—Улыбыз ни хәлдә микән?

—Зирәк әйбәт кенә,—диде Заһит.—Әле өченче көн генә сөйләштем. Аны эшкә министрлар Советына күчермәкче булалар икән.—Ул бераз туктап, уйланып торды, баскан урынында таптанып алды.—Сине сораган иде, эштә, дидем...

Зәнфирәгә коточкыч кыен иде. Бу кыенлыктан котылу өчен ул:

—Ярый, мин керим инде, хәлем беткән кебек,—диде.

—Әйдә, әйберләрне кертеп калдырам,—дип Заһит ана иярде.

—Юк, юк!—диде Зәнфирә туктап.—Анда чит кешеләргә керергә ярамый.

Коридордан бу башка таба килүче күрше палатадагы кызны ул кул изәп чакырды:

—Үскәнем, минем әйберләрне генә кертеп куй әле.

Кыз иелеп сумканы күтәрүгә, Зәнфирә анын кулына кесәсеннән алып теге алманы тоттырды.

—Бусы үзенә булыр. Ярый, хуш,—диде ул Заһитка.

Ләкин Заһит китәргә ашыкмады. Ул кызарып, башын аска игән хәлдә акрын гына:

—Син дәфтәрләрне алгансың икән,—диде.

—Алган идем шул...

—Аларның сиңа кирәге юктыр ич инде?

—Сиңа кирәкме?—дип сорады ул һәм Заһит җавап бирмәгәч:—үзем чыккач, кире кайтарырмын,—диде, аннары палатасына керергә борылгач:—Берүк кабат килеп йөрмә...—дип өстәде.

Хатыннар алмаларның бу вакытка кадәр саклануына ис-акыллары китеп, хәйран калдылар, шытыр-шытыр алма кимерделәр. Зәнфирә "үзебезнеке" дигәч, җыю-саклау тәртипләре белән кызыксындылар, ләкин сумканы күтәреп кергән кыз аларга ир-ат килүен әйтеп чыгып киткән иде, күрәсен. Барысы бертавыштан күчтәнәчләр китерүченең кемлеге белән кызыксындылар.

—Ул минем абыем...—дип алдашырга мәҗбүр булды Зәнфирә.

Ирек күренмәгәч, Зәнфирә, тырышлыкларым гел бушка булды микәнни, дип өзгәләнде. Анын янына күчеп килгәч, Ирекне аякка бастыру өчен, керфек какмыйча, ничәмә-ничә төннәр саклап чыкты. Ничә мәртәбәләр ул көчкә пышылдап: "Бир әле кулынны, торгыз мине..."—дип хәлсез кулын сузды. Иреккә тагын җан керде, кабат үлем хәленә килде. Зәнфирә арыды, ябыкты, ашый һәм йоклый алмас булды. Нидер эшләргә кирәк иде. Ләкин анын кулыннан килерлек барлык чаралар бетте, ул үзе дә хәлсезләнеп сулды. Ахырда, күнеленнән елап, "китәргә!" дигән катгый карарга килде. Бу хакта әйткәч, Ирек:

—Зәнфирә, син мине оныт инде,—диде, күзләрен еш-еш йомып.—Агачка төшкән корт кебек, мин синен бөтен көченне суырып бетердем, мин кабәхәт... Шушы көнгә кадәр яшәтә алганың өчен генә дә рәхмәтем чиксез...

Зәнфирә аны кысып кочагына алды, Ирекнең йөрәк тавышын тынлап, бик озак тын да алмый торды...

Икенче көнне иртүк ак халаттан Хәлимә килеп керде. Ул Зәнфирәне кочаклап алды, битләреннән үпте, икесе дә елашып алдылар.

—Менә мин сөйләгән Хәлимә апа шушы була инде,—диде Зәнфирә хатыннарга.

Коридорга чыгып, алар бик озак сөйләштеләр. Китәргә әзерләнгәч, Зәнфирә ана:

—Әйтергә дә кыен инде, Ирекне үгетләп чыга алмассың микән, Хәлимә

апа?—диде.—Бүген дә күренми. Сизәм: эчүеннән котыла алмый ул.

—Ярый, тырышырмын,—диде Хәлимә.—Минем дарулар да аласым бар иде. Өлгермәсәм, ачуланмассың инде...

Хәлимәнең аптекага кирәсе юк иде. Аның өчен Ирек янына бару инде төзәлеп беткән яраны кабат кузгатасын ул яхшы аңлады. Җиһандагы нинди көч Ирекне аның күнеленә китереп индергәнен аңламаса да, бу хәлдән ул әле һаман котылып бетә алмый иде. Ирек янына бару кыен иде аңа. Барган сурәттә дә юньле-башлы бер генә сүз дә әйтә алмас иде. Моны бит Зәнфирәгә берничек тә аңлатып булмый. Ни гаҗәп, үзеннең бөтен тормышыңны туганнан башлап көнгәчә сөйләп биреп була, анкеталарга язып була, әмма бу чын дөреслеккә һәрвакытта да туры килми. Туу, яшәү һәм үлем мәңгелек сер булган кебек, һәрбер кешенең яшәеше дә, гомер юлы да үзенә генә хас бормалар белән каймаланган, аяк асты чәчәкләр һәм шайтан таяклары белән түшәлгән. Бу гомернең күк йөзендә кургаштай авыр, давыллы болытлар да, бәхет юраучы аккош мамыгыдай җинел ак болытлары да бар, бер салкын итеп карауч, бер нурлар белән җылытучы ай һәм кояшы да бар. Хәлимәнең өч кешегә булган мәхәббәте дә әнә шулай аерылгысыз биргә үрелгән, аның күнеленә тамыр җибәреп, чәчәкләр аткан, җимешләрен биргән һәм инде сагыш җилләре ул катлаулы тойгыларны киптереп, шиңдереп бара, гомернең азагына якынаюын искәртә иде. Хәлимә үзен мәҗбүр итеп, Ирек торган йортка кадәр төште, ишеге бикле булса гына ярар иде, Зәнфирә алдында күңелем чиста калыр иде, дип теләп төшсә дә, ишектә йозак күренмәде. Ул авыр сулады да ашыга-кабалана аларның капкасы турыннан борылып китеп барды.

***

Ирек, әз-мәз капкалап котылырмын, яңадан кабатламам, дип уйлаган иде, ләкин ялгышты. Теге вакытта аны кабер якасына китергән кәмешкәне врачлар чөгендер жомыннан ясалган булырга тиеш, диделәр. Бүген кич аның әчәренә бетте, беркая да барырлык хәле юк, акчасы да юк иде. Йөрәге туктыйм, туктыйм, дип типкән хәлдә ул авыр сулап ята бирде. Шулчак Сөембикә килеп керде. Ул өйдәге тәртипсезлеккә аптырап карап торды, барысын да аңлады һәм, күн курткасын салып куеп, өйне җыештырырга кереште.

—Сөембикә, үләм бит,—диде Ирек, күкрәген кулы белән тотып.—Зинһар берәр нәрсә табып китер.

—Кеше бер генә мәртәбә үлә,—диде Сөембикә.—Син инде мин белгәннән бирле гел үлеп торасың.

—Алып кил, бусы соңгысы. Тереләм дә туктыйм.

—Алып килмим!—диде Сөембикә ачулы тавыш белән.—Сиңа этлек эшләргә теләмим. Ничек син аңламыйсың? Ул бит сине һаман эчкәрәк сөйриячәк.

Ирек күзләрен йомып тынып калды. Ул, Сөембикә өйне җыештырып бетереп, курткасын алганда гына, керфекләрен күтәрде.

—Миһербансыз син...—диде Ирек көч-хәл белән.—Ярга йөзеп чыгарлык кына кирәк. Хәлем юк, йөзә алмыйм...

—Өметеңне өз, шул чакта йөзәрсең,—диде Сөембикә.

Ул чыгып киткәч, Ирек кемнең дә булса килеп керүен, аны аңлавын теләде. Менә бүген йөрәге туктамаса, әгәр хәле әйбәтләнсә, иртәгә иртүк Зәнфирә янына барырмын, дип хыялланды, бармавына бәгыре телгәләнде. "Түзәргә, ничек булса да түзәргә!"—дип боерды ул үз-үзенә. Көне буе тәнеңнән тир акты, өзлексез салкын су эчте, гәүдәсе сызлады, буыннары тотмады.

Төштән соң кулына зур гына юл сумкасы тоткан бер ир кеше килеп керде.

—Әллә танымыйсың?—диде ул, Ирекне кочаклап, күкрәгенә кыскач.—Әхмәзетдин бу!

Ирек шатлыгыннан кычкырып җибәрде: анын белән беренче класстан бер партада утырган Әхмәзетдин иде бу! Ул сигезенчене бетерү белән авылдан чыгып китте, шахтада эшләп, Кемерово якларында төпләнеп калды. Анын күчтәнәчләре дә, акчасы да күп иде. Әхмәзетдин елады да елады, үзенен маржага өйләнүен, өч баласынын да татарча белмәвен, шуна күрә авылга кайтырга оялуын, Баллы Төбәкне, Ык буйларын өзелеп сагынуын, көн саен төшләрендә күрүен, үлгәнче хушлашып булса да китим, дип кайтуын сөйләде дә сөйләде, авыл кешеләренен үзен кичерүләрен үтенде, бәхиллек сорады... Ул Ирекне кочаклады да елый-елый гел бер җырны җырлады:

*Ык суында кер чайкадым,*
*Беләкләрем бик талды.*
*Гомер үтте, яшьлек сулды,*
*Сагнып сөйләргә калды...*

Алар кич җиткәч кенә кочаклашып, елашып аерылыштылар, Әхмәзетдин төнге Бөгелмә поездына дип чыгып китте...

Ирек анын белән күпме эчелгәнен дә хәтерләмәде. Караңгы төшкәч, капка турына машина килеп туктаганын да, ишек ачылып ябылганны да, мәче адымнары белән Зәһитнын керүен дә сизәрлек хәлдә түгел иде ул. Зәһиткa теге дәфтәрләр кирәк иде. Ул иң элек шкафны актарырга кереште, аннары кире уйлады. Алар чоланда булырга тиешләр, дигән уй белән өйдән чыкты, андагы барлык нәрсәне актарып бетерде, дәфтәрләр юк иде. Ул кабат өйгә керде. Ирек яткан караватт астын, аннары түрдәге караватны, ястык-мендәрләрен, матрацларын идәнгә ата-ата тикшерде. Морҗа өстендә юк микән, дип урындык куеп менгәч, урындыгы чайкалып китеп, идәнгә дөбердәп килеп төште. Тавышка Ирек кинәт сикереп торып утырды һәм карлыккан тавыш белән:

—Кем бар анда?!—дип кычкырды.

Җавап ишетелмәде, анын күкрәгенә көчле куллар китереп басып, чалкан аудардылар да, йөзен, борынын мендәр белән томаладылар. Ирекнен болай да күкрәгеннән чыгарлык булып типкән йөрәге чатнап китте, ул кулы белән тырмашты, тыпырчынмакчы булды, бер генә мизгелдә үзен буган кешенен күлмәк якасына бармакларынын керүен сизде һәм ул аны аска тартып, умырып төшерде. Шуннан ары ул артык тыпырчына алмады, буылды һәм каядыр очты...

Атылып-бәрелеп Зәһит өйдән чыкты, тышкы ишекне койма буенда яткан юан имән белән терәтеп куйды. Машинасын кабызгач, утларын кабызмыйча гына тыкрыктан олы юлга чыкты һәм Баллы Төбәккә юнәлде. Баш миен коточкыч бер уй утлы күмер кебек яндырды: "үтермәдем микән?" Бу җан өшеткеч уй аны юл буе борчыды. Авылга кайтып җиткәч, ул кабат борылды. Болынкырда анын кайчандыр институтта бергә укыган дусты—буйдак Сабир бар иде. Ул туп-туры анын өенә килеп туктады, өч сүз белән бәлагә тарыганын аңлатты, нәрсә икәнен әйтмәде, ләкин кичке тугыздан (ул шул вакыттан, машинасын яр буена куеп, Ирекнен өен бинокль белән күзәтеп торган иде) төнге унбергә кадәр мин синен янында булдым, диде. Сөйләшеп утырдык, беркая да чыкмадык, сүз бер булсын, диде. Сабир ризалашты. Шушы алибины әзерләгәннән соң гына Зәһит өенә юнәлде...

Умырылган күлмәген салып түрде дә, малларга ишек алдында аш пешерә торган казаннын астына ягып җибәрде һәм күлмәкне кисәүагач белән болгата-болгата яндырып бетерде. Бу анын үз гомерендә беренче һәм соңгы мәртәбә үз куллары белән үз әйберсен исраф итүе иде. Һәм ул аны үз гомерендә беренче мәртәбә әлеге дәфтәренә язмыйча калдырды...

*Ахыры киләсе санда.*

Şiğriət
Шигърият



## Җәүдәт Сөләйман

# НӘФЕС КҮГЕ

***

**Атларга йөгән кидермим,**
**Йөгәнсез атлар оча,**
**Бир ирек! Атың-канатың**
**Күкләр гизеп кайтачак.**

**Атларның тып-тып басуы**
**Тимер дагадан микән?**
**Тып-тып итеп, саный-саный,**
**Гомерләр ага микән?**

**Атлар кайта су буйлатып,**
**Җил җилкенә көнләшеп:**
**Атлар йөри гасырларда**
**Ак бәхетләр өләшеп.**

**Таң алдыннан тояк эзе**
**Чолгана көмеш чыкка,**
**Тояк тавышы күңелне**
**Кайтара балачакка.**

**Атлар уйный болыннарда,**
**Гомердән гомерләргә,**
**Чирәмгә түгел, эзләре**
**Уела бәгырьләргә.**

**Атларга карап кычкырам:**
**—Атларым, әй-һәй-һәй-һәй!**
**…Тояктан чыккан аваз да**
**Күңелгә яткан сүздәй.**

***

**Җирдә чакта адәм вазифасы:**
**Әрле-бирле килеп,**
**Җирне күккә тегү…**

**Тегелгән җир күктән аерылмас…**

**Сирәкләргә, әмма, насыйп кәсеп:**
**Җан җепләрен тетеп, әрләп, үреп,**
**Җирне күккә**
**Бишек итеп элү…**

**Җир-бишектә үскән җан югалмас…**

---

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) *– шагыйрь, "Күләгәләр", "Кызык" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Җан күгендә очар мизгелләрдә
Канатларны салып
Җирдә баскыч ясау—
Җирдән күккә күтәрерме
Бер-бер кемне?

Баскыч ясау
Изге гамәл үзе,
Әмма баскыч канат түгел бит ул.
Баскычларны күпме бастырсаң да,
Якынайтмый
Күкнең үзен бит ул.

Акыл әйтә: үзең бул биектә,
Күктән түгел, күккә сал эзең.
Син талпынган чалым өскә илтсә,
Һич булмассың анда берүзең.

Баскыч түгел, ачкыч кирәк җанга,
Ачылган җан кирәк җирдә дә,
Җан ачылса, күңел канатлана,
Бәгырь тынычлана—җилдә дә...

Тик... барыбер баскыч ясый Кеше,
Безне Күккә якынайтам диеп,
Тынычланмый, кайчак сыкранса да,
Баскычлары яшеннәргә тиеп.

Баскыч ясый Кеше, үҗәтләнеп,
Җиргә төшеп, канатларын салып,
Баскыч көтеп карап торучылар
Җылыналар...
Каурыйларын ягып...

***

Коедан су алмый торсаң—саега бара кое,
Мүкләнә бара бурасы, саргая кое суы.

Хәтта күкләр түбәнәя—очмый торсаң беравык,
Күк катламы иңгә төшә, тормасаң канат кагып.

Тоныклана калса дөнья, җуелса бизәкләре,
Нечкә кыллары өзелсә, таш була үзәкләрең.

Яшәешнең тәме бетә, хис яшькә әйләнмәсә,
Күңелләрнең тибрәнүе бәгырьгә бәйләнмәсә.

Саегая акыл күле, йөзеп-чумып тормасаң,
Читтән торып балык тотып яшәрмен дип уйласаң.

Нәфес күге—ябыштыргыч, орынма димәдемме?
Тишсәң тишәрсең бу күкне, очлап фикерләреңне.

Зиһен, кайда канатларың, таркалдымы җилләрдә?
Җиде кат күктә очкаһың калды сагынып сөйләргә.

**Күк катларын гизә идең, буйга да аркылыга,**
**Әллә калдымы үзеңә утырып ясин чыгарга.**

**Диңгез булып тибрәнүләр—бар иде түгелме соң,**
**Уй-фикерләр уянгандай,—**
**Шәт әле түгелдер соң?**

**Ә бүгенгә диңгез димим, күл дә түгел ул хәтта—**
**Сазлык суы тибрәнүен, халәтен хәтерләтә...**

***

**...Нечкә кыллар**
**тирбәткәндә тәнне,**
**инде җанга рәхәт дигәндә,**
**"нәрсәнедер онытмадым микән?"—**
**Тырнап үтте фикер чигәдән.**

**Җиде күктән**
**җиде төсләр эзләп,**
**Җирдән Күккә юллар сузганда,**
**Җирдән китеп Күккә җитәлмыйча**
**азапланмыйм микән ызанда?..**

**Күктә ризык—Җаның теләгәне,**
**Җирдә ризык—Нәфес ризыгы.**
**Күңел генә бәргәләнә, сайлый,—**
**ахры, шулдыр Күңел азыгы...**

**...Күктә көткәннәрдән—**
**күптән көткәннәргә—**
**кайтумы ул,**
**әллә төшүме?**
**Кешеме мин**
**Җирдә талпынганга,**
**Күккә атылганга—**
**Кешеме?**

**Нәфрәтләнеп тулу**
**куык булып,**
**ут-ялкынга охшап ярсулар—**
**күк катына сыймас кабырчыкмы,**
**әллә шулмы җиргә кайтулар?**

**Күкләр биек, иге-чиге булмас,**
**күперләре берьяк юллылар,**
**менәм дисәң—менү өчен юллар,**
**төшәм дисәң—меңләп юлы бар.**

**...Әмәлләрен шуның**
**эзләп уза гомер,**
**тау юлында—гомер-кулазак*...**
**Тәннән тәнгә күчеп йөргән кебек,**
**менеп-төшеп йөрү—һай газап...**

---

*Кулазак — бүрәнә тарттыру өчен җайланган ике тәгәрмәчле арба

***

Күңел тишкәләнсә—ямау салам,
Ямаулыкка—бишек көйләре,
Нәфес ямый күңел тишекләрен,
Нәфес-җилем тота җөйләрен.

Үзәк өзелгәндә—нәфес кылы тота,
Ялганганчы үзәк кыллары,
Сыңар канат булып күңел талпынганда,
Пар канатка нәфес—сыңары.

Нәфес бетсә—теңкә корыйдыр ул,
Тияләрме, юкмы—барыбер.
Теңкәләргә тигәч ярсый идем,
Хәзер аңлыйм—
...әле бар гомер...

***

Минем көймә янә дулкыннарда,
Нәфес җиле этә көймәне,
Инде җилкән кирәк булмас дигәч,
Күңел-дәрья әллә нишләде.

Әллә кайдан дулкын килеп бәрде,
Әллә кайдан чыкты җилләре,
Инеш идең, кыйблаң—диңгез диден,
Инде кайда, күңел, мөнбәрең?

Син тынгысыз, күңел, ә җан сыкрый,
Йөрәккә дә тия авазы,
Яхшыгамы, юкмы диеп сорый...
Янә сипләү нәфес арбасын.

Яхшыгамы, юкмы—җан чайпала,
Күзе—ачык, күрә ал-артны,
Әйдә күңел, нәфес җене тигәч,
Киереп бак янә канатың.

Тынычлыкны ташлап дулкыннарга,
Ияргәнсең икән нәфескә,
Нәфес булсын—күңелеңдә көймә,
Көймә була күрмә—нәфестә...

*2003*



## Кыям Миңлебаев

# АКЫЛЛЫ АТЫН МАКТАР...

РОМАННАН ӨЗЕК

### Дәрвиш васыяте

*Иң татлы тел–туган тел,*
*анам сөйләп торган тел.*

Татар халык мәкале

*Миңа калса, язучы булган*
*кешенең төп сәяси вазифасы–*
*яхшы язу.*

Г.Гарсиа Маркес

*Үләннән соң мактау вә сагыну*
*–терек булу, әмма терек вакытта*
*макталу–үлү вә оныту.*

Ризаэддин Фәхреддин

Күңеленә авыр алмаса иде укучым, ниләр уйлаганымны язарга, йөрәк серләремне чишәргә ниятләдем. Мишәр холкына буйсынып, берсәк тупасрак та катырак әйтеп ташласам, яки, сүзгә мавыгып, озынгарак суза калсам, ачуланмасын иде укучым, кинә сакламасын иде, кичерә генә күрсен иде.

Укучыга мөрәҗәгать итүем бүген уйлап чыгарган нәрсә түгел. Дөньяда бер укымышлы, талымлы вә таләпчән татар укучысының күңелкәенә җим булырдай, хуш килердәй әсәрләрне генә тәкъдим итү ниятеннән, кырык-илле ел эчендә утызлап китапны үзебезнең ана телебезгә күчереп-язып чыктым. Ашык-пошык эшләгәнем булмады, һич юк. Дөрес анысы, авторларыма да хыянәт итмәскә тырыштым, ягъни эчтәлекне сөйләп чыгу белән мавыкмыйча, һәркайсының стиль үзенчәлекләрен, теленең байлыгын, әсәрнең камиллеген түкми-чәчми күчереп утырту ягын карадым. Иҗат эше әйтеп бетергесез катлаулы бер нәрсә инде ул. Аңа бер җигелсәң, тиз генә котылырмын, димә. Үз-үзеңә гомер буе ышанып бетмисең, канәгатьләнү хисен кичермисең. Иҗат – чын мәгънәсендә газап инде ул. Затлы газап, татлы газап, зәвыклы

---

Кыям МИҢЛЕБАЕВ (1929) –*язучы, тәрҗемәче; "Бакый", "Үткәнгә сәяхәт", "Чынлы чишмәләре" исемле китаплар авторы. Рус теленнән татарчага утызга якын тәрҗемә китабы бар. Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

газап, ләззәтле газап. Ана теленең тирән сандык төпләреннән үзеңә кирәкле сүзләрне актарып чыгарасың, дистәләрчә синонимнардан нәкъ шул урынга утырырдаен сайлап аласың. Анда да әле күңелең һаман тыныч түгел, авторыңның рухи дөньясын тулаем гәүдәләндерә алуыңа, тәмам җиренә җиткерүеңә һич кенә дә ышанып бетмисең.

Камиллекнең чиге юк бит аның. Әмма шулай да, әнә шул омтылышыңда да автордан оялу, тәнкыйтьтән курку дигән нәрсәнең эзе дә юк. Алары белән, мөгаен, уртак тел табар да идең. Тик менә алардан бөегрәк, алардан таләпчәнрәк гади вә гали зат бар бит әле, анысы – у-ку-чы! Әйе-әйе, иң олы хөрмәткә ия – ул да булса укучы. Хезмәтеңнән үзең бик үк канәгать булып бетмәгәндә, укучы моңа ни әйтер икән инде, дигән сорау туа. Бер дә генә сынатасың килми инде, әй! Соңгы романым да укучының күңеленә хуш килсә, аннары инде үлсәм дә үкенмәс идем...

## Миңлебай Сәләхе

*Мин янмасам,*
*Син янмасаң,*
*Ул янмаса—*
*Кем җылытыр*
*Бу дөньяны?!*

Назыйм Хикмәт

Дәрья өстендә чатнама суык. Гыйнварның раштуа суыклары бу. Узган елларны кар мул яткан урыннарда җылырак була торган иде. Быел һич аңламассың!

Авыл араларындагы ачык кыр юлында җил өермә кубарып, чанага кар тутыра, тун якасыннан кар тузаны муенга чаклы үтеп керү җаен таба да тәнеңне кымырҗытып ала, кай арада эреп өлгерә дә чиркандырып аркаң буйлап ага, киемеңне суыта…

Гомерендә беренче тапкыр чанага толыпсыз утырып кайта Сәләхетдин. Кара дуплы туны суык үткәрми үткәрүен, әмма шулай да, юл йөргәндә ике толыбының берсен (якын-тирәгә барганда җиңел кызгылтын, ерак сәфәр чыкканда саллы зур карасын) кияр иде, һич онытып калдырмас иде. Башында колакчыннары гадәтенчә артка кайтарып куелган саргылт күн бүрек, аягында кара киез итек, өстендә сырган җылы чалбар, чак кына өшәнә башласа да җылысын җуймаган кыска тун булса да, үзен шәрә кебегрәк тоя Сәләхетдин. Әле ярый, өр-яңа саллы толыбын төпчек улына васыять итеп калдырырга акылы җитте: шундый затлы киемгә кызыгучылар табылыр иде, һәрхәлдә үзенә тәтемәс иде...

Гомерендә беренче мәртәбә дилбегә тотмыйча гына атка утырып баруы Сәләхетдиннең. Ничаклы ат узды аның кулыннан, күпме холык—тыңлаучаны һәм сабыры да булды, үшәне һәм чыгымчысы да булмады түгел, булды,—тик инде һәркайсы дилбегәне кем тотканын шундук шәйли торган иде. Аннары инде кайсылары, дилбегәне бер кагып, чөңгереп җибәрүенә, озын сыйракларын еш-еш алдыртып, биегәндәй тигез юыртып бара, кайсылары йөнтәс калын аякларын авыр гына кузгатып, юыртуны авырсынып, тиз арада батыраеп чабуга күчә дә хәле беткәнче әнә шулай җилдереп, тәмам хәлдән тайгач, йөнтәс авыр аякларын көчкә сөйрәп бара башлый. Малкаенның хәленә кермичә, дуамалланып, камчылавын дәвам иттергән хуҗа—атсыз кала: бичара, телсез җан иясе, аңа ярарга тырышып, янә бер, инде соңгы тапкыр талпына да, манма тиргә батып, йөрәгенә ут кабып, дәрмансыз егыла...

Хәзер менә Сәләхетдин дә нәкъ шундый бичара малкай хөкемендә: ярыйсы ук өшәнгән чананың үрәчәсенә таянган хәлдә, ян-яклары ашалган, таушалган чана табаннарының аяусыз суыкта берөзлексез шыгырдавын үзенчә аңлап, аны кайчан гына әле үзе яратып җырлаган борынгы озын көйгә юрап бара...

Элекләре атын юыртып (син кумасаң да, авыл моржаларыннан югары күтәрелгән төтен күренү белән, ат үзлегеннән юырта башлый!) урамга керүенә, җәмәгате Ләйлиҗамал капканы шар ачып куяр, аш-суын, чәен хәстәрләгән булыр. Атын тугарып, җылы аранга кертеп, өстенә берәр чикмән-мазар ябып, алдына азык салып, муенын сыйпап, ялын аралап, сыртына йомшак кына суккалап, болдырга якынлашуына, җылы

су салган комганын тотып сөекле карчыгы күтәр иде...

Төнлә кайткан чакларында, чәй эчәргә дип, тетелеп йоклап яткан төпчеген уятмыйча калмас иде. Нинди генә җитди булып күренергә тырышмасын, бигрәкләр сагынып кайта иде шул тәтелдек малаен...

Шәйморза чуашының үзе шикелле үк муртайган чанасында Казанга кайта Сәләхетдин. Хәер, бу юлы үз теләге белән кайтмый, ул инде үз иркендәге кеше түгел. Аны тоткын сыйфатында Казан төрмәсенә китерәләр. Ун елга хөкем ителгән җинаятьче булып "кайта" Сәләхетдин үзе яшәгән шәһәргә... Җәмгыять өчен хәвефле затларны калага кеше күзенә күрсәтмичәрәк, төн караңгысында алып керү хупланадыр инде, шулай эшләү кулай саналадыр. Сакчыларның ашыкмавын башкача аңлатыр әмәл юк. Иске Шәйморзадан өч көн элек әче таңда юлга чыккан булсалар да, Иделгә бүген эңгер-меңгердә генә килеп җиттеләр. Бу юл таныш иде Сәләхетдингә, яхшы ук таныш: ике-өч атна элек кенә шушы юлдан авылына кайткан иде Сәләхетдин. Ул чагында аның өстендә иркен кара толып иде. Толыбының биек якасын күтәреп җибәрәсең дә—һичбер төрле җил-буран да үтеп керә алмый синең битеңә-башыңа. Ул чагында юл буе кар явып кайтты. Эре кар бөртекләре, гүя һәммәсе бер-беренә тотынышып, әйлән-бәйлән уйныйлар, күкләрнең бөтен йөзкәйләрен тоташы белән бөтереп алганнар да, төшик микән, юк микән дигәндәй, аптырашып, әйләнеп тә тулганып йөриләр, һәрхәлдә, төшәргә бик ашыкмыйлар, бере өстенә бере юлыгып, йомшак кына бәрелүдән бер ишесе югарыга, бер ишесе түбәнгә, күпчелеге исә ян-якларга таралыша да юллана иде. Сабыр гына, үз дәрәҗәләрен үзләре белеп кенә...

Ул чагында Сәләхетдиннең кулында, әлбәттә, дилбегә иде. Ул да үз кадерен үзе белеп кенә, саллы гәүдәсен туры тотып тезләнгән көе кайтты, йомшак печәнгә күмелгән кара киез итекләренә утырмады, кысыграк күзләрен юлдан аермады. Хәер, ничә генә карасаң да, фани дөньяны бөтереп алган кар бөртекләре арасыннан юлны һич шәйләрмен димә, бар ышаныч атта инде—чана юлын шул шәйли, шул малкай...

Нинди изге ниятләр белән, нинди өметләр белән кайткан иде бит Сәләхетдин үзенең туган авылына!..

Төн карасыннан да кара бинага аларны мондагы сакчылар алып керде. Биек тимер капканың эчке ягында тулаем алар хуҗа иде. Өч бөртек тоткынны әлеге сакчылар баз кебек шыксыз бер сасы баракка алып керделәр дә буш сәндерәләрне күрсәттеләр. Сәләхетдин аскысына ятарга ниятләде. Кармашып кына сәндерәдә шикләнерлек әйбер-мазар юклыгын ачыклагач, урта бер җиренә килеп утырды. Ышкыланмаган тупас такталар, үз язмышларыннан зарлангандай, ыңгырашып куйдылар. Авыр гәүдәле мәхбүс яткач, тагын да ныграк зарланышып алдылар.

Сәләхетдин дә ыңгырашып куйды. Шактый арылган икән шул. Гомер буе эш, эш дип яшәгән, кулыннан йә балта-чүкеч, йә урак-чалгы, йә көрәк-сәнәк ише нәрсә төшмәгән ир-ат кинәт кенә эшсезлеккә дучар ителсен әле! Яту белән, бөтен сөяк-саяклары сызларга тотынды, известь базына егылып төшкәннән соң кичергән әрнүләре ике-өч ел узгач үзен ныграк сиздерә башлады. Әмма пәһлеван гәүдәле кешегә әлеге әрнүләр әллә ни тәэсир итмәде, ул аларга бирешмәде, фәкать эченнән генә: "Их, өйдә булсам! Карчык духым гына билгә банкы салыр иде дә—вәссәлам!.."—дип уйларга өлгермәде, банкы салгандагы шикелле үк, хәлләре җиңеләеп киткәндәй тоелды. Тик менә иртәрәк сөенгән икән әле. Гомумән, сөенерлеге бөтенләй дә юк икән ләбаса! Бил тирәләренең, сөяк-саякларының әрнүләре басылырга өлгермәде, бөтен барлыгын шыксыз җан газабы тинтерәтә башлады. Монысыннан банкы салып кына арынырмын димә инде син. Җәмгатен, бала-чагасын уйлаган саен, үтереп әрнергә ябыша. Хикмәт шунда ки, өйдәгеләрне бит син һич кенә дә исеңнән чыгара алмыйсың. Нишлиләр икән инде менә хәзер? Ишеткәннәрдер инде миңа ун ел биргәннәрен. Ишетмичә ни: хәбәр синең үзеңнән тизрәк йөри ләбаса! Көне-сәгате белән калавылга килеп җиткәндер...

Оланнар бу фаҗигане бераз үсә төшкәч кенә аңлап җиркерерләрдер, ә менә карчык... Ул инде мин киткәннән бирле ут йотадыр. Әйткән иде бит, әйткән иде: "Ил өстенә зур афәт килде, ярты авылның ир-атын сугышка озатканнар. Шунда син кайтып төшәсең, түшең киереп... Җәен уфалла тартып җәфаланган, кышын бәләкәй чанага җигелеп интеккән авыл халкын син узып китәсең шәп атың белән... Йөрмә син анда, акылың булса!.."—дигән иде.

Башы җитмәде шул Сәләхетдиннең авылдашлары булып уйлап карарга, акылы җитмәде. Элекләре кермәде безнең белән колхозга... Кулак булып калды, аннары

индукка әйләнде, аерым хуҗалыкка чыкты... Йортын кырмыска оясыдай туздырып ташлаганны ул оныткандыр дисезме? Һич юк! Онытылмый андый җәбер-золым, мәсхәрәләү. Ун ел элек булган мистный влачка гына түгел аның ачуы да җәбере, бөтен авылга төшә аның каргышы. Әнә, күрәсезме, нинди шәп атлар җигеп алган, бер дигән толыплар киеп алган, кар тузаны тузгытып узып китте безнең яныбыздан... Барчабызны адәм мәсхәрәсе итәргә кайткан лабаса ул, бөтен авылыбызның көлен күккә очырырга кайткан! Колхозчыларның баеп китүеннән көнләшеп үләдер әле... Хан булыргадыр әле исәбе, колхозларны бетереп...

Күрәзәче диярсең, нәкъ шулай килде дә чыкты. Гаепкә алма инде, карчык, сүзенә колак салмадым ла! Төптән уйларга үземнең башым җитмәде шул, башым җитмәде... Элегрәк тә, җилгә каршы бармыйк, керик без дә шул колхозларына, керик, дигәнеңне дә, балалар хакына тыңла, зинһар, сүземне, дигәнеңне дә "ишетмәдем", ике бите белән җир себереп, шундый зур йортны алып барган карчыгымның зар елаганын да, канлы яшьләр түккәнен дә "күрмәдем"... Себер сөреләсе бәндә идем бит, синең аркада гына котылып калдым—качып өлгердем. Бу юлы да, авылга кайтып, барча халыкның акаеп караганын сыртым белән тоеп тордым. Ахыр чиктә, ичмасам, бәлагә тарыгач, Минтук каенага үзе Казанга килеп, үзе сатып алып киткән чүпрәк-чапракны өстемә алмаска иде лә миңа! Әйтте бит адвокат марҗа, төшерәсем килми ак эт бәласен кара эткә, алмагыз аның товарларын үз өстегезгә, диде, калавыл халкыннан җыеп, ярма-онга алмаштыру нияте белән үзегез алып кайткан ике чемодан өчен генә закон алдында гөнаһлы булып калыгыз, анда да: "Гаепле дип саныйсызмы үзегезне?"—дигән соңгы сорау куелгач, кыю рәвештә әйтегез: "Юк, гаепсез",—диегез. Шулай дисәгез, каенагагызны аралап калырга маташмасагыз, бөтен бәлане үз өстегезгә алмасагыз, күп дигәндә ике ел бирәчәкләр сезгә, дип үгетләгән иде. Тотмадым бит шуның алтын киңәшен, тотмадым... Син инде, Минтукның чанасына утырып, аның көен көйләгәнсең, шул карт төлкене җәлләгәнсең, диярсең. Юк, ышанмадым, карчык, аның күз яшенә, зәррә кадәр дә ышанмадым. Мин бит аның судан коры чыгып, үземне батырып калдырырга маташуын бик тиз шәйләдем. Мин бит аны шунда ук сугып үтерә ала идем, әлхәмделилла, тыелып кала белдем. Бәреп үтермәгәч, аны зур бәладән йолып калдырырга булдым. Аның белән бергә үткәргән атна-ун көнем җәл, янә дә ун ел бер камерада утыртмагайлары, дип котым алынды. Кыскасы, җирәндем мин аңардан, җирәндем ул нәҗестән...

Бәхилли күр, газиз карчыгым, ачу тотма, зинһар!.. Балаларымны тәрбияли күр, зинһар, капчык асып, хәер сорарга чыгып китүдән коткара күр, зинһар, минем йөрәк парәләремне!.. Кичерә күр инде, карчыгым, яратуын яратсам да, киңәшләреңә һичбер вакыт колак сала белмәдем шул, белмәдем...

Газаплы уйлар диңгезеннән, хәсрәтләр дәрьясыннан чыга алмыйча, таңны аттыра Сәләхетдин мәхбүс. Инде сызылып таңнар атканда, юлдан һәм уйдан алҗыган тоткын оеп китә. Шулай миңгерәүләнеп, уяулы-йокылы яткан чагында күкрәгенә күсеме, тычканмы үрмәләп менгәнен шәйли. Күзен ачмыйча гына сул кулы белән генә теге күсене ялт иттереп эләктереп алуы була—колак төбендә үк чәрелдәвек тавыш белән берәүнең ачыргаланып илереп җибәрүенә күзен ачса—тычканмы, күсеме дигәне сыек кына гәүдәле бер үсмернең кулы булып чыга. Кесәгә кереп маташа икән бичара. Анда нәрсә бар дип уйлагандыр инде? Әйтерсең, моңа чаклы милициядә аның бөтен киемнәрен дә, үзен дә энә күзеннән үткәрмәгәннәр инде...

Ул арада аргы баштан:

—Кем тия анда минем пацанга?!—дигән калынрак тавыш ишетелә.

Озак көттермичә, әлеге тавышның иясе үзе дә күренә. Колгасар гәүдәле, сап-сары чәчле, почык борынлы, зур авызлы, утызларны узган бәндә икән үзе. Килә-килешкә сасы авызыннан катлы-катлы сүгенү сүзләре чәчеп:

—Төрмәдә Майкапның хуҗа икәнен белмәгәннәргә белдерәбез, танымаганнарга танытабыз! Майкапның пацанына кул күтәрүче булса, аны момент акылга утыртабыз!—дип сөйләнә.

Яңа килүчеләр сәндерәсе янында, әрнүен басарга тырышып, кулын селкеп торучы үсмерне, хатыннарны кочаклагандай, ике кулы белән дә кочаклап ала, аңа елмайгандай кылана, шундук чыраена гаять яман гайрәт кундырып, кай арада яшел сырма якасыннан нидер алып, "сояркәсен" рәнҗетүчегә якынлаша:

—Туны да җылы күренә моның...—дип аты-чуты белән сүгенүен белә.

Ышкыланмаган такта сәндерәдә утырган килеш, күзәтә Сәләхетдин, иллене узгач,

үзенә төрмә сабагы өйрәтергә маташучы сасыкның шыксыз озын, хәтта колакларын каплаган сары чәчен дә, зәһәр чәчкән яшел күзен дә, почык борынын да, нәзек иренен дә күрә-күзәтә Сәләхетдин. Бу гомер эчендә аны акылга утыртырга маташучылар булмады түгел инде, булгалады. Биш-ун ел гомерен бирер иде мәхбүс әлеге сасыкның җирәнгеч кыяфәтен күрмәс өчен. Тик ун елын бирә алмый шул мәхбүс—нәкъ ун ел буена җыен әтрәк-әләм арасында көн итүгә, йокысыз кышкы озын төннәрне санауга дучар ителгән шул Сәләхетдин...

Кай арада теге сарыбайның ике бармак арасына кыстырган бритва кисәген шәйләп өлгерә дә кулын сузып килгән хәчтерүшкә уң кулының сырты белән генә берне селтәп җибәрә. Моңарчы тоткыннарга туган-тумачалары әйбер-кара китерсәләр, иң әүвәл әнә шул хәчтерүш кулыннан уза, аның тавышы-тыны чыкмасын дип, май капсын дип, ул куйган "тәртипкә" бирәү дә каршы килә алмый иде. Сугыш башлану белән, моның елгыларга фронтка китү хәвефе яный башлагач, районда җаваплы эштә эшләүче, үзе бронь белән калган бер кардәше моңа амбардан бер капчык ашлык урларга куша; аны тотып, биш елга рәшәткә эченә утыртып куялар; аның үзенә ризык-мазарны күп ташысалар да, ул аны "сөяркәсе" белән генә бүлешә; район үзегеннән үзләренә дә азмаз тамгач, төрмә түрәләре аның кыланышын күрмәмешкә салыналар иде. Әле теге кыска чал чәчле, чал сакал-мыеклы, башына түбәтәй кигән татар агае мондагы хәлләрне белеп бетермәгән шул. Белгән булса, һич тә Майкапка болай кул күтәрмәс иде. Яңа кеше бит, яңа кеше... Үзе болай хәйран шәп сылады да бит—кем белә эшнең ни белән очланасын.

Тоткыннар барысы да уянып беткән, якын-тирәдәгеләре сәкеләрендә яткан килеш кенә башларын сузып күзәтәләр, ә инде түрдәгеләре, әйбәтрәк ишетү-күрү өчен, якынгарак елышкан иделәр. Бу рәнҗетелгән кешеләрнең һәркайсы Майкапның бака шикелле җәйрәп ятуына эчтән сөенә, көлемсерәп тә куя, әмма чыраендагы үзгәрешне күршеләре сизмәгәе, дип тә хафалана.

Исенә килгәч, үзенең нишләп болай бусага төбендә чалкан ятуын тиз генә аңлый алмыйча азаплана Майкап. Башының үтереп чатнавы гына барлы-юклы акылын җыярга мәҗбүр итә. Көч-хәл белән кул-аякларын бергәрәк җыя да гәүдәсен кузгатмакчы булып карый, бер батман кургашын салгандай башын кыймылдатып маташа, әмма хәленнән килми. Тик инде барча халык алдында болай озаклап яту килешми, аларга үзеңнең бөтен һөнәрләреңне күрсәтеп бетермичә, бирешергә ярамый. Әле бит аның янә дә бер һөнәре бар. Шунда күрерләр Майкапның кемлеген!

Зәһәр ачу Майкапка көч бирә, һәм ул авырлык белән генә булса да аяк өстенә калкына. Кай арада сырма эченнән, каяндыр култык астыннан кыскарак кына фин пычагы тартып чыгара. Үзен төрмә халкы алдында әдәм мәсхәрәсенә калдырган теге татар картына якынлашып килгәндә... тегенең сәкесенә сузылып ятканын, кая ул сугышырга әзерләнү, хәтта әле күзләрен үк йомганын күреп, хәйран кала. Ә инде якынрак килеп, йөз чалымнарын яхшылап карагач, моңарчы да аны күргәне барын, бу затның Киндерледәге күршесе Федор дәдәйгә көз көне печән кайтарып бушатканын, дөресрәге, тау хәтле печән олавын иңе белән җиңелчә генә кагылып аударганын үзенең авыз ачып карап торганы хәтеренә төшүгә—Майкап тораташтай катып кала, дөньясы онытыла, кулындагы фин пычагы шапылдап идәнгә төшә. Майкап эчендәге зәһәр ачуын яраннарына юнәлдерә:

—Безнең ташпулатыбызга утырмага Вагоностройның мөхтәрәм аксакалы Сәләхетдин пәһлеван килгән! Ул минем күршем Федор дәдәйнең җан дусты. Мин аны көзлектә күргән идем. Ул чагында аның сакалы юк, мыегы кызлар кызыгырлык иде. Хәзер бөтенләй танырлык түгел үзен: чал сакал баскан. Бөркет борыныннан гына шәйләдем. Куәтле булуыннан да, кәнишне...

Майкап, янтыгын капшап, әйләнә-тирәдәгеләргә бер карап ала да:

—Шуны колакларыгызга киртләгез, Федор дәдәйнең дусты—минем дә дустым. Аны рәнҗетергә маташучы табылса, миннән рәхим-шәфкать һич көтмәсен!—дип зәһәрен чәчә.

Шундый нотыктан соң үземне килеп кочаклар, дип көтсә дә, өмете акланмый гына бит: мәхбүс ичмаса кымшанмый да, күзен йомган килеш ята бирә. Әллә бар Майкап аның өчен, әллә юк... Яу кырында сугышып йөрүдән рәшәткә артында, зинданда утыруны артыграк санаган сарыбайгамы соң юньле кешенең хәлен, эчке кичерешләрен аңлау! Авызың тулы кан булса да, кеше алдында түкермә, дигән бит безнең халык.

Сәләхетдиннең, шушы хәлгә төшкән, күсе, тычкан, сарыбайлар ише җыен хәшәрәт арасында, аларга баш иеп, шушы хөрәсәннәрдән өркеп яшәүгә дучар ителгән әдәп-инсаф иясенең эче тулы ут, йөрәгендә ялкын, бугазында ачы төер булса да, үзенең чын халәтен һич сиздерәчәк түгел җыен әтрәк-әләмгә. Күз яшен чыгарырга һич тиеш түгел Сәләхетдин, һич! Сөенмәсен җыен әтрәк-әләм. Тешен кысып булса да түзәр, Аллаһы Тәгалә шулай кушкандыр инде, дип түзәр.

Олы агайларның истәлекләренә караганда, Кече Чынлы авылы аша Болгар дәүләтенең зур бер сәүдә юлы үткән. Юлчылар авылыбызга ат ашатырга, ял итәргә генә кермәгән, кырыс холыклы, уңган һәм таза ир-атны юл йөрүгә дә өйрәткән. Имештер, безнең авыл халкының юл йөрергә яратуы шул заманнардан калган гадәт икән.

Әлеге чир Сәләхетдингә дә йоккан. Иген-тару эшләре беткәч, кышка кергәч, хуҗалыктан артканын чанага төяп, рәхәтләнеп бер йөреп кайталар икән болар. Авылдашлар берсен-берсе яхшы белә, аралашып яши, тик инде юл йөргәндә һәммәсе дә Сәләхетдиннең авызына карап торырга мәҗбүр икән. Юлда бит мукшысы, урысы, тагын әллә кеме очрап кына тора. Каян белеп бетермәк кирәк аларның барысының да телләрен авыл кешесенә?! Ә ул, яшьли читкә чыгып йөргәнгә, телләрне әйбәт белә.

Шулай баралар болар йөк төялгән чаналарга кырын ятып. Аксакал иң арттан бара, башкаларга күз-колак булып. Менә берзаман алдагы олаулар туктап калалар, кай арада берсе йөгереп килеп тә җитә аның янына, карга бата-чума.

—Сәләхдин әбзәй, анда артлы чана белән урыс албуты. Безгә юл сапмый—"голопобый" дип тетә генә...

Аксакалның чырае шундук кара янып чыга. Өстендәге иләмсез олы толыбын сыдырып ташлый, зур тире бияләйләрен билбавына кыстыра да салмак адымнар белән генә олауларның башына чыга. Тагын бераз барып, кара туры айгырны да, ат башына утырган кучерны да уза, артлы чанага кырын яткан, явыз кыяфәтле, үзеннән шактый ук яшь, тазарак кына гәүдәле алпавыт янына килә. Сүзне, әлбәттә:

—В чем дело?—дан башлый.

Теге исә, урыныннан да кымшанмыйча, сүгенү сүзләрен дә белгәнен күрсәтеп, "гололобыйлардан" фәлән фамилияле господин алпавытка юл сабуларын даулый. Сәләхетдин бер дә кызмыйча гына аңарга җиде-сигез олауны, йөк төялгән авыр чаналарны кörткә төшереп батырганчы туры айгырны юлдан алып тору ансатрак булганын аңлатырга тырышып карый. Сабырын җуймаска тырыша.

Алпавытның гына сабыры төкәнә. Үзенең фәлән фамилияне йөртергә дә, юл сабуны дауларга да хакы барлыгын күрсәтергә теләп, артлы чанасына торып баса да, аюга алып йөри торган, тәртә хәтле кистәнен алып, аның каеш элмәген кулына кия дә:

—Я проучу тебя, гололобый!—дип, зәһәрләнеп, тегенең башына томырырга кизәнә.

Миңлебай Сәләхен зәһәрләнеп кенә алдырып та, җинеп тә булмаганын аңламый шул урыс алпавыты, аңламый. Ул гололобый дип хурлаган пәһлеван күзләрен кысыбрак, башына төшәргә, башын ярырга тиешле кистәнне сыңар кулы белән һавада эләктереп ала да, хуҗасы-ние белән бергә, ярылмый калган башы аркылы чөеп җибәрә. Тирән күпшек кар эченә әллә кайларга барып төшкәч кенә, ихтимал, аңлагандыр яшь алпавыт зәһәрлек белән генә җиңүгә ирешү мөмкин түгеллеген. Аңлаганмы тирән күпшек кар эчендә исенә килә алмыйча яткан урыс алпавыты җир йөзендә гаделлек дигән нәрсәнең хөкем сөрүен, әллә юкмы—анысы тамчы да кызыксындырмый Сәләхетдинне. Ул сабыр гына атлап тораташтай катып калган кучерны әйләнеп уза да айгырның алдына чыгып, урысча ягымлы гына сүзләр әйтеп, аны юлдан чыгарып, кар эченә төшерә.

Олаулар узгач, айгырны сабыр гына чыгарып бастыра. Айгырның хуҗасы да, кучеры да аны бүтән кызыксындырмый. Ул чанасына сикереп менә дә толыбын кия. Сембер юлындагы бу очрашу халык телендә риваять рәвешендә саклана.

Ат җене кагылган кеше бәхетлеме ул, әллә бәхетсезме—әйтүе кыен. Сәләхетдин шундый затлардан була. Берзаман бу Сембер базарында искиткеч мәһабәт, затлыкилбәтле бер айгырга юлыга.

—Себердән китергәннәр икән,—диешкәннәре колагына чалына. Халык мәш килә кызыл туры айгыр янында. Карап туймаслык инде менә, бөтен җире килгән: колакларын уйнатып, гаҗәеп килешле башын горур тотуы дисеңме, көлтә хәтле ялы дисеңме, елкылдап торган сырты, куна тактадай киң күкрәге дисеңме, озын торыкларын әледән-әле кыймылдатып, купшы койрыгын селкеткәләп, биеп торуы дисеңме—карап

туймаслык мәһабәт, сөлектәй инде менә. Күп кеше сокланып та, якын барырга кыймыйчарак та карап торганда, Сәләхетдин кызыксынып куя—тешләрен тикшерә. Чегәннәр мәзәгенә юлыкмагаем, дип шикләнә. Юк, өч-дүрт яшьлек кенә, хәрәмләшү күренми.

Кызыл туры айгырның шундый да күркәм кыяфәте җитә кала бит безнең ат җене кагылган кешегә. Тәвәккәлли бит Сәләхетдин. Сатып алырга ниятли Себер айгырын. Әмма затлы айгырның бәясе дә якын килерлек кенә түгел икән. Мөгаен, кызыгучыларның күбесе, хакын ишеткәч, айгырны ерактанрак күзәтү, сокланып карап торуны кулайрак тапкандыр. Тик инде Миңлебай Сәләхе андыйлардан түгел. Көязлек баштин ашкан аңарда. Чынлы халкын шаккатырырга уйлаган икән, ул инде айгырның бәясеннән өркеп тормас, ничек тә морадына ирешер.

Сәләхетдин атның иясенә үз бәясен бирә. Килде-китте атларга түгел, шәбрәк атка бирелә торган бәя була монысы да. Әмма теге бәндә бик төшәргә ажгырып тормый:

—Җир йөзендә таба алмыйсың бит мондыйны!—дип, малкаеның елкылдап торган сыртын сыйпаштыра. Бу чаклы да матур булыр икән булса да: белә бит, хәерсез, ат яраткан кешенең атланып очарга кызыкканын!

—Атың шәп, сүз дә юк. Мин дә бит сиңа кәҗә бәясен бирмәдем, тиярен бирдем, шуннан да артыгын сиңа, ай-һай, бирүче булыр микән?!—дип сатулаша торгач, килешәләр тагы, кул сугышалар. Ат иясе акчаны алып, эчке кесәсенә шудыра, Сәләхетдин тезгенне кысып тота, айгырлы була.

Сәләхетдин белән бергә килгән авылдашлары өчесе дә бер авыздан:

—Хәзер үз атыңны сат инде, һәйбәтләп айгыр җигеп кайтырсың, ичмасам,—дип үгетләп карасалар да, тыңлата алмыйлар.

—Юк, егетләр, әйтмәгез дә сүзегезне әрәм итеп. Җигәсем юк аны мондый арбага! Тарантаска гына җигәм мин аны! Хәзергә яннан гына юыртыр—мичәүгә җигеп җибәрәм, боерган булса. Ул арада айгыр каты куллы, таза гәүдәле кешегә ияләшә дә башлый, сыйпаганда башын артка чөйми, үзен назлаганда кытыршы иреннәре белән ир-атның җилкәсенә орына, юри генә тешләгәндәй кылана. Ә инде яңа хуҗасы муенын сыйпап, каты бармаклары белән ялын аралаштырып, саллы гына кулы белән сыртына шапылдатып алгач, хәтта әле бераз мөлҗерәбрәк киткәндәй була, аның таләпләренә тулаем буйсына башлый.

Тарантасын ясап та өлгерми Сәләхетдин, айгырдан уңмавына төшенә. Җир каткач, атларны уҗымга җибәрәләр. Шунда сәер бер хәл була: кызыл туры айгыр күз күреме җирдәге барлык атларны бергә тупларга тотына; уҗым кертләп йөргән ат янына бара да инсәсеннән эләктереп, селки, шундук зырылдап арты белән борыла да кушаяклап тегеңәр берне кундыра. Табун айгыры булган икән ләбаса! Кай арада авылның шул тирәдәге атларын барысын бергә туплап өлгерә. Әлеге хәлне күрүче авылдашлар Сәләхетдингә килеп зарланалар—атларыбызны имгәтмәгәе, дип хафалануларын белдерәләр.

Уйга кала Сәләхетдин. Бу айгырны болай асрап булмый бит инде, халык рәнҗетеп... Нишләтим икән инде үзен?

Шулчагында Заретдин атлы дусты моңа сүз куша:

—Сат үземә көтүчеңне! Бәясен арттырып түләргә риза,—ди.

Ир-ат шап та шоп кул сугыша—кызыл туры Себер айгыры шул рәвешле югары урамга, тегермән хуҗасы аранына күчә. Айгырны җигеп, Заретдин кыш буе юл йөри. Җилдерә генә. Шул рәвешле яз да уза, җәй дә. Көзге яңгырлы төннәрнең берсендә урлыйлар бу Себер айгырын. Заретдин мескен шешенеп бетә елый-елый. Сәләхетдингә дә килеп зарлана.

Әлеге хәлләрдән соң шактый вакыт узгач, Уби базарында юлыга бит Сәләхетдин әлеге кызыл туры айгырга. Йөгәненнән башлап бөтен дирбиясе—эшлиясе, камыты, ыңгырчагы-фәләне—кыйммәтле ташлар, көмеш тәңкәләр белән бизәлгән; тарантасмазар гына да түгел, фаэтон җигелгән; ат башында куе кара сакаллы кучер утыра. Нинди генә дирбиягә "киендермәсеннәр", танып ала бит Сәләхетдин айгырны. Ат җене кагылган кеше буларак инангандыр инде бичара. Дустын сөендерү, айгырын кайтарттыру нияте белән, жандармнарга хәлне сөйләп бирә. Тегеләр башта ярыйсы ук тупас итеп:

—Бер-беренә охшаш атлар азмыни бу дөньяда!—дип кенә котылмакчы булып маташалар.

Дөресен әйткәндә, фаэтонның хуҗасы берәр түрәдер дип, һич тә аның белән

ачылышлы буласылары килми. Тик инде Сәләхетдин үз дигәненнән кайтмагач, әлеге түрәгә сүз кушарга туры килә үзләренә. Мәсьәләне анлап алгач, теге әфәнде:

—Нинди сафсата ул тагын?!—дип бик эредән сөйләшмәкче була да соң, жандарм ротмистры:

—Каршы торган очракта без сезне, галиҗәнаб, җавапка тартырга тиеш булабыз,—дигәч, бераз йомшара төшә:

—Беләсезме, күпме түләдем мин бу айгыр өчен?—дип котылырга, юашлык күрсәтеп юмаларга маташа.

—Сез фаэтоныгыздан төшмәссез дә, әфәндем. Менә бу татар әйткән авылга, шуннан урланган, дип өзми дә-куймый да тәкрарлаган Кече Чынлыга барып кына кайтыйк инде. Ике-өч чакрым гына ул, шуннан да артык түгел...

Теге түрә дә, эшләр болайга киткәч, үз ягыннан таләпләр куя:

—Минем айгырым урланган мал булмаган очракта ул такыр башка нинди җәза бирәсез?—ди.

—Сүзегез дөрес, әфәндем,—дип җупли дә ротмистр, Сәләхетдин ягына борыла:—Әгәр дә мәгәр сүзегезне исбатлый алмыйсыз икән инде, гаепсез әфәндегә нахак бәла таккансыз булып чыга. Андый очракта сезнең үзегезне җавапка тартачакбыз.

Уйланырлык яңгырый бу сүзләр, җитди кисәтү инде бу. Ат җене кагылмаган кеше, мондый кисәтүне ишеткәч, бәла-казадан башаяк, дип әле генә әйткән сүзенән ваз кичәр иде. Тик инде Сәләхетдин үз сүзендә нык тора:

—Мине җавапка тартканчы, юк белән янаганчы, ат урлаган кешеләрне нишләтергә икәнен уйласагыз, дөресрәк булыр иде. Айгырның Кече Чынлыдан урланган икәнен сезгә кабатлап әйтәм. Моңа минем бертөрле дә шигем юк,—ди.

Айгырның дилбегәсен бушата төшеп, кузлага бәйләп куялар да Чынлы юлы белән иң алдан җибәрәләр. Кайта айгыр, башын чайкый-чайкый, таныш юлдан. Авыл башындагы йортлар күренгәч, адымнарын ешайта, озакламыйча юыртып китә. Аны кызулаучы да, тыючы да юк. Башкалар аңардан калышмаска тырышалар. Менә айгыр, олы урамнан бара торгач, гадәтләнгән юл белән тыкрыкка бордырып ала, аннан югары урамга каера да Заретдиннар капкасына барып төртелә. Йорт хуҗасы чыгып, капканы ачкач, туп-туры үзе яшәгән аранга юнәлә.

Инде бертөрле дә шик калмый. Фаэтонга җигелгән килеш тә малкай үзенең хуҗасына сыена. Йомшак күңелле авыл кешесенә җитә кала—атының муенын кочаклый да елап җибәрә.

Теге "кунаклар" актлар язып, ул актларга куллар куйдырып, Себер айгырын "чишендереп", барча затлы дирбиясен фаэтонга төяп, ул фаэтонны жандармнар утырып килгән арбаның артына тагып, авыл этләрен ырылдатып, хурлыклы рәвештә китеп баргач, Заретдин үзенең дустын сыйлап утырганда, күңеле нечкәреп:

—Син миңа әйтеп бетергесез изгелек эшләдең, Сәләхдин. Бу изгелегең өчен теләсәң күпме акча, теләгән нәрсәңне сора, дустым,—ди.

Сәләхетдин көлә генә:

—Бер ат өчен ике кат акча алмыйлар!

—Юк, алай түгел. Син бит мине зур бәладән коткардың. Ни үле, ни тере, боегып йөри идем ләбаса бүгенгә хәтле, син миңа җан өрдең, Сәләхетдин.

—Мин бит аны берәр файда алырмын дип эшләмәдем. Сине якын күреп, сөендерәсем килде—шуның белән вәссәлам.

—Чын дус икәнеңне белә идем, Сәләхдин, әле тагын бер кат шуңа инандым. Гомерлек дус син минем өчен, мең рәхмәт үзеңә!

***

...Гәрчә биш вакыт намазын укулар насыйп булмаса да, бүтәннәр уянгалаганчы иртәнге намазны, кеше аягы басылгач исә кичкесен укырга җаен таба. Суфыйлар дөньясыннан, аларның фәлсәфәсеннән һич хәбәрдар булмаган хәлдә, нәкъ аларча яши Сәләхетдин: эченнән генә догаларны кабатлый, бүтәннәргә ишеттерергә тырышмый, Ходай Тәгаләнең ризалыгын алу өчен укый. Хак дин нәкъ әнә шуннан гыйбарәт булса кирәк.

Намазлык сыйфатында җәелгән зәңгәрсу җиләне өстендә шулай тезләнгән килеш утыра да утыра мәхбүс. Намаздан соң ул әти-әнисенең, әби-бабаларының, вафат булган

карт хатыны белән сабый чагында бәхилләшкән кызчыгының әрвахлары рухына—һәркайсына берәр генә аять булса да укып багышларга онытмый. Андый вазифасын да үтәгәч, сабыйларын мең газап белән тәрбия кылучы карчыгына, ике кызына, ике улына иң изге теләкләрен юнәлдерә.

Фәкать шуннан соң Ходай Тәгаләгә ялварырга тотына:

—Йа, Раббым! Бу бәндәңне зиндан колы итәрлек нинди генә явызлыклар эшләдем, гөнаһлар кылдым соң? Ярлыка, зинһар, үзең ярлыка, Илаһем! Син кушканча гына яши алмадым, дөнья куып, еш кына өйлә намазын укырга вакыт тапмадым, фани дөнья мәшәкатьләре аркасында ахирәтне истән чыгаргаладым...

Күзе йомган, иреннәре дерелдәгәне күренми караңгыда.

—Әмма да ләкин калебем саф минем. Бер генә мизгел дә кяфер коткысына ияргәнем булмады... Синең барлыгыңа һәм дә берлегеңә ихлас күңелдән инанамын, синең өчен жаным фида...

Оеп утырган хәлендә ялваруын дәвам иттерә мәхбүс:

—Тик шулай да төп гөнаһымны аңлап бетермим, Ходаем. Газиз карчыгымнан, сабый балаларымнан барча калган гомеремә аерырлык, таш капчыкта интектерерлек нинди гөнаһ кылганымны аңларга ярдәм итә күр, зиһенемне ач сана! Берәр яманлык кылдыммыни? Кешеләрне рәнжеттеммени? Кемне дә булса алдадыммы? Нәрсә дә булса урладыммы? Берәрсен нахакка тотып кыйнадыммы? Аннан да яманы—кан койдыммы, жан кыйдыммы?.. Йокысыз төннәр аның күңел төпкеленнән әллә нинди истәлекләрне тартып чыгарды. Сәләхетдин аларны бөтенләй оныткан ук иде инде: азмыни баштан кичкәннәр шул гомер эчендә?! Юк икән менә, хәтердә икән һәммәсе дә. Гаять зур әһәмияткә ия булырдайлары да, үзе бөтенләй илтифат итмәгән вак-төякләре дә.

...Йомшак холыклы зат була Миңлебай абзый, аның әткәсе. Берәүгә дә каршы әйтмәс, һич бәхәсләшмәс, берәр ярамаган сүз әйтеп кемне дә булса рәнжетмәгәем, дип коты очып яши. Йортны карчыгы алып бара. Тик менә кызлары Фатыймага—15, уллары Миначетдинга—12, Сәләхетдиннәренә 6 яшь тулганда Миңлебай абзыйның яраткан карчыгы дөнья куя... Гәрчә ир-ат эшләрен әйбәт белсә дә, аш-су ягын кызына тапшырырга мәжбүр була йорт хужасы. Мәгәр Фатыйманың чибәрлеге белән төп йортта артык озак утырырга ирек бирмиләр—яучы арты яучы килеп кенә тора. Үткен холыклы чая бала, әти кемгә кияүгә бирер икән, дип, сабыр гына көтеп утырмый, үзе дә дәртенә керешә: яучы жибәргән егетләрне берәм-берәм күреп сөйләшә. Аулактамы, туган-тумачадамы—жаен таба чибәркәй, гомер итәрлек кешене үзе сайлый. Шуларның берсенә, әйтик, син кыр эшен яратмыйсың, ягага китү ягын каравың бар, дип баш тартса, икенчесе белән менә-менә вәгъдәләшә дигәндә, егет моның ике кулын да учларына алгач, безнең кулларыбыз охшамаган икән ләбаса, бармакларыбыз, тырнакларыбыз бөтенләй үзгә төрле, дип, ризалашмый. Әнә шулай сайлый торгач, авылның бик чибәр Сәнәтулла дигән егетенә 16 яшьтән кияүгә чыга.

Йортны алып барырга күрше авылдан бер ятимә кызны күндерәләр. Баштарак өендә чит хатын-кызны күрергә теләмәгән абзый, акрын-акрын ятимәгә ияләшеп китә һәм... өйләнеп тә жибәрә. Васбиҗамал аңа елның-елында бер-бер артлы өч кыз бала табып бирә. Йомгак шикелле генә яшь хатын кай арада өй эшләренә дә өлгерә, сабыйларын да карый, олыракларын да ашата-эчертә, өс-башларын кайгырта. Ятимлекнең ни икәнен үз жилкәсендә татыган яшь ана балаларның берсен дә үгисетми, рәнжетми. Ипле генә яшәп ятканда, йорт башын Фатыйхасы бакый дөньяга чакырып ала...

Әтисеннән Сәләхетдин 14 яшендә кала. Ичмаса, йортта бер тамак кимер, дип, ягага китәргә тәвәккәлли. Берәү дә каршы килми. Ундүрттә дә буйга зур, эшләп үскән, гәүдәгә таза малай Донбасс шахталарына барып урнаша. Дөресрәге, әле дөнья күрергә өлгермәгән үсмер өлкәнрәк абзыйларга ияреп ягага китә. Анда татар агайлары күп була, киң күңелле, юмарт холыклы, уңган егетебез шулар арасына сыя. Әнә шунда, авыр хезмәт шартларында ул чыныга, жир астыннан жир өстенә күмер чыгару һөнәренә өйрәнә. Ташкүмер чапканда өсләренә "түбә" ишелеп, ничәмә-ничә мәртәбә жәрәхәләнгән чаклары да булмый түгел. Әмма ул исән кала. Солдатка китәр вакыт житкәч, армиягә яраклы булу-булмавын каралырга авылга кайта.

Йортта бердәнбер ир-ат буларак, аның абыйсы Миначетдин солдатка алынмаган, ул арада башлы-күзле булырга да өлгергән икән ләбаса. Сәләхетдин кайтып төшкәч, ул шундук башка чыгарга ниятләвен белдерә. Бераз мал туплап кайткан Сәләхетдин абыйсына йорт салырга булышасын әйтә, йортка ияләшкән ат белән сыерны шунда

калдырып, аларга тиң мал-туар сатып алырга киңәш бирә, сәкегә акча янчыгын чыгарып сала. Әтиләренә охшаган, гаять сабыр холыклы, әдәпле вә инсафлы абыйсы башын чайкап:

—Юмартлыгыңа рәхмәт, Сәләхетдин, шулай да килешеп бетмәс бит йортны да син күмер чабып тапкан акчага салу, ат белән сыерны да син көч түгеп җыйган малга алу...—дип көлемсери.

—Юк, әбзәй, бер дә алай түгел. Мин ягада йөргән арада син бит семьяны карагансың, йортны алып баргансың. Монда барысы да синең кул көчең белән табылган, ким дигәндә хәерчелеккә төшмичә иске хәлендә сакланган.

—Алла ярдәме белән инде...

—Анысы дөрес, әбзәй, Алла ярдәме белән. Өстәп әйтергә кирәк, синең тырышлыгың аркасында.

Миначетдин янә көлемсерәп куя:

—Тик ятмаганмындыр инде, хәлдән килгәнчә тырышканмындыр...

—Шулай булгач, мондагы байлык—барысы да синеке, әбзәй. Теләсәң, монда каласың да, тора-бара мин башка чыгармын, барысын да өр-яңадан җыярмын. Зимагурларча булыр.

—Юк инде, Сәләхетдин, борынгыдан килгән гадәт буенча, ата йортында, төп йортта нәкъ менә төпчек малай кала. Башка мин чыгарга тиеш.

—Алайса, әбзәй, син моннан җаның теләгән мал-туарны, башкасын алып чык, йортны сиңа икәүләшеп җиткезик.

—Шулай гадел булыр, дисеңме?

—Әйе, әбзәй, нәкъ шушылай хәл иткәндә, гадел булыр.

Йомшак холыклы абыйсы, инде нишлим икән, каршы әйтсәм, рәнҗүе бар бит энемнең, дип, ризалаша моңа, ризалашмый хәле юк.

—Семья синең өстә кала бит инде, алай булгач?

—Мине солдатка алсалар, үзең күз-колак булырсың инде...

Әниләре белән дә киңәшләшеп, аның ризалыгын алгач, эшне кызу тота яшьләр. Түбән очта бер флант алып, шунда кечерәгрәк кенә өй салып җибәрәләр, каралты-кура җиткезәләр. Төп йортны алып бару кайгысы, үги ана белән гаиләне карау мәшәкате—һәммәсе "төпчек" егет өстенә төшә.

Солдат хезмәтеннән туп-туры авылга кайта Сәләхетдин. Җимертеп эшли, нәкъ шахтадагыча: җирен сөрә, игенен игә. Күзге уңышларны җыеп алгач, апасы Фатыйма аңа авылның чибәр генә кызын димли. Үги ана да ачык чырай белән кабул итә зифа буйлы, чем-кара чәчле, кара күзле, очлырак төз борынлы Аләмнисаны. Йортка тиз ияләшә килен. Каенсеңелләре белән дә тату гына яши. 1915 елның башында, ире Бөтендөнья сугышына киткәч, малай таба. Миңлебаевларның яңа буынын башлап җибәргән егет кисәгенә Гыйлметдин дип исем кушалар.

Үзенә охшаган олы малаен Сәләхетдин 4-5 елдан соң гына күрү бәхетенә ирешә. Ник дигәндә, бер сугыштан икенчесенә—Ватандашлар сугышына эләгә, шунда аягы яраланып кайта. Сәясәттән ерак була Сәләхетдин, элек гап-гади солдат була, берзаман үзен кызылармеец дип йөртә башлыйлар. Исән-имин кайтып җитә үз өенә.

Әңгер-меңгердә янкапканы ачып кергәч, таякка атланып чабып йөргән яланаяклы малайны күреп, башта аптырабрак кала Сәләхетдин. Ялгыш кермәдемме, дип, артына борылып карый—капка шул ук. Үз кулы белән ясап киткән капка. Такталары гына бераз төсен җуйган...

Ул арада лапас ягыннан сарыга кызгылт чәчәкләр төшкән озын күлмәк итәген бөрмәсенә кыстырган, төенчек шикелле генә булып калган Васбиҗамал карчык күренә. Солдат киемендәге яшь ир-атны, сул кулын козырек сыман иттереп каш өстенә куйгач, шундук танып ала:

—Ай-һай, Сәләхдинебез кайткан лабаса!—дип кычкырып җибәрә, апын-төпен атлап солдат янына килеп тә җитә, кочаклап та ала:—Исән-сау гына кайттыңмы, Сәләхдин?—дип сораштыра да башлый.

Солдатның күз угы таякка атланган хәлдә туктап калган малайда икәнен шәйләп, ике кулын да изәп, дәшә:

—Кил әле Гелметдин, әтәң кайтты бит! Кил инде, кил!—ди.

Ләкин аптыраудан тәмам югалып калган һәм нишләргә белмәгән малай олылар янына килергә ашыкмый. Фәкать инде әнисе өйдән бәреләсугыла чыгып, әлеге

солдатның күкрәгенә капланып, куанычыннан елап җибәргәч кенә, таягын ташлап, якынрак килергә тәвәккәлли. Анда да әле әнисенең зәңгәрсу күлмәк итәгенә сыенудан узмый.

Эшләр болайга киткәч, әтисе дигән солдат иелә дә малайны ике култык астыннан эләктереп ала, күкләргә чөя, киң күкрәгенә кыса:

—Улым нинди зур булган икән инде!..

Сәләхетдин бөтенләйгә кайткач та, Миначетдин ташлап бетерми төп йортны. Хәләхвәл белешә, дөнья күргән энесеннән киңәш тә сорый. Аннары дога кетә бит әле төп йорт. Үзе шулай килгәләп йөргәч, үзләренә чакыруы да җайлырак. Бермәлне шулай икенде намазын очлап кына ятканда, төпчеген ияртеп энесенең җәмәгате Ләйлиҗамал килеп керә. Намазын бозмый-нитми генә тәмамлап, битен сыпыргач та өй хуҗасы:

—Һай, киленебез килгән икән, бик хуп! Һай, Кыямдинны да алып килгән икән ләбаса, бик рәхмәт!—дип гөрли-гөрли, 4-5 яшьлек малай янына барып, аны күтәреп ала да кәнәфигә килеп утыра.

Тел яшергән хатын-кыз белән нәрсә генә сөйләшмәк кирәк! Серләшсеннәр әнә аш-су ягында ике килен-килендәш.

—Без менә шушында җайлап кына утырыйк әле икәүләшеп,—дип сөйләнә-сөйләнә, сабыйны алдына утырта.—Бигрәк зур үскәнсең мин күрмәгән 2-3 көн эчендә, прәме егет булгансың!..

Энесенең шундый бәләкәче булганга сөенә бала күңелле картлач. Үзенең уллары зур шул инде, башлы-күзле булырга да җыеналар, озакламыйча оныклары җыелыр, боерган булса... Кеше, мөгаен, Газраил белән очрашасыларын алданрак белеп торадыр. Миначетдин да бакый дөньяга китәргә 2-3 көн кала төп йортка килеп чыга. Энесе чирәмдә арба ясап маташа икән, төпчек улы шунда уйнаган булып, өлкәннәр сөйләшкәннең һәммәсен дә колагына элеп йөри.

—Һай, зур эшкә тотынгансың икән, Сәләхдин. Булышасы түгелме соң? Бик авырга килмәгәе берүзеңә.

—Юк, әбзәй, ашыгыч эш түгел, янмый болай үзе. Тик инде, ватылыпмы, таралыпмы ятмасын, дип кенә тотынган идем. Искегә тотынсаң—исең китәр, дип тикмәгә әйтмәгәннәрдер.

—Үз кулың белән ясаган нәрсә дә искергәч, бүтәнен әйтәсе дә түгел инде.

—Вакыт уза бит, әбзәй. Әнә, оланнар күз алдында үсә, без акрынлап кына картаябыз...

—Әле сиңа иртәрәк әле, Сәләхдин, алай диярго. Син миннән алты-җиде яшькә кечерәк. Бер ояны аякка бастырдың бастыруын, хәзер менә икенче ояң, менә бу егетләреңне кайгыртасы... Мин генә берсәк хәлсезләнебрәк торам әле кичәле-бүгенле...

—Әбзәй, сине монда тотканга ачуланма, зинһар. Әйдә өйгә керик, чәйләр эчкәч, сихәтләнеп китәрсең.

Сәләхетдин, бераз алданрак атлап, өйдәгеләргә хәбәр бирә, чәйләр әзерләргә куша.

Абыйсы, бусаганы атлап керү белән, өйдәге фәрештәләргә сәлам бирә, ата-бабаларының әрвахларына һәйбәтләп кенә догалар укый. Бу аның үзе фани дөньяга килгән нигез белән бәхилләшүе була...

Дүрт-биш елдан Вагоностройга килеп, эшкә урнашкач, Сәләхетдин үз янына абыйсының өч улын да алдыра. Олылары, әлбәттә, әниләрен дә, хатын һәм бала-чагаларын да төяп килә. Һәммәсе дә бер зур бүлмәдә бер гаиләдәй тату гына яшәп ятканда... әлеге дә баягы сугыш афәте өсләренә ишелеп төшә. Миңнисламны шундук сугышка алалар, тиз арада кара пичәтле хәбәре дә килә; аның хатыны Фәхрелбәнат, бала-чагаларын төяп, авылга кайтып китүне кулай күрә; кызы Әминә белән матур гына яшәп яталар. Габдрахманны хәрби заводта эшләгән җирендә бронь белән калдыралар; ул үз көче белән йорт салып, шунда бала-чагасын аякка бастыра; дөньядан китүе генә һич көтмәгәндә, фаҗигале төстә була. Абделәлим исә, егет булып җиткәч тә, чир-сырхаулардан арына алмыйча, тыныч кына китеп бара...

Сугыш...

Бөтен мәмләкәтне тетрәндергән, барча халыкны, һәр гаиләне төпсез хәсрәткә төшергән, олы кайгыга салган, бихисап михнәт вә ачлык-ялангачлык газапларына дучар иткән сугыш барча халыкның яшәешен гүя икегә бүлде дә ташлады: сугышка чаклы тормыш, сугыш вакытындагы һәм сугыштан соңгы тормыш...

Илле яшьтән узган Сәләхетдинне фронтка алмадылар алуын. Әмма таныш-белешләрдән китүчеләр хәтсез булды. Елау-сыктау гадәти бер хәлгә әверелде.

Тамак ягы кысылганнан-кысыла барды. Кибеткә азык-төлек торган саен азрак кайтты. Ипигә чиратны төнлә үк алырга туры килә иде. Сиңа ипи җитсә җитә, җитмәсә юк, җиткән тәкъдирдә дә бер кирпечтән артык сатмыйлар иде. Ничек итеп җиткермәк кирәк аны көн буена?

Ачлы-туклы халык кышка керә. Ул елны кыш иртә килүе белән дә, зәмһәрир суыклары белән дә хәтерләрдә саклана. Мукшысы-чуашы, урысы-татары аксакалга шунда сүз куша:

—Сәләхдин абзый! Балаларыбыз ачка шешенә. Өйләребездә бер мыскал он калмады, ярма калмады... Атың да бар, әллә авылга кайтып, кием-салымга бераз ондыр, ярмадыр ише нәрсәләр юнәтеп киләсеңме?..

Аксакал уйга кала. Дус-ишләренең зары аңа таныш хәлләрне сөйли. Яңалык юк монда. Яңалык фәкать авылга кайтып килү. Аз-маз гына булса да азык-төлек алып кайту. Әллә бәлкем, бераз тернәкләнеп китәр иделәр. Сабыйлар сөенер иде. Үземнекеләрдән беләм, алар да бит ач утыра... Өсләренә карап әрнисең...

Ризалаша аксакал. Башка берәүнең дә андый эшкә алынмасын аңлый.

Кайсылары бала-чага аяк киеме, кайсы әле кияргә өлгермәгән кофта-мазар, кайсы кешелеккә генә кия торган затлырак киемен китерә торгач, ике чемодан әйбер-кара җыела. Чуашы-урысы, мукшысы-марие, шушы әйберләрне аксакалыбыз, авылга кайтып, азык-төлеккә алмаштырып килер дә сабыйларыбызга җим булыр, юаныч булыр, ул арада, бәлкем әле, сугышы да туктар, дип өметләнә.

Вагонострройда яшәүче төрле милләт вәкилләре зур өметләр баглаган әлеге сәфәргә аксакал үзе ныклап әзерләнә. Гәрчә кар ерып кайтырга туры киләсен белсә дә, атының дагаларын тикшерә, хәтта әле бер аягындагысын алыштырта, яңадан дагалата, камытын, ыңгырчагын, аркалыгын, дилбегәсен берәм-берәм күздән һәм кулдан кичерә, чанасын караштыра, юлга чыккан чагында алып йөри торган балта, көрәк, сәнәк ише нәрсәләрен хәстәрләп куя. Атына азык ягын кайгырта. Сәфәр чыгу аның өчен һәрвакыт җаваплы бер эш саналса да, бу юлы аеруча җаваплылык сизә. Һәммә нәрсәсе әзерләнеп беткәч кенә, атлар аранына барып, чанасына күп итеп печән сала, атын һәйбәтләп җигә дә өйгә кайта. Башыннан бүреген салып, кәләпүштән генә кала да, үз кулы белән ясаган озын өстәлнең түренә уза, хатыны тукыган тастымалга көрәктәй кулларын салып, күзен йома да акрын гына тавыш белән юл догасын укып җибәрә. Бала-чага инде әллә кайчан торган, әтиләренең вәкарь белән генә көйләп укыганын аяк өсли тынлап тора. Бу аның үз өендә соңгы дога укуы булганын да, тавышын ахыргы ишетеп, үзен ахыргы күрүләре икәнен дә, газиз әткәләре белән бөтенләй-бөтенләй бәхилләшүләре икәнне дә, әлбәттә, белмиләр-шәйләмиләр.

Һәйбәтләп дога кылгач, ике кызының да, төпчек улының да башларыннан сыйпап, кырыс елмаеп:

—Әниегезне тыңлагыз, оланнар, яхшы итенегез, тәүфыйклы-инсафлы булыгыз,— ди.

Шушы сүзләре әтиләренең васыяте булып кала...

Үзенең туган авылына кайтып төшми Сәләхетдин: төп йортында берәү дә калмагач, туган-тумачаны борчымагаем, дигәндер инде... Кече Чынлыдан унбиш-егерме ел элегрәк аерылып башка чыккан Чалуга туктала. Анда ул Казанга килгән саен кунакка чакыра торган Минтук, беренче хатынының агасы йортына туктала.

Минтук дигәннәре үзе ай саен Казанга килеп, итен-фәләнен сатып, чанасын чүпрәк-чапрак белән тутырып киткәләде.

—Кайтсаң, туп-туры үземә кайтасың, семьем кайтасың икән—бер баз бәрәңге, берәр капчык оны-ярмасы! Әлхәмделилла, яхшы яшибез. Кайткач, үзең дә күрерсең,—дигән иде.

Ышана иде шул Сәләхетдин кеше сүзенә, бик ышана иде. Үзе уйнап та сөйләшмәгәч, алдашмагач, башкаларны да шулай, аның шикелле, гелән дөресен сөйлиләр, диебрәк фикер йөртә иде. Азык-төлектә генә түгел хикмәт. Соңыннан мәгълүм булганча, ул хәйлә капчыгы Казаннан кайткан саен: "Менә Сәләхдин төяп җибәрде әле, сата торырга кушты, үзе күбрәк тә алып кайтыр әле..."—дип сайраган. Кәтәнә каенагасы янә дә нинди "изгелекләр" кылгандыр гомер эчендә, шактый булган бугай кәкре каенга терәтүләр, тик инде соңгысы аларның барысыннан да хәтәррәк килеп чыга—төпсез коега төртеп төшерә ул Сәләхетдинне...

"Алла теләсә, иртәгә базарга чыгабыз",—дип кенә торганда, шимбә көнне кич белән

район үзәгеннән ике милиционер килеп төшә. Өй хуҗасының базарда сатарга дип әзерләп куйган чүпрәк-чапрагын, Казан кунагының ике чемоданын, чанасы белән атын, өстәвенә аларның үзләрен дә Шәйморзага алып китәләр... Каенага төне буе күз яшьләре түгә:

—Җәүһәриям җәл кала инде... Мине утырталар инде...—дип сөйләнгәли.

—Икәү бергә бит инде без. Утырткан тәкъдирдә икебезгә дә эләгә.

—Юк, Сәләхдин, син шәһәр кешесе, авыл судъясы төрмәгә утырта алмый сине... Әле минем әйберләрне өстеңә алсаң да, утырта алмый авыл судьясы.

—Һай, каенага, карап тормастыр ул кайсы авылдан икәнеңә! Шап иттереп пичәтен сугар да куяр.

—Юк, Сәләхдин, алай түгел бит ул...

Хатыннар елаганны күргәне бар Сәләхетдиннең, күп тапкырлар күргәне бар, һәм аңа ул табигый бер хәл дип карый. Ә менә ирләр мышкылдаганны җене сөйми. Якын кардәшең бәләкәй кызчыгын җәлли икән, бер дә гайрәтең чигәрлек түгел, тик инде аны миңа сөйләве, туктаусыз балавыз сыгуы һич акылга сыя торган эш түгел. Минем хәл дә нәкъ шундый да бит... Ярый инде, Гелметдинем чит-ят җирдә, әллә бәлкем, сугышка да алганнардыр үзен... Ә бит Казанда Мәрьямбану, Фәүзия, Кыямдин... Аларны җәллим дип, елап утырмассың бит инде! Бабайлар ни дигән бит: авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә, дигән. Күр инде, күр син аның кәҗә сакалын селкетә-селкетә елап утыруларын!..

Әллә миңа бик рәхәт дип белде микән? Җылы түшәгемдә ятар идем, Казанымда булсам. Ерак сәфәргә чыкмаган булсам. Коры сөяккә калган нарасыйларның күз алдында дәрмансыз гәүдәләре, мескен кыяфәтләре. Шуларның хәлләрен берсәк җиңеләйтеп булмасмы, дип чыктым да инде сәфәргә. Үзем файда күрим дип түгел. Әкәмәт инде! Мин шуларның киемнәрен җыеп, сәфәр чыкмасам, әйбер-кара милиция кулына кермәгән булыр иде. Үз киемнәренең җылысын тоеп яшәрләр иде. Тамаклары ач булса да, өсләре бөтен булыр иде ичмасам. Минем аркада килеп чыкты лабаса бу мәхшәр! Хәзер инде алдакчы хәлендә калдым. Ышандылар шул аксакалга, бичаралар. Моңарчы тамаклары гына ач иде, хәзер инде өсләре дә ялангач...

Нишләргә дә белми Сәләхетдин: каенагасы балавыз сыгудан туктамый, нинди генә түбәнлеккә төшүдән дә тайчынмый.

—Сәләхдин, кил, зинһар, атам бул, коткара күр мине бу бәладән! Әйтче, зинһар, следовательгә, мин биреп җибәрдем Минтукка бу тауарны, дип! Аякларыңны үбәргә ризамын,—дип сөйләнә-сөйләнә, тезләнә дә киявенең аякларын кочаклап ала. Шушы яшенә җитеп ир-ат белән кочаклашу уены уйнамаган Сәләхетдин тәмам югалып кала, мондый түбәнлеккә төшкән каенагасына җирәнеп карый, аңардан көчкә арына.

Суд тикшерүчесе һәркайсыннан сорау алганда Минтуктан:

—Кемнәргә саттың Казаннан сатып алып кайткан әйберләреңне? Кемнәр исәбенә баеп яттың?—дип, ачыклык кертүне дәгъва кыла.

Авылның сәлперәйгән карты, кәҗә сакалын селкетеп:

—Кая инде ул безгә баеп яту!—дип ничек кенә булса да акланырга маташа.—Мин бит кеше кушканны гына башкардым, үземә бер тиен калдырмадым...

—Кем кушканны?

—Сәләхдин, билгеле.

—Синең белән бергә кулга алынган Миңлебаевмы ул? Тулырак сөйлә. Исем-фамилиясен әйтеп сөйлә.

—Шул инде, шул мине бәлагә тартучы. Холкым йомшак икәнне белеп, мин Казанга баргач, сатарга дип әйберләр төяп җибәрде. Табышын мин тиенenә хәтле түләдем. Бер генә тиенен дә кесәмә салмадым, ипи белән ант итәм.

—Миңа синең ант итүең кирәкми, свидетельләр кирәк.

—Ай, миннән әйбер сатып алган авылдашлар әйтер дөресен, әйтми калмас...

Чынлап та, кәҗә сакалның һәр эштә алдын-артын уйлап куюы аклана: суд залында аның шаһитлары беравыздан:

—Минтук әбзәй фәлән нәстә өчен фәләнчә сорагач, мин биш-ун тәңкәгә төшүен сорадым, шунда ул: "И факырым, сиңа гел бушлай бирер идем дә шул, иясе бар бит; Сәләхдин кияү бер тиен дә төшәргә кушмады, бак миңани, берәр атнадан үзе кайта, яңа товар алып кайта..."—дигәнен икърар итә... Хөкем вакытында Чалудан китерелгән шаһитларның күрсәтүе, Минтукның "валлаһие" нигезендә билгеле бер карар кабул

ителә. Әгәр дә мәгәр Вагонострой халкыннан арыслан йөрәкле берәрсе табылып, ике чемоданга салынган нинди киемнең кемнән алынган икәнен күрсәтеп исемлек төзесә һәм әйбер-кара ияләреннән куллар куйдырса, анда базарда сатып алынган бер генә (!) әйбер дә юклыгы тәгаенләнгән булыр иде. Әмма гомер буе куркып-коты алынып яшәгән халык арасында арыслан йөрәклеләр табылмый—һәркем фәкать үз әйберенең әрәм китүен генә җәлләп, дивана дәрвиш Сәләхетдинне онытып, акрын гына гомер кичерү ягын карый. Ул чагында башкалар мәнфәгатен кайгыртып, гозерен үтәргә тырышып та кулга алынган аксакалны йолып алу фикере ичмасам башына гына килгән берәү булды микән?!

Законга таянып эш иткәндә, сугыш вакыты булмаган очракта да, шаһитлар гаепләнүче ике затның берсен яклап, бөтен гаепне икенчесе өстенә өйгәндә, гаепләнүчеләрнең берсе үзе өйгән тау кадәрле гаепне кардәше өстенә аударып төшергәндә һәм үзен гаепсез вә гөнаһсыз дип антлар эчкәндә, икенчесе бөтен гаепне, бүтән берәү өйгән теге тауны да, хәтта әле яклаучы хатынның сүзенә дә колак салмыйча, үз өстенә алып, үзен гаеплегә санап ятканда... нинди карар чыгасы көн кебек ачык. Адвокат ханым гаепләнүчене якларга тырышып нинди генә дәлилләр китермәсен, Миңлебай Сәләхе үзе аларны исбатламый, киресенчә, бөтен гаепне үз өстенә ала. Шулай итеп, ак эт бәласе дә кара эткә тагыла. Болар җитә кала.

Нәтиҗәдә, Сәләхетдиннең элекләре кулак булганлыгы да исәпкә алына, Ватаныбызның авыр сугыш еллары кичерүе дә, элеккеге череп чыккан кулакның (бер аты, бер сыеры булган, ике бите белән җир себергән затның!) кабат баш калкытуы да хөкем итеп утыручыларның ачуын кабарта, әнә шул нигезгә теге кара тау өелә—җәзаның катысы бирелә: Миңлебай Сәлахе ун елга хөкем ителә.

Олпат затлар җәмгыять вә табигать тарафыннан күрсәтелгән гаделсезлекләргә бик сизгер булалар бугай. Үзләре гаять зур фикер ияләре, физик көчкә ия булган хәлдә бөтен көч-сәләтләрен, барча кодрәтләрен көчсезләр файдасына, рәнҗетелгән кешеләр мәнфәгатен яклауга юнәлдерү, әнә шул изге юлда тән вә җаннарын фида кылырга әзер, һәрхәлдә үлгәнче көрәшә торган затлар, гаделлек тарафдарлары, гаделсезлек һич көтмәгәндә үзләренең өсләренә ишелеп төшкән очракларда бигрәкләр инде көчсез, карусыз, бичара хәлендә, сабыйлар хөкемендә калучан.

Олпат затлар андый чакта барлык үткән гомерләрен күздән кичерәләр. Шунысына иманым камил: кодрәт ияләре үзләре бүтәннәргә кылган игелекләрне түгел, бәлки мохтаҗларга ярдәм кулы суза алмаган чакларны, фаҗигагә тарыган адәмнәргә вакытында ярдәм итәргә өлгерә алмый калган очракларны хәтерләренә төшерәләр, әнә шуның өчен әрниләр.

Олпат затлар һичбер вакыт үзләрен кызгану дигән нәрсәне белмәсләр, үзләре өчен көймәсләр. Гаять четерекле хәлдә калган чакларда да бәла-казадан үзләре арынып калуны кайгыртмаслар, бәлки бүтәннәр мәнфәгате белән янарлар да көярләр, ничек тә аларны коткару дәртенә керешерләр. Сәләхетдиннең гаять аянычлы хәлдә дә үз башын аралап калу өчен тырышмыйча, үзе белән бергә бәлагә тарыган бәндәне—каенагасын йолып алып иректә калдыру өчен генә бар куәтенә тырышуы хак. Минтукны гаепсезгә чыгару бәхетенә ирешкәч, фани дөньяда кылган шушы олуг изгелегенә сөенеп, сакал баскан йөзендә елмаю чагылып уза. Әмма бу соңгы елмаюы бер мизгелдән артыкка сузыла алмый: аның үзенең дәүләт вә җәмгыять алдында гаепле дип табылуын һәм ун елга хөкем ителүен игълан итәләр.

Ходайга ялварулар бертөрле нәтиҗә бирмәде, мәхбүснең фикерләренә бернинди ачыклык кертмәде, тән вә җан газапларына һичбер җиңеллек китермәде. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм дә берлегенә ихлас күңелдән инанган Сәләхетдин фәкать:

—Бу гомердә гөнаһлы эшләрне чамасыз күп кылдым бугай шул...—дия алды. Сирәгәйгән чәчен сыйпаштырып, гүя ул карусыз тыңлаучан малай чагына әйләнеп кайтты.

Әнисе түшәктән башын да, гәүдәсен дә күтәрә алмыйча ята. Ана янынннан көндез дә, кичен дә китмичә караучы кыз бала Фатыйма ике энесен дә әниләре янына алып килә. Ана улларын башларыннан сыйпый, бәхетле булуларын тели, үзе аларга елмая, ике күзеннән дә яшь ага. Таң алдында Фатыйха япь-яшь көе дөнья куя... Гөнаһсыз-керсез күңелле сабыйларын калдырып китә ана. Әмма ана үзенең балалары белән бәхилләшеп үлә—дөньядан бик яшьли китсә дә, һич югы сабыйларын күреп бәхилләшү бәхетен кичерә...

Биш-ун елдан әтиләрен паралич суга. Тәүлек буе күзгала да, сөйләшә дә алмыйча яткан ата, гәрчә газаплы үлем белән китсә дә, бәхетле мизгелләр кичерә—һич югы балаларын үз янында күреп, аларга соңгы карашын юллый... Әүлиялар иде һәр икәве, җаннары җәннәттә булсын!

Тик менә Сәләхетдин генә, алар шикелле, үзенең гаиләсе, бала-чагасы белән бәхилләшә алмады. Әсирлек ачыгыйсын җаны вә тәне белән ахыргача татып үләргә язган булып чыкты. Олы улын күрә алмавы бер хәер инде—Гелметдинем үз көнен үзе күрә, хәзер ул сугыш кырындадыр, исән-имин йөри күрсен дә үз аягы белән әйләнеп кайтсын, миннән бәхил син, улым, мең бәхил! Кызларым Мәрьямбану белән Фәүзия икесе дә чибәрләнеп үсеп җиттеләр бугай инде, бәхетләре була күрсен, һәркайсы миннән бәхил! Газиз карчыгым, аларны да, төпчегебезне дә тәрбияләү, кеше иттереп аякка бастыру синең өстеңә төшә инде, гаепләмә, зинһар! Бик күп бәла-каза китердем үзеңә, бөлгенлеккә төшердем, кадереңне белеп җиткермәдем, газизем, кинә тотма, зинһар, бәхилли күр! Үзең миннән бәхил. Синең сылулыгың, синең укымышлылыгың, синең чибәрлегең дә уңганлыгың белән кырык яшеңнән тол итеп яшәтмәсләр, күз төшерүчеләр байтак иде, миннән генә курыктылар... Инде үзең берәрсен сайлыйсың икән, мең бәхил. Кызларымны юньле кешеләргә, ияләренә тапшыр да төпчегемне капчык астырып урамга гына чыгарма...

Сөекле улым Кыямдинем! Сине бигрәк яшь калдырам шул, яшәвемнең мәгънәсе дип үзеңне укытып, кеше итеп, аякка бастыру вазифасын куйган идем, өлгерә алмадым шул. Бик аяныч, бәгырькәем, бик аяныч. Инде миннән сиңа фатиха гына кала. Әниеңне карусыз тыңлап, аныңча гамәл кылсаң, шөт иншалла, намуслы, юньле адәм булып җитлегерсең. Аннары инде, баш-күз алгач, ниндирәк юл белән китәргә икәнен үзең хәл итәрсең. Менә хәзер сине алдыма утыртып, синең тәтелдәгәнеңне ихлас күңелдән тыңлау мөмкинлеге өчен җаным фида кылырга да риза булыр идем. Хәтта әле мыегымны тартсаң да, элеккечә тешләргә иткәндәй авызымны ачмас идем, күзем йомып, түзеп утырыр идем. Хәзер, нарасыйтам, әтиеңне бөтенләй үк танымас та идең әле: мине сакал басты, ап-ак сакал. Кайгы-хәсрәт билгесе инде ул, балакаем, һич тә бүтән нәрсә түгел. Сиңа андый ачы тормыш язмасын инде, газизем. Әлеге михнәтләрне үзем белән гүргә алып китим дә, сугышлар тиз арада-тиз көндә бетеп, сезгә имин гомерләр кичерергә насып булсачы! Аллаһе Тәгаләдән фәкать шуны ялварып сораймын. Бәхетле бул, нарасыйтам, тәүфыйклы бул, миннән бәхил ...

## Балчык ызба варислары

*"Тәрбия беркайчан да усаллык аша бирелми, шәфкатьлелек аша гына бирелә..."*

Әнием сүзләре

Бәләкәй чагымда мин бигрәк зирек тәртәле идем. Ашап утырганда, әйтик, апаларның берәрсе күңелемә бик үк хуш килмәстәй сүз ычкындырса, миңа шул җитә кала—турсаеп, артым белән борылып утырам, яисә бөтенләй табын яныннан торып читкә китәм, ягъни ач калам... Бернинди мәсхәрә-фәләнне күтәрми идем. Ихтимал, кайсыбер компаниягә сыймавым да шуннан килеп чыккалагандыр: көлке-мәзәкне күтәрә алмаганмындыр...

Бу тискәрелек, мөгаен, нәселдән киләдер. Нинди әйбәт, гомер буе диндар зат була торып, абыем әле дә үпкәчел. Ул Казанга кайтканда, табын янына утыргач, һәйбәтләп пешергән чәеңне беренче итеп, олылап, аның чынаягына агызасың инде; шул чагында чынаягы тулы булса—кинаясен белдермичә калмый:

—Син мине, тизрәк эчеп туйсын да, тизрәк китсен бу, дими торгансың бит?—ди. Чын-чынлап турсая.

Апалар да бер-берсе белән һич кенә дә тыныша алмадылар. Мин исә, Мәрьям апам кияүгә чыгып, Ковровка киткәч, бертуган апам белән, ызгышмый-талашмый гына, турсаеп, сөйләшмичә йөргәли идем. Ичмасам, һәркайсының аерым бүлмәсе булса икән! Агач (дөресрәге, тактадан корылган) барактагы бердәнбер бүлмәдә өчәү яшәгәндә ләбаса әниебезнең үзегенә үткәнбез икән...

Әти белән Ленинградка баргач та, Гелметдин абыем төзелештә артык юанмый, Урта Азиядән килгән егетләргә ияреп Ташкент якларына сәфәр чыга. Анда

текстилькомбинатка жепләр манучы-буяучы булып урнаша да шунда төпләнеп кала. Абый азып-тузып йөрми, киләчәктә үз гаиләсенә иркенрәк яшәр өчен йорт салып, бакчалар утыртып җибәрә, җиләк-җимешкә тиенә. Хәер, башлы-күзле булуны да артык сузарга уйламый. Өйләнер алдыннан абый авылга кайтып килә. Хат-мазар язмый гына кайтканын күреп, өйдәгеләр бик нык гаҗәпләнәләр. Ул әйтә:

—Сезне алырга кайттым,—ди.—Әти риза булмаса, ичмасам, әни, сезне генә булса да алып китим,—ди.—Заводта эшлимен, таш йорт салып кердем, җимеш бакчасы утырттым. Безнең күрше урамда гына да авылдашлар әллә күпме. Татарлар шактый анда. Үзбәкләр үзләре дә әйбәт халык болай. Тиз ияләшерсез. Сөйләшүләре дә безнеңчә үк...

—Гелметдин, рәхмәт яусын алып кайткан бүләкләреңә дә, үз яныңа чакырып әйткән сүзләреңә дә. Тик инде, әтәң риза түгел икән, бара алмыйм анардан башка. Гаеп итмә, үз көнеңне әйбәт кенә үзеңә күрергә насыйп булсын. Күршеләрне дә күрәсеңдер бит? Сәнәт әбзәйнең Мәгъсүмәсен алып җибәрсәң, дигән идем...

—Әни, минем күз бүтәнгә төште шул, икенче берәүгә.

—Бик матур бит Мәгъсүмә.

—Шулаен шулайдыр да бит, әни, сиңа охшаган, сиңа тартым кыз очраттым. Шуны алырга иде исәп. Әни, әле мин булачак киленеңә бирәр затлырак күлмәк тә биреп җибәрмәссеңме дип өметләнгән идем...

—Ай, синең өчен әйбер-кара җәл түгел дә бит, ярар микән соң бер кешенең күлмәге икенче кешегә?

—Килен буласы кешең төскә-биткә сиңа тартым, буй-сыны белән дә, уңганлыгы белән дә нәкъ синең шикелле.

—Бәхетле булыгыз инде. Миңа ошаган аңа да ярар, дисәң, абый үземә Харбиннан алып кайткан күлмәкләрем арасыннан үзең сайлап аласың инде, алайса...

Ватан сугышында абыем минер булып хезмәт итә. Үз гаиләсе белән дә, безнең белән дә хәбәрләшеп, хәл белешеп, ярдәмләшеп тора. Ә инде сугышлар туктаганнан соң бер-ике елдан туп-туры Казанга, безнең калавылга кайтып төшә.Алып кайткан бүләкләре үзебезне искиткеч сөендерә. Күр инде син аны, беребезне дә онытмаган бит! Тик инде үземә атап алып кайтканы барысыннан да җиллерәк! Әнә шул затлы кара постау френчтан ательеда үземә искиткеч шәп пинжәк тегеп бирделәр. Ул затлы киемемне беренче мәртәбә мәктәпнең чыгарылыш кичәсенә киеп алган идем, университетны тәмамлаганчы өстемнән салмадым.

Хәйран ачык күңел белән кайткан абый әледән-әле:

—Минер фәкать бер генә тапкыр ялгыша,—дигән яраткан сүзләрен тәкрарлап, үзенең фронтта ялгышмавына һәм исән калуына туганнарының чын күңелдән сөенүен күреп, айга якын ял итә, кунак була, гаиләгә ярдәм күрсәтә.

Әни белән искене искә төшерәләр, авылны сагынып сөйлиләр. Һәрхәлдә, серләре килешә бу икәүнең, үгилек әллә кайчан эреп беткән, бер-беренә дөрес бәя биреп, хөрмәт белән карыйлар. Баксаң, бер-беренең уңганлыгына соклану әнинең яшь хатын булып килгән чагыннан ук башланган икән ләбаса.

Ташкенттан да хатлар язып тора абый. Баштарак әни үз кулы белән җавап яза, ә инде университетта гарәп алфавитын үзләштергәч, бу эшне миңа тапшыра. Чирек гасырдан соң, әниебез вафат булгач, Казанга янә кайтып китә абый. Карт анасын гүргә иңдергәч, бергәләшеп матәм көннәрен үткәрәбез. Самолетка озата баргач, күңелләре нечкәреп:

—Мин нәрсә әйтмә келим, инде әтиебез дә юк, әниебез дә... Мин олыгаеп барам, син дә бик үк яшь түгел, бишенче дистәне кимерә башладың. Нәрсә әйтмә келим, давай ешрак очрашыйк без моннан соң!—ди.

Шулай вәгъдәләшәбез дә соң... әмма кеше дигәнең үз гомерендә гел такыр юлдан гына йөри алмый, үзенең сукмагын сала адәм баласы. Ләкин шунысы кызык, үз сукмагымнан барамын туп-туры атлап, диебрәк фикер йөртсәң дә, алай ук булып чыкмый кана. Адымнарыңны акрынайтып яки барудан туктап, артыңа борылып карасаң—хәтта әле үзең салган, туры дигән сукмагың да бормалы да сырмалы икән ләбаса!..

Шаккатырлык хәл бит: абыебыз утызга җитәрәк исемен алмаштыра. Үзенең дәлиле болайрак: янәсе, бер егет белән бик дус булганнар да, гомер буена берсен-берсе онытмас өчен, исемнәрен бүләк итешкәннәр; шуннан соң теге егет Гелметдин, чын Гелметдин

исә Әнвәр булып йөри башлаган (паспортта фамилиясенең Минабаев дип язылуы анысы Рәсәй писерләренең укып та надан калуыннан киләдер инде)...

Янә дә бер сәерлек: Әнвәр дигән абыебыз инде пенсияләргә чыккач, алтмышны тутырганнан соң... никах яңарта. Дөресрәге болай килеп чыга.

Иртә таңнан эшкә китеп, кичен генә хатынын да, сугышка чаклы ук туган Зәйтүнә белән Мансурын да, алардан биш-ун яшькә кече Эльвира белән Тәнзиләсен дә сагыныплар кайта торган булса, көннәр буе өйдә яту берзаман туйдыра моны. Карчыгы картайган, улы белән серләре килешми, кызлары да үсеп җиткән, үз көннәрен үзләре күрү ягын карыйлар, хәтта әле төпчек кызы Тәнзилә дә әтисенә килеп сарылмый... Үзеңнең беркемгә дә кирәгең калмаганны тою-аңлау—ай-һай ла—җан газабы инде ул! Абыебыз моңа баштарак, вакытлы хәлдер, үзгәрерләр, киңәш-табыш итәрләр, дип өметләнә, моны шәрран ярып әйтеп тә карый—берни үзгәртергә моның кодрәте җитми. Хатынының, үсеп җиткән балаларының үзен бөтенләй дә санга сукмауларына түзеп торырга теләмичә, дөресрәге, сабыры төкәнеп, Лев Толстой сыман тәвәккәлли бу: берзаман вак-төяк кирәк-яракларын салган нәни чемоданын кулына тотып, утызкырык ел дәвамында үз кул көче белән тапкан бөтен милкен калдырып, гаиләсен ташлап, чыга да китә өеннән. Казанга килми. Әстерхандагы туган-тумача янына сәфәр кыла бу. Анда бераз баш-күз алгач, шунда төпләнеп калырга ниятли.

Бергә-бергә дөнья күтәргә җайлырак булыр дип, үзеннән бераз яшьрәк тол хатынны димлиләр абыйга. Шуның белән яңа оя да корып җибәрәләр болар. Җиңгинең бәпбәләкәй оныклары моны бигрәкләр инде үз итәләр, алдыннан төшмиләр. Тол хатын ир-атны тансыклаган, өстәвенә гаять ачык чырайлы ханым булып чыга. Әнвәрем дип кенә тора, аның туганнарын да якын күрә, үз итә. Бер-беренә бик тизияләшеп китәләр. Фронтовик буларак эш йөртеп, абыебыз яңа йорттан бер дигән фатир алу бәхетенә ирешә. Ул арада мөселман халкының ислам диненә мөнәсәбәте үзгәреп, шәһәрдә мәчет ачыла. Анда беренчеләрдән булып Әнвәр Минабаев йөри башлый—бала чакта өйрәнгән догаларын яңарта...

Абыебыздан биш-ун яшькә кечерәк Мәрьямбану апам, гомумән, үз әнисен хәтерләми, яшь ана тәрбиясендә үсә. Әмма күрше хатыннары аның үги бала икәнен исенә төшерә торалар. Шуңа күрә кыз бала кече яшьтән моңланырга күнегеп китә. Кызык хәл инде: үсеп җиткәнче бергә-бергә яшәсәк тә, бер кашыктан ашасак та, сугышлар башланып, әтиебездән мәхрүм булып, үги ана авылга кайтып китәргә әзерләнгәч, Мәрьямбану апа ризалашмый:

—Эшлим бит инде, үз көнемне үзем күрермен, авыр булса да...—дип калавылдагы баракта кала.

Безнең туганнан туган Габдрахман абыебыз үз гаиләсенә йорт салырга тотынгач, аларга чын-чынлап булыша. Йортны җиткезгәч, алар белән бергә шунда күченә. Ике елдан без яңадан калавылга килеп, Фәүзия апам җыештыручы булып эшкә урнашкач һәм гомуми торак почмагында бәп-бәләкәй бүлмә алгач, безнең янга күченә...

Биш-алты еллап вакыт узгач, Каураудан өйләнергә кайткан пөхтә генә бер егеткә димлиләр Мәрьямбану апаны. Әмма кара язмышы анда да ияреп барган булып чыга: тату гына яшәгәндә, берзаман ире чирләп китә һәм тиз арада вафат була. Шуннан соң апабыз Гөлшат исемле кызчыгын ялгыз үстерә. Үзе яшь, үзе чибәр тол хатынга кызыгучылар, өйләнергә теләүчеләр булса да, гомерен баласына багышлый.

—Мин нәкъ әниебез кебек, яңадан кияүгә чыкмадым,—дип үзен тәрбияләп үстергән асыл затны һич тә үгисетмичә, яхшылыклары белән искә төшерә.

Гөлшаты үсеп җиткәч, кызын туганнары белән таныштырырга Казанга бер генә тапкыр кайтып өлгерә. Чынлап та, кызы пешкән алмадай чибәр генә дә түгел, кай арада үзенең искиткеч уңган икәнлеген дә күрсәтеп өлгерә. Акыллы кыз бала туганнарын бик тә инде якын итә, Каураудан җылы-җылы хатлар язып тора.

Кызганыч ки, һәркем ата-анадан уңганлык-матурлык шикелле күркәм сыйфатларны алу белән генә чикләнми, өстәвенә әле теге яки бу авыруларын да мирас итеп алып кала. Гөлшат сеңелкәебез малай табып, сөенеп кенә яшәгәндә, әтисенең яшенә дә җитә алмыйча, дөнья куя...

Мәрьямбану апабыз шуннан соң, гомумән, дөньяда яшәүнең мәгънәсен күрүдән туктый. Шулай да оныгы Җәүдәтне тәрбияләп үстерә. Инде анысын да аякка бастыргач, акрынлап кына кәфенлекләр әзерли һәм караңгы-күрексез фани дөньядан тыныч кына, бернинди үкенүсез китеп бара...

Фәүзия апам белән бергә үстек. Бәләкәй чагында урамда уйнаганда малайлардан сине яклый идем, ди дә соң... Алай ук булмагандыр: үзем дә бирешми торган идем; аннары үзебезнең урам малайлары тиңнәрем вә дусларым булып, барыбыз да бер чама "байлыкта" яшәп, бүләр нәрсәбез юк, бик тә инде тату идек, үзара дус идек; урамыбыз утрау сымак булу сәбәпле безнең янга Югары очтан да, Түбән очтан да уйнарга, мәйдан яки урам бүлешергә алай атлыгып торучылар юк иде. Ә үзебезгә исә, елга-ерынты арасында яшәгәч, көннәр буе кызыклы уеннар уйлап чыгарырга урын җитәрлек иде.

Браты чамасыз иртә укый-сыза, "рәсем ясый" башлагач, шуңа сөенеп, дәфтәрләрен, буяу карандашларын җәлләми инде, анысы хак. Аннары яратмыйча да калмагандыр инде тәтелдек малайны. Акыл өйрәтергә, киңәш бирергә уйласа, апа кешегә каршы әйтеп, сүз көрәштереп тормам ич инде—елмаям гына. Акыл дигәнең анысы безнең үзебездә дә бер капчык. Апаң акылы белән яши дә, уйный да алмыйсың.

Ниһаять, без Казанга күчендек. Вагонстрой дигән калавылда фәкать миңа яраклы 2 нче сыйныф кына булганга, кыз баланы шәһәрдә тотып укытырга мөмкинлек булмаганга, апама да минем белән бер сыйныфта укырга туры килде. Әнә шул мәҗбүрият аның уку дәртен сүрелдерде, сүндерде. Бу аның кара язмышта алган иң әүвәлге шәхси "бүләге" булды, һәм туганым аны гаять авыр кабул итте. Ике-өч ел буена шулай энекәшләре белән бергә укып йөргәч, көтмәгәндә сугышы башланып, бала-чаганың бишенчене ачалар(!) дип юанган өметләре чәлпәрәмә килгәч, апам кая барып бәрелергә белмәде. Татарча дүртенчене тәмамлагач, урысчаны яхшы гына сукалаган биш-алтыбызны урысның бишенчесенә, калган сабакташларыбызны исә урысча дүртенчегә керергә билгеләделәр. Апам үзенең ахирәтләре Бибинур, Галияләр белән бергәләшеп сугышка шәфкать туташлары булып китәргә талпынып, анысы барып чыкмагач, ФЗӨ мәктәбенә дә сугылып карады бугай, әмма яшьләре җитмәү сәбәпле анда да кабул итмәделәр бугай.

Әтинең, аны мәктәптә укытасы килеп:

—Үз аягың белән бармыйсың икән, мин сине дилбегә белән бәйләп илтәм!—дип янавы бертөрле дә нәтиҗә бирмәде. Апам укудан ваз кичәргә мәҗбүр булды.

Монысын ачы язмышының икенче "бүләге" дип кабул иткәндә, аның өченчесе дә әллә ни көттермәде—шул ук каһәр төшкән сугыш аркасында булды: аның кордаш егетләре сугыш кырларында ятып калды...

Без фәкыйрегезгә әни ягындагы шигърияткә хирыслык бирелгән булса, Фәүзия апама әтинең математик фикерләү осталыгы күчкән. Авылга кайтып тора башлагач, кырчылык бригадасында аңа озаклап эшләргә ирек бирмәделәр—кәнсәгә хисапчы итеп алдылар. Әнә шул һөнәрне үз иткәч, сугыштан соң калавылда да бухгалтер вазифасын башкарды. Ул эштән гарык булгач кына, кичке техникумны тәмамлап, заводның үзендә (КОМЗның механика цехында бугай) мастер булып эшләде.

Безнең гаилә өчен иң олы фаҗига атасыз калу булды. Вакытында, колхозга кермәгән өчен генә, кулак тамгасы тагылып, йорт-җиребез вәйран ителгәнен ике-өч яшьлек сабыйлар әллә ни сизмәгәндер, һәрхәлдә, рухи җәрәхәт алмагандыр. Ә инде сугышлар башланып, изге ният белән йөргән әтиебез иреген-нән мәхрүм ителгәч, аннары озакламыйча ятим калгач, гүя һәммәбезне паралич сукты...

Апам белән икебез дә әнинең канат астына ныграк сыенырга мәҗбүр булдык. Әниебезнең нинди генә кыен чакларда да зарланмавы, тагын да кырысланыбрак китүе, мөгаен, балчык ызбабызны дзотка якынлаштыргандыр. Шундый шартларда һәркайсыбыз үзенең вазифасын тәгаен белеп, җиренә җиткереп башкарырга мәҗбүр иде.

Гәрчә ул елларда элеккеге сабакташларымның шактые укуын ташласа да, безнең укымышлы гаиләбездә андый мәсьәлә бөтенләй купмады. Укуымны зур тырышлык белән дәвам иттереп, җиденчене уңышлы тәмамладым.

Апам эшләде дә эшләде, минем укуымны һич күпсенмәде.

Без фәкыйрегез, башлы-күзле булып, башка чыккач, апам баракта әни белән торып калды. Юньлерәк фатирга өметләнеп, еллар буе завод карамагындагы төзелештә эшләде, әүвәл таш йортның бер бүлмәсенә, тора-бара аерым ук фатирына күченде. Әниебезне ул карады, ул тәрбияләде—мең рәхмәт аңа.

Калавылга барып-кайтулары, гәрчә бик авыр булмаса да, апам белән атнага бер дә күрешә алмаган чаклар була. Андый вакыт һич югы телефоннан бер-беребезнең хәл-әхвәлен белешә торабыз. Телефоннан үзенә минем улым чылтыратса, бигрәкләр инде

сөенә; аның балкып китүен күз алдына китерүе бер дә читен түгел.

Шунысы кызык, әниебез әле исән чакта калавылга ялгызым барып чыксам, әни бусагадан ук:

—Улымны алып килмәдеңмени, балакаемны?—дип каршылый торган иде.

Хәзер инде карт-корыны гына күрсә, апам:

—Нәрсә, Альбертны алмадыгызмыни?—дип гаҗәпсенә.

Дәвамчыңны шулай үзеңнән артык күргәч, сөенәсең инде, елмаеп җавап кайтарасың.

***

Кичке якта әниемне һавада йөрергә алып чыктым. Ашыкмыйча гына атлыйбыз шулай. Нигәдер сүзебез ялганып китә генә алмый бит. Әнинең йөзендә елмаюның әсәре дә юк, авызын бөргән. Димәк, нидер борчый аны, сүз башларга уңайсызланып кына атлый, күрәсең. Ашыкмыйча гына, әчке бер гарьлек, әрнү белән башлады әнием сүзен:

—Бу арада мине бик рәнҗетәсең әле... Сабыемны көн саен караңгы бүлмәгә ябасың. Җан иясе ләбаса ул, ничек син дигәнчә генә эшләп бетерсен, үз белдеге белән дә йөриселәре килә, эшлиселәре килә. Гаеп тапкан саен караңгы бүлмәгә ябып, котын аласың нарасыйтамның...

Ни әйтеремне тапмадым.

—Әни, бик азынмасын дип кенә тырышудан бит инде ул... —дигән булам, акланып маташам инде үземә күрә.

—Мин сине ялгызым гына үстердем. Гомердә рәнҗетмәдем үзеңне,—диде дә күтәрелеп миңа карады.—Әллә рәнҗеттемме?

—Сүз дә юк, мең рәхмәт үзеңә, рәнҗетмәдең. Тик син мине ялгызың гына тәрбияләмәдең. Синең ярдәмчең бар иде.

Әнием барудан туктады. Аның газиз вә нурлы йөзкәендә аптырау катыш сорау иде.

—Хәерчелек соң! Әнәй, берсәк әпәй юкмы, дип, бер телем икмәккә тилмереп үскән кеше әллә ни азына алмый шул. Аның бар куәте әлеге хәлдән ничек тә исән-сау чыгу, мохтаҗлыктан котылу максатына юнәлдерелгән булучан.

—Анысы шулай инде. Сабыйны тәүфыйклы итеп үстермә келисең. Аны аңлавын бик аңлыйм да бит, улым, нарасыйтага катырак кагылганда, бәгырьләрем телгәләнә. Берсәк йомшаграк булыр идең, улым. Тәрбия беркайчан да усаллык аша бирелми, шәфкатьлелек аша гына бирелә...

Әниебез әледән-әле үзенең туганнарын, аларның төс-кыяфәтләрен, холыкгадәтләрен, кылган хикмәтләрен, кичергән маҗараларын, әйткән сүзләрен шундый да оста итеп сөйли иде ки, без аларны үз күзебез белән күргәндәй булабыз—әни үзенең газизләрен искиткеч яратып та сагынып кына искә төшерә ки, гүя һәркайсының бүтән беркемгә дә охшамаган, гаять үзенчәлекле образларын аермачык гәүдәләндерә торган иде.

Гаҗәеп дәрәҗәдә кече күңелле була Садыйк абый. Әнидән ул ундүрт яшькә өлкәнрәк була. Димәк ки, әнием кечкенә чагында, ул инде үсеп житкән егет икән.

Көз. Урак өсте. Кырга барырга җыеналар. Садыйк абый атны жигеп бетерә дә өйгә ризык алырга кереп китә. Чыкса, ни күрсен—яраткан сеңелесе арба түрендә утыра.

—Син ничек итеп анда менеп кунакладың, Ләйлиҗамал?—дип кызыксына егет.

—Абый, беләсеңме, тәгәрмәчкә басып үрмәләдем мин арбага,—ди сеңелкәе.—Син кайчан чыгасың да мине күтәреп утыртасың бит әле...

—Арбага утырасың килдемени?

—Килде шул. Арбага утырмыйча гына кырга бара алмыйм бит инде мин.

—Кырга бик барасың килдемени?

—Килде шул. Анда бит борчак үсә, ә минем борчак ашыйсыларым килә.

—Һе!—дип куя Мөхәммәдсадыйк, үзе елмая.—Борчак ашыйсың бик килгәч, сине кырга алып бармыйча да булмас инде...

Имчәк баласын күтәргән килеш, олы улын озатырга чыккан Алимә әбиебез уртанчы кызын арбада күреп, бераз аптырауга кала.

—Ник анда утырттың инде, улым, сабыйны? Китәргә җыенасың лабаса?—ди.

Ул арада кызы әнисен сөендерергә ниятли:

—Мине абыем күтәреп утыртмады, әни, мин үзем менеп утырдым. Тәгәрмәчкә басып мендем!—ди.

Тик әниләре нигәдер сөенми, аның йөзенә борчылу билгеләре чыга:

—И-и-и, кызым Ләйлиҗамал, егылып төшә күрмә, балакаем, имгәнә күрмә...—ди.

Шунда аның олы улы серне чишә:

—Әни, Ләйлиҗамалның борчак ашыйсы килә икән. Әгәр дә мәгәр син риза булсаң, мин аны арбага утыртып кырга алып барыр идем,—ди.

—И-и-и, улым Мөхәммәдсадыйк, ул анда сиңа комачаулык итәр бит...

—Юк, әни, бер дә борчылма. Ләйлиҗамал хәзер зур инде, бик акыллы бит ул, әйткәнне тыңлый.

Абделнәфыйк карт, иртәнге намазын тәмамлап, болдырга чыгу белән, хәлне аңлап ала, мыек астыннан гына елмаеп, сөекле карчыгы белән саубуллаша:

—Хафаланма, карчык, кызыбыз, әлхәмделиллаһ, зур инде. Аның белән бергә күңеллерәк булыр безгә дә. Син тыныч бул, карчык, алай артык соңгармабыз,—дип юата.

Олпат карт арбаның уң ягына чыгып утыргач, үзе ясаган нинди нык арба да зарлану йөзеннән шыгырдап куя. Абделнәфыйк карт, бисмилла әйтеп, дилбегәне кулына алу белән, ат баскан урынында аякларын алмаш-тилмәш кузгаткалап куя. Ул арада Мөхәммәдсадыйк, өр-яңа капканы тутырып ачып җибәрә, әтиләре чыккач, капканы җиңел генә яба да, әнисенә елмаеп, тизрәк янкапкадан чыгу ягын карый.

Тик ана кешенең әйтер сүзләре бетмәгән икән әле:

—Мөхәммәдсадыйк балакаем, Ләйлиҗамалга, зинһар, күз-колак була күр инде. Әтиең дә бик артык онытылып мавыгып китмәсен. Эшләмәгән түгел инде, эшләгән. Хәзер бераз йөрәген сакласын дим дә бит... Ярый, балакаем, миннән фатиха үзегезгә!

Эш белән вакыт бик тиз үтә бит ул. Кояш кай арада, күгелҗем-ак болытларга чума-чума, басу-кырларның күз күреме җирендәге аргы башына якынлашырга да җыена. Өлкәннәр, эш белән мавыгып, аны-моны абайламый да калалар. Әмма сабый бала үз дигәнен һич онытмый, аның күңеле шөбһәләнә: абыйсы атны җигеп, кайту юлына чыксалар?..

Сеңелесенең чүмәлә янында акрын гына елап утырганын күреп, егет хафалана кала.

—Нәрсә булды, Ләйлиҗамал?—дип, аның каршысына килеп тезләнә.

—Эчем а-в-вы-ы-рта-а...

—Нишләп авырта икән соң? Нәрсә ярамады икән эчеңә?

—Борчак ашыйсы килә-ә-ә...

Егетнең йөзенә елмаю куна. Шунда гына иртәнге әңгәмә исенә төшә. Тиз генә әтисе белән сөйләшеп, аның ризалыгын ала да, бөтен ару-талуын онытып, атка атланып, юлга чыга. Каян да булса табарга кирәк инде...

Аның кайтканын сеңелесе дүрт күз белән көтә. Менә абыйсының атын юыртып кайтканын күрә дә камыл арасыннан каршы юнәлә. Абыйсы шулчак атын туктата, иң кадерле нәрсәдәй бер кочак саргая башлаган борчакка зарар китермәскә тырышып кына, ат сыртыннан шуып төшә, тезгенен кулына тоткан хәлдә, сыңар аяклап аның янына атлый-сикерә килә:

—Менә минем яраткан сеңелемә яраткан ризыгы. Борчак ашагач, аның инде эче дә авыртмас,—дип кучтәнәчен аңа суза.

Габделсадыйк абый сугышларда бик күп йөри. Татар сугышчылары чыгарган җыр һәм бәетләрне хатка язып җибәргәли. Кайсыберләрен үзе үк чыгарган булуы да бик ихтимал. Ватандашлар сугышын Урта Азиядә тәмамлаганнан соң шунда гаскәри командир буларак торып кала, күпмедер вакыттан соң демобилизацияләнеп, ниндидер җаваплы эшкә урнаша һәм шунда төпләнеп яши. Әнинең үзе өчен генә түгел, Фәүзия апам белән минем өчен дә Садыйк абый әдәплелек өлгесе, Зариф абый исә егетлек, батырлык үрнәге булды.

Әнвәр, Адиҗан белән бергә Чалуга барган идек. Шуннан кайтып килешебез. Кыр станы яныннан узганда, Сәра әптәй үземне күреп алды да, ял итүче ахирәтләре арасыннан гына:

—Кыямдин, синең Садыйк әбзәң кайткан диләр, шулай микән?—дип яңа бер хәбәр әйтте.

Аны күрмичә узарлык түгел: үзе буйга зур, үзе таза, үзе чибәр. Аның хәбәре мине тетрәндереп җибәрсә дә, туктап тормадым. Ихтимал, бер көтү хатыннар алдында сүз куертудан качканмын, әллә инде үземне егеткә санап, вакланып тормаганмын. Фәкать юл уңаенда гына:

—Юктыр ла...—дип куйдым сыман.

Шулай да кызурак атлый башладым. Адиҗан атлый-йөгерә дигәндәй:

—Чынлап та, кайтса, нишләр идең?—дип кызыксынды.

Әнвәр дә битараф түгел иде, әмма авыз ачып сүз әйтмәде.

—Садыйк әбзәй кайтсамы? Ул кайтса, өйгә дә кереп тормас идем әле, туры шунда чабар идем...—дигән булдым.

Тик инде авылга кайтып җиткәнче, тегермәннәр янынннан үзебезнең тыкрык буйлап төшкәнче әлеге хәбәр бөтенләй исемнән чыкан иде. Әбинең пошаманга калып:

—Садыйк әбзәң кайткан, Мәхмүбҗамалларда. Әниеңнәр шунда киттеләр, әниең сиңа да барырга кушты...—дигәнен ишеткәч кенә, кыр станы янындагы хәбәр искә төште. Әбием ул арада күршеләргә кереп, Әнвәрнең кыска җиңле өр-яңа ак күлмәген алып чыккан икән, шуны миңа кигезмәкче булып азапланды. Тик инде минем һич тә күрше күлмәген киеп көязләнергә исәбем юк иде. Аның култык астыннан шома гына шуып чыктым да бәрәңге буразналары арасыннан Зурәптәйләргә элдерттем. Бичара әбием калды шунда ут йотып...

Малай чакта болай атлап кына бөтенләй үк йөрелмәгәндер. Атлый-йөгерә барып та життем Зурәптәйләргә, мендем болдырларына, кердем ачык ишекләреннән өйалдына. Бусага төбендәге биш-алты яшьлек яланаяк йолкышны әнинең абыйсы шундук шәйләп алды. Чөнки ул елмаеп-балкып, яныма килде дә, түбәтәемне салдырып, шуңа кәнфитпрәннек тутырып, кулларыма тоттырды, саллы гына кулы белән башымнан сыйпады.

—Зур егет булган икән инде Ләйлиҗамалның улы!—дигән кебегрәк хуплау сүзләре әйтте.

Кунаклар минем үземә бик сәер затлар булып тоелды. Иң әүвәл җиңгине күреп алдым: гаҗәеп зифа буйлы, калку кара озын чәчле, зур яшькелт күзле, төз борынлы, уймактай авызлы, аңарчы мин күргәннәрнең барысыннан да чибәррәк тә, затлырак та ханым иде.

Мөхәммәдсадыйк абый, әни сөйләгәннәрдән чыгып фикер йөрткәндә, җир йөзендә иң акыллы, иң төпле, иң зирәк, иң әдәпле, иң инсафлы, иң укымышлы, асылның-асылы бер зат иде. Чалара башлаган чәчен уңга салган, кыска гына мыегына да чал кергән икән инде; җаенкерәк битендә кечрәгрәк кенә кылыч борын, зәп-зәңгәр күз; аның җитди чагын күрергә туры килмәде, гел елмая иде. Базык гәүдәле булуы аның карсаклыгына аеруча басым ясый, янәшә туры килсә, зифа буйлы чибәр хатынынннан калышрак икәне сизелә иде.

Безнең дөнья көтүләребезнең аянычлы хәлдә икәнен күреп, Садыйк абый әтиләрне үз янына, Урта Азиягә чакырган:

—Теләсәң, шәһәрдә үзеңә әйбәт фатир алып бирәм. Теләсәң, мин инде үземнең хуҗалык белән, үз өемдә яшәргә гадәтләнгәнмен, дисең икән инде, шәһәр читеннән үзеңә йорт сатып алам, ат белән эшлим, дисең икән инде, үзеңә ат алып җибәрәм. Әйдәгез генә, бу фәкыйрьлектән, индуклыктан котылыгыз гына! Зинһарлап сорыймын үзегездән, әйдәгез, ризалаша күрегез!..—дип үгетләгән.

Акыллы киңәшне тыңлау-тыңламау бер хәл, ә менә каенагаң сатып алып биргән өйдә яшәү ул, безнеңчә әйткәндә, йортка керү белән бер була бит инде! Әлхәмделилла, андый көнгә калмаган әле! Начармы-яхшымы үз йортым, үз хуҗалыгым. Аннары авыл буйлап, Миңлебай Сәләхе йортка кергән, дип сөйләп йөрерләр иде бугай! Бөтен авыл чын атыңны да онытыр, ягага китеп, йортка кергән Сәләх дип кушамат тагарлар иде бугай. Такмый гына торсыннар әле менә!..

Садыйк абыйны бик еш сөйли иде әни. Бу образ балалар өчен идеалга әверелгән иде инде. Ичмаса бер күреп калдык үзен, бүтән күрешүләр насыйп булмады. Ихтимал, бу аның сәламәтлеге какшау аркасында күңеле тартыпмы, утыз җиденче еллар мәхшәрен алданрак сиземләпме, туган туфракны соңгы кабат күреп, әти-әнисенә зыярәт кылып, сеңелләре белән бәхилләшү өчен кайтулары булгандыр...

Әнинең үзеннән бер генә яшькә кече Мөхәммәдзариф атлы энесе була.

Менә житез вә елгыр Мөхәммәдзариф Нәфиев мәдрәсәгә укырга йөри башлый. Хәлфә бер үк таныш текстны һәркайсыннан укытып карый.Чират Зариф абыйга килеп житә. Һәм ул гөбедән чыккандай калын тавыш белән бөтенләй башкача укып җибәрә. Гарәп сүзләренең мәгънәсенә төшенүе, әлбәттә, икеле, тик инде ул сузык авазларны үзенчә куя, үзенчә укый. Хәлфә моны буразнага төшермәкче булып карый да соң, Зариф шәкерт бирешми:

—Әнәй шылай укырга кушты!—дип тартыша.

Хәлфә, мөгаен, төпле генә егет булгандыр. Шул арада, моның әнисе зур укымышлы зат, мулла нәселеннән, Нәптәй галава җәмәгате, гарәпчәне миннән әйбәтрәк белүе бәхәссез, дип бер мизгел эчендә уйлап өлгерә дә бәхәсләшүдән читкә тайпыла:

—Ярый соң, укы алайса әниең кушканча,—дип әйтергә мәҗбүр була.

Гайяр егет булып үсеп җитә Зариф абый. Берара, дөнья белән таныштыру, кеше арасына кертү өчен, Садыйк абый аны ягага, үз янына алдырып, урысча да укыта.

Беренче бөтендөнья сугышында Садыйк абый офицер булса, Зариф абый кавалериядә хезмәт итә. Әрсезлеге, житезлеге, үткенлеге сугышта ярап куйгандыр, ахрысы: Георгий тәресе белән бүләкләнә.

Безнең төбәктә аның тәвәккәл һәм курку белмәс егет буларак даны тарала...

Әтиләрне кулак дип туздыру белән генә чикләнмичә, Себер сөрергә була "жирле власть"нең нияте. Әмма әти аларның йорт-жирне бөтенләй рисвай итеп ташлауларын күргәч, янә дә нинди хикмәтләр күрсәтер икән инде болар, дип кул кушырып көтеп утырмый—олы малаен ияртә дә Ленинградка юллана. Чуртанны ычкындырдык бит, дип хафага төшә авыл Советы активистлары. Бигрәк тә район үзәгеннән килгәннәр гасабилана—көн саен, иреңне кая яшердең, дип әнидән таптыра. Шунда берсе үз акылына килә дә:

—Без монда Минлебай Сәләхен таптырып аның җәмәгатен чакыртабыз да тинтерәтәбез тинтерәтүгән. Тик менә бернәрсәне истән чыгарганбыз. Ул хатын бит Зариф Нәфиевнең туган апасы. Зариф үзе кайтып төшмәгәе! Көн бетә аннары үзебезгә... —дип, шиген белдерә.

Димәк ки, ягада йөргәндә дә Георгий кавалеры Зариф абыйның туганнарына ярдәме тия—әнине бүтән борчымас булалар...

Әниемнең мондый бер хәлне сөйләгәне дә хәтердә.

Мөгаен, зур бүләк бирелгәннән соңдыр, Зариф абыйга берәр атнага өенә кайтып килергә рөхсәт итәләр. Кайта бу урак өстендә. Әни ерак басуга уракка йөри икән. Зариф абый да барырга була.

—Син ял итеп алыр идең,—дигәнне ишеткәч:

—Шунда ял була инде ул, кырда,—дип җавап кайтара да ат җигәргә чыга.

Болар басуда чакны авыллар арасындагы юлда өч җайдак пәйда була. Сәлам биреп тору юк, урысча сорый офицерлары: фәлән авылга ничә чакрым, ди. Зариф абый җавап биргәч, теге офицер, ярсып:

—Берегез әйтә, унбиш, ди, икенчегез, егерме, ди. Сезне камчы белән сыйларга кирәк!—дип, кулын күтәрә.

Шунда Зариф абый мундирының якасын рәтләп куя, сынын турайта. Алыптай гәүдәле крәстиәннең күкрәгендә Георгий тәресен күреп, теге офицер югалып кала. Тиз генә атыннан төшә дә тыйнаксызлыгы өчен гафу үтенә. Мөгаен, хәрби бүләккә хөрмәт күрсәтү белән бергә, монда әле бу бүләкнең нинди кыюлыклар кылган өчен бирелгәнен аңлау да үзенең ролен уйнагандыр. Офицер, мөгаен, бу пәһлеван дуласа, өчебезнең дә башына җитмәгәе, дип тә уйлап алгандыр, шөбһәләнгәндер... Гаҗәеп дәрәҗәдә җитез була Зариф абый. Койма янына килеп, койма башына кулы җитсә, күз ачып күз йомганчы икенче якка сикереп төшә икән.

Бөтендөнья сугышы артыннан Ватандашлар сугышы да туктап, илдә тыныч тормышлар башлангач, кайтып төшә Зариф абый туган илгә, төп йортка. Әмма озак тормый—сәфәренә җыена башлый. Апасының:

—Бер дә хат язмыйсың. Әллә нигә бер генә булса да хат язсаң, кайларда яшәгәнеңне, хәлеңне белеп торыр идек, ичмасам,—дигәненә каршы:

—Хатлар яза башласам, хәлләр мөшкел дигән сүз булыр. Исән-сау, матур гына дөнья көтсәм, язып тормам, бигайбә...—ди икән.

Җир йөзендә иң якын, иң мәрхәмәтле кардәшләребез—Зурәптәйләр. Гәрчә әниемнән өч-дүрт яшькә генә өлкәнрәк булса да, искиткеч чибәрлеге һәм житезлеге белән, әлбәттә, утырып калмый, бәлки әле бераз иртәрәк тә, унҗиделәрдә үзбаш дөнья көтә башлый—Аптелгайни бабайларның ишле тармагында үскән үзе матур, үзе таза Шакирҗан исемле егетләренә ябышып чыга. Кызларына Сара, малайларына Таһир, Фарук, Фариз, Шәфикъ дигән заманчарак исемнәр кушыла. Тупырдап торган балалары береннән-бере таза да, береннән-бере чибәр булып, кече яшьтән кул арасына керә баралар, һәркайсы уңган да таза булып җитлегәләр.

Озатып куялар шул өенә хәтле.

Зурәптәйләр дүрт-биш бала белән такы-токы гына яшәп яткан бер заманда... алар бәхетенә кумәкләшү дигән бернәрсәне уйлап чыгаралар. Шакир җизни колхоз эшенә үзе генә түгел, Таһиры һәм Сарасы белән ургыла. Алар бик тиз ударник исеме алалар. Ә көзге якта уңышларны җыеп алгач, аларга өч кешенең хезмәте хакын олау-олау китерәләр. Әнә шул рәвешле Зурәптәйләр тиз арада тернәкләнеп китәләр.

Таһир әбзәй мәһабәт гәүдәле, искитәрлек дәрәҗәдә таза да матур егет булып исемдә калган. Минем ише бала-чага белән аралашырга аның вакыты-җае да булмагандыр инде. Эш тә эш. Сабан туйларында көрәшү, батырга калу традициясен ул башлап җибәрә. Колхозыбызга кайткан беренче тракторларны иярләүчеләр арасында да Таһир әбзәй булды сыман. Һәрхәлдә, трактор ише замана техникасына ул энекәшләрендә дә мәхәббәт уятып калдырды. Атаклы Фатих мулланың тулган айдай түгәрәк йөзле Гөлсем атлы чибәркәен каратырлык булгач, төшеп калганнардан булмаган инде. Бергә-бергә яшәүләр, бәхет-сәгадәт кенә үзенә насыйп булмады... Ире сугышка китеп, беренче елда ук кара кәгазе килсә дә, Гөлсем җиңги әдәп саклый, ирен көтә, кискән икмәк телемедәй әниләренә әйләнеп кайтмый, иренең йортын үз күреп, шунда тугрылыклы хезмәт итә.

Фарук абый гәүдәгә бераз калышрак булса да, гаҗәеп зур көчкә ия, төскә-биткә чибәр генә, мин белгәндә инде кара тут йөзле шадра бер көяз егет иде. Без бәләкәйрәк чакта, әнигә йомышы төшеп, безгә сугыла да, балчык ызбасының кысан һәм карсак булуына исе китеп:

—Ни дай бог!—дип сөйләнә.

Апа моны отып кала да әнидән моның нинди сүз икәнен сорый.

—Алла күрсәтмәсен, дигән икән,—ди әни, хәйран гарьләнеп.—Кара син ул шадра пәрине! Син үзең ни дай бог!

Икенче бер юлы мин аръякка укырга барганда, күперне чыккач, мине куып җитә дә:

—Мә, нәнәм, кеше алдында ашарсың,—дип ике печенье суза.

Сугышлар бетеп, Таһир абыйның кайтмаслыгы тәгаенләнгәч, Фарук абый белән Гөлсем җиңги рәсми төстә никахлашалар һәм, ишле генә гаиләгә нигез салып, бергә-бергә тату гына озын гомер кичерәләр. Уллары-кызлары барысы да үзләре кебек үк чибәр һәм таза булып үсәләр, аннары инде кайсы Ульянга, кайсы Буага таралышып бетәләр, ягада төпләнеп калалар, тормыш корып җибәрәләр.

Озак еллар авылыбызга кайтмый торып, сукмакны янә яңарткач, туп-туры Фарук абыйларга кайтып төштем. Җиңги белән икесе дә ачык чырай белән каршы алдылар. Икесе дә әле таза-сау, икесе дә аяк өстендә иделәр. Кайткан саен матур гына сөйләшеп, элеккеге хәлләрне искә төшереп утыра идек. Җиңүнең илле еллыгына кайтканда гына, тәмам тугарылып калганнарын күреп, күңел әрнеде.

Кызганыч ки, минем кордашлар да, бераз олырак лар да мәчет картлары булып йөрүгә кызыгалар. Хәзрәтнең Коръән укыганын сабыр гына тыңлап утыралар, ана телендә сөйләгән вәгазьләрен исә аңласалар да, аның киңәшләрен тотмыйлар: эчеп исерү ләззәтен һәммә нәрсәдән өстенрәк күрәләр...

Җиңүнең илле еллыгын авылда гаять зурдан кубып уздыралар. Аз санлы фронтовикларга аеруча зур хөрмәт күрсәтәләр. Шуның нәтиҗәсендә безнең Фарук абый Иске Шәйморзадагы шифаханәгә эләгә. Кәеф-сафа кылуны дәвам итәргә ниятләп, анда да аракы таптыра. Таләбе үтәлмәгәч, өенә кайтарып куйдыра. Мин инде, үземчә, аны олылап, Җиңү хөрмәтенә тегесен-монысын, тагын хәйран затлы коньяк алып кайтам. Җиңги әйтә:

—Бераз-бераз гына тотарсыз да, аннары калганын яшереп куярмын,—ди. Һәм шулай эшли дә.

Кичен кайтсам, теге күчтәнәчкә дигән затлы шешә табылган, бушаган, өстәл астында аунап ята. Фарук абый үзе шул тирәдә үк караватта яткан җиреннән:

—Синең теге кара сумкаңдагы шешәдә нәрсә ул?—дип кызыксына.

Юлда эчәргә алган чәй икәнен белгәч, кулын гына селти. Иртәнге яктагы затлы шешәне бушатканнан соң эзләнеп йөргән икән. Газлы су сала торган зур шешәнең яртысыннан артык шундый ук саргылт нәрсә күреп, бик сөенә бу, стакан-мазар эзләп тормыйча, тегесен бушаткан кебек, монысын да шешә авызыннан ук голт-голт итеп йоткалый, әмма бер дә тегенең зәһәрлеге сизелмәгәч, аптырабрак кала. Тагын татып карый, алданганын аңлагач, татлы коньяк урынына нindидер аңлаешсыз нәрсә салып

куючыларны аты-чуты белән сүгеп ташлый...

Туганнары арасында, мөгаен, иң куәтлесе Фариз абыйдыр. Зурәптәй үзе аны Зариф абыйга охшата иде. Ничәмә-ничә ел буена Сабан туйларында батыр кала. Тракторда да эшли ул, комбайнда да, башка эшләрдән дә йөз чөерми. Нишләптер аның табын янына утырып ашаганын күз алдына китерә алмыймын: йә ул хуш исләр бөркеп торган зур түгәрәк ипинең саллы гына кыерчыгын каерып ала; йә урамнан кабаланып килеп кергәч, ике өй арасындагы өйалдында аркылы матчадагы элмәккә эленгән чиләкне күреп, шундагы сөтне чөмерә. Табын янына утырып ашарга, мөгаен, вакытын җәлләгәндер.

Буденный районының үзәге Иске Шәйморзада чакны ул анда нинди дер эш белән барып чыга. Ике катлы бинага урнашкан дәүләт оешмасы янында җыелган халык арасында таныш-белешләрен күреп, яннарына килә, күрешә, нишләп монда җыелганнарын сүз уңаенда гына сораштыра.

—Урманга сыяр, кырга сыймас вана шул шкафны икенче катка ничек менгезик, дип баш ватып торабыз әле...

Шунда гына күреп ала Фариз абый иләмсез ул шкафны. Ике дә уйламый, шкаф янына барып, суккалап карый, агач басмаларга күз төшереп ала да:

—Егетләр, кая, булышыгыз әле аркага салырга?!—дип, җыелган халыкны шаклар катыра.

Хәйран таза, матур Фариз абыема калавыл кызлары да гашыйк булмый калмагандыр анысы, әмма ул үзебезнең авылда туып-үскән, бергә-бергә спектакльләр куеп йөргән, ТБУМда укытучы булып эшләгән искиткеч чибәр Сылу апа белән гаилә корып җибәрүне кулай санады. Шуннан алар авылыбызда әллә ни тоткарланмадылар—Ульянга китеп, йорт салдылар, бала-чаганы шунда аякка бастырдылар.

Олы малайлары Әлварис КАИга укырга кереп, бездә яшәгән чакларда Сылу җиңгиләр ешрак килә иделәр. Аннары Казанга килеп-китеп йөрүләре бераз сирәгәя төште, анысы табигый хәл. Үтеп-сүтеп йөргәндә икенче уллары Фирнат та, әнисенең чибәрлеген алган төпчекләре Венера да читләтеп үтмиләр болай үзе, туган итәләр, бик-бик якын күрәләр. Монда, әлбәттә, Фәүзия апамның роле зур: әледән-әле телефоннан сөйләшү белән генә канәгатьләнмичә, Ульянга иренмичә барып, хәлләрен белеп кайткалый. Үзара фидакяр мөгамәләгә корылган туганлык хисе, аралашу алдында чал башыңны иярга мәҗбүр буласың.

***

Рәхмәт төшкере, Зурәптәйләрдә беркадәр яшәгәч, көннәр акрынлап җылыга борылгач, үзебезнең балчык ызбабызга күченү ягын кайгырта башладык. Гәрчә беркем караңгы чырай күрсәтмәсә дә, җәйгә хәтле яшәгез әле, дисәләр дә, аларның һәркайсының чын күңелдән кыставына ихлас ышанган хәлдә, мең-мең рәхмәтләр әйтеп, кеше өстендә күпме яшәп була инде, әзрәк оят кирәк дип, күченеп тә куйдык. Зурәптәйләрдән тегесен-монысын, уфаллаларын ала торып, үз көнебезне үзебез күрә башладык.

Ягу ягына һич тә аптырамадык, әниебез кайгысын күргән бәп-бәләкәй мичебезгә айбагар сабагы, камыл ташып өйне җылы тотарга иләшеп киттек. Уфалла тартып әни белән кырга чыгабыз да рәхәтләнеп камыл йолкабыз, аны арбага коелмаслык итеп һәйбәтләп кенә бәйләп куябыз. Хәер, әнә шул көн саен кабатлана торган шөгылебездә бер аянычлы хәл булып алды алуын...

Ара-тирә без Диңгелде дигән коры тирән елганың аргы ягына чыгып та камыл җыйгалыйбыз. Диңгелденең гәрчә ярлары яман биек булса да, кар сулары китеп беткәч, суы тап-тар шарлавык булып төбендә генә кала. Әнә шул су аркылы рәхмәт төшкере авылдашларыбыз ике такта салганнар. Диңгелденең бер ягыннан икенче ягына чыгасың килә икән, син инде бәләкәй арбаңның ике тәгәрмәчен дә әнә шул такталардан туп-туры алып барырга тиеш буласың. Арбаң буш булганда бер хәл, ә менә йөк төялгәч—бигрәкләр четерекле синең хәлләр.

Бермәлне олавыбызны әлеге такталардан ипле генә алып чыгып, кечтеки генә үрне дә менеп, җәенкерәк җирендә бераз хәл алырга уйладык. Әмма сират күперен уңышлы гына кичүебезгә сөенергә дә өлгермәдек—уң куллан күкләр күкрәтеп, янаулы мөгрәгән бер хәтәр тавыш ишеттек. Ни күрик, безгә табан салмак кына атлап тау хәтле мир үгезе килә. Аның әледән-әле үкерүен ишетү, аска салган йөнтәс башын, ул башның ике ягында

тырпаешып торган очлы мөгезләрен күрү—ял итү ише ваемсыз ниятләребезне бик тиз җилгә очырды. Безгә ничек кенә булса да олавыбызны ул явыздан саклап калырга кирәк иде. Моңа ирешү өчен фәкать бер генә юл—тау башына тизрәк менеп җитү зарур иде. Уфалланы мин алдан тартам, әни бар куәтенә арттан этеп килә. Каян алганбыздыр шулчаклы тиз менәрлек көч—әле хәзер дә аңларга һич башым җитми. Ничек итсәк иттек, әмма дәртләнеп бер талпынуда тау башына менеп җиттек. Теге хәерсез мир үгезе безнең турыдан үкерә-үкерә үтеп киткәндә, без инде аны тыныч кына югарыдан күзәтә ала идек.

## Канатлы мәхлуклар

*Тау башына салынгандыр безнең авыл,*
*Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;*
*Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,*
*Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.*

Габдулла ТУКАЙ

Авылыбызның кыл уртасыннан бормаланып ага торган Кече Чынлы инешенең холкы әллә нинди: язгы ташу вакытында суы күтәрелеп, ярларының ике ягына да җәелә, болыннарны ялмап алу белән генә чикләнмичә, кибән хәтле бозларын тизрәк агызып бетерергә омтылгандай, тау елгаларын хәтерләтеп, ургылып ага да ага—бимазалап торган күперләрне җимерә-вата, юл өстендәрәк торган мунчаларны эһ тә итмичә агызып алып китә. Мәгәр аның ярсуы-дуамаллануы ике-өч көннән ары бармый, суы да атна-ун көн эчендә ярларына кайтып төшә, янә дә берәр атнадан кимегәннән-кими бара, җәйгә таба исә бөтенләй саега, бала-чага коенырлык та суы калмый, каз-үрдәкләрне генә үз өстендә тибрәндерә...

Авылның һәр ике ягында инешкә табан юлланган елга-ерынты бихисап. Шуларның бигрәкләр иләмсезе, дию карчыгының авызыдай ерылганы—безнең урам кырыннан уза, гүя кечтеки генә тәрәзәләребезгә карап күз кыса—безне урамга уйнарга чакыра. Ул үзе югары урамнан ук башланса да, бер тыкрыкны сизелер-сизелмәс кенә, мыштым гына уза, әмма олы урамга җитәрәк ел саен тирәнрәк үрмәләвен белә, инде күпер астыннан да чыккач, әллә кайларга төпкә үк сикерә дә гөрләвек хасил итә. Дию карчыгының авызы нәкъ әнә шуннан башлана да инде. Инешкә җитәрәк ул бөтенләй дә җәелеп китә, сулары да саега.

Без үскәндә ул чокырның ярлары гаҗәеп биек, ә инде иң төптәге су юлы аркылы такта салынган булыр иде. Ни хәл итмәк кирәк, дөньяның бит карт-корысы, хатын-кызы бар. Кая инде ул аларга чокыр төбеннән аккан су аркылы безнең шикелле сикерүләр, алар бит әле кыр кәҗәсе хәтле дә сикерә алмыйлар.

Ул чагында әле ярның бу яктагы якасында безгә каршы өч-дүрт йорт булып, аларның һәркайсы, чокырга ачулангандай, сырты белән утырган, тәмам йөз чөергән иде. Бәрәңге бакчалары кайда булгандыр инде, һич башыма сыймый. Анда әле бакчасыз да, яр убып китмәгәе, дип дер калтырап торалардыр... Кышкы тымызык кичләрнең берендә ул яр упты бугай шул—балчык ызбалары уртасында кукыраеп утырган ыспай гына, җыйнак кына агач йорт кичен бар иде, иртәгесен... гүя җилгә очкан.

Кичтән ишелеп-ишелеп кар яуды. Әбием иртә таңнан уянып китсә, каршыдагы йорттан... җилләр искән! Әбием инде карт кеше, "бик күп яуды шул кар, әнә, күршеләрнең өен гел күмеп киткән",— дип сукрана-сукрана, иртәнге намазын укырга әзерләнә. Шул чагында тәрәзәдән ике-өч ир-атны күреп ала. Йорт түбәсенә менгәннәр икән дә әлеге карны көрәргә җыеналар икән, дип фикер йөртә. Ныклабрак караса, өй түбәсендә түгел икән теге кешеләр, җирдә йөренәләр, үзара нидер сөйләшәләр икән ләбаса! Тукта, йортлары кая качкан соң әле? Кичен бар иде ләбаса! Чуашка яисә мукшыга сатканнар дисәң, бер төн эчендә сүтеп-ташып өлгерә алмас иделәр. Җир упкан, бер дә бүтәнчә түгел! Шаклар катып, догасын укый-укый, әниемне уята:

—Ләйлиҗамал, тор әле, тор! Афәт килде, әнә, күршеләргә ябырылды, безнең тарафларга да канатын җәймәгәе...—ди.

Әнием тәрәзәдән урамга күз салса, яшьрәк кеше бит, янгын булганын, кар астында бүрәнәләр пыскып ятканын шәйләп ала. Бер исәп белән, бала-чаганы да уятып, ничек

булса да уттан качып котылу ягын да уйлап ала; аннары ашыкмаска була. Башта урамга чыгып, хәлне бераз ачыклап кирәргә ниятли. Әбинең килешми хәле юк: ире ягада чакны йорт хатын кешегә йөкләнә. Әниләрнең пышылдап кына сөйләшкәнен беравык тыңлап яттым әле: серләре бардыр, югыйсә таң тишегеннән уянып, алай шыпыртлап сөйләшмәс иделәр әле, миңа, егет кешегә, сер сыймас, дип чишмәскәдер әле исәпләре...

Берни аңламыйча, башымны калкыттым да тәрәзәгә табанрак авыштым. Адиҗан белән Әнвәрне күргәч, йокым шундук качты. Нишләп йөриләр икән инде минем дуслар анда? Чыксам, ни күрим—Майҗан әптәйләрнең йортлары янып, кара күмергә әйләнгән. Дуслар диген инде Әнвәр белән Адиҗанны—шунда кызык күрергә мине дә уятсалар, ни була инде?!

Ул арада кызыкка юлыгып, ачуымның эзе дә калмады. Каз мамыгыдай йомшак кар астыннан төтен исен абайлап, бергәләшеп чабаталарыбыз белән карны як-якка тибәрә торгач, янып бетмәгән дәү бер кисәүгә, дөресрәге, бүрәнә башына юлыктык. Аннары тагын берсен казып чыгардык, тагын...

Мәшәкатьле бу уеннан туйгач, тирән кар эченнән мәтәлешеп кенә ярдан төштек тә, йомшак карга билдән чума-чума, көлешә-көлешә, Фатыйхлар ягына үрмәләдек. Шундый кызык көнне йоклап ятмасын әле, чыксын да уптым илаһи карга чумдырыйк үзен!

Фатыйх атлы дус малаем арада бер үзенчәлекле иде. Ихтимал, миннән берәр яшькә олырак та булгандыр. Анысын төгәен әйтә алмыйм, тик инде гәүдәгә шактый калкурак һәм ныграк булуы бәхәссез. Аның белән бергә-бергә бик еш безгә сугыла торган идек. Шуларның берсендә әнием аңа сорау бирә:

—Фатыйх, син үскәч кем буласың?—ди.

Теге күзен дә йоммый:

—Үскәч, мин ягага китәм. Ягада бик күп акча төшерәм дә әтәйгә тула оек белән шәп кенә чабата алып кайтам,—ди.

Хыялының чабатага сыеп бетүе миңа бик мәзәк тоелды, шулай да мыскыл итү, көлү безнең арада юк иде, һәм мин үзалдыма көлемсерәү белән чикләндем. Әни исә:

—Әтиләреңә бүләк алып кайтуны уйлагач, син акыллы малай инде, Фатыйх,—дип аның ниятен хуплады.

Кичен, мин сүз кузгаткач, әнием:

—Нишләсен соң... Әтисе ямьшәеп-тузып беткән чабатасын кигәндә: "Их, булса иде юньлерәк тула оегың, шәбрәк яңа чабатаң",— дип зарлангандыр, бичара...—дип нәтиҗә ясады.

Фатыйхларның шатрун түбәле зур агач өйләре әлеге тирән чокырның аргы ягында, олы урамга карап тора, күпер янында ук. Садыйк әбзәй безнең авылга читтән килгән, тап-таза егет чагында ике малайлы Камилә әптәйгә йортка кергән, дустым аның үз улы иде. Өйләре әллә кайдан күренеп тора, эче дә бик иркен иде. Бәрәңге бакчалары кырыенда, яр өстендә үк мунчалары булып, әнием һәрчак шулар мунчасын яга торган иде. Авыл мунчасы дигәндә әнә шул әйбәт кешеләрнең кара мунчаларын күз алдына китереп, әниемнең каен себеркесе белән чапкан чакта:

—Картны күрсәң—бабай диң, яшьне күрсәң—абый диң...—дия-дия көйләгәнен гел исемә төшерәм.

Дустымның зур абыйсы бездән шактый олы булып, гаиләләрендә ничектер бүтәннәрдән аерылып торыр иде: үзе чандыр гәүдәле, үзе гаять монсу, үзе... Иң әүвәл күргән музыка уен коралым скрипкә булды. Аны әлеге моңсу егет Рәхимҗан әбзәй мунчалары артына алып чыгар иде дә, башын кырын салып, сыздырып уйнап җибәрер иде. Ул уйнаган моңлы көйләрне гүя әле бүген дә ишетәмен, ялгызы моңаеп уйнаганын, кызгылтрак скрипкәсен һәм уң кулындагы салмак кына йөреткән сызгычын гүя әле дә күрәмен. Иң беренче гыйшкым Рәхимҗан абзый кулындагы моң тулы сихри инструмент булды. Беренче мәхәббәт—гомерлек!.. Әлеге хәлне мин теләсә нинди җан иясенең күзе ачылганда иң әүвәл күргән затны гомере буе оныта алмавына тиңлим.

Каян килсен ди ул кулак малаена уенчык ише нәрсә?! Әле ярый, затлырак әйберләребезне үз өйләренә ташыганда, өебезне сүттереп сатканда, мал-туарыбызны алып чыкканда бәреп имгәтә алмаганнар—"Елгабыздан акмасын кулак каны!"—дип, йортыбызны вәйран итү, үзебезне урамга ач-ялангач себереп түгү-чыгару белән чикләнгәннәр. Әле ярый, әниебез уңган зат булып, канатлары астына яшереп саклап калган, иркәләп тә юмалап, ике бите белән җир себереп үзебезне үстергән, кече яшьтән

кул арасына керергә—эшкә өйрәткән. (Җаны җәннәттә булсын!)

Бермәлне, өйдә үземне генә калдырып, әни Зурәптәйләргә нидер өметләнеп барырга җыена. Өйдә ялгызым гына каласым килмәгәндер инде:

—Мин дә барам!—дип, ишек төбенә киләм.

—Синең белән озак йөрелә, мин хәзер әйләнеп кайтам,—дип, әни кесәсеннән өч тәңкәлек кәгазь акча чыгарып, миңа суза:—Мә, уйный торырсың,—дип тә өсти.

Бер яшел акчага карыймын, бер әни артыннан ябылган ишеккә —һич ризалашасым килми генә бит. Аптырагач, әнине өркетергә исәпләп:

—Мин бит аны барыбер ертам!—дип ычкындырам.

Әни ялт кына ишекне ача да:

—Әһә, ертасыңмыни әле? Китер, алайса,—дип акчаны да ала, ишекне ябып, аңа йозак та сала.

Гарьләнүемнән кая барып бәрелергә белмимен. Нишләп ертыйм ди инде мин аны?.. Нигә андый сүз ычкындырдым икән?.. Йә, дивана түгел диген инде мине!.. Ичмасам, шул яшел кәгазьнең бизәкләрен караштырыр идем...

Уңышсызлыкка юлыкканда иң әүвәл үз-үземә ачулану гадәте, ихтимал, әнә шул заманнардан ук киләдер.

Әбинең тәсбихен сорап алып, анынча тартып караганым булмады түгел дә бит, күпме генә юана ала сабый андый җитди нәрсә белән... Хәер, бер мәзәк шөгыль таптым табуын да, аның да ахыры кызык чыкмады—үземне берәү дә мактамады, менә булдыргансың, егет икәнсең, димәде...

Мич башыбыз иркен иде, анданиләр генә юк! Минем игътибарны әбинең киез катасы җәлеп итте. Зур борынлы, йомшак кына ката. Кунычы кайтарылган. Шул кайтарылганын турайтырга ничаклы гына тырышсам да, булдыра алмадым. Хәлемнән килмәгән нәрсәне алай гына ярты юлда ташлап калдыру гадәте сабый чактан юк иде, ничек тә әмәлен җаен табарга булдым. Егет кешенең башы тиз эшли бит аның. Мыштым гына мич башыннан төштем дә ипи пычагын алып мендем, аннары кунычының кайтарылган җирен черт иттердем. Ләкин ул кунычны турайттың ни дә кайтардың ни—барыбер икән ич! Бу мавыгу бик тиз туйдыргач, икенчесен кисеп тә азапланмадым.

Орышмады да әби, сукмады да, бары тик башын селкеп:

—И-и-и, улым...—дигәне хәтердә.

Әле тагын әтинең хәтсез зур, хан заманыннан калган счеты бар иде. Төймәләре, синең нәни генә бармагың кагылганны көтеп, бере арты бере йөгерешергә әзер торалар. Ә инде учың белән югарыдан түбәнгә таба сыдырып алсаң, бик озак тәгәрмәчтәй күчәрләре тирәсендә әйләнәләр, шул ук вакытта гүя бер-бере белән качышлы да уйныйлар. Кулыңны кызурак йөрткән саен тәгәрмәчләр дә тизрәк әйләнә. Счетны әле тагын, бер башына бау бәйләп, идән буйлап тартып йөрсәң дә була. Тик менә туфрак салсаң, шундук коелып бетә. Хәер, җир идәннең бер почмагыннан туфракны икенче почмагына ташу өчен бездә бер агач тартма да бар. Андый эшкә хәйран кулай нәрсә. Җитмәсә күп сыя үзенә. Түгелми дә. Элек бер почмакка ташып өясең, аннары икенчесенә. Кызык инде, бик кызык. Ара-тирә, атны әйдәгәндәй:

—На-а-а, хайван!—дип куйгалыйсың.

Атыбыз юк шул безнең. Әти кайтса, алып кайтыр иде дә берәр ат, кайтмый бит, Ленинградта эшли, ди...

Кече Чынлыда безнең өебез Тау ягындагы аркылы урамнарның берсендә, инеш буендарак, күпергә якын гына иде. Кендек каным тамган нигезнең урынын 2000 елда төшереп кайткан идем, төсле рәсем язу өстәлемдә, Н.Рерих картиналарыннан күчермәләр белән бергә күз алдымда тора...

Әнә шушындагы балчык ызбасыннан арьяктагы башлангыч мәктәпкә йөреп укыдым. Ул чагында укырга сигездән керәләр иде, мин дә бик ашыкмадым. Берәр ел гына элек инешебез аша иләмсез зур күпер салып куйганнар иде, шуның аша укырга йөримен. Бермәлне шулай укудан кайтып килгәндә, күпергә җитәрәк бер картны очратып сөйләшкәнем нишләптер хәтергә сеңеп калган. Әнинең мунчада үземне лач-лач каен себеркесе белән чапкан чагында: “Картны күрсәң, бабай диң...”—дип әйткәнен һич онытасым юк. Танымасам да, әдәп саклап, ерактан ук:

—Нихәл, бабай?!—дип сәлам бирдем.

—Ай, якшы, әле улым!—диде картым, минем янга житәр-житмәс туктап калды.—Әллә мәптектән кайтасың инде, укыйсың мәллә?

—Укыйм шул!—димен, әти фанердан ясап биргән, сары-кызыл, яшел-зәңгәр шакмакларга буялган үземнән зур сумкамны алга-артка селеккәләп аламын.

Бабайга бу бәп-бәләкәй малайның шулай зурдан кубып сайравы, мөгаен, кызык тоелгандыр, һәм ул сораштыруын дәвам иттерде:

—Ничәнчедә соң, улым?

—Беренчедә инде!..

Картым болай да ачык чырай белән, елмаеп күңелле итеп сөйләшә иде, шуңа күрә үземнең әлеге җавабымнан соң да аның чыраенда үзгәреш-мазар абайламадым. Көлемсерәмичә булмагандыр инде, сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәгәндер, дигән уй башыма соңгарып килде, һәм әнә шул уй хәтеремә сеңдергәндер дә инде.

Икенчегә үзебезнең якка йөрдем. Манарасы киселгән үз мәхәлләбезнең мәчетендә укыдык. Әллә тәнәфестә, әллә дәресләр беткәч, гаять зур һәм биек тәрәзәләр янына өелешәбез дә күк йөзендә ачылган болытларны бүлешәбез, алардан төрле-төрле сурәтләр ясаштырабыз...

Әбермәлне югары очтагы йортларның кайсы матуррак икәнен ачыкларга тотынабыз. Шунда бәхәс кубуы табигый хәлдер инде, һәркемнең үз бизмәне:

—Фәләннәрнең өе матур!

—Юк, тегәннәрнең йорты матуррак!

—Юк шул менә!..

—Фәләннәрнеке ямьсез матур!

Уйламыйчарак, ашыгыбрак әйтелгән сүзне ишеткәч, һәммәбез дә сагаеп калабыз, аннары инде кайсыбыздыр:

—Шулай икән шул: үзе ямьсез, үзе матур...—дип куя.

Без елмаешабыз, әмма сабакташыбыздан көлү, мәсхәрәләшү ише нәрсә безгә хас түгел иде.

Дүрт-биш елдан авылыбызга әйләнеп кайткач, алты-җиде сыйныфларны ТБУМда тәмамладым. Шул елларда укымаган китабым калмагандыр. Мәктәптән кайту белән, ашыйм-эчәм дә бәләкәй генә тәрәзәбез каршына китап алып утырам. Каршыбыздагы кәнсә янына малайлар җыела, уйныйлар, көрәшәләр, карда ауныйлар... Ә мин алар ягына ара-тирә күз генә төшергәлим дә үҗәтләнеп укуымны дәвам иттерәм—китаптан һич аерыла алмыймын...

Казанга китеп, өч-дүрт ел имин генә яшәгәннән соң, Ватан сугышы башланып, без әтидән мәхрүм булып, ятим калдык. Әти кулга алынгач, авылга кайтып, Зурәптәйләрдә кич кунгач, таң тишегеннән сөйләшкән тавышлар ишетеп, уянып китсәм, ишек төбендәге мине яткызган тимер караватк башыннан дустыма охшаганрак таза да, зур да яшүсмерне күреп алдым. Исеме белән дәшәр идем, Фатыйх булмас, артык зур бит, дип шикләнәм. Тагын кем булсын инде шул чаклы ерык авыз! Ул арада кунак үзе телгә килде:

—Кыямдин кайтканны ишетүгә, торып чаптым. Ашарга да утырмадым.

Бу чаклы да сагынган дустыма елмаймыйча булдыра алмадым.

—Әйдә, тор, Кыямдин, авылда алай озак йокламыйлар. Сәгать алты инде.

Гәрчә тазалыгы белән калкурак булуы шикләндерсә дә, елмаюы белән гөлдерәвек тавышы бу минем дөньяма сабый чаклардан йөгереп килеп кергән дустым икәнчегенә ышанырга мәҗбүр итте. Аның әрсезләнеп караңгылы-яктылы атылып килеп керүе дә, тартынып-нитеп тормыйча әмер бирүе дә мине йомшак җылы түшәктән бик тиз кубарды.

Фатыйх белән ул көнне кайларга барып, ниләр күреп йөргәнебез исемдә калмаган. Тик инде, беркадәр сипләп, салынкырак күренгән түшәменә терәүләр куеп, мичен рәткә китереп дигәндәй, үз өебезгә чыккач, без аның белән еш күрешә торган булдык.

Янә Казанга китеп, озак еллар буена аралашмагач, кайтып, сорашсам—фаҗигале үлемен ишетеп, имәнеп китә яздым...

Әнвәрләрнең өйләре безгә каршы йортның түбән ягында, инешкә табарак иде. Кергәнем бар аларга, кермичәни... Өй эчендә әллә ни шаклар катарлык нәрсә күрмәдем шикелле. Тик инде өс-башлары бөтен иде. Әти-әнисенең дә, Әнвәр белән сеңелесенең дә.

Әнвәр үзе тыныч кына, сабыр холыклы малай иде. Акыллырак булгандыр инде безнең ише ерык авызлардан. Тик ул һәрчак безнең белән бергә әвәрә килә, бер дә инде менә читләшми иде.

Мин белгәндә алар каяндыр ягадан кайткан иделәр, ике-өч ел гына авылда яшәп алдылар да яңадан ягага шылдылар...

Адиҗан—сабый чаклардагы дусларымнан бүгенгәчә авылыбызда яшәп яткан бердәнбере. Буйга минем хәтле генә булса да, аның кул-аяклары да, җилкәләре дә ныграк иде кебек. Без бер-беребезне бик яхшы аңлый идек, сүзгә килгәнебез, нидер бүлешә алмаганыбыз булмады. Карап торышка ул беркадәр тупасрак, пырдымсызрак күренсә дә, бигрәк сабый күңелле, кешегә ышанучан, самими зат булып исемдә калган. Вагонстройда да без аның белән бик нык аралашып, тату яшәдек. Безнең күрешүләр көн саен булмаган икән инде—моңа фәкать үземне мавыктырган, бер генә минутка да аерылырга ирек бирмәгән исәпсез-хисапсыз китаплар гаепледер...

Аның әтисе Миначетдин бабай (нигә "бабай" дигәнмендер инде—һич аңламыйм) әтиемнең гомерлек җан дусты булып кала килде. Эре гәүдәле, бераз тупасрак йөзле, зур борынлы, кабартма иренле, күкрәктәй киң һәм озын куллы, гаҗәеп дәрәҗәдә сүзле, искиткеч уңган һәм эшчән зат иде. Алар авылның зур байлары булып, элегрәк туздырганнар—коры казыкка калдырганнар. Хәтерем алдамаса, Минач бабай Сабан туйларында халык алдында чыгып көрәшергә һичбер вакыт базмады, тыйнак булды. Әмма чалгычылар ярышы оештырсалар,—ай-һай ла! —Кече Чынлыдай зур авылда аның белән тиңләшердәй кеше табылыр иде микән?! Һәрхәлдә, аның кебек эре адымлы, ул чаклы киң колач белән алдырып барырдай чалгычыны башка очратмадым.

Әнә шул әзмәвер минем әтиемә гомере буе турылыклы булып кала белде. Безнең өйдә кунак-мазар җыелса, әти аны чакырырга онытмас иде. Минач бабай түрдә кукыраеп утыруны, гомумән, бик үк өнәп бетерми иде бугай: анда утыргач, туктаусыз җырларга да сайрарга кирәк, аның исә бар белгәне—Варшавада солдат чакларын искә төшерүдән:

—Әх, гурт Варшау!—дип тавыш бирүдән һәм кувалдага тиң йодрыгы белән өстәлне бер "кашып" алудан гыйбарәт иде.

Авылда чакны аларның безнекеннән дә калышрак балчык ызбалары безнең каршыдагы тирән чокырның инеш белән тоташыр алдыннан иләмсез нык саегып та җәелеп киткән җирендә, бик түбәндә булып, аның янында бернинди каралты-кура яисә койма-капка ише нәрсәнең, бәрәңге бакчасының әсәре дә юк иде.

Адиҗанның әнисе Фатыйха атлы булып, өй эчендәге һөнәре гап-гади салма пешерүдән узмагандыр. Өйләренә ничә кереп, аны очратканым булмады бугай, чөнки ул күрше-күлән арасында киләп сарып йөрүдән бушамады сыман. Ире соң дәрәҗәдә юаш һәм тыйнак булып, хатыны чәрелдәвек тавыш белән әрепләшеп йөргәне хәтердә. Татар Убиенда бер бай гаиләсендә туып, кадер-хөрмәттә генә үскән, эшкә өйрәтмәгәннәр үзен...

Дустымның авырудан башы чыкмаган Сәлимә исемле апасы бар иде. Авылда ук чирләшкәрәк матур кыз бала, Казанга килгәч, мөгаен, җитлегү дәверен гаять авыр кичергәндер, балигъ була алмыйча ук, гомеркәе өзелде...

Без малайлар белән уйнап йөргән чакны кызыл канатлы бер күбәләк тирәбездә әйләнде дә тулганды гына бит. Аның кызыл канатларын ипле генә җилпеп очып йөрүеннән һич күзеңне алырлык түгел иде. Шул күбәләкнең матурлыгына сокланып:

—Бу берәрсенең җаныдыр инде...—дип акыл сатып куйганымны сизми дә калдым.

Шулчагында Адиҗан:

—Безнең апаның җаныдыр инде...—дип тыныч кына боегу белән әйтә куйды.

Чокырның аргы ягында, Адиҗаннар турысында Хәят әбинең биләмәсе иде. Аның иске генә агач өе төсен тәмам югалтып, муртаеп, тау башында кукыраеп утыра бирә. Гүя бу аның тау башындагы тәхете дә түбәнгә таба инешкә җиткәнче тезелешеп үскән зифа таллары—аның гаскәре. Каргалар оялый торган ярыйсы ук зур утрау булгандыр бу. Язга чыккан саен кошларның монда төрлесе җыела, кайсы кайчан концерт бирә. Узган-барган чакны каргалар каркылдавыннан колагыңны томалап котылсаң да, Хәят әбинең хәле мөшкелрәктер: көннәр-төннәр буе шул концертны тыңларга туры килә бит...

Ә безгә рәхәт. Сыбызгы ясыйсыбыз килсә, хәзер Хәят әбинең талларыннан берәр яшь ботакны пәке белән чеметеп алабыз да—вәссәлам. Шунда инде каргалар хорына безнең сыбызгы тавышлары кушыла.

Ә бермәлне минем искиткеч зур сыбызгы ясыйсым килде. Яшелрәк бер зифа гына талның беләктән калынрак ботагына күзем төшеп, өйдән балта алып килдем дә агач башына үрмәләдем. Дивана түгел диген инде! Әлеге ботакны шак та шок кисәргә керештем. Әле ярый берзаман Хәят әбинең:

—Ах, разбунниклар!—дип тирги-тирги, кулына чыбык тотып, таудан төшеп килгәнен абайлап алдым.

Ике уйларга вакыт калмаган иде. Чыбыкның сыртымда чыжлаганын көтеп тормадым—балтаны җиргә ыргыттым да шоп-шома талдан шуып төштем. Күз ачып күз йомганчы төшеп тә җиттем. Мәгәр күкрәгемне нидер көйдереп үткән иде. Карасам—агачтагы бер төер күлмәк үтәли сыдырып узган һәм алсу төстәге җептәй бер эз калдырган. Һәй, исең киткән икән! Балтамны эләктердем дә йөгердем генә. Кая ул Хәят әбигә минем арттан җитүләр!.. Сабый чактагы шуклыгымны саный китсәң, шактый гына булыр иде:

—әбиемнең киез катасын кистем;
—әтинең эшлиясен әрәм иттем;
—печәнлеккә менеп тәмәке тарттым;
—кыярдыр, сугандыр урладым...

Саный китсәң, аларның бихисап күп булуы ихтимал икән ләбаса. Ярар, җитәрдер, туганнар, барысын да санап тормыйк инде, бигайбә!

Авылда минем өчен гомерлек сер булып калган Иршат дигән дустым бар иде. Аның белән безнең юл-сукмакларыбыз әледән-әле кисешә килде.

Әйтик, Дәрвишләр калавылында мин бишенче сыйныфны тәмамламыйча кайттым. Көз көне янадан бишенчегә дигәнемне ишеткәч, Иршат бәхәсләшергә урын калдырмыйча:

—Сөйләмә юкны! Син бит инде бишенчедә укыгансың. Сабакташларың бөтенесе алтыга бара. Нәрсә, алар синнән акыллырак дип торасыңмы? Юк,—диде.

—Мин бит бишне бетермәдем шул...

—Бетерсәң-бетермәсәң дә, икәү бергә алтыга барабыз да керәбез.

Каршы тора алмадым, ризалаштым.

Шәйморзага барып, дәреслекләр сатып алып кайттык. Әдәбият үзем өчен кызык тоелды, җәй көне үк аркылыга-буйга укып та чыктым. Уби базарына баргач, китап кибетенә кереп, әдәби китаплар алып кайттым. "Сиваш"ны шулчагында укыганым хәтердә.

Казанда чакны рәсем ясау белән ара-тирә генә булса да мавыгып, авылга акварель буяуларымны алып кайткан идем. Иршат аларга сокланып үлә язды. Бер үк төснең ачыграк һәм куерак төсмердәгеләрнең әүвәл берәрсен, акрынлап кына юмалый-юмалый калганнарын да сорап алып бетерде. Дустың сораганда җәлләмәссең бит инде.

Безнең өйләребез инешнең ике ягында, бер үк урамда, якын гына иде. Тик шул араны да Иршат җәяү чыкмас, велосипедка гына атланып йөрер иде. Гәрчә күзе төшкән һәммә нәрсәмне шудырып бетерсә дә, күңел өчен генә, бер генә мәртәбә дә үзенең велосипедына атландырганы булмады. Бу хакта сүз кушасың икән, ул сиңа әллә нинди сылтаулар табып, байлыгына якын да китерми. Нәүмизләнеп каласың инде...

Алтынчыны бетергәч, җәй көне ул кәбестә-кыяр бакчасында каравылчы булды. Мин идарәдә йомышчы малай идем. Урып-җыю вакытында көнлек мәгълүматны әүвәл телефоннан хәбәр итәләр, аннары язма рәвештә җиткерәләр. Андый вазифа, әлбәттә инде, йомышчыга йөкләнә.

Ике тәгәрмәчле бәләкәй генә арбага яшь кенә атны җигәмен дә китәмен район үзәгенә. Кайчагында Иршат үземә юлдаш була. Юл буе сайрашып кайтабыз инде, икебез дә тел бистәсе. Менә бер заман юлда барганда кызлар кесәсеннән төшеп калган көзге таптык. Дустым аны, теленә салынып, кесәсенә шудырды. Икенче юлы ап-ак бер пар перчаткага юлыктык. Анысы да аңа кирәгрәк булып чыкты. Карап торсаң, йорт тулы сарык инде үзләрендә, тик әлеге табышка ул кызыккач, дустымны рәнҗетмим, дигәнмендер инде...

Җәйге көннәрнең берсендә мондый бер әкәмәткә юлыктык.

Шәйморзадан шулай икәүләшеп кайтып киләбез. Торна елгасы дигән сөзәк бер тугайлык аркылы салынган арба юлына бордырып алдык—тау ягыннан кайтырга инде исәбебез, мин яшәгән яктан. Хәер, кәнсәдән гел әнә шул юл белән "турыдан" суктыра идек сыман. Печәнне монда сирәк чабалар, анда да әле корырак урыннарны сайлап, бераз чокчыналар. Шуннан инде элекләре инеш үзәне булган, хәзер күпчелек урыны сазга әйләнгән тугайлык анда-санда әскәтер җәйгәнгә охшап кала.

Тыныч кына сайрашып кайтып килгәндә, берзаман безелдәгән-мезелдәгән тавышлар ишетәбез. Җиккән атыбыз ул арада борчыла башлады, купшы койрыгын шап та шоп

ботларына чаба, уңлы да суллы карана. Берәр яры каерып алып, сазлыка-мазар кереп батмагае дип шөбһәләнеп, дилбегәне кысыбрак тотамын.

Кучне без алдарак, юлдан бераз уң кулдарак күреп алдык: ниндидер карасу тасма әле бер якка, әле икенче якка сугыла, бер түбәнгәрәк төшә, бер югарыга ургыла, ниндидер мажор көйне көчәйткәннән-көчәйтә бара. Атны туктаттык та шул кучкә төбәлдек. Малайларның күзе үткен бит аларның—кара тасма бөтерелгән тирәдә ниндидер бер куакны шәйләдек. Без аның янынннан атны юыртып, һичшиксез, үтеп китә ала идек. Әмма без алай эшләмәдек.

Тилене бит аны чәчеп үстермиләр. Диваналык сыйфаты да картая-картая гына килми, тумыштан ук синдә була да сабый чагыңнан ук үзен сиздерә. Дилбегәне дустыма тоттырганчы, атны кире якка борып куйдым. Хәзер инде өркеп-нитеп китә калган очракта да олы юлга чыгачак. Тиз генә арбадан төшеп, әлеге куч янына якынлаша башладым. Бал кортларын йокы симертеп яткан аюга тиңләдемме, әллә бүтән берәр сәбәп булдымы, тик мин куч өеменә бик тә акрын адымнар белән бардым: өркетмәскә инде исәбем. Аларга якынлаша барган саен күпчелеге иләмсез зур шайтан таягына кунганын ачыкладым. Малай чакта баш минем ярыйсы ук тиз эшләгәндер, мөгаен, чөнки барган мәлгә үк өстемдәге күлмәгемне сыдырып салдым, аның яка-изүләрен җиңнәре белән бәйләп куйдым, кесәдән 6-7 яшьле пәкемне (мин аны, авылга кайткач, үземдәге әллә күпме значокка алыштырган идем) чыгарып, иң үткен пәкесен ачтым. Бал кортларына каршы пәке белән сугышырга бугай моның исәбе, дип көлми торыгыз, сабыр итегез, агай-эне. Чөнки мин киек җанвар житезлеге белән бердәнбер күлмәгемне шайтан таягына кигезеп, аны сул кулым белән кысып тоттым да уң кулымдагы пәке белән шайтан таягының аскы өлешен кисеп калдырдым. Кулымдагы "күлмәклесен" кызыл әләм урынына мөмкин кадәр югарырак күтәрдем. Шайтан таягына кунган корт анасын сарып алганнары күлмәк "кигән" булса да, иректә калганнары әле бихисап иде. Һәм алар шәрә тәнле малайны атакалау белән генә канәгатьләнмичә, олы юлдан чаптырган атыбызның да әледән-әле хәлен белешә тордылар—теңкәсенә тиеп, кызурак кайтырга куштылар. Чынлыга кергәндә инде аларның бер өлеше минем күлмәгемә һәм өстемә-башыма кунаклап өлгергән, башкалары исә юлда адашып калган иде.

Кулак йортының каралты-курасы да, капка-мазары да калмаган иде, табышыбызны туп-туры дустым йортына алып кайттык. Аларның каралты-куралары да бөтен, капкалары да нык иде. Уртак умартабызны аларның бакчаларына куярга булдык. Дустым житез генә капкаларын да ачты, ярыйсы ук тирләгән атыбызны да ихаталарына житәкләп алып керде, әллә кайлардан бер иске подаука да алып килде. Шуннан без табышыбызны шул подаука эченә салып, аны тип-тигез җиргә каплап куйдык, чыга алмасыннар өчен саллы гына таш белән бастырдык.

Ул арада Иршатның гомерендә дә колхоз басуына чыкмаган, кызлар кебек сакланган әнисе дә күренде, болдырдан гына безгә акыллы һәм файдалы киңәшләрен биреп торды. Аларның чыбык очы кардәшләре колхозның умарталыгында эшли икән дә әлеге канатлы мәхлукларның бөтен холык-фигыльләрен биш бармагыдай белә икән. Дустым әнә шул кардәш хатынны чакырасы булып, минем арттан капкаларын бикләп калды—бикле булгач, бал кортлары качып китә алмыйлар инде! Мин исә атымны кайтарып тапшыру дәрте белән үзебезнең якка юлландым. Икенче көнне дустымны көчкә эзләп таптым. Нишләптер минем ягыма карамавын абайладым. Ә мин бит аның янына очып килдем—тизрәк беләсем килде умартабызның хәлен. Шуны сорагач, дустым илтифатсыз гына кулын селтәде:

—Качып беткәннәр алар барысы да,—диде.

—Нәрсә, калай подауканы тишеп чыкканнармы?

—Подаука астыннан җирне казып чыкканнар да качканнар...

Дустыңа да ышанмагач, кемгә ышанырга кала соң! Бал ашарга насыйп булмагандыр инде, бал ашарга... Күр син ул канатлы мәхлукларның җир казу осталыгын!

Ихтимал, бу озын гомер эчендә кулак малаен, атасы төрмәдә үлгән бәндәне рәнҗетүчеләр күп булгандыр. Ләкин аларның берсенә дә ачу саклаганым, үч алырга яисә кару кайтарырга маташканым булмады. Мишәр ягында халык ярыйсы ук усал бит, анысы берәүгә дә сер түгел. Мәгәр миңа ничектер ул усаллык ябышмады-йокмады. Әллә этидән килә инде, әллә аның да этисеннән?.. Бәс, рәнҗүләремнең дә кайсыберләре генә истә калган.

Иң әүвәлгесе.

Әтисез калгач, авылга кайтып төштек. Фронтка озатылмый калган ике-өч бөртек егеткә тагылып без малай-шалай аулак өйләргә йөрибез. Санга тулмаганга гына инде, кызлар исе борынга кергәннән түгел. Болай гына. Аръякка чыктык. Бәйләнә-нитә калсалар дип, Фариз әбзәйләр тимер таяклар алды. Без ләңкелдәшеп аларга тагылдык.

Иршатлар ихатасында аръякның бер таныш малаен очраттым.

—Нихәл, Мансур,—димен.

—Ай, мин сине белмим бит, танымыйм бит.

—Беренчедә бергә укыдык бит инде!

—Ай, мин сине танымыйм бит,—ди теге, күзен дә йоммый.

—Мин аръяктан чыгып йөри идем...

—Ә-ә-ә, син теге, чабата киеп йөргән малаймыни?!

Сабый чакта йөрәгемне телгәләде әлеге сабакташым сүзләре.

Икенче рәнҗүем моннан гыйбарәт.

Авылда без ике елдан артык яши алмадык, яңадан калавылыбызга юллandык. Мин генә ара-тирә кайткалап йөрдем. Әйтик, бала-чага белән, каяндыр бәләкәй сука табыштырып, бәрәңге утыртып килдем. Аны, рәхмәт төшкере, Гөлсем җиңги караштырды. (Авыр туфрагы җиңел булсын!) Бәрәңгене җыеп алганнан соң "уфалла" белән Уби базарына алып барышты. Шул акчага бодай сатып алып кайттык. Аны тегермәндә тарттырып, бер пот ярым онны капчыкка салдым да, аны биштәр иттереп, аркама астым. Зурәптәй, җаны җәннәттә булсын, бераз сыер мае, аннары тагын юлда тамагыма кабарга ризык юнәтте.

Көзге көннәр кыскарганнан-кыскара бара бит, кай арада әйләнә-тирәгә эңгер-меңгер пәрдәсе җәелде. Станциягә егерме чакрымнан артыграк шул, ничек кенә ашыксам да, күз бәйләнгәнче барып җитүләрем икеле. Ярый да бит бүреләргә азык булмасам...

Һай, бәхет! Артымнан атлы килә икән ләбаса—тәгәрмәч дыңгырдаганы әллә кайдан ишетелә башлады. Эчемә жылы керде. Менә килеп тә җитте өметем арбасы, узып та китте... Калдым юл кырыенда баскан көе, нык аптырап. Атлары ять-яшь, җилдерә генә. Җиңел арбага ике егет кисәге утырган. Берсенең янында култык таягы ята, фронтовик-мазардыр инде. Тик менә үзенең аягына сыер баскан адәм булса, үзеннән зур биштәр аскан, җәяү килүче малайны җилдереп узып китәр иде микән?.

Әһә, туктадылар түгелме?

—Егыр, малай!

Йөгермимме соң, бик йөгерәм. Егерме чакрым күтәреп килгән йөгем торган саен авырая барса да, бернигә карамыйча йөгерәм. Кешеләрне көттереп булмый бит инде.

Тик егетләр мине көтмәскә уйлаганнар, ахры, эшләре кызудыр —дилбегә тотканы чөңгереп җибәрде. Хәзер инде йөгереп кенә тотармын димә. Бераз шулай җилдереп баргач, янә туктадылар болар.

—Егыр инде! Ник туктадың?

Оятларына көч килде, ахры. Кеп-кечкенә малайны төнгә каршы ялан кыр уртасында калдырмаслар бит инде... бүреләрдән ашатырга! Шундук йөгерә башладым. Ни дәрәҗәдә кызу барганмын инде, анысын ять-яшь ат җиккән җиңел ход арбада утыручы татар егетләре генә әйтә алган булырлар иде. Мөгаен, аларга якынлаша төшкәч, бераз гына кызулый да алдым бугай, тагын бер талпынсам—арбаларына ябышам дигән сүз!

Әмма җитү егетләр малай-шалайны ул арбага утыртырга бик атлыгып тормыйлар иде бугай—атларына дилбегә белән бер генә кагылып алдылар да җилдереп алга ургылдылар. Калдым авыз ачып.

Тегеләр янә туктадылар, янә дивана малайны йөгертәселәре килгәндер инде. Тик мин барудан туктап, аларга артым белән борылдым. Егерме чакрым юлны пот ярымлы биштәр күтәреп адым белән килә-килә дә (җәяүлегә янчык та авыр, диләр бит) ярыйсы ук өшәндергән иде үземне, ә инде теге бәндәләрнең этлеге аркасында йөгерүләрем—бөтенләй дәрманымны алды. Гарьләнүемнең чиге юк иде. Ирексездән атылып чыккан күз яшьләрен йота-йота:

—Казанда очрамассыз микән!..—дип сөйләнгәнем хәтердә.

Ул җитү егетләрне очраткан тәкъдирдә нишләтергә җыенганмындыр инде, анысы һич тә акылыма сыймый. Башка чарам калмаганга сайраганмындыр инде, бүтәнчә түгелдер...

1944 елда әле Муса Җәлилнең язмышы да, әсирлектә иҗат иткән үлемсез әсәрләре дә безгә мәгълүм түгел иде. "Бүреләр" шигырен белми идем. Шулай да әлеге ике

милләттәшемнең "егетлек" күрсәтеп үземне рәнҗетүе күңелемдә зәһәр нәфрәт хисе тудырды һәм бүредән курыкмаска этәрде. Чөнки:

*"... Бүреләр,*
*аһ... ләкин бүреләр*
*Бу кадәр үк ерткыч түгелләр".*

Табигать үзе әледән-әле көйли тора ул очрашуларны. Яхшысын да, яманын да. Аңа һич гаҗәпләнәсе түгел. Безнең телдә ул, язмыштан узмыш юк, диебрәк бәяләнә бугай.

Унынчыга укырга керер алдыннан бик тә инде көязләнеп-масаеп йөргән чакларым. Сугыш чукмары булмасам да, берәүдән дә курка белмәдем.

Урак өстендә әнием белән авылга кайттык. Авылыбызда атна-ун көн яшәгәнбездер, шуннан да ким түгелдер. Безгә ияреп Казанга бер абый да бармакчы булды. Иртәгә сәфәр чыгабыз дип, шуңа хәбәр бирергә кичке якта Чалуга барып кайтасы идем. Юл уңаенда кыр станына сугылып, анда бераз сөйләшеп тордым, кичке эңгер куера башлаган чакта юлымны дәвам иттерергә ниятләдем. Арыш басуы арасына салынган ат юлыннан гамьсез генә кызу-кызу атлап барганда... ни күрим—юлның ике кырыена ике багана утыртып куйганнар. Кайсы дивана алай эшләде икән инде, аннан арба уза алмый лабаса, дип гарьләнебрәк шунда уйланып барам. Ул арада баганалар якыная төште, багана башларында очлаеп торган колаклар күзгә чалынды. Фәкать шунда гына, баганалар дигәнем ике бүре түгелме соң, дигән шик килде. Күземне кыса төшебрәк карагач кына, юлның икесе ике ягында кара-каршы утырган бүреләрне шәйли алдым. Курку дигән нәрсә күңелемә килмәсә дә, башым гаять тиз эшләргә кереште. Иң әүвәл кесәмнән җиде япьле пәкемне чыгардым да, җанварларга сиздермичә генә, иң үткен ябен ачтым, пәкене ипләбрәк уң кулыма тоттым. Өсләренә барып чыккач, алар һөҗүм иткәнне көтәргәме, әллә үзем тәвәккәлләп һөҗүмгә күчәргәме, диебрәк фикер йөртеп алдым. Шунда гына ул җанварларның да көтеп тормаячагы, берсен чәнечкән арада икенчесенең сикереп бугазыңа ябышачагы башыма килде. Шуннан инде адымымны акырынайту ягын карадым, ә берзаман туктап, артка чигә башладым. Пәкемне кысып тоткан килеш, ике бүредәге күземне алмыйча гына, шактый ара узып, ат юлы бераз борылып, бүреләр күздән язгач кына, артым белән барудан туктадым, әледән-әле, тегеләр килмиме, дип карангалап, кыр станына юл тоттым. Чапмадым, йөгермәдем, пәкене әзер тоткан килеш, адым белән генә баруны кулайрак санадым. Бүредән куркып качкан, дип берәү дә әйтә алмас иде минем кыяфәтемне күреп, чөнки станга сулуым кабып, йөгерә-йөгерә хәлдән таеп аяк басмадым. Шулай да бу минем чигенүем, бирешүем, беренче җиңелүем иде.

Алаша җигеп, Чалу юлына яңадан төшкәндә... теге баганалардан җилләр искән иде инде.

Тик әнә шул гөнаһсыз очрашудан соң күңелемдә бүреләргә карата нindидер җылы бер хис уянды бит, әй! Гәрчә минем кесәдән пәке чыгарып, өсләренә ябырылырга дип кыю адымнар белән килүемне бик үк аңлап җиткермәсәләр дә, артка чигү "фокусымны" күреп, үзара елмаешканнардыр әле...

Тик инде мине өркетергә һич уйламаганнар. Югыйсә ике-өч сикерүдә өстемә басарлар иде. Эрелек, вәкарь бар шул карап торышка гына этләргә охшаган, куркыныч бу җанварларда. Бераз кыюрак булып яннарына ук барып җитсәм дә, ихтимал, кымшанып та карамаслар иде. Фәкать инде үзем пәке белән (!) селтәнә калган очракта ниләр килеп чыгарын әйтүе кыен: йә үземне акылга утыртыр иделәр, яки анда да әле дивана малай белән алышырга, көч сынашырга теләмичә, биек арыш арасына тыныч кына кереп югалыр иделәр. Һәрхәлдә, аларның үзләрен эре тотулары хөрмәткә лаек бер истәлек буларак хәтеремдә сакланган. Тора-бара әлеге фикерем көчәйде генә: укыган китапларым аларның гаять акыллы җан ияләре булуын раслады.

Поезд димәктән...

Сугыш алдыннан Бөгелмә ягына поезд юлы салмакчы булганнар иде. Казаннан әүвәл Арча юлы белән барып, нәкъ безнең барак яныннан уңга бордырып алып, Әкиләр аша узарга тиеш иде. Рельсларны да суздылар, тәбәнәк кырыйлы ачык өсле товар вагоннарына тутырып ком ташыдылар. Безгә кызык өстенә кызык, шул вагоннарга утырып йөри торган идек. Йөзләрчә кеше көрәк белән җир казыды, ул туфракны олау белән ташып, тирән чокырларны күмделәр.Әмма... җанланып киткәч кенә, әлеге эшләр "вакытлыча" туктатылды, кай арада тимер юлны чирәм басты...

Хәер, җөмһүриятнең күп кенә төбәкләренә әле бүгенге көндә дә юллар шактый ук әйләнгеч. Безнең авылдан иң якын станциягә дә егерме-егерме биш чакрым. Ярый да

бит ул хәзерге көндә машинаның төрлесе йөреп тора. Ул чагында... Ул чагында тәпитәпи барудан башка чара юк иде.

Әле бит сине станциягә барып житкәч тә беркем көтеп тормый. Ульяннан яки Сталинградтан килә торган поездга билет алырмын димә. Җөмһүрият эчендә бертөрле поезд-мазар йөрми иде.

Һәрхәлдә, безнең төбәккә, Буа-Чүпрәле ягына. Аның каруы товар төягәннәре туктаган очракта йә берәр кондуктор-мазар белән сөйләшеп, аңа күпмедер төртеп, утырасың; яисә кеше-кара күрмәгәндә берәр ярыкка кереп посасың. Тик аларның һәркайсы гадәттә мажара белән очлана торган иде.

Менә качып-посып кына товар вагонына жайлашам. Матур гына барган чагында, хәтерем алдамаса, Албаба станциясендә поезд туктагач, бригада алышынып кына калмады, дезертирларны ауларга чыккан солдатлар үземне вагоннан төшерделәр. Көпәкөндез, жәй көне булган хәл. Бәй, минем ишеләр тагын бар икән ич әле! Үземнән дә кечерәк "дезертирларны" күргәч, көләргә дә белмим, еларга да. Тик менә бөтенебезне бер читкә жыеп китергәч, бәләкәйрәк бала-чага балавыз сыгарга тотынды. Поездыбыз кузгалган чагында теге усал кыяфәтле солдатлар үзебезгә карабиннарын төрәп тордылар. Ихтимал, төрлебез төрле якка сибелсә, безне атып та үтерә алмаган булыр иделәр, тик инде безнең күңелебездә кораллы солдатлардан качып котылу түгел, бәлки ничек тә үзебезнең Казаныбызга кайтып житү, моның өчен әлеге поездга эләгү иде. Әмма ул якка талпынып караучы бала-чаганың бик тиз арт сабакларын укыттылар—бәргәләп тә суккалап көтүгә кире кайтардылар. Акрынлап кына кузгалып киткән поездыбыз артыннан яшьле күзләребез белән карап озатып калдык...

Гәрчә ундүрт кенә яшь булса да, әнә шунда мин ни рәвешледер кисәктән олыгаеп киттем. Әллә үземә әтиемнең акылы керде, зиһенем ачылып китте инде, әллә "дезертирлар" көтүендә иң өлкәне, иң тәжрибәлесе, иң тәвәккәле булу сәбәпле үземнән кечеләргә ничек кенә булса да ярдәм итәргә тиеш булуым көч-куәт бирдеме? Һәрхәлдә, мин аларга күз яшемне күрсәтмәдем. Хәтта артыграк көләч түгел идем микән әле?!

Поезд күздән югалу белән, солдатлар отделениесе безнең яннан китеп барды. Хәер, шундый зур хәрби вазыйфаны үтәгәннән соң аларга безнең янда бүтән эш калмады бугай инде.

Ул заманнарда укыган китапларым хәтсез иде. Ихтимал, нәкъ әнә шул сәгатьтә берәр әдәби каһарман исемә төшеп, хыялга бирелгәнмендер, үземне төплерәк бер-бер эш кылырга тиеш һәм сәләтле дип санаганмындыр...

Бала-чаганы авызыма карату, аларны таратмый-нитми генә өйләренә кайту юлына төшерү тел бистәсенә бер дә авырга килмәде. Чөнки бүтән һичбер төрле чарабыз юк иде. Поезд юлы ярыйсы ук ерау булганга, командамны авыл юлы белән турыдан алып киттем. Үземнең жилкәмдә пот ярым авырлыгындагы биштәрем артка тартканга түгел, бәлки жиде-сигез яшьлек сабыйлар да булганга, артык кызулый алмадык. Хәер, безнең артыбыздан куучы юк, атлы-мазар көтеп тормый—кайчан барып житсәк тә Зөя каласыннан гына утырып китә алачакбыз.

Юлда узган ике-өч татар авылында шау чәчәктә утырган алмагачлар гүя бала-чаганы елмаешып сәламләп калдылар.

Бер караганда, командир алдан барырга тиеш инде. Тик менә дәшми-тынмый гына атласаң, юлның чамасыз озын булып тоелуы ихтимал. Башкаларга күңелсез булмасын дип, юл буе сайрап барганым хәтердә. Андый чакта сөйләгәннәрем гел китаптан алынган вакыйгалар гына булмыйча, шундук уйлап чыгарганнарымны да ялгап жибәрә торган идем. Ун-унбиш чакрым юлны күңелле генә үттек болай үзе. Аручы-мазар булмады, берсе-бер зарланмады. Станциягә илтеп житкергәч кенә, поезд килгәнче, төрлебез төрле якка сибелде.

Икенче бер вакыт, көзге көндә, товар поезды станциягә килеп туктауга, кондуктор белән уртак тел таптым. Үзеннән зур биштәр күтәргән малайдан күпмедер алып, өсте ачык, галәмәт зур пульманга менеп кунакларга рөхсәт бирде бу. Поезд кузгалып киткәндә, көзге кич әйләнә-тирәгә үзенең карасу пәрдәсен жәеп өлгергән иде инде. Нindидер чатлы-ботлы нәрсәләр өстенә менеп сыенгач, аптырап калдым: нәрсә булыр бу? Нинди товар алып баралар? Караңгыда аз-маз агарып күренә үзләре. Ниндирәк нәрсәләр икәнен кармалап ачыкларга тотындым. Йа, раббым! Сөяк төягәннәр икән ләбаса пульманга!..

Йөрәкләрем жуу итеп китте. Нинди сөякләр икән соң—адәм сөякләреме, терлек-

туар сөякләреме? Нишләргә? Әмма нәрсә генә эшли аласың инде: юлның хакы түләнгән, поезд баруын белә, синнән билет сораучы юк, өеңә кайтасың, калавылыңа; анда сине дүрт күз белән көтеп торалар, үзеңнең исән-имин кайта алуыңа да, биштәреңдәге ризыкка да сөенерләр. Хәзергә тыныч кына мал-туар сөякләре өстендә тыпырчынмый гына ята бир. Синең башка юлың юк. Ә инде сөякләргә килгәндә, алар, әлбәттә инде, сыер сөякләре...

Әлеге фәлсәфәмә сөенеп тә юанып, тынычлана алгач, ерак юл килеп алҗыганнан соң әгъзаларымны җайлап кына урнаштыргач, изрәп йоклап киткәнмен. Берәү үземне дорфа гына төрткәләп уятты. Поезд туктаган. Таң атарга ерак әле. Бик тиз шәйләп алдым: Зөя станциясенә җитәрәк, семафорга туктаганбыз икән. Фонарь тоткан агай миннән акча даулый.

—Юк миндә акча,—димен.

—Бушлай утыртып килдеммени мин сине? Түлә булгач, түлә давай!

—Мин бит Борындыкта ук утырдым, шунда кондукторга фәлән сум бирдем.

—Ялганлама! Кондуктор мин монда, миңа берни биргәнең юк, малай актыгы!

—Албабада бригадагыз алышынганга мин гаепле түгел бит. Ул миңа, Зөя станциясенә хәтле шунда барырсың дип, менә монда менәргә рөхсәт итте.

—Иткәнме рөхсәт, юкмы—анысы миңа кирәк түгел. Миңа акча кирәк. Син шуны бир!

—Абый, минем бүтән акчам юк шул.

—Ах, юкмыни әле?! Үзеңне күпме утыртып килгәннең кадерен белмәсәң, тәпи-тәпи атлап кара әле, малай актыгы!

Пульманнан мин җиргә төшкәндә, поезд әле кызулап өлгермәгән иде. Нинди хәлдә икәнемне бик тиз аңлап, бүтән вагонга елышырга уйладым. Арткыларына ябышсаң, теге явыз, тамбурдан сикереп төшеп, сине йолкып атачак. Алга чабу хәерлерәк булыр, синең кая киткәнеңне күргән тәкъдирдә дә артыңнан чапмаячак. Алга, Кыям, алга!..

Каян килгәндер инде акрын булса да барган, тизлеген арттырганнан-арттырган поездлан кызурак чабарлык дәрман—һич башыма сыймый. Күрәсең, миннән тиярен алган кондуктор үзен алыштыручыга, анда пульманда бер пассажирым бара, Зөягә чаклы шуңа күз-колак бул инде, дигәннән соң да, вәгъдә биргәннән соң да антын бозган һәм орчык хәтле генә бер малайны төн уртасында кыр уртасына куып төшергән бәндәгә ачуым кабаргандыр, тәмам гайрәтем чиккәндер. Һәм әнә шул миңа үҗәтлек биргәндер, яңа көч вә дәрт өстәгәндер. Алга йөгерә торгач, бер цистернага життем, аның баскычларына ябышып карадым. Әһә, болай барып була икән! Монысы качмас, дип, тагын да алгарак ургылам соң. Үҗәтләнеп йөгерә торгач, тамбурлы вагонны да куып життем. Шуның тоткасына ябыштым. Ул чакларда сыңар кулым белән берәр нәрсәгә ябышсам, пот ярымлы йөгем белән кызу барган поездга да үрмәләп менү җаен таба идем. Бу юлы да шулай булды. Вагон тамбурының аскы баскычы нәкъ минем җилкәм турысында иде. Үҗәтләнеп тырыша торгач, үзем дә, аркама аскан һәм артка өстерәгән йөгем дә тамбурның баскычларын берәм-берәм җиңеп, өскә менеп җитү бәхетенә ирештек.

Иплэп кенә утыргач, артка карап, җилле генә барган поезд тәгәрмәчләре көенә теге бәндәгә сәлам сүзләре җибәрдем. Көлә-көлә, нинди сүзләр җибәргәнмендер инде—һич хәтерләмим.

Ихтимал, укучыда, ярты гасыр буена үзен рәнҗеткән кешеләрне онытмагач, бу бигрәкләр хәтәр мишәр абзый икән, дигән фикер калыр. Юк, туганнар, мин бит әлеге хәлләрне фәкать гыйбрәт өчен сөйләдем. Берәүгә дә кинә саклаганым яки, аннан да яманрагы—үч алганым булмады. Күңел җәрәхәтләреннән дә гыйбарәт икән ул гомер… Гәрчә андый җәрәхәтләр шактый булса да, күргәнегезчә, без фәкыйрегезнең күңелендә калганнары бармак белән генә санарлык. Ә менә киң күңелле, мәрхәмәтле-шәфкатьле затларның үземә кылган изгелекләре—санап бетергесез. Әнә шул гуманистлар, олы җанлы затлар иң авыр чакларда да минем күңелемдә якты өметләр уятты, өшегән чагымда җан җылысы өреп бәгырькәйләремне эретте, ешрак елмаерга өйрәтте...

Авылдан кабат чыгып китүләре, ай-һай, авыр булды! Теге чакны бит, әле тугыз-ун яшендә, төрле җирләрне күреп йөрисең килә, һәммә нәрсәнең кызыгын табасың. Барыннан да әһәмиятлерәге—үзебезне әти көтә. Ул булган җиргә дөньяның читенә дә китәргә әзерсең. Кая да булса бармыйсың ла, атаң янына барасың.

Бу юлы шул ук Вагонстройга таныш малайлар янына, таныш җиргә сәфәр чыгарга

җыенсак та, аермасы бик зур, аермасы аянычлы—анда безне әтиебез көтми...

Калавылга тәүге килүебездә авылны сагынмаган идем. Бу юлы нишләптер сагындыра гына бит! Әллә нәрсә булды үземә. Югыйсә бит әле күченүебезгә дә нибары ике-өч ай гына. Имтиханнар тапшырырга кайтырмын, кайтмый калмам, дип вәгъдәләшеп киткән идем, тик инде уку елы беткәнне көтәрлегем калмады—кайттым.

Һәй, сөенделәр, һәй, шатландылар сабакташларым! Үземнең куанычымны әйтеп торасы да юк инде—авызым ерылган көе йөримен. Үзем югында да искә алып сөйләгәннәр икән сабакташларым:

—Мәтәм, нишләп иң әйбәт укучыларыбыз авылдан китә икән, дим.

—Алар бит үзләре китми, алар бит ниндидер сәбәпләр аркасында китәргә мәҗбүр була.

—Әйе, Кыямыбыз да китте шул, Сәгыйтебез дә...

—Ичмасам, шуларның берсе имтихан тапшырырга кайтсын иде. Икенчесен көтмә инде, ерактa...

—Ул кайтып, синең өчен тапшыра алмый лабаса имтиханны!

—Ичмаса, төртелеп калган җиреңдә сорап куйсаң да ни тора...

—Аның белгәнен белү генә дә сине белүгә китерә, дисең икән, алайса?

—Нәкъ шулай димен, өстенә бастың!..

Имтиханнарны барыбыз да гаҗәеп матур тапшырдык. Һәркайсыбызның күнеле тулы шатлык.

Кайткан-кайткан, ичмаса бәрәңге утырту ягын карыйсы булыр. Зурәптәйләргә базга салып калдырган бәрәңге миңа авылда чакны үземә ашарга да җитәр, чәчәргә дә. Тик минә ялгыз башым казып чыгуы гына авырга килер. Үзебезнең урам ташландык инде, әнием үскән йортның бакчасы, мөгаен, кулайрак булыр. Күршедә генә яшәүче сабакташларым Нәҗип, Фуат белән Мансурлар килмәсләр, өйләрендә дә әллә ни кырмыйлардыр әле, үз өендә өйрә пешермәгән, кеше өендә ботка пешерә, дип көләрләр үзләреннән.

Җан биргәнгә юнь бирә, диләр бит. Нәкъ шулай килеп тә чыкты. Әкиятләремне яратып тыңлаучы үземнән кечрәгрәк бер көтү малай миңа булышырга алынды. Күршетирәдән табып алдым бәләкәй генә бер сука, егетләрем шуңа җигелде, үзем сука башын тоттым. Эһ тә итмәдек унган егетләр белән.

Янә дә бер зур эшем бар икән ләбаса! Өебезнең түбәсен Зурәптәйләргә үзем илтеп, үз кулым белән тапшырасым бар: акчасы ике-өч ай элек үк алынган. Миңлебай бабайларның нигезен саклый алмаучы да, корытучы да, чынлап уйлап карасаң, мин булып чыгам икән ләбаса! Йә Раббым... Төпчек малай!..

Уфаллага балта белән бау салдым да киттем кашлак урамнан аска табан, тәгәрмәчләр дыңгырдатып. Әйдә, буш арбадан шундыйрак көй чыгарсалар да ярар, кайтканда икенче төрле сайрарлар! Чынлап та, балчык ызбасын кар-яңгырдан саклап утырган такта түбәнең кыегын кыекка аергач, шактый зур булып чыктылар. Ә инде уфаллага шудыра-шудыра салып бәйләгәч, авырлыгы да ныграк тоелды, тәгәрмәчләр дә бөтенләй икенче төрле шыгырдау авазлары чыгара башлады. Хәтта әле җәлләп куйдым. Уфалланың күчәре сынмаса гына ярар иде, дип ут йоттым.

Бер талпынуда хәйран авыр йөкне олы урамга чаклы алып мендем дә тип-тигез урамнан матур гына бардым, кайчандыр үзебезнең мәхәлләбез мәчете булган, ә инде манарасы киселгәч, мәктәпкә әйләнгән, үзем шунда укыган мәчет бинасын да уздым, унга борылдым, гайрәтләнеп, үргә менә башладым. Шакир җизниләргә җитәм-җитәм дигәндә, нибары илле-алтмыш метр калганда—тәмам тугарылдым. Җиргә якынрак иелеп, инде бишкә бөгелеп, тартып карыймын йөгемне бар куәтемә—берни майтара алмыймын, әле уң тәгәрмәчен кул яссуы алга күчерәмен, әле сулын, шуннан артыгына дәрманым калмаганлыгын аңлыймын, бөтенләй хәлдән таеп, тукталырга мәҗбүр буласын да чамалыйм. Һай, сулу алулары авырга килә, йөрәгем үрсәләнә, дөп-дөп тибә. Әмма хәлем нинди генә булмасын, арбамны кулдан ычкындырмыймын, калтырку аякларыма ял итәргә ирек бирмимен, утырмыймын, олавымның артка чигүенә һич тә юл куймыймын.

Фәкать сынымны акрынлап турайтып, билемне бераз яздырып, әйләнә-тирәгә күз саламын. Каз бәбкәләре, әнә, яшел чирәмне кимереп өзәләр дә сыйланырга, тамак туйдырырга өйрәнәләр. Казыкка дилбегә белән бәйләнгән кәкре мөгезле ап-ак кәҗә тирәсендә үзе төсле үк бәтиләре мәйхана киләләр. Яңа салына торган сап-сары бүрәнәле

йортка сыртларын терәп утырган өч җиту егет салмак кына гәпләшәләр. Берсеннән берсе чибәр егетләргә сокланып туя алмыймын. Ни әйтсәң дә, безнең нәселдә матур да затлы, таза да көчле агайлар бар шул—кардәш тиешле егетләр алар, икесе ата, берсе ана ягыннан. Икәве сугыш тәтенен иснәп кайткан инде, берәве әлегә өйдә, мөгаен, китәргә әзерләнәдер. Хәер, фафирусны ул алардан да остарак көйрәтмиме икән әле, әнә минем якка нинди куе төтен алкалары җибәрә. Менә ичмасам егет! Карап туймассың бит аның тазалыгына да матурлыгына. Колхозыңа күпме гомер файда китерәчәк, тәмам баетып бетерәчәкләр бит әле бу тәрбияле-шәфкатьле абыйларым! Кинәндерәләр инде алар, кинәндерәләр!..

Ул арада каршы йортның капка астыннан шау-гөр килеп бер оя үрдәк чыкты, ана үрдәк "нарт-нарт"ын кабатлап, кадерле нәниләрен су буена алып төшәргә ниятләде, саргылт йомгаклар җепкә тезгәндәй әниләренә тагылалар, әткәләре иң арттан аларга күз-колак булып килә. Менә алар апын-төпен килеп минем турыга җитәләр, узып та китәләр. Мин аларны борылып-борылып озатып калам. Дөньяның шултикле дә ямьле, туганнан-туган абыйларымның берсеннән-берсе чибәр дә таза, куәтле дә шәфкатьле булуын күреп, ирексездән авызым ерыла, кул-аякларыма көч вә дәрман кайта, йөрәгемә кодрәт вә дәрт өстәлә.

Гайрәтләнеп, тәртәгә ябышамын, чытырдатып кыскан көе, кисәк кенә арбамны кузгатамын. Матур агайлар белән аралар адым саен якынайганнан-якыная бара, хәзер инде мин аларның көләч, дөнья барышыннан канәгать, сокланыч йөзләрен тулаем күреп кенә калмыйча, кайсының зәңгәр, кайсыларының кара күзләрен, төз борыннарын, әңгәмә вакытында ачылып ябылган иреннәрен, һәйбәтләп кырынган ияклөрен аермачык күрәмен. Әнә бит өчесе дә тиң ни рәвешле килештереп утыралар затлы егетләр. Күз тимәсен үзләренә!

Миңа ничек кенә булса да кардәш агайлар турысыннан узганда сынатмаска иде. Үгезеңне егарлык таза егетләр, һәй, кул арбасын да тарта алмый лабаса энекәшебез, дип көлмәсен, аннан да бигрәк—җәлләмәсен әле үземне! Әллә бәлкем, алар хәйран әһәмиятле берәр темага әңгәмә корып җибәргәннәрдер, кешелек дөньясына ук булмаса да, һич югы район, Кече Чынлы кайгысын кайгыртып шыпырт кына киңәш-табыш итәләрдер, авылыбыз халкына тагын нииндирәк изгелекләр кылыйк икән, дип баш ваталардыр...

Гайрәтләнеп, бар куәтемне салып, олавымны тарткан идем, кардәш агайларым яныннан хәтта әле азмы-күпме сынымны турайтып, җилле генә узу бәхетенә ирештем. Әлхәмделилла, сынатмадым, бирешмәдем. Ундүрт кенә яшемдә булсам да, Миңлебай нәселеннән ич мин!

*Ахыры киләсе санда.*



## Рөстәм Мингалим

# ЯНУЛАРЫМ, КӨЮЛӘРЕМ...

ТӨРЛЕ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

***

**Ашкынуым гел яктыга,
шуңа күрәдер инде—
бүгенемнән иртәгәмне
якты күрәмдер инде,—
матур күрәмдер инде.
Һәр кеше дә киләчәген
матур күрәдер инде.
Сабыр җаннар сабыр бара,
мин йөгерәмдер инде,
ник йөгерәмдер инде?
(Януларым, көюләрем
шуңа күрәдер инде...)
Гел яктыга ашкынганнар
утка керәдер инде.**

**...Утка керәдер инде.**

### Ачлык җыры

**Булган икән шундый кеше—
икмәк тәмен белгән кеше;
ятып ачлык түшәгендә,
үлгәннән терелгән кеше.
Җыр язган ул, көй чыгарган
һәм чал башын иеп куйган.
Язганының иң өстенә
"Ачлык җыры" диеп куйган.**

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) —*шагыйрь, драматург; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Күпсанлы китаплары (балалар өчен шигырьләр, лирика, драма әсәрләре) татар, башкорт, рус телләрендә дөнья күрде. Казанда яши.*

Бу җыр кемгә дә кирәкми?!
Кемгә, нигә бу җыр кирәк?
"Югалт аны!"
"Юк, югалтма!"
"Нишләтергә!"
"Тизрәк, тизрәк!"
Нәрсә язган?!
Ярый әле
дөньяга тәкъдим итмәгән?!
...Тик колагыннан үз җыры
китмәгән шул, аһ, китмәгән.

## Кайвакытта

Кайвакытта үз-үземне мактыйм мин:
Ап-аз яшәп, күпме нәрсә таптым, дим.
Тапканым да хәрам йә ялган түгел —
Мин югалту хисабына таптым гел.
Мактанырлык тапканың ни дисезме?
И дусларым, шуны да күрмисезме:
Күпме җиргә күз нурларым чәчелде,
Дөнья уе сирәгәйтте чәчемне...
Кимеп калды йөземдәге алсулык, —
Элек булган көлү инде миндә юк.
Җитдилегем арта бара бермә-бер,
Көтмәгәндә әллә нишли йөрәгем.
Ташкын кебек гөрләп килгән елларым
Артта кала моңсу гүләү чыгарып.
Минем күңел—бераз нечкә күңел бу,
Тик белегез, зарлануым түгел бу.
Бу югалту минем өчен чүп әле,
Югалтканнан югалтасым күп әле...
Бер... үземне югалтырмын, шунда сез
Минем нәрсә тапканымны күрерсез.

## Сеңелләр

Авылыбызга килдем якты кышта.
Ник, дисезме? Кызлар күрергә...
Абый булып, бераз шагыйрь булып,
"сеңелкәйләр!" диеп йөрергә...
Шәһәрдә дә авыл кызлары күп,
егылып уңа шәһәр ул яктан.
Тик авылдан китү белән кызлар
югалта шул нидер, югалта...
Шуңа килдем әле авылыгызга,
авыл матурларын күрергә.
"Матуркайлар, сеңелкәйләр!" диеп,
картлач кына булып йөрергә.
Чана эзләреннән, ат күзеннән
үткәнемне килдем карарга...
Кызлар юган кебек авылыгыз,
ак күбектәй таулар кабарган.
Җилләп кибә керләр кер бауларда,
якты кыштан якты—ак керләр.
Безнең гомер соңын яктыртырга
ярый әле сез бар, сеңелләр!

## Уйлашыйк

Ник күзләрең болай кайгылы соң,
Сөйләп бир дә миңа, уйлашыйк.
Мин алай ук хәзер кайгырмыйм бит,
Ә сәбәбе гади—мин гашыйк...
Каплап килгән кара кайгының да
Бавырына керәм, таратам...
Гел ышанып барам туар таңга,
Мин кояшны шулай яратам.
Калганнары нәрсә, дус-дошманың,
Алар хыянәте, үлемнәр...
Барысы да, әйе, дөньясы да
Күз яшемә лаек түгелләр.
Мин аларга Идел ташы кебек,
Йә чирәме сыман, нараты...
Беләсеңме, әйдә, мин көнләшмәм,
Зур кояшны бергә яратыйк.
Шул аралый ала бар кайгыдан,
Кояшны бер күрү—бер гомер:
Әмма белеп булмый, кояшы да
Бәлки бер мәл безне көйдерер.

## Ак болытлар үтте

Еш сөйләшәм быел күккә карап,
үзем генә калгач, бергә-бер.
Әткәм, бабам, аның бабасы да
бу күк йөзен шулай күргәндер.
Күпме үтте, ак болытлар үтте—
еллар битен сыйпап, иркәләп.
...Гомер иттем,
җиңдем,
канатландым,
бәйрәм, җырлар—
истә... Истәләр...
Әрнеп-әрнеп елаганым да бар,
чынлап елау—булмый онытырлык.
Җан телендә, ачык яраларда
тоз таулары эреп утырды.
Көлгән чагым булды үз хәлемнән,
яралану, әрнү, елаудан,
мәхәббәттән,
табу, югалтудан,
гомер, тарих,
уйдан,
юллардан.
Мин көлмим дә быел, еламыйм да,
кайдан килде бу ел, ник килде?
Еласам—
мине һичкем
юаталмас,
көлсәм — туктап булмас шикелле.

*1970 – 1997*



# Вазыйх Фатыйхов

## ТАБИГАТЬ ХОЗУРЫНДА

### Мин үзгәрмим бугай...

**Кемгә ничек, белмим анысын,
Миңа күзләр ошый күберәк:
Күзләр миңа гомер бүләк иткән,
Күзләр бирә миңа көч-куәт.**

**Сары төсне тиңләп сагышларга,
Күпме җаннар кача күзләрдән.
Сары төс ул—байлык, алтын төсе—
Мин үзгәрмәм инде, үзгәрмәм.**

**Сары яфрак юлларыма төшсә,
Гел яхшыга юрыйм юлларым.
Мәдхияләр язам көзгә атап —
Көз турында сузган җырлар ул!**

**Көзге күктә—торна тавышлары
Оркестрга гүя тиңләшә...
Кышын, язын сагышланып алам,
Төшләремә көзем кермәсә.**

**Көзге кояш гел үзенчә балкый,
Көзге нурлар кипми күзләрдә.
Мин көзләргә гашыйк гомер буе,
Юк, үзгәрмәм бугай, үзгәрмәм...**

### Үз—үземне юату

**Дәш инде, кызганма бер сүзең,
Һич югы карашың кызганма.
Бик читен көткәндә өзелеп-өзелеп...
(Бу юлны ничә кат узган бар!)**

**Үҗәтлек килешми, син аңла,
Карышу сөюне бизәми.
Гашыйклар илендә, ни хикмәт,
Кануннар мәңгелек, үзгәрми:**

---

Вазыйх ФАТЫЙХОВ (1958) *— шагыйрь, «Тормыш арбасы», «Тормыш—ормыш» һ.б. китаплар авторы. Балык Бистәсендә яши.*

Сөяргә, сөяргә, сөяргә,
Алсаң да, кушсаң да—шул ук сүз.
Йөрәгем атылыр сәгатьтә
Эчемнән пышылдыйм: бераз түз!

***

Инешләрем, кая югалдыгыз,
Болыннарым, кая киттегез?!
Әйтми-дәшми генә, бер хәбәрсез,
Нигә мине ятим иттегез?!

Урманнарым, кая югалдыгыз,
Чишмәләрем, нигә сулдыгыз?!
Эзли-эзли инде, алҗып, арды
Сезне якын күргән улыгыз.

Рәссам кышлар, ниләр булды сезгә,
Авыртамы әллә җаныгыз?!
Кычкырасы килә бар җиһанга:
Язларымны минем табыгыз!

Күрше-күләннәрем, кая соң сез,
Туган йортым калган күршесез...
Туган авыл—бүген кайтыр йортым,
Кала күрмә берүк кешесез!

Каен зират тора горур гына,
Югалтмаган, шактый тапканы...
Язмыш үзе ачып-ябып тора
Табигатьтәй мәжрух капканы!

## Табигать хозурында

Хәтерләтеп яшибез без
Кырмыскалар оясын:
Үз-үзеңне табигатьтә
Әнә шулай тоясың...

Агачлар күк яшибез без,
Киселеп, тишелеп тә,
Яшеннәрдәй бөтерелеп,
Комнарга ишелеп тә.

Дулкыннар кебек яшибез
Ярларда, кыяларда.
Бөркет булсак та, төшәбез
Җирдәге ояларга.

Җилләр булып исәбез без,
Бәрелеп упкыннарга.
Учакка төшеп янабыз—
Әйләнеп ялкыннарга...

## Ага чишмә

Ничә еллар, ничә гасыр
Ага чишмә.
Дәрья-тарих туар иде,
Серен чишсә.

Кайдан көче, каян ала?
Ага, ага...
Күпме җаннар ярасына
Дәва таба.

Җыры ага, моңы тама,
Кага, кага.
Берәү әнә йөрәгенең
Утын сала...

Ничә еллар, ничә гасыр
Ага чишмә.
Зарланмас ул берәүгә дә,
Юк, юк, һич тә!

Улагына ләм тулмаса,
Убылмаса,
Чишмә яшәр, су юллары
Ябылмаса.

Без китәрбез—сулар кебек—
Серле генә...
Чишмә килгән мәңгелеккә—
Гөрли генә.

***

Мин бер генә!
        Һәм мин шулай калачакмын!
Үлгәндә дә пыскып түгел,
        дөрләп кенә яначакмын!

Атлаганда адымнарым
        санар түгел,
                томырылган.
Эзем калыр, серле булып,
Тарих-бәкнең
        диварына сыдырылган.

Мин гел үзгә: югалырмын,
        табылырмын.
Ялгышларым кабат булыр, абынырмын.
Тузан кагып кузгалганда,
        якын торма:
Үпкәләрсең, ялгыш кына кагылырмын.

Мин серлеме?!
        Серләремнең тирәнлеге,
Сабак алган язмышымда, юл башымда.
Мин бер генә, инде башка һич үзгәрмәм,
Шулай калыйм нәни генә тормышымда.

Мин иң бае—дөньяларның...
                Бу фанида
Әвенемне әй йолкыйлар, ишелмимен:
Изгеләрнең байлыгы да гел бай була,
Шуны аңла Кешем минем, ишем минем!

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Владимир Лавришко

## КҮҢЕЛ ДУЛКЫННАРЫ

### Даһиның тылсымлы таякчыгы

Казанда Салих Сәйдәшевка багышланган мемориаль музей бар. Мин еш кына бөек композиторның гаҗәеп дәрәҗәдә моңлы, аһәңле вә илаһи көйләрен тыңлыйм да, "татарның Моцарты ич бу!"—дим.

Шулай көннәрдән бер көнне миңа бер яңалык килеп ирешге: Татарстан Республикасының дәүләт музеенда даһи композиторның хәтта үз исеме белән аталган музеенда да булмаган бик тә кадерле бер ядкарь—аның дирижерлык таякчыгы саклана икән. Салих Сәйдәшевның мемориаль музее ничәмә-ничә тапкырлар гозерләп сораса да, дәүләт музее исә әлеге затлы-олуг экспонатыннан аерылырга теләми икән.

Бу яңалык миндә кызыксыну уятты: таякчыкның бер-бер хикмәте булса кирәк, әгәр берәүләр аны күз карасыдай сакларга тырыша икән, берәүләр исә фәкать үзләрендә генә булуын тели икән, әлбәттә инде, монда нинди дә булса бер хикмәт бардыр! Бәлки ул бик тә затлы, бары тик диңгез арты илләрендә генә үсә торган агачтан эшләнгәндер? Бәлки ул асылташлар белән бизәлгән фил сөягеннәндер?

Мин музей хезмәткәрләреннән әлеге серле таякчыкны күрсәтүләрен үтендем. Һәм менә, ниһаять, хәзинәләр залыннан, бәллүр күтәргәндәй сак кына атлап, миңа әлеге таякчыкны китерделәр. Гаҗәпсенү катыш соклануудан мин кычкырып җибәрә яздым: шул ич бу, нәкъ үзе! Нәкъ менә даһи кулындагы дирижерлык таякчыгы! Нәкъ мин уйлаганча...

Юк, диңгез арты илләрендә генә үсә торган затлы агачтан да, асыл ташлар белән бизәлгән фил сөягеннән дә эшләнмәгән иде ул. Гап-гади, кайрысы кесә пәкесе белән юнылган утыз сантиметр-ярым аршын озынлыгындагы бераз кәкрерәк тал чыбыгы иде бу! Скрипка һәм янә дә дистәләгән башка төрле нәзберек, гаярь вә дәртле-моңлы уен кораллары белән идарә итүче даһи кулына килеп эләгәсен каядыр Мишә буенда үскән бу тал чыбыгы чамалады микән?!

... Аны мөгаллимнең күрсәткеч таягына да охшатып була. Менә ул мәктәптәге иске география картасы буйлап, кыйтгалар вә океаннар аша уза, бөек калаларга барып төртелә, елга-күлләрне сыйпап үтә.

---

*Владимир ЛАВРИШКО (1944) —язучы, драматург. Рус телендәге "Узел связи", "Трава", "Перевод с глухонемого" h.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

...Озак кулланудан шомарып беткән әлеге дирижерлык таякчыгына янә текәлдем. Гап-гади тал чыбыгы да даһи кулында тылсымлыга әверелә икән ләбаса!

### Ак песи бәласе

Йоннары каралып, киезләнеп, яралары кутырланып, күзләре эренләп-үлекләп беткән бу песи бахыркай туган чагында ап-ак булган диләр. Шуннан соң... Әллә шуннан соң аның юлын кара мәче кискәнме?

... Кала чүплегеннән ике адым ераклыкта песи бахыр битен юып утыра. Кала шакшысы, көзге пычрак аның тәпиләрен аямаган: алар да кап-кара...

Әмма дә ләкин песи битен юарга тиеш! Борынгыдан килгән табигать кануннары шулай куша. Чисталык—сәламәтлек билгесе!

Тик менә... Кешеләр үзләре пычраткан бу калада ничек итепләр чистарынырга да, чиста калырга?!

Песинең кара тәпиләре һаман саен битен пычрата. Ә ул һаман битен юа да, битен юа...

### Тимер пәрдә

Хәзер каладагы һәр йортның подъезды, квартиралары тимер ишеккә бикләнә. Кемгә генә барсаң да, тимер ишеккә килеп төртеләсең. Ул тимер ишекләрнең эчке ягында кемнәр яши дип уйлыйсыз? Һәрхәлдә эре түрәләр белән банкирлар түгел. Алар һәммәсе дә житешле, затлы, өч-дүрт катлы һәм каравыллы-саклы үз йортларында яшиләр.

Тимер ишекле бу бетон йортларда сезгә ишекне тиз генә ачмаячаклар. Башта кемлегеңне өч мәртәбә сорап, күзләү тишегеннән биш тапкыр карап алырлар.

Әле кайчан гына: "Ил тимер пәрдәдән котылды, без, ниһаять, азат, ирекле!"—дип тантана иттек, жырлар жырладык. Ирек... Тимер ишекләр артында нинди ирек инде ул, йә?!

### Котырган этләр

Бу илдәге үзгәртеп корулар тәмам дөньяны үзгәртте дә куйды бит, әй! Калада котырган этләр пәйда булды...

Хужалары тарафыннан урам язмышы хөкеменә ташланган, артык азык кисәге табылмаганга күрә куып чыгарылган бу жан ияләре үз көннәрен үзләре күрергә мәжбүр. Ошбу мәжбүрият аларны өерләргә туплый һәм бу өерләр адәм баласының котын алырлык дәрәжәгә житә.

Казан "гарлем"ы—атаклы "Калуга" читендәге чокыр-чакыр вә ерганакларда, чүплекләрдә шәхсән үземнең дә бу котырган эт өеренә тап булганым бар. Шунысын кистереп-өзеп әйтәм: тап булырга язмасын икән аларга! Котырган эт өере бүре көтүеннән мең вә мең мәртәбәләр хәттәрәк икән, валлаһи! Әле бүренең канында-аңында, геннарында кешедән курку хисе яши. Ә менә котырган эткә ни кычкыру, ни таяк-мазар, хәтта төбәлгән мылтык көпшәсе дә тәэсир итми, аңа барыбер.

Этләрне адәм баласының дүрт аяклы тугры дустына әверелдерү өчен мең еллар кирәк булган. Әйе, каршында койрык болгап, кулыңны ялап, тугрылык тулы мөлдерәмә күзләре белән сиңа карап торучы бу жан ияләренә кешелекнең байтак гасырлык хезмәте сарыф ителгән. Әлеге хезмәтнең санаулы көннәр эчендә юкка чыгуы да бик ихтимал икән бит, әй! Әле моннан берничә көн элек кенә сиңа тугры күзләре белән баккан этең инде хәзер көтү кануннарына буйсынган да, әнә шул көтүе белән бергә синең бугазыңа ташланырга әзер торсын әле!

Социаль дарвинизм, мәдәни катлам мәсьәләләренә тәфсилләп вә жентекләп тукталасым килми. Хәер, мәдәни катлам, дигәннән... Илдәге үзгәртеп корулар шаукымы бер этләрнең генә түгел, кешеләрнең дә мәдәни

катламын нәзегәйтте. Кайбер танышларыма карыйм да, шаккатам: боларның мәдәни катламы котырган этләрнекенә караганда да нәзегрәк, юкарак икән ләбаса!

## Аккош күле

Көннәрдән беркөнне шулай кичкырын электр поездында калага кайтып барам. Тимер юл кабыргаларын җилле генә санап барган поездыбыз, тизлеген киметте дә, чираттагы платформага туктады. Тәрәзәдән бактым. Карашым поездга керүче кешеләр аша йөзеп үтте дә, колгадай гәүдәсе бераз бөкрәя төшкән, артистларча озын чәчле бер таныш ир-атка беректе. Чәчләренә чал кунса да, бу кешедән яшь егетләргә генә хас бер гаярьлек бөркелә иде. Алай гына да түгел, бу агайның назлы-илһамлы карашы күңелләргә ут үрләтер дәрәҗәдә якты вә ялкынлы иде ки, аның homo sapiens кавемендә хәзер бик тә сирәк очрый торган зат—Шагыйрь булуына һич тә шикләнмичә, "иманым камил—бу Шагыйрь!"—дип өздереп әйтергә мөмкин иде.

Гәрчә бик якын танышым булмаса да, әлеге татар шагыйре белән мин үткәндә-сүткәндә сәлам алышып йөрим. Поездыбыз туктаган бу "787 нче километр" платформасын исә халык телендә "Аккош күле" тукталышы дип атыйлар. Казанлыларның яратып ял итә торган урыннары да бирелә генә. Ә түп-түгәрәк Аккош күле буенда әдәби фондның дачалары тезелешеп утыра.

Күзләреннән назлы илһам ташкыны бөркелгән әлеге танышым, әлбәттә инде, мине тәрәзә аша искәрмәде. Шагыйрьнең карашы тулаемы белән кулына озын сабаклы ап-ак эре чалма чәчәк-пион тоткан яшь ханымга йотылган иде. Дулкынланып торган алтын чәчле бу ханымның кулында шушы гаҗәеп матур чәчәктән гайре берни дә юк. Аңлашылып тора: шагыйребез үзенең кунагын электр поездына озата килгән...

Ниһаять, поезд кузгалып китте. Шагыйрь, вагон әңгер-меңгереннән затлы чалма чәчәк тоткан алтын чәчле гүзәлен шәйләргә тырышып, платформа буйлап йөгерә-атлый бара-бара, безне озатып калды. Хәер, безне дисәм дә, ул мине—нәкъ тәрәзә турында ук утыручыны—бөтенләй күрмәде, искәрмәде дә. Шагыйрьнең бөтен барлыгы-вөҗүде белән әлеге яшь ханымга бирелгәнлеге, сөюе, аңа ихлас рәхмәте шулкадәрле дә ачык, ярылып ята иде ки, минем йөрәгем, ирексездән, сулык-сулык тибеп куйды. Фәкать исәп-хисапка гына корылган җансыз-битараф вә циник заманыбызга ничектер хас түгел иде бу мөнәсәбәт. Шагыйрьнең мөнәсәбәте... Соң, ярар, карап карыйк, "шигъри сын" күздән югалуга ук, ул бүләк иткән затлы чалма чәчәкне гүзәл ханым вагон эскәмиясе астына атып бәрүе дә ихтимал ич"—дип уйладым мин.

Яшь ханым, утырырга уңай урын эзләп, вагон буйлап минем каршыма килә башлады. Күз чите белән генә күзәтәм: заманнан, модадан артта калган Шагыйрь ише түгел бу. Бөтенләй башка, яшь буын вәкиле бу! Үзе матур, буй-сыны төз, адымнары да—ныклы, ышанычлы...

Электр поезды тизлеген һаман саен арттыра бара, тимер юл кабыргаларын да отыры шәбрәк, җәһәтрәк саный башлады. Алтын чәчле, ап-ак чалма чәчәкле ханым миңа бер эскәмия аша урынга аркасын куеп урнашты. Һм-м... Ни моның йөзен, ни Шагыйрь бүләк иткән чәчәкне күреп, күзәтеп булмый лабаса... Поезд хәрәкәтенә тәңгәл рәвештә тибрәнүче аркасы да, иңенә төшеп торган алтынсу чәчләре генә...

Минем тукталышка килеп җитә идек. Торып чыгу юнәлешенә атладым. Шулай да, барыбер түзмәдем бит, әй: ханым янынннан үтеп китешли, тоттым да, тәвәккәлләп, моңа борылып карадым. Яшь ханым ап-ак чалма чәчәкнең саллы вә дымлы таҗларын алсу яңагына тидереп уйга талган. Ул үзенең уйлары белән шулкадәрле дә еракка-еракка китеп барган—хәтта минем үзенә борылып каравымны да шәйләмәде.

Вагоннан чыгып барышлый нигәдер җиңел сулап куйдым: модадан артка калган Шагыйрь өчен дә, ул сөя торган яшь ханым өчен дә күңелдә сөенеч һәм шатлык хисләре пәйда булды.

## Сәер илнең сәер халкы

Яналыклар тапшыруында телевизион репортаж күрсәтәләр: “Курск” атом су асты көймәсендә һәлак булган хәрби диңгезчеләрнең гаиләләренә ярдәм итү фондына пенсионерлар акча күчерәләр.

Сәер, валлаһи сәер безнең илдәге халык! Бу кешеләрне ул гомерендә бер мәртәбә дә үз күзе белән күрмәгән, ә менә дәүләтнең: “ярдәм итәргә кирәк!”—дип оран салуына шундук каһарманнарча җавап бирә. Әлеге фондка акчаны бер карт-коры гына түгел, ә бәлки саллы-саллы фирмалар, банклар һәм оешмалар да күчерде. Бу, әлбәттә, бик тә югары кимәлдәге шәфкатьлелек һәм миһербанлылык гамәле. Сүз дә юк—изге эш. Вәләкин һәммәбезгә мәгълүм ич: һәлак булган һәр диңгезченең гаиләсенә дәүләт миллионышар сум акча, квартиралар бүлеп бирде. Бу гаиләләр хәзер бернинди дә матди ихтыяҗ кичермиләр. Ә менә карт-коры, саллы банк вә фирмалар күчергән акчалар кая китә? Гадәттәгечә—урлыйлармы? Шул ук вакытта, акча күчергән ошбу мәрхәмәтле затлар белән янәшә үк, йортсызлар, ятимнәр, бер сынык ипигә тилмергән ялгыз карт-карчыклар да җан асрый. Соң, азмыни бу илдә матди кыенлык кичерүчеләр: күршеләр, хезмәттәшләр, туган-тумача... Әмма дә аларны күрүче юк. Болары—дәүләт күләмендәге бәла-каза түгел имеш...

Вәләкин дәүләт үзе дә икейөзле: күрергә-белергә теләмәсә, бинигая зур афәтләргә дә күз йомып кала ул. Чечен илендә һәлак булган мең вә меңнәрне дә бу дәүләт күрмәмешкә салына. Атом су асты көймәсендә һәлак булучыларныкы шикелле үк, бередәге яу корбаннарының да гаиләләренә миллионышар сум акча бүлеп бирдеме дәүләт? Әйдәгез, ярдәм итик!—дип оран салдымы дәүләт?—Һич юк! Әгәр дә бөтен дөнья шаулаган Чечен фаҗигасына дәүләт күз йомып карамаса, комга башын тыккан тәвә кошы хәлендә калмаса, Каф тавындагы илдә барган бу җан өшеткеч кан коюлар инде әллә кайчан тәмамланган булыр иде кана.

Сәер, валлаһи, сәер яратылган безнең илдәге халык...

## Кыя—таулар, кичерегез!

Төньяк Осетиянең Кармадон тарлавыгында фаҗига: актер һәм режиссер Сергей Бодровның кино төшерү төркеме таудан кубып төшкән боз астында калган. Телевизордан бу хәбәрне ишеткәч, йөрәк чәнчеп куйды: шундый сәләтле егет... яп-яшь килеш... мәгънәсез үлем белән...

Сергей Бодров “Брат” һәм “Брат—2” кинофильмнары аша киң танылды, яшь буынның үзенә күрә бер каһарманына әверелде.

Әйе, бу хәбәрне ишеткәч, йөрәк чәнчеп куйды. Ә башта бер уй пәйда булды. Шундый ябышкак бер уй—күңелдән һич кенә дә куптарып алып булмый... Илдә яшәүче тулаем бер буын мөкиббән киткән кинофильмда Бодров уйный торган каһарман кавказ халкы вәкилен әшәке сүзләр белән мыскыллый. Милли яктан аерып мыскыллый...

Каф тауларында Бодровның беренче генә мәртәбә булуы түгел иде. Тау халкы аны һәрвакыт шатланып, колач җәеп, дустанә кабул итте. Тау халкы зирәк, кичерә белүчән. Алар, әлбәттә, үзләрен мыскыл итүче әлеге каһарманны Бодров уйлап тапмаганын бик яхшы аңлыйлар иде. Бит егет үзеннән ни-нәрсә таләп итәләр—шуны гына башкаручы. Әле, мөгаен, мыек астыннан гына елмаеп та куйганнардыр: бөек мәмләкәтчел урыс базар читендәге чүплектә фыр исерек килеш аунап яткан бер мәлдә Рәсәй базарларында кем сату итә—Кавказ! Әшәке сүзләр белән кемне мыскыллау зарурлыгын әле башта ныгытып уйлыйсы бар...

Анысы шулай... Әлбәттә, тау халкы Бодровның зыялы, итәгатьле һәм акыллы егет икәнен белә иде. Аның үз ихтыяры белән бәгъзе кабәхәт каһарман исеменнән тулы бер милләтне уптым-илаһи мыскыл итмәячәген дә тәгаен чамалый иде бу халык.

Әйе, тау халкы аны аңлады һәм кичерде дә. Ә менә таулар? Таулар...

***Марат Закир*** *тәрҗемәсе.*

Мирза
Мәхмүтов

# МӘГЪЛҮМАТИ КӨРӘШТӘ МӘДӘНИЛЕК

## XIII—XVI гасырларда татарлар

Тарихи экскурслар безгә һич тә ата-бабаларыбызның мәдәниятен бөек итеп күрсәтү өчен кирәкми, алар безгә татарлар «кыргый» булган, ул чор рус мәдәниятенә алар бернәрсә дә бирмәгән, дигән тезисларны кире кагу өчен кирәк.

Алтын Урда дәүләте төрле сәяси һәм икътисади сәбәпләр аркасында таркалып, берничә мөстәкыйль (суверен) дәүләтләргә—Казан ханлыгы, Кырым, Әстерхан, Нугай, Себер һәм башка ханлыклар булып калган.

Казан ханлыгы нинди булган соң? Ул шәрекъ тибындагы күпмилләтле феодаль дәүләт булган, икътисады алга киткән, сугышчан кораллы көчләре дә булган. Атаклы тарихчы академик И. Р. Таһиров Казан ханлыгы җитәрлек өйрәнелмәгән, бозып күрсәтелә дип саный. Ул, янәсе, артта калган кыргый, комсыз һәм мәрхәмәтсез баскынчылар дәүләте булган. Ә ул чынлыкта Урта гасырлар дәүләтләре арасында алга киткән дәүләт булып, үзен-үзе тәэмин итеп торган. «Атаклы Казан патшалыгы,—дип яза революциягә кадәр Иван Михайлов,—русларга гына билгеле булып калмаган, ул дөньяның башка кыйтгаларында да танылган, чит ил тарихчылары дөньяда булып үткән башка хәлләр турында язганда әлеге патшалыктагы вакыйгаларны да искә ала торган булганнар».

Поляк тарихчысы Александр Гвагнин болай дип язып калдырган: «Казан татарлары башка татарлардан әдәплелекләре, йортлар төзү осталыгы һәм игенчелек белән дә аерылып торган. Алар бик яхшы төзелгән йортларда яшиләр, россияннар, фарсилар һәм башка халыклар белән товарлар алмашып сәүдә итәләр, аларның үз патшалары булган, алар В. К. Иоанн Васильевич һәм аның улы Василий Иоаннович патшалык иткән чорларга кадәр беркемгә дә кол булмаганнар» (И. Таһиров). А. Курбский Казан ханлыгында төрле милләт халыклары тигез хокуклы булганнар, ул «болгар теленнән башка патшалыкта тагын биш телдә—мордва, чуваш, чирмеш, вотяк, башкорт телендә сөйләшкәннәр» дип билгеләп үтә. Бу хәл ханлыкта төрле халыкларның үзара дус-тату яшәүләре турында сөйли.

Ул чордагы дәүләтләрнең сәнгать, Болгар-Казан ханлыгы мәдәниятенең көнбатыш Европа һәм шулай ук шәрекъ илләре белән бер дәрәҗәдә үскәнлекләре күренә. Казан һәм болгар-татар культурасы шул мәдәниятләр

*Ахыры. Башы 4 санда.*

чигендә булуы аркасында ул заманнарда Европа мәдәниятенә дә шактый зур йогынты ясаган. Шуңа күрә дә А. Курбский үзенең «Казанны яулап алу турында бәян»ендә Казан болгарларының бөек һәм көчле измаил токымы булуларын, шуның белән халыкның борынгылыгын да искәртә, «кайчандыр бөтен дөнья кан калтырап торган алар алдында» дип яза ул. (Ф. Салихова).

1882 елны басылып чыккан В. Рогозинның «Волга» дигән китабында Идел буе халыклары этнографиясенә фәнни анализ бирелә. Халыкларның уңай сыйфатлары аерып күрсәтелә һәм, кушылган очракта, рус халкына да уңай йогынты ясарлар иде, диелә. «Казан татарлары яхшы тән төзелешле, алар матурлар. Үзләренең тән төзелеше һәм акыл сәләте буенча аларны затлы, зәвекъле халыклар исәбенә кертәләр. Тарихчылар татарларның ягымлы сөйләшүчән-килешүчән холыклы, матур мөгамәләләре һәм гаҗәп киң күңелле булулары турында язалар. Шул ук вакытта абруй-дәрәҗәләрен дә саклый беләләр. Алар горур кыяфәтле, якты карашлылар. Һәрвакыт горурбәйсезлекләрен иркен-ирекле елмаюлары белән күрсәтәләр. Бу аңлашыла да, чөнки алар эчми, Мөхәммәт өммәте кануннары белән яшиләр» (Ф. Салихова).

Димәк, Казан ханлыгында, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен хәзер язылган дәреслек авторлары «кыргый татарлар» дип күрә торып ялганлыйлар, алар россияле татарларны мыскыллыйлар, татарларның милли горурлыгын мәсхәрәлиләр. Көнбатышта мәдәниятләрнең үзара бәйләнышларын әллә шулай аңлыйлармы?

## Рус дәүләтенең мәдәниятлеге хакында

Киев Русенең мәдәнияте турында күп язылган. Рус халкының үз этник мәдәниятен үстерү өчен тырышуы бик табигый, ул аны башка халыклар мәдәниятеннән ала-ала да үстергән. Бүген бу бөек халыкның бөек мәдәнияте бар. Ләкин күп кенә тарихчылар Русьның үткәненә кремльнең алтынланган сарайлары һәм бүгенге рус мәдәнияте аша карыйлар. Ул мәдәният көнбатыш Европа мәдәниятен «куып җитәргә» бик тырыша, әмма һич кенә куып җитә алмый. Шуңа күрә гаепле итеп әлеге дә баягы «татар-монгол иго»сын саныйлар...

Россия нинди булган? Төрле чорда төрлечә. Ул һәрвакыт зур һәм ярлы, шуның өстенә бик сугышучан дәүләт булган. Тарихчы К. Д. Кавелин язганча: «Россия империясенең барлыкка килүен, аякка басуын идеаллаштырып карарга ярамый. Урта Азияне яулап алу, Ермакның Себер ханлыгына походы, Амур буйларындагы тыныч халыкны талап йөргән Хабаров, камчадалларга карата бик күп явызлыклар кылганы өчен үз казаклары тарафыннан үтерелгән Атласов...» (К. Д. Кавелин. Наш умственный строй.—М. Правда, 1989, стр. 69).

Күренекле галимнәр Карамзин, Костомаров, Платоновлар Россиянең бөек үткәне, аның мәдәнияте турында гына язып калмыйлар, алар ул заманнардагы кешеләрнең гореф-гадәтләре турында, патшалар, боярлар, воеводаларның рәхим-шәфкатьсез эш-гамәлләре турында да сөйлиләр. Иван IV (XVI гасыр) чорындагы опричникларның явызлыгы, яулап алу сугышлары турында, үз улын үтергән патша турында укыганда чәчләр үрә тора. Ил үзениндирәк булган? Иван IV чорында Россиянең мәйданы 2800 мең кв. км., халкы 7-8 миллион булган. Күпчелек халык чиркәүле авылларда (село) һәм чиркәүсез (мәктәпсез) авылларда (деревни) яшәгәннәр. «Әй, син, деревня!»—дигән мыскыллы гыйбарә шул заманнардан калган. Шәһәр халкының саны 2% тан артмаган (һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр). Ел саен төбенә кадәр диярлек янып торган агач Мәскәүдә—100 мең чамасы, Новгородта—30 мең, Можайск, Серпухов, Коломна ише вак шәһәрләрдә 3 меңнән 8 меңгә хәтле кеше яшәгән (Казанцев).

Хәзерге тарихчылар әле күптән түгел генә (XX гасырның утызынчы елларына кадәр диярлек) Россия халкының төп өлеше авылларда салам түбәле агач өйләрдә яшәгәнлеген, агач савытлардан агач кашыклар белән ашаганлыкларын, өйдә сугылган күлмәк-ыштаннан, чабатадан йөргәнлекләрен бөтенләй онытканнар... Авыл халкы шуңа күрә дә «лаптем щи хлебали» (чабата белән кәбестә шулпасы чөмерә идек) дип шаяртканнар. Совет чорында шәһәрләшү авыл халкының 80%ын шәһәр кешесе иткән...

Ә шәһәрләргә килеп тулган бу халык ничегрәк яшәгән соң? Әдәбиятта астыртын хәйлә-мәкер белән тулган боярлар, кенәзләр, дини руханиларның «татлы» тормышы күбрәк сурәтләнә. Шәһәр ярлы. Шыгрым тулы кысанлык, караклык һәм даими янгыннар эчендә яшәгән. «Комсызлык, акчага хирыслык, ач күзлелек, эчкечелек, бозыклык һәм наданлык—руханиларның төп сыйфатлары әнә шундый. Болар барысы да чиркәүгә йөрүче халыкта ризасызлык тудырган. Руханиларны тәнкыйтьләү, гомумән, чиркәүләр кирәкмәс, дигән фикергә китергән» (Казанцев). Шул заманнардан Россиядә чиркәү кагыйдәләренә каршы хәрәкәт, динсезлек башланып киткән.

Шулай булгач, Россиялеләр арасында бүгенге әхлаксызлык кайдан килеп чыккан соң? Тарих дәреслекләре язучы авторларның кайберләре турыдан-туры моны татарлар йогынтысы дип тамгалыйлар. Шулаймы икән? Буыннардан-буыннарга күчеп килә торган генетик милли гореф-гадәтләр түгелме икән ул? Күренекле тарихчылар нәкъ шуны раслыйлар да бит. Н.К. Карамзинның бик үткен әйткән сүзләре бар: «XVII гасыр Россия өчен тәмуг уенына тиң хакимлек ярату, коточкыч ачлык, һәркайда талаулар, йөрәкләрнең таш булып катуы, халыкның бозыклыгы белән ачыла. Болар барысы бергә дәүләтне ватып бетерүгә илтәчәк киләчәктер».

## Игомы, әллә хезмәттәшлекме?

«Татар-монгол игосы» дигән гыйбарә йөз еллар буена тарих дәреслекләре битләреннән төшми йөри. Яшьләрнең аңына гасырлар дәвамында «дошман татар» образы сеңдерелә. Бу бигрәк тә татар дәүләтләрен—Казанны, Әстерханны, Себерне, Кырымны яулап алу чорларында ачык чагыла. Россия дәүләтенең барлыкка килү тарихы һәм христиан чиркәвенең татарларны «дошман» итеп күрсәтүе Россиянең Төркия белән сугышларын идеологик яктан да дәлилләү өчен кирәк була (8 сугышның барысын да Россия башлап җибәрә). Россия сәяхәтчеләре бу төшенчәне үзләренең мәнфәгатьләре өчен һаман да файдалана торалар. Мәсьәлән, Г. Н. Селезнев, Европарламентта чыгыш ясап, Европаны татар-монгол игосыннан Русь кына коткарып калган, дип ялагайланып сөйләгән. Ләкин бит беренче һөҗүм вакытында ук татар-монголлар рус җирләре аша Польшага, Чехиягә бәреп кергәннәр, хәзер инде бу илләр, Батый хан гаскәрләренең көнбатышка баруын без генә туктатып калдык, дип раслыйлар.

Ике күрше халыкның хезмәттәшлеге дә булганмы, әллә алар «иго» йогынтысы белән даими дошманлашып торганмы? Менә тарихи тикшеренүләрдән берничә өзек: «Әле 1917 елга кадәр үк кайбер галимнәр Мәскәү дәүләтенең үсешенә монгол дәүләте зур йогынты ясаган. Икенчеләре исә монгол-татар игосы рус дәүләте тормышына тирән социаль үзгәрешләр китермәгән дип саныйлар.»

Тарихчылар сугыш хәрәкәтләре тукталгач ике арада хезмәттәшлек башланганын инкяр итә алмыйлар. «Урда белән Русь мөнәсәбәтләренә килгәндә, инде 1243 елда ук ике як өчен дә файдалы килешү төзелгән. Алтын Урдага рус кенәзләре еш барып йөргән, алар татарлардан өйләнеп хатыннар алып кайткан...» (Платонов). Менә сезгә «иго»! «Л.Н. Гумилев иго булганлыгын кире кага һәм руслар белән монгол-татарлар арасында һәр ике як өчен дә файдалы союз булган дип раслый...» (Казанцев). Тарихи фактлар да Л.Н. Гумилевның хаклы булганлыгын күрсәтә. Рус кенәзләре Алтын Урда оешкач та ханнар һәм морзалар белән дуслашкан. Мәсәлән, Александр Невский Батыйның улы Сартак белән җан дуслар—борадәр булган (монголларның бер өлеше христиан динен тоткан). Невскийның оныгы Юрий Данилович «озак еллар Урдада хан сараенда яшәгән, Үзбәк ханның сеңлесенә өйләнгән. Юрийдан башлап рус кенәзләре Урдага йөз тоткан, ханнар һәм татар аксөякләре белән тыгыз элемтә булдырганнар, бу Русьта үз позицияләрен көчәйтү һәм кенәзлекләрен ныгыту өчен эшләнгән» (Казанцев).

## Европа белән элемтәләр турында

Тарихчылар татарларны, игодан тыш, Русьның Европадан артта калуына сәбәпче итеп тә гаеплиләр. Дәреслекләрдә шундый сорау да очрый: «Алтын Урда Россиянең Көнбатыш Европа белән мәдәни багланышларына һәм рус мәдәнитенең алдагы язмышына йогынты ясаганмы?» Сорау очраклы гына куелмаган, авторлар шуңа таянып татарларны гаеплиләр.

"Монголларның басып алуы һәм Алтын Урда игосы рус җирләренең Көнбатыш Европадагы алга киткән илләрдән артка калуына сәбәпләрнең берсе булган. Русьның икътисади, сәяси һәм мәдәни үсешенә гаять зур зыян китергән... Рус җирләренең мәдәни үсеш темплары бик акрынайган...» (Казанцев). Әлбәттә, монголлар һөҗүме зур зыян салган (дөрес, ул немец фашистларының хәзер сөйләнми торган һөҗүме белән чагыштырырлык та түгел). Ләкин бит татар-монголлар барып җитә алмаган гомер-гомердән рус җирләре дә булган, мәсәлән, Новгородтан башланган төньяк төбәкләре. Аларына үсеш алырга кем комачаулаган?

Ә татарлар Русьның Көнбатыштагы агрессив көчләргә каршы көрәшендә кем ягында булганнар? «Әгәр дә Литва һәм башка дошманнар белән сугышларда татар сугышчылары да катнашкан булса, XIV—XV гасырларда ул Урда ханы ярдәме түгел, ә татар патшаларының һәм башка феодалларның русларга хезмәткә кергән һәм Русь дошманнары белән шул исәптән үз кабиләләре белән дә сугышкан уллары булган» (Казанцев). Рус кенәзләренең литвалылар, поляклар, немецлар, шведлар белән һәм үзара да туктаусыз булып торган сугышларында татарлар һәрвакыт кенәзләр яклы булган, аларга җиңү яулашкан (кара—Н. Карамзин). Урдалылар Русьның Европа белән багланышларына берничек тә кире йогынты ясый алмаган, рус кенәзләре үзләре таркау һәм көчсез булган. Икенче закончалык бар: Русьның Европадан артка калуына татарлар гаепле түгел, ә рус халкы үзе европалылардан 500 елга яшьрәк булган (Казанцев редакциясендә чыккан дәреслекнең 72 битен кара).

Россиядә колбиләүчелек булганы билгеле—ул крепостное право, феодализмның үзенчәлекле бер төре, ягъни алпавытның крепостной крестьяннарны эксплуатацияләүгә һәм җәзаларга хокуклы булуы... «Феодализмның мондый үзенә бер аерым төре булу—татар-монгол игосы аркасында Русьның 240 ел буе Европадан чикләнгән хәлдә үсеш нәтиҗәсе» (Казанцев). Болай дип раслау дөресме? Фактлар алай сөйләми. Беренчедән, Алтын Урдада турыдан-туры колбиләүчелек булмаган (бары тик йорт коллары гына булган). Икенчедән, Россиянең көнбатыш чикләре Урда тарафыннан тикшереп торылмаган, төньяк җирләре, гомумән, ирекле булган, (шулай булгач, Урда Русьны чикләп тә тора алмаган). Әллә поляклар, шведлар, литвалылар аркылы рус кенәзләре немец шәһәрләре белән сәүдә алып бармаганмы? Шул «изоляция»-чикләүләрсез алга китү булыр идеме? Шикләнәм, чөнки Русь тормыш логикасының башка законнары белән үсеш алган, ул үз гореф-гадәтләре, үз үзенчәлекләренә таянган.

Бер халыкның икенче халыкка йогынтысы күбесенчә үз зыялылары, сәүдәдә аралашулары, товар, тел-логать һәм мәдәни байлыкларын, белемнәрен, осталыкларын алмашу юлы белән тормышка ашырылган. Казанцевларның 250 ел буена руслар Европа белән багланышта булмаган дип аһ орулары бик тә беркатлылык. «XV гасырда,—дип язалар дәреслек авторлары,—Европада 30 университет булган, ә Россиядә шул ук вакытта белемлелек кискен түбән тәгәри, хәтта кенәзләр дә һәр очракта да белемле булмаган». Әйе, татарларның моңа ни катнашы бар? Мөселманнар дөньясында университетлар Европага караганда күпкә алданрак барлыкка килгән, Европа исә X гасырда халкының белемлелек дәрәҗәсе буенча Кытайдан ун мәртәбә артта калган.

Ә тарих дәреслекләре язганча, рус кенәзләренең поляклар, литвалылар, шведлар белән туктаусыз сугышып торганлыкларын, тегеләренең рус җирләрен татарлардан да күбрәк басып алуларын һәм талауларын кая куясың? Александр Невский кебек кенәзләр Көнбатышны Урда белән ныклы союзы булганга гына, татарларның хәрби һәм сәяси ярдәме белән генә җиңә алганын тарихчылар раслый, фактлар раслый.

## Татар мәдәниятенең рус мәдәниятенә йогынтысы булмаганмыни?

Югарыда «башка» халыкларны түбәнсетергә теләгәндә, аның мәдәнияте юклыгы турында сөйлиләр, дип язылган иде инде. Моның бер мисалы—Алтын Урда чорындагы татар халкы мәдәниятенең рус мәдәнияте үсешенә ясаган йогынтысын инкяр итү. Ләкин бу мәсьәләдә әдәбиятта ике төрле караш яши. Беренчесе—ә ул йогынты булмаган. Икенчесе—булган, әмма аз булган.

Алтын Урда Русь мәдәнияте үсешенә уңай йогынтысы булганмы-юкмы? Үз-үзенә каршы килеп, культурология дәреслеге авторы Драч болай яза: «Безгә әле хәзергә андый йогынтыны эзләп табарга туры килмәде»,—ди.

Россия тарихы бары тик кенәзләр һәм патшалар эшчәнлеге турында гына язылган, аннары, сугышлар, революциягә бәйләп, халык турында да яза башлаганнар, ләкин хәзергәчә бу тарих рус халкы тарихы гына, анда башка халыкларга урын юк.

Шуның өчен дә кемгәдер «эзләп табарга туры килмәгән...» Ә бәлки, Россия халыкларының тарихын белергә кирәктер, бигрәк тә аның хәзерге биләмәләрендә кайчандыр зур һәм кечкенә дәүләтләре булган, рус дәүләтенең аякка басуына йогынты ясаган һәм рус тарихының бер өлеше булган халыкларның тарихын. Дәреслекләр авторы Россиядәге рус булмаган халыклар—татарлар, чувашлар, якутлар, кареллар һәм башкаларның тарихларын белмиләр дигән тәэсир кала. XI гасыр төрки телле шагыйре Йосыф Баласагуни бик акыллы әйткән:

*Табиблар дәваламас авыруын наданның,*
*Дәвала белем белән наданлыгын аның.*

## Татар мәдәниятенең үзенчәлекләре нәрсәдә?

Күрше булып яшәгән халыклар мәдәниятләренең үзара йогынтылары турында фикер йөрткәндә, без һәрвакыт бер сорауга килеп төртеләбез: татар мәдәнияте нинди булган соң? Югарыда татарларның борынгы халык булганлыгы, Бөек Болгар дәүләте мәдәнияте, аның мирасчысы Алтын Урда һәм Казан ханлыклары турында сөйләнелде. Тарихи фактлар шуны раслый: Алтын Урданың (Жучи Олусының) бик кыска башлангыч чорыннан тыш, монгол мәдәниятеннән бигрәк, анда төрки-татар мәдәнияте өстенлек иткән, ул исә һуннар, борынгы татарлар, Төрки каганат, Идел Болгары һәм дала кыпчаклары мәдәниятләрен үзенә сеңдергән. Алтын Урдада дәүләт теле төрки-татар теле булган, шул телдә рәсми эшләр, дипломатик язышулар алып барылган, әдәбият үскән.

Татар-монголлар,—Кытай мәдәнияте белән таныш халыклар,—корал йөртүне, сугышуны гына белгән кыргыйлар булганмы? Юк, әлбәттә.Тарихның һәр чоры үз дәрәҗәсендә мәдәниятле булган. Татар монгол аксөякләре, түрәләр Алтын Урданың беренче дистә елларында да, дәреслекләр авторлары язганча, кыргый булмаганнар. Шул чорның шаһиты монах Плано Карпини болай яза: «Монголлар рәссамнарны ятратканнар... Людовикның илчесе (француз короленең—М.М.) хан сараенда (ул вакытта Мәнгү хан хакимлек иткән—М.М.) венгрларны, инглизләрне һәм Париж алтын остасы Гильйомны очраткан... «Әлеге Француз татар морзаларына сарайлар салганда скульптор да, архитектор да булган. Бу мәдәниятнең аерым йогынтысын рус кенәзләре дә кичергән.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, Алтын Урда чорында Русьта беренче мәртәбә халык санын алу үткәрелгән, ям (почта) хезмәте оештырылган, төзелеш эшләре алып барылган, игенчелек үсеш алган, хәрбиләр көчәйгән һ.б. Урда һөнәрчеләренең шактый оста булулары турында күп тарихчылар яза.

Рус аксөякләре, бигрәк тә хатын-кызлары татар киемнәрен иң яхшы модалы дип санаганнар. Рус кенәзләренең кием-салымында, аяк киемнәрендә дә татар киемнәре йогынтысын күрергә мөмкин. Мәсәлән, Иван Грозный турындагы «Иван Васильевич сердится» исемле кинофильмда ул яхшы чагылдырылган.

## Әхлакый мәдәнилек турында

Хәзерге россияннәргә әхлаксезлек кайдан килә? Дәреслекләр авторлары янә дә татарларны мәсхәрә итеп әхлаксезлектә, рәхимсезлектә һәм башка гөнаһларда гаеплиләр. Шулаймы соң? «... Рус кенәзләренең һич бетмәслек үзара дошманлык-низаглары халыкның барлык катламнарында, бигрәк тә югары катламнарда әхлак дәрәҗәсенең түбәнәюе нәтиҗәсе ул. Череп таркалу, бозыклык чиркәүләргә дә үтеп керә,татарлар хакимлек иткән шартларда анда исә,чиркәүнең өстенлекләренә кызыгып, күп кенә аксөякләр һәм түрәләр дә агыла. Үз мәнфәгатьләрен кайгырту, шәфкатьсезлек, икейөзлелек, хыянәтмәкер, татарларга тәлинкә тоту һәм алардан курку, эчкечелек һәм башка гөнаһлар гади кешеләр белән чиркәү руханилары арасында киң тарала...» (Казанцев). Әгәр дә инде эчкечелек һәм бозыклык хәтта христиан руханилары арасында да шулай таралган икән, монда татарларның ни гаебе бар, алар бит исерткеч эчемлекләр эчми, ә зина кылу үлем җәзасы белән тәмамлана. Ә үз мәнфәгатеңне кайгырту,тәлинкә тоту-ялагайлану һәм икейөзлелек рус түрәләренә XXI гасырда да хас түгелмени?

Күп авторлар ни өчендер сүгенү татарлардан кергән дип уйлыйлар. Хәтта бу хакта еш кына рус руханилары да газеталарга язып чыгалар. Ләкин бу бит чи ялган. Сүгенү сүзләре татарларда һәм башка төрки телләрдә рус телендәгедән күпкә азрак. Хәтерлим әле, Үзбәкстанда руслар үзбәкләр турында ярым шаярып: «Кара, үз телендә мыгырдый, ә русча сүгенә, үз сүзләре җитмидер,ахрысы»,—диләр иде.

Сүз уңаеннан, күпләр сүгенү сүзләре рус телендә нык таралган,дип уйлыйлар һәм ялгышалар—иң күп сүгенүчеләр венгрлар. Әмма алар бер дә күршеләренә ымламыйлар: һәр халык үз телен үзе үстерә.

Татарларның эчке мәдәнилеге бик түбән дәрәҗәдә, дип расламакчы булалар. Әмма тарих башкача сөйли. Н.М.Карамзин хезмәтләрендә кызыклы фактлар бар. Мәсәлән, ул монах Карпининың сүзләрен китерә. Карпини әйтә: татарлар «әшәке сүз әйтүне күрәлмиләр» (димәк, сүгенү аларга хас түгел—М.М.), «хатын-кызлар белән мөгамәләдә тыйнаклар», «уйнаш-зина гына түгел, хәтта караклык та үлем белән җәзалана»,—ди. Күргәнебезчә, татарларның төп әхлак дәрәҗәләре бүгенге русларныкыннан да югарырак булган». «... татарлар, -дип яза Карамзин,—түземлелек белән данлыклы вә үз диннәрен башкаларга такмыйлар...» Д.М.Карамзин.

Культурология дәреслекләре авторларыннан аермалы, башка абруйлы галимнәр татарларның рус мәдәниятенә уңай йогынтысы шулай да булган, дип язалар. Мәсәлән, академик Френ: «Алтын Урданың хакимлеге азмы-күпме дәрәҗәдә безнең ватанның язмышына, төзелешенә, карарларына, мәгарифенә, гореф-гадәтләренә һәм теленә йогынты ясарга тиештер...»,—дип яза.

Тарихчы Платонов: «XIV гасырдан башлап руслар «яман» татарларның шәрекъ йолаларын, гореф-гадәтләрен күчереп ала, хәтта никахлашып туганлашалар да»,—дип яза. Әйе, руслар, татарлардан гореф-гадәтләрен, йолаларын алган шикелле үк, бераз соңрак—XIX йөз башларында французлар белән дә шулай эшләгәннәр: гореф-гадәтләрен, хәтта кием-салым ишеләрен дә алганнар, никахлашканнар да. Никахлашуны, әлбәттә, беренче чиратта аксөякләр, боярлар һәм кенәз балалары башкарган. Шунысын да искә алырга кирәк, ул заманнарда, гыйшык-мәхәббәткә бик игътибар итеп тормыйча, нигездә сәяси һәм матди мәнфәгатьләр алда булган. Сәясие—ханнан кенәзлеккә ярлык—указ алу яки башка берәр кенәзгә һәм чит кешеләренә каршы көрәштә аның ярдәмен көтү. Матди мәнфәгать исә теге йә бу җирләргә ярлык алып, үз кенәзлегендә ясакны үзе җыю хокукына ирешү һ.б. Татар морзалары һәм гаскәр башлыклары да, үз чиратларында, рус кызларына өйләнгәннәр.

Димәк, мәдәни дәрәҗәләре дә чама белән бер тирәдәрәк булганмы?! Әле җитмәсә, «бернәрсәгә дә өйрәнмәгәннәр» дип сөйләнәләр һәм язалар бит. Туганлашканнар икән, дуслашканнар да дигән сүз ич! Димәк, тарихчы

Л.Н.Гумилевның «иго» булмаган, ә хезмәттәшлек булган» дигән сүзләре дөрескә чыга. Бөек Габдулла Тукаебыз да:

*Рус белән гомер кичердек сайрашып,*
*Тел, гөрәф, гадәт вә әхлак алмашып,—*

дип юкка гына язмагандыр, шәт.

Соңгы елларда ярым ялган белән бер рәттән үткәннәргә азмы-күпме дөрес бәя дә бирелә башлады. «Русиядә Урда игосы, -дип, элекке гадәтләр буенча, язалар Сахаров белән Буганов,—һичшиксез, тискәре йогынты ясаган... Шулай да, элек тә һәм хәзерге йөзьеллыкларда да чит ил хакимлеге Русиянең үсешенә уңай тәэсир иткән, дигән фикерләр әйтелә килгән: дәүләт тәртибен ныгыту, кенәзләр арасындагы ызгыш-талаш-тарткалашны йомшарту... урдалыларның хакимлеге, барыннан да тыш, ике яклап та хуҗалык эшләрендә, тормыш-көнкүрештә, телдә һем башкаларда үзара алмашып яшәүгә китергән». (Сахаров А.Н., Буганов В.И. 1995 елны басылып чыккан дәреслектә.)

Димәк, ул хакта беркайда да диярлек сөйләнмәсә дә, «уңай йогынты булган, 250 ел хезмәттәшлек» (Л.Н.Гумилев) дәверендә Кытай, Һиндстан һәм, гомумән, Шәрекь мәдәнияте өлгеләрен кием-салымда, йорт кирәк-яракларында гына түгел, фикерләүдә дә алып килгән татарлардан руслар күп нәрсәләргә өйрәнеп калганнар...

## Казан ханлыгы һәм мәдәниятләрнең үзара йогынтысы турында

Тарихи фактларны рус һәм татар мәдәниятләренең үзара йогынтысы турында дөрес мәгълүматларны без М.Г.Худяков китабыннан таба алабыз (Очерки по истории Казанского ханства, Казань, Фонд ТЯК, 1990). Алар Казан ханлыгы тарихына караса да, бераз Алтын Урдага да кагылып үтә: «Җиңелгән илгә яулап алучылар (монголлар—М.М.) тарафыннан кертелгән дәүләт төзелеше татарларга кадәр Русиядә яшәгән патриархаль тәртипләргә караганда бик нык уйланылган һәм нык тәртипле булган. Дәүләт белән идарә итү нигезләрен руслар татарлар аша танышкан: беренче мәртәбә халык санын исәпкә алу үткәрелгән, мәҗбүри ясак, салым һәм пошлина түләтүләр башкарылулары буенча шуннан да яхшырак була алмаган.

... Болар бик күп яхшы белемле һәм тәҗрибәле түрәләр булуын таләп иткән,—биредә кытайлыларның традицияләре сизелә,—татарларга кадәр белемлелек бары тик руханилар, сәүдәгәрләр һәм бөек кенәзләр арасында гына төсмерләнгән иске Русия моны күз алдына да китерә алмаган».

Алтын Урда таркалганнан соң, рус һәм татар мәдәниятләренең үзара йогынтысы турында бер-ике сүз белән генә Мәскәү кенәзлекләренең Казан ханлыгы арасындагы тыгыз бәйләнешларын әйтеп үтү кирәктер. Күпмиллэтле Казан ханлыгы 1432-1552 еллар дәвамында (Иван Грозный Казанны яулап алганга кадәрле) яшәп килгән. Ул да шул чордагы Мәскәү кенәзлеге кадәр мәйданны биләп торган. Рус тарихчысы М.Худяков Казан ханлыгының чәчәк ату чоры дип аның Мәскәү белән әле бәрелешеп, әле килешеп, файдалы сәүдә, дуслык һәм үзара йогынтылар белән яшәгән озак вакытлы тыныч елларын атый.

Ул чорда ханлыкта чама белән 2,5 млн. кеше яшәгән, шуларның I миллионы татарлар булган. Мәскәү кенәзлеге исә, Тверь һәм Новгород кушылганнан соң Казан ханлыгын җирләре белән дә, халык саны буенча да (5-6 млн.чамасы) шактый узып киткән.

Халыкның тарихи хәтерендә яхшы заманнар да, начарлары да сакланып каладыр. Шундый начар заманнар Мәскәү белән Казанның 1439-1445 елларда Мәскәүдә кенәз Василий III (Темный) хакимлек иткән чорына туры килә. Казан ханы Олуг Мөхәммәт Суздаль янындагы сугышта Мәскәү кенәзенең гаскәрләрен тар-мар итә, энесе белән үзен әсирлеккә алып, зур салым сала. Салым җыяр өчен рус җирләренә татар түрәләре җибәрелә. Моны халык кына түгел, боярлар һәм кенәзләр дә өнәми. Алар Василий III не тәхеттән бәреп төшереп, күзләрен сукырайталар. Әмма Олуг Мөхәммәт гаскәр җибәрә һәм Василий III не яңадан тәхеткә менгезә. 1439-2445 еллардагы вәзгыять шундый

була. Ләкин нәкъ шул чорда татарлар белән руслар арасында сәүдә һәм дәүләт элемтәләре көчәеп китә, товарлар алмашып кына калмыйлар, гореф-гадәтләр, дәүләт белән идарә итү һ.б. багланышлар да ныгый.

М.Худяков үз китабының «Татарларның Россиягә мәдәни йогынтысы» дигән бүлегендә татарлар белән руслар арасындагы мәдәни багланышлар турында тәфсилләп яза: «... казанлыларның тормышын мәдәниятсез кыргыйлык дип күзалларга ярамый. Мәдрәсәләрдә укырга-язарга өйрәткәннәр, суфыйлык серләрен төшендергәннәр. Татарлар арасында укый-яза белү шактый киң таралган булган, чөнки мәчетле һәр авылда мәдрәсәләр дә эшләгән. Төбәкнең үз әдәбияты булган, шуннан байтак китаплар хәзерге заманга кадәр килеп җиткән...»

«...Татар халкы башка халыклардан үзенең байлык-муллыгы, рәхәт тормышы белән аерылып торган... Болгарларның электән килгән игенчелеге язгы милли бәйрәмнәре сабантуйда чагылыш тапкан. Бу бәйрәмдә яшьләр спорт ярышлары үткәргән... Матди мәдәният өлкәсендә аларның чүкеп төшерелгән бизәкле савытлары, зәвекьле үрелгән ювелир бизәнү әйберләре, мәчет манараларының матур гөмбәзләре, аллы-гөлле тукымалары, матур каллиграфик кульязмалары, катлаулы миниатюралы китаплары булган...»

Татарларның русларга ясаган уңай йогынтысы турында М.Худяков:

«Татарларның рус дәүләтендәге вечены (ягъни дәүләт һәм җәмәгать эшләрен тикшерү өчен шәһәр халкының җыелышын) бетерү, Мәскәүнең бербөтен дәүләтчелеген булдыру һәм аны ныгыту кебек йогынтылары булган, руслар көнчыгыш күршеләреннән мәдәни казанышларны да күчереп алганнар. Рус хакимнәре падишаһ титулын Византия китаплары йогынтысында гына алмаган, татар ханнарына да охшарга тырышканнар, аларны Россиядә «падишаһлар» дип атаганнар бит.

Хәзер инде халык санын исәпкә алуны руслар татарлардан өйрәнгән, дигән фикер тулысынча раслана. Канцелярия эшләрен язмача башкару шәрекь-Кытай, фарсы һ.б. илләрнең мәдәниятендә гомумән үзенчәлекле сыйфат булган, ул урта гасыр көнбатышына капма-каршы буларак, Русьта киң кулланылыш тапкан. Язма эш кәгазьләре, барлык халык санын гаять зур күләмдә исәпкә ала—болар барысы да татарлар турындагы «кыргый күчмә халыклар» дигән гадәти күзаллауларны кискен юкка чыгара... Нугай биләмәләрендә кәгазьне бик күп кулланганнар—димәк, бу да эш башкару һәм язу-сызуның яхшы үсеш алганлыгын искәртә. Татарларның русларга тагын бер мәдәни өлкәдәге йогынтысын билгеләп үтү кирәктер—дипломатиядә... (Худяков).

## Татар мәдәниятенең рус мәдәниятенә йогынты ясау юллары

Димәк, татарлар рус мәдәниятенә бернәрсә дә кертмәгәннәр, дибезме? Мондый фикер йөртүләрне хата санап, без бу йогынтының шул заманнардагы ике генә юлын күрсәтергә телибез.

Беренче юл—татарларның һәм татарлардан чыккан күренекле кешеләрнең рус кенәзлекләренә һәм рус мәдәнияте тормышына турыдан-туры катнашулары. Өстәрәк татар түрәләренең рус җирләрендә булулары сөйләнелгән иде. Үзләренең белемнәре, хәрби һәм җитәкчелек итү осталыклары, тәрбияле һәм гыйлемлекләре булган ничәмә-ничә ханзадә, морза һәм бәкләр рус кенәзләренә һәм патшаларына хезмәткә күчкән бит! Алар әллә үзләре бернәрсә дә алып килмәгәнме? Алар тәҗрибәләрен, белемнәрен алып килгәннәр, алдагы буыннарда Россиянең ватанпәрвәрләре булып әверелгәннәр. Бу очракта гадәти үк булмаган вакыйгаларны искә төшерү дә зыян булмастыр. Распутинны үтергән кенәз Йосыпов Россияне сәяси шарлатаннан коткармаганмы әллә? Татар кенәзләре бертуган Урусовлар Серпухов тирәләрендәге урманда икенче Ялган Дмитрийны тураклап, полякларны җиңүне тәэмин итмәгәнме? Болар рус дөньясына өлеш түгелмени?

Милләтнең менталитеты, ягъни фикер йөртү үзенчәлеге гасырлар дәвамында барлыкка килгәнлектән, бу милләткә саркып кергән чит тел

вәкилләренең белемнәрен дә инкяр итәргә ярамый.

Татарларның русларга йогынтысы нәтиҗәләрен әдәбиятта, дәүләт төзелешендә, хәрби эшләрдә, архитектурада күрергә мөмкин. Әллә Мәскәү тирәләрендәге (Архангельскоедагы) һәм Петербургтагы кенәз Йосыпов, Шереметьев, Измайловларның атаклы сарайлары рус мәдәниятенә саллы өлеш түгелме?

1311 елны, Үзбәк хан ислам динен Алтын Урдада дәүләт дине дип игълан иткәннән соң, аның белән килешмәгән татарларның бер өлеше рус кенәзлекләренә китеп барган. Кемдер үзенең өч йөз кешесе, кемдер хәтта биш меңлек гаскәре белән дә киткән. Алар рус кенәзлекләренең ышанычлы сакчылары булып әверелгәннәр. Хәтта Касыйм ханлыгы кебек аерым дәүләтләр дә барлыкка килгән.

«Ислам диненә каршы татарларга табардай бердәнбер ышык һәм дустанә урын рус кенәзлекләрендә генә булган. Шул рәвешле, Русьта Урдадан чыккан нык холыклы, тәвәккәл кешеләр барлыкка килгән, алар менә дигән сугышчылар булганнар һәм рус кенәзләренең дружиналарын, ә соңрак Мәскәү кенәзенең дә гаскәрен тулыландырып, аларның сугышчанлыкларын сизелерлек дәрәҗәдә күтәргәннәр»...,—дип яза тарихчы Платонов. Алтын Урданың Мәскәү кенәзлекләрен поляклар, литвалылар һәм шведлардан саклап торулары турында язылган иде инде.

## Кем син Русич?

Күп телле җәмгыятьтә халыкның үзара аралашып кушылуы һәрвакытта да аксөякләр арасында гына бармаган. Рязань өлкәсендә, мәсәлән; Алтын Урдадан килгән татарлар токымыннан торган тулы районнар бар. «Һәр өченче русны чокып кара һәм син аңарда татарны табарсың»—К.Маркснның бу сүзләре рус әдәбиятында аңа кадәр дә яхшы билгеле булган. Күпмегә дөрестер бу сүзләр, әйтүе кыен. Әмма шунысы хак, руслашкан миллионлаган татарлар рус халкының аерылгысыз өлешенә әйләнгән. Үзләрен «рус» дип яздыручы һәм рус исем-фамилияләрен йөртүче татарлар бер генә миллион түгелдер. Күпме, рус фамилияләренең тамырында татар чыгышы ята бит: Муратовлар, Сабуровлар, Батышевлар, Калгановлар, Балабановлар, Измайловлар һ.б. шәһәрләрдә генә түгел, рус авылларында да яшиләр, үзләренең борынгы бабаларының кайдан килеп чыгышын, белсә дә, бик азлары гына беләдер.

Тарих дәреслекләреннән укып, мәктәп балалары Афанасий Никитинның Һиндстанга сәяхәте турында беләләр. Үзенең «Хождение за три моря» («Өч диңгез артына сәяхәт») дигән китабында ул үзе күргән шәһәрләрне сурәтләп китә.

«Казан биек тау башында тора,—дип яза ул,—елгадан бик яхшы күренә, шәһәр өстенә биек-биек мәчет манаралары һәм хан сарае күтәрелгән». Афанасий Никитинның бу китабын татар телендә язганлыгын белә идегезме? Гаҗәпкә калдыгызмы? Тикшеренүче галимнәр бу хәлне аның «урман болгары», ягъни мишәрлеге белән аңлаталар. «Димәк, Тверь кенәзлегендә XY гасырларда татарча язган һәм сөйләшкән «урман болгарлары» да яшәгән»,—дип нәтиҗә ясый тарихчы Ф.Салихова.

Русларның аксөяк, затлы катламы ничек барлыкка килгән? Тарих моның өч юлын күрсәтә: мирас булып атадан балага күчә килүе; кенәз һәм граф, сирәгрәк бояр исемен Россиядә дәүләткә яки патшага шәхсән зур хезмәтләр күрсәткәне өчен патшаларның гади кешеләргә дә бирүе (классик мисалы—кенәз Меньшиков) һәм өченче юл: рус дворяннары сафларының татар морзалары һәм бәкләре,соңрак немец, швед һәм башка чит-ят кешеләр белән тутырылуы—тулыландыруыннан барлыкка килгән.

Әдәбиятта Россиядә дворяннар катлавының барлыкка килүе турында материаллар шактый. Бик күп татар кенәзләре, морзалары һәм бәкләре рус дворяннары сафына кереп кушылган, алар үз белемнәрен: дәүләт белән идарә итүләрен, дипломатия тәҗрибәләрен, шәркый телләрне белүләрен, хәрби гыйлемнәрен, билгеле бер дәрәҗәдәге әхлаклы булуларын һ.б. шунда салган.

Алар йөзәр еллар дәвамында Польша һәм Литва аша Идел Болгарыннан, Алтын Урдадан, Казан һәм башка ханлыклардан рус хезмәтенә күчә барганнар.

А.Х.Халиковның «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (Казань, 1992) дигән китабыннан кайбер мисаллар китерик. Руслар өчен бүген дә бик таныш берничә исемне атап үтәбез. Иң күп төркемне әдәбият-сәнгать әһелләре тәшкил итә. Әдәбиятчылар атаклы рус язучысы Аксаков, шулай ук танылган Мусин-Пушкин, Радищев, Чадаев; бояр дәрәҗәсе һәм Мәскәү тирәләрендә авыллар биләгән Булгаковлар, Иван Бунин, Иван III заманында Урдадан чыккан Гардиннар... Кем генә соң Г.Р.Державинның, И.А.Тургеневның (морза Турген Арслан нәселе), Купринның һәм инде безнең заманда М.Львовның, әнисе татар булган Чыңгыз Айтматовның рус әдәбиятына керткән бер өлеше дә юк дип әйтер икән? Күп кенә әсәрләр халык авыз иҗаты дип йөртелә. Театр сәхнәләрендә без әтиле-уллы Абдуловларны күрәбез. Рус әдәби әкиятләрендәге Салтан патша (Солтан-хаким), Руслан (Арслан) һ.б.

Ә музыка өлкәсендәге Алябьев, Рахманинов, Скрябиннар (Урданың Сокур бәй нәселеннән). Рус халык җыры «Во поле березонка стояла»ның авторы Казан университеты укытучысы Нигъмәт Ибраһимов икәнен дә бик азлар гына беләдер. Рәссамнар Шишкин, Китаевлар...

Хәрбиләр... Рус кенәзләре татар морзаларын, бик тәҗрибәле булганнары өчен аларга утарлар һәм авыллар бүләк иткәннәр, татарлар исә ул җирләрне көнчыгыштан да, көнбатыштан да һөҗүм итүчеләрдән саклап торганнар. Чыгышлары белән Дмитрий Пожарский, Михаил Кутузов, Александр Суворов, кенәз Василий Кочубей—Петр I нең көрәштәше һ.б. татарлар булган.

Рус һәм совет армиясендә һәрвакытта да татарлар күп булган. Атаклы маршал Тухачевский (тухач-тукач—байрак йөртүче). Инде безнең заманда да татар хәрбиләре шактый, мисалга армия генералы М.Гәрәев. Совет армиясенең Генштаб башлыгы урынбасары һәм Әфганстанда, Мисырда хәрби киңәшче иде. Фашистлар әсирлегендә инженер-генерал Карбышев батырларча һәлак була. Үзенең автобиографиясендә ул бабасының Себер татары икәнен язып калдыра. Ватан сугышында керәшен татарлары генерал Яковлев белән Брест крепосте герое майор Гаврилов та тиңсез батырлыклар күрсәтәләр. Советлар Союзы герое исемен алучылар буенча татарлар дүртенче урында тора.

Галимнәр, татарлар һәм аларның буыннары Россия фәненә дә зур өлеш керткән. Россия фәннәр академиясенең беренче президенты Екатерина Дашкова булган (ул Урданың 1400 елгы морзасы Дашек нәселеннән). Гавриил Романович Державин морза Ибраһим нәселеннән, морза үз вакытында Зур Урдадан бөек кенәз Василий Васильевичка хезмәткә килгән. Ул шагыйрь генә түгел, дәүләт эшлеклесе дә булган. Россия дәүләтенең беренче тарихын Н.Карамзин язган,ул чыгышы белән татар дворяны Кара Морза тамырыннан. Инде безнең заманнарда СССР Фәннәр Академиясенең җитәкчесе академик Мстислав Кельдыш поляклашкан татар дворяннарыннан. Безнең замандашыбыз Тимирязев Урдадан 1408 елны бөек кенәз Василий Дмитриевичка хезмәткә кергән Ибраһим Тимеряз нәселеннән булган.

Дәүләт эшлеклеләре: Россия тәхетенә Борис Годунов утырганына кадәр Иван Грозный Бикбулатовичны премьер-министр итеп куйган. Аракчеев та бик зур эшчәнлек күрсәткән. Аның турында А.С.Пушкин: «нинди бөек һәм атаклы булган Кочубей, аның җирләренең дә иге-чиге булмаган...»—дип язып калдырган. Ә күпме зыялы татарлар Мәскәүгә «шәрекь» җирләрен үзләштерергә ярдәм иткәннәр! Мәсәлән, XIV гасырда Россиянең Һиндстандагы беренче илчесе Әстерхан татары Касыймов булган. Совет заманнарында илчеләр Йәмәндә, Төркиядә, Әфганстанда һ.б. илләрдә шулай ук татарлар булган.

Рус тарихында татарларның эзе-буразнасы шактый тирән, культурология дәреслекләрендә моны чагылдырырга кирәк иде, болар бит Россиянең һәр патриоты горурланырлык фактлар, һаман да татарларны рус халкы өчен «дошман» итеп сурәтләүдән туктарга бик вакыт.

Шул ук культурология дәреслекләрендә: «Монгол гореф-гадәтләре рус

аксөякләре тарафыннан күчереп алынган, мәсәлән, патшага хәләл җефетен дә аларның иң чибәр кызларыннан сайлаганнар, сарай хезмәтенең дә киң тармакларына... лачын белән ауга йөрү, бурзайлар белән ауга чыгу да алардан күчкән. Рус казаклары алардан бик күп сугыш һөнәрләренә өйрәнгән, яшеренеп засада полклары, «лава», «куренной» формаларын армиягә һәм тыныч тормышка да кертү һ.б. шактый булган.

Әмма ул дәреслекләрдә төрки-татарларның руслар белән мәдәни һ.б. бәйләнешләрен сөйләү урынына, «христианлыкның ислам динен җиңүе белән горурлану», Иван Грозныйның җиңүеннән соң йөз еллар үткәч тә аның канлы эшләрен хуплау гына бар.

Ярар, шулай да булсын, ди: революциягә кадәрге тарихчы хәзерге кебек тирән тарихи белемнәргә ия булмаган, аннары ул бит патшага хезмәт иткән. Ләкин бит бүгенге «рус тарихчылары да шул ук «бер җырны җырлыйлар», патша империясенең идеологиясен алга сөреп, хакимият һәм чиркәүнең агрессив асылын аңлатмакчы булалар. Әле хәзер дә рус зыялылары арасында, халыкка хезмәт итү урынына, хакимияткә хезмәт итеп, хакыйкатькә түгел, ә ялганга, тәлинкә тотарга тырышалар (А.Х .Борһанов).

## Телем—дустым минем

Мәктәп дәреслекләренең авторлары рус мәдәниятенә татарлардан кергән алынма сүз-гыйбарәләрне кире кага алмыйлар. Татар мәдәниятенең рус мәдәниятенә йогынтысы рус теленә кергән татар сүзләре—алынмалары аша да булган; сүзләр исә әйбер белән бергә алына; яңа сүзләр, гыйбарә-терминнар, аңлашулар дусларның үзенчәлегенә һәм фикер йөртүләренә дә тәэсир итми калмаган, әлбәттә. (Бу хакта, ягъни россияннарга Евразия үзенчәлеге төп элемент булып керү турында күп язылган (Трубецкой һ.б. китапларында).

Бер халыктан икенчесенә күчереп алу, әгәр дә ул бигрәк тә күрше халыкларныкы да булса, объектив закончалыклы күренеш. Хәзер, әйтик, хәтта америка гамбургерларын, бигмакларын ашыйбыз, кока-кола эчәбез, джинс чалбар-юбкалар футболка-кроссовкалар киябез икән—болар бит рус аш-суына кайчандыр татар шашлыклары, токмач, пилмән, бәлеш һ.б. да кергәнгә дәлил генә. Ә киемнәр: толып, ыштан, халат, шәл, башмак, башлык—һәммәсе татарлардан кергән ич, һәр чорның үз теле-үз йөзе һәм үзенчә күчереп алуы да бар.

Сүз һәрвакыт фикерләүне, уйлауны чагылдыра. Уй-фикерләүдән соң кешенең эш-гамәлләре, үз-үзен тотышы, тәртибе килеп туа. Димәк, сүз, кайбер авторлар уйлаганча, аралашу чарасы гына түгел. Әйтик, «тынычлык» сүзе «сугыш юк» дигән сүз генә түгел бит әле, ул дәүләтләрнең дистә еллар буе алып барган сәясәте дә, мәдәниятенең үсеше дә һәм халыкның мул-иркен тормышын күтәрү-тәэмин итү дә... Сүз теге яки бу әйберне (өстәл, урындык, тәрәзә һ.б.) шулай ук теге яки бу эш-гамәлне (уку, язу, эзләү, аралашу һ.б.), аннары тормыш-көнкүрештәге, фәндәге, фәлсәфәдәге хәл-әхвәлләрне дә аңлата. «Сүз белән кешеләрнең йөрәкләрен яндыр...» А.С.Пушкин бу гыйбарәне Коръәннән алып Мөхәммәт галәһисәламны шуңа чакырган. Сүз ул үзенең бер лексик мәгънәсен генә эченә алмый. Ул үзе аңлаткан бик күп мәгънәләрне, аларның фәнни дәрәҗәләрен һәм аларның тышкы бәйләнешләрен, аларның (прагматик) бәяләрен дә ачып бирә торган лексик берәмлек.

## Читтән алынган сүзләр нәрсә аңлата?

Теге культурология дәреслегендә рус теленә «татар теленнән бик аз сүзләр кергән: чердак, магазин...» дип кенә аңлаталар. Әлбәттә, рус теле соңгы йөз еллар эчендә, бигрәк тә Көнбатыш Европа телләре аша бик үскәндер. Ләкин татар сүз-гыйбарәләре элегрәк анда шактый күп булган. Бүгенге сүзлекләр күбесенчә архаизм , (иске) сүзләрне генә искә ала, ул сүзләр исә хәзер инде әһәмиятләрен дә югалтканнар. Мисалга, арчак—ыңгырчак, аргамак—ат, чаптар

ат; аршин, арык, атаман, караул, есаул, атлас, аул, бадана -кулчак, ягьни кулга кия торган тимердән үрелгән бияләй (шуннан Колчак исеме), бадья, байбак, байгуш, балакир—сөт савыты (шуннан Балакиревлар), амбар, алтын (алты тәңкәгә яки өч тиенгә тиң—шуннан биш алтынлык), алпавыт һ.б. бик күп сүзләр, инде социаль әһәмиятен югалтып, төшеп калганнар.

Әмма әле бүген дә кулланылышта булган татар сүзләре дә шактый күп. Рус телендә хәзер «чердак»—чарлак, «дорога—«даруга», «лошадь»—алаша, «корзина»—кәрзин; кием-салымнан «шаровар», «ыштан», «халат», башлык», «башмак», кәвеш—«калош»; азык-төлектән—«пилмән», «бәлеш» һ.б.— кабатлансак та, әйтеп китәбез әле... Хәтта «кәрзин», «кинжал», «булат», «түбәтәй», «аркан», «буран» һ.б. бездән-татарлардан барып кергән бит.

## Тарихи белемнәр чыганагы буларак сүзләр

Бер телдән икенче телгә күчерелеп алынган сүзләр нәрсә турында сөйлиләр соң? Әлбәттә, әйткәнебезчә, йөз еллар дәвамында рус теленнән татар сүзләре кысырыклап чыгарылган. Ләкин әле бүген дә сүз тамырларына карап (этимологиягә) татарларның рус тарихында нинди урын тотканнарын әйтергә була. Бик күп кенә икътисад һәм мәдәният өлкәсендәге сүзләр татарчадан килә бит әле. Әйтик, «кремль» (кирмән), кирпеч, сандык, тара, тариф, чапрак, урман, арба, батрак, бурлак, бояр, «богатырь»—батыр-баһадир, базар, кәҗә, баран, сабантуй, чәй һ.б. һ.б. Мисалга, дәреслекләрдә еш кына «боярин», «бояре» сүзләре кулланыла. Ә төбендә бит татарның «бай ир»е ята! Кайбер сүзләр хәзер инде беренчел мәгънәләрен яшерә дә төшкән. Мәсәлән, һәркем белгән «товарищ» сүзе ике татар сүзеннән «товар» «иш», Руслар инде шул сүз белән ничә гасырлар буе яши, диген! Әле бит А.С.Пушкин да: «Товарищ, верь, взойдет она, Звезда пленительного счастья...»—дип язган. Әмма... бәхет кенә һаман еракта әле.

М.Худяков үз хезмәтләрендә «балалайка» сүзенең дә татардан булганлыгын исбат итә.

Һәр сүз аркылы үзара мөнәсәбәтләрне ачыкларга була. Мисалы—татар сүзе «казак»—атлы казак мәгънәсен белдергән.Алар Алтын Урданың атлы сугышчылары булган һәм дәүләтнең ил чикләрен саклап торганнар, тора-бара аларга рус алпавытларыннан качып киткән рус крестьяннары да килеп кушыла барган. Әкренләп аларның саны үсә барган һәм Россия чикләрендә рус казаклары үскән-көчәйгән. Хәзер инде «казак» сүзенең татарныкы икәнен бик азлар гына беләдер. Менә шулай безнең сүзебез саф рус сүзе булып киткән һәм әле кайбер тарихчылар аны Россия чикләрен саклаучылар итеп тә күрсәтергә тырышалар.

Әгәр дә без хәзер рус телендәге «базар» сүзләрен (лексика терминнарын) Алтын Урда чорында ук барлыкка килгән, дисәк, күпләр ышанмыйча, елмаер гына иделәр. Ә бит шулай дип дәлилләргә бөтен нигезләр бар. Кешеләр бит һәрвакыт үзләре яшәр өчен төп нигез шартларны булдырганнар: азык-төлек, кием-салым, йорт кирәк-яраклары, хезмәт кораллары, сәүдәгәрлек һ.б,—болар сөйләп бетермәслек күп. Алар бер халыкның икенче халык белән аралашуында да нык чагылган. Шуннан ул сүз—гыйбарәләр аерым төшенчәләр белән билгеләнгән. Алар билгеле бер социаль-икътисади шартларда башка телләргә дә үтеп кергән.

Рус теленә кергән татар сүзләре «товар» («туар-тывар») нәрсә аңлаткан? Русларның икътисади фикерләүләрен үстергән диган сүз. Русларга «деньги» («тәңкә») сүзе килеп керү дә шул ук «товар» сүзе аша түгелме соң? Ә аңа кадәр, бик борынгы заманнарда, әле акча «тәңкә» сүзе юк чакта, төркиләр-татарлар бит тиешле бер урынга, уз «товарын»—малын куйган да, «биш тиен», «ун тиен» дип бәя биргән. Теләгән кеше «биш тиен» (тиен тиресе) яки «ун тиен» түләп алган. Руста безнең бу «тиен» сүзе кереп китмәгән, алар үз вак акчаларына, ук тоткан сугышчы сукканнар да, «копейка»—«копья» сүзен алганнар.

Казына башласаң, менә бит ул Тарих нинди!

Аннары, «базар» сүзе үзе дә төрки-татарлардан килеп кергән ич. Татарлар тәңкәләр сукканнар. Хәтта руслар үзләре тәнкәләр суга башлагач та элгәре

аларга гарәп хәрефләре белән татар сүзләрен яза торган булганнар.

Башта Россиядә акчалар агачтан, күннән булган. XIV гасырда рус кенәзе Иван III тимер—бакыр-көмеш акчалар суга башлаган. Димәк, Алтын Урданың бу мәсьәләдә дә зур йогынтысы булган. Әйткәнебезчә, аларда башта гарәп хәрефләре белән татар сүзләре генә язылган. Менә шул рәвешле, рус җирләрендә товар—акча («товар—деньги») мөнәсәбәтләре барлыкка килгән. Әллә бу хәлләр рус икътисади фикеренә һәм финансына йогынты ясамаганнардыр дип уйлыйсызмы?

... Йөз еллар үткән. Күп кенә татар сәүдәгәрләре, зыялылары йотылып руслашкан, әмма аларда барыбер татар рухы, үз ата-бабаларының эшгамәлләренә хозурлыгы сакланып калган, күпләр, диннәрен һәм исемнәрен алыштырып, христиан диненә күчкән, үзләрен «рус» дип йөртә башлаган.

Ә дәреслек авторлары әле һаман да «татар-монгол иго»сы дип, ясак түләтергә теләгән татарларга һаман да нәфрәт уятырга теләп язуларын дәвам итәләр... Әллә болар татар халкының горурлыгына, үз дәрәҗәләренә китереп сукмыймы? Һәм шушы шартларда әлеге дәреслек авторлары ике мәдәният өчен уңай йогынты ясый, дип әйтеп буламы? Татарларны «дошман» итеп күрү шундый ук иртәрәк язылган дәреслекләрдә дә бар. Бу мөнәсәбәт хәзер гади рус кешесенең аңында йөз елларча яши һәм ул аның дәреслегенә һич кенә дә шикләнми. Бу тискәре уй-фикерләр нигездә революциягә кадәрле авторларның китапларыннан алына.

«Татар тәртипләре,—дип яза С.Ф.Платонов,—Рәсәй өчен бик авыр булган. Баскаклар һәм кораллы гаскәрләре булган татар түрәләре халыкны бик нык җәберләгән, татарларның ясагы бик авыр һәм мәсхәрәле булган, (бу ул вакыттагыча «десятина», ягъни табышыңның 10%ын ясакка түлә – М.М.) дигән сүз. Әмма ләкин халыкны «баскаклар түгел», ә үз ясак җыючылары җәберләгән икән ләбаса (ә кайчан һәм кайда ясак җыючыларны кочак җәеп каршы алганнар?—М.М.). Рус кенәзләренең үзләре ясак җыючылар»,—дип яза С.Ф.Платонов —халыкны татарлар белән турыдан-туры бәйләнешка кертүдән, димәк, алар ягыннан еш кына булырлык көчләү-җәберләүләрдән дә коткарып калган» (С.Ф.Платонов).

Рус тарихчылары Россия дәүләтенең сугышчан, басып алучанлыгын акламакчылар. Мәсәлән, шул ук С.Ф.Платонов, Казанны яулап алуны сурәтләп, болай яза: «Шәһәр тулысынча яндырылган, татар сугышчылары якын-тирәдәге урманнарда кырып бетерелгән. Казан патшасы Едигәй (Ядигар) әсирлеккә алынып, чукындырылган, шулай итеп, Казан ханлыгы тулысынча юкка чыккан... Казан татарлары һәм аларга буйсындырылган халыклар Мәскәү тирәләренә һаман да тынгылык бирмәгәннәр, һәм русларның шәрекъкә таба яулап алу юлын бикләп торганнар...»

Ничек»бикләп торганнар» икән? Димәк, алар алга табан да чит җирләрне басып алуга комачаулаганнар. Бик ачыктан-ачык һәм әхлаксыз рәвештә шулай язылган. Татарлар үз җирләрендә, беркемгә дә комачауламыйча, гомер сөргәннәр. Димәк, болай фикерләгәндә, Польша да, Прибалтика белән Румыния дә Көнбатышка табан юлны ябып тора, ә Төркия диңгез бугазларын бирми—димәк, боларның барысын да тар-мар итәргә кирәктер? Әмма... Россиянең моңа көче җитми, әлбәттә.

Платонов менә мондый нәтиҗәләр ясый: «Татар патшалыгын буйсындыру—ул халыкның бөек эше иде... Ниһаять, христианлыкның ислам динен җиңүе Европаның Азияне дә җиңүе тантанасы булды. Үз җиңүенең барлык бөеклеген аңлаган рус халкы аның хакында җырлар җырлады, шуның өчен Иван IV не Грозный (Явыз патша) дип, эпик (тарихи) дәрәҗәгә күтәрде.» (С.Ф.Платонов).

Шушы сүзләрдә Мәскәү патшаларының басып алу сәясәтенә тарихчылары да тулысынча дан җырлаганлыклары ачык чагыла. Һәм иң төп фикер—«христианлыкның ислам динен җиңүе». Нәкъ шушы фикерне бүгенге авторлар да күтәреп алды, алар христианлыкның ислам дине өстеннән җиңү яулавын, руссиannар арасында руслар гына түгел, ә күпмилләтле рус булмаган халыклар да яшәвен оныталар. Әле күптән түгел генә Россия президенты В.В.Путин: «Россиядә 20 миллион мөселман яши»,—дип игълан иткән иде. Без—катнаш халык. «Мин рус түгел, әмма россиянмын»,—дип татар шагыйре Әхмәт Ерикәй

язса: «Мин татармын, ләкин каннар катыш татар...»—дип рус шагыйре Корнилов та язган иде.

Аннары бит тарихи белемнәр дә артты, хәзер инде тарихчылар күбесенчә тарихи фактларга таяна, ә элекке әкиятләргә ышанмый, яки кульъязмаларның, язучыларның һ.б. язмаларына көлеп кенә карый.

Дәреслек авторлары исә һаман да чеп-чи уйдырма язалар, рус балаларында татар—«дошман» дигән сурәтне тудыралар (»История отечества. Учеб.пособие для 8 кл. с.ш. Коллектив).

## Хәзерге татарлар турында берничә сүз

Әлбәттә, бүгенге рус теле татарлардан сүзләр алуга мохтаҗ түгел. Заманнар үзгәрә. Россия белән дүрт йөз ел яшәү дәвамында, татар теле дә руслардан күп сүзләр алды; рус теленең фонетикасы, морфологиясе һәм синтаксисы йогынтысы аркасында үз грамматикасы да үзгәрешләр кичерде. Рус телен бик яхшы белгән татарлар хәзер үз телен яхшы белгәннәреннән күпкә артыграктыр.

Шулай булуга карамастан, халык рухы яши, халыкның тарихи хәтере бар, шуның нигезендә татар җәмгыятенең милли үз аерымлыгын яшәү тәррәкый итә. Халыкның милли үзаңы, рус түрәләренең рухи кысымнарыннан азат булырга теләп, егерменче гасырның туксанынчы елларында бик активлашып киткән иде. Фәндә, хөкүмәттә, идарә итүдә, әдәбиятта, сәнгатьтә, музыкада, рәсем сәнгатендә, сәясәттә, дипломатиядә татарлар һәм аларның токымнары милли аерымлык сыйфатлары белән генә аерылып тормый; рус зыялылары арасында бүген Россия фәннәр академиясенең танылган академиклары физик Роальд Сәгъдиев, Камил Вәлиев, А.Сюнәев, философ Булат Галиев, кардиолог Ринат Акчурин һ.б. бар. Татар халкының талантлы уллары һәм кызлары Европа мәдәниятенә дә үз өлешләрен һаман кертәләр.

Ә спортта күпме данлыклы милләттәшләребез?! Футболчылар Г.Хөсәенов. Р.Дасаев, хоккейчы Р.Нигъмәтуллин һ.б. Бүгенге Россия данын яклаучы теннисчыларыбыз Ш.Тарпищев (тренер), Марат Сафин. Шахмат буенча дөнья чемпионы булган Алисә Галләмова... Әмма беркем дә аларны ассызыклап татарлар дип әйтми. Һәм шунысы яхшы да, без үзебезне күптән инде шушы дәүләтнең гражданнары, россияннәр итеп хис итәбез, без бу дәүләтне төзүчеләр һәм дошманнардан яклаучылар арасында.

Татарстан тарихчылары Урта гасырлар чорына ничегрәк карый соң? Г. Ковальская «Татарстан тарихы» дәреслегендә руслар белән татарларның һәрвакыт бердәм, иңгә-иң куеп яшәүләре турында яза. Татарстанда хәзер татарлар руслардан әз генә күбрәк, аларның мул-тыныч яшәве—ике милләтнең дә тыныч, килешеп яшәве дигән сүз ул. Бездә мәктәпләрдә татар укучылары да, рус укучылары да Казанны кайчандыр руслар яулап алганлыгы турында тузынып сөйләнми.

## Мәдәниятләрнең үзара килешү–сөйләшүе

Мәгълүмати көрәш бай капиталистик илләрнең идеаллары, аларның кыйммәтләре белән җир шарындагы күпчелек ярлылар арасындагы көрәш ул. Мөселман дөньясы, гаять күп нефть байлыклары булса да, үз халкын туйдыра алмый, чөнки аның байлыкларын капиталистик илләр талап бетерә.

Мәдәниятләрнең үзара килешү-сөйләшүләре, цивилизацияләрнең килешүе күршеләреңнең Урта гасырда яшәгәнлекләрен аңлау-төшенү өчен кирәк түгелмени? Тынычлык һәм кешелекне төрле һәлакәтләрдән йолып калу хакына гаделлек-дөреслек өчен көрәшү кирәкмимени? Цивилизацияләрнең үзара килешүе халыкларның мәдәни психологиясе дәрәҗәсенә, аларның бер-берләрен аңлау дәрәҗәсенә дә бәйле. Һәр халыкның зыялы акыллыларын халыкларны якынайту юлына юнәлдерергә кирәк. Белмәү, Фицжеральд ишеләрнең наданлыклары һәркайда нәфрәтләнү һәм сугышлар гына тудыра. Моны халыклар күптән белгәннәр.

*Наданнарны дәваламас табиблар,*
*Наданлыкны гыйлемең белән дәвала.*
*Акыл-гыйлем—кайсыдыр шул бер баудыр –*
*Упкыннан безне һәрчак тотып торыр.*

Й.Баласагуни.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы да рим-католик чиркәүләре белән мөселман диннәре арасында сөйләшү-килешүләр алып барырга чакыра... Әмма бу сөйләшүләрнең дәүләт-хөкүмәтләр арасында, сәяси рәвештә алып барылырга тиешлеге хакында бер сүз дә юк. Башка мәдәниятләрне, башка халыкларның гореф-гадәтләрен белү мондый сөйләшүләрдә иң кирәклеседер.

Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында бу сөйләшүләр халыклар мәдәниятендә ничек чагыла соң? Халыкларның төп өлеше бу гамәлдән читтә кала. Моны Россия халкының мәдәни мәнфәгатьләре никадәр «европалашкан» мисалында да күрергә була. А.А. Андреевның тикшеренүләре Европа мәдәниятенең Россия мәдәниятенә бик аз үтеп керүе турында сөйли. Гамәлдә россиялеләрнең дүрттән бер өлеше читтә кала бирә. А.Андреев халыкны өч өлешкә бүлеп карый: «мәгълүматлылар» (нигездә эшмәкәрләр, студентлар һәм зыялылар), «кызыксынучылар» (хәрбиләр, хезмәткәрләр, инженер-техник вәкилләр), сәүдә һәм хезмәт өлкәсе кешеләре), «читкә тибәрелгәннәр» (җәмгыятьнең иң түбән катламы—эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре һәм пенсионерлар). Халыкның өчтән бере—Европа мәдәнияте белән кинофильмнар һәм әдәбият аша гына таныш.

Америка халкының күпме өлеше генә мөселман илләре мәдәнияте белән кызыксына икән? Бик аз өлешедер, мөгаен. Шулай булгач, ике мәдәният арасында нинди эшлекле сөйләшү булырга мөмкин.

Мисыр кинофильмнар эшләп чыгару буенча Һиндстаннан кала икенче урында тора. Америка халкы ул фильмнарны карыймы? Юк, әлбәттә. Алар ислам дөньясы турында бары тик телевизион тапшырулар аша гына беләләр. 2001 елның II сентябрендә булган фаҗигадән соң исламга каршы мәгълүмат күпкә артты. Көнбатыш белән Көнчыгыш мәдәниятләре арасында нинди сөйләшү-килешүләр булырга мөмкин?

## Йомгак

*Россиядә мәдәниятләр сөйләшүен уңышлы башкарырлык социаль-сәяси шартлар бармы? Дини тәрбия бирү, милләтләрнең килешеп яшәвен ничек хәл итеп булыр? Беренче чиратта, тарих дәреслекләреннән татарларга карата кире мөнәсәбәтне алып ташларга кирәк. Мәктәпләрдә укучыларның әхлакый хокукларын кысу булмаска тиеш, психик басым да ясалмаска тиеш.*

*Бары мәсьәләне шулай хәл иткәндә генә кеше хокукларын кысу бетерелер. Һәм бу сәяси дә, тарихи да, этик яктан да дөрес булыр иде.*

*Яшь буынны тәрбияләүнең төрле формалары—якшәмбе мәктәпләре, дин тарихы буенча факультатив курслар, христиан дине белән ислам динен дөрес тәрбияләү һ.б. Яңа тип дәреслекләр кирәк. Бары тик шул шартларда гына яшь буында Россия патриотизмы хисен һәм аңын тәрбияләргә мөмкин.*

*Дискуссия: “Безнең заман герое”*

**Рафаэль Мостафин**

## ЧОРЛАР ЧАТЫНДАГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘР

«Казан утлары»ндагы дискуссия бик вакытлы, хәтта бераз соңгарак калып та башланды. Чыннан да, XX гасыр ахырында, XXI гасыр башында тирә-як мохитыбызда бик зур үзгәрешләр булды, хәтта кыйблалар алмашынды. Мондый кискен икътисади һәм рухи үзгәрешләр әдәбиятка да тәэсир итми калмый. Соңгы 15-20 ел эчендә татар әдәбиятының үзендә нинди процесслар бара соң?

Иң беренче күзгә ташланган үзгәреш—буыннар алмашыну. Соңгы елларда арабыздан иң олпат, иң ихтирамлы, әдәбият дәреслекләренә кергән һәм әдәбиятыбызның классиклары булып саналган язучылар: Г. Әпсәләмов, А. Расих, М. Әмир, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Б. Камалов һәм башка бик күпләр китеп барды. Бу әле проза өлкәсендә генә. Поэзиягә күз ташласак исә анда да Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, Г. Афзал кебек һәрберсе бер шигъри дөнья тәшкил иткән шагыйрьләрнең арабыздан югалуын күрәбез.

Әлбәттә, изге урын буш калмый, өлкәннәр урынына яшьләр килеп тора. Әмма яшьләрне күпме генә мактасаң да, аларга әле олылар дәрәҗәсенә үсәргә дә үсәргә кирәк. Бу процессны мин “әдәбиятыбыздагы буыннар алмашыну кризисы” дип атар идем. Нәрсә генә әйтсәң дә, әдәбиятыбыз бүген кризис кичерә. Моны тиражларның бик нык кимүендә, әдәбиятка булган ихтыяҗның әкренләп сүнә баруында да күрергә була.

Әлбәттә, бу кризисның тамырлары бер буыннар алмашынуга гына кайтып калмыйча, шактый тирәнгә китә.

Сиксәненче еллар ахырында, туксанынчы еллар башында идеологиябез төптән үзгәрде. Элеккеге рухта тәрбияләнгән буынга 180 градуска борылу җиңел узды дип әйтеп булмый. Күпләр аптырап, югалып калды, хәзер нәрсәгә табынырга дип баш ватты.

Моннан ярты гасыр элек шигъриятебезне “бөек юлбашчы Сталинга” багышланган шигырьләр күмеп киткән иде. Сталин культын фаш иткәннән соң кайбер елгыр язучылар үз әсәрләрендәге бит саен кабатланып килгән Сталин исемен җиңел генә Ленин исеменә алмаштырдылар. Шуның белән заманга ярарга тырыштылар. Хәтта ул чорның классигы дәрәҗәсенә күтәрелгән Кави Нәҗми дә үзенең “Язгы җилләр” романында бу алымны кулланды. Һәм, әйтергә кирәк, әсәре моннан әллә ни отмады да, югалтмады да.

Әмма хәзер мәсьәлә бүтәнчәрәк. “Социализм” сүзен “капитализм” сүзенә алмаштырып кына яңа идеологиягә яраклашып булмый. Дөресен әйткәндә: яңа идеология үзе дә юк әле. Без аны һаман эзлибез генә, аның кирәклеге турында тәкрарлыйбыз гына... Шулай да күпчелек әкренләп булса да шуны аңлый: коммунистик идеология урынына яңа рәсми идеология, ягъни әзер догмалар кирәкми. Дөньяны дөрес аңлар өчен гомумкешелек идеологиясенә, халкыбызның мең еллык рухи мирасына таянырга кирәк. Әлбәттә, моны әйтүе җиңел, тормышка ашыруы гына шактый читен...

Идеология алышынуның бер конкрет мисалы итеп дингә карашның үзгәрүен күрсәтергә була. Татарда “иман” дигән бик мәгнәле, бик тирән төшенчә бар. Ул бер дингә генә кайтып калмый, халыкның бөтен әхлакый тормышын иңли. Әлбәттә, бу төшенчәне һәркем үзенчә

аңлый. Әмма шулай да бу төшенчәгә таянмыйча булмый. Имансыз яшәп карадык инде, нәрсәгә китергәнен яхшы күрдек... Гомумән, диннән башка безнең мең еллык әдәбиятны да аңлап булмый. Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Фатих Әмирхан һ. б. иҗатыннан динне алып ташласаң, нәрсә генә калыр икән?

Тагы бер зур үзгәреш—цензураның юкка чыгуы. Главлит дип аталган бу оешма теңкәбезгә күп тиде. Мин яхшы хәтерлим: Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыять" хикәясен бастырган вакытта цензура аны энә күзеннән үткәрде. Нәрсәгә генә бәйләнмәделәр! Имештер, язучы хәзерге тормыштан канәгать түгел, патриархаль үткәнне мактый... Имештер, партия ролен күрсәтми, алдынгы кеше образын тудырмый... һ.б., һ.б... Чыннан да, бу әсәр коммунистик идеология белән сугарылмаган—анысы хак. Шуңа күрә дә бу хикәянең дөньяга чыгуы әдәбиятыбызда динамит шартлаган төсле тәэсир ясады.

Хәзер инде цензура киртәләре алып ташланды. Нәрсә телисең—шуны яз. Нәрсәгә инанасың—шуны якла.

Әмма бу процессның да кире яклары бар. Совет чорында әдәбият барын да диярлек алмаштыра иде: публицистиканы да, журналистиканы да, философияне дә. Гомумән, сүз иреге булмаганда, әдәбият дөреслекне сөйләүче бердәнбер өлкә иде. Чөнки әдәби әсәрдә кайбер кыю фикерләрне образларга төреп, "текст астына" яшереп биреп була иде. Әйтик, Аяз Гыйләҗев шул чорда ук колхоз тормышының кимчелекле якларын бик үтемле итеп фаш итеп чыкты.

Хәзер исә бездә публицистика да, политология дә, башка өлкәләр дә үз аякларына басты. Әйтергә теләгән фикереңне образларга төрмичә дә әйтеп була. Шул уңай белән сиксәненче елларның икенче яртысында туксанынчы елларның башында әдәбиятыбызның публицистика тормагы бик нык үсте, аякка басты дип әйтергә кирәк. Бер Айдар Хәлимнең ялкынлы публицистикасы гына да ни тора! Шулай ук Фәүзия Бәйрәмова, Әмир Мәхмүтов, Әхмәт Рәшитов, Рафаэль Хәкимовларның чыгышлары суверенитет өчен көрәш барганда үз ролен уйнады, халыкның аңын агартуда зур әһәмияткә ия булды.

Шул ук вакытта матур әдәбиятка игътибар бераз кимеде. Ул элеккеге пәйгамбәрлек ролен шактый дәрәҗәдә югалтты. Хәер, бу бездә генә түгел, бөтен дөньяда да шулай. Тоталитаризм чорында язучы бердәнбер туры сүз, кыю фикер әйтүче булса, демократия чоры килү белән ул гади бер авторга әйләнә. Аңардан хәзер сәяхәткә тыкшынудан бигрәк, тулы канлы образлар тудыруны, эстетик кыйммәткә ия булган әсәрләр язуны көтәләр. Ә бу яктан караганда әдәбиятыбыз әле шактый аксый. Югарыда "кризис" дип аталган төшенчәгә монысы да керә.

Соңгы еллардагы тагы бер җитди үзгәреш—классик мирасыбызның әйләнеп кайтуы. Мин монда Гаяз Исхакый, Шиһап Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдинов кебек классик әдипләребезнең әсәрләре яңадан басылып, халыкка кайтуын күздә тотам. Алар белән бергә безнең тарихи аңыбыз да тулылана төште. Язучылар алдында да яңа мөмкинлекләр ачылды.

Әмма шуны да әйтергә кирәк: җитмеш елдан артык дәвердә мондый бай мирастан аерылып тору эзсез калмый. Бу арада өч-дүрт буын алмашынырга өлгерде. Яшь буыннар исә бүтәнчә уйлый, бүтәнчә фикер йөртә. Шуңа күрәдер, Исхакый томнары китап кибете киштәләрендә дә, китапханәләрдә дә шул көе хәрәкәтсез ята бирә. Югыйсә, Г. Исхакый әсәрләре басылу белән укучылар аларны ябырылып укырга тиешләр иде! Әмма чынлыкта алай булмады шул. Халыкның менталитеты үзгәрергә өлгерде. Җыен детектив әсәрләрне укыйлар, күрәзәчеләр турындагы әсәрләрне кулдан кулга йөртеп "йоталар" гына! Ә Г. Исхакый, Һ. Атласи, М. Солтангалиев кебек әдипләр әсәрләренә исә бик күпләрнең теше үтми.

Дискуссия "Безнең заман герое" дип атала. Әмма заман героен күрсәтәм дип кенә заманча әсәр тудырып булмый. Дискуссияне башлаган "Киләме, күрәбезме?" дигән мәкаләсендә Рәфыйк Шәрәфиев бу турыда бик ачык итеп яза. Элеккеге "уңай герой" урынына кемнәр килде, дигән сорауга, мәкаләнең авторы болай дип җавап кайтара: җыен әтрәк-әләм, казна караклары, мафия корольләре, азгынлыкның чиген узган бәндәләр, сөйрәлүче хатыннар, алар янында ялманып йөрүче мескеннәр. "Чыннан да безме соң бу?—дигән сорау бирә автор.—Бигрәкләр дә пычранганбыз, гөнаһка батканбыз, миһербансызланганбыз, йөзебезне үк югалта барабыз ич". Мондый куштырнак эчендәге "геройларны" Т. Галиуллинның "Тәүбә", "Элмәк", "Төнге юллар", М. Маликованың "Алтын ятьмә", "Өермә" романнарында һәм башка бик күп әсәрләрдә дә күрергә була. Р. Шәрәфиев бик дөрес әйткәнчә, социалистик реализм "бозыклык реализмы" белән алмашынып килә. Әлбәттә, мондый әсәрләрдәге персонажларны, никадәр тормышчан булмасыннар, чын заман герое дип атап булмый.

Минемчә, бу—вакытлы күренеш. Һәрьяктан камил булган "уңай герой" урынына җыен вак җаннарны күрсәтергә омтылу—бер чиктән икенче чиккә ташлану гына дип уйлыйм. Бу да шул ук кризисның бер чагылышы гына.

Безне алга дәшеп, киләчәгебезгә юл күрсәтүче геройларны Р. Шәрәфиев Марат Әмирханның "Тояк эзе", Флүс Латыйфинең "Ишелеп төшкән бәхет", Зиннур Хөснярның "Терсәк сугышы" романнарыннан эзләп карый. Әмма бер герой да аны тулысынча канәгатьләндерми. Ни өчен? Мәсәлән, "Ишелеп төшкән бәхет" каһарманы Сирин Сабиров турында ул "милләт башында торырлык кыю кеше түгел әле,—дип яза.—Хәтта андый көрәшчене тудырып үстерерлек киләчәге дә юк аның. Әсәрдә без Сириннәребезнең ничек итеп буыннан буынга рухи имгәтелүен генә ачык күрәбез".

Ничек кенә булмасын, Р. Шәрәфиевнең фикере белән тулысынча килешәм: әйе, әдәби персонажларыбыз вакланды, үрнәк булырлык геройларыбыз бөтенләй юкка чыкты. Бу да соңгы еллар әдәбиятына хас күренеш.

Тагы бер күзгә ташлана торган үзгәреш: соңгы 15-20 ел эчендә тарихка игътибар күзгә күренерлек артты, бер-бер артлы тарихи романнар, повестьлар, поэмалар һ. б. жанрдагы әсәрләр дөнья күрде. Милләт яшәсен өчен, аның тарихы да җанлы образларда яшәргә тиеш. Тарихсыз милләт— хәтерсез, үзаңсыз милләт дигән сүз. Торгынлык елларында тарих әдәбиятыбызда мыскаллап (һәм мыскыллап!) кына бирелә иде. Әйтик, тарихи-революцион роман язарга ярый иде. (Андыйлар шактый язылды да). Ә менә борынгырак чорга керүне бер дә хупламадылар. Шуңа да Нурихан Фәттах һәм Мөсәгыйт Хәбибуллин романнары ("Итил суы ака торур", "Сызгыра торган уклар", "Атилла", "Хан онытгы Хансөяр", "Аллаһы бүләге" һ.б.) әдәби тормышыбызда кыю бер адым, яңа сүз булып яңгырадылар.

Ул чорда язучылар гына түгел, тарихчылар да Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын читләтеп үтәләр иде. Бу күренешне Марат Әмирхан үзенең "Тояк эзе" романында бик ышандыргыч итеп тасвирлый. Романның төп герое Кәшшаф—тарихчы-галим. Ул Алтын Урда чорын өйрәнеп, бу дәвер турында дөреслекне әйтергә омтыла. Әмма аңа коточкыч интригалар, аяк чалулар, хыянәт һәм алдаулар аша үтәргә туры килә. Шулай итеп кенә үз максатыңа ирешеп була.

Өлкәннәр башлаган изге эшне яшьрәк буыннан Ф. Латыйфи, Р. Батулла, С. Шәмси, Р. Зәйдулла һ.б. дәвам итте. Тарихи әдәбият—үзе бер дискуссия таләп итә торган аерым һәм зур тема. Шуңа күрә мин монда, әлеге әсәрләргә тукталып тормыйча, шуны гына әйтеп китәм: тарихи темага игътибар арту—шулай ук соңгы еллар әдәбиятына хас күренеш.

Бу дискуссия уңаеннан үрнәк герой проблемасы да калка. Үрнәк геройга каршы чыгучылар болайрак фикер йөртә: имеш, әдәбият—тормышның көзгесе. Шулай булгач, тормышта нәрсә бар, язучы да шуны язарга, шуны күрсәтергә тиеш. Бер яктан караганда, дөрес кебек. Совет чорындагы "уңай геройлар" үзләренең ясалмалыклары, "корылган" булулары белән күңелне кайтаралар иде. Ләкин әдәбиятның төп максаты тормышны битараф рәвештә "чагылдыруга" гына кайтып калмый шул. Әдәбият—укучыны тәрбияләүче, тормышка юнәлеш биреп боручы рухи көч тә.

Уйлап карыйк. Рус телендә "литература" сүзе "литера", ягъни хәреф сүзеннән алынган. Татар телендә исә "әдәбият" сүзе "әдәп" сүзеннән ясалган. Шуңа күрә дә әдәпсез геройларны, җыен жулик-фахишәләрне халыкның күңеле кабул итми. Булган кадәресе дә туйдырды инде.

Әдәбият-сәнгать әсәренең тормышка йогынты ясау көченә бер генә мисал. Моннан бер ел-ел ярым элек үзәк телевидениедән "Бригада" исемле күп серияле телефильм күрсәтелде. Бу фильмның төп герое—атаклы мафиози. Бандит төркеменең башлыгы ролен талантлы артист Сергей Безруков уйнады. Бик тәэсирле итеп уйнады, мөлаем образ тудыра алды. Нәтиҗәдә, илнең төрле өлкәләрендә дистәләгән "бригадалар" барлыкка килде. Телефильм тәэсирендә яшь-җилкенчәкләр җинаять төркемнәре төзеп, "Бригада" геройларына ияреп, кеше талап, кибетләрне басып йөри башладылар. Бу турыда Эчке эшләр министрлыгында эшләүче зур бер түрә телевизордан сөйләде. Димәк, әдәбият-сәнгать кеше аңын формалаштырудагы ролен әле тулысынча югалтып бетермәгән. Тик кайсы якка таба юнәлдерә ул укучыны, бигрәк тә яшьләрне?

Тагы бер мисал, монысы инде рус классик әдәбиятыннан. Танылган рус язучысы И.С. Тургенев үзенең искиткеч мөлаем хатын-кыз образларын тудырган чакта, тәнкыйтьчеләр фикеренчә, андый хатын-кызлар тормышта әле бөтенләй булмаган. Әмма Тургенев язып чыккач, андый турылыклы, инсафлы, нечкә күңелле хатын-кызлар тормышта да барлыкка килә. Хәтта чит илләрдә дә аларны "Тургенев хатын-кызлары" дип йөртәләр. Безнең әдәбиятта да мондый образлар юк түгел. Юкка гына Р. Шәрәфиев Г. Әпсәләмовның "Алтын йолдыз" романы геройларын искә алмый.

Әйе, уңай герой кирәк, бик кирәк! Ләкин, ясалма түгел, тормышчан, тирә-як мохитның үзеннән алынган герой. Бармы соң безнең әдәбиятта андый геройлар?

Шундый геройны мин Факил Сафинның "Саташып аткан таң" романында күрдем ("Казан утлары", 2001, 8-9 саннар—беренче кисәк; 2002, 4-5 саннар—икенче кисәк, 10-11

саннар—өченче кисәк). Шуңа да бу романга тулырак тукталасым килә.

Романның исеме үк аның төп идеясен ачып бирә. Романның башлангыч өлешендә сүз төн уртасында кинәт яктырып киткән офыклар турында бара. Ләкин бу әле чын таң булып чыкмый, саташып аткан таң гына була. Әсәрне укып чыккач, шуны аңлыйсың: сүз монда Октябрь инкыйлабы турында бара. Әйе, революция бик күп татар һәм башка милләт язучылары тарафыннан таң белән тиңләштерелде (Мәҗит Гафури, Муса Җәлил, Һади Такташ һ. б.). Әмма чынлыкта бу саташып аткан таң гына булып чыкты. Һәм автор әсәрнең буеннан буена бу фикерен образлы күренешләр ярдәмендә раслый.

"Саташып аткан таң" романының төп герое Әхмәтсафа Дәүләтъяров кайсы ягы белән күңелне җәлеп итә? Беренчедән, ул—реаль тормыштан алынган чын кеше. Роман документаль нигезгә корылган. Әхмәтсафа Мостафа улы Дәүләтъяров (1905—1938)—күренекле җәмәгать эшлеклесе. Күп еллар буе ул партия-совет эшләрендә катнаша, соңыннан "Кызыл Татарстан" газетасының баш мөхәррире, ә 1937 елда Татарстанның Халык комиссарлары советы рәисе булып эшли. Кыскасы, Дәүләтъяров—республиканың иң беренче дәрәҗәдәге шәхесләреннән.

Әсәрдә тасвирланган башка персонажлар да—реаль кешеләр. Мин, мәсәлән, монда яшь Муса Җәлил образын очратып чын күңелдән шатландым. Муса монда шактый җанлы, елгыр, ихлас күңелле, хәрәкәтчән егет итеп күрсәтелә. Уңай яклары белән берлектә аның кимчелекләре дә яшерелми (әйтик, хатын-кызлар белән артык мавыгуы).

Башка тарихи шәхесләр дә (Шамил Усманов, Һади Такташ, Салих Сәйдәшев, Гомәр Толымбайский, Ченәкәй, Шәриф Камал, Нургали Надеев һәм башкалар) шулай ук бик җанлы, тарихка хилаф итмичә тасвирланганнар.

Үзем дә документаль әсәрләр язган кеше буларак, мин бу жанрның авырлыгын яхшы аңлыйм. Реаль дөреслек язучының хыялын бераз чикли, уйдырмага бирелеп китәргә ирек бирми. Ләкин шул ук вакытта ул язучы алдында зур мөмкинлекләр дә ача, үткәнне тулырак итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Иң мөһиме шунда: Ф. Сафин реаль кешенең тулы канлы образын тудыра алган. Әхмәтсафа Дәүләтъяров тырыш, эшчән, нәрсәгә тотынса да булдыра ала торган кеше. Авылда үссә дә ул шактый укымышлы, иң атаклы татар шагыйрьләренең иҗатын яттан белә. Байтагы белән аралашып үскән, фикерләре дә уртак. Шуңа күрә дә аны Татарстан китап нәшриятендә җаваплы урынга куялар. Ул искиткеч намуслы, кешелекле, алга омтылучан, туктаусыз үсә, камилләшә торган кеше. Аны берсеннән-берсе җаваплырак урыннарга куялар. Һәрберсен дә ул бик уңышлы башкара.

Әхмәтсафа Дәүләяров образының тагы бер көчле ягы—халык язмышы белән тыгыз бәйләнештә булуында. Оренбург өлкәсенең Каргалы авылында туып-үскән егет соңыннан Татарстан районнарында эшли. Тормыш агышында актив катнаша һәм халык кичергән афәтләрне күрә генә түгел, үзе дә тулысынча татый.

Геройның яшүсмер еллары гражданнар сугышы чорына туры килә. Бу чор турында әдәбиятыбызда шактый күп язылды инде. (Ибраһим Газиның "Онытылмас еллар" дилогиясен генә искә төшерергә була.) Әмма берьяклы, совет идеологиясе кушканча гына язылды. Ф. Сафин романында исә бу чор бөтенләй яңа күзлектән тасвирлана, чын тарих ачыла. Авылга аклар килсә, крестьян балаларын көчләп үз армияләренә алалар. Берәрсе каршы чыкса—стенага терәп аталар. Кызыллар килсә—шул ук хәл кабатлана. Кайберәүләр мобилизациядән качып-посып котылмакчы була. Андыйларны тотып, дезертир дип, шулай ук атуга хөкем итәләр. Кыскасы, әсәрдә гражданнар сугышы—халыкка зур афәтләр китергән, туганга каршы туган сугышы итеп күрсәтелә.

Бу уңайдан Шамил Усманов образы да яңа яктан ачыла. Ул татарлардан дивизия төзеп, крестьян балаларын акларга каршы сугышырга әзерли. Максаты изге: чөнки булачак мөстәкыйль дәүләт армиясез яши алмый! Форсаттан файдаланып, ул татар-башкорт республикасына нигез булырлык гаскәр төзеп калырга омтыла. Әмма теләге тормышка ашмый. Шундый авырлыклар белән оешкан гаскәрне большевиклар үз файдасына куллана. Теләкләре тормышка ашмагач, Ш. Усманов, 180 градуска борылып, йөз процентлы интернационалистка әйләнә...

Шул уңай белән әсәрдә Сталин образы да күрсәтелә. Аның кушуы буенча Ш. Усманов төзегән гаскәрне, өйрәтми-нитми, бер әзерлексез фронтның иң катлаулы урыннарына җибәрәләр. Менә шунда инде татар балаларының күбесе кырылып бетә дә.

Ил буенча репрессияләрне оештыручы—Сталин үзе. Татарстанда исә аның күрсәтмәләрен арттырып үтәүче—Алемасов.

НКВД наркомы Михайловка обком секретаре Алемасов менә нинди күрсәтмәләр бирә: "Аларны (ягъни—татарларны Р. М.) даими курку хәлендә тота алсак кына

Татреспубликада уңышка ирешеп булачак. Курку хисе генә татарларны асыл инстинктка—үз-үзләрен саклау инстинктына—кайтара, шушы хис булганда без үзебезне тыныч тота алачакбыз. Кеше үз-үзен саклау турында уйлый башладымы, идея, дуслык, намус, вөҗдан дигән төшенчәләрнең поты сукыр бер тиенгә әйләнә..."

Әсәрнең геройлары барысын да аңламасалар да, бу афәтне бик авыр кичерәләр. "Яшәүнең яме качты. Эштә бер-беребезгә күтәрелеп сүз әйтергә куркабыз. Нинди ил бу, нинди чор бу?"—дип өзгәләнә Әхмәтсафаның хатыны Рабига.

Бер гаебе дә булмаса да, Дәүләтъяровны кулга алып төрмәгә ябалар. Һәм вәхшиләрчә җәзалый башлыйлар. Кыйналган-сытылган хәлендә Дәүләтъяров төрмә камерасында Шамил Усманов белән очраша, "ни өчен бу газаплар безгә, безнең ни гаебебез бар?—дип сыкрана. Шамил Усманов ул сорауга болай дип җавап бирә:

"— Гаепме? Бар анысы. Без революциягә сукырларча ышандык. Без тарихның табигый агышына каршы гамәл кылуда турыдан-туры катнаштык, кан, үле гәүдәләр өстендә яңача тормыш төзергә маташтык. Бу иң зур ахмаклык булган. Мин моны соңрак аңладым, таш капчыкка эләккәч, уйларга вакыт бар менә... Ата-бабаларыбызның йолаларына төкереп, үзебезчә әхлак әвәләдек, сәясәт укмаштырдык, денсез-имансыз кавемгә әйләндек. Шушы хәлдә үзебезне гаепсез итеп, акланып маташу зур хата, Дәүләтъяров. Болар барысы да безнең акыл, безнең йөрәк белән эшләнде. Без үстергән үсентеләр агулы җимеш бирделәр. Аларны без ашамыйча, кем ашасын?"

Әлбәттә, чынлыкта Шамил Усмановның бу сүзләрне әйтү-әйтмәве билгесез. Әмма ул сүзләрдә авторның чорны бүгенге күзлектән карап аңлавы сизелә. Дәүләтъяров һәм Ш. Усмановлар язмышы аша автор халык кичергәнне тасвирлый.

Автор бу әсәрдә үзен көчле аналитик, зур акыл иясе итеп тә күрсәтә, ул социаль күренешләр тамырын ачып бирергә омтыла, тарихи логиканы тирән һәм яңача аңлап эш итә.

Романны укып шул нәтиҗәгә килдем: әйе, әдәбият—тормыш көзгесе. Әмма аның роле моның белән генә чикләнми, ул кеше аңын формалаштыручы төп факторларның берсе дә. Ф. Сафин героенда укучы күңелен яуларлык сыйфатлар ярылып ята. Шул ук вакытта аның язмышы милләт, халык язмышы белән бик тыгыз бәйләнгән дә.

Факил Сафинның "Саташып аткан таң" романын мин соңгы еллар әдәбиятындагы иң җитди, иң уңышлы әсәрләрдән дип саныйм. Монда заман герое бөтен тулылыгы белән алдыбызга килеп баса. Иң мөһиме, автор заманча фикер йөртә, тарихны яңача күзли.

"Әсәрнең бер кимчелеге дә юкмыни?"—дип сораулары мөмкин. Бар алар. Романның беренче ике кисәге чын матур әдәбият рухында язылган. Өченче кисәгендә исә автор документлар, гаепләү актыннан озын-озын өзекләр китерә, кайвакыт турыдан-туры публицистик алым белән яза башлый. Бу әсәрдәге хәрәкәтне тоткарлый, жанр бөтенлеген боза. Документаль нигезгә корылган булса да роман, тулаем алганда, матур әдәбият әсәре бит!

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: XX гасыр азагында, XXI гасыр башында татар әдәбияты бик авыр чор—кризис чоры—кичерә. Кабатлап әйтик, моны тиражларның нык кимүендә, әдәби геройларның вакланауында, художестволы фикернең тоныклануында һәм югарыда күрсәтеп үтелгән башка бик күп кимчелекләрдә күрергә була.

Әмма, зур сикереш ясар өчен, кайвакыт бераз артка чигенү дә кирәк. Күргәнебезчә, түбән сыйфатлы һәм тирән мәгънә салынмаган әсәрләр белән беррәттән, тулы канлы образлары булган, яңача фикер йөртә алган әсәрләр дә дөнья күрә. Никадәр генә зарлансак та, уңай якларны да күрә белергә кирәк. Әйтик, милли әдәбият-сәнгать үсү өчен шартлар яхшыра төште: цензура бетте, дин яңадан әйләнеп кайтты, татар телендә яңа газета-журналлар чыга башлады, нәшриятләр дә байтак. Язучыларыбыз да, авырлык белән булса да, торгынлык елларында формалашкан шаблон алымнардан, әзер штамплардан әкренләп арына баралар. Болар барысы да киләчәккә өмет-ышаныч белән карарга нигез бирә һәм кызыклы яңа геройлар белән очрашуга өмет уята.

✤

*Миркасыйм Госмановка 70 яшь*

# КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ, ӘДИП, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Татар халкының күп гасырлы тарихын, мәдәниятен һәм әдәбиятын өйрәнү тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов исеме белән тыгыз бәйләнгән. 45 еллык фәнни-тикшеренү эшчәнлеге дәверендә аның тарафыннан конкрет тарихи проблемаларга багышланган һәм шулай ук тарихи чыганаклар базасын баетуга хезмәт итүче 450 дән артык төрле характердагы хезмәтләр иҗат ителгән. Ул хезмәтләр шактый кин тарихи дәверне, ягъни XIII—XX йөз башы тарихы, әдәбият белеме һәм мәдәнияте проблемаларын үз эченә ала.

Галимнең хезмәтләре, проблематикасы аның тормыш юлы, тәрҗемәи хәле белән тыгыз бәйләнгән.



Ул 1934 елның 31 маенда Көнбатыш Кытайның Синьцзян провинциясендәге (Шәркый Төркестандагы) Голҗа шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Әмма Госмановлар гаиләсенең нәселе тамырлары Татарстан җөмһүриятенең хәзерге Әтнә районындагы борынгы Олы Мәнгәр авылына барып тоташа.

XIX йөзнең 20 елларында ук аның бабалары башка күп кенә кавемдәшләре кебек үк бәхет эзләп хәзерге Казакъстан җирләренә күчеп китә. Анда алар игенчелек, умартачылык һәм соңрак сәүдә белән шөгыльләнәләр. 1917 елда, бөек социаль тетрәнүләр чорында, Госмановлар гаиләсе вакытлыча гына, "яхшы заманнар житкәнчегә кадәр" Россиянең концессиясе булган Голҗа шәһәренә күченеп китә. 1917 елдан соң чикләр ябылгач, гаилә Кытайда яшәп кала. Әмма, башка бик күпләр кебек, алар да башта Россия, ә аннан соң совет гражданлыгын саклап калалар.

1941 елда М.Госманов Голҗа шәһәрендәге татар мәктәбенең башлангыч сыйныфында укый башлый, ә аннан соң белем алуын рус гимназиясендә дәвам иттерә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, татар мәктәбендә балалар Казан һәм Мәскәүдә нәшер ителгән дәреслекләрдән файдаланганнар. Шул ук вакытта татар мәктәбендә укуның, совет мәктәбендә белем алу белән чагыштырганда, үзенчәлекләре дә булган. Анда укучылар бер үк вакытта уку-язу нигезләрен ике графика – гарәп һәм кириллица – нигезендә үзләштергәннәр. Бу хәл, үз чиратында, кызыксынучан укучыларга 1917 елга кадәр үк нәшер ителгән басмаларга да юл ачкан.

Күп милләтле төбәктә яшәү табигый рәвештә төрле кардәш төрки телләрне өйрәнүгә этәрә. Голҗа татарлары, туган телләреннән тыш, казакъ, кыргыз, уйгыр, үзбәк телләрендә дә җинел аралашалар. Соңрак бу хәл чыганакчы тарихчының профессиональ эшчәнлегенә һәм шулай ук тәрҗемәчелек өлкәсендә дә унай тәэсир ясый. Мәсәлән, атаклы язучы Ч.Айтматовның иҗаты белән татар укучысы беренче булып М.Госманов тәрҗемәләре аша таныша. Аның тарафыннан тәрҗемә ителгән "Җәмилә" повесте Казанда ике тапкыр (1962, 1965) басылып чыга. Шулай ук хәзерге

заман казакъ, уйгыр әдәбият үрнәкләрен дә ул турыдан-туры татар теленә тәрҗемә итеп укучыга ирештерә.

Һәр ел саен җәй айларында аңа әти-әнисе белән туган шәһәрен чолгап алган тауларга чыгарга һәм андагы җирле халыкның урта гасырларга хас булган кайбер үзенчәлекләрен саклаган тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре белән танышырга туры килә. Ургылып аккан тау елгаларында балык тоту, тирән тарлавыкларда һәм куе урманнарда тау кәҗәләре, мараллар аулау, тирмәдә яшәү, яшь-җилкенчәкләр уенында катнашу, атта чабулар — болар барысы да аның соңрак Казанда дөнья күргән "Киек сукмакларында" (1966) исемле беренче китабында моңлы бер жылылык белән тасвирланган. Бу басманы балалык һәм үсмер чакның онытылмас мизгелләре белән саубуллашу дип тә санарга була. Хәер, ул чорның башка характердагы истәлекләре дә аның күнелендә тирән эз калдыра. 1944 елның көзендә Көнбатыш Кытайның, ягъни Синьцзян провинциясенең җирле халкы гоминьданьның черек режимына каршы милли-азатлык хәрәкәтенә күтәрелә. Голҗа шәһәрендә урам сугышлары бара. Нәтиҗәдә, Синьцзян провинциясенең көнбатыштагы өч өлкәсен үз эченә алган яңа дәүләт - "Азат (соңрак - Инкыйлаби) Шәркый Төркестан" дәүләте барлыкка килә. Беркем тарафыннан да танылмаган бу дәүләт 1951 елга кадәр "мөстәкыйль" рәвештә яши.



*Туфан Миңнуллин белән. 1994 ел.*

1944—1951 елларда бу төбәктәге җирле халык арасында социалистик идеяләр торган саен киңрәк колач җәя бара. 50 еллар уртасында җирле татарлар арасында Ватанга кайту фикере тагын да көчәя, һәм 1955 елда Госмановлар гаиләсе СССРга (Казакъстанга) күчеп кайта.

1955—1958 елларда М.Госманов Сары-Болак совхозында, Талды-Курган өлкәсенең Киров районында шикәр заводында, ДОСААФ оешмасында һәм Алма-Ата киностудиясендә эшли. Шушы ук дәвердә ул Киров поселогындагы эшче яшьләр мәктәбендә урта белем алуын тәмамлый.

Әлбәттә, аның күңеле ата-бабалар ватаны булган Татарстанга, университетлы Казанга тартыла. 1958 елда ул бу теләгенә ирешә дә—Казанга килеп университетка укырга керә. Башта ул тарих-филология факультетының татар филологиясе бүлегендә, ә III курсны тәмамлагач тарих бүлегенә күчерелә һәм СССР тарихы кафедрасында чыганакчылык гыйлеме белән махсус шөгыльләнә башлый. Университетта уку дәверендә үк ул студентларның фәнни-тикшеренү эшенә керешеп китә, фольклор һәм археологик экспедицияләр эшчәнлегендә актив катнаша. Университетта уку дәверендә үк аның мәкаләләре республика матбугатында күренә башлый. Ә Җүчи Олысының (Алтын Урданың) башкаласы Яңа Сарайда археологик, казу эшләре вакытында табылган бер язма истәлек турындагы Мәскәүдә басылган мәкаләсе белән студентларның фәнни эшләре күргәзмәсендә катнашып, Бөтенсоюз Халык Хуҗалыгы Казанышлары (ВДНХ) медаленә лаек була. Университетны тәмамлаганда язган диплом эше дә Мәскәүдә басыла һәм шул аның кандидатлык диссертациясенә өлеш була.

Университетны тәмамлагач, М.Госманов СССР тарихы кафедрасында калдырыла, 1964—1967 елларда аспирантурада укып, 1968 елда XVII—XVIII йөз татар тарихи чыганакларын тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. 1967 елдан башлап ул СССР тарихы кафедрасында укытучылык эшчәнлеген башлап җибәрә. 1981 елда "XIV-XVI йөзләрдәге Җүчи Олысының ярлыкаш актлары" дигән темага докторлык диссертациясе яклап доктор һәм соңрак профессор дәрәҗәләрен ала, 1982 елдан совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасы, ә 1989 елда яңа ачылган татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында үзе оештырган татар халкы тарихы кафедрасын җитәкли. Бер үк вакытта ул 1988 елда кафедра каршында фәнни-тикшеренү археографик лабораториясенә дә нигез сала,

1985—1991 елларда Казан дәүләт университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры һәм ректор вазыйфаларын башкаручы булып та эшли.

М. Госмановның укытучылык эшчәнлеге, традицион дисциплиналардан лекцияләр курсы уку белән беррәттән, Идел-Урал буе халыклары тарихы чыганакчылыгы, иске татар палеографиясе кебек яңа курслар барлыкка китерү белән бергә үрелеп бара. 1968 елдан алып 1985 елга кадәр ул Татарстан тарихы буенча специализациянең (җирле тарих буенча махсус белем алучы төркемнең) җитәкчесе дә була.

М. Госмановның фәнни-тикшеренү өлкәсендәге төп юнәлеше булып Идел-Урал буе төрки халыкларының тарихы һәм мәдәниятенә караган XIII-XX йөз башы төрки язма чыганакларны өйрәнү тора. Татарстан һәм Россия Федерациясенең төрле өлкәләрендә сибелеп яшәүче татар халкы арасында татар, гарәп, фарсы телләрендә иҗат ителгән, күчерелгән язма ядкарьләрне җыю һәм тикшерү буенча оештырылган археографик экспедицияләр бу өлкәдә аерым урын алып тора.

1963 елда аның идеясе һәм инициативасы белән университетта археографик экспедиция оештырыла. Моны исә Казан ориенталистика мәктәбенең көнчыгыш кульязма ядкарьләрен җыю һәм өйрәнү өлкәсендәге элеккеге традицияләрен мәгълүм дәрәҗәдә торгызу дип тә бәяләргә кирәк.

1964 елдан башлап 1989 елга кадәр М. Госманов КДУның даими эшләп килгән археографик экспедициянең фәнни җитәкчесе булды. Экспедицияләр вакытында көнбатышта Мәскәү астындагы Касыйм төбәгеннән алып, көнчыгышта Иркутск өлкәсенә кадәр, төньякта Пермь-Вяткадан башлап, көньякта Әстерханга кадәр, ягъни Россия Федерациясенең өчтән ике өлешендә эзләнүләр булган дигән сүз.

Элеккеге биш автономияле республика һәм унбиш өлкәдәге татарлар яшәгән 900гә якын авылны тикшерү нәтиҗәсендә 9 меңнән артык кульязма һәм мең ярымга якын иске басма китаплар җыела. Экспедицияләрнең унышлы эшләве Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш кульязмалар фондын ике тапкыр диярлек баетырга мөмкинлек бирде. Әйтергә кирәк, археографик экспедиция үз эшчәнлеген хәзергә кадәр дәвам иттерә һәм милләттәшләребез яшәгән төбәкләрдән ел саен йөзләгән кульязма истәлекләр алып кайта.


*Хельсинкида татар җәмгыятендә мәҗлестә. 2002 ел.*

Җыелган кульязмаларда VII гасырдан алып XX гасыр уртасына кадәр вакыт эчендә иҗат ителгән әсәрләрнең текстлары теркәлгән. Жанр ягыннан караганда да алар гаять күптөрле. Нәрсәләр генә юк алар арасында: мөселман юриспруденциясенә караган дәү кульязмалар, шәрекъ филологиясе, ислам тарихы, астрономия, математика, география һәм фәннең башка тармакларына караган хезмәтләрнең күчермәләре, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият әсәрләре һ.б.

Галимнең халык арасында кульязма ядкарьләрне җыю һәм өйрәнү процессын яктырткан "Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары" исемле хезмәте Казанда 1984, 1994 елларда ике тапкыр нәшер ителеп, үзәк һәм җирле матбугатта югары бәя алды. Элеккеге СССРның төрле шәһәрләрендәге (Казан, Алма-Ата, Баку, Ереван, Киев, Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Симферополь, Ташкент, Томск, Уфа һ.б.) архивларда һәм фәнни китапханәләрдә татар халкы тарихы һәм әдәбиятына караган язма истәлекләрне ачыклау һәм фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрү буенча да М. Госманов тарафыннан ифрат зур эш башкарылды. Шундый истәлекләр нигезендә аның тарафыннан Идел—Урал буе төрки халыклары тарихы чыганакчылыгына багышланган "XVII-XVIII йөз татар тарихи чыганаклары" (Казан, 1972) һәм "Җучи Олысының ярлыкаш актлары" (Казан, 1979) исемле фундаменталь хезмәтләре дөнья

күрде. Тикшеренүләрнең бай чыганаклар корпусына нигезләнүе һәм аларны өйрәнү нигезендә ясалган нәтиҗәләрнең ышанычлылыгы Казан, Мәскәү, Баку, Тбилиси, Будапешт, Анкара һәм башка шәһәрләрдә дөнья күргән рецензияләрдә, ягъни халыкара фәнни җәмәгатьчелектә уңай яңгыраш тапты.

Археографик экспедицияләрдә, архив һәм китапханәләрдә табылган кульязмалар һәм 1917 елга кадәр дөнья күргән басмалар нигезендә М. Госманов тарафыннан XIX йөз татар әдәбияты классиклары Габделҗәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмуллаларның әдәби мираслары тикшерелеп, төп оригиналдагыча бастырып чыгарылды. Бу хезмәтләрнең әдәбиятыбыз тарихы өчен никадәрле әһәмиятле икәнлеген аңлау өчен берничә мисал китереп узу да җитәр. Мәсәлән, Г.Кандалыйның 1960 елда басылган китабында 2500 юлдан артык шигъри текст дөнья күргән булса, М. Госманов тарафыннан төзелеп, 1988 елда чыккан басма 8500 юл чамасы текстны үз эченә ала. Бу — мәсьәләнең бер ягы. Икенче яктан, Г. Кандалый, М. Акмулла китапларында галимнең классик әдипләребезнең тәфсилле тәрҗемәи хәлләре белән бергә аларның әдәбиятыбыз тарихында һәм, гомумән, иҗтимагый тормышыбызда тоткан урыннарын билгеләү һәм кабатланмас әдәби иҗатларының үзенчәлекләрен, әһәмиятен яктырткан монографик пландагы күләмле мәкалә-тикшеренүләре дә урын алган.



*«Азатлык» радиосы редакциясендә.*
*Сулдан: Надир Дәүләт, Фәрит Иделле. Прага, 1999 ел.*

Ул, шулай ук, XIII йөз болгар-татар шагыйре һәм фикер иясе Кол Гали, татар халык эпосы "Идегәй" һәм XVIII-XIX йөз мәгърифәтче шагыйре Габдрәхим Утыз-Имәни басмаларының текстологик һәм фәнни мөхәррире дә булды.

Галим җитәкчелегендә XVIII йөздә халык азатлыгы хәрәкәте тарихын өйрәнүгә мәгълүм өлеш керткән җыентык—1773—1775 еллардагы Крестьяннар сугышына караган татар документлары җыентыгы төзелә һәм бастырылып чыгарыла. Баш күтәрүчеләр лагерыннан чыккан һәм моңа кадәр аз өйрәнелгән 188 документ гарәп хәрефләре белән төп нөсхәдә һәм русчага тәрҗемәдә бастырылды. Нәтиҗәдә, Е.И.Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы тарихына караган беренче кульязма чыганакларның кыйммәтле комплексы фәнни хәрәкәткә кертелде.

М. Госманов аз өйрәнелгән тарихи чыганаклар нигезендә XIX—XX йөз башы күренекле татар мәгърифәтче галимнәре Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, Р. Фәхреддиннәрнең эшчәнлеген һәм мирасын яңача өйрәнеп җәмәгатьчелеккә тәкъдим итте.

Фәнне пропагандалап яисә киң җәмәгатьчелек игътибарын тарих фәненең хәл ителмәгән мәсьәләләренә юнәлтеп, М. Госманов вакытлы матбугат битләрендә фәнни-популяр һәм публицистик чыгышлар ясауга да зур игътибар бирә. Шундый характердагы басмаларның сайланма бер өлеше "Үткәннән - киләчәккә" (Казан, 1990) исемле җыентыкта дөнья күрде.

Тарихчы-галим яшь буынны халкыбызның данлы узганы белән таныштыру юнәлешендә дә нәтиҗәле эш алып бара. "Серле балбал" (1979), "Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт" (1977) исемле әсәрләр иҗат итте. Бу китаплар 1984 елда бертомлык булып кабат басылып чыкты.

Татарстан Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы, профессор һәм язучы М. Госманов тарафыннан барлыгы 450 дән артык фәнни хезмәт, шул исәптән 11 монография һәм җыентык бастырылган. Галимнең күп кенә мәкаләләре Алмания, АКШ, Төркия, Франция, Тайвань, Көньяк Корея һәм башка илләрдә нәшер ителүче фәнни журнал һәм җыентыкларда басылган. АКШ һәм Мажарстан галимнәре белән берлектә Берлин һәм Сегедта татарча тарихи чыганаклар буенча

ике китабы дөнья күрде. Моннан тыш 30 дан артык китап, тикшеренү галимнең мөхәррирлегендә һәм эшкәртүендә дөнья күрде.

Педагог-галим буларак М. Госманов фәнни алмаш әзерләү өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Аның гыйльми җитәкчелегендә 18 аспирант кандидатлык һәм ике шәкерте докторлык диссертацияләре яклады.



*Сулдан уңга: Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт, Миркасыйм Госманов, Сөләйман Даишев. 1982 ел.*

М. Госманов даими рәвештә бөтенроссия һәм халыкара фәнни конференция һәм симпозиумнарда катнаша һәм киң фәнни җәмәгатьчелекне халкыбызның тарихы, мәдәнияте белән таныштыруга зур өлеш кертә.

Казан дәүләт университетының проректоры булып эшләгән дәвердә М. Госманов төрле яңа подразделениеләр — язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару буенча фәнни-тикшеренү археографик лаборатория, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты (һәм аңдагы берничә тарихи-филологик кафедралар), экология факультетын оештыруда актив катнашты. Аның якыннан катнашуы нәтиҗәсендә Казан дәүләт университеты берничә чит ил университетлары белән элемтәләр урнаштырды (Венгрия, Алмания, Кытай, Төркия).

М. Госманов Россия Фәннәр академиясенең Археографик комиссиясе (1969 елдан), "Казан утлары", "Мәгариф" журналлары редакцияләре әгъзасы булып торды яки тора. Ул тарих һәм филология фәннәреннән докторлык дәрәҗәсе бирү буенча гыйльми советлар әгъзасы да.

Татарстан Фәннәр академиясен нигезләүчеләр арасында да без М. Госманов исемен очратабыз. Ул көнчыгышны өйрәнүчеләрнең XXXV Халыкара конгрессын (Будапешт, 1997) оештыру комитеты составында да нәтиҗәле эш алып барды. 1997 елның октябрь аенда Россиянең Көнчыгышны өйрәнүчеләр съезды аны ике елга Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыятенең президенты итеп сайлады.

Татарстанның атказанган фән эшлеклесе М. Госманов республикабызның иҗтимагый-мәдәни тормышында да актив катнаша. 1989 елдан алып татар телен һәм мәдәниятен үстерүгә өлеш кертүче "Җыен" фондының рәисе булып тора. Аның җитәкчелегендә һәм шул фондның ярдәме белән М. Худяков, К. Фукс, И. Гаспралының халкыбыз тарихын яктырткан, әмма элек "оныттырылган" хезмәтләре янадан дөнья күрде. Тынгысыз галимнең һәм аның бер төркем шәкертләренең тырышлыгында библиографик белешмәләр һәм күренекле шәхесләребезгә багышланган махсус җыентыклар сериясе чыга башлады.

Башкалабыз Казанга 1000 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек буенча республика комиссиясе әгъзасы сыйфатында М. Госманов 1998—2000 елларда Җүчи Олысы тарихы, Урта Иделнең тарихи географиясе һәм безнең төбәктә шәһәрләр барлыкка килүе һәм үсешенә багышланган өч халыкара конференцияне оештыруда һәм фәнни яктан җитәкчелек итүдә, шулай ук федераль программа кысаларында үткәрелә торган "Бөек Идел юлы" халыкара фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашты.

Хәзерге вакытта М. Госманов язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару өлкәсендә интенсив тикшеренү һәм оештыру эшләре белән мәшгуль. Бу эшкә татар халкы тарихы кафедрасы хезмәткәрләре һәм студент яшьләр дә җәлеп ителә. Соңгы елларда галим 1917 елга кадәр Россия империясендәге һәм чит илләрдәге татар диаспоралары тарихын өйрәнүгә зур игътибар бирә. Әнә шулай итеп ул үзенең олуг юбилеен бертуктаусыз эзләнүләр, туган халкының тарихын пропагандалау кебек мәшәкатьле, мәгәр игелекле эшләр белән каршы ала.

**Җәүдәт МИҢНУЛЛИН,**
*КДУ доценты.*

Миркасыйм Госманов

# АЛТЫН УРДА: БАШЛАНГЫЧ ҺӘМ МИРАС*

XIII—XV гасырларда яшәгән гаҗәеп зур дәүләтнең—Җучи Олысының тарихына (соңрак ул Алтын Урда дип атала башлый) вакыт ягыннан да, киңлек-пространство тарафыннан да аерымланган хәлдә генә карарга ярамый. Чөнки бу тарихны тулаем Урта гасыр Авразия халыклары язмышында зур роль уйнаган һәм аңа кадәр булып узган, күп күренешләргә элгәр булып хезмәт иткән мөһим вакыйгалардан башка күз алдына китерүе мөмкин түгел.

Бу вакыйгалар XII гасыр ахырларында һәм XIII гасырның беренче яртысында Үзәк Азиядә аерым-аерым хөкем сөргән һәм озак вакытлар үзара ызгышып яшәгән күчмә кабиләләр берләшү нәтиҗәсендә яңа дәүләт туудан, гөрләп үсүдән—Бөек Монгол дәүләте барлыкка килүдән башлана. Дәүләт башына Тимучин (Тэмужин) дип аталган хөкемдар утыра. 1206 ел башында Тимучин хакан, ягъни барлык монголларның олуг ханы итеп сайланганда аңар Чыңгызхан дигән дәрәҗә—титул бирелә.

XIII гасырда ике кыйтгада да—Азия һәм Аурупа киңлекләрендә булып узган вакыйгаларның һәммәсе диярлек кешенең үз исемен алыштырган, шул үзенә күрә серле дәрәҗәне исем итеп йөрткән шәхес белән, дөресрәге аның эшчәнлеге белән бәйле. Чөнки Чыңгызхан үзенең хакимиятен ныгыткач һәм хәрби-административ, социаль үзгәртеп корулар үткәргәч, дәвамлы тышкы яулап алулар белән шөгыльләнә башлый. Сугышлар барган вакытта талау һәм салым (соңрак ясак) җыю аркылы күрше халыкларны эксплуатацияләү төп максат булып тора. Мондый хәл борынгы заманнар һәм Урта гасырлар өчен табигый күренеш санала иде.



Чыңгызхан үзе исән вакытта ук төрле чаралар—сәяси басым ясау һәм хәрби талау юлы белән Саян-Алтау таулары, Көньяк Себер, Уйгыр кенәзлекләренең җирләре һәм аларның кабиләләре әлеге яңа дәүләт составына кертеләләр. Соңрак һөҗүмнәр һәм хәрби яучабулар үткәрү, кайчагында тагын да кан койгычрак талаулар оештыру нәтиҗәсендә Төньяк Кытай, Урта Азия дәүләтләре, Төньяк Кавказ, Кырым җирләре һәм халыклары, шулай ук тангутларның Си-Ся исемле патшалыгы монголлар тарафыннан буйсындырыла. Монголларның тәэсире Япон һәм Сары диңгезләрдән алып, Көнбатышта Түбән Идел һәм Төньяк Кавказга кадәр җәелә. Шул рәвешле нибары бер 15-20 ел эчендә генә Чыңгызхан юлбашчылыгында гаять зур тупраклы (территорияле) дәүләт—әр-яңа империя төзелә.

Чыңгызхан үлеменнән соң (1227) яулап алулар аның уллары һәм оныклары тарафыннан дәвам иттерелә. Көнчыгышта чөрчетләр (җүрҗәннәр) дәүләте, Көньяк Сунь династиясе хөкем сөргән Кытай империясе, Корея ярымутравындагы дәүләтләр, көньяк-көнбатышта Әфганстан, Иран, элеккеге Гарәп хәлифәлеге шәһәрләре һәм өлкәләре яулап алына; төньяк-көнбатышта исә Идел Болгарстаны, төньяк-көнчыгыш рус кенәзлекләре, ниһаять төньяк-көнбатыш Аурупаның кайбер өлкәләре дә яулап алуларга дучар була. Дөрес, кайбер җирләр—көнбатыш һәм төньяк көнбатышта иң кырыйдагы кенәзлекләр һәм өлкәләр тулысы белән Чыңгызыйлар дәүләте составына кертелмиләр. Алар даими рәвештә ясак һәм салым түләп торучы протекторатлар яки, бүгенгечә әйтсәк, колонияләр хәлендә яшәп киләләр. Андыйлар рәтендә, күрәсең, кенәзләре монголларга көчле каршылык күрсәтмәгән, яулап алучылар белән уртак тел таба алган илләр һәм халыклар калгандыр.

Шулай итеп, 40-50 ел дәвамында тупрагы буенча галәмәт зур киңлекләрне эченә алган һәм халкы ягыннан бик тә чуар булган Чыңгызыйлар мәмләкәте (державасы)—Тын океан ярларыннан Атлантик океанга кадәр җәелгән Бөек монгол империясе, дөресрәге, суперимперия барлыкка килә.

Шушы уңайдан түбәндәге сорауның тууы ихтимал: күчмәннәр хәлендә генә яшәгән, ягъни социаль үсеш җәһәтеннән "примитив" дәрәҗәдә генә дип исәпләнә торган монголлар ни рәвешле һәр җирдә һәм һәрвакыт гел җиңүләр казанган, ахыр чиктә, моңарчы тарихта мисалы күрелмәгән галәмәт зур империя төзүгә ирешә алганнар соң?

*Бу хезмәт иң элек русча, инглизчә вариантлары белән түбәндәге каталогта басылган иде: «Сокровища Золотой Орды».—Санкт-Петербург: «Славия» нәшрияты. 2000. 26-53 битләр.

Бу сорауга төрле дәверләр һәм мәдәниятләрнең вәкилләре, кайчак капма-каршы карашларда торуларына да карамастан, ышанычлы-дәлилле җавап табарга омтылыш ясап караганнар. Мона дәлил итеп үтә дә куәтле армия төзи алган җиһангирның таланты һәм бөеклеге, шулай ук чамасыз кансызлыкка ия булган "кыргый" монголларның бары тик тыныч яшәп ятучы халыкларны "тулаем җәберләргә", мәдәниятле, бай илләрне һәм "чәчәк атып утыручы шәһәрләрне" таларга, туздырырга гына сәләтле булулар һ.б. китерелә.[1]

Мондый "аңлатуларның" нигезендә, әгәр алардан уйдырма сафсаталарны һәм фәннилеккә охшаган "серлелек" пәрдәсен алып ташласак, күп очракта үткән чор вакыйгаларын бары "безнекеләр тукмаган!", яисә "безнекеләрне тукмаганнар!" ише принциптан туа торган ретроспектив гоманлаулар, ягъни узганны бүгенге аңга буйсындыру алымы ята. Мондый алымнарның беренчесе Урта гасыр монгол һәм төрки халыкларның вәкилләре өчен хас күренеш иде; хәер, бу бүген дә дәвам итә әле. Икенче төр алым исә билгеле бер күләмдә гарәп-фарсы тарихи традицияләре өчен характерлы, соңрак ул Аурупа һәм рус-совет тарих белемендә дә гәүдәләнде. Соңгысы бигрәк тә дәреслекләрдә, фәнни-популяр басмаларда һәм кинофильмнарда киң урын алды.

Чын-олы тарих фәне, әйтик, кайбер көнбатыш һәм рус ориенталистларының хезмәтләреннән күренгәнчә, мәдәниятләр һәм цивилизацияләрне, этнослар һәм расаларны бер-берсенә кара-каршы куймыйча, шул ук вакытта сугыш мәхшәрләренә дә күз йоммыйча, мәсьәләнең асылына төшеп яктыртырга һәм тасвирларга омтыла. Ләкин мондый карашлар, табигый буларак, махсус басмаларда гына урын ала килде һәм алар бик тар даирәләрдә генә кала бирделәр. Димәк, алар, дәреслекләрдән һәм фәнни-популяр басмалардан аермалы буларак, киң иҗтимагый фикергә һәм көнкүреш психологиясенә сизелерлек йогынты ясый алмадылар. Шуңа күрә дә киң җәмәгатьчелек аңында монгол-татар фобиясе—куркыныч карачкы образы хөкем сөрде. Вакыт-вакыт мондый фикер тарих белән уйнаучы сәясәтчеләр тарафыннан да махсус күпертелеп торды.

Чынлыкта исә, монгол коралының һәм башлангыч чор Чыңгызыйлар хакимиятенең уңышы Тимучин хакимияткә килгәч алып барылган махсус үзгәртеп корулар, асылда чын **реформалар** үткәрүнең нәтиҗәсенә бәйле иде. Кыскача гына бәян иткәндә алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

**<u>Беренчесе.</u>** Монгол яулап алулары буенча белгечләр Чыңгызханның үз гаскәрләрендә мәгълүм унарлы системаны куллануын атап күрсәтәләр. Галимнәр билгеләп үткәнчә (мәсәлән, Б.Я.Владимирцов фикеренчә), бу системаның кайбер элементлары башлангыч мәгънәдә чорчетләргә (җүрҗәннәргә) һәм монголларга кадәрге бүтән борынгы халыкларга, мәсәлән, төркиләргә дә мәгълүм була. Чыңгызхан исә аны, гаскәриләрдән тыш, ун, йөз, мең һәм аннан да артык сугышчы бирә алу мөмкинлекләреннән чыгып, бөтен күчмәннәрнең административ төзелешенә дә җәелдерә. Шул рәвешле гражданлык һәм хәрби структураларның органик берләшүе нәтиҗәсендә, "халык—гаскәр" дигән шартлы исем-атама белән атала торган, идарә итүе гаҗәп җиңелләшкән, тиз оешуга сәләтле, хәрәкәтчән җәмгыять барлыкка килә.

**<u>Икенчесе.</u>** Һәм гаскәр белән, һәм гражданлык җәмгыяте белән идарә итүдә Чыңгызхан мәсьәләнең хокук якларына зур игътибар бирә, тотрыклы хокук нормалары булдыру максатыннан чыгып, закончалыкны үстерүгә әһәмиятен юнәлтә. Бу хакта атаклы Ясаның ("Ясак" яки "Җасак" дип аталган кануннар җыелмасының) сакланып калган өлешләрендә һәм аның махсус бүлекләрендә тәфсилләп бәян ителә. Анда җәмгыять әгъзалары арасындагы, аерым шәхес белән рәсми хакимият, түбән һәм югары катламнар арасындагы үзара бәйләнеш, мөнәсәбәт нормалары җентекләп тасвирлана; Ясада шулай ук хөкүмәт әһелләренең, гади сугышчыларның, гаскәри түрәләрнең, аларның гаилә әгъзаларының бурычлары һәм хокуклары катгый тәгаенләнгән була; ниһаять, этика нормаларына, тәртип мәсьәләләренә, аларны бозган, җинаять кылган өчен җәза күләмен билгеләүгә дә махсус игътибар ителә.

Шул рәвешле Чыңгызхан борынгы Үзәк Азия халыкларының бай тәҗрибәсенә таянып, электән хөкем сөргән гадәти хокук өйрәтмәләрен, көнкүреш әхлагын һәм этик нормаларын бозылмас катгый законга—рәсми хокук дәрәҗәсенә күтәрә. Аны үтәү гади халыкка да, сугышчылар өчен дә, хәтта хаканның үзе өчен дә мәҗбүри булган.

Чыңгызның Ясасы бөтен житдилеге белән үтәлә һәм ул гомуми тәртип урнаштыруга хәлиткеч йогынты ясый, аны бозучы каты җәзага, хәтта үлемгә хөкем ителә. Ясаның күрсәтмәләрен үтәүне күзәтеп тору өчен башында падишаһның кырыс холыклы, каты куллы угылы Чыгтай торган баш прокуратура кебегрәк махсус оешма-хезмәт булдырыла. Шулай ук баш казый да билгеләнә, бу вазыйфа "сатылмаучанлыгы" белән даны чыккан Шиги-Кутукуга йөкләнә. Нәтиҗәдә, болар барысы бергә империядә билгеле күләмдә дөрес тәртип урнаштырырга мөмкинлек бирә: үтереш, талау, алдау, гаилә бозыклыгы кими, өлкәннәрне ихтирам итмәгән һәм этик кагыйдәләрне сакламаган өчен житди шелтә белдерү гадәткә керә.

Яса, тулаем алганда да һәм аның аерым өлешләре рәвешендә дә, озак вакытлар хокук кодексы булып хезмәт итеп килә, монголларның һәм аларга буйсынган халыкларның яшәеш-көнкүрешенә житди йогынты ясый. Шунысын әйтү дә зарур, Ясаның аерым күрсәтмәләре гадәти хокук калдыклары сыйфатында, кайбер төрки халыкларның, шул исәптән мөселманлашкан төркиләрнең дә көнкүрешендә бүгенгә кадәр сакланып калган. (Мәсәлән, өлкәннәрне олылау, ата-ана "учагының" варисы итеп кече улның билгеләнүе, янган утка хөрмәтле караш, суны пычраткан

өчен шелтәләү һәм башкалар әнә шундыйлардан исәпләнә.)

Күрәсең, санап кителгән хәрби-административ, социаль, хокукый һәм этик кагыйдә күрсәтмәләрнең берсе дә, мөгаен, Чыңгызханның үзе тарафыннан шәхсән уйлап чыгарылмагандыр. Ул аларны чынлыкта тормышның үзеннән җыйган, Үзәк Азиядәге күпләгән халыклар белән гасырлар буена идарә итү тәҗрибәсеннән туплаган, билгеле бер тәртипкә салган һәм аларны Яса маддәләре—барлык кешеләр өчен дә үтәлүе мәҗбүри булган Закон дәрәҗәсенә күтәргән булса кирәк. Боларның барысы бергә, ахыр чиктә, җәмгыятьне тиз оеша торган, хәрәкәтчән, көрәш-сугышка сәләтле "халык-гаскәр" итеп үзгәртеп корырга—чын реформалар уздырырга мөмкинлек биргән. Бу, үз нәүбәтендә, Чыңгызханга һәм аның турыдан-туры дәвамчыларына кыска гына вакыт эчендә "Иске дөньяның"—бөтен Ауразиянең яртысын диярлек яулап алырга мөмкинлек биргән.

Кыскасы, Чыңгызханның һәм аның варисларының уңышы очраклы рәвештә килеп чыккан күренеш түгел һәм ул аерым фактларга гына да бәйләнмәгән. Алар тирәнтен үзгәртеп корулар, ягъни барлык халыкны гаскәри-административ яктан берләшүгә китерә торган чын социаль-иҗтимагый реформалар үткәрү нәтиҗәсе булып тора. Димәк, телдән-телгә күчеп йөри торган "монгол коралының тантанасы" ул үзгә бер системаның, үзенчәлекле культураның—күчмә тормышның һәм, гомумән, күчмәнлек цивилизациянең үсү процессында иң югары ноктасына житкән чорының —"чәчәк ату чорының" җимеше булып тора.

Яулап алучыларның һөҗүмнәре дәверендә каршы тарафта—утрак тормышлы илләрдә бөтенләй башка хәлләр күзәтелә: аларда, кем әйтмешли, феодаль таркаулык "гөрләп хөкем сөрә". Әйтик, төньяк Кытай белән көньяк Кытай туктаусыз ызгыша; эчке каршылыклар харәземшаһлар дәүләтен дә эчтән җимерә; Бөек далада да бердәмлек булмый, анда, күрәсең, кабиләләр арасындагы һәм кабиләләрнең үз эчләрендәге каршылыклар киң канат җәйгән булгандыр; Русьта дистәләгән вак-вак кенәзлекләр барлыкка килеп, билгеле булганча, аларның башлыклары йөз елдан артык бер-берсенең бугазларын чәйнәп өзәргә әзер торалар һ. б. Бу уңайдан Калка буендагы мәгълүм сугышны хәтергә төшереп үтү дә җитәр кебек...

Димәк, Бөек Монгол империясенең барлыкка килүе ул бер күчмә цивилизациянең чәчәк ату чоры нәтиҗәсе генә түгел, бәлки шул чор Аурaзиядәге утрак тормышлы халыкларның тормышында барлыкка килгән бүлгәләнү, таркаулык һәм көчсезләнүнең нәтиҗәсе дә икән. Әгәр күчмә дөнья үзенең төзек оешкан йөзәрлекләре, меңәрлекләре, төмәннәре белән, образлы итеп әйткәндә, нык йомарланган бер йодрык кебек гамәл кылган булса, моңа каршы утрак тормышлы җәмгыятьләрнең тәртипсез ополченецлары тырпайган "бармаклар белән" кизәнүләрне хәтерләткән...

Монда китерелгән фикерләрдә, асылда, әлләни яңалык юк. Аларның аерым өлешләре, кайбер тезислары безгә кадәр дә әйтелгәләгән иде. Ләкин Чыңгызханның **реформаторлык эшчәнлеген** таныган һәм исәпкә алган чакта алар ныклы нигезгә утырып яңа көч белән яңгырыйлар.

Әдәбиятта, бигрәк тә совет чоры дәреслекләрендә һәм фәнни-популяр басмаларда монгол яулап алучыларын мәгънәсез рәхимсезлек белән халыкларны юк итүчеләр сыйфатында тасвирладылар. Аңлашылса кирәк, бернинди дә яулап алулар һәм сугышлар, шул исәптән яңа җирләрне буйсындырулар да кешеләр үлеменнән, чит ил баскынчыларына каршы торган халыкның бер өлеше кырылудан, шәһәрләр җимерелүдән башка бармаган. Каршы торучыларны бастыруда, кырыслыкта һәм рәхимсезлектә "кыргый" азиатлар да, "цивилизацияле" ауропалылар да бер-берсеннән калышмаганнар (мисаллар эзләп ерак йөрисе юк). Шуңа күрә дә, монголларны бары тик "рәхимсез яулап алучылар", буйсындырылган илләрнең халыкларын баштанаяк юк итүчеләр, "шәһәрләрне жир белән тигезләп" көтүлеккә әйләндерергә омтылучылар дип әйтер өчен житди дәлилләр юк. Димәк ки, Чыңгыздан "куркыныч карачкы" ясау чире белән авыручыларга шикләнеп караган Б.Я.Владимирцов һичшиксез хаклы булган. Чөнки яулап алучыларга мәетләр һәм шәһәр, торакларның җимерек калдыклары түгел, бәлки буйсындырылган дәүләтләрнең исән халкы—яулап алу вакытында талау объекты, сонрак исә даими салым чыганагы булырлык тере кешеләре кирәк булган.

В.В.Бартольд билгеләп үткәнчә, Чыңгызыйларга җәмгыять һәм халык мәнфәгате өчен хезмәт итү идеясе ят нәрсә була. Ләкин алар житәрлек дәрәҗәдә исәпчел-хисапчыл булганнар һәм бу аларга тере кеше кыйммәтен мәетнекеннән аерып карау мөмкинлеген биргән. Шуңа күрә дә, Чыңгызыйлар яулап алынган илләрдә ин элек җан исәбен алуны үткәргәннәр, ягъни җан башына ясак һәм салым салу юлы белән эксплуатация объектын исәпкә алуны оештырганнар. Яулап алучылар халык хуҗалыгының уңышлы үсүенә, бөтен империя биләмәләрендә, яулап алынган илләрне дә кертеп, хокукый тәртипләр урнаштыруга омтылганнар. Шуңа да XIII гасыр урталарыннан башлап бинаһая киңлекләргә җәелгән империянең төрле төбәкләрендә, олысларында элекке шәһәрләр янадан җанланып китә һәм яңалары барлыкка килә башлый. Көнчыгыш белән Көнбатыш, Көньяк белән Төньяк арасында сәүдә көчәйгәннән-көчәя бара. Бу максатка ирешүдә Яса күрсәтмәләре дә билгеле күләмдә ярдәм итеп торган.

Чыңгызханның һәм аның якын варисларының мондый сәясәтне уңышлы үткәрүенә аларның буйсындырылган халыкларның дини эшләренә һәм гомумән рухи мәдәниятләренә (телгә, язуга, гореф-гадәтләргә) тыкшынмавы да уңай йогынты ясый. Алар хәтта җирле дин кенәзләренә төрле

өстенлекләр биреп, аларның уңай мөнәсәбәтен булдыруга ирешәләр. Яулап алучыларның мондый гамәлләре төрлечә аңлату таба, бик еш кына ул мәҗүси-шаманнарның хорафатларга ышануы нәтиҗәсе кебегрәк аңлатыла. Чынлыкта исә бу аңлы сәясәт үткәрүнең күрсәткече иде. Мәсәлән, Чыңгызхан үзенең Ясасында бу хакта бик ачык итеп әйтеп биргән: **"Барлык дини ышануларны да, кайсына да булса өстенлек бирмичә, ихтирам итәргә. Моның барысы (...) Ходага тугрылык күрсәтү чарасыдыр"** *(Хара-Даван, 1989)*.

Әмма ләкин, Чыңгызханның һәм аның улларының суперимпериясе барыбер озак яши алмый. Тышкы яулап алулар башланганнан соң якынча 45-50 ел үтүгә аның әкренләп таркалу чоры башлана. Ул процесс төрле төбәкләр һәм олыслар арасындагы социаль-иҗтимагый, этник-мәдәни вә сәяси мәнфәгатьләренең каршылыклары нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән; XIII гасырның 60 елларында исә, үзәк хакимият хәлсезләнгән чорда—Кобылай белән Арыг-Буга арасында бөек хан тәхете өчен көрәш барган дәвердә —тагын да тизләнә төшә. Нәтиҗәдә, дүрт яңа дәүләт—Бөек хан биләмәсе (соңрак—Юань империясе), Чыңгызханның уллары һәм оныкларына караган биләмәләр, ягъни Җучи, Чыгтай һәм Һүләгү олыслары оеша. Алар да, үз чиратында, биләмә тупраклары һәм халыкларының составлары буенча эре империяләр иделәр.

Тарих белемендә Җучи Олысының—Алтын Урданың—аерымланып чыгу дәвере сыйфатында, гадәттә, XIII гасырның 40 елларын, ягъни Батуның көнбатыш сәфәреннән Идел буйларына әйләнеп кайту елларын күрсәтәләр. Бу хаклыкка бик үк туры килеп бетми. Мондый "даталаштыру" үзләре һәм урыс кенәзләре өчен абруйлы саналган "Батый падишаһ" артында Бөек хан—бердәм бөек мәмләкәтнең чын хөкемдары хакан торуын күрмәгән рус елъязмачыларының бик үк төгәл булмаган хәбәрләрен абсолютлаштыру нәтиҗәсендә барлыкка килә. Соңгы чор тикшерүчеләре исә, нигәдер Батуның бер үк вакытта Бөек ханнан соңгы икенче урында торган хөкемдар икәнлеген (бердәм Бөек империядә ранг буенча икенче шәхес булуын) онытып җибәрәләр. Өстәвенә ул, Бату хан, бүгенгечә әйтсәк, ахырга кадәр унитарист булып калган кеше дә.

Мондый даталаштыруга, Бату позициясеннән тыш, шундый факт та каршы килә: Бәркә ханның (1256—1266), асылда Җучи Олысының икенче хөкемдарының, үз акчасын сугарга омтылуы, Бөек хан хакимияте санкциясе нәтиҗәсендә, уңышсызлыкка очрый. Бары тик Мәнгү Тимер (1266—1280) вакытында гына Алтын Урда хөкемдары, мөстәкыйль дәүләт башлыгы буларак, үзенең тулы титуллары күрсәтелгән тәнкәләр суга башлый. Һәм аның акчалары гамәлдән чыгарылмыйлар. Димәк, Алтын Урданың юридик яктан тулы мөстәкыйльлеккә ирешүе XIII гасырның 60 еллары ахырына туры килә дип танырга кирәк.

Чыңгызыйлар мәмләкәте (державасы) таркалганнан соң барлыкка килгән дүрт олыс-империя арасында Алтын Урда, үзенең вассаль дәүләтләре белән бергә, биләмәләре ягыннан, күрәсең, иң эреләрдән булгандыр. Ләкин халык саны ягыннан ул Юань империясеннән шактый калышкан.

Җучи Олысының чикләре көнчыгышта чама белән Саян-Алтай-Тянь-Шань тауларыннан башланып, Харәземне, Сырдарьяның түбән агымын, Төньяк Каспий киңлекләрен эченә алып, Иран Әзербайҗанын, Кавказның да күп өлешен, Кырым һәм Кара диңгез алды далаларын да үз составына кертеп, Түбән Дунай буйларына кадәр җәелә. Көнбатышта ул чикләр, Көньяк Русь биләмәләренең бер өлешен үз эченә алып Төньяк-көнчыгыш Русь өлкәләренең дә күпчелеген иңлиләр. Ары китеп, элеккеге Болгар ханлыгы җирләрен үз составына беркетеп, Урал аша үтеп, бөтен Көнбатыш һәм Көньяк Себерне дә урап Саян тауларына кадәр барып чыгалар. Кайбер галимнәр (аерым алганда, М.Г.Сәфәргалиев) Җучилылар империясенең төньяк чикләре Төньяк боз океаны ярлары буйлап үткән дип раслыйлар. Төньяк-көнчыгыш Русь кенәзлекләренең күп җирләреннән тыш, кенәз Александр Ярославичның үз ихтияры белән Батуга буйсынуын таныганнан соң, аның кул астындагы Новгород кенәзлеге биләмәләре дә, ниһаять, чиктәш Көнчыгыш Аурупа илләренең кайбер өлкәләре дә Урда ханнары хакимиятенә сәяси буйсынуда торалар. Тулаем алганда, югарыда санап кителгәннән күренгәнчә, Җучилылар мәмләкәте һәм аңа бәйле дәүләтләр биләмәсе бинһая киң вә зур була. Аның күләме тагын берничә гасырдан соң барлыкка килгән Русия империясенең һәм соңрак аның дәвамы булган СССРның тупрагына—территориясенә туры килә яза.

Алтын Урданың халкы төрле этник төркемнәрне берләштергән һәм шактый чуар булган, анда, әле генә билгеләнгән чикләрдә яшәүче, хәзер безгә билгеле барлык халыкларның да бабалары яшәгән. Дала һәм урман-дала зонасында, шулай ук кайбер утрак тормышлы өлкәләрдә—Харәземдә, Урта һәм Түбән Идел буйларында, Төньяк Кавказда, Кырымда, Көнбатыш һәм Көньяк Русь далаларында яшәүчеләрнең күпчелеген төрки телле халыклар һәм кабиләләр тәшкил иткән. Аларның күпчелеге кыпчак, өлешчә угыз телле халыклардан торган. Җучи Олысының чик буе биләмәләрендә фарсы-таҗик, кавказ-иберия, алан-чиркәс, финн-угор һәм славян халыклары да күпләп яшәгәннәр.

Яулап алу чорында һәм соңрак, илнең төп өлешендә Чыңгызыйлар хакимияте ныклап урнаштырылгач, Ауразиянең элекке этник картасында, тулаем алганда бераз, урыны белән исә шактый нык үзгәрешләр барлыкка килә. Чөнки ил эчендәге халыкларның "тарих тегермәнендә тартылу" процессы—кабиләләр һәм халыкларның, аеруча төрки этносларның үзенчәлекле кушылу, укмашу процессы бара. Нәтиҗәдә, этник процесста, ягъни киләчәк "яңа" халыкларның

этногенезында компонентларның сизелеп үзгәрүе күзәтелә. Бу катлаулы күренешне яктыртканда монголларының Алтын Урдадагы төркиләшү мәсьәләсе аерым игътибарга лаек.

Кыпчак далаларында яшәп калган монголларның ассимиляцияләнү фактын барлык белгечләр дә билгеләп үтәләр. Тарихчылар да, тел белгечләре дә бу процессны XIV гасырга кайтарып калдыралар. Шул ук вакытта барлык очракларда да диярлек мисырлы әл-Гомәринең киң дәрәҗәдә мәгълүм сүзләренә таяналар. Ул, мәсәлән, яшәү рәвешенең, көнкүрешнең һәм мәдәниятләрнең якынлыгы нәтиҗәсендә килмешәк монголлар тиз арада кыпчаклар белән кушылып, этник йөзләрен тулысынча югалтканнар, дип язган иде. Бу очракта фактның тарихилыгы түгел, бәлки аның XIV гасырга кайтарылып калдырылуы бәхәс уята. Хикмәт шунда ки, 1349 елда вафат булган әл-Гомәри аңар кадәр тулаем төгәлләнгән күренеш турында хәбәр итә. Димәк, процессның үзе шактый элек булып узган дигән сүз.

Мәгълүм булганча, монголлар үзләренең тышкы экспансияләренә хәтле үк күп вакытлар элегрәк Үзәк Азия һәм Көньяк Себердәге төрки телле халыклар белән тыгыз бәйләнештә булганнар. Бу хакта монгол теленә иртәрәк чорда ук үтеп кергән төрки алынмалар ачык сөйли (Б.Я.Владимирцов һәм башкалар). Ике этнос арасындагы шундый традицион якынлык нәтиҗәсендә Тимучин, булачак Чыңгызхан, үзенең балаларын укытыр өчен мөгаллимлеккә һәм хөкүмәт хезмәтенә дип грамоталы уйгыр бахшиларын, ягъни төрки телле чиновникларны чакыра. Монголларның уйгыр язуын кабул итеп алулары да шулай ук мәдәни бәйләнешләрнең тирән тамырлы булуы турында сөйли. Уйгыр кенәзлекләрен "тыныч юл белән" Монгол дәүләтенә кушканнан соң (1209) монголлар хезмәтендә торган төрки телле укытучыларның, түрәләрнең саннары тагын да арткан дип уйларга нигез бар. Б.Шпулер ачыклаганча, Чыңгызхан, үзенең туган теле—монгол теленнән тыш, төрки телдә дә иркен сөйләшкән икән.[2] Болар барысы да, минем карашымча, Алтын Урдадагы монголларның төркиләшүе өчен хәзерлек этабы ролен үтәгән.

Шулай да Алтын Урдада монголларның чагыштырмача тиз арада ассимиляцияләнүенә төп йогынтыны демографик, дөресрәге сан ягыннан күплек факторы ясаган булса кирәк. Б.Шпулер билгеләп үткәнчә, зур яу чабулары башлангычыга кадәр үк Чыңгызхан армиясенең зур өлешен төрки сугышчылар тәшкил иткән. Бу компонент уйгырлар һәм урянхайлар кушылгач та, Алтай тауларын узып кимәк-кыпчак далаларына килеп чыкканнан соң да арта барган. Барлык фактлар да үзара таркау яшәгән, көчле һәм бердәм дәүләтләре булмаган Дәште-Кыпчак кабиләләренең Җучи һәм Бату гаскәрләренә чагыштырмача җиңел кушылулары хакында сөйли. Бу күренеш монголлар армиясендә төркиләрнең тагын да күбәюенә китергән.

Тагын шундый күренеш тә игътибарга лаек. Алтайдан алып, Идел буйларына кадәр, дөресрәге Отрар шәһәре тар-мар ителеп, Болгар җирләре яулап алынганчыга чаклы, монгол яугирләре дала халыкларының җитди каршылыкларына очрамыйлар диярлек. Каракытай империясендә буйсыну хәлендә яшәгән төркиләр, күрәсең, монголларга каршы баш күтәрмәгәннәр. Менә бу хәл әлеге дәүләтнең Чыңгызхан тарафыннан чагыштырмача тиз генә тар-мар ителүенә сәбәп булган, күрәсең.

Харәземшаһ дәүләтендәге төрки кабиләләренең дә күпчелек өлеше шулай ук монголларга каршылык күрсәтмәүне өстен күргәннәр (И.П.Петрушевский). Гомумән, Калка янындагы уңышсыз бәрелештән (1223) һәм болгарларның беренче каршылык күрсәтүеннән соң, 30 елларның ахырында Идел тирәсендә Бачманның монголларга каршы көрәшеннән тыш, чыганакларда Дәште-Кыпчак халыкларының нинди дә булса җитди көрәш алып барулары хакында бернинди хәбәр юк.

Боларның барысы да, күрәсең, үзара таркау дала бәкләренең, көчле армиягә каршы торуга караганда, Чыңгызханга һәм аның улларына буйсынуны кулайрак күрүе хакында сөйлидер. Әчке төзелеше токым-кабилә мөнәсәбәтләренең табигате белән тәгаенләнә торган күчмә җәмгыятьләрдәге, вассалитет системасының үзенчәлекләре нәтиҗәсендә, андый бәкләргә буйсынган халык та, үзеннән-үзе Чыңгызыйлар гаскәренә килеп кушылган. Шуңа күрә дә 1236 елда Идел Болгарстанына, аннары Русь кенәзлекләренә ташкын булып ябырылган монгол гаскәрләре үзләренең этник составы ягыннан, монголлар булудан бигрәк, төркиләрне тәшкил иткәннәр иде.

Аңлашылса кирәк, хан һәм аның якын яраннары, махсус хан гвардиясе һәм, табигый ки, күп санлы армиянең беркадәр өлеше монголлардан торган. Шуның белән бергә яулап алуларда катнашкан монголларның билгеле бер өлеше, чыганаклар билгеләп үткәнчә, Гөек һәм Мөңкә исемле ханзадәләр белән бергә кире Монголиягә кайтып китәләр. Шуңа күрә дә рус теленең XIII—XIV гасырлардагы—Русьның Урдага аеруча нык бәйле булган чорындагы—рус теленә кергән көнчыгыш алынмаларының зур күпчелеген монгол сүзләре түгел, ә бәлки төркичә сүзләр тәшкил итә *(Баскаков, 1974; Аракин, 1974)*.

Ниһаять, тагын шундый факт та игътибарга лаек. XIII гасыр уртасында Бәркә хан (1256—1266) Мисыр илчелеген кабул иткәндә, Мәмлүк солтанның гарәпчә язылган битиге (хаты) казый тарафыннан төркичәгә тәрҗемә ителә һәм ханга хатның эчтәлеген аңлау өчен шул җитә дә. Озак вакытлар Сарайда Үзбәк хан (1312—1342) ставкасында яшәгән гарәп сәяхәтчесе Ибне-Баттута үзенең истәлекләрендә күп кенә җирле сүзләр китерә һәм, В.В.Бартольд билгеләп үткәнчә, алар арасында чыгышы буенча бер генә монгол сүзе дә юк.

Болар барысы да шул хакта сөйли: Чыңгызхан державасының көнбатыш өлешендәге монголлар XIII гасырда ук төркиләшәләр, ягъни бу процессны бары тик XIV гасыр белән генә билгеләргә бернинди дә нигез юк икән.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып шундый нәтиҗә ясарга мөмкин. Җучи Олысы, бары тик идарә итүче династиянең чыгышы буенча, шулай ук аксөяк катламнарның билгеле бер өлеше генә монголлар булганлыктан, үзенең башлангыч чорыннан ук халыкның төп өлеше ягыннан төрки дәүләт булып оешкан һәм ул шулай булып калган да.

Мондый нәтиҗәнең дөреслеген археологик материаллар да раслыйлар: Көнчыгыш Аурупа киңлекләрен монголлар яулап алу нәтиҗәсендә хан һәм иң өске аксөяк катлам гына алмашынып, гади халык исә тулаемы белән диярлек элеккегечә кала бирә *(Г.А.Федоров-Давыдов)*.

Шулай итеп, Алтын Урда тарихын җирле тамыры булмаган, ниндидер читтән килгән "килмешәкләр" тарихы гына дип карау дөрес түгел икән. Икенче төрле итеп әйткәндә, ил һәм халык тарихын, ягъни шөбһәсез төп һәм нигез факторны тулысынча аның тармак һәм икенчел компонентлары белән—җирле этник мохиттә тиз йотылып беткән, юка аксөяк катламга ияреп килгән династия белән генә тәңгәлләштерү һичшиксез урынсыз булыр иде.

Шуны да күз уңында тотарга кирәк, Алтын Урда үзенең шундый сәяси тарихы белән тарихта бердәнбер дәүләт түгел. Мондый фактлар бик күп. Һич югы үзләренең этник йөзләрен бик тиз югалткан Газна, Һиндстан, Иран һәм Мисырдагы төрки хөкемдарларны, яки чыгышлары буенча хань (чин) нәселеннән булмаган Кытай империясе династияләрен алып карыйк. Ниһаять, Русьтагы Рюриковичларны, Көнбатыш Аурупа илләрендә династияләр "алмашуны", шулай ук Россиядә XVIII гасырда Романовларның "кан яңартуын" һәм башкаларны искә төшерик. Әмма, ничек кенә булмасын, ханьнар (чиннар) хань-чин булып, иранлылар иранлы хәлендә, славяннар славян килеш кала бирделәр. Ауразиянең кимәк-кыпчаклар ягъни төркиләр яшәгән далаларында да шундый ук хәлләр күзәтелгән.

Ләкин биниһая зур киңлекләрдәге этник фонның тулаем тотрыклы булуын билгеләп үтү белән бергә, яулап алулар, җиңүчеләр тарафыннан яңа биләмәләрне үзләштерү процессында үзгәрешләр барлыкка килүен, халыкларның бер өлеше көченә нәтиҗәсендә аларның үзара берләшүләрен, үзгәрешләр барлыкка килүен күрмәү дә хата булыр иде. Ләкин биредә сүз төрки макроэтносның үз эчендә якын тугандаш халыклар һәм кабиләләр арасындагы, ягъни этнос эче аралашу-берләшүе турында, ягъни этник консолидация турында бара. Бер үк вакытта һәм катлаулы, һәм бик гади булган бу процесс Алтын Урда чорындагы һәм Алтын Урдадан соңгы дәверләрдәге кайбер төрки халыкларның этногенезына хәлиткеч йогынты ясаган. Нәкъ менә шушы этнос эчендә барган "тегермән тарттыруы" процессында мөселман-болгарларның теле кыпчак теленә әверелгән. Икенче төрле итеп әйткәндә, XIII—XIV гасырларда Җучи Олысының көнбатыш өлешендә төрки телле болгарларның сан ягыннан күпчелекне тәшкил иткән кыпчак һәм угыз кабиләләренә кушылуы, шулай ук, алар тарафыннан хәзәр кабиләләренен калдыклары һәм җирле финн-угор халкының да бер өлеше йотылуы нәтиҗәсендә империядәге яңа этносның— **төрки-татар халкының** нигезләре барлыкка килгән.

Җучилылар мәмләкәте аякка баскан һәм чәчәк аткан чорда шулай ук яңа этносның тууы процессында, барлык империя өчен уртак булган рәсми язма тел, кайбер очракта Идел буе төркисе дип атала торган төрки-татар әдәби теле дә барлыкка килә. Ул санап кителгән тугандаш халыкларның сөйләмнәре нигезендә акрынлап формалаша, башлангыч этабында исә шул чор өчен югары камиллеккә ирешкән уйгыр-карахани әдәби традицияләрнең көчле йогынтысын тоеп үсә.

Шулай итеп, Алтын Урда сәяси яктан, дөресрәге династия җәһәтеннән караганда, мөстәкыйль дәүләт булып Монголларның суперимпериясе таркалу нәтиҗәсендә оеша. Ләкин ил һәм биләмәләре, һәм төп халкының составы ягыннан, шулай ук аңа бәйле, ясак-салым түләп торучы илләрнең күплеге ягыннан караганда, үзе дә эре империяләрнең берсе була. Шулай икән, Алтын Урданы бер генә халыкның "милли дәүләте" дип, бигрәк тә соңыннан оешкан милләтнең дәүләте дип атарга омтылучы авторлар яки ялгышалар, яки тарихны махсус рәвештә бозып күрсәтергә тырышалар.

Алтын Урда дәүләте белән идарә итү бер үк вакытта бик гади дә, шул ук вакытта бик катлаулы да булган. Гадилеккә күчмә киңлекләрдә идарә өчен җайлы булган "унарлы" системаны кертү аша ирешелгән. Катлаулылык исә утрак тормышлы биләмәләрдә идарә итүнең кайбер үзенчәлекләре белән бәйле була. Чөнки ул үзенчәлекләр элекке идарә итү аппаратының кайбер, ә аерым очракларда исә төп элементларын саклауны таләп иткән. Бу бигрәк тә бәйле илләргә хас күренеш иде.

Бер үк вакытта монголлар өчен традицион булган удел—хосусый биләмә системасы да кертелә. Җучилылар мәмләкәте ике эре уделдан тора: Җучиның олы улы Ордунның биләмәсе—илнең көнчыгыш өлешендәгесе—Күк Урда дип атала; икенче улының—Батыйның—биләмәләре илнең көнбатыш өлешендә булып, ул Ак Урда дип атала[1]. Бу ике макроудел эчендә вак-төяк аксөякләр тарафыннан идарә ителә торган тагын кечкенә уделлар да була. Хәер, алар хакында конкрет мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә аз. Мондый уделларның аерым төре булып суйыргал биләмәләре, ягъни файдалану өчен билгеле шарт белән бирелә торган җир-сулар хисаплана;

андый ярлыкларны алучылар хәрби һәм хөкүмәт хезмәте башкарырга тиеш булганнар. Утрак тормышлы, ягъни игенчелек белән шөгыльләнә торган төбәкләр өчен суйыргал җир биләү системасы киң таралган күренеш була. Мондый уделлар белән бергә провинция, өлкәише территориаль-административ бүлемнәр дә сакланган, алар даругалар дип, хакимият башлыклары исә даруга-бәкләре дип аталганнар. Зур шәһәр һәм кальга башлыклары да шундый ук титуллар белән аталганнар.

Дәүләтнең хөкемдары булып Җучи нәселеннән чыккан хан—Җучилы хан торган. Хан янында диван дип атала торган дәүләт советы ише махсус идарә эшләп килгән. Аның әгъзалары булып төрле бәкләр—мәшһүр аксөяк ыругларның вәкилләре торган. Алар арасында иң кодрәтле төркемнәрнең вәкилләре —дүрт бәк—дүрт карачы (киңәшчеләр) зур абруйга ия булган.

Аеруча мөһим мәсьәләләр кабилә һәм ыругларның аксөяк вәкилләре катнашында үткәрелә торган корылтайларда—съездларда хәл ителгән. Димәк, Алтын Урда үзенең дәүләт төзелеше буенча вәкаләтле монархия булган икән.

Хөкүмәт башында бәкләр бәге, ягъни баш бәк торган. Түбәндәрәк торган бәкләрнең титулларына ул җитәкләгән идарәләрнең исемнәре өстәлгән, мәсәлән, диван-бәге һәм башкалар кебек. Илдә күп төрле дәүләт түрәләре була, әйтик, диван-кәнсәләр чиновниклары, салым җыю, ям (почта) һәм тамга (таможня), сак-полиция хезмәткәрләре; шулай ук кичү, күпер сакчылары, базар башлыклары һ. б. Ислам дине дәүләт дине дип игълан ителгәч, җәмгыятьнең югары катлам вәкилләре сыйфатында, рухани кеңәзләр катламы да барлыкка килә. (Төрле дәрәҗә һәм вәкаләткә ия түрәләренең исемлеге ярлыкаш хан ярлыкларында теркәлгән.)

Ил белән идарә итүдәге мондый катлаулылык һәм эзлексезлек Чыңгызыйлар дәүләтендә, шул исәптән Җучи Олысында да, җирле вә төбәк үзенчәлекләрен һәм мәдәни-дини шартларны исәпкә алган хәлдә, идарә итү аппаратының даими хәрәкәттә һәм үсеш-үзгәрештә булуы хакында сөйләсә кирәк. Күп санлы фактлар күрсәткәнчә, Чыңгызыйлар шактый ук сыгылмалы хәлдә эш йөрткәннәр, басып алынган халыклардан идарә итү сәнгате өлкәсендә өйрәнүдән, бигрәк тә финанс хуҗалыгын алып баруда, эксплуатацияләнүче халыкның җан санын исәпкә алуда, эш йөртү культурасындагы яңалыкларны кабул итүдән тартынып тормаганнар. Кытай һәм Үзәк Азия халыкларының бай тәҗрибәсе аларда киң кулланыш тапкан, бу—идарә итүгә, бигрәк тә финанс һәм сәүдәгәрлек эшләренә җирле түрәләрне күпләп җәлеп итүдәге күп санлы фактлар белән раслана. Алтын Урдада, Көнчыгыш Ауропада беренче тапкыр утрак тормышлы төбәкләрдә җан санын исәпкә алу үткәрелә. Русьта бу Бәркә хан вакытында 1259 елда гамәлгә ашырыла. Күчмә халыкны исәпкә алу исә баштан ук унарлы системасы ярдәмендә башкарылган була. Шуңа күрә дә бу дәүләттә кыска вакыт эчендә генә икътисадый үсештәге барлык үзгәрешләрне тиз сизә торган финанс хуҗалыгы системасы җайга салына *(С.А.Янина, Г.А.Федоров-Давыдов, Ә.Г.Мөхәммәдиев).*

Алтын Урдада финанс-икътисад сәясәтенең төзек тәртиптә алып барылуы һәм халыкка карата да, бигрәк тә сәүдәгәрләргә мөнәсәбәттә дә (төбәкара һәм халыкара сәүдәне үстерү максатыннан чыгып сәүдәгәрләргә тарханлык өстенлеге бирү шуның ачык мисалы булып тора) тулаем уйланылган, акыллы салым сәясәте үткәрү (салым катгый рәвештә керемнең ун проценты күләмендә генә алынган)[4] —ахыр чиктә болар барысы бергә җимерелгән шәһәрләрне һәм бозылган хуҗалык итү эшчәнлеген тиз арада торгызырга мөмкинлек биргән. XIII гасырның икенче яртысында Җидесудан алып, көнбатыш чикләргә кадәр, Җучи Олысының төрле төбәкләрендә уннарча яңа шәһәрләр калкып чыга икән, бу бер дә очраклы түгел иде (моны В.В.Бартольд та билгеләп үтә).

XIII гасырның ахырларында һәм XIV гасырның беренче яртысында әлеге шәһәрләрнең күпчелеге тулаем илнең һәм төбәкләрнең эре сәүдә-икътсадый, һөнәрчелек һәм мәдәни үзәкләренә әвереләләр. Алар арасында үзләренең зурлыгы, икътисадый әһәмияткә ия булулары һәм иҗтимагый-мәдәни үсешнең дәрәҗәсе белән Сарай әл-Мәхрүсә (Сарай Бату), Сарай әл-Җәдид (Яңа Сарай) шәһәрләре, шулай ук Гөлстан, Үкәк, Сарайчык, Мукша, Болгар, Казан, Кырым (Иске Кырым) һәм башка калалары аерылып торалар (В.Ф.Баллод, А.Ю.Якубовский, В.Л.Егоров һ. б.). Бу шәһәрләрнең социаль-хуҗалык һәм мәдәни үсеше дәрәҗәсе хакында Г.А.Федоров-Давыдовның бер хезмәтендә аеруча сурәтле тасвирланган. Шуннан берничә өзек китереп үтәргә җөрьәт итәм:

"Озак вакытлар Алтын Урда шәһәрләрендә югары сәнгатьчә эшләнгән керамика җитештерелмәгән дип уйланылып киленде. Ләкин Сарай һәм Яңа Сарайдагы остаханәләрне казып өйрәнгән вакытта ялтыравыклы (глазурьле) савыт-сабаларның бөтен төрләренең дә калдыклары табылды(...). Бу—Алтын Урда шәһәрләрендә куәтле сәнгатьчә һөнәрчелек, шул исәптән керамика җитештерү тармагы да булганлыкны раслый".

"Ханнарның мөселманлыкка һәм Урта Азия-Иран рәвешендәге шәһәр көнкүрешенә йөз тотуы нәтиҗәсендә" бу шәһәрләрдә "күчмәннәргә бөтенләй ят булган купшы кыяфәттәге Урта гасыр шәрекъ культурасы—глазурьле савыт-сабалар һәм мәчетләрдәге мозаик паннолар, гарәп мөнәҗҗимнәре (астрологлары), фарсыча шигърият, мөселманча рухи гыйлемнәр, Коръән тәфсире һәм математик-алгебраистлар, нәзакәтле нәфис орнаментлар һәм каллиграфия культуралары гөрләп чәчәк ата".

"Алтын Урда шәһәрләрендә "Идел буе төркисе" дип атала торган әдәби тел барлыкка килә, анда безнең көннәргә кадәр килеп җиткән берничә әдәби әсәр иҗат ителгән. Бу телдә хисләрнең нечкәлегенә, чәчкәләрнең хуш ислелегенә, хатын-кызларның гүзәллегенә дан җырлана, шул ук вакытта бу әдәбиятта бик демократик мотивлар белән халыкның үткен фикере вә акылы да чагылыш тапкан".

"Монгол яулап алучылары җирле төрки мөхиттә бик тиз "эреп" бетәләр... Алтын Урда шәһәрләре кыпчаклар, болгарлар, руслар һәм Урта Азия, Кавказ, Кырым һәм башка җирләрдән чыккан халыклар белән тулган була. Шәһәр культурасы нәкъ менә аларның көче белән барлыкка китерелә. Анда Ерак Көнчыгыш һәм Үзәк Азиядән килгән сыйфатлар бик тә аз күләмдә була". *(Г.А.Федоров-Давыдов, 1976.— 124, 125 бб.).*

Алтын Урда тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә кырык елдан артык гомерен багышлаган мәшһүр белгечнең каләменнән чыккан бу өзекләрдән соңгысының ахыргы җөмләсе генә бераз аңлатуга мохтаҗ. Монда сүз гомумән культура хакында түгел, ә бәлки бары тик Алтын Урда шәһәрләрендә барлыкка килгән һәм тәгаенләнгән мәдәниятнең стиле турында гына бара. Галим, әлбәттә, үткәндәге мәдәни бәйләнешләрнең башлангыч этаплары һәм нәтиҗәләре турында да яхшы белгән.

Чынлап та, Алтын Урда культурасы формалашуның беренчел чорында, җирле компонентлар белән бергә, һәм Көнчыгыш, аеруча Ерак Көнчыгыш, һәм Көнбатыш башлангычларның йогынтылары да сизелерлек була. Өстәвенә, бу йогынты синкретик, ягъни укмашкан хәлдә гамәлгә аша. Иң киме Җучи Олысы шәһәрләренең кайбер архитектура үзенчәлекләрен генә алып карыйк. Әгәр биналарның бизәлеше, суүткәрү системасы ул чор өчен хас булган көньяк-көнбатыш чыганакларга барып тоташсалар, дүрткел формадагы яндырылган кирпечләр, каннар— җылытылган идән ярдәмендәге җылыту системасы Ерак Көнчыгыш төзелеш традицияләренең йогынтысы иде. Идел буена чуен кою сәнагате дә, шулай ук, Кытайдан килә. Кытай язуы белән гарәп-төрки язу стильләре кушылу нәтиҗәсендә рәсми мөһерләрнең Алтын Урдага гына хас төре— хан ярлыкларын һәм битикләрен раслый торган квадрат формалы тамгалар барлыкка килә. Ниһаять, бу культура чыганакларының күп компонентлылыгы "Алтын Урда хәзинәләре" дип аталган ядкәрләр—күргәзмә материаллары белән дә раслана. Шул күргәзмә материалларының зур каталогында М.Г.Крамаровский дәлилләп күрсәткәнчә, Чыңгызыйлар сәнгатенең оешуында Ерак Көнчыгышның да, Урта Диңгез буе башлангычларының да тәэсире көчле булган икән. Әгәр без Алтын Урданың төрле башка илләр белән сәүдә бәйләнешләре материалларын җентекләп тикшерә башласак, югарыда санап кителгән аргументларга тагын дистәләгән вә дистәләгән яңа фактлар өсти алган булыр идек. Боларның барысы да оешу һәм озак кына яшәү чорында Алтын Урданың Көнчыгыш белән Көнбатышны тулаем тоташтырып, берләштереп торучы буын—күпер ролен үтәве хакында сөйли. Башкачарак итеп әйтсәк, XIII гасырда, яулап алынган халыкларның башларына ишелеп төшкән бәла-казалар, трагик нәтиҗәләр белән бергә, суперимперия төзелү һәм Җучи Олысының мөстәкыйль рәвештә яшәве процессында Көнчыгыш белән Көнбатышлар арасында үзара ачыш ясау—бер-берсен якыннан тану барлыкка килә. Алга таба күрербез, бу хәл "Иске дөнья" илләре һәм халыкларының язмышларына да хәлиткеч йогынты ясый: аларга, торган җирләре "таррак" булып тоелган сыман, "киңәю" юлларын эзләткәндәй, киләчәк гасырлардагы яңа географик ачышларга этәргеч һәм сәбәп була.

Беренче Җучилыларның Чыңгыз сәясәтеннән килә торган дини түземлелек традицияләрен эзлекле рәвештә саклавы нәтиҗәсендә Алтын Урда башкаласында һәм башка эре шәһәрләрендә күп кенә диннәрнең вәкилләрен очратырга мөмкин иде. Бу—төрле дини өйрәтүләрнең һәм рухи мәдәниятләрнең үзара тыныч яшәүләренә сәбәп була. Дин әһелләре һәм гыйбадәтханәләр (монастырьлар) тарханлык өстенлекләреннән файдаланганнар.

Алтын Урданың хуҗалык тормышы һәм икътисадый структурасы, мәгълүм булганча, күп укладлылыгы белән аерылып торган, бу—төбәкләрнең табигать-климат шартлары һәм социаль-мәдәни үзенчәлекләре белән билгеләнгән. Мәнфәгатьләрдәге аерымлыклар күчмә һәм утрак тормыштагы җәмгыятьләр арасында гына түгел, ә бәлки, игенчелек белән шөгыльләнсәләр дә, бер-берсеннән еракта урнашкан төбәкләр арасында да күзәтелгән. Әлеге социаль проблемаларга этник, тел-диалект, мәдәни традицияләр һәм, табигый ки, дини инанулар үзгәлеге дә килеп кушылган. Боларга шулай ук бер тарафтан дәүләт, икенче яктан Урдага буйсынган илләр һәм кенәзлекләр арасындагы сәяси каршылыкларны да кушып карарга кирәк. Аңлашылса кирәк, Җучилылар мәмләкәтенең нигезләренә баштан ук, объектив рәвештә, империяне һичшиксез таркалуга китерәчәк "акрын хәрәкәттәге бомба" салынган була.

Монголларның тиз таркалган суперимпериясенә караганда, Чыңгызыйларның олыс-биләмәләре дәүләт буларак, озаграк яшәп алалар. Бу берничә төрле сәбәпкә бәйле иде: олысларның тупрак-биләмә ягыннан чагыштырмача кечерәк булуы; монгол яулап алуларның "яшен суккан" кебек тиз җиңү эффекты; монголларга каршы юнәлгән беренче баш күтәрүләрнең уңышлы бастырылуы; яулап алучыларның урыннардагы сепаратистик карашлы кенәзләр белән уртак тел табуы; катгый тәртип урнаштыру һәм хәрби-административ системаның тәгәл эшләве нәтиҗәсендә хуҗалык һәм сәүдә-икътисадый тормышның чагыштырмача тиз арада торгызылуы; беренче Чыңгызыйларның эзлекле рәвештә дини түземлелек сәясәте алып баруы; акылга һәм

чынбарлыкка муафикъ салым җыю сәясәте үткәрелүе; коммуникация системасының бигрәк тә төзек ям-почта хезмәтенең җайга салынуы һәм шулар ише башкалар белән бәйле иде. Болар барысы бергә Җучи Олысында дәүләт хакимиятенең чагыштырмача тиз арада ныгуын тәэмин итә, шуңа күрә дә ул XIII гасырның икенче яртысында һәм XIV гасырның беренче яртысында бөтен Авразиядәге иң кодрәтле мәмләкәтләрнең берсенә әверелгән иде.

XIV гасырның беренче яртысында, Үзбәк хан хакимлек иткән чорда, (1312—1342) Җучи Олысы аеруча нык чәчәк ата. Бу дәвердә Алтын Урда Ерак Көнчыгыштан, Һиндстаннан башлап, Византия, Мисыр һәм кайбер Аурупа корольлекләре, кыскасы, һәм көнчыгыш, һәм көнбатыш илләре белән тыгыз сәүдә-икътисадый, сәяси, дипломатик вә мәдәни бәйләнешләрдә тора.

Ләкин Үзбәк хан вафат булганнан соң килеп чыккан табигый бәла-казадан—тагун (чума) эпидемиясе нәтиҗәсендә югарыда телгә алынган "акрын хәрәкәттәге бомба" эшли башлый. Ә Көнчыгыштан башланган тагун-чума чире коточкыч була. Алтын Урданың авыл һәм шәһәрләре, бигрәк тә көньяктагылары бик нык бушап кала, рус елъязмаларында билгеләп үтелгәнчә, урыны-урыны белән хәтта мәетләрне күмәргә дә кешеләр табылмый.

Шулай ук моңарчы җитәрлек дәрәҗәдә исәпкә алынмаган тагын бер факторны да билгеләп үтәргә кирәк. Ул да булса, эпидемиягә чаклы ук Олыста, аеруча илнең көньяк өлкәләрендә, халыкның артык тыгыз булуы аркасында, экологик кризис башлануы *(Э.С.Кульпин)*. Бу процесс халыкның яшәү дәрәҗәсенә, иминлегенә начар тәэсир итә һәм ул аның хакимияттән канәгать булмавын китереп чыгара.

Менә шуларның нәтиҗәсендә, илдәге халык һәм хуҗалык ресурслары какшый. Бу исә эчке каршылыкларның каты кискенләшүенә, таркаулыкка омтылучы көчләрнең тизләтелгән рәвештә үсешенә китерә. Хакимият өчен илнең үзе эчендәге ызгыш, кан коеш, туктаусыз көрәш чоры башлана. Бу көрәш тәхет тирәсендәге талашлар белән генә чикләнми—гәрчә егерме ел эчендә (1359—1359) Урда тәхетендә курчак-ханнарның егерме бише булып китсә дә— бәлки феодаль төркемнәр һәм алар кул астындагы халыклар арасында да канлы бәрелешләргә китерә.

Эчке низаг-ызгышлардан тыш халыкара өлкәдә дә, бигрәк тә бәйле илләр белән үзара бәйләнешләрдә проблемалар килеп туа. Моның ачык мисалы булып мәгълүм Куликово сугышы (1380) тора.

Туктамыш ханның барлык җөйләр буенча да сүтелеп ишелә башлаган империяне саклап калу юлындагы уңышлары кодрәтле Идегәй бәк белән булган бәрелеше һәм 1395 елда Алтын Урдага Аксак Тимернең басып керүе белән юкка чыгарыла. Бу сугыш Җучи Олысы шәһәрләре өчен коточкыч фаҗига була, һәм алар моннан соң беркайчан да тернәкләнә алмыйлар *(Г.А.Федоров-Давыдов)*.

Нәкъ менә шушы чорда, дөресрәге XIV гасырның соңгы чирегендә белемле, зыялы кешеләрнең илдән качуы характерлы күренеш булып тора: укымышлы дин әһелләренең, әдип һәм шагыйрьләрнең, каллиграф һәм хокук белгечләренең күпчелеге тыныч яшәүче илләргә— Сүриягә, Мәмлүкләр Мисырына, Кавказ артына һәм Урта Азиягә күченеп китәләр. Мондый процесс Җучилылар империясенең җимерелүе котылгысыз икәнлеген ачык күрсәтә торган билге-галәмәт иде.

Шул рәвешле Идел буеннан Төньяк Африкага "зиһен агылу" нәтиҗәсендә анда, Мисырның югары катлам мәмлүкләре (нигездә кыпчак далаларыннан чыгучылар) арасында, күпмедер дәрәҗәдә мәдәният һәм тел-әдәбият өлкәләрендә, "киредән төркиләшү" процессы башлана. Анда кыпчакча, ягъни Алтын Урдадагы төркичә язма телдә югары сәнгатьчән әсәрләр, төрле трактатлар, шул җөмләдән филологик тикшеренүләр, гарәпчә-төркичә һәм төркичә-гарәпчә сүзлекләр һ.б. төзелә *(Ә.Нәҗип, 1965)*. Мисыр тарихчысы Әмин әл-Холи язганча, бу вакытта мәмлүкләрнең югары катламында рәсми тел буларак кулланылган гарәп теле җитди сынауга дучар ителә.

Таркалу үзен озак көттерми. Ул алдагы, нәүбәттәге XV гасырның беренче яртысы белән урталарына туры килә. Шул рәвешле, 20 елларда Себер ханлыгы, 30 елларда Казан, 40 елларда Кырым ханлыклары оеша; шушы ук елларда Нугай урдасы, аннары 60 елларда һәм бераз соңрак Әстерхан, Казакъ, Үзбәк ханлыклары бүленеп чыга.

Алтын Урда мирасына юридик яктан иң элек гаять зур империянең кечкенә генә үзәк өлешенә хуҗа булган Олы Урда дәгъва кыла; ул династия җәһәтеннән империянең "ярчык-варисы" булган башка дәүләтләр белән ызгышып яши. Үзе җинелү артыннан җимерелүләргә дучар була, 1502 елда Кырым ханы Миңле-Гәрәй тарафыннан тәмам тар-мар ителә. Шушы вакыйгадан соң җиңүче хан үзенә "Бөек Урданың Бөек ханы Миңле-Гәрәй хан" дигән олы титул-дәрәҗә ала. Шул рәвешле, Кырым ханы үзен барлык Алтын Урда мирасына төп варис дип игълан кыла.[5] Шул ук вакытта ул Казаннан, Әстерханнан, Себер һәм Касыймнан булган башка Җучилыларның да үзләрен ханлык дәрәҗәсенә хокуклы дип исәпләүләрен танымыйча булдыра алмый.

1480 елда, ягъни Куликово сугышыннан соң нәкъ йөз ел узгач, Мәскәү Русенең Урда ханнарыннан юридик планда бәйлелеге юкка чыгарыла. Һәм Мәскәү Русе иленең төньяк-көнчыгыш өлешендә генә түгел, бәлки аның чикләреннән тыштa да, бигрәк тә Казан тарафына карата актив сәясәт үткәрә башлый. Монда шунсы игътибарга лаек, Мәскәү хөкемдарлары үзләренең Казанга һәм Идел буйларына юнәлгән экспансияләрен иң киме Алтын Урда мирасының бер өлешенә булган хокуклары белән акларга омтылалар. Мәсәлән, Иван III 1487 елда Казанга

ясалган уңышлы сәфәреннән соң үзенең болай да купшы титулларына тагын "болгар кенәзе" дигәнен дә өстәп куя. Алга таба бөек кенәзләр үзләренең кайбер илләрнең хөкемдарларына күндергән битикләрендә "Казан—безнең йорт ул" дип кабатлыйлар.

Шундый бер факт та игътибарга лаек. Мәгълүм булганча, бу чорга кадәрле "хан" (падиша) дигән титул бары Чыңгызыйларның гына монополиясендә булып, алардан башка беркем дә "хан" дип олылана алмаган.[6] Рус кенәзләре, сюзерен-ханнар күзлегеннән караганда, бары тик бәкләргә генә тиңләштерелгәннәр, алар үз чиратында ханнар алдында "баш орырга" тиеш булганнар. Иван III генә, беренче тапкыр үзен падишаһ дип игълан итәргә омтылыш ясап карый. Ләкин бу титул Мәскәү хөкемдарларына чын-чынлап 1547 елда, Иван IV патшалык итә башлаган чорда, ягъни Алтын Урда ханнарының реаль йогынтылары тәмам бетерелеп, Мәскәүнең территория ягыннан якын күршеләре һәм династия буенча—сәяси яктан Алтын Урданың турыдан-туры варислары булган Казан һәм Әстерхан ханлыкларына һөҗүмгә көчү алдыннан беркетелә.[7]

Атын Урда мирасы проблемалары әле генә билгеләп үтелгән чын-чынлап сәяси аспектлар белән генә чикләнми, әлбәттә, гәрчә һәм этногенетик, һәм культурологик, һәм тел-филологик аспектлар да сәясәттән, сонрак хәтта "сәясәт уйнаулардан" да азат булмыйлар. Бу мәсьәләләр аерым тукталып үтүгә дә мохтаҗдыр.

Иң катлаулысы һәм чын-чынлап каршылыклысы булып, СССР һәм Русиядә кайбер соңгы чор милләтләрнең Алтын Урда халкына карата булган этногенетик мөнәсәбәте мәсьәләсе тора. Бу мәсьәлә ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 ел 9 август карары, беренче карашка зыянсыз кебек һәм тышкы яктан гөнаһсыз булып тоелган "Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яктырту турында" дигән карар чыкканнан соң тәмам катлаулана. Әмма бу карар үзенең эчтәлеге, бурычы һәм төп максаты буенча бик тә куркыныч ниятле була. Чөнки ул үткәндәге төгәл бер илне бөтенләй реакцион, "паразитларча" күренеш дип атап, күп этнослы әлеге илнең барлык халкын рус милләтенә тулысынча каршы куеп, кайбер төрки халыкларның, бигрәк тә татарларның тарихларына карата тенденциоз сәясәткә корылган тискәре мөнәсәбәт урнаштыруны максат итеп куя .

Шунсын да исәпкә алырга кирәк, 1944 ел бер үк вакытта күпләгән халыкларны—балкарларны, ингушларны, калмыкларны, карачайларны, кырым татарларын, чеченнарны һ.б. үз илләреннән куып җәзалау елы булып та тора. Мәгълүм ки, Сталинның көн тәртибендә шулай ук Казан татарларын да көнчыгышка таба сөрү максаты торган була, ләкин алга бөтен Советлар Союзы буенча таралган бишмиллионлы халыкны бер "учка" җыю кебек авыр мәсьәлә дә килеп баса. Шуңа күрә дә "халыклар атасына" югарыда телгә алынган карарны чыгарып, татар халкын янәсе "кыргый" илбасарларның—монголларның варислары дип атап, аларны рухи яктан җәзалауга чакыру белән "канәгатьләнергә" туры килә. Шушы карардан соң махсус тикшеренүләрдә, аеруча мәктәп дәреслекләрендә, фәнни-популяр әдәбиятта һәм кинематографта барлык рус халкының тарихи мәңгелек дошманы образын тудыру башлана. Шушы репрессияләр комплексы фонында Сталинның "халыклар дуслыгы" дигән идеясе тормышка ашырыла башлый.

Сугыш елларыннан соң татар халкының этногенезын тикшерүгә багышланган туктаусыз кампанияләрнең башланып китүе менә шуларга каршы реакция иде. Боларның барысы да, "татарлар—татар түгел ул", бары тик "болгарлар" гына, аларның кырым татарларына, бигрәк тә Алтын Урдага "бернинди дә мөнәсәбәтләре юк" дигән карашны "раслау" өчен эшләнә. Нәтиҗәдә, татар этногенезы мәсьәләсе гадәти фәнни танып белү дисциплинасы булган этнология өлкәсеннән чыгып, нык сәясиләшкән социаль психологиянең бер өлешенә әверелә. Ә иң кызганычы, бер үк вакытта иң көлкесе дә шунда ки, татар этногенезы турында теге яки бу теориянең тарафдарлары да, каршы яклары да төгәл бер халыкның этник тамырлары белән хакимлек итүче династиянең этник чыгышын бутадылар, яки тәңгәлләштерделәр. Яисә, киресенчә, этногенетик процессның аерым бер элементларын гына билгеләп үтеп, аның әһәмиятлерәк булган башка компонентларына күз йомдылар.

Мәсьәләне болай "биологлаштыру" процессында, табигый ки, халык тарихының әһәмиятләре ягыннан мөһимрәк булган башка аспектлары тиешле дәрәҗәдә яктыртылмады.

Этнос тарихын этноним тарихы, ягъни халыкка тагылган исем белән бутау һәм тәңгәлләштерү мәсьәләсенә килгәндә, киң таралган мондый күренеш хакында кайбер аңлатмалар биреп китү белән чикләнәм. Еш кына кабиләләргә һәм халыкларга исемнәр, табигый буларак, якын һәм ерак күршеләре тарафыннан да бирелгән, һәм мондый читтән кушылган исемнәр тора-бара халыкның үз исемен кысрыклап чыгарган (мисаллар җитәрлек: кытайларны, бирманнарны, һиндстанлыларны, индеецларны, әрмәннәрне һ.б. искә төшерү дә җитә). Еш кына кайбер кабиләнең исеме, әкренләп киңәя барып, күршеләр каршында яулап алынган халыклар өчен дә, аннары төгәл бер дәүләтләргә карата да уртак атамага әверелә, ягъни ул **политоним** булып китә. Соңрак, күрәсең, мондый этно-политонимнар "чәрдәкләнү" һәм таркалу чорын кичерә, тора-бара аларның өлешләре бөтенләй юкка чыга, "онытыла". "Татар" атамасы белән дә шундыйрак "метаморфоза" булып узган. Шуна күрә дә Урхан язмаларындагы татарлар (VIII гасыр) һәм Чыңгызхан тәхеткә күтәрелгән, ул яу чапкан чорлардагы татарлар белән (XIII), бигрәк тә соңгы дәвер Идел—Урал буе татарлары арасына тәңгәллек билгеләре куярга ярамый. Урта гасырлардагы татар кабиләләренең һәммәсе дә бер үк халык булмавы хакында түбәндәге фактлар да сөйли:

кытайлар аларга карата төрле эпитетлар биреп, үзара аерып караганнар, әйтик кара, ак, дала, урман, хәтта су буе татарлары дип. Әгәр кайбер чыганаклар аларның монгол телле булулары хакында сөйләсәләр, икенчеләре (мәсәлән, Мәхмүд Кашгарый) татарларны төрки телле халык дип күрсәтәләр. Болар барысы да шул хакта сөйли: XIII гасырда Көнчыгыш Ауропага "татар" дип аталган ниндидер бердәм этнос түгел, бәлки ул этноним киң кулланыштагы политоним составында гына килеп чыккан. Бу уңайдан шунысы да игътибарга лаек: бу көнгә кадәр бер генә җитди археологның да Байкал якларыннан алып Идел буена кадәр, нәкъ "татарларның матди эзен" таба алганы юк.

Шул рәвешле, югарыда күрсәтелгәнчә, хәзерге Идел—Урал буе татарлары X йөз башында ук мөселманлашкан болгарларның XIII гасырның беренче яртысында көчле күченешләр кичергән тагын да күбрәк санлы кыпчак-угыз кабиләләре белән аралашуы һәм акрынлап кушылуы нәтиҗәсендә XIII—XV гасырларда бердәм халык булып формалаша башлый. Алар, үзара, кардәш буларак берләшү процессында хәзәр кабиләләре калдыкларын да "йотып", аз санлы монголларны үз араларында "эретәләр" һәм җирле финн-угор кабиләләренең дә билгеле өлешләрен төркиләштерәләр. Хәзерге заман татар халкының антропологик тип җәһәтеннән бердәй түгеллеге, ырык-раса ягыннан мәгълүм дәрәҗәдә катнаш икәнлеге менә шуның белән аңлатыла.

Икенче яктан караганда, Алтын Урда барлыкка килгән чордагы этник процесс бер татар халкының гына этногенезы үзенчәлекләренә кайтып калмый. Ауразия киңлекләрендә электән үк яшәгән халыкларның үзара нык аралашулары, ягъни монгол яулап алулары нәтиҗәсендә "уртак тегермәндә тартылулары", билгеле бер күләмдә аларның эчке, этник нигезләренә дә үзгәрешләр кертkән иде. Моның шулай икәнлегенә ышанып өчен әлеге күчмә халдә яшәгән төрки халыкларның, мәсәлән, казакъ, кыргыз, каракалпак, башкорт, нугай, күчмә үзбәк, шулай ук кырым татарларының дала өлешендәге ыруг, кабилә исемнәренә күз ташлау да җитә.[8]

Чынлыкта исә, XIII гасырда һәм XV йөз башында Алтын Урдада бер төрки-татар халкының, ягъни тулаем бер макроэтносның формалашу процессы барлыкка килә. Шул ук вакыт эчендә, бу процесс белән параллель рәвештә, кайбер төрки халыкларның, аерым алганда, булачак милләтләрнең төбәк-этник җирлегенә нигезләр дә салына башлый. Шуңа күрә дә Җучи Олысының тарихы, теләсә нинди хәзерге заман төрки халыкның аерым тарихына караганда киңрәк тә, тирәнрәк тә. Ләкин шул ук вакытта Алтын Урда чорында яшәгән теләсә нинди халыкның тарихы Җучи Олысы барлыкка килгәнчегә кадәр булган, шартлы рәвештә әйткәндә, автохтон бабаларның (илнең төп халыкларының) тарихларына караганда киңрәк тә. Мәсәлән, хәзерге заман Казан татарларының тарихы болгарныкына, Болгар дәүләте тарихына караганда киңрәк, ләкин Җучи Олысы һәм тулаем төрки-татар этносы тарихы белән чагыштырганда таррак.

Шуның белән бергә бердәм төрки-татар этносы барлыкка килү процессы тәгалләнмичә дә кала, дөресрәге ул бозыла, хәтта бердәм дәүләт җимерелгәч, бөтенләй туктала. Ауразия төрки халыкларның этникара якынлыгының да, миллилек җәһәтеннән аерымлыгының да тарихи язмышы менә шулар белән аңлатыла да инде.

Санап узылган дәлилләрнең һәммәсе расланганча, Җучи Олысының—Алтын Урданың—тарихын этник культуралар планында караганда, бер халыкның гына, ягъни соңрак оешкан бер милләтнең генә хакимияте нәтиҗәсе дип бәяләргә ярамый икән. Әмма, шул ук вакытта, бу империядә төрки-татар этносының өстенлек алып торуын да инкарь итеп булмый. Алга таба империя таркалу нәтиҗәсендә, шушы этностан төбәк-диалектлар җирлегендә бүленеп чыккан өлешләр буларак, төрки халыкларның тулы бер төркеме, тагын да арырак —төрки телле аерым милләтләр оешып җитә.

Мондый үсешнең иң җете мисалы булып Идел—Урал буе татарларының язма-рухи мәдәнияте үзенчәлекләре тора. Бу өлкәнең күренекле белгече Э.Н.Нәҗип үз вакытында дәвамлы билгеләп килгәнчә, татар теле, башлыча рухани-дини әдәбияттагы тел, озак вакытлар Алтын Урда дәверенең язма традицияләрен саклап, дәвам итеп килә. Татар язма теленең үзенчәлекле үсеше, ягъни аның диалекталь нигездә янарыш алу чоры, Урта Азиядәге һәм Кырымдагы әдәби төрки телләргә караганда, соңрак дәверләргә туры килә. Шуңа күрә дә татарның рухи-язма мәдәниятен иң элек Алтын Урда чоры әдәби традицияләреннән һәм әлеге илнең гомум сәяси тарихыннан башка дөрес аңлавы мөмкин түгел.

Алтын Урда таркалу процессында аякка баскан төрки һәм татар дәүләтләренә килгәндә (болай дигәндә, Себер, Казан, Кырым, Әстерхан, Казакъ, Үзбәк ханлыклары һәм Олы Урда дәүләте күздә тотыла), аларның һәркайсының хөкемдарлары—ханнары булып Җучилылар династиясе вәкилләре күтәрелгән. Ул чакта аларның законлы хаким булуы беркем тарафыннан да шик астына алынмаган. Чыгарма булып хакимият башында Мангыт бәкләре торган Нугай Урдасы гына исәпләнгән. Шулай булгач, һәм сәяси, һәм тарихи-мәдәни тарафлардан караганда да, Алтын Урда чорының мирасы—XIII-XV гасырларның күп төрле мәдәният, сәнгать вә әдәбият өлкәләренә караган барлык ядкәрләре бер төркем тугандаш халыкларның *уртак байлыгы* булып тора. Мәсәлән, Идел—Урал буе татарларының, нугайларның, кырымлы татарларның, башкортларның, комыкларның, балкарларның, карачайларның, әзәриләрнең, казакъларның, каракалпакларның, кыргызларның, күчмән үзбәкләрнең һәм башкаларның. Шуңа күрә дә төгәл бер дәвер-заманага караган бу бердәм хәзинәне өлешләргә бүлгәләү һәм соңгы чорларның милли "фатирларына"

таратып чыгу, мөгаен, кирәк тә түгелдер. Җитмәсә, шул мәсьәләне дә истә тотарга кирәк, бу бай, үзенчәлекле һәм чоры өчен югары дәрәҗәдәге культура—Алтын Урда чоры культурасы—чыгышы белән һәм төрки һәм төрки булмаган цивилизацияләрнең өлешләре мул кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм үсеш алган. "Җучилылар хәзинәсе", ягъни "Алтын Урда хәзинәләре" дигән темага караган бер комплексның ядкәрләре дә моңа ачык мисал булып тора.

Мәгълүм ки, югарыда санап үтелгән милләтләрнең тарихларын киң планда яктыртканда монголларга кадәрге башлангычлар белән бәйле өлешләрне дә, шул ук вакытта матди һәм рухи кыйммәтләрнең Алтын Урдадан соңгы дәверләрдәге үсү үзенчәлекләрен дә җентекләп исәпкә алырга кирәк. Ягъни югарыдагы нәтиҗә аталган халыкларның тарихи язмышларында мөһим роль уйнаган конкрет дәвергә карата гына хакыйкатькә туры килә икән.

Сүз дә юк, Алтын Урданың тарихи мирасын һәръяклап бәяләгәндә барысын да бер генә төрки халыкның тарихына кайтарып калдыру ярамас иде. Күпләгән халыклар һәм илләрнең матди-рухи кыйммәтләреннән өлешләр кушылып берләшүдән туган Алтын Урда, ягъни төрки-татар цивилизациясе соңгырак чорлардагы башка халыкларның, җөмләдән русларның да дәүләтчелекләре, сәяси структуралары, мәдәниятләре тернәкләнүгә, үсүгә йогынты ясаган. Белгечләргә генә түгел, бәлки тарихтан азмы-күпме дәрәҗәдә мәгълүматы булган кешеләргә дә рус телендәге төрки-татар алынмаларның урыны һәм күләме хакында яхшы ук билгеле. Көнкүреш, хуҗалык итү өлкәләрендәге сүзләрдән алып, хәрби-сәяси, административ эчтәлектәге атамаларга кадәр. Мәсәлән, *кафтан, ичик, башлык, караул* кебек сүзләрдән башлап *"ура!"* оранына кадәр (*атаман, есаул, улан* кебек хәрби дәрәҗәләрне әйткән дә юк) әнә шундыйлардан. Рус казачиларындагы төрле исемнәр, хәрби төзелеш башлангычлары һәм гаскәри кирәк-яракларның тамырлары хакында да сүз куертуның хаҗәте бар микән. Әгәр Петр Iгә кадәрге рус аксөякләренең кием-салым элементларына кагыла калсак, мәсьәлә тагын да ачыклана төшәр иде.

Белергә теләүче кеше монгол һәм Алтын Урда чорларындагы унарлы система белән соңгы дәверләр хәрби төзелешләрендәге взвод, рота, полк, дивизия белән билгеле бер бәйләнеш барлыгын күрә алыр иде. Әлбәттә, әлеге элементлар арасына тигезлек билгесе куярга ярамастыр, Русиянең соңгырак чор хәрби эшләренә немец һәм француз йогынтысы көчле булуын да исәпкә алырга кирәктер. Әгәр боларның барысына йөзләрчә рус фамилияләрендәге төрки-татарча тамырларны кушып карасак, Алтын Урда һәм аннан соңгы татар ханлыкларына барып тоташа торган XVI—XVIII гасыр рус аксөякләре шәҗәрәләре материалларына кереп китәрбез.

Димәк ки, Мәскәү хөкемдарларының, югарыда күрсәтелгәнчә, Алтын Урданың сәяси мирасына дәгъвасына, баксаң, мәдәни-көнкүреш, хәрби-административ, хәтта генеалогик яктан да дәлилләр табыла икән. Билгеле, XX гасырдагы милли аң белән фикер йөртүчеләр дәрәҗәсеннән түгел, бәлки элекке чор кешеләренең юридик карашларына хас позициядә торганда. Ә бу чор ике йөз ел дәвамында Мәскәүдәге Бөек Владимир кенәзлеге тәхетенә утырыр өчен Сарайдагы хан кулыннан ярлык алу тәртибенең хәтердә нык сакланган чоры иде. Ягъни сүз рус Бөек кенәзе хакимиятенең Алтын Урда дәүләтенә буйсынып торган бер өлеш хәлендәге ике йөзьеллык чоры хакында.

Мәскәүнең бөек кенәзләре йортының татар ханнары династиясе белән билгеле бер күләмдә "туганлык" җепләре (әлбәттә, биологик түгел, бәлки нибары сәяси "кардәшлек" кенә) булуы хакында түбәндәге мисаллар да сөйли. Мәсәлән, баласыз бөек кенәз Василий III үзенең ир баласы—булачак Иван IV—туганчы, "Петр" исеме белән чукындырылган Казан ханзадәсе Ходайколны, Ибраһим ханның улын, үзенең варисы итеп билгели. Тәҗ киюгә ирешкән яки ирешмәгән Җучилыларның Мәскәүдә патшаларча югары урын биләүләре хакында Сигизмунд Герберштейн да язып калдырган *(Герберштейн, 1988)*. Рус-татар бәйләнешләры чылбырында XV гасырда (Василий II Темныйның татар әсирлегеннән азат ителүеннән соң) Касыйм ханлыгының барлыкка килү һәм XVII гасырда аның "юкка чыгу" тарихы да шулай ук үзенчәлекле бер күренеш булып тора *(Вельяминов-Зернов, 1863—1887)*. 1575 елда Иван IV тарафыннан Симеон Бикбулатовичка "бөтен Русьнең бөек кенәзе" дигән дәрәҗә бирелүен дә искә төшерик... Кыскасы, XV— XVI гасырларда Җучилылар белән Рюриковичлар арасында үзенчәлекле, XX йөз психологиясе буенча аңлавы шактый ук кыен булган бәйләнешләр хөкем сөргән икән.

Мондый карашларның файдасына икенче төрле, ягъни килеп чыгышлары ягыннан русларга түгел, бәлки татарларның үзләренә бәйле булган дәлилләр дә сөйли.

Мәгълүм булганча, Алтын Урданың аерым-аерым дәүләтләргә таркалу чорында Русьтә "йомышлы татарлар" дигән, рус хезмәтендә торган махсус бер катлам кешеләре барлыкка килә. Ул үзенең составы ягыннан бик чуар булган: аңа эреле-ваклы морзалардан, бәкләрдән алып, Казан һәм Әстерханда тәхет биләгән яки шуңа дәгъва кылган ханнарга, ханзадәләргә кадәр кергән. Алар күп очракта үзләренчә Мәскәүгә хезмәт итеп, Казан һәм Әстерханга каршы Мәскәү ягында сугышалар. (Болай дигәндә, 1552 елда, Казанны яулап алу вакытында, Иван IV ягында күпсанлы, ун меңләгән татарның катнашуын искә алу да җитәр кебек.) Казанда, шулай ук, Мәскәү яклы катламның яшәп килүен, аның рус патшасы өстенлеген танырга әзер торуын да очраклы хәл дип атап булмый. Боларның барысы да шул хакта сөйли: XV гасырның ахыры һәм XVI йөзнең беренче яртысында, татар аксөякләренең бер төркеме, арага Җучилылардан да кертеп, хәзергечә әйтсәк, Мәскәүнең Алтын Урда мирасына карата дәгъвасында легитимлык булуын таный торган катлам

барлыкка килгән була. Бөтен нәрсәне дә, бүгенге көн—XX гасырның әхлак-әдәп нормаларыннан чыгып, гади "сатылуга" һәм гадәти "хыянәткә" генә кайтарып калдыру, Урта гасырларда яшәп килгән проблемаларны тулысынча аңлатырга мөмкинлек бирми. Ахыр чиктә хыянәт тә, әгәр ул киң таралган гаммәви күренеш икән, аның хокукый, һич югы әхлакый җәһәттән сәбәпләре була.

Аңлашыла булыр, биредә телгә алынган проблема, ягъни XVI—XVII гасырлардагы Рус дәүләтенең Алтын Урда мирасына (бигрәк тә, аның территориясенә) дәгъва итү мәсьәләсе хәзергә гипотеза—гоманлау рәвешендә генә тәкъдим ителә. Китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, ул мәсьәлә киләчәктә җентекләп махсус өйрәнүгә мохтаҗ.

Ниһаять, бу проблеманың тагын бер аспекты, ***аурaзиячелек*** дип атала торган тармагы да бар бит әле. Бу концепция, аның кайбер мәсьәләләренең (аеруча алдагы көннәрдә, киләчәктә каралыр дип исәпләнгәннәренең) чишелеп бетмәслек дәрәҗәдәге катлаулылыгына карамастан, бигрәк тә, үткәндәге чынбарлыкны исәпкә алганда, бөтенләй үк " сәбәпсез"—нигезсез түгел.

Аурaзиячелекнең барлыкка килүе XX йөз башында Аурупа һәм Азиянең икесендә дә урнашкан иң зур дәүләт—Русия империясе тарихында туган катастрофик үзгәрешләр чоры белән бәйле иде. Русиядә ул 90 еллар башындагы кризислар чорында, СССР таркалган һәм аның дәвамчысы булган Русия Федерациясе дә шундый ук хәлгә тарыган дәвердә "реанимацияләнде", ягъни яңадан тергезелде. (Эшләр әйбәт кенә барган заманда, күрәсең, аның хакта уйларга вакыт җитмәгәндер.)

Шунысы характерлы, аурaзиячелекнең өр-яңа тарафдарлары илнең киләчәк язмышына карата булган концепцияләрен нигезләгән чакта, табигый буларак, Ауразия халыкларының Русиядә һәм СССРда гына бердәм яшәү тәҗрибәсенә игътибар юнәлтәләр, ләкин тарихның элгәреге чорларына әһәмият биреп җиткермиләр. Минем фикеремчә, алардан—яңа аурaзиячеләрдән—аермалы буларак, элекке, ягъни XX гасыр башы аурaзиячеләре, тарихи дошман образын торгызу белән шөгыльләнмичә, башлангыч фактор булган Бөек Монгол империясе һәм Алтын Урда дәүләте оешкан чорларга тиешле игътибар бирүләре белән киңрәк тарихи карашны алга сөргәннәр иде. Нәкъ менә Ауразиянең шул галәмәт зур, күп этниклы дәүләтләре таркалгач "мирас мәсьәләсе" калкып чыкты да инде.

..."Мирас һәм аның варислары" турында кыю фикер йөртүләр һәм кискен каршы чыгулар, житди тикшеренүләр белән җиңел генә "миф" тудырулар, бердәм караштa торучыларның бәхәсләшүләре һәм капма-каршы фикердәгеләрнең килешүләре бездән соң да дәвам итәр әле. Чөнки дөнья, хәят дигән нәрсә, Киңлек—пространство ягыннан гына түгел, Вакыт—хәрәкәт җәһәтеннән дә чикләнмәгән, ләбаса!

### Искәрмәләр

*1. Күчмә халыкларны гел ерткыч, утрак халыкларны исә тулаем "әйбәт" итеп күрсәтергә омтылу махсус карауга лаек түгел. Болай дигәндә, Аурупа һәм Американың кайбер халыклары һәм кабиләләре бөтенләй юкка чыгуны һәм шулай ук XX гасырда үткәрелгән геноцид фактларын искә төшерү дә җитәр кебек. Монгол яулап алучыларының уңышлары җиңелүче халыкларның (Кытай, Урта Азия илләренең) хәрби техникасына бәйле дигән уйдырма да, гомумән, фәнни карашка туры килми. Алай булгач, нигә соң әлеге техниканы уйлап табучылар аннан үзләре файдаланмаганнар? Болай фикер йөртә калсак, Үзәк Азиянең күчмә халыклары, шул исәптән монголлар да, үз чоры өчен начар коралланмаган булганнардыр.*

*2. Күрәсең, шушы факт нигезендә кайбер тарихчылар, аерым алганда Әхмәтзәки Вәлиди, Чыңгызханны төркиләрдән килеп чыккан дип исәплиләр.*

*3. Бу ике уделның кайсы көнбатышта, кайсы көнчыгышта урнашканлыгы хакында әлегә кадәр ачыклык юк, бәхәсләр дәвам итә.*

*4. Билгеле, җирле идарәчеләр тарафыннан мондый бердәм норманы бозу очраклары да була. Моның аеруча ачык мисалы булып, салымны күп каеру хисабына баеган һәм мул ришвәт бирергә яратканы өчен "калита" кушаматы алган ("калита—хапта, калта, "акча капчыгы" дигәнне аңлата) Мәскәүнең бөек кенәзе Иван Данилович тора.*

*5. Әгәр элегрәк Җучилылар мәмләкәтенең халыкара атамасы Җучи Олысы булса, соңрак ил эчендә Олуг Урда варианты кулланыла башлый, рус документларында ул "Большая Орда" буларак билгеләнә.*

*6. Хәтта кодрәтле Аксак Тимер дә үзенә андый титулны алырга җөрьәт итмәгән, ул үзенә карата "әмир", ягъни гомумән "хөкемдар" мәгънәсендәге дәрәҗәне кулланган, яисә хан йортының кияве дигән мәгънәдәге "гүргән" атамасын алган.*

*7. Әлбәттә, падиша (царь) титулын алуда Борынгы Русьнең Бизанс (Византия) империясе белән бәйләнешләренең һәм православие дине көчәюенең әһәмияте дә бар иде. Әмма бу титулның ныгып калуында Иван IV тарафыннан 1547—1556 еллар арасында оештырылган яулап алуларның да әһәмияте барлыгы бәхәссез булса кирәк.*

*8. Хәзер кайсыбер төрки халыкларның вәкилләре үз бабаларының тирән тамырларын эзләү белән мавыгалар. Мин һич кенә дә мондый омтылышларны чикләргә җыенмыйм, чөнки мин этногенезның аерым компонентларын гына (образлы итеп әйткәндә, ерактагы әби-бабаларының килеп чыгышын гына) күздә тотмыйм, бәлки билгеле бер чоры турында, бу очракта оныклар һәм туруннар турында сүз алып барам. Гомумән, теләсә нинди халык этногенезының башы да, ахыры да юк, ул —мәңгелек хәрәкәттә, үсештә.*

## Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ВӘЛӘКИН*** *г.* — Ләкин, әмма, тик, бары. "Вәләкин" сүзе "Древнетюркский словарь"га да теркәлгән. Кыскартып: *вәли.* // *Вәләкин Галәм чынбарлыкта без кабул иткәннән тыгызрак булса, аның киңәюе акрыная башларга да мөмкин. (М.Г.Җиһаншин).*

***ВӘССӘЛЯМ, ВӘССӘЛАМ*** *г.* — Бетте, тәмам (булды), бар булганы шул (вә хушыгыз!). Кайчагында *вәс-сәлам* язылышы очрый. // *Рәхимлегең белән булыр эш тәмам, Рәхимле бул барчабызга, вәс-сәлам. (Мөхәммәдьяр).*

Сүзне тәмамлагач әйтелә торган ымлык функциясен дә үти.

***ГАБА*** *г.* — Бәдәви гарәпләрдә ирләр кия торган җиңел ябынча. Согуд Гарәбстанында аны дөя яки сарык йонынннан эшләнгән ике кисәк йон тукымадан (киездән) әзерлиләр. Ул юка да, калын да булырга мөмкин. Фәкыйрьләрне һәм суфиларны *габалы* дип тә әйткәннәр. // *Габа кияр, үз-үзени суфи белер... (Мәүла Колый).*

Язылышта *каба, къәба* вариантлары да очрый.

Тагын кара: ***ГАБАЙЯ.***

***ГАБАЙЯ*** *г.* — Читләренә ефәк тоткан кара төстәге ябынча, аны бәдәви гарәп хатын-кызлары чатырдан чыкканда башка киемнәре өстеннән ябыналар. Бай хатыннарның һәм шәһәр хатын-кызларының ябынчасы алтын җеп белән чигелгән була. Гадәттә кара төстәге дәрвиш ябынчасы да габайя дип аталган (иңбашына салып йөри торган җиңсез кием). Кайбер хәбәрләргә караганда, Мөхәммәд Пәйгамбәр дә габайяга төренеп йөргән.

***ГАБДЕЛ ЛИМОН*** *тар.* — XX гасырның егерменче елларында (НЭП еллары) миллионер спекулянтларга бирелгән кушамат, *миллион колы* мәгънәсендә.

***ГАВАМ, ГАВӘМ*** *г.* — Төркем, (кара) халык, масса. // *Гавами кыйсьме* — халык массасы. *Гавам дарелфөнүне* — халык университеты. *"...бер бичара улгучы гавамнан мән, хассллардан дәгел мән"*. Таҗетдин Ялчыгол. *"Х" хәрефе* (авазы — *А.Т.*) *гавәм халык телендә "къ" хәрефенә мөнкалиб буладыр: "халык" урынына "калык", "хак" урынына "къак" ишетеләдер. (К.Насыйри).*

Тагын кара: ***ГАМ.***

***ГАВӘМИ*** *г.* — Халыкчан; массакүләм. // *Гавәми китапханә* — халык китапханәсе (публичная библиотека). *Гавәми төс алу* — массакүләм җәелү.

***ГАВӘМПӘРВАР*** *гф.* — Демократ; демократик; халыкчанлык, халыкны сөючелек.

***ГАВӘМПӘРВАРЛЫК*** *гфт.* — Демократия.

***ГАЗА*** *г.* — Изге сугыш. Күплек саны шәкеле — *газават. Гази* — сугышчы. // [Бишенче баб] *Газа кылмыш сүзләрен бәйан кылур...* Мөхәммәдьяр. Мөхәммәдьярның замандашы Колшәрифнең "Зәфәрнамәи вилайәте Казан" дигән әсәрендә "газават" урынына *"газат"* сүзе кулланылган: "Газат әһлигә бу бер хөсне ләтафәт бар: Зафәр тапса — ганимәт, гәр шәһадәт тапса — җәннәт бар." (Мәгънәсе: Газаватка баручының һәрвакыт бер яхшы әҗере бар: әгәр җиңсә — ганимәт табар, шәһид китсә — җәннәт табар.)

Тагын кара: ***ГАЗВӘ.***

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 1 нче санында.*

**ГАЗИЗ** *г.* – **1**.Кадерле, хөрмәтле; кыйммәтле. // *Бу көн бу дөньяда кешелек газиз.* Борынгы төркичәдән. **2**.Изге. Татар телендә күплек саны шәкелендә еш кулланыла. // *Газизләрдән берсе кылыр риваят, Нәкыльдер дип борынгыдан хикәят.* (Мөхәммәдъяр). *Газизләр чишмәсе*– изгеләр чишмәсе. **3**.Патша, хаким. // *Мисыр газизе.*

**ГАИБ ИРӘННӘР / ГАЙБ ИРӘННӘР**– *Рижаль әл-гаиб.* Кешегә күренми торган яхшылык эшләүче 40 изге ир-егет (дин өчен шәһит киткәннәр). Кайчакларда ак сакаллы карт кыяфәтенә кереп, адәмнәргә яхшылык кылып йөриләр. Мондый ышану төркиләрдә Исламга кадәр үк булган. "Гаиб ирәннәр" Кол Шәрифнең "Кыйссаи Хөбби Хуҗа" әсәрендә дә телгә алына. Ульяновск мишәрләрендә гаиб ирәннәр турында легендалар да бар. XVII гасырда мөнәҗҗимнәр төзегән "Йолдызнамә" китабында гаиб ирәннәрдән кайберләренең исемнәре дә атап күрсәтелгән, болар: *Котыб, Имамәт, Утаз, Бодла, Рокаба, Нәҗәба, Нукабад.* Шушында ук аларның *өч йөз алтмыш алты* (?) кемсә булып, елның һәр көненә берәү туры килгәнлеге әйтелә. "Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе"ндә сәләтсезрәк бер шәкертнең Шам Шәриф шәһәрендә гаиб ирәннәр төрбәсе янына килеп, бер гаиб ирән белән аралашуы һәм шуннан соң сабакларын бик яхшы белә башлавы турында сөйләнә. Догалары кабул булган кешеләр бу гаиб ирәннәрне чыннан да күрәләр икән.

Саннары кырык булганга, аларны *кырык газизләр* яки *кырыклар* дип кенә атау очрый.

Мөселманнарда гаиб ирәннәр санынча кырык түгәрәк күмәч (*гердә*) пешерү йоласы булган.

Татарда ялган паспорт белән яшәүчеләрне "*гайбирән*" (гаиб ирән) дип атаганнар.

**ГАИЛӘ** *г.* – Өй җәмәгате, семья. Көнбатыш телләрендә: *фамилия.*

*Гаилә – иҗтимагый хәятләрнең нигезе.*

Борынгы төркиләрдә гаилә төзелеше турында тарихчы Газиз Гобәйдуллин түбәндәгеләрне яза.

"Тарих белә башлаган заманда борынгы төркиләрнең гаиләләрендә баш – ата иде. Һәрбер ир кеше күпме хатын ала алса, шул кадәрне аладыр иде. Борынгы төркиләр бер дә туктамыйча үзләренең күршеләре белән сугышып торалар; бу сугышлар сәбәпле ирләр кимиләр, хатыннар күбәяләр. Шуның өстенә дә тагы дошманнары белән сугышканда төркиләр ирләрне үтерсәләр дә, хатын-кызга тимиләр, үзләренә хатын итеп алып кайталар иде. Шул рәвешчә ирләрнең саннары кими, әмма хатыннарныкы исә алай түгел, бәлки сугышларда алынган әсирләр белән арта; шуның өстенә дә бөтен халыкларда булганы шикелле борынгы төркиләрдә дә хатыннар бер гаиләгә яки бер ыругка мәнсүб булмаса, яши алмый, аның мөдафәгачысы булмыйдыр иде. Бер гаиләгә мәнсүб булу исә бары бер кешегә иргә барганда гына мөмкин булган. Шуның өчен дә бер кеше агай-энесе үлгәч килен, яисә җиңгәләрен никях итү гадәте булган; моның белән хатыннар химая ителә, җәмгыять эченә керә торган булганнар.

Борынгы төркиләрдә вә монголларда да үзе белән бертуган булмаган кызларны никях итәргә яраган. Борынгы заманда әле хәзерге төсле хатын итмичә алып тәрбия итү гадәте юк, аны белмиләр. Егет кызны алганда ата-анасына күп кенә акча вә мал биреп аладыр иде.

Гаиләдә олы хатын баш исәпләнә; башка хатыннар шуңар буйсыналар иде. Борынгы төркиләрнең бөтен эшләре хатыннар кулында булган. Ирләр бөтен вакытларын сугышта, ауда, яисә сугыш һөнәренә өйрәнеп, ат чаптырып, ук атып өйрәнеп көннәрен үткәрәләр. Хатыннар өйдә калып бөтен эшне башкаралар: кием тегү, итек чигү, киез өйгә киез басу, куй кырку, тула сугу, кымыз ясау күк мөһим эшләр барысы алар кулында иде. Аларда хатын-кыз качмый, күп эштә сугышка да баралар; артта торып гаскәрләргә кирәк-яракны әзерлиләр."

// *Гаилә әркяны* – гаиләнең баш кешесе.

*Гаилә*нең күплек саны шәкеле – *гаваил.*

**ГАЙФУЛЛА** – Татарда исем булып йөри торган сүз. Гарәпчә *'Афвулла* сүзеннән килеп чыккан дип уйланыла (Алим Гафуров). Ә аны *"[чын] ярлыкау Аллаһтан гына килә"* мәгънәсендә дип аңлатырга мөмкин. ("Татар исемнәре сүзлеге"ндә аңа башка

аңлатма бирелгән — *"Алланың сәламәт кешесе"*?) Алим Гафуров фикеренчә, "Афиулла" сүзе, фонетик үзгәрешләр кичереп, татар теленә яраклашып, "Гайфулла" исеменә әйләнгән. Шулай да бу исемнең сирәк булганлыгын әйтергә кирәк (Безнең сүзлегебездә ул бер-ике тапкыр гына очрый, "Татарский энциклопедический словарь"да — ике тапкыр). Хәзер инде ул фамилияләрдә генә сакланган.

"Татар исемнәре" сүзлеге"ндә тагы *Гайфетдин* исеме дә теркәлгән ("Диннең сәламәт кешесе"?). Бу исемдәге "гайф" өлешен дә, югарыда әйтелгәннәргә нигезләнеп, "ярлыкау" мәгънәсендә дип аңлату акылга муафыйк.

***ГАКЫЙК*** *г.* —Гакык ташы. "Гарәпчә — татарча — русча алынмалар сүзлеге"ндә *ахак ташы* дип бирелә, русчасы — *сердолик (акик)*. Кварцтай каты, якуттай кызыл, яхшы эшкәртелә. Аңардан йөзек, беләзек, муенсалар һәм мөһерләр ясыйлар. Ныклабрак тикшерсәң, татар телендәге ахак атамасының русча агатка, гарәпчә йашмунга туры килүе ачыклана. Шуңа күрә гарәпчә гакыйкны "Кыйсса-и Йосыф"та да теркәлгән гакык сүзе белән бирү акылга муафыйк (татар галиме һәм язучысы С.Ф.Әхмәтов фикере). Стәрлетамак сөйләшендә — *акык, акыкай.* // *Дөрлү-дөрлү дерәкләр анда диксүн, Бер нәчә дерәкләри инжү улсун, Бер нәчә дерәкләри гакык улсун, Бер нәчәсе кызыл мәрҗән улсун имди.* Кол Гали. *Гакыйклар салдым — батмады, Мәрҗән-мәнүвәр салдым — калыкмады.* Халык җырыннан (башка варианты: *"Акыкайлар салдым — акмады, Ак мамыклар салдым — акмады"*).

***ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ*** *г.* — Аңа сәлам (иминлек, исәнлек, сәлам) булсын. // *Адәм галәйһиссәлам.* Кыскартып: *(г-м)* яки *(г.с.м.).* "Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе"нең соңгы басмасында бу сүз, кыскартып, *гамь* рәвешендә бирелгән. Гадәттә пәйгамбәрләр исеме белән янәшә килә, ләкин дүрт олуг фәрештәне Исрафил галәйһиссәлам, Микяил галәйһиссәлам, Җәбраил галәйһиссәлам, Газраил галәйһиссәлам дип атау кабул ителгән. *Салләллаһу галәйһи вәссәлам* (*с.г.в.*) һәм *салләллаһу галәйһиссаләтү вәссәлам* (*с.г.с.в.*) — болары Мөхәммәд Пәйгамбәргә карата әйтелә.

Татар сөйләмендә *галиәссәлам* рәвешендә дә әйтәләр.

***ГАЛӘМ*** *г.* I — **1.** Бөтен дөнья, җиһан, космос, универсум. Бүгенге фән күзлегеннән караганда, галәмнәр саны чиксез күп. Галәмнәрнең күплеге турында Коръән-кәримнең иң беренче сүрәсендә икенче (мәгънәви яктан беренче) аятендә үк ачык әйтелә: "Чын мактау галәмнәрне, бөтен мәхлүкләрне тәрбияләүче Аллаһу Тәгаләгә тиешле. "Комлык" сүрәсенең 3 нче аятендә: "Без күкләрне вә җирне һәм алар арасында булган бөтен нәрсәне хакыйкатькә туры китереп һәм билгеле бер вакытка дип төзедек," — диелә. Моннан Галәмнең башы булган һәм ахыры булачак дигән нәтиҗә чыга. "Ногмани тәфсире"ндә аларның "кыяматкә чаклы төзелгәнлеге" әйтелә, әмма Коръәннең үзендә мөддәт ачыклап күрсәтелмәгән. **2.** Халык; аерым бер төркем. // *Католик галәме* — католиклар дөньясы. *Галәм агачы* — тормыш агачы, нәсел шәҗәрәсе.

Текстларда еш кына күплек саны шәкелендә очрый: *галәмин* — галәмнәр.

***ГАЛӘМ-И ӘКБӘР*** *г.* — Макрокосм. Суфичылыкта — Аллаһы.

***ГАЛӘМ-И ӘСГАР*** *г.* — Микрокосм. Суфичылыкта — камил инсан, *инсан-и камил.* Камил инсанда Аллаһының исеме, сыйфатлары һәм фигыльләре төгәл чагылыш тапкан була.

***ГАЛӘМ-И СӨФЛИ*** *г.* — Түбәнге дөнья, фани дөнья.

*Мөнирә Булатовага 90 яшь*

# СӘХНӘ БӘХЕТЕ

Мөнирә ханым Булатова белән мин беренче тапкыр, әлбәттә, аның җырлары язылган пластинкалар аша таныштым. Һәм, ни гаҗәп, аның үзе белән шәхсән очрашкач, опера сәхнәсенең йолдызы булган көяз бер ханымны түгел, кечерәк кенә буйлы, җинел хәрәкәтле, тыйнак-гади генә бер хатын-кыз затын күреп хәйран калдым,—гәрчә ул үзен бик тә зыялыларча, ачык күнелле итеп тотса да.

Аннары Мөнирә ханым Булатова белән очрашулар (кеше буларак та, иҗат әһеле буларак та) гел янадан-яна ачышлар, яна тәэссоратлардан тора. Шундый очрашуларыбызның берсендә булып узган бер хәл аның гомер китабының кабатланмас тагын бер битен ачарга ярдәм итте.

...Көннәрдән бер көнне Мөнирә ханым күпчелек авторларның үз куллары белән язып бирелгән китапларны һәм документларны карап утырганда, шул әдәбият арасыннан бик матур итеп бизәлгән Коръән нөсхәсен тартып чыгарды һәм минем уемнан ул бу китапны гомерендә бер мәртәбә дә тотып карамагандыр дигән шөбһәле бер фикер йөгереп узды. Ләкин, гаҗәпләнүемә каршы, Мөнирә ханым китапны гадәтләнгән хәрәкәт белән ачты да Коръәннең беренче сүрәсе булган "Фатиха"ны укып җибәрде: "Мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән *(башлыймын)*. Бөтен галәмнәрнең *(халыкларның)* тәрбиячесе Раббы Аллаһка рәхмәтләр язсын!" Юк, мине аның гарәп графикасын белүе түгел (аның яшендәге кешеләр әле хәзер дә кирәк чагында гарәп китапларын "теттереп" укыйлар, ләбаса), ә бәлки матур итеп сузып-сузып, аерым бер гүзәл мәкам белән укуы гаҗәпсендерде. "Фатиха" сүрәсен укып бетергәч, ул "Ясин" сүрәсенә күчте: "Хикмәт тулы Коръән белән ант итәмен ки, *(ий, Мөхәммәд)* син, һич шөбһәсез, Пәйгамбәрләрнең берсе булдың. Син тугры юлдан барасың". Ничек шулай оста итеп Коръән сүрәләрен укуы мәсьәләсенә күчкәч, Мөнирә ханым балалык-яшьлек елларын хәтеренә төшерде.

...Архангельск шәһәре. 1912 елда бирегә Закир Бикбулатов* Вятка якларыннан хатыны белән олы кызы Мәрьямне алып килә. Шушы ук елны Суфия исемле кыз дөньяга килә. 1914 елның 19 маенда исә нәниМөнирә дөньяга аваз сала.

Озакламый Бикбулатовлар гаиләсе туган якларына әйләнеп кайта. Шул еллардан кечкенә Мөнирәнең бер матур хатирәсе сакланып кала. Казаннан 60-70 чакрымнар ерактагы Кармыш** авылы. Олылар урак уралар. Дүрт яшьлек Мөнирә арбага менеп чүмәшкән дә "моңлы" җыр суза:

*Каракүл бүрек бетә, диләр,*
*Алып калырга кирәк;*
*Ахыр заман җитә, диләр,*
*Җырлап калырга кирәк.*

Крәстиән гаиләсеннән чыккан Закир Бикбулатов баштарак магазинда приказчик була, аннары күн заводында эшләп ала, ләкин кешеләр арасында барыннан да

* Мөнирә ханымның чын фамилиясе Бикбулатова булып, Казанда укыган елларында ул "Булатова"га әверелә.

** Рәсми документларда бу авыл Чувашия АССРның Козловск районына кергән "Янгильдино" авылы дип теркәлгән.

бигрәк матур итеп халык көйләрен җырлаучы җырчы, оста гармунчы, хәтта драма түгәрәкләрендә уйнаучы һәвәскәр артист буларак танылa.

1925 елда әтиләренен үлеп китүе Мөниpәләр гаиләсенә авыр кайгы булып ябырыла. Шушы көннән башлап биш балалы гаиләне тартып бару 39 яшьлек Шәфикамал апа җилкәсенә төшә. Шәфикамал ханым көчле рухлы шәхес була (бу сыйфаты аның балаларына да күчә). Мөнирә Булатованың автобиографисеннән берничә юл китереп үтү дә бу хакта күп нәрсә сөйли:

"...1927 елда әнием Чувашия АССРның эшче, крәстиән һәм кызыл армия депутатлары әгъзаларыннан сайланган хатын-кызларның I республика съездына хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән делегат итеп сайлана.

...1929 елда Янгильдино авылында оешкан К. Маркс исемендәге колхозның беренче рәисе итеп сайлана. Соңрак балалар яслесе белән җитәкчелек итә".

—Кечкенә вакытымда мин бөтерчек кебек идем,—дип искә ала Мөнирә ханым.—Җырлый да идем, бии дә идем, кыскасы, бернидән дә тартынып тормый идем.



*Архангельскида мәктәптә укыган вакытта. Сулдан икенче—Мөнирә Булатова. 1925 ел.*

1926 елда Кармыш авылына Казанда татар балалары өчен интернат ачылган икән дигән шатлыклы хәбәр килеп ирешә. Балалар йорты Казансу елгасы буена, Хәзерге "Казан" шифаханәсе тирәләрендә, кыскасы, бик матур урынга урнашкан була. Анда барлыгы 600 дән артык бала тәрбияләнә. Һәм Мөнирә шушы балалар йортында уйный-көлә, укый-җырлый, бер сүз белән әйткәндә, бәхетле гомер кичерә.

Тормышта шулай килеп чыга ки, Казанга күченеп килгәч ул алты ел дәвамында, ягъни 1930 елдан башлап, производствода эшләп ала: баштарак Вахитов исемендәге комбинатта кара эшче, цех мастеры булып эшли, соңрак киез ката басу фабрикасына химик-лаборант булып күчә.

Комбинатта эшләгән елларында ул гомерен музыка сәнгатенә багышларга карар кыла.

1934 елда Шәрекъ музыка техникумында чын-чынлап музыка белән шөгыльләнә башлый. Бу уку йорты хәзергеләренә бөтенләй охшамаган була. Яңалыкка, ачышка омтылу, педагогларның бетмәс-төкәнмәс энтузиазмы (аларның күбесе Мәскәү консерваториясен тәмамлаган югары белемле музыкантлар булалар) техникумда шундый иҗади атмосфера тудыра ки, аны хәзер штампка әйләнгән "укыту процессы" дигән күңелсез бер нәрсә белән чагыштырасы да килми.

Мөнирә Булатова Музыка техникумында 1934 елның башыннан алып 1936 елга кадәр танылган рус шагыйре А. Н. Апухтинның хатыны, соңрак Мәскәүнең Гнесинглар исемендәге музыка училищесы педагогы Ксения Александровна Апухтина классында белем ала. Булачак җырчының аннан соңгы сәнгати осталыгын арттыруы Мәскәү шәһәре белән бәйле. Бу хакта Мөнирә ханым болай дип искә ала:

—1936 елда техникумда ачылачак татар опера студисенә сәләтле укучыларны сайлап алу өчен Мәскәү консерваториясе профессоры Назарий Григорьевич Райский җитәкчелегендәге комиссия килеп төште. Безне класста да, концерт залларында чыгышлар ясаган вакытта да сынап-тыңлап карадылар. Әле дә хәтеремдә, концертларның берсеннән соң, дәресрәге К.А. Апухтина һәм Е.Г. Ковольковалар үткәргән дәрес кичәсе тәмамлангач, Мансур Мозаффаров мине кемгәдер тәкъдим итеп (ул вакытта Мансур да техникум укучысы иде): "Беләсезме, киләчәктә ул

безнең үз йолдызыбыз булып кабыначак!"—дигән иде. Ул чакта мин әлеге сүзләрне көлүнең бер төре дип кабул итеп, бик кайгырып йөргән идем. Һәм мин шуңа да кайсыдыр бер студентның: "Сиңа—барырга!" дигән сүзләреннән соң башым күкләргә тиеп шатландым дип тә әйтә алмыйм. Житмәсә, бу хәбәрне ишетүгә әнкәй дә хафага төште: шулай булмыйни, мин бит тулы бер 95 сум хезмәт хакы алып эшли башлаган идем, бу безнең гаилә өчен бик аз акча түгел иде.

Мин боларның барысын да түкми-чәчми Ксения Александровнага сөйләп бирдем, ә ул шунда ук әнкәй янына килеп болай диде:

—Бу моңарчы күрелмәгән хәл, мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярыймы соң! Яхшы артистка булу өчен Мөнирәнең барлык сәләте житәрлек.

Һәм сүзләренә дәлил буларак, Н.Г. Райскийның: "Булатова бәрхет төсле гажәеп тавышка ия!",—дигән сүзләрен дә мисалга китерде.

Әлбәттә, Ксения Александровнаның дәлилләре безне яртылаш ышандырды һәм мин ярты елга укырга барырга, әгәр берни дә барып чыкмаса кире әйләнеп кайтырга ризалаштым. Житмәсә, комбинатта кабаттан эшкә алырга сүз биргәннәр иде.

Вакыт күрсәткәнчә, Мөнирә ханымның хафаланулары юкка булып чыга һәм аның тормышында "Мәскәү чоры" башлана.

...Әле күптән түгел генә үзешчән сәнгатьтә катнашып, музыка дөньясына кыюсыз гына атлап керергә хәзерләнгән жырчы каршында иксез-чиксез киңлек ачыла. Усман Әлмиев, Фәхри Насретдинов, Сара Садыйкова, Асия Измайлова кебек башка бик күп студентлар, Муса Жәлил, Гадел Кутуй кебек танылган шагыйрьләр белән аралашып яшәү аның фикерләү офык тарафларын киңәйтеп жибәрә. Зур театрның опера спектакльләреннән алган хис-кичерешләр, Н.А. Обухова, А.В. Нежданова, М. Андерсен, О. Клемперер кебек мәшһүр жырчыларнең чыгышларыннан сихерләнүләр аның нечкә тоемлы сизгер күнелендә мәңге дә онытылмаслык тойгылар уяталар.



*Мәскәүнең Союзлар йортындагы Октябрь залында. 1957 ел.*

Татар жырчыларының һәм композиторларының профессиональ осталыгын арттыру мәктәбе һәм татар культурасында яңа жанр-опера сәнгате жанрын булдыруда жирлек ролен үтәячәк Студия, әлбәттә, үз миссиясен уңышлы башкара. Житмәсә, бу чорда С. Габәши, В. Виноградов һәм Г. Әлмөхәммәтовлар ижат иткән "Сания" һәм "Эшче" әсәрләре яңа сәнгать тудыру чорында үрнәк булып торалар. Ләкин Студия ачылу анда белем алучылар өчен дә, гомумән, тулаем татар музыкаль сәнгате өчен дә әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия була. Яшь музыкантларны, әдипләрне һәм театр әһелләрен берләштергән даирәдә татар зыялыларының яңа буыны үсеп чыга, шул рәвешле яңа эстетик идеаллар, яңача сәнгати фикер йөртү алымы формалаша.

Студиядә белем алучылар Мәскәүнең бик күп сәхнәләрендә, шул исәптән иң зур концерт заллары сәхнәләрендә чыгышлар ясыйлар, кичәләр оештыралар. Нәкъ менә шушы елларда Мөнирә ханымның Мәскәү консерваториясе профессоры Мария Владимировна Владимирова белән озакка сузылган дуслыгы башлана. Танылган рус опера жырчысы игътибарын яңа студентка кайсы ягы белән жәлеп итә соң? Көчле, үзенең яңгыраш тембры белән уникаль саналган тавышы беләнме? Әллә юкса ижади эзләнүләре, зур тырышлыгы беләнме? Ни булса да булгандыр, шул вакыттан башлап Мөнирә ханым өчен Мария Владимировна иң якын укытучыларыннан берсе булып китә.

Мәскәүдән әйләнеп кайткан югары хәзерлекле студентлар, сугыш башланырга калган аз гына вакыт эчендә дә, зур эшләр башкарырга өлгерәләр. Менә, ниһаять, 1939 елның 17 июнендә Нәжип Жиһановның "Качкын" операсы белән (либреттосын

Ә. Фәйзи яза) Татар опера театры ачыла. Башкаручылар арасында 25 яшьлек Мөнирә Булатова да була. Әйе, нәкъ менә "Качкын" операсыннан Мөнирә Булатованың татар сәнгатендәге олы һәм мактаулы хезмәт юлы башлана. Әйтергә кирәк, бу сәнгать әле ул чорда оешып кына килә һәм башкаручылар, композиторлар, либретто иҗат итүчеләр, режиссерлар белән берлектә соавтор буларак та чыгыш ясыйлар. Бүген сугышка хәтле һәм сугыштан соң куелган спектакльләрне М. Рахманкулова, Т. Кайбицкая, С. Садыйкова, А. Измайлова, Ф. Насретдинов, К. Зәбировлар катнашыннан башка күз алдына китерүе дә кыен.

Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил белән берлектә иҗат иткән "Алтынчәч" операсы татар опера сәнгатенең чын мәгънәсендә беренче зур уңышы була. Тугзак исә—беренче һәм иң көчле милли каһарманнарның берсенә әверелә. Башкаручыларга аеруча игътибарлы караштa торган композитор Нәҗип Җиһанов бу образын беренче булып башкарган Мәрьям Рахманкулова турында бик җылы сүзләр әйтеп калдыра. Композиторның соңрак, шактый еллар узгач Мөнирә Булатовага операның клавирына язып биргән соклану сүзләре бу иҗатта аеруча истәлекле:

*"Кадерле Мөнирә,*

*Сине туган көнең белән котлыйм! Синең тууың бик вакытлы булган. Үзең уйлап кара, әгәр син үз вакытында булмасаң Тугзак партиясен кем башкарыр иде. Син бу партияне шундый итеп башкарасың ки, музыкантлар әйтмешли: "Ходай биргән дә инде!" Шуңа күрә сиңа бик рәхәтләнеп "Алтынчәч"нең клавирын бүләк итәм.*

*Автор. Казан, 19 май 1963 ел".*

Бу образ турында сүз алып барганда, Мөнирә ханым Булатова дулкынланып болай дип сөйләде.

—"Алтынчәч" тә Пролог бик көчле язылган. Биредә бик тирән кичерешләр чагылыш таба—халык бәйрәм итә, һәркайда гомуми тантана һәм кинәттән трагедия—Хан яу йөри. Безнең барлык ирләрне дә кырып бетерәләр, ә мине—җәзага тарталар: күзләремне чокып чыгаралар, йөри алмасын өчен табанымны яралар. Миңа нибары 40 яшьләр чамасы (тугыз бала анасы булсам да, ул чакта кияүгә бик иртә, 13-14 яшьләр чамасында биргәннәр ләбаса), ләкин мин нинди кыяфәттә булырга тиешлемен соң, күзләрем агып чыккан, бу тетрәнүләрдән соң чәчләремнең яртысы агарган. Минем ыруымның хатын-кыз затлары, минем килен-киленчәкләрем, кара төрбәгә төренгәннәр, алар бертуктаусыз "аһ" ора. Бер-ике сүз әйтүдән соң җан ачуым белән илереп кычкырып җибәрәм:

*Күзләремне чокып алсаң да,*
*Табан асларымны ярсаң да,*
*Ил күзеннән кача алмассың,*
*Ялчы торыңымны табармын,*
*Үстерермен, карармын.*
*Аждаһаның башын өзәр ул,*
*Явыз ханның нәселен ул өзәр!*

Ә инде III пәрдәдә (күп еллар ил гизеп йөргәннән соң) ерактан гашыйк Җикнең тавышын ишетәм һәм мин күңелем белән аның үземнең оныгым икәнлеген төшенеп алам. Һәм мин аңа ташланам да... муенына үзем таккан бөтине капшап, аны танып алам.

Бу инде хакыйкатьнең тантанасы иде. Димәк, яшәү дәвам итәр!.."

"Алтынчәч" операсын әле 70 елларда да Мөнирә Булатова катнашында күрергә була. Шулай да опера 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә аеруча зур уңыш казана. Бу операга багышлап бик күп газеталар тантаналы мәкаләләр бастырып чыгаралар. "Тугзак образына халыкның какшамас ныклыгы һәм батырлыгы, аның азатлыгы һәм гаделлеккә омтылышы тупланган. Тугзак образын сәхнәдә ТАССРның халык артисткасы М. Булатова калку итеп чагылдыра. Аның башкаруында көч вә омтылыш, ихтыяр көче вә ачу, рухи матурлык, туган халкынны ярату дөрес яктыртыла",—дип яза "Известия" газетасында (1957, 25 май) Владимир Фере.

Мөнирә Булатованың опера репертуары акрынлап үзгәрә. Әмма опера жанрына карата "амплуа" сүзен куллану бик үк дөреслеккә дә туры килеп бетмәс иде кебек. Тавышнын теститурасына һәм шулай ук театрның репертуарына бәйле рәвештә артистканың артык сайланырга мөмкинлеге бармы соң? Юк, әлбәттә! Шулай булуга карамастан, партияләрне башкаргандагы тональлек, теге яки бу рольгә карата башкаручы тарафыннан куелган шәхси акцентлар иҗади "алым" турында сөйләргә мөмкинлек бирә һәм болар, үз чиратында, амплуаны билгелиләр дә инде.

Мөнирә Булатовага килгәндә, аның игътибарын көчле рухлы, бәйсез характерлы, горур хатын-кыз образлары җәлеп итүен әйтми мөмкин түгел. Менә дигән җырчы, ике дистә елга якын Мөнирә Булатова белән бергә эшләгән Гөлшат Сәйфуллинаның әйтүенә караганда, опера җырчысы буларак аның амплуасын драматик, трагик һәм героик пландагы зур күләмле партияләр тәшкил итә. Төрледән төрле булсалар да, Мөнирә Булатова башкарган партияләрнең "үзәген" көчле, ирек сөючән, хакими тәкъдирле характерлар алыр тора. Инде телгә алып үткән Тугзактан тыш Римский-Корсаковның "Патша кәләше"ндә Любаша, Мусоргскийның "Борис Годунов"ында Марина Мнишек, Бородинның "Князь Игоре"ндә Кончаковна әнә шундыйлардан. Һәм, билгеле ки, бу уңайдан Бизеның җырчы репертуарына опера театрында эшли башлаганнан бирле килеп кергән "Кармен"ын да онытырга ярамый. Бизеның Кармены ничегрәк булган соң? Бу хакта Казанда, Бакуда, Ташкентта, Дүшәмбедә, Алма-Атада, Самарада һәм башка шәһәрләрдә барган спектакльләр вакытында төшерелгән тәэссоратлы фотолар буенча да хөкем йөртергә мөмкин. Ләкин болардан бигрәк җырчының бу рольгә хәзерләнгән вакытында алып барган көндәлекләреннән китерелгән, һәм төрледән-төрле цитаталар бу рольне башкаручы бөек җырчыларның сөземтә характерындагы бәяләмәләре күп нәрсә турында сөйлиләр булса кирәк.

Карменны бер читкә куеп торам да, Мөнирә ханымның көндәлек дәфтәренә күз салам һәм аннан Л. Н. Толстойның: "Цель художника не в том, чтобы необходимо разрешить вопросы, а в том, чтобы заставить любить жизнь в бесчисленных, никогда не истощимых проявлениях". Бу сүзләрен укып чыккач, Мөнирә ханым болай дип җавап биргән иде:

—Мин беләм, кайчакта кешеләр мине ниндидер көрәшче, бик тә актив җанлы кеше итеп күз алдына китерәләр. Әйе, мине андый характерлар кызыксындыралар. Театр сәхнәсендә, әлбәттә. Ләкин үземә карата мин алай дип әйтә алмыйм.

...Минем, дөрес, сәхнәдә бик бәхетле минутлар кичергәнем булды. Ләкин канәгатьсезлек хисе дә миңа чит-ят түгел. Кайчагында уңышсыз концертлар да җырчыга күп нәрсә бирә. Мондый минутларда җаныңны кая куярга белмисең, мин моңа нигә тотындым әле дип уйлыйсың. Ә бераздан анализ ясау һәм үз алдыңа сораулар кую вакыты килеп җитә: нишләргә, нәрсәне үзгәртергә? Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, кайчакта җавап бирәр әсәрне күп тапкырлар башкарганнан соң табыла...

Анлашылса кирәк, Мөнирә Булатова менә шул рәвешле бөтен сәхнә эшчәнлегендә инде гадәтләнеп беткән нәрсәләргә яңа баштан карап чыгу, үз-үзенә тәнкыйди күзлектән чыгып бәһа бирү белән шөгыльләнә. Шуна күрә дә күп еллар дәвамында ул башкарган партияләр торган саен үзләренчә "кызыклы" булалар.

Шулай килеп чыга ки, Мөнирә Булатовага үз гомерендә Чайковскийның "Пики дама"сында өч партияне—Полина, Милозора һәм Графиня партияләрен башкарырга туры килә.

Баштагы ике партияне Мөнирә Булатова Мәскәүнең Зур театрында башкара. (Л. В. Баратов тарафыннан куелган спектакльдә А. Ш. Мелик-Пашаев дирижерлык итә, Герман партиясен Г. Нэлепп, Лиза партиясен Е. Смоленская башкара.) Татар җырчысының Мәскәүдә стажировка үткән вакытында Зур театр сәхнәсенә күтәрелүе бөтен музыкаль җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә була. Әйтик, "Вечерная Москва" газетасының бер санында (1950, 12 март) басылып чыккан мәкалә "М. Булатованың дебюты. Татар җырчысы Зур театр сәхнәсендә" дип атала һәм җырчының "Зур башкару осталыгына ия булуы һәм зур мәктәп узуы" билгеләп үтелә.

Шулай да Чайковскийның Графиня партиясе Мөнирә Булатова өчен бүген дә, озак еллар үткәннән соң да, ин кадерле образларның берсе булып санала. Бу образның тамашачыларга тәэсир итү куәте шулкадәрле көчле була ки, V картинада колонналар артыннан Графиняның шәүләсе күренгәч, залда кайбер очракларда һушы китеп егылучылар да булгалаган.

—1989 елда үзенең юбилей кичәсендә ул мине тагын бер кат таң калдырды,— дип искә ала Гөлшат Сәйфуллина.—Программаның беренче бүлеге романслардан тора иде, икенче бүлеге "Пики дама"сының IV картинасыннан төзелгән иде. Операдан тулы бер күренешне җырлау үзе үк бик зур көч куюны таләп итә, җитмәсә шушы яшьтә. Моның өчен бик зур батырлык һәм... Булатова характеры кирәк. Аны тыңлаганда тамашачылар урыннарында селкенергә дә куркып утырдылар—чөнки аларны образның тәэсир көче шулкадәр биләп алган иде.

...Бик күп танылган композиторның, язучыларның, шагыйрьләрнең замандашы булган Мөнирә ханым Булатова һәрвакыт игътибар үзәгендә була (аның архивында Ә. Ерикәй, С. Хәким, Б. Урманче, Н. Нәҗми, Р. Яхин, М. Садри һәм башка әдәбият-сәнгать әһелләре язган күпсанлы хатлар саклана). Аның тавышына исәпләп композиторлар романслар язалар, хат аша иҗат турында фикерләр алышып торалар. Бу җәһәттән Нәҗип Җиһановның Мөнирә ханым архивында сакланган көндәлек тормышын чагылдырган бер язу кисәге игътибарга лаек. Хәзер нәкъ Мөнирә Булатова башкаруында олы сәхнәгә күтәрелгән "Сиреньнәр хуш исләр тарата" романсының автор текстына Нәҗип Җиһанов болай дип язып куйган: *"Мөнирә ханым! Бу пустякны минем иҗат кичәсендә җырласаң бигрәк яхшы булыр иде. 1956. 21/V – Нәҗип"*. Менә шулай Мөнирә Булатова җан өргән "пустяк" ярты гасыр инде төрле буын артистлары тарафыннан башкарылып сәхнәдән төшми янгырый.

Әйе, Мөнирә Булатова бик күп композиторлар белән иҗади дуслыкта яшәде һәм уннарча, йөзләрчә әсәрләргә яшәү бирде.

Менә шулай Мөнирә Булатова бик күп композиторлар белән – М. Мозаффаров яки Ж. Фәйзиме ул, З. Хәбибуллин яки Н. Җиһановмы, Х. Вәлиуллин яки А. Ключаревмы—төрледән-төрле концертларда һәм композиторлар союзында үткәрелгән тыңлап карауларда бергәләп чыгышлар ясый. Импровизация сүзен ычкындыруым була, Мөнирә ханым кинәттән кабынып китә:



*Н. Җиһановның "Алтынчәч" операсыннан бер күренеш. Түгзак—Мөнирә Булатова, Каракаш—Зөләйха Хисмәтуллина. 1957 ел.*

—Импровизациягә килгәндә, Ключаревка тиңнәр юк иде. Ләкин аның импровизаторлыгында композиторлык иштүе дә чалынмый калмый иде. Ул татар халык көйләрен дә зур осталык белән башкара иде.

Мөнирә ханым А. Ключарев тарафыннан бүләк ителгән "Туган җирем—Татарстан" (Г. Зәйнашева сүзләре) җырының кульязмасын аеруча пөхтәләп саклый. Татар радиосын озак еллар тыңлаган кешеләр хәтерли булыр, радиоэфир көн саен диярлек шушы җырның мелодиясе белән ачыла иде һәм ул республика символы буларак, күңелләргә газиз бер хис булып кереп урнашты. Мөнирә Булатованың шәхси китапханәсендә җыр авторларының берсе тарафыннан язып бирелгән китап саклана, анда мондый юллар бар: *"Туган җирем—Татарстан" җырын оста башкаруыгыз, халык күңеленә җиткерүегез өчен зур рәхмәт! Сез—халкыбызның күренекле җырчысы, озак яшәгез һәм бәхетле яшәгез! Сезне яратучы Гөлшат Зәйнашева. 24. X. 1977."*

Сүз дә юк, камера җырчысының хезмәте—үзенчәлекле хезмәт. Биредә театрдагы кебек тамашачыны җәлеп итә торган сюжет киеренкелеге, геройларның үзара мөнәсәбәтен чагылдыручы коллизияләр юк. Иң истә калырлык чыгышлар турында сүз башландымы, Мөнирә ханым соло рәвешендә башкарылган концертларын искә ала.

Артистның тормышында күп төрле очрашулар булуга да карамастан, шулай да соңыннан иҗади тормышта аеруча тирән эз калдырганнары була. Билгеле, 1948 елда очрашкач инде танылган җырчы Мөнирә Булатова да, әле яшь композитор Рөстәм Яхин да, мөгаен, озак еллар дәвамында иҗатташ дуслар булып яшәрбез дип күз алдына да китереп карамаганнардыр. Мөнирә Булатова башкаруында Графиня

партиясен тыңлаганнан соң Рөстәм Яхин чын мәгънәсендә тирән тетрәнү кичерә. 1991 елның маенда очрашып сөйләшү вакытында Рөстәм ага бу хакта болай дип сөйләгән иде:

—Аның тавышының тембры мине шунда ук әсир итте—сирәк очрый торган бик тә чиста, күкрәк тавышы. Бу тембр инструменталь яңгырашка ия. Хәзер мондый тембрлы тавышлар юк... Мөнирә Булатованың икенче бер сыйфаты тагын шунда ук күзгә ташланды—ул да булса, профессиональ мәктәпкә ия булуы...

Бу беренче очрашудан алган тәэсирләр яшәү барышында, бергә эшләү дәверендә тагын да тирәнәя, киңәя төшә, чөнки Мөнирә Булатова йөзендә Рөстәм Яхин нечкә тоемлы, барыннан бигрәк композиторның рухи дөньясын аңлаган башкаручысын таба. Композитор белән җырчы арасында утыз елдан артыкка сузылган иҗади дуслык татар музыка культура өлкәсе тарихында сизелерлек эз калдыра. Мөнирә Булатова һәм Рөстәм Яхин концертлар белән бергәләп кайларда гына чыгыш ясамыйлар: алар Татарстанның барлык почмакларында диярлек, Мәскәүдә, Идел буе шәһәрләрендә, Ленинградта (Санкт-Петербургта), Урта Азиянең һәм Казакъстанның бик күп калаларында күпсанлы концертлар бирәләр. Мөнирә ханым турында Рөстәм Яхин ихлас күңелдән тагын менә ниләр сөйләде:

—Анда артистизм, аңларга әзер булу һәм әзер тору, яңа әсәрләргә җитди һәм тәнкыйди күзлектән карау хас булды. Ул бер вакытта да яңа романсларга ашыгып бәя бирмәде, аңа яңа әсәрнең "төенен табу" зарур иде.

Бәлки шунадыр да "Ни сөйли урман?" (С. Хәким сүзләре), "Дулкыннар" (Ә. Ерикәй сүзләре) кебек киң аһәңле, тирән амплитудалы җырлар нәкъ менә аның башкаруында популярлашып киттеләр. Ә "Күңелем өзгәләнгән минутларда" (Ә. Ерикәй сүзләре), "Күңелем синдә" әсәрләрен композитор Мөнирә Булатовага багышлап иҗат итә.

Моннан тыш С. Сәйдәшевнең "Сагыну", "Өмә җыры" һәм "Халисә", М. Мозаффаровның "Тын бакчада", "Җиләк җыйганда" әсәрләре дә татар музыкасы тарихына Мөнирә Булатова башкаруында алтын хәрефләр белән язылып калды. Һәм, мәгълүм ки, Мөнирә Булатова бик теләп, зур зәвык белән рус һәм Европа классикларының романсларын башкарды. Аның камера репертуарының байлыгын, башкару осталыгын аңлау өчен генә мисал китереп үтү дә җитәр кебек: Мәскәүнең олы һәм данлыклы сәхнәләрендә үткәрелгән җыелма концертларда мәшһүр артистлардан С. Козловский, А. Безродный, В. Пикайзен, Д. Ойстрах, Г. Уланова, М. Плисецкая, П. Лисициан, В. Дударова, Д. Осипова, Н. Шпиллер аның коллегалары булып тордылар.

Бер сүз белән әйткәндә, Мөнирә Булатова иҗаты чәчәк аткан дәвердә ил һәм дөньякүләм танылган артистка иде. Ил күләмендә һәм чит илләрдә ясаган чыгышлары моңа ачык дәлил булып тора.

Шөкер, Мөнирә Булатова бүген дә исән-сау, фикере-хәтере ачык, дәрт-дәрманы чиксез. Шушы көннәрдә Татарстанның халык, РСФСРның халык артисткасы Мөнирә Закир кызы Булатовага 90 яшь тулды. Саулык-сәламәтлек телибез аңа...

*(Язма Гүзәл Сәйфуллинаның "Счастье сцены"*
*китабы буенча хәзерләнде.)*

*Юмор һәм сатира*

# Фәнзаман Баттал

## Хыял кирәк

Ач кешегә хыял бик тә кирәк,
Ботка пешереп була хыялдан.
Тик өстәргә кирәк шул хыялга...
Ярма белән майны иң алдан.

## Булмады!..

“Әйбәт булыгыз, балалар,
Үсегез тәүфыйкъ җыеп.
Яшәгез бер-берегезне
Яман эшләрдән тыеп.”

Шулайлар диеп үстердем!..
Бирдем гел яхшы үгет.
Өметләндем: “Һәркайсы да
Булыр вәйт дигән егет!”

...Әй эчәләр, сугышалар,
Куналар айныткычта.
Эшләмиләр, урлашалар,
Талыйлар, җае чыкса.

Ысбулычлар, сабакылар!
Өметемне кистеләр.
Кеше итәргә тырыштым...
Үзем булып үстеләр...

## Ихлас ярату

И бәгырем, мине бик тә
Яратасың шикелле:
Убә-үбә назлаганда
Карашларың сөйкемле.

Армый-талмый сыпырасың,
Сыйпыйсың һәрбер төшне.
Ахры, җаным, миңа булган
Мәхәббәтең бик көчле.

Тик шулай да бер сүз әйтсәм,
Карамассыңмы кырын?
Ныграк назлыйсың кебек син
Акчалы кесәм турын.

## Ник бирмәсен?!

“Саран җыя, саран туплый
Акчаны да, малны да.
Ач нәфесе белми аның
Алны да һәм ялны да...”

Шулай диләр... “Бирмәс,—диләр,—
Бер тиенен, бер йонын”.
Ник бирмәсен?!
Әҗәл килгәч,
Биреп китә берьюлы!

## Бергә рәхәтрәк

Көянтәләп, ямансулап
Су ташыма, и егет!
Тукай абзыең әйтмешли,
Бер шәп кенә ат җигеп,

Ал да кайт бер чәчбикәне—
Һич яшәтмәс суларсыз.
Өйлән, давай! Бергә-бергә
Парлап ямансуларсыз.

## Җитә!

Әлдән-әле: "Синең фатир тар",—дисең,
"Башың иеп, зур түрәгә бар",—дисең...
—Өстәл сыя каләмемне салу өчен!
Ятак сыя хәләлемне салу өчен!
Ни кирәк тагын?!

## Сәбәп кирәк

Тәнкыйтьче дус болай диде
(Бик кайгырып, әлбәттә):
—Ни өчендер сатириклар
Сирәк туа, гадәттә...

Юаттым аны шунда ук:
—Бөтен хикмәт—сәбәптә!
Һич кайгырма, үрчи алар
Патша карак дәүләттә!

## Киңәш

Дошманнарың белән дуслашырга тырыш!
Бетә күрмәсеннәр искереп.
Иске дошман яхшы, яңаларын
Куу өчен эттәй өстереп.

## Ничек тә ярамый

Нишләтергә бу хатынны?..
Көн дә теңкәгә тия:
—Кияр киемем калмады,
Оят, хурлык!— дия-дия.

Алган идем былтыр гына
Затлы тун, асыл бүрек.
"Модасы чыкты",—диде дә,
Балконга куйды төреп.

Бер үзенә бер шифоньер—
Кырык күлмәк, биш итек...
—Кияр киемем калмады,
Үтерәсең өшетеп!

Алай-болай өшеп үлсә,
Мин нишләрмен бичара?..

Ике билет алып кайттым
Африкага очарга.

...Барып җиттек.
Дөнья—мунча,
Кайнап утыра күлләр.
Килсә-килде җанашыма
Җылынып яшәр көннәр!

Негрлар да шәрә монда,
Маймыллар да тирләгән...
Әйткән булам хатыныма:
"Калмасын без күрмәгән".

Ул һаман да риза түгел:
—Булмады минем бәхет!..
Салыр киемем калмады,
Үтерәсең, бәдбәхет!..

# Йолдыз

## Әбисез авыл

**Авыл—шул ук шикелле,**
**Ләкин шул ук түгел дә:**
**Урамына борылгач та**
**Сагыш тула күңелгә.**
**Ярлар да шул,**
**Таллар шул,**
**Хәтта шул ук каргалар.**
**Авылымны авыл иткән—**
**Бер карашка, бар да бар.**
**Ләкин көтми бу авылда**
**Әби, бәлеш пешереп.**
**Кайтыр оныкларым диеп**
**Безне искә төшереп.**
**Шалтыратмый телефоннан,**
**Язмый хәтта хатын да.**
**Бер ел инде гүрдә ята**
**Авылым зиратында.**
**Авылга кайтып барабыз,**
**Авыл шул да, түгел дә...**
**Урамына борылгач та**
**Күзләр яшькә күмелә.**
**Авыл шул ук, әмма хәзер**
**Ул бит әбисез авыл.**
**Әбисез авылга кайту—**
**Белсәгез, шундый авыр!**

## Алдау уены

**Алдау уены уйныйбыз,**
**Алдый белә һәммәбез.**
**Ялганлыйбыз—ышаналар,**
**Оста булгач хәйләбез.**
**Маратны да алдадык без:**
**—Әнә әтиең кайта!—**
**Сикереп торып чабып китте**
**Ул без күрсәткән якка.**
**Өметләнеп йөгерде ул**
**Әтисенең каршына.**
**Эх, сизмичә кагылганбыз**
**Йөрәге ярасына.**
**Маратның шул әтисе юк.**
**Киткән ташлап, калдырып,**
**Нәни улы йөрәгенә**
**Сагыш уты яндырып.**
**Инде кайтып килә Марат.**
**Адымнар салмак, сүлпән.**
**Ул бу юлы гафу итсә,**
**Алдамас идек бүтән.**
**Алданганнан көлә идек,**
**Ә Мараттан—көлмәдек.**
**Үксеп елый—ничек итеп**
**Юатырга белмәдек.**

## Юату

Тукталышта нәни көчек,
Ташлап калдырган кемдер...
Күзләре кара карлыган
Карыйлар мөлдер-мөлдер.
—Өебезгә алып кына
Кайтыр идем дә сине—
Әнием шул рөхсәт итми,
Ачулана ул мине.
Без үзебез дә торабыз
Әле тулай торакта.
Фатир алу чиратыбыз
Әле би-ик тә еракта.
Безнең бәләкәй бүлмәдә
Урын җитми беркемгә.
Алып кайтсам да үзеңне,
Тормас идең бер көн дә.
Менә яңа фатир алгач...
Бул азрак түземле...—
Шулай юаттым көчекне.
Кем юатыр үземне?

## Кыярлар ник саргайган?

Бигрәк тә эшле инде
Гаиләдә барчабыз да:
Вакыт таба алмыйбыз
Барырга бакчабызга.
Беркөн барып карасак
Бакчабызны, шаккаттык—
Бер кыяр түтәленнән
Өч чиләк кыяр таптык.
Ләкин—хикмәт, һәммәсе
Яшел түгел, сарылар.
Сары күзләрен багып,
Үпкә белән карыйлар.
Без югында үскәннәр,
Безне зарыгып көткәннәр,
Бигрәк каты көткәннәр,
Саргаешып беткәннәр.
Карадым кыярларга,
Бирелдем хыялларга...
Дәү әни искә төште:
Йөзе—шул кыяр төсле...

*Укучы сүзе*

* * *

Әле дә хәтердә, 1981 елда "Казан утлары" журналының тиражы 107 меңгә житкән иде. Ә инде 82 елны Мәскәүдә журналга язылып булмады. Мәскәү чиновниклары моны кәгазь житешмәү белән аңлаткан иделәр. Татар журналына кәгазь юк, тиражы артык үскән. Совет хөкүмәте өчен кирәкмәгән хәл булган икән бу. Ә без тырышып-тырмашып аның тиражын тагын да үстерергә йөрдек.

Шушы елдан соң журналның тиражы аска таба тәгәрәп китте, әле дә мактанырлык түгел.

Әле дә хәтерлим, күренекле язучы, инде мәрхүм Тәүфикъ Әйди татар матбагасы өчен гомер буе ут йотып яшәде. 1970—80 елларда барча татар төбәкләрен йөреп чыкты, татар мәктәпләренең ничек эшләвен тикшерде, матбугатка язылу барышын даими контроль астында тотарга тырышты. Кайчак ул морадына ирешә дә иде. Чөнки Татарстаннан тыш төбәкләрдә, татар язучысы дигән абруйлы исем ана булыша иде дисәм, бер дә артык булмас. Чөнки, урыннардагы житәкче кешеләр аңлый иделәр, язучы кешенең турыдан-туры халык белән аралашканын. Ул елларда язучының абруе шактый югары иде, алар татар милләтенең элитасы иделәр. Язучылар тел өчен җаваплылык сизеп яши, иҗат итә иделәр, алар ул елларны тел сакчылары хезмәтен башкаручылар булды. Ә хәзер эшләр алай түгел, язучының абруе төште, ул китабын чыгарыр өчен төрле ширкәтләр, байлар бусагаларын таптый башлады. Кайберәүләре шамакайланып, түрәгә, байларга яраклашып беттеләр, шулай яраклаша-яраклаша, гап-гади кешеләр рәтенә кереп бастылар. Язучы белән укучы арасындагы аерма юкка чыкты, һәр каләм тибрәткән адәм язучы булып китте. Билгеле, бу эшләр үз нәтиҗәләрен бирми калмады, бирде, язучы дигән тылсымлы исем девальвацияләнде, әдәби тәнкыйть бетте, сүз иреге бездә үле туды, шуна күрә дә ул юк бездә. Сүз дә юк, ирек тә юк. Әсәрләр күбрәк бер тема тирәсендә, мәхәббәтне тасвирлауга гына кайтып калды. Билгеле, мәхәббәтсез тормыш юк, яшәешнең күрке, күп мәсьәләләре чишәрдәй илаһи ул тойгы кешегә Аллаһы тарафыннан бирелгән, тик никтер шушы изге гамәл дәүләтебезне торгызу юлында бер дә файдаланылмый? Моны кем эшләргә тиеш? Аллаһы тарафыннан һәр кешегә һөнәр, сәләт бирелгән, аның вазифасы билгеләнгән, димәк язучының да үз һөнәре, үтәргә тиешле вазифасы бар.

Татар әдәбияты хәзер—милләтсез түрәләр әдәбияты, милләтсез эшкуарлар әдәбияты, чын милли әдәбият инде әллә кайчан үлгән икән, тик без шуны белми генә яшәгәнбез. Милли әдәбиятыбыз Тукай-Исхакыйлардан соң күп яши алмаган икән, тик бераз тыпырчынып караган ул Г. Ибраһимов—Һ. Такташлар заманасында, соңрак Ә. Еники—Н. Фәттах, Х. Туфан—Г. Афзаллар һ. б. заманында да өметләр булган кебек. Аларның сүзләренә колак салучылар да булган, түрәләр дә аларның сүзләренә игътибар итми булдыра алмаганнар. Ә хәзер нәрсә, нинди түрә язучының сүзен тыңлый? Ул язучылар белән очрашырга айлап-еллап вакыт табалмый, тапса да, язучыларыбызның әйтердәй сүзләре юк.

Әллә хакыйкатьне яратмый башлады язучы, тугры сүздән курка, кача. Бигрәк тә меркантиль булып бетте, аңа акча кирәк, фатир—дача—машина һәм тагы әллә ниләр кирәк булып чыкты. Ул язучы сәләтен акчага, әйбергә алмаштырды, шуңа күрә язучының сүзе үтмәс булды, чөнки ул товарга әверелде, аның хакы, бәясе булдырылды, ул прилавкадагы товарга кайтып калды. Билгеле, сатуда иң кыйммәтле товар гына зур хакка ия була. Сүз белән дә шундый ук хәл, сүзенә карап, кешесенә карап, кем әйткән, хак, тугры кеше әйткәнме, сүз белән мавыгып кына әйтелмәгәнме? Менә, әйтик, Г. Тукай яки Г. Исхаки сүзләре булса, алар сүзе игътибарсыз калмас иде. Юкка гына талантлы кеше туры сүзле була дип әйтмиләр. Андый кеше әлбәттә Түрә кешесе түгел, Алла, милләт кешесе генә була ала, чөнки түрәләрне төзәтердәй сүзне теләсә кем әйтә алмый. Татар әдәбияты бай, әмма, бүгенге көндә туры сүзле язучыларга сай әдәбият, шуңа күрә әдәбиятыбыз да матбагабыз да елдан-ел, айдан-ай укучыларын югалта бара, милләт татарча укудан туктый.

Язучыларыбыз, милләт татарча укымый дип, әсәрләрен ашыга-ашыга урысчага тәржемә итәләр, кайберәүләре бөтенләй дә урыс телендә яза башлады. Билгеле, укучы язучыга иярми, киресенчә, язучы укучыга ияреп яза башлады, белмим,

мондый әдәбиятның киләчәге бармы? Элегрәк, язучы укучыга тормышка яраклы үрнәкләр күрсәтсә, ә хәзер ул шушы укучыларны кабатлый. Кемгә кирәк мондый әдәбият?

Әдбәттә, язучыны да аңларга кирәк, ул нинди шартларда, нинди акчага яши соң, аның башка һөнәре юк бит? Каләм хакын бирәү дә түләмәсә, китабын сатып алмасалар, ничек көн күрсен ул? Арлы-бирле чабулаган язучыны гаиләсе ихтирам итәрме, милләт аның хәлен төшенерме? Менә бит тагын чишелмәслек проблема, акча мәсьәләсе килеп баса.

Хәерче милләттә—хәерче әдәбият, бөтенесе дә дөрес. Димәк милләтне баетырга кирәк, анда байлык булса, ул китап алмый калмас!? Әгәр, әйтик, ул баеса, әдәбиятны үстерергә булышырмы, әллә Багам утрауларында, Әдрән диңгезе ярларында дөньяның "артына тибеп" яшәрме? Булган малны әле дөрес туздыра белү дә кирәк бит.

Әнә, Төрекмәнбашы "мин төрекмән халкын тиз арада бай итә алам, әмма тиз баеган кеше ул байлыкның кадерен белмәс дип куркам" (Рухнамә), дип шиген белдерә. Татарда да байлар юк түгел, бик кысынкы шартлар белән чикләнгән булса да, дәүләтчелегебез бар, тик алар байлыкларын әдәбиятыбызны үстерүгә туздырмыйлар. Ә байлык бит Аллаһы тарафыннан аңа бер үзенә генә бирелми, аны милләт байлыгы  итеп кабул итәргә кирәк иде. Әлбәттә, бай кеше башта үзен, гаиләсен, аннан милләтен кайгыртырга тиешле, бу аңа йөкләтелгән вазифа. Шуны аңлап яшиме безнең байлар, түрәләр?

Менә яһүдиләр төрле илләрдә  төрле-төрле хәйрия фондлары оештырганнар, һәр елны шушы фондлар лауреатларны игълан итә. Лауреат исемен алган язучыга мул итеп акча бирә, китапларын зур тираж белән чыгара, шуннан соң, ул инде мөстәкыйль язучы булып яши, матди мәсьәлә аны бүтән борчымый, ул ирекле рәвештә иҗат эшен дәвам итә.

Яһүдиләр булдырган бит, ник без татарга да шул юнәлештә эзләнмәскә, милли әдәбиятыбызны үстерү өчен бирәр шундый фонд төземәскә? Тырышкан табар дип, сөйләргә яратабыз, ә эшкә килгәндә беребез дә алынмый. Нәрсә безгә комачаулый, белем житешмәүме, әллә бер-беребезгә ышанмаумы? Җыелган акчаны җыештыручы үзенә тотар дип куркабызмы? Бәлки артык вакланмаска өйрәнергә иде безгә, карыйсың, эш тә алга китәр иде. Тәвәккәллек җитми ахрысы. Татар әдәбияты татар милләте өчен генә кирәк. Шуны һичкайчан истән чыгармаска иде.

Укучы татар китабында үзенә кирәкле, үзен борчыган сорауларга җавап табалмагач, чит-ят әдәбиятка күчте. Әлбәттә, анда инде татар исе юк. Язучы бит ул, милләт тәрбиячесе санала, ә мал, абруй, дәрәҗә өчен, теләсә нәрсә язарга торган язучы, ничек инде милләт тәрбиячесе булалсын? Мин шушы сүзләрем белән, бер язучының да кәефен дә, абруен да төшерергә җыенмыйм, киресенчә, әдәбиятыбызның абруе, милләтнең киләчәге өчен борчылып язам. Әйдәгез, шушы мәсьәлә буенча уйлашыйк, бәлки юлы да табылыр, татар да бит юләр түгел.

Т. Әйди дә дөньялыкта борчылып йөрде милләт өчен, миңа да шуны васыять итеп калдырды. Күп мәкаләләр, китаплар язды, аларны укучыларга җиткерер өчен соңгы сулышынача тырышты. Ә бүген андый фидакарьләр бармы, күпме икән алар?

Менә нинди проблеманы күздә тотып язуым иде, ачуланмагыз агай-эне, чөнки укучы белән язучы гына белә әдәбиятыбызның чын хәлен, мин укучы буларак кына шушы темага кагылырга булдым. Җитмәсә, матбугатта шушы мәсьәлә буенча бер аналитик язма юк. Әллә инде проблема юк дип, күз йомып яшәргә өйрәнеп беткәнбез, әллә, бездә андый язучы әлегә тумаган. Тумаган булса, бәлки ул бездә беркайчан да тумаячак та, чөнки сазлыкта балык үрчеми, бака гына үрчи. Ә ничек сайрый диген, бигрәк тә, язгы җылы кичләрдә?

**М. МИНАЧЕВ,**
*Мәскәү.*

\+

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Фәридә Ситдикова



*Ситдикова Фәридә Бижан кызы 1959 елда Казанда университет укытучылары гаиләсендә туа. Әнисе—күренекле тел галиме, профессор Флера Сафиуллина. Фәридә Ситдикова күпкырлы белем иясе: башта ул Казан университетында гамәли математика һәм кибернетика буенча белем алып, инженер-программист булып эшли, соңрак Казан педагогия институтының чит телләр факультетын инглиз теле буенча белгеч булып тәмамлый. "Физика" башлангычын "лирика" җиңеп, Фәридә филология, әдәбият дөньясына керен китә. Хәзерге вакытта аның төп иҗади шөгыле—тәрҗемә эше. Ул бүгенге язучыларыбызның байтак әсәрләрен (Т. Галиуллин—"Тәүбә", Ф. Латыйфи, Р. Якуш—"Тамга", Н. Гыйматдинова—"Хикәяләр" һ. б.) татарчадан русчага тәрҗемә иткән кеше. Аерым тәрҗемә китапларыннан тыш, "Идел", "Чаян" кебек журналларда аның күпсанлы тәрҗемәләре дөнья күрде. Татарстан китап нәшриятында чыккан "Татарские народные сказки" китабының рус телендә чыгуында аның да өлеше зур.*

*Татарстан Язучылар берлеге каршындагы тәрҗемәчеләр остаханәсе тәкъдиме һәм Кабул итү коллегиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә бирүчеләр—В. Корчагин, Р. Кожевникова, С. Малышев) шушы елның февраль аенда Фәридә Ситдикова Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.*

## Аяз Хәсәнов



*Хәсәнов Аяз Гәрәфетдин улы 1960 елда Красноярск крае Агинский районының Симонова авылында (язучы Гәрәф Хәсәновның сөргендә яшәгән җире) туа. Аяз башта Казанның 96нчы урта мәктәбен, 1983 елда Культура институтын тәмамлый. Яшь белгеч берничә ел Культура министрлыгы каршындагы фәнни-методик үзәктә эшли, соңрак төрле газета-журналларда ("Известия Татарстана" газетасында корреспондент, "Татарстан" журналында баш мөхәррир урынбасары) хезмәт итә. 1998 елдан ул—"Татар-информ" агентлыгының баш мөхәррире.*

*Аяз Хәсәнов иҗат эше белән мәктәп елларыннан бирле актив шөгыльләнә. 1978 елны Татарстан китап нәшриятында "Белая вода" исемле беренче китабы чыкканда аңа 18 яшь була. Ул М. Пришвин, В. Бианки, Г. Хәсәнов традицияләрен дәвам итеп "Табигатьнең җанын" аңларга тырышып иҗат итүче язучы. Соңгы елларда А. Хәсәновның "Легенды нехоженных троп", "Где живут лесные тайны", "Зәңгәр алан", "Занимательная биология" дигән китаплары дөнья күрде.*

*2004 елның февралендә Аяз Хәсәнов Татарстан Язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—К. Миңлебаев, М. Зарецкий, Н. Ахунова) әгъза итеп кабул ителде.*


# *«Казан утлары» архивыннан*



*Бөек Ватан сугышында катнашкан язучылардан бер төркем. Сулдан уңга, беренче рәттә— Н. Арсланов, Г. Иделле, М. Садри, Р. Ишморат, Ә. Исхак, Г. Галиев, Х. Госман, С. Баттал; икенче рәттә—Ш. Шаһгали, Ә. Еники, М. Мазунов, М. Хөсәен, И. Нуруллин, А. Расих, С. Сабиров, Ә. Кәримуллин, Б. Гыйззәт; өченче рәттә— Н. Дәүли, С. Шәкүров, Ә. Маликов, К. Латыйп, М. Насыйбуллин. 1985 ел.*



*Үткән гасырның 50-70 елларында халык арасында популяр булган күп кенә җырлар авторы—композитор Фәтхерахман Әхмәдиев. 60 еллар фотосы.*



*Язучы Газиз Кашапов-Үзиле. Чаллы. 1985 ел.*



*Китапханәдә укучылар белән очрашу. Сулдан уңга—Рәшит Әхмәтҗанов, Рәшит Гәрәй, Әхмәт Рәшитов. 1982 ел.*



*Украинада яшәп иҗат итүче татар рәссамы Рафаэль Мәсаутов. 1986 ел.*



*Айдар Хәлим—Гаяз Исхакый премиясе лауреаты. 2003 ел.*

*Котлыйбыз*

## Шагыйрә Энҗе Мөэминовага 80 яшь

Шагыйрәләрнең яшен язмаскадыр, бәлки? Шагыйрьләр картаймый, диләр бит. "Энҗе-алмазлар югалмас һәм ятып калмас—үтәр" дип язган иде Дәрдмәнд тә. Яшьлеге авыр сугыш елларына туры килгән Энҗе ханымның күңелендә җыр-шигырьнең энҗедәй кадерле бөртекләре әнә шул чорда ярала. Укытучы хезмәте һәм иҗат... Мәктәп, балалар дөньясы һәм замандашлары, үз буыны турында уйлар. Әнә шулардан "Ефәк яулыгым" поэмасы дөньяга килә, шул исемдәге китабы басылып, шагыйрәне укучыга таныта. Язучылар берлегенә алына ул, яңадан-яңа китаплары, нәниләргә һәм зурларга атап язган шигырьләре дөнья күрә, укытучыга багышланган җырына канат куела. Аннан —башка җырлар, туган ил, туган тел белән бәйле уйлар, сурәтләр... Озын-озак гомер, хезмәт, дәвамлы иҗат еллары—шагыйрәнең бәхете әнә шул!

Олуг юбилее белән котлап, шагыйрәнең киң билгеле берничә шигырен тәкъдим итәбез.

### Туган илем минем

**Кулым тисә, туфрак алтын була,**
**Тирем тамса, шыта гөл булып.**
**Күңелемдә туган җылы хисләр**
**Яңгырыйлар матур җыр булып.**

**Җиргә бассам, артадыр егәрем,**
**Күкрәк киереп иркен тын алам.**
**Туган илем минем — газиз җирем,**
**Мин бәхетле синең бер балаң.**

### Бәхет гөлем

**Бәхет гөлем дип карыйм мин**
**Бакча сиреньнәремә,**
**Бәхетемне яшергән ул**
**Чәчәк бөреләренә.**
**Таҗларын саныйм әле:**
**Берәү, икәү, өчәү, дүртәү—**
**дүрт кенә!**
**...Юк кына биш тармаклысы—**
**юк кына!**

**Чәчәк таҗлары тоела**
**Өмет йолдызы булып.**
**Бәхетемне яшергәндер**
**Яшел каурыйлы болыт.**
**Тагын бер саныйм әле:**
**Берәү, икәү, өчәү, дүртәү—**
**дүрт кенә.**
**Берәү, икәү, өчәү... бишәү—**
**табылды!—**
**Кабынды өмет йолдызым, кабынды.**

### Туган телем

**Дөньяда иң-иң матур ил**
**Ул—минем туган илем.**
**Дөньяда иң-иң матур тел**
**Ул—минем туган телем.**

**"Балам!"—диеп, туган телдә**
**Эндәшә миңа әткәм.**
**"Әнием!"—дип, әнкәемә**
**Мин туган телдә әйтәм.**

**Туган телемдә сөйләшеп,**
**Яшим мин туган илдә.**
**"Туган ил" дигән сүзне дә**
**Әйтәм мин туган телдә.**

**Иң изге хисләремне мин**
**Туган телдә аңлатам.**
**Шуңа күрә туган телне**
**Хөрмәтлим мин, яратам.**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАНЫШ ДЕПУТАТЛАРЫБЫЗ

Татарстан Дәүләт Советына март аенда булып үткән сайлауларда безнең дүрт язучыбыз янадан депутат булып сайланды. Бу язучыларның беренче тапкыр гына депутат булулары түгел, алар берничә чакырылышта халык вәкиле булып сайланганнар иде инде. Разил Вәлиев, Роберт Миннуллиннарның 1990 елдан бирле, ягъни дүртенче тапкыр депутат булулары, Туфан Миннуллинның да дүртенче тапкыр (үз вакытында СССР Югары Советы депутаты булган иде) сайлануы. Фоат Галимуллинның икенче тапкыр сайлануы. Т. Миннуллин, Р. Миннуллин, Ф. Галимуллиннар депутатлыкка "Бердәм Россия" партиясе исемлеге аша, ә Р. Вәлиев Түбән Кама төбәгеннән—25нче бер мандатлы округтан сайлаулар аша үтте. Боларга өстәп, каләмдәшләребез арасында тагын бер депутат бар: ул—Татарстан журналистлар берлеге рәисе, "Татар-Информ" агентлыгының элекке генераль директоры Римма Ратникова. Ул яңа чакырылышның беренче сессиясендә Татарстан Дәүләт Советы рәисенең урынбасары итеп сайланды.

Котлыйбыз, эшегездә уңышлар телибез, хөрмәтле каләмдәшләр!

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Татарстан язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышы булып узды. Анда башкалабыз Казанда, республикабызның шәһәр һәм районнарында, аерым алганда, Әлмәт һәм Чаллы төбәкләрендә, шулай ук чит өлкәләрдә яшәп иҗат итүче каләм әһелләре катнашты.

Иң әүвәл язучыларыбыз ике җыен арасында вафат булган каләмдәшләребезне бер минут тынлык белән искә алдылар. Аннары идарә рәисе Фоат Галимуллин танылган шагыйрь һәм публицист Рафикъ Юныска—Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләге, танылган тәнкыйтьче һәм публицист Рафыйк Шәрәфиевкә Ж. Вәлиди исемендәге бүләк дипломнарын тапшырды.

Рәис Фоат Галимуллинның кереш чыгышында узган елгы әдәби тормышыбызда байтак эшләр башкарылуы бәян ителде. Эшләмәгән эшләр, чыннан да, аз түгел. Әлбәттә, бу хисап киләчәктә язучылар алдында торган зур эшләрне дә күзаллау булды.

Төрле әдәби жанрлар буенча докладлар белән Зиннур Мансуров (шигърият), Мәдинә Маликова (проза), Җәүдәт Дәрзаман (балалар әдәбияты), Лилия Газизова (рус әдәбияты), Рифә Рахман (тәнкыйть) чыкты. Аннары Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамов чыгыш ясады.

Фикер алышуларда Равил Фәйзуллин, Харрас Әюп, Хәнисә Алишина (Төмән), Аркадий Мельников, Рәшит Ягъфәров, Гафур Каюмов, Марсель Галиев, Шәүкәт Гаделша, Фәрит Хәбибуллин, Нурислам Хәсәнов, Рашат Низами, Саимә Ибраһимова, Лена Шагыйрьҗан һәм Мөдәррис Әгъләм катнашты. Чыгыш ясаучыларның гамендә ил-көн, тормыш, тел, әдәбият мәсьәләләре иде. Бүгенге мәдәни тормышыбызның хәле, аерым алганда, хәзерге шартларда әдәбиятка булган мөнәсәбәт уңаеннан күпләр үзләренең борчылулы уй-фикерләрен белдерде. Чыгышларда китап сату эшенең ныклы нигезгә куелмавы, шул рәвешле, аның киләчәккә төбәлгән зур тәрбияви максатлар үтәлешен куркыныч астына куюы уртак фикер буларак яңгырады. Язучыларның матди хәле дә дәүләт югарылыгында кайгыртуга мохтаҗ.

Фикер алышу барышында сүз, нигездә, көнүзәк проблемалар турында барды: милли идея әченә кертеп карала торган дәүләтчелек мәсьәләләре, туган телебезне чын мәгънәсендә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү зарурлыгы, республикадан читтә яшәүче милләттәшләребезнең хокукларын яклау, әдәбиятыбызның иң яхшы үрнәкләрен дөнья укучыларына тәкъдим итү... Аерым чыгышларда киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәрдәй саллы әсәрләрнең сирәгрәк иҗат ителүе дә искәртеп үтелде. Драматургия һәм публицистика буенча докладларның булмавы да җыелышта катнашучыларда канәгатьсезлек тудырды.

Әдәби елга йомгак ясалды, әмма әдәби тормыш дәвам итә. Каләм ияләрен алда зур иҗат һәм оештыру эшләре көтә. Быел Татарстан Язучылар берлеге үзенең 70 еллыгын билгеләп үтәчәк. Бу уңайдан күп кенә әдәби-мәдәни чаралар үткәрү күздә тотыла. Ә инде киләсе елда республикабыз язучылары чираттагы корылтайга җыелачак.

## ТАТАРСТАНДА ЧУАШ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

23-25 мартта Татарстанда Чуаш әдәбияты көннәре булып узды. Үткән елның апрель башында Чуашстанда Татар әдәбияты көннәре үткәрелгән иде. Шушы бәйрәм тантанасы алдыннан Хөкүмәт йортында Татарстан Мәдәният министрлыгы белән Чуашстан Мәдәният

һәм милләтләр эше министрлыгы арасында мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә дә кул куелды. Һәм менә чуаш дусларыбыз безнең республикага җавап визиты белән килде. Чуашстан мәдәният һәм милләтләр эше министры Ольга Денисова җитәкчелегендәге делегация составында Чуашстан профессиональ язучылар берлеге рәисе Валерий Тургай, Чуашстанның халык шагыйрьләре Порфирий Афанасьев, Юрий Семендер, шагыйрәләр Раиса Сарби, Нина Артемьева, Язучылар оешмасының рус секциясе җитәкчесе Виктор Овчаров, җырчылар Вячеслав Вахтеркин, Юлия Юнисова һ.б.лар бар иде.

Беренче көнне төштән соң кунакларны Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов кабул итте.

Кичен "Казан" милли мәдәният үзәгендә Чуаш әдәбияты көннәрен ачу тантанасы булды. Анда Татарстан Дәүләт Советы исеменнән сәламләү сүзе белән шагыйрь Роберт Миннуллин чыкты. Аннары кичәгә җыелучыларны Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Рафаэль Вәлиев белән Чуашстан мәдәният һәм милләтләр эше министры Ольга Денисова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин белән Чуашстан профессиональ язучылар берлеге рәисе Валерий Тургай сәламләде. Кичә барышында шулай ук күренекле шагыйрьләр Раиса Сарби, Гәрәй Рәхим, Порфирий Афанасьев, Ренат Харис, Юрий Семендер һ.б.лар чыгыш ясады. Каләм әһелләренең сүзе Чуашстан һәм Татарстан сәнгать осталарының чыгышлары белән аралашып барды.

Икенче көнне чуаш һәм татар язучыларыннан торган ике төркем Аксубай, Нурлат һәм Чирмешән районнарында булды. Кунаклар чуаш авылларында күмәк хуҗалык хезмәтчәннәре һәм мәктәп укучылары белән очрашты, җирле музейлар һәм истәлекле урыннар белән танышты.

Әдәбият бәйрәменең соңгы көнендә Чабаксардан килгән кунаклар башкалабыз зиратларында чуаш мәгърифәтчеләре каберләренә чәчәк салдылар. Аннары Халыклар дуслыгы йортында "Әдәбият—дуслык илчесе" дип исемләнгән "түгәрәк өстәл" янында сөйләшү булды. Анда Татарстан ягыннан—Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Ф. Галимуллин, Р. Низамиев, З. Мансуров; Чуашстаннан—Ю. Семендер, В. Тургай, П. Афанасьев, Р. Сарби һ. б. чыгыш ясады. Алар ике туган-даш халык арасындагы әдәби-мәдәни бәйләнешләрне тагын да ныгыту җәһәтеннән үзләренең уй-фикерләре белән уртаклаштылар.

## ИҢ ЯХШЫ ПЬЕСАЛАР АЧЫКЛАНДЫ

27 мартта Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында "Театр көне"нә багышланган кичә узды. Артист Ильяс Кудашев-Ашказарскийның 120 еллыгы уңаеннан аның иҗаты хакында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова сөйләде. Г. Кариевнең "Артист" һәм Н. Исәнбәтнең "Гөлҗамал" спектакленнән өзекләр күрсәтелде.

1926 елда нәшер ителгән "Татар театры" китабын Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Әнвәр Хәйри бүгенге имлага күчереп эшләгән. Кабат дөнья күргән җыентыкны Әнвәр әфәнде тәкъдир итте.

Аннан соң дулкынландыргыч мизгелләрне драматурглар һәм күпсанлы тамашачылар көтеп алды. "Татар пьесасы" конкурсының йомгаклары игълан ителде. Иң элек жюри рәисе Миркасыйм Госманов сүз алды. Ул 111 пьесадан 14 е җыентыкка сайланып алынуы турында хәбәр итте.

Беренче урын Зөлфәт Хәкимгә "Телсез күке" пьесасы өчен бирелде (200 мең сум).

Икенче урынга Ркаил Зәйдулла белән Рөстәм Сабиров ("Хөкемдар") ия булды (100 мең сум).

Өченче урынга Равил Бохараев ("Тимер борчак") лаек дип табылды (75 мең сум).

Иң яхшы инсценировка авторы—К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы Тәслимә Халәф (Фәйзуллина) (150 мең сум). Ул Н. Гыйматдинованың "Утка очкан күбәләктәй" дигән әсәрен сәхнә әсәре итеп эшләгән.

Рабит Батулланың "Җимерелгән бәхет", Айдар Хәлимнең "Пәри туе", Аманулланың "Бер кирпеч, ике кирпеч...", Эсфир Яһудинның "Бер кояш астында", Ләйсән Гәрәеваның "Көтелмәгән кайгы", Разия Гарифуллинаның "Әйтелмәгән васыять" пьесалары махсус бүләкләргә ия булдылар. "Җыен" фонды Мәдинә Маликованың "Сөембикә", Батулланың "Ана каргышы", З. Хәкимнең "Бит" дигән әсәрләре өчен 10 ар мең сум акча тапшырды.

Мәдәният министрлыгы озак еллар сәнгатькә хезмәт иткән шагыйрь Илдар Юзиевның, Президент аппараты каршындагы мәдәниятне яклау фонды Г. Зәйнашеваның хезмәтләрен дә бәяләп үз бүләкләрен бирде.

Р. Батулланың "Җимерелгән бәхет" пьесасын "Казан утлары" журналында бастырырга, "Юл газабы"н радиога яздырырга, Ләйсән Гәрәеваның "Көтелмәгән кайгы"сын телевизион спектакль итеп эшләргә тәкъдим ителде.

Салават Фәтхетдинов "Тутык кыңгырау" әсәре өчен Фәнәвил Галиевка махсус бүләк тапшырды.

"Татар пьесасы" конкурсының төп спонсоры—"Татэнерго" берләшмәсе булды.

## МЕҢЬЕЛЛЫКНЫҢ СИМВОЛЫ САЙЛАНДЫ

Ниһаять, Казанның меңьеллыгын нинди эмблема белән бәйрәм итәчәгебез дә билгеле булды. Бу атнада башкаланың юбилеена иң яхшы символ конкурсына йомгак ясалды.

Жюри бертавыштан профессиональ дизайнер Айрат Халитовны җиңүче дип таныды. Аның эше башкалабыз юбилееның рәсми эмблема-символы дип игълан ителде.

"Мин эмблеманың сигез вариантын эшләдем, ләкин бу конкурска шуларның өчесен генә тәкъдим иттем. Аларны әзерләү өчен

мина ун көн кирәк булды",—ди Айрат Халитов.

Тиздән символиканы файдалану тәртибе дә булдырылырга тиеш. Аны махсус комиссиянең рөхсәтеннән башка куллану мөмкин булмаячак.

Конкурска тәкъдим ителгән башка эшләрне башкаланың Милли музеенда карарга мөмкин. Җиңүче эмбleманы Казан шәһәре хакимиятенең рәсми сайтында да урнаштыралар.

## "КАЗАНГА—1000 ЕЛ" ЭКСПОЗИЦИЯСЕ

24 мартта Мәскәүнең Федераль архивлар күргәзмә залында "Казанга—1000 ел" экспозициясен ачу тантанасы булды. Әлеге уңайдан үткәрелгән матбугат конференциясе Россия һәм чит ил гаммәви мәгълүмат чараларының күпсанлы журналистларын җыйды.

Россиянең борынгы актлар архивы директоры Михаил Рыженков, Федераль архив агентлыгы җитәкчесе Владимир Козлов, ТР мәдәният министры Илдус Тарханов, Казан мэры Камил Исхаков, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе җитәкчесе Дамир Шәрәфетдинов һәм башкалар, журналистларга күргәзмә оештыру фикеренең тууы, аны гамәлгә ашыру, Татарстан башкаласының 1000 еллык юбилеена әзерләнү турында сөйләделәр. Алар һәммәсе Казан тарихына караган мондый киң колачлы күргәзмәнең беренче тапкыр үткәрелүен билгеләп үттеләр.

Күргәзмәнең өч залында 360 уникаль экспонат куелган. Нигездә, алар—бәһасез төп нөсхәләр: Борынгы Болгар турында археологик казылмалар һәм документлар, Казанның яшен билгеләргә ярдәм иткән чех тәңкәсе күчермәсе, урта гасыр татар әдәбиятының күренекле истәлекләре—Кол Гали, Хисам Катыйб поэмалары, Хисаметдин Мөслиминең "Болгар тарихы" язмалары, Казан Кремленең төзелүе, бистәләре һәм Казан халкы турында мәгълүмат бирүче 1565—1568 елларның кульязма китабы...

Май аенда бу күргәзмә Казанга күчәчәк, тарихыбыз белән кызыксынган кешеләргә аның белән ныклабрак танышу мөмкинлеге булачак.

## ПАРКНЫҢ ИСЕМЕ—"ШҮРӘЛЕ"

Булачак "Шүрәле" паркының беренче җиһазлары Италиядән Казанга кайтарылды. Паркны быел җәен ачу күздә тотыла.

Парк Татарстан башкаласы үзәгендә—Кремль транспорт дамбасы тирәсендә—Казансу ярында урнашачак. Проект бик үзенчәлекле—монда эшләячәк аттракционнарга Идел буенда тиңнәр юк. Аттракционнарның җиһазлары халыкара стандартларга туры килә һәм техниканың соңгы казанышларына җавап бирә. Ул житештерүче—Италиянең "SBF-VISA Group" компаниясе җитәкчелегендә монтажланачак.

Эшне башкаручылар нияте буенча аттракционнар өч зонада тупланачак: "Экстрим", "Гаилә" һәм "Балалар". "Экстрим-зона" үтә кызык күренешләрне яратучылар таләпләрен канәгатьләндерәчәк. Аларны биредә 32 урынга исәпләнгән гигант таганнар, 11 метр биеклектә эленеп торучы "Пират" гондоласы, "Торнадо" шуу тавы ("Америка таулары"на охшаш) һәм Казан өчен яңалык—17 метр биеклектәге ирекле очыш манарасы көтә.

"Гаилә" зонасындагы приз аттракционнары комплексында таганнарда, 19 метр диаметрлы авышлыктагы чылбырлы каруcельдә һәм "Кенгуру" сикерү манарасында күңел ачарга мөмкин.

"Балалар зонасы"нда бала-чаганы күп сандагы аттракционнар көтә.

Паркта "Күзәтү тәгәрмәче" үзәк урынны алып торачак. Ул Кремльнең панорамасын гына түгел, Иделнең каршы як ярын күзәтү мөмкинлеге дә бирә. Ул—иң зур аттракцион булачак. Аның биеклеге—55 метр. Ә Горький исемендәге үзәк парктагы "Күзәтү тәгәрмәче"нең биеклеге 22 метр иде.

## ГАЛИМНӘР ХИСАП ТОТТЫ

Татарстан Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышы 2003 елгы гыйльми эшчәнлекнең төп йомгакларына һәм алдагы хәл итәсе проблемаларга багышланган иде.

Галимнәр алдында ТР Фәннәр академиясе президенты, академик Мансур Хәсәнов хисап докладь белән чыкты. Шулай ук баш гыйльми сәркатип, академик Илдус Хәйбуллинның өстәмә докладь тыңланды.

Татарстан Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышында Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады.

Җыелышта шулай ук вице-премьер Зилә Вәлиева катнашты.

## САБАНТУЙ—ДӨНЬЯКҮЛӘМ БӘЙРӘМ

Узган ел халкыбызның милли бәйрәме—Сабантуйлар Россиянең татарлар күпләп яши торган 43 төбәгендә гөрләп узды. Быел андый төбәкләр тагын да артырга тиеш. 16-17 март көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы ТР Мәдәният министрлыгы белән берлектә кырыктан артык төбәктән килгән 120 делегат катнашында семинар үткәрде. Аның максаты—Россиянең төрле төбәкләрендә милли бәйрәмне бөтен гореф-гадәтне саклап дөрес үткәрергә өйрәтү, юнәлеш бирү иде. Нәкъ менә Сабантуй үзенең элек-электән килгән гореф-гадәтләре белән кешеләрне ярыштырып кына калмаган, ә гаделлеккә, инсафлыкка, башкаларны хөрмәт итәргә дә өйрәткән бит.

Казанда үткән семинарда күп кенә төбәкләрдән әлеге бәйрәмне оештыручы-режиссерларның да катнашуы быел җәй Сабантуй тагын да күркәмрәк үтәр дигән ышаныч тудыра.

## ТАТАР КИТАБЫ—МӘСКӘҮДӘ

10-15 мартта Мәскәүдә "Россия китаплары" дип аталган милли күргәзмә-ярминкә узды. Анда Татарстаннан "Татмедиа" агентлыгы күрсәтмәсе буенча Татар китабы берләшмәсе, "Идел-Пресс" басмаханәсе, милли "Мәгариф" һәм Татарстан китап нәшриятлары, полиграфия комбинаты вәкилләре катнашты. Аларның максаты—республикабызда чыккан әдәбиятны Мәскәүдә пропагандалау. Күргәзмәгә алып барылган меңгә якын китап арасында—Татарстан һәм татар халкы тарихына караган басмалар, сүзлекләр, фәнни хезмәтләр, матур әдәбиятның классик үрнәкләре... Мондый күргәзмәләрдә Татарстан элегрәк елларда берничә мәртәбә катнашкан иде инде.

## ШӘМАИЛ ДИГӘН БАЙ ДӨНЬЯ

Мәскәүдә узган "Россия китабы—2004" күргәзмә-ярминкәсе кысаларында башкаланың Җәмигъ мәчете конференцияләр залында сәнгать фәннәре кандидаты Рөстәм Шәмсутовның "Татар шәмаилендә сүз һәм образ: үткәннән бүгенгә кадәр" исемле китабы тәкъдир ителде.

Әлеге чараны Татарстан китап нәшрияты республикабызның Россия Федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиллеге һәм Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте ярдәме белән оештырды. Биредә шулай ук Нәҗип Нәккаш, Әлфия Хәлиуллина, Рушан Шәмсетдинов, Рөстәм Шәмсутов кебек рәссамнарның шәмаилләреннән торган күргәзмә дә эшләде.

Тәкъдир итү кичәсендә Татарстанның Россия Федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Алмаз Фәйзуллин, тарих фәннәре докторы Абделхан Әхмәтҗан, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, Мәскәүнең татар иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнашты.

## ЯШӘСЕН ТАТАРСТАН РАДИОСЫ

Знче апрельдә Азнакайда Татарстан радиосы хезмәткәрләренең нефть төбәге радиотыңлаучылары белән очрашуы булды. Анда "Татарстан" радиосы җитәкчесе Тәуфикъ Сәгыйтов, җаваплы хезмәткәрләр: Җәүдәт Дәрзаман, Рафаэль Ильясов, Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет), Рәзин Нуруллин һәм баянчы, Татарстан дәүләт педагогия университеты профессоры Рәгъдә Халитов катнашты.

Радиотыңлаучылар белән экчерсез, җанлы әңгәмә рәвешендә барган бу кичәдә алар радио эшчәнлеге турында сөйләделәр, үзләренең һөнәри осталыкларын күрсәттеләр, иҗат үрнәкләре белән таныштырдылар.

Кичәдә катнашкан Азнакай районы хакимияте башлыгы, шагыйрь Әнәс Исхаков һәм чыгыш ясаган төрле район вәкилләре 76 ел тарихы булган "Татарстан" радиосының төрле дәверләрдә дә, төрле катлаулы чорларда да үз абруен югары тотуын һәм радиотыңлаучыларның иң яраткан радиосы булганын ассызыклап үттеләр һәм аның мәңге яшәвен теләделәр.

Азнакай һәвәскәрләре чыгышы белән тәмамланган бу кичә күтәренке бәйрәм рухы белән үтте. Моның өчен үзенә күрә матур сәбәп тә бар иде: берсе—танылган журналист Ясир Хөснетдиновның 50 яшьлек юбилее булса, икенчесе—Рөстәм Акъегетнең милли мәгарифне һәм татар халкының үзаңын үстерүдә күрсәткән фидакарь хезмәте өчен Бөгелмә татар җәмәгатьчелеге тарафыннан мәгърифәтче исеме һәм Һади Атласи бүләге бирелүе иде.

## ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП

Шагыйрь, тәнкыйтьче, тәрҗемәче, Муса Җәлил исемендәге премиянең узган елгы лауреаты Мөдәррис Вәлиев һәм шундый ук бүләкне ун еллар элек алган Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев Карадуганның Җәлил музеенда (Татарстанның Милли музее филиалы) һәм авылның мәдәният йортында укучылар белән очраштылар. Очрашуга Балтач район үзәгендә яшәүче танылган шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин да килде.

Кунаклар алдында Муса Җәлил шигырьләрен сәнгатьле уку буенча район укучылары арасында барган конкурска йомгак ясалды. Анда призлы урыннарны Норма һәм Карадуган урта мәктәпләреннән Рифнур Хафизов, Фирзәр Мәрданов, Гөлсинә Нуриева алды. Аннары Карадуган мәктәбе балалары, берсеннән-берсе остарак итеп, бүгенге очрашу кунагы Мөдәррис Вәлиевның шигырьләрен укыдылар.

Соңыннан Мөдәррис Вәлиев чыгыш ясап, каһарман-шагыйрьнең истәлеген кадерләп саклаган мирас йортына, аның иҗатын тырышып өйрәнгән балаларга сокылануын белдерде, шигырь уку осталарына үзе җитәкчелек иткән "Мәгариф" нәшриятының матурматур китапларын бүләк итте. Равил Шәрәфиев тә истәлекле очрашуга буш килмәгән иде: Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгында иҗат иткән шигырьләрен җанга үтәрлек сөйләп тыңлаучыларны сөендерде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан иртәсе. ***Н. Исмәгыйлев*** *фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Мөхәммәт Мирза.**

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Татар театры (1906-1926).** Коллектив. Тулыландырылган 2 нче басма.—Казан: “Мәгариф”, 2003. —308 бит. Тиражы—3000 данә.




Бу китап 1926 елда татар театрынын 20 еллык юбилеена багышлап нәшер ителгән зур күләмле һәм бай эчтәлекле мәкаләләр һәм истәлекләр җыентыгынын икенче һәм тулыландырылган басмасы. Биредә укучы, үзе өчен, театр сәнгатебезнең XX йөзнең беренче чирегендә шактый күп тармаклы булып, элеккеге СССРның күп төбәкләрендә, Идел буеннан ерактагы шәһәрләрдә дә, гөрләп торганлыгы турында күп кенә кызыклы мәгълүмат таба алыр. Җыентыкны басмага әзерләүдә һәм төзүдә шул чорның мәдәни тормышыбызда күренекле урын тоткан атаклы шәхесләребезнең һәм татар театрына нигез салып, аны аякка бастыруда биниһая күп көч куйган мәшһүр сәхнә осталарының актив катнашуы—аның әһәмиятен тагын да арттыра. Китап—сәнгать тарихы белән кызыксынучыларга һәм киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Китапка кереш сүзне академик М. Госманов язган.

**Равил Фәйзуллин. Калейдоскоп. Шигырьләр, поэмалар.**—Казан: “Рухият” нәшр. 2004. —640 бит. Тиражы—2000 мең.



Татар мәдәниятен, әдәбиятын пропагандалауда “Татнефть” карамагындагы “Рухият” нәшриятының өлеше зур. Соңгы 5-6 ел эчендә бу нәшрият халык күңеленә хуш килерлек дистәләгән исемдә китаплар, альбомнар, буклетлар бастырып чыгарды. “Бүгенге татар поэзиясе” сериясендә чыккан китаплар да унбиштән артык. Әле яңа гына бу сериядә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның калын томлыгы дөнья күрде.

“Өч кисәктән торган бу китапта беренче бүлек итеп “Кыска шигырьләр” урнаштырылган. Равил Фәйзуллин, мәгълүм булганча, кыска формалар остасы, алар шагыйрь иҗатының төп бер асыл сыйфатын билгелиләр. Икенче бүлектә балалар өчен язылган шигырьләр урын алды. Шагыйрьнең балалар өчен язылган әсәрләре чагыштырмача әлегә аз билгеле. Иҗаты инде дистә еллар буе мәктәп программаларына кертелеп, махсус өйрәнелә торган шагыйрь иҗатының бу юнәлешен калкурак күрсәтүне мәгъкуль булыр дип таптык. Өченче бүлеккә шагыйрьнең җәмәгатьчелектә киң билгеле поэмалары, монологлары, диалоглары кертелде”,—дип яза китапны төзүче-мөхәррир Галимҗан Гыйльманов. Китапны бизәүдә Татарстанның халык рәссаме Абрек Абзгильдин картиналарының иллюстрацияләре файдаланылган.

Индекс 73210



Мөхәммәт Мирза

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)